# Казан утлары

12. 1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

12

1986

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


Г. МӨХӘММӘДОВА. **Сикәлтәле туры юл.** *Документаль повесть* . . . . . . . . . . 3

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

С. ХӘКИМ. **Арча халкын беләм...** *Шигырьләр* 55

К. ТИМБИКОВА. **Тын бакчада.** *Повесть* . . . 60
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. **Сөю каршында.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . 98
С. ШӘМСИ. **Кала-тау өне.** *Повесть.* . . . . . . 102

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Н. МАТВЕЕВА. **Охшаш хәлләр.** *Хикәя.* . . . 124
М. МУСАЕВ. **Акчарлак.** *Хикәя.* . . . . . . 130
К. ВАСИН. **Җыр шулай туды.** *Легенда.* . . . 132

СҮЗ — ТУКАЙ КУНАКЛАРЫНА

М. КӘРИМ. **Олуг Тукай турында.** . . . . . 135
Н. ДОРИЗО. **Шагыйрь генә түгел.** . . . . . 136
С. КОШЕЧКИН. **Күңелдәге йолдыз.** . . . . 137
А. АРИПОВ. **Тукай хакында сүз.** . . . . . 138
Н. БАБУГЛЫ. **Шагыйрь.** . . . . . . . . 139

ЯЗУЧЫ СӘЯХӘТТӘН КАЙТТЫ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. **Хуш, Италия! Исәнме, Ватан!** 140

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Н. МОРОЗОВ. **Бәрелешләр аша.** . . . . . . 154

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

О. С. МӨХЕТДИНОВ. *(Азнакай)* **Чатыр-тауга чал кунмый.** . . . . . . . . . . . . 163

ТАТАР ТЕАТРЫНА 80 ЕЛ

И. ИЛЯЛОВА. **Халык хезмәтчесе булу** . . . . 167

К. ТИНЧУРИН. Мулланур иптәш Вахитов һәм татар театры . . . . . . . . . . . 171

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тормыш таләбе. *Әдәби тәрҗемә турында сөйләшү йомгаклары* . . . . . . . . . . 173

БИБЛИОГРАФИЯ

Н. МОРАДЫМОВ. Хезмәттәшлек җимешләре 177
Р. МОСТАФИН. Зиннәтле сүзләр хәзинәсе. . . 178
М. ГАИНЕТДИНОВ. Туганлык тамырлары 180

КОНКУРСКА

С. ХАФИЗОВ. Җаныгызга сукмак салыйм . . 182

1986 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. . . . . . . . . 185

Культура тормышы көндәлеге. . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр. . . . . . . . . . . 192

## В нашем номере

Документальная повесть Г. МУХАМЕДОВОЙ о жизни классика татарской советской литературы Г. Ибрагимова.
Последние стихи народного поэта ТАССР С. ХАКИМА.
Повести К. ТИМБИКОВОЙ «В тихом саду» и С. ШАМСИ «Эхо Кала-тау».
Стихи Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Дружба народов — дружба литератур». Рассказы Н. МАТВЕЕВОЙ, М. МУСАЕВА, К. ВАСИНА.
«Слово — гостям юбилея Тукая». Выступления М. КАРИМА, Н. ДОРИЗО, С. КОШЕЧКИНА, А. АРИПОВА, Н. БАБУГЛЫ.
Путевые записки Р. ФАЙЗУЛЛИНА «До свидания, Италия! Здравствуй, Родина!»
«Литературный пост журнала Тат. АЭС». Статья Н. МОРОЗОВА «Через «толкновения».
«Татарстан — родной мой край». Статья первого секретаря Азнакаевского райкома КПСС О. С. МУХУТДИНОВА.
Материалы к 80-летию татарского театра: статья И. ИЛЯЛОВОЙ «Служить народу», из литературного наследия — К. ТИНЧУРИН «М. Вахитов и татарский театр».
Итоги дискуссии о проблемах художественного перевода. В разделе «Библиография», рецензии Н. МУРАДЫМОВА, Р. МУСТАФИНА, М. ГАЙНУТДИНОВА и С. ХАФИЗОВА.
Содержание журнала «Казан утлары» за 1986 год.
На обложке — творчество художника В. Попова.

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИННУЛЛИН
ФӘНИС МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар —53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Минһаҗева.*

Производствога бирелде 30.09.1986 ел. Басарга кул куелды 20.11.1986 ел. ПФ 05427. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62449. Заказ В-394. Бәясе 90 тиен

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

Гөлсем Мөхәммәдова

# СИКӘЛТӘЛЕ ТУРЫ ЮЛ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ



Киевтә, хатын-кызлар өчен ачылган гали курсларда укучы курсистка Гөлсем Әхтәмова бүлмәсендә егермедән артык студент җыелган. Гөлсем уртача буйлы, нечкә билле, шаян күзле сылу туташ Уфаның мәшһүр бае мирза Абдусәгать Әхтәмовның кызы һәм Дәүләт Думасына депутат булып сайланган адвокат Ибнеәмин Әхтәмовның бертуган сеңлесе иде. Бала вакытыннан ук бай тормыш шартларында тәрбияләнеп, үз кәефе, үз рәхәте өчен генә яшәргә өйрәнгән кыз. Киевкә килеп студентлар арасына катнаша башлагач, кавказлы егет Ордубатский белән таныша һәм аның киңәше буенча Киев мөселман студентларының якташлык оешмасына керә. «Без халкыбызның авангарды булырга тиеш, аны тәрәккый иттерергә, аңа юл күрсәтергә тиешбез!» — дигән кебек буш, купшы сүзләрдән ары китмәгән нотыклар сөйләнә торган җыелышларны ул үз бүлмәсендә үткәрә, шул җыелышларның беркетмәләрен язып бара. Болар барысы да аның өчен этисенең утарында «амазонка» дигән киемнәр киеп, атка атланып йөргәндәге кебек кызык бер яңалык булып тоела.

Гөлсем туташ белән Хәлләдән башкаларның чем-кара чәчләре, мыеклары һәм кашлары, кәкрәеп килгән борыннары, акцентлары бүлмәдәгеләрнең кавказлы егетләр икәнен әйтеп тора иде.

Еникеев белән Ордубатский тәрәзә төбенә утырганнар. Болар арасында ниндидер җитди әңгәмә бара. Дулкынланып торган кара чәчләре, озын кара керфекләре арасыннан ягымлы караган күзләре Ордубатскийны артистка охшаталар. Аның тавышы, сөйләшүе дә нәкъ артистларча. Ул сөйли башлადымы, бүлмәдәге шау-шуны баса да китә.

— Бу фикерегезгә тулысынча кушылам, Хәлиулла әфәнде, без халкыбызның алдынгы сафында торган затлар белән элемтә тотарга тиешбез. Сез менә, укучыларның тормыш шартларын яхшырту өчен «җәмгыяте хәйрия» төзегән Фатих Кәрими кебек затлар, Фатих әфәнде Әмирхан, Габдулла әфәнде Тукай, Галимҗан әфәнде Ибраһимов кебек халыкны мәгърифәткә чакырган кешеләр, Ямашев әфәнде кебек халык бәхете өчен көрәшүчеләр бар дисез. Без — кавказлылар арасында да мондый затлар бар. Мисал өчен Нәриман бәк Нәриманов, Сөләйман бәк Ахундов, Әбдерәхим бәк Ахвердов һәм шулар кебек башкаларны күрсәтергә мөмкин. Якташлык җәмгыятебезне Мәгариф министры тасдыклаган көннән

---

Ахыры. Башы 11 нче санда.

без, студентлар, мөселман галәменең шундый тәрәккый пәрвәр затлары белән элемтәгә керербез, әлбәттә!

Стенага терәп куелган өстәл тирәсендә, башын артка ташлап, маэаеп, Гөлсем туташ белән янәшә бер студент утыра. Председатель урынында утырган киң кара кашлы, тар маңгайлы бу егет, Талышинский, бүлмәдәге спай киемле студентларның барысыннан да купшырак күренә. Гөлсем туташ кулыннан бер кәгазь алып укыганнан соң, ул аягүрә басып, карандаш белән алдындагы графинга какты. Тавыш-тын басылгач:

— Мәҗлесне башларга вакыт,— диде.— Идарә әгъзаларыннан тыш, якташлык оешмабызның иң эшчән кешеләре дә килгән. Бу — бигрәк тә яхшы. Бүген без ике гариза буенча карар чыгарырга тиешбез. Берсе Ахундов әфәндинең гаризасы. Ул «Коперник һәм аның тәгълиматы» дигән брошюраны мөселманчага тәрҗемә иткән. Шуны бастырып таратыр өчен йөз илле манат акча сорый. Икенчесе — студент Асанов гаризасы. Аның Шемахыда яшәгән бабасы вафат олмыш. Бабасын җирләргә барыр өчен егерме манат ярдәм сорый. Бу ике гариза буенча сөйләргә теләүчеләр бармы?

Ордубатский тәрәзә төбеннән сикереп төште:

— Миңа рөхсәт итегез! Беренче гариза буенча мин бер-ике сүз әйтергә телим.

— Рәхим итегез,— диде председатель.

Студентлар арасында җиңелчә хәрәкәт булып алды. Алар Ордубатскийның сүзгә осталыгын беләләр. Шуның өчен кызыксынып тыңларга әзерләнүләре иде. Ордубатский сөйли башлады:

— Безнең уставның бүгенгәчә расланмаганын барчагыз да беләсез. Ләкин уставыбыз расланмаган дип без кул кушырып утырырга тиешме? Юк, әлбәттә! Шуны онытмаска бурычлыбыз: уставыбызда «без — мөселман халкының алдынгы сафында торган мөселман студентлары,— рухи бөлгенлеккә төшерелгән, наданлыкка мәхрүм ителгән халкыбыз арасында аң-белем таратып, аны мәгърифәткә алып бару юлында хезмәт итәргә тиешбез»,— дип язылган. Ахундов әфәндинең тәрҗемә иткән әсәренә килсәк, бу — безнең максатларга туп-туры алып бара торган китапларның берсе икәнен күрәбез! Әгәр чын-чынлап халкыбызга хезмәт итәргә теләсәк, мондый әсәрләрне бастырып тарату юлында акчаны кызганмаска кирәк! Халкыбыз арасында белем, мәгърифәт тарату — безнең иң беренче мөкатдәс бурычыбыз! Мин, оешмабызның хәзинәдары буларак, Ахундов әфәндинең үтенечен кире какмаска кирәк дим!

Бу юлы Ордубатскийның чыгышы көтелгәнчә үк көчле һәм матур булмаса да, студентлар төрле яктан аны куәтләделәр:

— Әлбәттә бирергә!

— Мондый эшкә акча кызганмаска кирәк! — диделәр.

Ордубатский сөйләгән вакытта урынында тыныч утыра алмыйча кыбырсыган Еникеев, дустының сүзен бүлеп, үзе сөйли башлар дәрәҗәгә килгән иде. «Менә бит, Галимҗан да, Зураб та, Агаш та бу егетләргә ышанмыйлар, бик сак булырга, сынарга кирәк, дигән булалар. Ә бу яшьләр халык бәхете юлында җаннарын фида итәргә хәзер торалар»,— дип уйлый иде ул. Инде башкаларның да Ордубатскийның фикеренә кушылганын ишеткәч, чыдамы калмады, кулын күтәреп, утырган урыныннан сикереп торды. Талышинскийның рөхсәтен дә көтмичә, бүлмә уртасына атылып чыгып, сөйли башлады:

— Фирүз бәк Ордубатскийның сүзләрен шатлык белән тыңлап утырдым. Бөтен күңелем белән аның әйткәннәренә кушылам! — дип, уң кулын күкрәгенә куеп, Ордубатскийга таба башын иде һәм сүзен дәвам итте: — Инде мәҗлестәге башка әгъзалар да аны хуплагач, шатлыгым чиктән ашты. Бу хәл безнең мөселман студентларының халыкка хезмәт итәр өчен өлгергәнлеген, җитешкәнлеген ачыктан-ачык күрсәтә! Шулай! Наданлык, җаһиллек, кыерсытылу, изелү — халкыбызның бүгенге көндәге язмышы менә шул! Мин сездән шуны сорыйм: ни өчен алай?!

Студентлар гөрләшеп алдылар. Соравына җавап көткән төсле булып, Еникеев аз гына туктап торды. Соңыннан башын селкеп, күз өстенә төшкән чәчләрен артка ташлады да, тагын сөйләп китте:

— Әгәр дикъкать белән тирә-ягыбызга карасак, хөкүмәт үзе халыкны изгәнен, җәберләгәнен күрәчәкбез. Хөкүмәт үзе бөтен көче белән безнең халыкны җаһиллектә яшәтергә тырыша. Мәгърифәт мәсьәләсендә генә түгел, экономика җәһәтендә дә безнең халыкка юл бирми ул! Кай якка карасак та, халкыбыз үтә алмаслык киртәләр күрәбез! Хәтта безнең уставны да, төрле мәгънәсез сылтаулар табып, хөкүмәт расламый бит! Я, әйтегез! Халкыбызның авангарды булган без — студентлар — бу хәлне күрә торып, эндәшми, күз йомып, түзеп утырабызмы?! Әллә бөтен көчебезне куеп, мондый хөкүмәткә каршы көрәш ачабызмы? Белем, мәгърифәт тарату гына җитми! Бу — аз! Безнең халыкны шундый авыр хәлгә калдырган явыз, кара көчләргә каршы көрәшер өчен безгә берләшергә кирәк, каты, зур сәяси көрәшләргә әзерләнергә кирәк! Берләшик, туганнар!

Хан Талышинский да сүзсез калырга теләмәде. Ул үзен башкаларга җитәкче булырлык акыллы һәм ярсу йөрәкле егет дип уйлый иде. Шуның өчен, дирижер кебек кулларын җәеп, шау-шуны туктатты да, гадәтенчә, башын артка ташлап сөйли башлады:

— Еникеев әфәнденең сүзләре халыкка бәхет-сәгадәт теләгән һәрбер ярсу егетнең йөрәген ялкынландырып, көрәшкә чакырырга тиеш! Бу омтылыш күптән инде минем дә йөрәгемне яндыра. Ләкин бүген Еникеев әфәнде мин әйтәчәк фикерләрне алданрак әйтеп өлгерде...

Талышинский да халыкка фидакарь хезмәт итү турында күп сөйләде. Ул да Еникеевнең чыгышын хуплагач, студентлар бөтенләй дәртләнеп киттеләр: кайберләре кулларын болгап нәрсәдер кычкыралар, кайберләре килеп Хәлләнең кулын кысалар, аркасын кагалар. Шул шау-шу арасында хәтта председатель үзе дә, башта әйтелгән көн тәртибен онытып, аякка басты, гайрәт белән өстәлне шакыды. Халык тынычланганнан соң:

— Хәлиулла әфәнде Еникеевнең чыгышы буенча нинди тәкъдимнәрегез бар? — дип сорады.

Фирүз Ордубатский Еникеев белән әйтешеп алганнан соң:

— Минемчә, оештыру комиссиясен сайларга кирәк. Бу комиссия безнең беренче чираттагы вазифаларыбызны билгеләсен, планлаштырсын,— дигән тәкъдим кертте.

Башкалар да:

— Дөрес! Комиссия сайларга кирәк! — дип аның фикеренә кушылдылар, чөнки бу тәкъдим алар өчен бик томанлы булган эшләр турында уйланулардан коткарачак иде.

Сайлау вакытны күп алмады, комиссиягә якташлык оешмасында актив эшчәнлек күрсәтеп йөргән Талышинский, Еникеев, Вәзирев, Ордубатский һәм Әхтәмова сайландылар.

— Минем бер тәкъдимем бар! — дип, Еникеев тагын сикереп торды, председательнең рөхсәтен дә көтмичә:

— Мәшһүр татар әдибе Галимҗан Ибраһимов бүгенге көндә монда, Киевтә яши. Аны да комиссиягә сайларга дип тәкъдим итәм. Иҗтимагый, сәяси мәсьәләләрдә аның тәҗрибәсе безгә караганда, әлбәттә, күбрәк. Арабызда атаклы язучы булгач, башлаган эшебезгә мөселман студентлары тагын да һәвәсләнебрәк катнашырлар дип уйлыйм!

Еникеевнең бу тәкъдимен дә бик хуплап каршы алдылар һәм комиссиягә сайлануы турында Галимҗан Ибраһимовка хәбәр итүне Хәлләнең үзенә тапшырдылар.

* * *

Якташлык оешмасындагы чыгышы студентлар тарафыннан шундый зур теләктәшлек белән кабул ителүенә куанып, Хәллә өенә дә кереп тормыйча туп-туры Галимҗан фатирына китте. Барса, анда Агаш белән

Лиза утыра икән. Дулкынланып торган аксыл кыска чәчле, зур зәңгәр күзле бу матур кыз, егетләрчә кыланырга тырышып, тезләрен берсе өстенә берсен чалыштырып куйган да терсәгенә таянган. Галимҗан исә кызның матурлыгына сокланып, күзләрен ала алмыйча карап калган. Хәллә Лизаның:

— Атнага ике тапкыр җиде белән сигез арасында...— дигән сүзләрен ишетеп калды. Ишек тавышына күтәрелеп караган Лиза сүзен кырт кисте. Карлыгач канатына охшаган кара кашларын күтәреп, ризасызлык белән борылып карады. Ишектә Еникеевне күргәч:

— Кеше өенә кергәндә жандармнар да ишек шакыйлар,— диде.

Хәлиулла аптырамады:

— Жандармнар өй хуҗалары ишекләрен бикләп йокларга ятканда киләләр. Ә мин көпә-көндез, якын дустымның фатирына килдем,— дип җавап бирде дә, шинель төймәләрен чишә-чишә, бүлмә уртасына килеп басты.

— Ишекне какмавың гына җитмәгән, син бит әле исәнләшмәдең дә, егет! — диде Агаш.

«Җирдән җиде куян тапкан төсле шулай атылып керүе юкка түгел. Әнә бит, йөзе ничек балкый! Бер урында басып тора алмый»,— дип уйлап, Галимҗан Хәлләгә карап эндәшми торды. Еникеев көттермәде.

— Аристократларча кылануыгызны читкә куеп, алып килгән яңа хәбәремне тыңласагыз яхшырак булыр! — диде.

Польша магнатлары нәселеннән булган Лиза, аристократлар турындагы сүзләрне турыдан-туры үзенә кабул итте. Ул болай да шул мохит белән мөнәсәбәтен тәмам өзгәнлеген күрсәтер өчен мөмкин кадәр садә, демократларча, хәтта бераз тупасрак та кыланырга тырыша иде. Хәлләгә ачуы чыгып, кулын күтәрде, зур күзләрен тагын да зуррак ачып:

— Син кемгә төрттерәсең? — диде.

Ләкин егетнең аңа исе китмәде, игътибарсыз гына кулын селекте дә:

— Сөйләргә ирек бир әле! — дип, Галимҗанга борылды.— Сез ни генә дип әйтсәгез дә, минем сүз дөрескә чыкты! Алар барысы да безнең идеягә чын күңелдән кушылдылар!

Галимҗан Ибраһимовның йөзе караңгыланып китте. «Без әйткәнне тыңламыйча якташлары арасында нәрсәдер такылдаган булса кирәк»,— дип уйлады.

— Рәтләп сөйлә әле! «Алар» дигәнең кемнәр?

— Кем булсын?! Әлбәттә, якташлык оешмасының әгъзалары! Мин сезгә: «Алар халык өчен җаннарын фида итәргә әзер торган егетләр!» — дип, башта ук әйткән идем бит. Шулай булып чыкты да!

Галимҗан Ибраһимов тагын да кырыслана төште:

— Әйдә, бөтенесен баштанаяк сөйләп бир әле!

Хәлиулла, шинелен салмастан, урындыкны Галимҗан алдына ук китереп куйды да атланып утырды. Лиза белән Агашка илтифат та итмичә, якташлык оешмасы утырышында булган хәлләрне ялкынланып сөйләп бирде һәм:

— Студент булмасаң да, киңәшче хокукы белән оештыру комиссиясенә сине дә сайладылар,— дип, сүзен бетерде.

Галимҗанның чырае торган саен караңгылана төште:

— Бу нишләвең, Хәллә? Вәгъдәңне оныттыңмы әллә? Җыелышка килгәннәрнең барысына да ышанырга мөмкинме соң! Егерме кешенең егерме төрле фикере, тормышка егерме төрле карашы булу ихтималы бар бит! — диде ачулы тавыш белән.

— Шула-а-ай,— дип сузганнан соң Агаш та: — Артын-алдын уйламыйча эш эшләп куйгансың! Эчләреңдә ни барын белмәгән, сыналмаган кешеләргә сәяси көрәш турында сөйләргә ярыймы соң, Еникеев! — дип өстәде.

Агаш сүзен бетереп өлгермәде, Хәлләнең «аристократларча кылану» турындагы сүзләренә болай да каны кызган Лиза:

— Житмәсә тагын Ибраһимовны да бу сазлыкка китереп тыккансың! Шул егермеләп кеше арасында, бер генә булса да, синең кебек тел бистәсе табылмас дип беләсеңме? Тиктормас телле шундый берәү, үзе дә сизмәстән, сезнең барыгызны да жандармерия кулына тапшырмасмы? — дип орыша башлады.

— Ни дип миңа бәйләнәсез әле! — дип кычкырды Хәллә, үпкәле тавыш белән. Аның үзенең дә күңеленә, «уйламыйчарак эшләп ташладым бугай» дигән шик килгән, ләкин хатасын тану урынына, ни өчендер киреләнеп, кылган ялгышын яклап маташа иде.

— Конспираторлар, имеш! — диде ул мыскыллы тавыш белән.— Һәркемнән шулай шикләнеп, адым саен куркып, посып яшәсәгез, гомерегез буена ялгыз калырсыз, бер адым да алга атлый алмассыз!

Ачуыннан Хәлләнең хәтта тыны кысыла башлады. Һәр сүзеннән соң туктала-туктала, сөйләп китте:

— Кешеләр... жаннары... тәннәре... белән... халыкка... хезмәт итәргә... халыкны... җәберләүче... изүче... кара... көчләргә... каршы... көрәшергә... әзер... торалар... ә сез!..

— Аларның халыкка нинди юллар белән хезмәт итәргә, кара көчләргә каршы ничек көрәшергә теләгәнлекләрен яхшы беләсеңме? — дип сорады Галимҗан.

— Минемчә, без үзебез аларга юл күрсәтергә тиеш,— диде Хәллә, бирешмәскә тырышып. Ләкин инде ул суына төшкән иде. Уйланып торды да: — Баштарак бәлки, чыннан да, оешманың бөтен әгъзаларын җәлеп итмичә, тик оештыру комиссиясендә генә эш алып барырга кирәктер,— диде.

«Бик ашыгучан, мавыгучан шул бу Хәллә. Уйламый башлаган эшнең уңышсыз бетәсен алдан ук әйтергә мөмкин шул. Яхшылап аңлата алмаганбыз, күрәсең. Инде нишләргә? Башланган эш нәтиҗәсез калмасын дип, әллә аңа тиешле юнәлеш биреп җибәрергәме?» — дип уйлады Галимҗан Ибраһимов.

— Һәрвакыттагыча ашыккансың Хәллә! Инде бу эшне ничек төзәтергә, ничек юлга салырга кирәклеген бик нык уйлашырга туры килер. Сиңа тик бер үтенеч: киңәшмичә, сөйләшмичә тагын шундый бер дуамаллык эшли күрмә, зинһар. Лизаның монда туры килүе бик яхшы булды. Студентлар, курсисткалар арасында түгәрәкләр оештыру, аларны сәяси белем белән коралландыру, революцион көрәшкә хәзерләү кебек эшләрдә Лизаның байтак тәҗрибәсе бар. Безгә ярдәм итүдән ул баш тартмас дип ышанам. Агаш та бергә киңәш белән булышыр,— дип, Лизага карады һәм күзен аңардан алалмыйча бераз тукталып торды.

— Зураб һәм Николай белән дә сөйләшеп карарга кирәк,— диде Агаш.— Шуңа кадәр син шауламый тор, Еникеев! Бушбугазланып почмак саен сафсата сату халыкка хезмәт итү түгел ул. Бу эш өчен иң элек үзеңне нык әзерләргә, бернинди сынауларга да бирешмәслек итеп әзерләргә кирәк. Син шуны комиссиягә сайланган якташларыңа әйбәтләп аңлат.

— Җитәр инде! — диде Еникеев уңайсызланып. Бу турыдагы сүзне туктатыр өчен Галимҗанга мөрәҗәгать итте: — Оештыру комиссиясендә эшләргә ризалык бирәсеңме?

— Эшне шулай уйламастан башлавың яхшы түгел. Тәҗрибәле иптәшләр белән киңәшеп карарга кирәк... Бәлки, башланган эшне ташлау ярамас. Аз гына берәр мәгънәле нәтиҗә чыгарып булмасмы дигән өмет тә бар...

Галимҗан Ибраһимовның сүзләрен ишеткәч, Хәллә шатланып, утырган урыныннан сикереп торды, дустының кулына ябышты:

— Димәк, син риза! — дип кычкырды.

Галимҗан аның кулын кире какты:

— Мин бит кистереп «риза» дип әйтмәдем, иптәшләр белән киңәшер-

гә, уйлашырга кирәк булыр. Тик шуннан соң гына билгеле бер карарга килербез.

Барыннан да бигрәк Галимҗан Ибраһимовны үзенең дә, Хәлләнең дә мондый җитди эшкә җитәкчелек итәрлек әзерлекләре булмау борчый иде.

## Беренче адымнар

Рождество бәйрәмнәре якынлаша. Студентлар каникулга әзерләнәләр. Имтиханнарын вакытында биреп, башка эшләрен дә төгәлләргә тырышалар. Бу арада Хәлләнең дә эшләре тыгыз, ләкин ул, бер урамда торуларыннан файдаланып, сирәк булса да, юл уңаеннан Галимҗан янына кергәли иде. Соңгы килүендә ул:

— Сине оештыру комиссиясенең әгъзалары белән таныштырырга һич вакыт табалмыйм. Үзең беләсең, каникул алды, имтиханнар,— дип зарланып алды.

— Ничек соң, бу эштән якташларыңның күңелләре суынмадымы әле? — дип, Галимҗан күптән борчыган соравын бирде.

— Киресенчә! — диде Хәллә бик җанланып.— Каникулга таралыр алдыннан комиссия әгъзалары җыелып, якын киләчәктәге эшләребез турында уйлашырга, киңәшергә булдык. Син дә бу мәҗлескә бик әзерләнеп барырга тиешсең! Алар сине әһәмиятле фикерләр, яхшы киңәшләр бирерсең, юл күрсәтерсең, дип көтәләр.

— Мин аларга юл күрсәтергә тиешме? Бу, әлбәттә, синең үз сүзләрең! Шундый юк-бар фантазияләр белән иптәшләреңнең башын әйләндермәсәң иде. Ул юлны күрсәтүче табылса, мин үзем беренче булып шуннан атлап китәр идем.

— Юкны сөйләмә әле! Синең тормыш тәҗрибәң студентларга карагйнда һәр яктан киңрәк тә, тирәнрәк тә. Әллә моны инкарь итмәкче буласыңмы?

— Мин һичбер нәрсәне расларга да, инкарь итәргә дә теләмим, тик ни барын гына әйтәм. Халкыбызга бәхет бирик дисәк, Русиядәге тормышны тамырыннан үзгәртергә, ә моның өчен самодержавиене бәреп төшерергә, юк итәргә кирәклеген үзең дә беләсең. Ләкин шуннан соң төзеләчәк яңа тормышны нидән, ничек башларга икәнен син дә, мин дә белмибез бит.

— Аңа баш ватып утырасы да юк. Рус революционерларының программалары белән танышсак, эшне башлап җибәрер өчен шул җитеп торыр!

— Мәсьәләне бик җиңел хәл кыласың! Алай булмый шул, дус. Кулга төшкән прокламацияләргә генә кара, рус революционерлары үзләре дә төрле партияләргә бүленәләр: социал-революционерлар, социал-демократлар, анархистлар, тагын белмим нинди генә революционерлар юк! Болар үзләре дә икешәр-өчәр тармактан тора икән. Социал-революционерларны гына алыйк, болар арасында уң тарафка тартканнары да, сул тарафка тартканнары да, үзәктә торганнары да, бәйнәлмиләлчеләре дә бар. Социал-демократларны алсаң да шул ук, болар арасында да большевик, меньшевик дигән тармаклары бар икән. Инде Думада күпчелек хасил иткән националистлар, кадетлар, октябристлар, монархистларны алсак, партияләрнең саны да, тармаклары да әллә никадәр артачак. Мәсьәлә син әйткәнчә шулай җиңел хәл кылына торган булса, бар, менә шул партияләрнең программаларын табып китер, ә мин аларны укып, кайсын кабул итәргә кирәклеген сайлап, оештыру комиссиясендәге иптәшләреңә тәкъдим итәрмен. Алар, авызларын ачып тыңлап утырганнан соң, программаны алкышлап кабул итәрләр. Шулаймы? Юк, дустым, минемчә, эшне бүтәнчәрәк башларга кирәк.

Үпкәсен дә, ирониясен дә яшерә алмаган Хәллә:

— Мина ышанмыйча, үзеңнең хәттин тыш акыллы, тәҗрибәле,

ышанычлы иптәшләрең белән киңәшеп, оештыру комиссиясенең эшләрендә иштирак итәргә ризалык бирдең ич! Шулай булгач, комиссиянең җыелышына әзерләнеп бар дип әйтүемнән нинди гаеп табасың? Ул иптәшләрең акыллары, тәҗрибәләре белән уртаклашканнардыр, киңәшләр биргәннәрдер бит сиңа!

Галимҗан Ибраһимов, гадәтенчә, бернича минут башын артка ташлап уйланып торганнан соң, Хәлләнең мыскылына һич илтифат итмичә:

— Әйе, иптәшләр белән киңәштек, уйлаштык,— диде.— Нәтиҗәдә шул фикергә килдек: Русиянең бик күп шәһәр-авылларында яшәүче төрек-татар халыкларының авыр язмышын үзгәртү, якты киләчәккә алып бару тик минә шушы Киевтә яшәүче студентларның гына эше түгел. Әгәр без бу хәрәкәтне баштан ук тиешле юлга куярга теләсәк, Русиядәге башка төрек-татар яшьләре белән дә киңәшергә, аларның да бу турыдагы фикерләрен белергә тиешбез. Оештыру комиссиясенә сайланган иптәшләрең белән бу турыда сөйләшеп кара. Тик, зинһар өчен дип әйтәм, башка студентлар алдында телеңне тыеп тор!

— Тыеп тор, имеш! Бу ни дигән сүз! Әллә син мине үзең кебек, Агаш белән Лизаң кебек ахмак дип уйлыйсыңмы? Болай булса...— дип, Хәллә әйтер сүзен әйтеп бетермичә, утырган урыныннан ярсып сикереп торды.

— Ачуланырга хакың юк, Хәллә! — диде Галимҗан сабыр гына.— Үземә әйтеп тә тормастан, ризалыгымны алмастан, араларына мине дә китереп тыккансың! Шулай булгач, ничек итеп тыймаска! Син миңа шуны әйт, каникул вакытында кая да булса китәргә уйлыйсыңмы?

— Әлбәттә, китәм! Әнкәй, бик сагындым, кайт, дип яза.

— Бәлки юл өстеннән, бернича көнгә, Казанда тукталырсың? Столыпинның үтерелгән хәбәрен ишеткәч, Казан студентлары, Казан яшьләре дә җанлана башламадылармы икән? Тәкрар әйтәм, Киев белән генә чикләнергә ярамый. Бер яктан, Киев мөселман студентлары хәрәкәтенең үзәге булырлык шәһәр түгел. Икенчедән, әле былтыр гына бу шәһәрдә баш министр Столыпин үтерелде, шуны да онытмаска кирәк. Дөрес, бу эштә революционерларның катнашы булмаган, Распутин белән Столыпинның үзара килешә алмаулары нәтиҗәсендә булган, дип сөйлиләр. Шулай да бу вакыйгадан соң жандармерия аеруча саклык күрсәтеп, иҗтимагый, сәяси хәрәкәтләргә җәелергә, киңәергә мөмкинлек бирми башлады. Безгә Петербург, Мәскәү кебек зур шәһәрләрдә укучы яшьләр белән элемтәгә кереп киңәшергә кирәк булыр. Син бу турыда да оештыру комиссиясе белән сөйләшеп кара. Алар да бу фикергә кушылмаслармы, элемтәгә керү юллары турында уйламаслармы?

Галимҗан Ибраһимовның тәкъдимен Хәллә дәртләнеп кабул итте.

— Менә бу идея! Әлбәттә, комиссияне бу тәкъдимең белән таныштырырмын! Һичшиксез, Казанда бернича көнгә тукталырга кирәк булыр миңа. Анда бик якын дустым да бар! Хәнәфи Кайбышев дигән студент-медик. Бик акыллы егет! Хәер, син аны үзең дә яхшы белергә тиеш. Ул миңа булышыр, кулыннан килгән ярдәмен күрсәтер!

Киевкә китәр алдыннан Кайбышев белән очрашып сөйләшүе исенә төшеп, Галимҗан Ибраһимов кашларын җыерып куйды:

— Син Кайбышевка бик үк ышанма. Ул хәзер әүвәлге идеяләреннән ераклашканга, үз мәнфәгатен генә кайгыртып торган мещанга әверелгәнгә охшый.

Хәллә ут кебек кабынып китте:

— Юкны сөйләмә әле! Шундый акыллы, мәдәниятле егет мещан булачакмы? Үлсәм дә ышанмам! Менә күрерсең, көчен кызганмас, бар мөмкинлеге белән безгә ярдәмләшер!

Галимҗан шикләнгән кыяфәт белән башын чайкап куйды:

— Һәрхәлдә, аның белән сөйләшкәндә, авызыңны бик зур ачма!

— Әллә Казан яшьләре белән дә ачыктан-ачык сөйләшергә ярамый, дип әйтмәкче буласыңмы?

— Хәзерге көндә патша хөкүмәтенә каршы көрәшергә кирәклегеп башында аз гына акылы булган һәрбер кеше аңлый инде! Аны махсус әйтеп торырга да кирәк түгел дип уйлыйм. Әгәр оештыру комиссиясе Казан яшьләре белән очрашуны кирәк дип тапса, Киевтә шундый комиссия сайланганын һәм аның программасын, тактикасын ачыклау өчен төрле шәһәрләрдә укучы яшьләр белән җыелып киңәшергә кирәклеген сөйләргә тиешле булачаксың. Әлбәттә, яшьләр җыенга үзләре дә әзерләнеп килергә тиешләр. Мондагы комиссия дә үз программасын һәм тактикасын, җыенга тәкъдим итәрлек дәрәҗәдә әзерләп өлгертергә тиеш. Безнең идеягә кем кушыла, кем кушылмый, менә шунда ачык күренер. Минемчә, хәзергә эшне шулай планлаштырырга мөмкиндер...

* * *

Хәлиулла Еникеев Казанга декабрь аеның беренче көннәрендә килеп төште. Иң әүвәл ул дусты Хәнәфи Кайбышевка юнәлде. Хәлләнең Казанга ни өчен килгәнен ишеткәч, Кайбышев мыскыллап көлде:

— Сезне, әлбәттә, хыялый Галимҗан Ибраһимов котырткандыр. Тирә-ягыңа бер күз ташла әле син. Үзләрен революционер дип шапырынып йөргән кешеләр кая алар? Хәзерге көндә аларның күбесе зинданнарда, крепостьларда тереләй череп яталар, ә бу фаҗигале язмыштан котылып калганнары акылга утырдылар, әүвәлге хыялларыннан айнып...

— Син нәрсә?! — дип кычкырды Хәллә иптәшенең сүзен бүлеп. Йодрыкларын кысып, Хәнәфинең алдына ук килеп басты.— Күрсәт миңа ул мөртәтләрне! Алар кемнәр? Син революционерларга яла якма!

— Мисал кирәк булса, менә, Гомәр Терегуловны гына алыйк. Кып-кызыл революционер, самодержавиенең әшәке дошманнарыннан саналган кеше иде, бүгенге көндә, губернаторга юмакайланып, сәяси ышанычлылык кәгазе алган, патшага буйсынган чиновник булып, земствода эшләп йөри.

— Сиңа ни булды, Хәнәфи? Революционерлар өстенә пычрак атудан ничек оялмыйсың? — дип җикеренде Хәллә ачулы рәвештә.— Беләсең килсә, бу турыда миңа бөтенләй башкача сөйләделәр. Мәктәп-мәдрәсәләрне реформалаштыру эшләрен, әкрен-әкрен, земство аркылы ачык юл белән үткәрүне аңа тапшырганнар. Өстенә йөкләнгән шул вазифаны башкарыр өчен аңа легальләшергә, сәяси ышанычлылык алырга кирәк булган!

— Шулаймы-юкмы, анысы томанлы мәсьәлә. Тик фактлар белән исәпләшергә туры килә. Тормыш безгә, акылга утырыгыз, нигезсез буш хыяллар белән мавыкмагыз, ди. Хәзергә бездә тиешле шартлар туып җитешмәгән. Без татарларда гына түгел; хәтта русларда да, мәдәният-ләре руслардан да күп югары булган Европа халыкларында да бу шартлар юк әле. Алар күптән инде социализм җәмгыятен корган булырлар иде...— Ул тукталып торды да, сүзләренең мәгънәсен йомшартырга теләгән төсле: — Хәзергә без рухи көч җыярга, үзебезне рухи баетырга һәм көчебезне буш хыялларга сарыф итмәскә тиешбез! — дип өстәде.

Хәллә ни әйтергә белми каушап калды. Иптәшеннән мондый сүзләр ишетермен дип көтмәгән иде ул. Аптыравыннан нәрсәдер эзләгән төслé, бүлмә эченә күз йөртеп алды. Андагы җиһазларны яңа күргәндәй булды. «Шулай! Рухи яктан гына түгел, башка яклардан да баета икән бу үзен»,— дип уйлады ул. Шулай байларча яшәр өчен каян акча таба икән, дигән сорау аның күңелендә шик тудырды... Күзләрен кысып, башын чайкады:

— Син, дус, күрәм, бик үзгәргәнсең. Үзеңчә әйткәндә, акылга утыргансың, артыгы белән баеп киткәнсең.

— Фикерләрем турындамы, әллә квартирамдагы җиһазлар турында әйтүеңме? — дип сорады Хәнәфи һәм Хәлләнең җавабын да көтмичә: — Әллә син мәдәни тормышның ямьле якларыннан файдалануны зур җи-

наять дип саныйсыңмы? Синеңчә, халыкка хезмәт итәргә теләгән кешеләр теләнче кебек яшәргә тиешме?

— Сәяси көрәшкә катнашкан кешеләр теләнче кебек яшәргә тиеш, дип берәү дә әйтми. Ләкин миңа синеке төсле «мәдәни» тормыш корыр өчен байтак акча кирәк бит! Ул кадәр акчаны син каян табасың?

Хәлләнең шулай һәрвакыттагы дорфалы, җайлап-чөйләп тормыйча турыдан-туры бәреп әйтүе Хәнәфине бераз уңайсыз хәлгә куйды. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды, мыек астыннан көлемсерәп, иңбашларын җыерып куйды.

— Допрослыйсыңмы? Әгәр син якын дустым булмасаң, соравыңа җавап та бирмәс идем. Бик кызыксынасың икән, миңа кара, язган хикәяләрем өчен алган гонорарларым тормышымны бизәргә имканият бирә. Шуның өстенә, дөньяда тора белергә дә кирәк.

«Галимҗан Ибраһимов Хәнәфигә караганда бик зур әдип булса да, аның бу эштән килгән табышы ачлы-туклы яшәүдән артмый»,— дип уйлады Хәллә. Ләкин фикерен бу юлы әйтми калды, чөнки барыбер дөрес җавап ала алмаячагын аңлады. Кашларын җыерып, ишеккә таба атлады һәм шинеле белән фуражкасына тотынды. Артына да әйләнеп карамыйча әйтеп салды:

— Башлаган эшебезне утопия дип саныйсың икән! Ярар! Син ярдәмләшмәсәң дә, Казан яшьләре белән очрашырга юл табармын әле!

— Ни өчен ярдәмләшмәскә? Анысы мөмкин. Шимбә көн Гафур Коләхметовның квартирында очрашырбыз. Казан студентларын синнән яхшырак беләм мин. Җыелышка кешеләрне үзем чакырырмын.

Хәнәфи Кайбышевның акылга сыймаган сүзләре, аңлавы кыен булган кыланышлары Хәлләне бик күңелсезләндерде. «Шундый акыллы, алдынгы фикерле яшьләребез үз идеалларыннан кире чигенгәч, башкалардан ни көтәргә мөмкин? Әле күптән түгел бу егет: «халыкка хезмәт итү — безнең иң мөкатдәс, иң изге бурычыбыз, дип, докладлар сөйләп, төрле иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр турында рефератлар укып йөри иде бит, ә хәзер, кара, ни ди, имеш, болар барысы да буш хыял, утопия!»

Әмма, Хәнәфинең Гафур Коләхметов квартирындагы җыелышта сөйләгән сүзләре, андагы кыланышлары Еникеевне тагын да ныграк аптыраттылар. Монда да Хәнәфи үз фатирындагы кебек сөйләнер, дип уйлаган иде ул, ләкин бөтенләй башкача булып чыкты. Кайбышев Хәлләнең чыгышына һичбер төрле каршылык күрсәтмәде. Иң каршы чыккан кеше Петербург студенты Фуат Туктаров булды.

— Революцияләр ясарлык булып пешеп өлгермәгәнбез әле. Хәзергә бу эш хәтта русларның да кулларыннан килми. Бишенче ел вакыйгалары безгә моны бик ачык күрсәтте. Киев студентларының бик томанлы, чынбарлыктан бик ерак булган идеяләре турында баш ватмыйча, бүгенге көндәге ихтыяҗларыбыз турында уйланырга кирәк. Ул нинди ихтыяҗлар дисәгез — мәктәпләрдә яңача укыту, халкыбызны Европа мәдәниятенә якынлаштыру өчен аңлы-белемле кешеләр тәрбияләп җиткерүдер. Пролетариат, рабочий, капиталист дип милләтебезнең эчендә каршылык тудырмаска, киресенчә, аларны үзара бердәмлеккә чакырырга тиешбез!

Үзен бик зыялыларча тоткан, дәресрәге, тәҗрибәле, атаклы адвокатларча кыланган студент Туктаров бик озак, сәгатьтән артык сөйләде. Хәлиулланың бернәчә тапкыр утырган урыныннан сикереп торып, бу такылдыкның тетмәсен тетәсе килсә дә, иңбашына басып Кайбышев аны урынына кире утырта торды. Ә Фуат Туктаров сүзен бетерү белән Хәнәфи үзе аякка басты һәм үтә мәдәниятле төчелек белән:

— Хөрмәтле әфәнделәрем! — дип сөйли башлады.

Бу тагын үзенең мөртәт фикерләрен әйтергә тели ахры, дип шикләнеп, Хәллә кырт борылып Хәнәфигә карады. Анысы, Еникеевнең хәрәкәтен күрмәгәнгә салышып, сүзен дәвам итте:

— Киевтә укучы студентларның вәкиле Хәлиулла әфәнде Еникеевнең дә, Санкт-Петербургта укучы хөрмәтле Фуат әфәнде Туктаровның да сүзләрен ишеттегез. Минем тик шуны гына өстәп әйтәсем килә: Киевтә башланган бу хәрәкәтнең үзәгендә безнең яшь, атаклы әдибебез Галимҗан әфәнде Ибраһимов тора...

Фуат Туктаров Кайбышевның сүзен бүлде:

— Гафу итегез, Хәнәфи әфәнде! Галимҗан Ибраһимовны бу хәрәкәткә мөнәсәбәте булганын сез каян белдегез?

Кайбышев, ашыкмыйча, кесәсеннән конверт чыгарды:

— Менә, Галимҗан әфәнденең үз кулы белән язган һәм узгачча декабрьдә миңа Киевтән җибәргән хаты. Теләсәгез, укып бирим,— дип, хатны конверттан чыгарды.

— Әлбәттә, укыгыз!

— Аның фикере белән танышу зарар итмәс! — дигән тавышларны ишеткәч, Кайбышев: — Хатны башыннан соңына кадәр укып сезне ялыктырмам, кирәк урыннары белән генә таныштырырмын,— дип укый башлады: — «Хәлиулла әфәнденең күңеленә Киевнең һавасы бик ошады... Ул монда, алла белсен, ничек котыра башлады. Казанга да шул эш белән китте...— Кайбышев бераз тукталып хат юлларыннан күзен йөртеп чыкты да, боларның ул кадәр әһәмияте юк, дип берничә юлны калдырып, шуннан соң укуын дәвам итте: — Аның өстенә алган вәкиллек вазифасы идея ноктаи назарыннан бик әһәмиятле. Сез бу мәсьәләгә ничек карыйсыз? Мин фатиха бирдем».— Кайбышев, ашыкмыйча хатны бөкләп, пиджагының кесәсенә салды. Галимҗанның фикере ничек тәэсир иткәнен белергә теләгән төсле булып, өстәл тирәсендәге иптәшләрен күздән кичерде. Тик шуннан соң гына сүзен дәвам итте:

— Минемчә, бу хат Галимҗан әфәнденең позициясен бик ачык күрсәтә, ә халыкка хезмәт итү юлында аның җанын да, тәнен дә фида итәргә торганын без барыбыз да бик яхшы беләбез. Минем фикеремчә, Киев студентларының идеясе, Фуат әфәнде әйткәне кебек алай ук томанлы да, чынбарлыктан ерак та түгел. Шулай ук Фуат әфәнде сөйләгән идеяләргә, рухи бурычларга каршы да килми. Хәзерге көндә Киев студентлары безне халкыбызның якты киләчәге юлында берләшеп, патша хакимиятенә каршы көрәшергә чакыралар. Көрәшсез җиңү булмый. Бу — һәркемгә билгеле хакыйкать. Үзебезне халкыбызның алдынгы сафында торган затлар дип санасак, аның бәхете-сәгадәте өчен көрәшергә бурычлыбыз! Инде, бу көрәшне нинди ысул, нинди юллар белән алып бару кирәклеге турында Еникеев әфәнде бик ачык итеп әйтте. Безнең вәкилләр Киевкә җыелып, шул юлларны, шул ысулны билгеләргә тиешләр һәм шул нигездә Русиядәге бөтен мөселман студентларының съезды чакырылырга тиеш. Бу съездда, киләчәктәге эшләребезнең программасы бәйнә-бәйнә тикшерелеп, тастык ителәчәк. Минемчә, Киев студентларының бу эшне башлап җибәрергә тырышуларын без котлап каршы алырга тиешбез һәм бу идеянең яшьләр арасында тизрәк таралуы һәм кабул ителүе юлында бар көчебезне куеп ярдәмләшергә бурычлыбыз!

Еникеев таң калды. Казан яшьләре алдында Хәнәфи шулай сөйләр дип көтмәгән иде. «Бу ни хәл? Үзара сөйләшкәндә безнең идеяне мыскыллап, әллә нинди каршы фикерләр әйтеп утырды, ә монда, халык арасында, бөтенләй башкача сайрый. Бу икейөзлелекнең чыны минем белән сөйләшкәндәгесе булырга тиеш, ә монда ул үзен алдынгы фикерле итеп күрсәтер өчен лыгырдый»,— дип уйласа да, дунгыздан бер кыл — ул да файда, дип, Хәлиулла Кайбышевның сүзен бүлмәде.

Чыннан да, Хәнәфи Кайбышевның чыгышы икеләнеп торган кайбер яшьләргә унай тәэсир итте. Гафур Колахметовның студентлар арасында башланган иҗтимагый хәрәкәтнең бик әһәмиятле һәм кирәкле булуы турындагы чыгышы Хәллә Еникеевнең позициясен тагын да ны-

гыта төште. Шунда ук комиссия сайларга булдылар. Киевка җибәреләчәк юл хәраҗәте өчен акча җыю, андагы җыенда тикшереләчәк мәсьәләләргә хәзерләнү кебек эшләр бу комиссиягә тапшырылды.

* * *

Киевкә кайткач Хәллә өенә дә кереп тормады — вокзалдан туры Галимҗан Ибраһимовка китте. Казанда булып үткән очрашуларны, үзенең шулардан алган тәэсирләрен тизрәк иптәшенә сөйлисе килә иде аның.

Каникул сәбәпле, буш вакыты күбрәк булудан файдаланып, Ибраһимов «Казах кызы» романын язып утыра иде. Хәллә кереп килүгә, өстәл яныннан торып, ачык йөз белән иптәшенә каршы атлады. Аның да тизрәк Казан хәбәрләрен ишетәсе килә иде.

— Хуш киләсең, Хәллә! Әйдә, шинелеңне сал, чемоданыңны әнә теге почмакка куеп тор. Мин, самавыр куйсыннар, дип әйтеп керим,— дип чыгып китте. Берничә минуттан соң бүлмәгә әйләнеп кергәндә Хәллә чишенеп, сабырсызлык белән сакалын тарткалап, кызу мичкә аркасын терәгән көе аны көтеп тора иде. Галимҗан Ибраһимовны ул:

— Әмма да уңайсыз хәлгә калдырдың син мине үзеңнең киңәшләрең белән! — дип каршы алды.

— Нинди киңәшләр икән ул тагын?

— Сораган була бит әле! Иң беренче нәүбәттә Хәнәфи Кайбышевка мөрәҗәгать ит, дип киңәш биргән син түгел идеңме?

Чиксез гаҗәпләнүеннән Галимҗанның кашлары югары күтәрелде. Ләкин шунда ук Хәлләнең начар гадәтен исенә төшерде: берәр эше уңмаса, гел шулай кешегә сылтый, үзем булдыра алмадым, дип уйламый.

— Син, дус, чынлап әйтәсеңме, юри котыртасыңмы? Хәзерге көндә Хәнәфи әүвәлге идеалларыннан ваз кичкән, аңа бик ышанма, ачылма, дип искәртүче мин түгел идемме? — диде Галимҗан Ибраһимов.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышкан кебек, Хәллә бераз күзләрен түшәмгә текәп торганнан соң башын селкеп алды.

— Шулай дисеңме? Димәк, Хәнәфи турында дөрес әйткәнсең,— дип шунда ук Галимҗан белән килеште, ләкин анда да үпкәсе барлыгын белдерми түзмәде: — Син аның турында миңа тиешенчә аңлатып сөйләмәгәнсеңдер. Ул анда икейөзләнеп, провокатор кебек кыланды.

— Провокатор дисеңме? Була торган эш түгел! Юкны сөйләмә! Син һәрвакыт шулай чамадан арттырып җибәрәсең! — дип, Галимҗан иптәшенең шикләнүен кире какты.

— Юк! Юк! Син тыңла әле! — дип, Хәллә кызуланып, Галимҗанның сүзен бүлде дә, Казанда күргәннәрен һәм ишеткәннәрен сөйли башлады:

— Үзе алпавытларныкы кебек зиннәтле фатирда яши. Язган хикәяләре өчен алган гонорарлары аңа шундый квартирда торырга мөмкинлек бирәләр, имеш! Я, әйт миңа, ни өчен син шул чаклы күп һәм зур күләмле хикәяләр язасың да, алган гонорарларың шундый хан сарайларында яшәргә мөмкинлек бирми? Бу дөньяда тора белү кирәк икән аныңча, ә дөньяда тора белү тик үз-үзеңне кайгырту, үз хәлеңне, үз файдаңны гына күзәтү икән. Икәүдән-икәү булганда бер төрле сөйли, ә кешеләр арасында бөтенләй башкача сайрый!

— Безнең һәркайсыбызда нинди дә булса бер җитешмәгән як бар инде, Хәллә! Хәнәфидә дә шундый бер кимчелек юк түгел. Ул кешеләрне шаккатырырга ярата. Сиңа да шундый бер эффект ясарга теләгәндер әле. Ул сиңа барыбер ярдәм иткән ич!..

— Итүен итте, ләкин соңыннан тагын мыскыллый башлады. Халыкның бәхет-сәгадәте өчен көрәшүне тик студентлар гына алып бара алачак, дип уйлау — үзе бер буш хыял, диде ул. Хәер, бу фикерне ул гына түгел, җыелыштагы Мостафин фамилияле берәү дә кабатла-

гач, башкалар да аңа кушылган иде. Миңа да фикеремне үзгәртеп, студентларны гына түгел, алдынгы фикерле прогрессив яшьләрне дә көрәшкә өндәргә кирәк, дип сөйләргә туры килде.

Галимҗан Ибраһимов гаҗәпләнеп:

— Бу мыскыл итү түгел, бик төпле фикер бу. Дөресен әйткәндә, сәяси көрәшне тик студентлар көче белән генә алып баруны мин дә туры юл дип санамыйм. Бу — мөмкин дә түгел! Сәяси көрәшкә олылар да, яшьләр дә катнашырга тиеш, тик теләкләре булсын да, күңелләре саф булсын!

* * *

Март аеның соңгы көннәре. Тротуар читләрендәге көртләр астыннан челтерәп кар сулары ага. Язгы дымсу һава, көньяктан искән җылы җил күңелне күтәреп, каядыр ашкындыра, чакыра, ниндидер шатлыклар вәгъдә иткән сыман була. Шуның өчендер Хәлиулла бик җилкенеп, ашкынып килеп керде. Ишек янында басып торган көе Галимҗанны ашыктыра башлады:

— Әйдә, киттек! Ярты сәгатьтән оештыру комиссиясенең утырышы башланырга тиеш. Утырыш Гөлсем туташ бүлмәсендә үткәрелә... Ара ерак, кичекмик!

Утырышка килгән студентлар Галимҗанны кызыксынып каршы алдылар, чөнки Хәллә аның турында иптәшләренә: «Ул татарның атаклы язучысы, ялкынлы көрәшчесе, революционеры»,— дип, гадәтенчә арттырып, тиешеннән артык мәдхияләр укыган иде.

Галимҗанны исә кереп килүе белән Гөлсем туташның бүлмәсе гаҗәпләндерде. Монда иң беренче күзгә ташланган нәрсәләр: алдына әллә ни хәтле ислемай флаконнары, пудра тартмалары, крем савытлары, берсеннән-берсе матур шкатулкалар тезелгән трильяж һәм өстенә чигүле кечкенә бернечә мендәрчек ташланган тахта иде. Бу нәрсәләр курсистканың бүлмәсен аксөяк ханымнарның будуарына охшата иде.

Өс-башын салып, иптәшләре белән исәнләшкәннән соң, Галимҗан Ибраһимовны да алар белән таныштыргач, Еникеев Талышинскийга карап:

— Без азрак кичегеп килдек бугай, гафу итегез,— диде.

Анысы, үз дәрәҗәсен яхшы белгән кеше кыяфәте белән эреләнеп, җиңелчә генә башын иде:

— Зарар юк, борчылмагыз! — диде һәм өстәл янына килеп Гөлсем туташ белән янәшә утырды.

— Комиссия әгъзалары һәммәсе дә килеп житеште, утырышны башласак та була,— дип игълан иткәннән соң беркетмә язарга әзерләнгән Гөлсем туташ, кулына бер кәгазь кисәге алып, утырышның көн тәртибен игълан итте.

— Күрәсез, беренче мәсьәлә итеп «Съездның физиономиясе нинди булырга тиеш?» дигән сорау куелган. Хәтерегездә булса, үткән мәҗлестә Шәфи-бәк Рустамбеков әфәнде, апрель аенда булачак җыенга килгән студентларны бу турыдагы фикерләребез белән таныштырырга тиешбез, дигән иде. Шул вакытта без, бу тәкъдимгә кушылып, съездның физиономиясен ачыклаган программаны язу эшен, Хәлиулла әфәнде Еникеевнең рекомендациясе буенча, Галимҗан әфәнде Ибраһимов белән Хәлиулла әфәнденең үзенә тапшырган идек. Ибраһимовның бүгенге мәҗлесебезгә килүе, үтенечебезне кире какмавын күрсәтә, дип уйлыйм. Шуның өчен съездның физиономиясе турындагы сүзне Галимҗан әфәндегә бирәбез.

Якын көннәрдә булачак җыенда тикшерелергә, хәл кылынырга тиешле мәсьәләләрне хәзерләү, шул турыда уйлашу урынына, бу оештыру комиссиясе дигәннәре кайчандыр булачак съездның физиономиясен билгеләргә керешкән икән. Талышинскийның кереш сүзеннән Галимҗан Ибраһимов шуны аңлады. Рәис — бу фикерне Рустамбеков кузгатты,

дип әйтсә дә, монда сабырсыз, ашыгучан Хәлләнең роле зур икәне Ибраһимов өчен шиксез иде. Шуның өчен ул сүзне көн тәртибендәге беренче мәсьәләнең иртәрәк куелуы турында башлады:

— Русиядә яшәүче төрек-татар яшьләренең съездын чакыру турында фикер барлыгы миңа мәгълүм. Ләкин бу утырышта аның физиономиясе турында сөйләшү иртәрәк түгелме икән дип уйлыйм. Минемчә, бүген без бу турыда шуны гына әйтә алабыз: әгәр безгә яшьләр съездын күрү насыйп булса, анда фәкать сәяси мәсьәләләр генә тикшерелергә тиеш булачак! Ни өчен дисәгез, сәбәбе барыгызга да мәгълүм. Халкыбызның мәдәни тарафтан да, икътисади, иҗтимагый тарафтан да артта калуының сәбәбе самодержавие хакимиятенең сәясәте икәнен исбатлап торуның ихтыяҗы юк. Бу сәясәткә каршы, әлбәттә, тик сәяси көрәш белән җавап биргәндә генә җиңеп чыгарга мөмкин! Башка юл юк! — диде дә бераз тукталып торырга мәҗбүр булды, чөнки кызу канлы, мавыгучан кавказлы студентлар аның сүзләрен көчле алкышлар белән каршы алдылар. Шул арада Галимҗан Ибраһимов әзерләп килгән тезисларын кесәсеннән алып күздән кичерде. Бүлмәдә тынлык урнашканнан соң гына сүзен дәвам итте: — Ләкин без төп максатларыбызга алып бара торган көрәш юлыбызны съездга чаклы ачыкларга тиешбез. Менә шуның өчен башка шәһәрләрдәге студентларны чакырып үзара аңлашырга, теләкләребез, омтылышларыбыз белән уртаклашырга карар кылуыбыз яхшы. Бәлки, җыенга килгән яшьләр без тәкъдим иткән фикерләрне тулыландырырлар. Шуның өчен Хәлиулла әфәнде белән без шундый карарга килдек: хәзергә җыенда уртага салып тикшереләчәк мәсьәләләр турында уйлашырга кирәк. Бу мәсьәләләр менә шундый булырга тиеш...— дип ул, кулындагы кәгазьгә карап, өйдә язып килгәннәрен укый башлады.

Сәяси мәсьәләләр турында уйланырга өйрәнмәгән бай балаларына Галимҗан Ибраһимовның сөйләгәннәре бик мавыктыргыч, кызык булып тоелды. Шуның өчен Талышинскийның:

— Ибраһимов әфәнденең докладының буенча сөйләргә теләүчеләр бармы? — дип соравына каршы, берничә минут җавап бирүче булмады. Бераздан якташлык җәмгыятенең хәзинәдары Фирүз Ордубатский аякка басты.

— Галимҗан әфәнденең сәяси мәсьәләләр буенча тәкъдим иткән программасына мин тулысынча кушылам. Ләкин программабызны сәяси мәсьәләләр белән генә чикләндерү, минемчә, дөрес булмастыр... Без халкыбызның икътисади, мәдәни ихтыяҗларын да онытырга тиеш түгелбез. Бу тарафлардан без ни дәрәҗә һәм ни өчен артта калганыбыз турында Ибраһимов әфәнде үзе дә сүз башында сөйләгән иде. Минемчә, программага өстәмә рәвештә икътисади һәм мәдәни мәсьәләләрне дә кушарга кирәк,— дигән тәкъдим ясады.

Ордубатский сүзен бетереп урынына утыру белән студент Алибәков сүз алды:

— Минем искәрмәм шуннан гыйбарәт: Ибраһимов әфәнде Думага депутатлар сайлау тәртибе турында сөйләгәндә ни өчендер муллаларны алпавытлар, сәүдәгәрләр, байлар белән бер рәткә куйды. Бу, әлбәттә, дөрес түгел. Муллалар — чын-чыннан халык хезмәтчеләре. Аларның бөтен гомерләре надан халык арасында үтә, гомерләре буе кара халыкның дини игътыйкатенә, дини рухына азык биреп көнә калмыйлар, дөньяви белемнәр дә биреп, аларга мәгърифәтнең якты йөзен ачарга тырышалар. Минемчә, мәктәп-мәдрәсәләрне реформалаштыру, халык арасында мәгърифәт тарату эшләрендә муллаларның роле киләчәктә дә зур булачак. Шуның өчен сәяси программадан муллалар турында кимсетүле сүзләрне чыгарып ташларга кирәк булыр.

Тагын берничә студент, программаны кабул итәргә кирәк, дип сөйләделәр һәм, шуның белән бергә, Ордубатский һәм Алибәковның чыгышларын да якладылар.

«Мәдрәсәи Галия-диния» — дигән исеменнән үк чын асылы кычкырып торган мәдрәсәдә укыганда «Коръән алладанмы-түгелме?» дигән китап язган Галимҗан Ибраһимовка гимназияләр тәмамлаган, университетларда зур галимнәрнең лекцияләрен тыңлап йөргән яшьләрнең диндарлыклары, муллаларның иҗтимагый тормыштагы рольләрен шулай күпертеп, идеаллаштырып караулары гаҗәп тоелды. Аның күз алдына Вәли мулла белән Заһидулла хәзрәтнең кыяфәтләре килеп басты. Халыкка хезмәт итүче, мәгърифәт таратучы галиҗанәп муллалар күбесенчә шундый булалар, дип уйлап ул, ихтыярсыз, мыек астыннан, көлемсерәп куйды. Ләкин аллага ышану-ышанмау һәркемнең үз вөҗдан эше, аннары җыенда төрле яктан килгән кешеләр белән фикер алышканда бу мәсьәлә барыбер калкып чыгар һәм шул вакытта киңрәк мөзакәрә кылыныр әле, дигән уй белән ул хәзергә бу хакта сүзне озынайтмаска булды.

Башкача сөйләүче булмагач, Талышинский йомгаклагандай әйтте:

— Комиссиягә өч тәкъдим кертелде. Беренчесе — Галимҗан Ибраһимов һәм Хәлиулла Еникеев әфәнделәр тарафыннан язылган сәяси программаны шул килеш кабул итү. Икенчесе — икътисади һәм мәдәни мәсьәләләрне кушып, сәяси программаны киңәйтү. Өченчесе — муллалар, гомумән, руханилар турында әйтелгән кимсетүле сүзләрне сәяси программадан чыгарып ташлау. Бу өч тәкъдимне бергә кушыпмы, яки аерым-аерым тавышка куябызмы?

Галимҗан Ибраһимовтан башкалар:

— Бергә кушып!

— Бергә кушып! — дип кычкырышып, кулларын күтәрделәр.

Оештыру комиссиясенең әгъзалары сәяси көрәшкә чыннан да җитди әзерләнергә уйлыйлар кебек тоелды Ибраһимовка. Шулай да Алибәковның муллалар турындагы чыгышы һәм Хәлләдән башкаларның аңар кушылулары егет күңелендә борчулы уйлар тудырды...

* * *

Дүртенче апрель көнне Хәнәфи Кайбышевтан килгән телеграмма Галимҗан Ибраһимовка көтелмәгән дәрәҗәдә авыр тәэсир итте. Кулы пешкәндәй кискен хәрәкәт белән телеграмманы өстәл өстенә атып ташлады, ләкин шунда ук аны кире алып учы белән каплады, башын түбән иеп уйланып калды.

Телеграмма Габдулла Тукайның вафаты турында иде.

Соңгы вакытта шагыйрьнең авыруы көчәеп, Клячкин шифаханәсендә ятуын Галимҗан Ибраһимов белә, ләкин аның үлү ихтималын ничектер башына да китерми иде. Дөресрәге, Киевка килеп укыта башлагач, шәкертләренә ныклы белем бирү өчен нинди программа нинди ысуллардан файдаланырга кирәклеге турында уйланулары, күптән эзләп тә, ниһаять, монда тапкан революцион мохиткә якынлашуы, ирекле тыңлаучы сыйфатында гына булса да, университет аудиторияләрендә лекцияләр, докладлар, рефератлар тыңлау дәрәҗәсенә ирешүе, Лиза белән бергәләп Киевнең мәдәни учаклары белән танышып йөрүләре, Ибраһимовны хәттин тыш бәхетле итеп, Казанның әдәби мохитеннән дә, Тукай иҗаты турындагы фикерләреннән дә ераклаштырган иде.

Телеграмманы укыгач, «Болгар» мосафирханәсенең Тукай торган бүлмәсендә очрашулары, өстәл өстендә кайнап утырган самавырдан да ныграк кайнарланып әдәбият, шигърият турында бәхәсләшүләре, ихтыярсыз, Галимҗанның күз алдына килеп басты. Тукай, һичшиксез, зур талант иде. Ләкин дөньяда чагында ул талантын бөтен көчкә янгыратып яшьни, күкри алмады шикелле. Моның сәбәбе нәрсәдә?

Галимҗан Ибраһимов бүлмә буйлап йөренә башлады һәм йөри

торгач, һәрвакыттагы кебек, башында туган уйлары бер җепкә тезелеп тигез генә аккан төсле булдылар. «Дөрес,— диде ул үз-үзенә.— Тукай тормышы белән чын алтынга бай мәгъдән иде. Ләкин гамәлдә талантлар бөтенләй үк мөстәкыйль була алмыйлар. Алар да дөньядагы һәммә нәрсә кебек тарихның, тормышның әллә ничә төрле агымнары эчендә кайнап, хәятнең һәрбер таләбенә бурыч түләп барырга мәҗбүрләр».

Фикеренең дөреслегенә шикләнгән сыман, ул кинәт бүлмә уртасында туктап калды. «Чыннан да, бу канун табигатьнең бөтен хадисәләренә дә туры киләме икән?» — дип уйлады. Күзләрен кысыбрак бер ноктага карап торганнан соң соравына җавап тапкан кебек булды. Тагы бүлмә буйлап йөри башлады. «Әйе, бу — фәкать адәмнәргә генә хас булган хәл түгел! Бөтен табигатьтә шулай! Әгәр асыл чәчәкне суык шимальгә, мүкләр генә үсә торган карлы тау башына күчереп утырсаң ни булачак? Шагыйрьләр, талантлар да шулай. Аларның үсүе, асыл гөл булып матур чәчәкләр атуы өчен тиешле шартлар, кайнап торган хәят кирәк»,— дигән карарга килде. Шушы фикернең дөреслегендә ул шикләнми иде. Әдәбият сандугачлары булган шагыйрьләр сайрау сәләтләрен югалтмасыннар өчен йөрәкләренә көч биреп торган җанлы хәят кирәк. Ләкин хәзерге көндә, безнең ике уртада калган, җанлы хәяттән мәхрүм булган тормышыбызда тик эш атлары, сабан үгезләре генә куәттән язмый. Нәзек җаннар исә, суларга һава таба алмыйча, карлы тауга туры килгән асыл гөл кебек корыйлар».

Бу уйлар Галимҗан Ибраһимовны күкрәгенә авыр таш куйган кебек итеп тарсындырдылар. Аның якты кояшлы урамга, кешеләр арасына чыгып китәсе килде. Ул Киевнең иң матур, иң шау-шулы җире саналган Крещатикка чыкты. Урамны бер-ике кат әйләнсә дә, уйлары һаман шул Тукай иҗатына, аның авыр язмышына кайталар иде. Сәнгатькә тышкы матурлык бирә торган хосусиятләргә артык дәрәҗә әһәмият биреп фимиам төтәтү, Галимҗан Ибраһимовның күзләрен әчеттереп, Габдулла Тукай иҗатының мәгънәви кодрәтен, хакыйкый матурлыгын ачык күрергә ирек бирми иде...

Крещатик буйлап бер-ике сәгать йөргәннән соң ул бераз тынычланган кебек булды. Үзләрен шагыйрьнең дуслары дип санап йөргән дошманнарын фаш итеп, тотнаксыз мактаулары белән аларның Тукай талантына нинди зур зыян китерүләрен күрсәтеп мәкалә язу — минем бурычым, дигән карарга килеп, Ибраһимов фатирына кайтып китте. Шул көнне үк утырып уйлаган эшен тәгалләде. Киевтә сәяси түгәрәккә катнашу, үзләрен сәяси көрәшкә багышлаган Зураб, Лиза, Агаш кебек кешеләр белән аралашу Галимҗан Ибраһимовта революционер булырга теләгән кеше үз мәсләгендә, үзенең карашларында корыч кебек нык торырга, кирәк чакта бернәрсәдән дә курыкмыйча кискен рәвештә үз фикерләрен яклый белергә тиеш, дигән ышаныч тудырганнар иде. Мәкаләне дә Галимҗан Ибраһимов шул ышанычына нигезләнеп язды.

Мәкалә бик кискен, хәтта дорфа булып чыкты. Автор моны үзе дә сизде. Шулай да аның бер сүзен дә үзгәртмәде. Киресенчә, хаклы дип ышанган фикерен шулай революционерларча каты һәм кискен рәвештә әйтә белүенә канәгать булды. Мәкаләне конвертка салганчы, тагын бер кат укып чыкты: «Юк, әлегә моны бастырырга ярамый. Тукайның вафаты халык арасында тудырган матәмле хисләр бераз басылсын, югыйсә, фикерләрем бу көннәрдә тиешенчә дөрес аңлашылмас»,— дип мәкаләне өстәл тартмасына куйды.

Бу мәкалә бер елдан соң гына «Йолдыз» газетасы битләрендә басылып чыкты. Ләкин бер ел үткәч тә татар халкы Галимҗан Ибраһимовның Габдулла Тукай иҗаты турындагы фикерләрен кабул итәргә теләмәде.

1913 елның 17 апрелендә Киевтә үткәреләчәк җыенга чакыру кәгазе Казан яшьләренә 14 апрельдә килде. Дәгъватнамәдә[1] вәкил сайлап, аңа тиешле күрсәтмәләр биреп, Киевкә җибәрүләрен үтенгәннәр иде.

Бу кәгазьне алу белән, яшьләр үзара тиз генә хәбәрләшеп, теш докторы Хәдичә ханым Ямашеваның өенә җыелдылар.

Биредәге унбишләп кеше арасында күпчелеге студентлар булса да, яшь мөгаллимнәр дә, хәтта чакырылса-чакырылмаса да, һәр җиргә тыгылырга тырышкан, кай җире беләндер сасы көзәнгә охшап торган учитель Төхфәтулла Мамлеев тә бар.

Хат Хәнәфи Кайбышев адресына килгән иде. Шуның өчен аны мәҗлестәгеләргә Хәнәфи укыды. Узган ел Хәлиулла Еникеев Казанга килеп, Киевтә башланган яшьләр хәрәкәте турында сөйләгәч, һәм шул хәрәкәткә кушылырга димләгәч, Кайбышев, Байтирәков, Мостафиннардан өч кешелек ячейка сайлаганнар иде. Киевкә җибәреләчәк вәкилнең юл хәрәҗәтләренә акча җыю, аңа биреләчәк күрсәтмәләр турында уйлану кебек эшләр дә бу ячейкага тапшырылган булганга, хат укылып беткәч тә Кайбышевның сүзен көтеп, яшьләр эндәшми утырдылар.

— Үткән мәҗлестә сайланган ячейка ике тапкыр җыелып вәкилгә биреләчәк күрсәтмәләр турында уйлашты һәм билгеле бер карарга килде, акча да җыйналды,— диде Хәнәфи, җыелышның үзеннән ни көткәнен аңлап.— Ләкин хәзер мин башка нәрсә турында әйтмәкче булам. Ул вакытта мин Хәлиулла әфәнденең тарафдары булып сөйләгән идем һәм ячейкага сайландым. Ләкин бу турыда байтак уйланулар соңында шул карарга килдем: татар халкының язмышын бары тик студентлар кулына гына тапшыру була торган эш түгел! Бу фикерне мин сайланачак вәкилебез өчен язылган күрсәтмәләрдә беренче маддә итеп кертелүен үтендем. Бу күрсәтмәләр хәзер Гафур Коләхметов әфәнденең кулында. Вакыты җиткәч, ул сезне ячейканың карарлары белән таныштырыр.

Фикерен ныграк исбат итәр өчен Кайбышевның тагын сөйләргә дәрте бар иде, ләкин Фуат Туктаров, үтә төче зыялы булып күренү гадәтен онытып, аның сүзен бүлде:

— Хәнәфи әфәнде бик дөрес әйтә! — дип кычкырды да, шунда ук исенә килгәндәй, аңа таба борылды.— Гафу итегез, мин сезнең сүзегезне бүлдем, кичерегез, зинһар! — дип башын иде. Хәнәфи дә төчелектә Туктаровтан калышмады, көлемсерәп уң кулын күкрәгенә куйды һәм:

— Зинһар, борчылмагыз! Рәхим итеп фикерегезне соңына кадәр әйтүегезне үтенәм! — диде.

— Рәхмәттән гаҗизмен, әфәндем! — дип, Туктаров куе кара мыегын имән бармагы белән ике якка сыйпап куйды һәм бик канәгать булып сүзен дәвам итте: — Уйлап карагыз, әфәнделәрем: халыкның ихтыяҗларын тик студентлар гына аңлыйлар, тик аларның гына күрәшерлек, халкыбызны якты тормышка алып барырлык сәләтләре бар икән, имеш! Хәзерге көндә сөргендә яшәгән көрәшчеләребезне милләтебезнең язмышы һич кызыксындырмыймы икәнни? Шулай булгач, бары тик студентлардан гына торган җыеннарның, съездларның кемгә кирәге бар?!

Соравына җавап көткән төсле, Фуат әфәнде туктап калды, күзе белән бүлмәдәгеләрне сөзеп чыкты. Шул тынлыктан файдаланып Абдерәшит Фәхретдинов исемле яшь егет сүзгә кысылды:

— Шуны да исәпкә алырга кирәк, например, бу кеше бүген студент, значит, Киев студентларының фикере буенча ул, конечно, халык-

---

[1] Дәгъватнамә — чакыру кәгазе.

ның интересларын яклаучы фидакарь көрәшче. Вдруг, бу кешене иртәгә университеттан кусалар, яки дә ул университетны тәмамлап, доктормы, адвокатмы, агрономмы, әллә тагын башка специалист булыпмы чыкса, ничек?! Инде бит ул студент түгел, значит, студент булмагач, көрәшче дә була алмый! Бу бит абсурд! Моннан нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин? Минемчә, мөселман студентларының съездын чакыру мәгънәсез, кирәкмәгән эш! Бу — вакытны бушка үткәрү генә булачак!

Фәхретдиновтан соң яшь укытучы Гафур Коләхметов сүз алды. Аның чырае Фәхретдиновның чыгышыннан бер дә риза түгеллеген күрсәтә иде.

— Әйдәгез, бирегә җыелуыбызга сәбәп булган нигез мәсьәләгә күчик,— дип, ул Фуат Туктаровка кырыс караш ташлап алды.— Киев студентларының әмәлләрен мәгънәсез, кирәксез эш дип әйтү, минемчә, дөрес булмас. Иң беренче нәүбәттә, бу әмәл яшьләр арасында безгә бик кирәк булган хәрәкәтнең җанлана башлаганын күрсәтә. Тик аны туры юлга юнәлтү турында уйлашырга кирәк безгә. Әгәр унҗиденче апрельгә тәгаен ителгән җыенга вәкилебезне җибәрсәк, Киев студентларының теләкләрен, ният-омтылышларын ачыкласак, аларны да үзебезнең гаяләребез, карашларыбыз белән таныштырсак, анда кабул ителгән карарлар буенча эш йөртергә мөмкин булыр,— дип, сүзен бетерде.

Коләхметовның чыгышына бик кызулык белән студент Искәндәр Мостакыймов кушылды:

— Менә бу — туры фикер! Җитәр, кырын ятып болай да бик озак йокладык. Хәрәкәтләнә башларга вакыт! Бәлки, әйтәчәк фикерем ул кадәр әһәмиятле дә булмас, шулай да Коләхметов әфәнденең әйткәннәренә шуны өстәр идем: әгәр без җыенга үз вәкилебезне җибәрмәсәк, Казан яшьләрен куркаклыкта, яки дә артта калганлыкта гаепләрлек сәбәп булмасмы бу?

Мондый ихтималның булуы һәркайсын гамьгә салды. Моңарчы эндәшми утырган яшьләрнең дә тавышлары чыкты:

— Чыннан да, шулай дип уйлаулары бик мөмкин!

— Бушка вакыт үткәреп, бәхәсләшеп утырудан файда юк. Вәкил сайларга да Киевкә озатырга кирәк — дип, Коләхметов белән Мостакыймовның чыгышларын куәтләүчеләр күбәйде.

Вәкил сайлау вакытны күп алмады. Нурелгаян Байтирәковның:

— Әбүбәкәр Имамбаевны сайлыйк. Студентлыгын ташламаса да, ул быел лекцияләргә йөрми. Аңардан да уңайлы кеше табылмас! — дию белән барысы да аның тәкъдимен кабул иттеләр.

Вәкилгә күпме юл акчасын бирү, аңа йөкләнәчәк вазифаларны ачыклау кебек мәсьәләләр үткән ел декабрь ахырларына сайланган ячейка тарафыннан эшләнгән булсалар да, аларны монда мөзакәрә итү тагын бер-ике сәгатькә сузылачагы сизелә иде. Хәнәфи Кайбышев урыныннан кузгалды. Ул ашыга иде. Өстәл тирәсендә утырганнарга мөрәҗәгать итеп:

— Мине кичерегез! Тәәсефкә каршы[1], китәргә мәҗбүрмен! Сезгә үтенечем шул: вәкилгә тапшырылачак һәм хәзерге моментта Коләхметов әфәнденең кулында саклана торган күрсәтмәләргә мин тулысынча кушылам. Бу мәсьәлә тавышка куелган тәкъдирдә моны игътибарга алуыгызны үтенәм,— диде.

Хәнәфи башкалардан читтәрәк утырган өй хуҗасы Хәдичә ханым Ямашева янына килеп басты һәм ягымлы елмаеп, аның алдында башын иде. Хәдичә ханым:

— Нигә болай ашыгасыз? Тиздән чәй булыр, чәйгә калыгыз! — диде.

— Бик зур рәхмәт, Хәдичә ханым! Бик ашыгыч эшем булмаса, сезнең дәгъватегезне кире кагарга җөрьәт итмәс идем. Миңа рөхсәт итүегезне үтенәм! — дип, өй хуҗасы белән саубуллашып чыгып китте.

---

[1] Тәәсефкә каршы — кызганычка каршы.

* * *

Урамга чыгу белән Хәнәфи Кайбышев тирә-ягына каранып, бераз басып торды. Аннары, вакыт-вакыт кесәләрен капшаган, папирос кабызган булып, артына әйләнеп карана-карана, охранка бинасына барып житте. Тиз генә тирә-ягына күз ташлады, беркемне дә күрмәгәч, капкадан үтеп, бинаның арткы ишегенә юнәлде.

Башка вакыт булса ул болай тәвәккәлләмәс тә иде. Ләкин узган ел Хәлиулла Еникеев килгән чактагы җыелыш турында икенче көнне генә хәбәр иткәне өчен, охранка аңа кисәтү ясаган һәм яшьләр арасында сизелгән һәрбер хәрәкәт, һәрбер җыелыш, утырыш турында бер сәгать тә кичекмичә белдерергә тиешлеген әйткән иде.

Бу юлы Кайбышевның доносын язып тапшыруын да көтмичә охранка, утырышта катнашучыларны кичекмәстән тотар өчен, бик тиз генә полиция нарядын җибәрде.

Полиция килеп кергәндә Имамбаев белән Мамлеевтән башкалары әле китеп өлгермәгән, чәй эчеп утыралар. Әбүбәкер Имамбаев юлга кирәк булган акчаны һәм үзенә тапшырылган күрсәтмәләрне алганнан соң, юл кирәк-яракларын карыйсы бар дип, ашыгыч чыгып киткән иде инде.

Төхфәтулла Мамлеевнең исә чәйгә калмыйча чыгып китүенең сәбәбе бөтенләй башка. Аңа да, мөмкин кадәр иртәрәк, бу утырыш турында охранкага донос язып тапшырырга кирәк иде.

Жандармнарның көтелмәгәндә шулай кинәт килеп керүләрен күргәч, яшьләрнең кайберләре аптырап, кайберләре каушап, куркынып калдылар. «Болар безнең монда җыелганны каян белделәр икән? Әллә берәребез артыннан шымчы ияреп йөриме? Кем артыннан ияргүе ихтимал? Охранканың дикъкатен җәлеп итәрлек кешеләрдән бүген монда үзенең революцион фикерләре белән мәгълүм Хәнәфи Кайбышевтан башка кеше юк. Житмәсә тагын, Хәнәфи Кайбышев әле күптән түгел генә охранка кулына эләгеп зинданда утырып та чыкты бит! Аның артыннан ияреп килүләре бик ихтимал шул!» — дип уйлаучылар да булды. Ләкин, безнең утырышта берьюлы ике провокатор, ике охранка агенты бар иде, дигән фикер берсенең дә башына килмәде. Хәлбуки, охранкада «Житель» кушаматы белән йөргән Төхфәтулла Мамлеев, «Теоретик» кушаматы белән йөргән һәм охранканың иң ышанычлы агентларыннан саналган Хәнәфи Кайбышев читтән күзәтеп йөргән шымчылардан да куркынычрак иделәр. Өйдәге карактан сакланып булмый бит! Хәлиулла Еникеевнең сизгерлеге бар икән шул! Яшьләр арасында философ, әдип, галим, революционер дип саналган һәм шулай күренергә тырышкан Хәнәфи Кайбышев, чыннан да, провокатор иде!

Охранканың боерыгы белән килгән полиция бүлеге күзәтүчесе иң әүвәл яшьләргә утырган урыннарыннан кузгалмаска, үзара сөйләшмәскә кушты. Аннары, барысының да исем-фамилияләрен язып алды. Тик шуннан соң гына үзе белән алып килгән городовойларга егетләрнең өс-башларын тентергә боерды.

Өйдә дә, егетләрнең кесәләрендә дә бирегә ни өчен җыелуларын күрсәткән бер төрле дә документ чыкмагач, полиция күзәтүчесе Ямашевадан:

— Бу кешеләрне монда ни өчен җыйдыгыз? — дип сорады.

Хәдичә ханым бик гаҗәпләнгән кыяфәт белән:

— Әллә дус-ишләрне кунакка чакыру, яки туган көн мөнәсәбәте белән кунак сыйлау сезнеңчә бик зур гөнаһмы? — диде.

Ханымның җавабы күзәтүченең ачуын китерде. Мыскыллы тавыш белән ул:

— Сез бик үткен, әче телле ханымга охшыйсыз. Хатын кеше була торып, ни өчен ирләрне кунакка чакыруыгызның сәбәбен аңлатып бирерсез, бәлки? — дип, мәгънәле итеп сорады.

Чиктән тыш гарьләнүеннән Ямашеваның яңаклары алсуланды.

— Сез монда хатын кешенең намусына тукыныр өчен килдегезме әллә? Полиция күзәтүчесе булгач сезгә сүз дә, кул да тидерергә ярамаганлыктан файдаланасызмы? — дигән сүзләр белән утырган урынынннан торып алга атлады. Ул шул дәрәҗәдә ярсынган иде ки, хәтта тавышы яңгырап, теле тотлыга башлады. Күзәтүче аптырый төште. Ул мондый һөҗүм булыр дип көтмәгән иде. Ләкин үзенең каушап калуын сиздермәскә тырышты. Җирән кашларын җыерып катгый әйтте:

— Берәү дә сезне хурламый, кимсетми. Ләкин рөхсәтсез җыелышлар ясарга ярамаганын яхшы беләсездер, ә сезнең өегездә уннан артык кунак бар. Менә шуның өчен мин сезгә биш йөз сум штраф, ә калганнарга йөзәр сум штраф салам!

Икенче көнне иртән, Кайбышевның доносы буенча, Казан жандармерия башлыгы Киев жандармериясенә шифр белән язылган телеграмма суктырды. Бу телеграммада унҗиденче апрельдә Киевтә Пушкинская урамының 34 йортында студентларның яшерен җыены булачагы һәм бу җыенга университетлы башка шәһәрләрдә укучы яшьләр исеменнән вәкилләр барачагы, ә Казаннан исә вәкил булып казах егете китәчәге турында әйтелгән иде.

* * *

Казан жандармериясеннән телеграмма килү белән, Киев жандармериясе башлыгы полковник Шредель үзенең хозурына подполковник Лахутинны чакырды. Подполковник килеп урындыкка утыруы белән Шредель аның кулына телеграмманы тоттырды һәм бик тәрбияләп үстергән, күпереп торган куе сакалын ике якка сыйпаштыргалап, Лахутинның депешаны укып бетергәнен көтеп торды. Подполковник кәгазьне кирәгеннән озаграк тотып торганнан соң, ниһаять, аны өстәлгә куйды. Шуны гына көтеп торган Шредель:

— Борын төбебездәге вакыйгаларны безгә әллә кайдагы Казан күрсәтеп утыра. Бу дәрәҗә ваемсызлыкның сәбәбен ачып бирсәгез бик яхшы булыр иде! — дип, подполковникка шелтә белән карады.

— Бу хәрәкәт, һичшиксез, яңа башланган булырга тиеш. Үзегез беләсез, галиҗәнап Романовлар династиясенә өч йөз ел тулу мөнәсәбәте белән эш бик күп булды. Ул көннәрдә бөтен дикъкатебезне, бөтен көчебезне социал-демократлар, социал-революционерлар, анархистлар, бундчылар кебек фетнәчеләр җәлеп иттеләр. Халык арасында төрле чуалышлар тудыра күрмәсеннәр дип, шулар артыннан бертуктаусыз күзәтеп торырга, һәрбер омтылышларын кисәтеп торырга кирәк булды,— дигән җавапны алгач, Шредель Лахутинны артык шелтәләп утырмады, чөнки юбилей алдындагы һәм юбилей көннәрендәге эшнең ни дәрәҗәдә киеренке булганын подполковник әйтмәсә дә яхшы белә. Икенче яктан, Киевтәге аз санлы мөселман студентларының әллә нихәтле зур хәрәкәт тудыра алу ихтималына ул ышанмый иде. Бармаклары белән өстәлне бераз шакылдатып алды да:

— Я, хәзер нишләргә уйлыйсыз? — дип сорады.

Подполковник Лахутин күп уйланып тормады. Аның җавабы телеграмманы укыган чакта ук әзер иде. Ул бит аны кулында юкка гына кирәгеннән озаграк тотып утырмады.

— Минемчә, телеграммада күрсәтелгән йортны күзәтеп тору өчен ике шымчы җибәрергә кирәк. Алар үзара алмашып, өч-дүрт сәгать үткән саен ни күргәннәре турында охранкага хәбәр биреп торырлар. Шулай ук вокзалга да ике шымчы җибәрергә кирәк. Казаннан киләчәк казах егетен тану кыен булмастыр. Башка шәһәрләрдән килгән студентларны Пушкинская урамына җибәрелгән шымчылар исәпкә алып калырлар.

Полковник Шредель Лахутинның планы белән ризалашты. Кичектермичә, университет канцеляриясеннән мөселман студентлары арасында ышанычсыз күренгәннәренең рәсемнәрен алдырып, шымчыларга күрсәттеләр. Бу эш юкка булмады. Икенче көнне үк студентларның фамилияләрен атап-атап, шымчылардан игътибарга лаек доносლар килә башлады.

Шул араны вокзалдагы ике шымчы Казаннан киләчәк вәкилне көтә иде. Ниһаять ул да Киевкә килеп төште. Поездан төшкән кешеләр арасыннан киң яңаклы, кысыграк күзле казах егетен танып алу шымчыларга авыр булмады.

Казан суыкларыннан йөдәгән Имамбаевка Киевнең һавасы саф, рухландыргыч нурлы, җылы булып тоелды. Әнә агачлар яңа ярган ялтыравык яфраклары белән зиннәтләнә башлаганнар. Зәңгәр күк йөзендә, аккошларга охшаш ак болытлар йөзә. Урамда очраган кешеләрнең йөзләре ачык, елмаючан. Я, мондый матур көндә ничек итеп яманлык бардыр дип уйлыйсың? Имамбаев үзе дә якты чырай белән артына да, тирә-ягына да карамыйча алга атлады һәм беренче очраган яшь егеттән:

— Пушкин урамы еракмы? Анда ничек барырга? — дип сорады.

Шымчылар шул урамдагы Рустамбеков торган йортка хәтле аның артыннан калмый озатып килделәр.

Җыенның унҗиденче апрельдә башланачагын белгән жандармерия башлыгы губернатордан да, прокурордан да тентү ясарга һәм, кирәк булса, кулга да алырга рөхсәт бирә торган кәгазьләрне әзерләткән иде инде. Шымчылар җыен башлануы турында хәбәр бирү белән, подполковник Лахутин бульвар участогына шалтыратты. Анда да әзер торалар иде. Шул ук минутта пристав үзенең ярдәмчесе Шмырев белән дүрт городовойны Назарьев урамына җибәрде.

Җыен әле яңа башланган иде. Ярый әле ишекне кемдер бикләп куйган, городовойлар турыдан-туры басып керә алмадылар, ишекне шакырга мәҗбүр булдылар.

— Кем анда? — дигән сорауга каршы тупас, калын тавыш:

— Ачыгыз? Хәзер үк ачыгыз!! — дип кычкырды.

Шундый кыргый тавышны ишеткәч, яшьләр бөтенләй каушап калдылар.

Арада Еникеев кенә аптырамады. Иптәшләренә:

— Тизрәк кәгазьләрне яшерегез! — диде дә, ишеккә таба атлады.

— Хәзер ачабыз! Тик ачкычны таба алмыйбыз, куйган җирне онытканбыз! — дип, күбрәк тавыш чыгарырга тырышып, урындыкларны урыннан-урынга сөйрәргә тотынды. Тыш яктан бөтен өйне тетрәтерлек итеп ишекне тагын да катырак тарткалый, кага, шакылдата башладылар. Еникеев, иптәшләренең кулларындагы кәгазьләрне ашыга-ашыга кием шкафы, буфет, келәм, матрац асларына яшергәннәрен карап торды да:

— Таптым ачкычны, ачам, хәзер ачам! — дип сөйләнә-сөйләнә, ишекне ачалмый газапланган кеше кебек вакытны тагын беразга сузды. Иптәшләренең кулларында бернәрсә дә калмавын күргәч кенә: — Уф! — дигән булып уфтанып ишекне ачты. Ачуыннан күркә кебек кабарган надзиратель артыннан бүлмәгә бер-бер артлы городовойлар, алардан соң уңайсызланудан кутәрелеп тә карый алмаган ике пунәтәй килеп керделәр.

Тентү башланды.

* * *

Иртәгә Киевтәге мөселман студентларының башка шәһәрләрдән килгән вәкилләр белән берләшкән җыены була дигән көнне Галимҗанга ике кунак килде. Боларның берсе Мәскәү коммерция институтында укучы Гариф Кәримов, икенчесе Петербург университеты студенты Нәҗип Корбангалиев иде. Икесе дә Галимҗан Ибраһимов белән танышлар, иркенләп сөйләшер өчен махсус бер көн элгәре килгәннәр икән. Галимҗанга

болар берсеннән-берсе ягымлы, ачык йөзле, кыю карашлы егетләр булып күренделәр.

Беренче күрешү-танышу вакытында әйтелә торган гадәттәге сүзләрдән соң, Галимҗан Ибраһимов кунакларыннан сорап куйды:

— Бу җыен турында фикерегез ничек? Сезнеңчә кирәк эшме бу, яисә мәгънәсез, киләчәге өметсез буш хыялмы?

Егетләр икесе дә бердән кабынып киттеләр. Нәҗип Корбангалиевнең:

— Ник хыял булсын?! Шулай дип уйласак, без монда килмәгән булыр идек! — дип әйтә башлаган сүзен Гариф Кәримов эләктереп алды:

Бу эшне әллә кайчан башлау зарур иде! Патша хакимиятен себереп ташларга күптән вакыт инде! Әлбәттә, берләшергә, кара көчкә каршы рәхимсез көрәш ачарга кирәк!

— Монархия үзенә каршы көрәшүчеләрне башларыннан сыйпап, иркәләп утырмас, әлбәттә! Зинданнар, крепостьләр, каторга, столыпин галстугы — барысы да аның үз кулында бит! — дип, Нәҗип тагын сүзгә кушылды. — Бу мөкатдәс көрәш юлына аяк баскан кешеләр үзләрен авыр кичерешләрдән, авыр сынаулардан курыкмаслык итеп әзерләргә тиешләр!

Гариф Кәримов тә Нәҗипнең сүзләрен куәтләде:

— Дөрес! Төрле кыенлыклардан, газаплардан курыккан кешеләргә менә шуның өчен дә безнең арада урын бирелмәскә тиеш!

Аларның чын күңелдән сөйләгәннәрен Галимҗан Ибраһимов яхшы аңлады, ихтыярсыз: «Чын мәгънәсендә батыр революционер булачак егетләр икән болар! Реакция елларында иманнарын, юлларын югалткан Казан егетләре түгел! Болар мактанмыйча, кайгырмыйча һәрбер куркынычка, һәрбер дошманга каршы торачаклар» — дип уйлады, сокланып кунакларына карап торды. Мондый егетләрнең көрәштән тайпылмасларына нык ышанды һәм алар башлаган сәяси хәрәкәткә якынрак торып, кулдан килгән кадәр дөрес юлга салырга кирәклеген аңлады. Шулай да ул җыенның беренче утырышына бара алмады. Беренчедән, бу хәрәкәтнең сәяси программасын аныклау турында киңәшләр өчен ул Зураб белән дә, Николай белән дә очрашып сөйләшергә өлгермәде, икенчедән, Галимҗан үзенең шәкертләрен көн саен укытырга мәҗбүр иде. Чөнки русларның бөек уразалары сәбәпле, гимназияләрдә һәм университетта дәресләр бөтенләй үк тукталмаса да, уку сәгатьләре киметелгән һәм шунлыктан шәкертләрнең буш вакытлары күбәеп киткән иде. Шуның өстенә, университет китапханәсендә дә озаграк утырып калган икән. Һәрхәлдә, бүлмәсенә кайтып кергәндә сәгать унберенче иде инде. «Бүген анда барыбер җыенны ачып җибәрү, килгән вәкилләрне сәламләү кебек рәсми вазифалар гына үтәләчәк, җитди эшләр иртәгә генә башланыр әле. Хәлле иртәгә иртүк килеп, җыенның беренче көне ничек үткәнен энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирер», — дигән уйлар белән Галимҗан тыныч кына йокларга ятты.

Күңеле тыныч кешенең йокысы тирән булучан, Галимҗан да яшьлеккә хас сәламәт, тирән йокыга талган иде. Тышкы ишекне бик каты итеп кагуларына да уянмады. Керүчеләр Галимҗанның күршесендә торган студентның ишегең шакыдылар:

— Фамилиягез ничек?

Студент каушый төшеп ишекне ачты һәм фамилиясен әйтте.

— Сезгә түгел икән шул, — диде керүчеләрнең берсе. — Безгә Ибраһимов кирәк, ул кайда тора?

Боларның барысын да Галимҗан йокы аралаш ишетеп торды, ләкин өнме, төшме икәнен аера алмады. Бары тик зал аркылы тәкәллефсез атлап килгән шпорлы итекләр аның ишеге янында туктап, кемнеңдер боерулы, рәхимсез тавыш белән:

— Ачыгыз! — дип акыруыннан соң гына ул тәмам уянып китте. Ләкин шунда да «җандармнардыр» дигән уй аның башына килмәде. Яткан урыныннан кузгалмыйча:

— Кем анда? Мин чишенеп яттым инде, гафу итегез, кертә алмыйм,— дип җавап бирде.

Ләкин ишекне тагын да катырак ккактылар. Калын тавыш тагын да ачулырак ишетелде:

— Сезгә әйтәләр, ачыгыз! Без кунакка килмәдек!

Шуннан соң гына, Галимҗан Ибраһимов үзенә кемнәр килгәнен аңлап алды һәм, сабыр итегез, дия-дия урыныннан торып, электр лампасын яндырып җибәрде.

Ләкин төнге кунаклар сабыр итәргә теләмәделәр. Ишек ярыгына нечкә тимер тыгып келәне күтәрделәр дә бүлмәгә зәңгәр шинельле жандарм, аның артыннан берничә городовой, йорттагы дворник, каравылчы басып керделәр. Зәңгәр шинельле кырыс тавыш белән:

— Жандармерия башлыгының әмере буенча сездә тентү ясарга килдек,— диде.

Галимҗан Ибраһимов ашыкмый гына аягына итек киде, Тинчуриннан алып торган накидканы җилкәсенә салды. Шуннан соң гына сүзен әйтте:

— Рәхим итеп ордерыгызны күрсәтегез.

Жандарм шөбһә катыш шелтә белән Галимҗанга карап алды.

— Ә-ә! Сез тәҗрибәле бүре икән! Шула-а-ай! — дип, мәгънә белән әйтеп куйды.

Галимҗан Ибраһимов та җавапсыз калмады:

— Моңа кадәр андый тәҗрибәмнең булганы юк әле. Ләкин рәсми ордерсыз тентү ясарга ярамаганын ишеткәнем бар.

Ордерны күрсәттеләр дә тентү башладылар. Галимҗан тирән креслога җайлап утырды да һәм ашыкмый гына папирос кабызды. Тыштан караганда ул бик тыныч күренә иде.

Моңа кадәр бүлмәдә тәртипсез рәвештә таралып яткан барлык китаплар, журналлар, газеталар, дәфтәрләр, хатлар, рәсемнәр, хәтта язулы кечкенә-кечкенә кәгазьләр, буш конвертлар бөтенесе дә жандармнар кулына кереп чыкты. Аларның берсен дә калдырмыйча карап, тикшереп чыкканнан соң төен-төен итеп бәйли башладылар. Төнге беренче яртыда башланган тентү иртәнге сәгать алтыда гына бетте. Надзиратель Крумин шулкадәр дә арыган иде ки, протоколының соңгы ике юлында «төенчек» дигән сүзне дүрт тапкыр кабатлавын да сизмәде. Пүнәтәйләрдән протоколга кул куйдырганнан соң жандарм:

— Ибраһимов, киенегез! Сезне кулга алырга әмер бар! — диде.

Городовойлар алты төенгә бәйләнгән нәрсәләрне күтәрделәр, Галимҗан да өс-башына киенеп, ишеккә атлады.

Бульварный дип йөртелгән полиция бүлеге бик якын иде, бишүн минутта барып та җиттеләр. Ярым караңгы, юеш, сасы коридорлар буйлап баргач, пычрак тимер баскычтан менеп, кизү бүлмәсенә кереп килгәндә, иң беренче булып Галимҗанның күзенә оешманың секретаре Гөлсем Әхтәмова чалынды. Йокысыз үткән төн сәбәплеме, туташның йөзендә үлем аклыгы, күзләре кып-кызыл, үзе тәмам хәлдән таеп утыра. Околоточныйга редикюленнән акчаларын, кәгазьләрен, кечкенә алтын сәгатен чыгарып биргәндә кулларының кылтыравын тыя алмады. Кызның бирегә ни өчен китерелүен белмәгәнгә салышып, Галимҗан Ибраһимов:

— Бу ни хәл? Сез ни өчен бирегә? — дип сорады.

— Сөйләшмәгез! — дигән әмергә карамастан, Гөлсем туташ калтыраган тавыш белән:

— Әйтәсе дә юк инде! Мин генә түгел, Ахундов та эләкте... Башкаларны да монда китерделәр...— дип әйтергә өлгерде.

Әхтәмованы каядыр алып киткәч, Ибраһимовның кесәләрен тагын бер тапкыр тентеп тикшерделәр, шул ук сасы коридорлар, себерелмәгән тимер баскычлар буйлап каядыр алып бардылар, ниһаять, караңгы почмактагы зур тимер ишекне янгыратып ачтылар да, аркасыннан төртеп, коридордан да караңгырак бүлмәгә кертеп җибәрделәр, артыннан ишекне шалтыратып ябып, авыр йозак салдылар.

Күзләре бүлмәдәге караңгылыкка күнеккәнче, Галимҗан ишек янында басып торды. Кемдер ишекле-түрле йөренеп, карлыккан ямьсез тавыш белән: «Я шансонетка, стреляю метко...» — дигән сүзләрне кабатлый иде. Инде юеш таш стена буйлап ике якта ясалган агач сәкеләр дә ачык күренә башладылар. Анда сары төймәле шинельләрен ябынып, студентлар йомарланып яткан. Болар арасында ул Еникеевне, Казаннан килгән Имамбаевны, Мәскәү вәкиле Гариф Кәримовны, Петербург студенты Нәҗип Корбангалиевне һәм сөргендә яшәгән Иран шаһының секретаре, Одессадан килгән аристократ Насырбәков Абдулфән ханны, киевле студентлардан Талышинскийны, Ордубатскийны, Ахундовны һәм Рустамбековны танып алды. Йокламыйлар икән. Әллә, йоклаган булсалар да, камерага яңа кеше килеп кергәч уянганнармы? Ничек кенә булмасын, Хәллә Еникеев яткан урыныннан сикереп торды:

— Бу Галимҗан Ибраһимов түгелме соң!

— Әйе, мин, Ибраһимов,— дигән җавапны ишеткәч, бүтәннәр дә кузгала башладылар.

Егетләр, борчылып, сорау бирешә башладылар:

— Я, инде ни булыр икән?

— Безне ни эшләтерләр?

— Шулай ук зинданга ябарлар микәнни?

Каршы буйдагы сәкедән дә калтыранган тавыш ишетелде:

— Инде нишләрбез? Шулай ук безне еллар буе төрмәдә утыртырлармы, Себергә сөрерләр микәнни?

Галимҗан Ибраһимовның:

— Бу кем сөйли? — дип соравына каршы, Ордубатский игътибарсыз гына:

— Батыр йөрәкле хан Талышинскийдан башка кем булсын? — дип җавап кайтарды.

— Аның батыр йөрәге жандармнарны күрү белән куян йөрәгенә әверелде,— дип өстәде Хәллә түзмичә.

Бөтен кыяфәте белән горур, нык егет булып күренгән бу студентның шул дәрәҗәдә куркуына Галимҗан Ибраһимов хәйран калды.

— Кая күпмегә утыртачакларын, шулай ук сөргенгә җибәрү-җибәрмәүләрен соңыннан белербез. Бу безнең үзебездән тора,— диде Галимҗан.— Ничек тотылдыгыз? Әлбәттә, тентү булгандыр. Нәрсә таптылар?

— Җыен башланып, Талышинский кереш сүзен сөйләп бетерергә дә өлгермәде, жандармнар басып керделәр. Бөтенебезнең исем-фамилияләребезне язып алганнан соң, тенти башладылар. Протоколларны, докладларны, тезисларны төрле урыннарга яшереп өлгергән идек инде, файдасы гына булмады, барысын да таптылар. Хәтта үзебезне дә тентеп, бер кирәк кәгазь калдырмыйча, кесәләребезне арчыдылар...

— Бөтен документларны үзегез белән алып йөрергә нигә кирәк булды икән?! Менә хәзер инде кәгазьләрнең барсы да жандармерия кулында,— диде Галимҗан.

— Шулай булды шул, нишлисең! Безнең тәҗрибәсезлек!

Бу хәл Галимҗанны чын-чыннан борчуга салды.

— Бик начар булды бит әле бу,— диде ул,— димәк, бернәрсәдән дә баш тартырга мөмкин түгел?

Елак тавыш Галимҗанның сүзен бүлде:

— Монда без гаепле әллә? Жандармнар килеп басар дип кем уйлаган?

Ордубатский ачуын баса алмады:

— Ыңгырашмый торыгыз әле! Кешегә фикерен әйтергә ирек бирегез! — дип кычкырды.

Ибраһимов сүзен дәвам итте:

— Минемчә, җыенда чит шәһәрләрдән махсус чакырылган студентлар булуын да, бөтен Русия мөселман яшьләренең съездын җыярга теләвебезне дә яшерүдән файда юк...

Тагын Талышинскийның калтыранган елак тавышы ишетелде:

— Сез ни сөйлисез! Әллә төрмәдән башыгыз чыкмасын дип әйтәсезме? Юк! Мин моңа риза түгел!

— Риза булмасагыз, үз ихтыярыгыз! Тик безне мазасызламый торыгыз әле! — дип кычкырды Хәллә.

Студентларның берсе Галимҗанның киңәшен көтеп:

— Сез нинди киңәш бирәсез? Әгәр кулларына төшкән кәгазьләрне күрсәтеп сорау ала башласалар, жандармнарга нәрсә дип җавап бирергә икән? — дип сорады.

Моңа кадәр эндәшми яткан студентлар да торып утырдылар. «Шансонетка»сын җырлап йөргән егет тә Галимҗан Ибраһимов белән Хәллә янына килеп баскан иде инде.

— Минемчә, җавап шундый булырга тиеш: безнең максатыбыз кичәләр, концертлар ясау, аң-белем тарату уңаеннан кайбер китапларны русчадан тәрҗемә итеп сату, шул юл белән табылган акчаларны мохтаҗлыкта яшәгән мөселман студентларга өләшү иде. Якташлык оешмабызны легальләштерерләр дип ышана идек. Шуның өчен университетлы башка шәһәрләрдәге мөселман студентларын үзебезнең шушы максатларыбыз белән таныштырырга теләп, алар белән язышa башладык. Съезд чакыру фикере дә менә шуннан килеп чыкты. Съездда без аң-белем таратуга, экономикага бәйләнешле мәсьәләләрне генә тикшерәчәк идек. Сәяси мәсьәләләргә кагылырга уебызда да юк иде...

Ибраһимовның гүя бармак белән санап әйткәндәй салмак кына сөйләвен тыңлап, студентлар тын калдылар.

— Минемчә дә шулай. Барыннан да бигрәк, бөтенебез бер авыздан, бертөрле җавап бирергә кирәк булыр,— диде Ордубатский бераздан.

Талышинскийның да тынычлана төшкәне сизелә иде.

— Әгәр без бернәрсә дә белмибез, болай гына дусларча утырышырга, күңел ачарга гына җыелган идек, дип әйтсәк ничек булыр? — дип сорады ул.

— Шундый чеп-чи ялганга ышанырга жандармнарны ахмак дип беләсеңме? — дип, Ордубатский аны кырт кисте.

Билгеле бер фикергә килгән кебек булгач, Галимҗан Ибраһимов та Еникеев белән Имамбаев арасына кереп, сузылып ятты.

## Зиндан

Икенче көнне иртән иртүк, Галимҗан Ибраһимовтан башкаларны, каядыр алып киттеләр. Аны тик көндезге сәгать икедә генә жандармериянең Левашевский урамындагы ямьсез, сары таш пулатына алып килделәр. Монда аны чоланга охшаган тәрәзәсез кечкенә бер бүлмәгә ябып, бик озак көттерделәр. Хәер, моңа Галимҗанның хәтере калмады. Төн буена сузылган тентү, участокта үткәрелгән йокысыз сәгатьләр аны бик арыткан иде. Чоланның бердәнбер җиһазы булган тар агач койканың такталары каты, тигезсез булуына карамастан, йокыга киткәнен сизми дә калган. Ишек ачылып, сакчы кергәнен дә ишетмәгән икән. Сакчының:

— Тор! Допроска! — дигән тавышына гына уянып китте.

Йокысы туйган, нервлар беркадәр тынычланган, сакчы аны зур, якты бүлмәгә алып кергәндә зиһене ачык, гәүдәсе җиңел иде. Ләкин караңгы чоланнан соң якты залга керү белән күзләре камашты һәм шунлыктан бераз вакыт күзләрен йомып, ишек янында басып торырга мәҗбүр булды. Бераздан соң гына Галимҗан күзләрен ачып карады һәм ишеккә каршы яктагы өстәл артында утырган киң җилкәле, икегә аерып таралган куе сакаллы, мәһабәт кыяфәтле хәрби кешене күрде. Бу кеше, аталарча елмаеп, Ибраһимовка өстәл янындагы урындыкны күрсәтте:

— Рәхим итеп утырыгыз! — диде ул. Бу — аерым жандарм корпусының подполковнигы Вахнин иде.

— Кичерегез. Мин сезне артыграк көттердем бугай. Шулай туры килде инде. Эшләр, һаман эшләр! Алар безнең теләкләр, безнең омтылышлар белән исәпләшмиләр. Киресенчә, безне үз ихтыярларына буйсындыралар! — дип сөйләнә-сөйләнә, өстәл читенә өеп куйган газеталар, китаплар өстеннән портсигарын алып ачты да Галимҗанга сузды.

— Тарта торгансыздыр, рәхим итегез! — диде.

Галимҗанның, чыннан да, тартасы килә иде, чөнки төн буена сузылган тентү вакытында ул тәмәке тартмасын бөтенләй бушаткан иде. Участокта яткан иптәшләренең дә папирослары беткән икән. Шуның өчен ул: «Дуңгыздан бер кыл — ул да файда!» — дип тартынмыйча, көмеш портсигарга кулын сузды. Подполковник шырпы яндырып биргәннән соң, үзе дә папирос кабызып, аркасын креслога терәде, төтенне тәмләп эченә суырды. Папиросын тартып бетергәнче эндәшми утырды. Соңыннан:

— Исемегез, фамилиягез ничек? Исемегезне белми мөрәҗәгать итү уңайсызрак,— диде подполковник.

Ул, әлбәттә, Галимҗан Ибараһимовның исемен дә, фамилиясен дә, кай якныкы икәнен дә яхшы белә иде, чөнки бу мәгълүматларны полиция участогы аңарга иртән үк биргән иде. Галимҗан исем-фамилиясен әйткәч, Вахнин бик үкенечле кыяфәт белән башын чайкап:

— Карап торам-торам да сезгә, кызганмыйча булдыра алмыйм! Яшь, күркәм, интеллигент булып та, шундый ямьсез, зарарлы эшкә керешүегез һич акылыма сыймый! Яшьлек, яшьлек! — диде.

Подполковник хәтта көрсенеп куйды. Галимҗаннан бертөрле дә җавап алмагач, дәвам итте:

— Яшьлек дигән нәрсә уйламыйча, кызулык белән күп ялгышлар эшләтә ул! Соңыннан үкенәсең дә, ләкин эшләгән эшне кире кайтарып булмый. Менә шундый ялгышлар аркасында кайбер яшьләр гомерләрен төрмәләрдә, каторгаларда үткәреп, дөнья рәхәтен күрә алмыйча һәлак булалар!..— Вахнин сүзеннән тукталып, Ибраһимовның күзенә текәлеп карады. Аңа тагын җавап булмады. Ләкин подполковник өметен өзми иде.

— Күрәм, сез бик яшь әле. Төрмәгә беренче тапкыр эләккәнгә охшыйсыз. Шуның өчен сезне чын күңелемнән кызганам, үзегезне тиешсез эшләрдән саклап каласым килә... Әгәр, сез, Ибраһимов әфәнде, сүземне тыңлап, бернәрсә дә яшермичә, барысын да турыдан-туры сөйләп бирсәгез, мин сезгә бу бәладән котылырга ярдәм итәрмен!

Ниһаять, Ибраһимов телгә килде:

— Яшерердәй бернәрсәм юк. Мин бертөрле дә ялгыш, яки ярамаган эш эшләмәдем.

Подполковник Вахнин зур өстәленең читендә өелеп торган китаплар, кәгазьләр арасыннан «Знамя труда», «За народ» исемле газеталарны алып Галимҗанның алдына куйды.

— Менә бу хөкүмәт тарафыннан тыелган, төрле фетнәчеләр тарафыннан яшерен басылган, яшерен таратыла торган газеталар сезнең квартирада табылган. Шул турыда ни әйтерсез?

Мондый сорау булачагын Галимҗан тентү вакытында ук уйлап, җавабын әзерләп куйган иде.

— Мин аларны Романовлар династиясенең өч йөз еллык юбилее көннәрендә урамнан табып алдым.

— Ярар, шулай да булсын, ә менә бу китаплар сезнең кулыгызга каян килеп эләкте? — дип, подполковник «Самозвановлар йорты» һәм Лядовның «Россия эшчеләренең социал-демократлар партиясе тарихы» дигән брошюраларны Галимҗанның алдына куйды.

Җавап шул ук булды:

— Бу китаплар әнә теге газеталар белән бер төргәккә бәйләнгән иделәр. Мин аларны Софийский собор янында бәйрәм көннәрендә урамнан таптым.

— Ә Киевтәге мөселман студентларының хөкүмәткә каршы юнәлтелгән хәрәкәтенә мөнәсәбәтегез турында ни әйтәсез? Сез аларны нинди партиягә җәлеп итәргә тырыштыгыз? Бернәрсә дә яшермәгез. Сезнең һәрбер адымыгыз безгә мәгълүм. Безнең кулга төшкән документлар нигезендә сезне хөкүмәткә каршы корал күтәреп көрәшкә чыгарга әзер торган революционер итеп судка бирергә бик мөмкин! Бер-ике елдан соң кайсы доктор, кайсы юрист, кайсы агроном булып халыкка файдалы хезмәт итәргә тиешле иптәшләрегезне дә уйлагыз! Әгәр акылга утырып, бөтен нәрсәне ачыктан-ачык сөйләп бирсәгез, үзегез дә, иптәшләрегез дә бүген үк котылырсыз, югыйсә төрмә... крепость... сөрген... каторга...

Чиктән тыш гаҗәпләнгән булып Галимҗан Ибраһимов кырт кисте:

— Мине революционерлар партиясендә әгъза дип күрсәткән документлар югын беләсездер. Минем һичбер вакыт революционерлар партиясендә булганым юк һәм хәзерге көндә дә әгъза түгелмен.

Вахнин ачуын яшерә алмыйча:

— Сабый бала кебек гөнаһсыз икәнсез. Ә Киев студентларын сәяси көрәшкә чакыруыгыз турында, аннан соң, үз кулыгыз белән язылган миңа бу хат турында ни әйтерсез? — дип кычкырды.

Декабрь аенда Хәлиулла Еникеевнең Казанга нинди мөнәсәбәт белән барып чыгуы турында Хәнәфи Кайбышевка язган хатының русча тәрҗемәсе Киев жандармериясе кулына килеп төшүе Галимҗанны бик гаҗәпләндерде. Бу хатны һәм жандармерияне кызыксындырган башка материалларны Кайбышев үз кулы белән охранкага тапшыруын Галимҗан, әлбәттә, белми иде. Ләкин ул сәерсенүен сиздермәскә тырышып, тыныч тавыш белән сөйләде:

— Киев студентларының бөтен гөнаһлары, минем белүемчә, үзләренең якташлык оешмаларын легальләштерү, халкыбыз арасында аң-белем тарату теләгеннән гыйбарәт. Студентлар съездын чакыру фикере дә миңа шул теләкләрдән чыгып барлыкка килде... Мин аларның утырышында бары ике тапкыр гына булдым. Съезд чакыру мәсьәләсе кузгалган чакта съездда тик сәяси мәсьәләләр генә тикшерелергә тиеш, дигән тәкъдим керттем. Шуның өчен съездның сәяси программасын язуны минем белән студент Еникеевка тапшырдылар. Хәтеремдә калганынча, сәяси мәсьәләләр дип санап без «руханиларга мөнәсәбәт», «Дәүләт думасындагы мөселман фракциясенә мөнәсәбәт», «Русиядәге башка милләтләргә мөнәсәбәт» дигән кебек бернечә тезис язган идек. Ләкин монда хөкүмәткә каршы әйтелгән бер сүз дә юк. Инде Казандагы иптәшем Кайбышевка язган хатка килсәк, мин аны Казан яшьләре Киев студентларының фикеренә кушылырлармы икән, дип кызыксынудан язган идем. Яшьләрнең рухы, аларның әмәлләре, омтылышлары, иҗтимагый мәсьәләләргә мөнәсәбәтләре белән кызыксыну, үзен әдип дип санаган кеше өчен бик табигый хәл дип уйлыйм.

Вахнин кабара барган ачуын басарга тырышып, Галимҗанны тагын үгетли башлады:

— Яшь чагымда мин үзем дә шулай кызылланып йөргән идем. Шуны аңлагыз, бу фетнәләр барысы да жидлар коткысы! Мәлгунь жидлар үзләре Парижларда, Швейцарияларда кәеф-сафа корып яшиләр, ә сезнең кебек яшьләрне монда ут эченә кертәләр. Безгә сездән күп нәрсә кирәкми, тик шуны гына әйтегез: кемнәр бу хәрәкәтне башлады, акча каян алдыгыз? Кичә тотылган яшьләрдән башка сезнең оешмагызда тагын кемнәр бар? Башыгызны әрәм итмәгез, сөйләгез!

Галимҗан Ибраһимов башын артка ташлап эндәшми утыра биргәч, подполковникның тәмам җене чыкты. Күзләрен кыса төшеп, симез бармагын янады:

— Шулай икән! Сөйләргә теләмибез икән! Алай булса, башыгызга төшәчәк бәлаләрне үзегездән күрерсез! — дип, Галимҗанның алдына допрос протоколының бланкын ташлады.

Протокол язылып беткәч Вахнин аны укып чыкты да Галимҗан Ибраһимовны ашардай булып карап торды:

— Мин сезгә яхшылык теләгән идем, ярдәм итим дигән идем. Изге теләгемнең кадерен белмәдегез, аңламадыгыз. Инде барыгыз, тиешегезне алыгыз! — дип, өстәл өстендәге кечкенә кыңгырауны шалтыратты. Шул ук минутта ишектән сакчы килеп керде.

— Моны башта фотограф бүлмәсенә! Рәсемен алдырганнан соң дежурный офицерга алып барыгыз. Офицер әфәндегә менә шушы кәгазьне дә тапшырыгыз! — дип, подполковник аңа кәгазь тоттырды.

Тоткынның төрмәгә ябырылырга тиешлеге турында допроска хәтле үк әзерләп куелган кәгазь иде ул.

Галимҗан Ибраһимовны икенче бүлмәгә кертеп, туры каратып та, яннан да рәсемен алганнан соң, Киев читендәге Полтавская урамының «Лукьяновка» төрмәсенә китереп, сәяси тоткыннар утыра торган унөченче коридордагы беренче номерлы камерага яптылар.

Галимҗан үзе «чын кешеләр» дип атаган рус революционерлары белән берләшеп, самодержавиегә каршы аяусыз көрәшкә хәзерләнгәне өчен жандармериянең рәхмәт укымаслыгын белә иде. Шуңа күрә, таш капчыкка охшаган бер кешелек тар камерага утыртуларына аптырамады да, курыкмады да. Ана жандармерия кулына эләккән һәм әлегә дөнья күреп өлгермәгән кулъязмаларының, бигрәк тә «Казакъ кызы» кулъязмасының язмышы гына борчый иде. «Казакъ кызы» тагын эләкте бит! Шулай ук бу юлы да, Оренбургтагы нөсхәсе кебек, жандармерия кулында югалып калыр микәнни? Мондый бәхетсез булырга тиеш түгел иде бит бу казах кызы!» — дигән уй аны һаман тынычсызлый иде. Ләкин аның иң газаплаган уй — «төрмәгә эләгүем турында хәбәр дөньяда иң яраткан, күңелемнең түрендә сакланган кешемә — әниемә барып житмәсә икән, аңа кайгы-хәсрәт китермәсә икән» дигән уй иде. Шундый борчылулардан соң ул дусты Шәһит Әхмәдиевкә хат язарга булды. Әгәр аның вакытлыча Казаннан китеп торган чагы булса, хат җавапсыз югалып калмасын дип, аны Заһит Нуркинга да адреслады.

Монда да ул, бүлмәсендәге тентүне тасвирлаганнан соң, бик әрнеп: «...бөтен хатларымны, барысыннан да бигрәк бөтен кулъязмаларымны, иң мөһиме, бөтен кыш буена эшләп чыккан теге бәхетсез «Казакъ кызы»н алдылар. Мин хәзер тик кулъязмаларым турында гына борчылам. Әгәр миңа шуларны кайтарып бирсәләр, башкалары ул кадәрле үк түгел»,— дип язды.

Ләкин бу хат Шәһитнең дә, Заһитнең дә кулына тапшырылмыйча, жандармериянең «әйберләтә дәлилләр» дигән кәгазьләре арасында батып калды.

Кулга алынганнан соң ай буена Галимҗан Ибраһимовка бер кеше белән дә күрешергә рөхсәт бирелмәве, хәтта төрмәнең биек таш койма белән чикләнгән кечкенә мәйданына аның берүзен генә йөрергә чыгарулары эшнең, чыннан да, «уен» түгеллеген күрсәтә торган фактлар иде. Әллә ни хәтле киртәләр аркылы тоткынга килеп житкән хәбәр дә шуны күрсәтте.

Көннәрнең берендә камера ишегенең түгәрәк күзеннән бер кәгазь кисәге идәнгә килеп төште. Башта Галимҗан аптырап катып калды. Соңыннан, исен туплап, тиз генә кәгазьне күтәреп алды һәм ишеккә аркасы белән әйләнеп, андагы язуны укый башлады. Язу кыска иде. «Сөрген яки крепость була калса, этаптан алдарак хәбәр итәргә тырышыгыз. Без юл кирәк яракларын хәзерләрбез»,— диелгән һәм соңында стенага чиртеп сөйләшү өчен төрмә әлифбасы язылган иде.

Әлеге кыска хат Галимҗанны дулкынландырып, күңелен күтәреп җибәрде. «Бу, әлбәттә, иректәге иптәшләрнең Агаш аркылы сузган ярдәм кулы! Бу бит — революцион көрәш брадәрлегенең мөкатдәс үрнәге! Бу брадәрлек — кан кардәшлегеннән дә якын һәм нык булырга тиеш һәм ул шулай да! Агаш, Лиза, Зураб һәм башкалар белән танышканыма берничә ай гына булуга да карамастан, алар миңа шундый авыр

сынау көннәрендә мөмкин кадәр, хәтта мөмкин булганнан артыграк ярдәмләшергә, булышырга тырышалар!»

Галимҗан Ибраһимовның бөтен көне төрмә әлифбасы буенча чиртергә өйрәнү белән үтте. Төрмә хәбәрләрен тизрәк беләсе килә иде аның. Бу әлифбаның ярдәме белән Галимҗан Ибраһимов җыенда кулга алынган студентлар турында да сорашырга, белешергә тели иде.

* * *

Мөселман студентлар жандармерия кулына эләккән беренче көннәрдән үк аларның ата-аналары, абый-апалары төрле яктан Киевкә агыла башладылар. Варшавадан Рустамбековның агасы Аббас хан, Гөлсем туташның апасы Зөһрә ханым белән Дәүләт думасының депутаты булган абыйсы адвокат Ибниәмин әфәнде, Мәскәүдән Гариф Кәримовның абыйсы Камил Кәримов, шулай ук башкаларның да туган-тумачалары Одессадан, Петербургтан һәм башка яклардан килеп җиттеләр. Алар төрле юллар белән губернатор хозурына да, жандармерия башлыгы полковник Шредель янына да кереп, үзләренең балалары, энеләре, сеңелләре белән күрешергә рөхсәт алдылар, аларны ничек булса да төрмәгә утырту «хурлыгыннан» коткарырга тырыштылар, допрос вакытында ничек җавап бирергә кирәклеген өйрәттеләр, бертуктаусыз ашау-эчү әйберләре ташыдылар.

Бу хәл Галимҗан белән Хәлләнең дә төрмәдәге көнкүрешләренә тәэсир итте. Хәлләнең таныш кызы Ольга ара-тирә колбаса, ветчина, ак күмәч кебек әйберләр китерә башлады. Соңыннан аңлашылды: бу ике тоткынга ярдәм итеп тору өчен Агаш яшерен «Кызыл хач» кассасыннан ай саен унбиш сум акча тотарга рөхсәт алган икән.

Режимның йомшара төшүе башка яктан да сизелде: төрмәгә утыртылуына бер айдан артык вакыт үткән иде инде, моңа кадәр һава алырга берүзе чыгарылган Галимҗан көннәрдән бер көнне төрмә ишек алдында кулга алынган иптәшләренең барысын берьюлы күреп, хәйран калды.

Аның үзе белән янәшә камерада студент Шәфиков утырганын Галимҗан белә иде инде. Ләкин ул аны беренче күрүдә танымады. Төрмәгә утыртылганчы яхшылап кырынып, бик пөхтә киенеп йөргән гайрәтле, яшь, чибәр егет, хәзер бөтенләй үзгәргән. Битен кара сакал баскан, чәбәләнгән чәчләре маңгаена төшеп, каш.арын каплаган, эчкә баткан күзләре үлем куркынычы белән карап торалар. Күрәсең, юк-бар уйлар уйлап, тамактан калган, йокысын югалткан булса кирәк.

Киевкә килгән беренче көннәрендә батыр революционер булып күренергә тырышкан Нәҗип Корбангалиевнең кыяфәте дә Шәфиковтан артык түгел. Ул да тышкы чибәрлеген югалткан, тирә-ягына дәһшәт белән карана. Аның белән бер көндә Киевкә килеп төшкән Гариф Кәримов кенә ул хәтле үк куркуга, өметсезлеккә бирешмәгән төсле. Ләкин ул да бераз ябыккан, саргайган, кайгылы кебек. «Бу егет нигәдер бик борчыла, сәбәбе ни икән?» — дип, Галимҗан аның янына барырга, дусларча сөйләшеп, мөмкин кадәр күңелен күтәрергә теләгән иде. Ләкин Хәллә комачаулады, дустын күргә үк янына килде дә, һәрвакыттагы кызулыгы, мавыгучанлыгы белән, башында туган хыялларын сөйли башлады:

— Ольга аркылы миңа хәбәр бирделәр, безне йөз дә икенче статья буенча хөкем итәчәкләр икән. Бу статьяны син беләсеңме?

Галимҗан Ибраһимов, әлбәттә, белми иде.

— Сөрген, крепость, каторга дигән сүз бу! Авызыбызны ачып, каторгага куганнарын көтеп ятарбызмы инде?

— Безне округ судында хөкем итәчәкләр дигән хәбәр миңа да килеп җиткән иде, ләкин минем крепость, каторга кебек сүзләрне ишеткәнем юк әле,— диде Галимҗан.

Хәлләнең башында һәркөн диярлек тузга язмаган яңадан-яңа планнар туа иде. Икенче көнне ул:

— Ольга аркылы ирektәге иптәшләргә хәбәр итәргә кирәк, безгә игәү табып җибәрсеннәр. Камера тәрәзәләрендәге тимер рәшәткәләрне игәүләп качарга кирәк безгә! — дип, бу планны башкару бик җиңел булачагына ышандырырга тырышты.

Инде һавага чыгару вакытын Галимҗан Ибраһимов сабырсызлык белән көтеп ала башлады. Ирektә чакта мөселман студентлары белән һәркөн очрашып, якыннан танышырга вакыт таба алмаган булса, хәзер моңа мөмкинлек бар иде. Ниһаять, беркөн ул Гариф Кәримов янына да бара алды. Сүз башлап җибәрер өчен:

— Бик күңелсез күренәсез, әллә берәр җирегез авыртамы? — дип сорады.

— Хәлемә керергә теләвегез өчен рәхмәт, ләкин минем бер җирем дә авыртмый. Тик шатланырлык нәрсә дә юк ич!

— Зинданга ябылу беркемгә дә шатлык түгел, әлбәттә. Ләкин бу хәл алай ук төшенкелеккә бирелә торган сәбәп тә түгел. Безгә биреләчәк җәза ул хәтле авыр булмастыр дип уйлыйм!

— Әгәр ул җәза нахакка булмаса, бәлки төшенкелеккә бирелмәскә дә мөмкин булыр иде. Ләкин хәзер без ни өчен айдан артык төрмәдә утырабыз соң? Һәм тагын күпме утырырбыз? Халкыбызга берәр файда китереп, шуның җәзасын алган булсак, тагын бер хәл иде. Ләкин бит бернәрсә дә эшләп өлгермәдек! Минә бигрәк тә шуның өчен күңел кырыла, ә алган һәм алачак җәзабыз бөтен киләчәгебезгә тәэсир итәчәк!

Кәримовның соңгы сүзләре бик нык әрнеп әйтелгән кебек тоелды. Егетнең сызлаган ярасына каты кагылмас өчен Галимҗан йомшак кына:

— Бәлки сез иртәрәк күңелсезләнә торгансыздыр. Ихтимал, бу җәзалар киләчәгегезгә сез уйлаган дәрәҗәдә тәэсир итмәсләр? — диде.

Ул Кәримовны юатырлык сүзләрне әйтеп өлгермәде. Алар янына Хәллә белән Насырбәков Абдулфән килеп бастылар. Качу турындагы планын сөйләргә тотынган Хәлләнең сүзен Одессадан килгән аксөяк студент бүлдерде:

— Кичерүегезне үтенәм, Хәлиулла әфәнде, сүзегезне бүләм. Сез Галимҗан әфәнде белән һәркөн сөйләшәсез. Бүген аның белән миңа киңәшергә рөхсәт итегез...

— Рәхим итегез, киңәшегез, минем каршылыгым юк,— диде Хәллә, ләкин үзе Галимҗан яныннан китмәде.

— Мин монда бик газап чигәм. Түзәр хәлем калмады. Камерадагы ятак шундый каты, кабыргаларым суелып, сыдырылып бетте. Уарга биргән керләремне, агарту түгел, соры төскә кертеп катырыгы кәгазь кебек катырып кайтаралар. Күлмәкләрем тәнемне кыра башлады. Ышанмасагыз, минә үз күзегез белән күрегез,— дип, Абдулфән җиңен сызганып, беләген күрсәтте.

Галимҗан Ибраһимов хәйран калды.

— Бу турыда ни өчен безгә сөйлисез? Безнең камераларга да пружинлы караватлар, йомшак диваннар куймаганнар бит. Безнең хәлебез дә сезнекеннән яхшы түгел,— диде ул.

Ватаныннан куылган Иран шаһының шәхси секретаре Насырбәков, Галимҗаннан да артыграк гаҗәпләнде:

— Ничек аңламыйсыз?! Бәлки сез үз өегездә дә шундый каты койкаларда ятарга күнеккәнсездер, ә бит мин мондый шартларда яшәргә өйрәнмәгән! — дип, ике кулын күкрәгенә кысты, ялварып: — Менә шуның өчен дә сездән киңәш сорыйм. Одессага, Мөхәммәт Гали шаһка телеграмма сугып, император Николай Икенче әгъзамнарына мөрәҗәгать итеп, мине коткарыгыз, дип үтенсәм ничек булыр икән?

Галимҗан Ибраһимов, таңга калуыннан сискәнеп киткән кебек, кинәт артка чигенде һәм күзләрен тутырып Насырбәковка текәлеп карап калды. Хәллә түзмәде, ачу белән хахылдап көлде:

— Николай патшага сыенып булгач, аңа каршы көрәшергә әзерләнгән яшерен оешмага кермиләр аны!

Насырбәков моны да аңламады:

— Мин бит, мөселман яшьләре берләшеп, мөселманнарга файда булсын өчен генә сезгә кушылдым.

Галимҗан Ибраһимов, аптыравыннан айнып, кулын гына селекте:

— Бу мәсьәләдә без сезгә бертөрле дә киңәш бирә алмыйбыз. Теләгәнегезне эшләгез!

Икенче көн тагын шундый бер хәл! Тоткыннарны йөрергә алып чыгулары булды, оештыру комиссиясенең рәисе хан Талышинский Ибраһимовның култыгыннан тотып, читкә алып китте. Әллә нинди ялварулы караш, хәерче тавыш белән мөрәҗәгать итте:

— Минем сезгә зур үтенечем бар, зинһар, мине кызганыгыз!

— Ни булды?

— Сезне жандарм подполковнигы яңадан допроска чакырса, мин хан Талышинский белән таныш түгел идем, аның белән эшләмәдем, дип әйтегез, зинһар! Бик ышанычлы кешеләрнең фикере буенча сезне барыбер хөкем итәчәкләр. Ибраһимов белән Еникеевкә бик каты җәза биреләчәк, дип әйтәләр алар!

Күңелендә туган нәфрәт хисен басарга тырышып, Галимҗан Ибраһимов яхшылап аңлатырга теләде:

— Сезнең үзегезгә дә билгеле: хәзерге көндә оешмабызның барлык материаллары, документлары жандармерия кулында. Гөлсем туташ, үзенең тәҗрибәсезлеге аркасында, исем-фамилияләрне атап, кемнең нинди тәкъдим ясавына, кемгә нинди вазифа тапшырылуына чаклы күрсәтеп язган. Шулай булгач, Талышинскийны белмим дип әйтүемнән ни файда булачак?

Ләкин Талышинский аңламады. Ибраһимовның кулын кысып, елар дәрәҗәгә җитеп, калтыранган тавыш белән ялвара бирде:

— Минем нишанлым[1] белән әнием карчык монда килгәннәр. Алар хакына мине үзегез белән эшләмәгән кеше итеп күрсәтегез! Коткарыгыз мине! Бөтен эшне үз өстегезгә алыгыз! Әйттем ич, сезгә барыбер авыр җәза бирәчәкләр! Шулай булгач, мине үзегез белән бергә төрмәгә тартудан сезгә файда булмаячак бит!

Галимҗан Ибраһимовның каны кызып кайнады. Ахмаклыкның, куркаклыкның бу дәрәҗәгә җитүен акылына сыйдыра алмый иде ул. Әгәр бу куян йөрәк ялваруын дәвам итсә, яңагына кундырудан Галимҗан үзен тыя алмаячак иде. Ибраһимов янында йөргән Хәллә, гадәте буенча, тагын кабынып китте:

— Сиңа ни булды? Җыелышларда авызыңнан утлар чәчеп, борыныңны югары күтәреп, синнән дә батыр, синнән дә акыллы егет юк иде төсле булып әтәчләнә идең. Үз файдаңа кирәк чакта кешенең мәете өстеннән атлап узарга да әзер икәнсең син!

— Күрдеңме инде якташларыңның кем икәннәрен?! Менә шундый сынаулы, авыр көннәрдә кемнең кем икәне билгеле була. Куй шул гаҗизне. Барыбер син аңа бернәрсә дә аңлата алмассың! — дип, Галимҗан Ибраһимов кулын селекте дә, төрмәдә дә үзенең шаян холкын ташламаган, зур, таза гәүдәле Гали янына китте...

* * *

Югары даирәләргә мөнәсәбәтләре булган, сүзләре үтә торган аксөяк ханнар, бәкләр губернаторга да, жандармериягә дә бардылар, кирәк кешеләргә кавказлыларча юмартлык белән кыйммәтле бүләкләр бирделәр, тоткыннарны ничек тә коткару юлларын карадылар. Каралтылган көмеш кынлы, асыл ташлар белән бизәлгән саплы, Дәмәшкъ

[1] Нишанлы — ярәшелгән кыз.

булатыннан коелган хәнҗәрләр, алтынга манылган көмеш билбаулар үз эшләрен эшләде.

Дәүләт думасы депутаты Ибниәмин Әхтәмов Киевтә озак тора алмады. Петербургка кайтыр алдыннан ул тагын губернатор янына керергә рөхсәт алды. «Ни дисәң дә Дәүләт думасы депутаты. Дәүләт күләмендә эш алып баручы кешеләрнең берсе. Кем белә, бәлки иң югары даирәләрдә аның таныш-белешләре бардыр»,— дип, губернатор аны ачык йөз белән каршылады. Санкт-Петербург хәбәрләрен сораштырды. Әхтәмов исә, бик соклануын күрсәтеп, Киевнең матурлыгын, чисталыгын, тәртипле булуын мактады.

— Әлбәттә, бу казанышлар, хөрмәтле Александр Феодорович, тик сезнең генә уңышларыгыз! Бу — сезнең зур зирәклек белән җитәкчелек итүегезнең нәтиҗәсе! — дип, салпы якка салам кыстырып куйды.

Губернатор мактауга исе китми торган кешеләрдән түгел иде. Шуның өчен Әхтәмовның сүзләре аның күңеленә хуш килде. Ләкин моны сиздерергә теләмичә:

— Куегыз шуны! Монда мин генә түгел, башкалар да бар! — дип әйтсә дә, чырае, мактауның Ибниәмин әфәнде теләгәнчә тәэсир иткәнен күрсәтә иде.

Ниһаять, әңгәмә Әхтәмовка кирәк юнәлешкә керде. Губернаторның елмаеп:

— Миңа нинди йомышыгыз төште, Әхтәмов әфәнде? — дип соравы, төп мәсьәләгә күчәр өчен Ибниәмингә җай бирде.

— Сез болай да сизгәнсездер, борчуымның сәбәбе, әлбәттә, сеңелем мадемуазель Гөлсем турында. Ул бичара бик гасаби, сәламәтлеге бик зәгыйфь кыз. Төрмәдәге шартлар аның соңгы көчен алып, авыруга сабыштырачак!..

Губернатор теләктәшлек күрсәтеп башын чайкады:

— Шундый шөһрәтле гаиләдә тәрбияләнгән кызның патшага каршы көрәш хәрәкәтенә катнашуы бик кызганыч!

Губернатор тукталып артык бер сүз дә әйтмәгәч, Әхтәмов үзе сөйләргә керешә:

— Башка студентлар, курсисткалар турында бер нәрсә дә әйтә алмыйм, чөнки мин аларның үзләре белән дә, кылган эшләре белән дә таныш түгел. Ләкин шуны гына әйтәсем килә: минем сеңлемне гаепләргә мөмкин булган бердәнбер нәрсә — аның рөхсәт ителмәгән якташлык оешмасына катнашуы. Бу бит кешене зинданга ябарлык зур гаеп түгел, бәлки гафу итәргә мөмкин булган балаларча ваемсызлык, гамьсезлек кенә!

Әхтәмовның сүзләренә каршы губернатор агара башлаган калын кашларын күтәрде:

— Мин ышанам, мадемуазель Әхтәмова турындагы фикерегез дөрес тә булыр, ләкин бит аның тирәсендәге яшьләр, халкыбызга хезмәт итәбез дигән булып, хөкүмәткә каршы революцион көрәш юлына аяк басканнар! Сеңелегез шул кешеләр белән катнашып, аралашып яшәгән.

«Гөлсем аркасында бу ахмак студентларны да коткарырга кирәк булачак икән! Ләкин ничек итеп?» — дигән фикер Әхтәмовны тукталып торырга мәҗбүр итте. Тәҗрибәле адвокат буларак, Ибниәмин монда да җаен тиз тапты:

— Хөрмәтле Александр Феодорович! Бармак белән санарлык бишалты мөхтәрәм татар байларыннан башка Киевтә тагын кемнәр бар? Киев бит ул татарлар, гомумән, мөселманнар күп булган Казан, Оренбург, Астрахань кебек шәһәрләрдән түгел. Мөселман студентлары менә шул шәһәрләрдә котыра башласалар, куркынычрак булыр иде, чөнки алар акылга утырып өлгермәгән мөселман яшьләре арасында үзләренә иярченнәрне күбрәк табар иделәр. Киевтә аларга кем иярсен? Киевтә эсдеклар, эсерлар, бигрәк тә бундчылар, поляклар, малорослар хәрәкәте куркынычрак. Аннары бу студентларның гаепләре дә әллә ни зур түгел. Алар якташлык җәмгыятьләренең уставы расланачак дип ышанганнар,

башка шәһәрләрдәге студентларны үзләренең планнары белән таныштырыр өчен генә җыен ясаганнар, студентлар съездын чакырырга хыялланганнар. Бу ахмак яшьләр һичбер төрле җинаять эшләп өлгермәгәннәр бит. Минем белүемчә, жандармнар килеп кергәндә башка шәһәрләрдән килгән студентларны сәламләп тә өлгермәгәннәр әле алар.

Александр Феодорович елмаюын яшерә алмады. «Адвокат — адвокат шул инде. Күр, уйланып та тормастан, жандармериянең гаепләү актындагы иң зәгыйфь урыныннан тотып алды. Аннары, бу мөселманнардан бигрәк, безгә еврейлардан, поляклардан, үзебезнең рус революционерларыннан сакланырга кирәк, дигән фикере дә дөрес бит моның. Бәлки, әлеге фикердән файдаланырга да туры килер әле. Һәрхәлдә, бу турыда полковник Шредель белән сөйләшеп карау зарар итмәс. Бәлки, чыннан да, бу студентларны төрмәдән чыгарырга кирәктер»,— дигән карарга килгәч, Ибниәмин әфәндегә:

— Үзегез беләсез, бу турыдагы тикшерүләр жандармерия кулында. Шулай да мин сезгә ярдәм итәргә тырышырмын. Якын көннәрдә барысы да хәл кылыныр,— диде, очрашу тәмам икәненә ишарә итеп урыныннан торды.

Ибниәмин Әхтәмов та аякка басып, губернатор белән саубуллашты.

Киевтән кайтуына айга якын вакыт үтсә дә, сеңлесе Гөлсем туташтан: «Ниһаять, мине ireккә чыгардылар».— дигән хәбәр килмәгәч, Ибниәмин әфәнде Тавр сараеның бланкасында язып, июнь башларында губернатор исеменә хат җибәрде. Бу юлы депутат Әхтәмовның тоны җитәрлек дәрәҗәдә катгый иде, хәтта ул: «Әгәр сеңлемне якын көннәрдә төрмәдән чыгармасагыз, эчке эшләр министрына да, полиция департаментына да шикаять итәчәкмен»,— дигән мәгънәдә янап та алган иде.

Бу хат килгәнче Александр Феодорович мөселман студентлары турында нинди карар чыгарырга һәм бу карарны ничек тормышка ашырырга кирәклеге турында полковник Шредель белән сөйләшкән иде инде. Тиешле кәгазьләрне рәсмиләштергәннән соң студентларны чыгара башлаячаклар иде. «Дәүләт думасында депутат булгач, полиция департаментындагы югары дәрәҗәле кешеләр, министрлар арасында сүзе үтәдер. Алардан юкка шелтә алып утырганчы, шушы акылсыз кызны төрмәдән чыгарырга кирәк»,— дип уйлап, губернатор шунда ук әмер бирде. Гөлсем туташ артыннан башкаларны да чыгара башладылар. Ниһаять, соңгы чиратка калдырылган өч-дүрт студент белән бергә, Галимҗан да төрмә капкасыннан чыгып, урамга аяк басты һәм:

— Бу нинди тантана икән? — дип аптырап калды.

Кавказлы тоткыннарны Европача купшы киенгән ата-аналары, нишанлылары, абый-апалары, зиндан капка төбендә шатланып, кычкырышып, бүрекләрен югары чөеп, тәбрикләп, үбеп, кочаклап каршы алалар. Читтән караганда монда туймы, яки нинди дә булса бәрәр бәйрәмме, дип уйларга мөмкин иде.

— Мондый тантана ясарлык, туй итәрлек нинди кирәкле, зур эш эшләдек соң без? Нәтиҗәдә бөтен омтылышыбыз төтен булып һавага очты. Мактанырлык, шатланырлык бер нәрсә дә юк бит! Киресенчә, көенергә, үкенергә кирәк! — дип, Галимҗан Ибраһимов гарьләнүеннән, фуражкасын баса төшеп, болар яныннан китәргә ашыкты һәм тизрәк трамвайга барып утырды.

Тентү вакытында охранка кулына төшкән документларын һәм башка кайбер нәрсәләрен кайтарып алыр өчен Галимҗанга да, Хәлләгә дә җиде көннән соң килергә куштылар. Менә шул бер атна буш вакыттан файдаланып, төрмәдән элегрәк чыгарылган студентлар белән яңадан элемтәгә керергә, кетмәгәндә туктап калган студентлар хәрәкәтен дәвам иттерү турында яшьләрнең фикерләрен белергә уйладылар. Төрмәдә чагында һавада йөрергә чыгарылган вакытларда очрашып сөйләшүләр нәтиҗәсендә оештыру комиссиясенең әгъзаларыннан да, җыенга килгән вәкилләрдән дә Галимҗан Ибраһимовның күңеле кайткан, ләкин башланган хәрәкәттән өметен бөтенләй өзмәгән иде ул...

* * *

Азат ителүенә бер атна үтү белән, Галимҗан Ибраһимов тентү вакытында охранка кулына төшкән әйберләрен кайтарып алырга дип килде. Зур-зур алты кисәк итеп бәйләнгән төеннән аңарга нибары кечкенә бер төргәк тоттырдылар. Галимҗан:

— Бу документлардан, альбомнардан тыш тентү вакытында бөтен кулъязмаларымны, бик күп китапларымны алган иделәр. Миңа бигрәк тә кулъязмаларым кадерле, шуларны кайтарып бирсәгез иде,— дип әйтеп карады.

— Ул нәрсәләрегезне соңыннан алырсыз,— дип җавап бирделәр аңарга, ләкин үзләре кайчан, ничек кайтарачакларын ачыкламадылар. Татар телен белгән тәрҗемәчедән тикшертер өчен кулъязмаларны Казан жандармериясенә җибәртелүен әйтеп тормадылар. Аның каравы, бүгенге көннән исәпләп, өч тәүлек эчендә Киевтән чыгып китәргә тиешлеге турында бик ачык итеп төшендерделәр һәм, кая китәчәген җентекләп сорашканнан соң, Галимҗан күрсәткән адресларны язып алдылар.

Юкка түгел иде бу. Икенче көнне үк Казан һәм Уфа губерниясе жандармерияләренә, Киев мөселман студентларының хәрәкәтендә үзәк роль уйнаган һәм шул вакыйга буенча «интеллигентный» кушаматы белән ачык һәм яшерен күзәтүгә алынган Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов якын арада Киевтән Казанга китәчәк, ә соңрак Уфа аркылы Солтанморат авылына барачак, дигән хәбәр җибәрелде.

Галимҗан Ибраһимовның мөселман студентлары белән төрмәгә эләгүе турындагы хәбәрне ишетүгә Каюм Мостакаев үзе яши торган Казатин белән Киев арасын бертуктаусыз таптый башлаган иде. Галимҗан төрмәдән чыккач та ул укыткан шәкертләрнең ата-аналары белән исәп-хисапны өзәргә ярдәмләште. Ниһаять, охранка биргән вакытның соңгы өченче көнендә дустын поездга озата төште.

Вокзалда Хәлиулла Еникеев күренмәде. Укуын дәвам итү өмете белән ул, контрабандистлар ярдәмендә Төркиягә качарга уйлап, берике көн элек Киевтән чыгып киткән иде.

## Яңадан Казанда

Казан Галимҗан Ибраһимовны ачык йөз белән каршы алды. Күптән түгел яңгыр явып узган булса кирәк, һава күңелне күтәрерлек саф, рәхәт. Урам буендагы агачларның яңгыр юган яфраклары үтә яшел булып ялтырап тора. Уйсурак җирләрдә әле кибеп өлгермәгән яңгыр сулары кояш нурлары астында күзгә кисәкләре кебек җемелдәп ята. Ә югарыда, зәңгәр күктә, аккошларга охшаган үтә күренмәле җиңел ак болытлар анда-санда йөзеп йөриләр.

Дустын каршы алырга дип вокзалга төшкән Шәһитнең дә йөзе ачык, шат иде. Кочаклашып күрешкәннән соң, Шәһит ике кулын иптәшенең җилкәсенә салып, аны җиңелчә артка этәрде, үзе дә бераз каерылып дустын баштан-аяк күздән кичерде. Шуннан соң көлеп җибәрде дә, иптәшенең аркасыннан какты:

— Саф һава суламыйча, арыш ипиеннән һәм боламыктан башка аш күрмичә ике ай буена төрмәдә утырып чыккач, син бөтенләй ябыгып, бичараланып калгансың дип уйлаган идем. Шундый кичерешләрдән соң үзеңне адәм рәтенә китерер өчен аена биш тәңкә түләп, Кабан күле буеннан дача алдым, ашау-эчү якларын хәстәрләдем, ә син төрмәдән тазарып, симереп чыккансың!

Галимҗан Ибраһимов та мыек астыннан елмайды:

— Мине анда, дускай, өч яктан ашаттылар. Бер яктан, патша хәзрәтләре кара ипи белән боламыгыннан коры калдырмады. Икенче яктан, Каюм дус базарда, ресторанда нинди тәмле нәрсә күрсә, шуны ташып торды, ә өченчедән, Агаш исемле бер иптәш, революционер студент-

ларның «Кызыл хач» кассасыннан акча алып, ветчина, колбаса кебек нәрсәләр дә китерә иде. Шулай булгач, ничек симермәскә? Тагын берике ай төрмәдә бот күтәреп ятарга туры килсә, чүмәләгә охшаш корсак үстереп чыккан булыр идем!

Бу сүзләрне ишеткәч, Шәһит рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Галимҗан исә, елмая биреп, аның көләч йөзенә яратып карады. Ниһаять, күрешкән арада тротуарга куеп торган әйберләрен күтәреп, дустын ашыктырды ул:

— Дачага чыгарлык баегансың икән, әйдә, киттек. Күрсәт, байлыгыңны! Дачаң Кабан күле буенда дидең шикелле.

— Әйе, Суконный бистәсендә. Трамвай белән хәерчеләр биржасы янына чаклы барырбыз да, шунда пароходка утырып, Кабан күленең аргы башына китәрбез.

Тукталышта трамвай әле юк иде. Галимҗанның көтеп торасы килмәде.

— Хәерчеләр биржасы моннан ерак түгел. Балык базары белән Печән базары арасында гына бит! Трамвайларга менеп-төшеп йөргәнче, шушы саф һавада җәяүләп китсәк булмасмы? — диде ул.

Ике ягына теләнчеләр тезелеп утырган һәм шул сәбәптән «теләнчеләр биржасы» дип йөргән тар, иске агач күпергә җиткәндә, Кабан күле аша йөри торган кечкенә пароход пристаньга килеп туктаган иде инде. Егетләр җәһәтрәк атладылар. Менеп утырулары белән, аларны гына көткән кебек, гудогын кычкыртып, пароход кузгалып та китте.

Күл өстендәге һава тагын да җиләсрәк, тагын да сафрак иде. Галимҗанга бу һава ширбәт кебек ләззәтле булып тоелды. Ул күкрәген киереп, сулышын тирәнрәк алырга тырыша иде. Пароход тәгәрмәчендәге калакларның су тамчыларын чәчрәтеп шапылдаган тавышлары да аның колагына ягымлы ишетелә. Ә инде мандолина, гитара чиртеп, гармун уйнап, җырлашып, көлешеп, кечкенә көймәләргә утырып күңел ачарга чыккан яшьләр бу җәйге ял көненең ямен тагын да арттырып җибәрәләр, җанландыралар кебек.

Күл уртасынарак җиткәндә алар каршына шундый ук кечкенә икенче бер пароход очрады. Аралары якынлашу белән бер-берсен сәламләп кычкырган гудок тавышларының күл өстен яңгыратуы Галимҗанның күңелен җилкендереп куйды.

— Кара син боларны! Идел суларында йөргән «Кавказ и Меркурий» пароходлары кебек бер-берсе белән сәламләшәләр! — дип елмайды. Бу кечкенә сәяхәт дустының күңеленә охшаганлыгына шатланып, Шәһит тә көлеп җибәрде.

Күл өстеннән пароход белән бару дуслар өчен күңелле булгандыр. Суконный бистәсенең «дачалары» янындагы пристаньга килеп житүләрен сизми дә калдылар.

Пароход пристаньга якынлашканчы ук Галимҗан каршы алучылар арасында берничә танышын күреп өлгергән иде. Әнә, иң алда, барысыннан озын булып, Гыйбад Алпаров басып тора. Урта буйлы Заһит аның янында кечкенә булып калган.

— Гыйбад белән Заһит кемне каршылыйлар икән? Әллә син аларга минем бүген монда киләчәгемне әйттеңме? — дип сорады Галимҗан.

Шәһит кыска киселгән кара мыеклары астыннан вак кына ак тешләрен күрсәтеп елмайды:

— Кемне каршыласыннар, сине каршылыйлар, әлбәттә! Алар гына түгел әле, яннарында басып торган бер төркем дачниклар да сине сәламләргә чыкканнар!

— Танымаган-белмәгән кешеләр сәламләргә мин я министр, я губернатор түгел ич! — дип, Галимҗан кашларын җыерды.

Каршылаучылар пароходтан төшүләре белән дусларын урап алдылар. Иң беренче булып Галимҗанны Гыйбад Алпаров кочаклады.

— Житәр, башкаларга да күрешергә бир! — дип, Заһит Нуркин

Галимҗанны аның кочагыннан тартып алды.

Таныш түгел кешеләрнең дә каршыларга чыгулары дөрес булды. Берәүләр килеп аның кулын кысалар, кайберәүләре җылы сүзләр әйтәләр, олылыйлар, ә кайберәүләре якын килергә тартынып, читтән генә кызыксынып карап торалар. Бу дәрәҗә хөрмәт күрсәтү Галимҗан Ибраһимовны уңайсызландырды да, гаҗәпләндерде дә.

Шул ыгы-зыгы арасында кешеләрне аралап, Галимҗан янына бай малае Салих кереп килде. Һәрвакыт әдипләр, шагыйрьләр арасында, газета-журнал идарәләрендә чуалып йөри торган бу егет, гадәтенчә, үзе әйтмешли, «английский дэнди» булып киенмәгән, шулай да, өс-башлары бик садә булган биредәге кешеләр арасында ала карга кебек аерылып тора. Дачаларда шулайрак киенергә кирәк дип уйлаганмы, русларның — «рубаха-парень» дип йөртелә торган кыяфәтен алырга тырышкан, якасы, җиң очлары, итәге чигүле ак күлмәген зур чуклы билбау белән буган, кара чалбарының балакларын гармун kунычлы итегенә тыккан, хәтта башына картуз да кигән иде.

Галимҗан Ибраһимов янына килеп җитүе белән Салих аның ике кулына ябышты һәм һәрвакыттагы тотнаксызлыгы белән такылдый башлады:

— Ниһаять, герой-революционерыбызны күрергә дә мөяссәр булдык! Беләсезме, Галимҗан әфәнде, мәдәниятkә аз гына мөнәсәбәте булган татар, кулына газета эләксә, Киевтән нинди хәбәрләр бар икән, коллык тормышына дошманлык белән янган заманыбызның революционеры Галимҗан әфәнде Ибраһимовка ни булды икән, каһарманыбызны бик җәберләмиләрме икән, дип эзләнә башлый иде!

Шундый сәер киемле Салихны Галимҗан башта танымады, төбәлеп караганнан соң кем икәнен абайлап алды.

Матбугат кешеләре арасында чуалырга яраткан бу бай малаеның башыннан бигрәк теле житез икәнен ул белә иде. Киевка киткәнче, театр, «Шәрык» клубы, газета редакциясе кебек урыннарда еш кына очраткалый иде ул аны. Шуның өчен сүзләренә артык исе дә китмәгән булыр иде, бәлки, ләкин ирексездән күзе Төхфәтулла Мамлеевка төште. Галимҗанның карашын очраткан Мамлеев ялагайланып елмайды һәм аңа таба якынрак елышты. Бу кеше белән Галимҗан турыдан-туры таныш булмаса да, аның укучы яшьләр, студентлар, җәмагать хадимнәре, шагыйрьләр, әдипләр арасында буталып йөргәнен еш күрә иде. «Бу да монда икән. Биш-алты кеше җыелып торган җирдә ул булыр», — дип уйлады.

— Сезнең белән таныш булмасам да, татар галәмендә күренекле әдип икәнегезне беләм, — дип, Төхфәтулла Мамлеев Галимҗанның каршына ук килеп басты. — Мин үзем сезне чын күңелдән хөрмәт итүче учитель Төхфәтулла Мамлеев булам. Патша козгыннарының тырнагыннан котылып, ватаныбызга сау-сәламәт кайтып килүегезгә чиктән тыш шатбыз! Салих әфәнде бик дөрес әйтте, сез Киевтә яшьләр арасында кузгаткан сәяси хәрәкәтегез белән чын-чыннан батыр йөрәкле, халкыбызның бәхет-сәгадәте юлында җаныгызны фида итәргә хәзер торган каһарман икәнегезне ачык күрсәттегез!..

Ул тагын да сөйләгән булыр иде әле, Галимҗан кулын селтәп туктатты:

— Куегыз, Төхфәтулла әфәнде, Киев хәрәкәтен шулкадәр күтәрерлек бернәрсә дә юк. Нәтиҗәсез эш булды ул, төтен булып һавага очты!

Киев мөселман студентларының шулай әзерлексез башланган хәрәкәтләренә кушылуы сәбәпле, Зураб, Агаш, Лиза, Петя, Коля кебек иптәшләреннән ераклашканы өчен ул бик үкенә иде. Шуның өчен Салихның да, Мамлеевнең дә мактау сүзләре аңа мыскыллау булып ишетелде.

Галимҗанның кәефе бозылганын сизеп, Гыйбад Алпаров ярдәмгә ашыкты:

— Галимҗан Ибраһимов — ерак юлдан килгән кеше. Арыгандыр,

ял итәсе килә торгандыр. Әгәр аңа дачага кайтырга рөхсәт итсәгез, бик яхшы булыр иде, әфәнделәрем!

Каршылаучылар, читкәрәк чигенеп, Галимҗан Ибраһимовка һәм аның дусларына юл бирделәр.

* * *

Шәһитнең дачасы ерак түгел, шунда ук — күл буендагы өянке агачларына барып теләлә икән. Дача өе күл читеннән эчкәрәк салынган, ә ишек алдындагы мәйданчыкта юкә агачы күләгәсендәге җиргә кагылган дүрт казык өстенә, такталар тезеп, өстәл ясалган. Өстәл тирәсендә эскәмияләр тора. Читтәрәк, уты сүнгән учак өстенә, суынмасын өчен, газеталарга уралган казан утыртылган.

Галимҗан тирә-ягына күз ташлады да:

— Әйбәт! Саф һава, тирә-як яшеллек, шәһәрдәге кебек ыгы-зыгы юк, авылчарак...— дип, канәгатьлек белдерде.

Заһит Нуркин, төгәллек яратканга күрә, һәр нәрсәнең үз вакытында эшләнүен куәтләп:

— Я, дуслар, әйберләрегезне өйгә кертеп куегыз да, юынып, өстәл янына утырыгыз, балык шулпасын суытасыз! — дип, сүз белән мавыга башлаган иптәшләрен ашыктырырга кереште.

Егетләр балык шулпасын бик тәмләп ашадылар. Шәһит шәрабны стаканнарга бүлгәләде дә:

— Я, дуслар, аз булса да, күп күреп, исәнлеккә-саулыкка күтәрик,— дип, иптәшләренә мәгънәле ым какты. Башкалар да аңа кушылдылар. Шуны гына көткән төсле Галимҗан Гыйбадка карап:

— Синең тавышың, дустым, Хөснинеке кебек үк булмаса да, моңлы. «Ашказар»ымы, «Кара урман»ымы сыздырып җибәрмәссеңме икән? — диде.

Егетләр Хөснинең татар-башкорт көйләрен бик матур, моңлы тавыш белән, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп җырлаганын беләләр иде. Ләкин хәзер ул иптәшләре арасында юк. Әгәр ул үзе шушында булып җырлап җибәрсә, рәхәтләнеп тыңлаган булырлар иде. Шулай да, Галимҗанның үкенечечә каршы, бер сүз дә әйтмәделәр. Киресенчә, Гыйбадка кушылып, үзләре дә җырладылар.

Җыр туктагач, иптәшләр бераз вакыт тынып калдылар. Ниһаять, Галимҗан, иелгән башын күтәреп, уйчан тавыш белән:

— Бу җырның моңында гына түгел, сүзләрендә дә никадәр тирән мәгънә бар! Уйлап карагыз әле, ничек әйтә бит:

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Бу сүзләр халыкның үз караңгы хәятен тасвир итмиме, бу караңгылыктан котылыр өчен яхшы атлар, сабит дус-ишләр кирәклеген әйтмиме?! Халык иҗаты ни дәрәҗәдә көчле, тирән мәгънәле күренешләр аркылы күңел төбендәге яшерен уйларны, тойгыларны ачып бирә ала!

Галимҗанның бу сүзләре иптәшләренең күңелләрен күптән кытыклаган мәсьәләгә күчәргә мөмкинлек бирде. Сүзне Алпар башлады:

— Безнең татар газеталары Киевтәге мөселман студентларының хәрәкәте турында язып тордылар. Ләкин цензура киртәләре сәбәпле, мәсьәләне бик ачыклый алмадылар. Шулай да бу хәрәкәттә синең күренекле роль уйнаганыңны читләтеп булса да аңлаттылар. Хәзер безгә бу хәрәкәтнең ничек башланганын, алдына нинди максатлар куйганын, охранка кулына эләккәнгә кадәр ниләр эшләп өлгергәнен сөйләсәң яхшы булыр иде. Безнең яшьләр арасында менә шундый җанлы сәяси хәрәкәт башлануы үзе үк өмет уята торган зур уңыш бит. Шуның өчен Киевтә булып узган вакыйгаларның безне кызыксындыруы бик табигый.

Галимҗан Ибраһимовның чырае кинәт караңгыланып китте. Алпар

туктагач та ул бераз вакыт түбән карап, эндәшми утырды, ниһаять, башын күтәреп, тирә-яктагы өянке, юкә, миләш агачларын, зелпе куакларын күздән кичерде. Тирән сулап куйды. Тик шуннан соң гына сүзен башлады:

— Мин бит пароходтан төшкәч үк, Салих белән Мамлеевнең мактауларына каршы бу турыда үз фикеремне әйткән идем. Анда әйткәнnәремә тагын шуны кушарга мөмкин: бер яктан, бу хәрәкәт әзерлексез башланды, икенчедән, бары тик ханзадәләр, бәкләр, бәйләрдән гыйбарәт булды. Тап соңында табигый рәвештә нәтиҗәсез булды, беренче сынауда ук таралды, юкка чыкты...

Заһит Нуркин Галимҗанның туктап торуыннан файдаланып:

— Әллә алар студентлар түгел идеме? — дип сорады.

— Студентлар!.. Бу яктан барысы да бертигез. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар бит, берсе — полиция башлыгының улы, икенчесе хан баласы, өченчесе — үзе хан, дүртенчесе — алпавыт улы, бишенчесе — ничә йөз дисәтинә җир хуҗасы! Кыскасы, эксплуататорларның төрле-төрле тармаклары. Бу яшьләрнең сәяси идеал, революцион көрәш төшенчәләре бик томанлы булганлыктан, алар сәяси түгәрәк төзүгә дә кызыклы мажарага катнашу кебек итеп караганнар икән. Сүздә алар бер-береннән үтә кызыл, бер-береннән җәсүр булып күренергә тырышсалар да, охранка кулына эләгүләре белән җебегән тавыкка әверелделәр. Мондый идеясез куркак куяннарга ышанып вакыт әрәм итү белән мактанудан бигрәк, оялырга, үкенергә кирәк, һәм мин оялам да, үкенәм дә!

Иптәшләр Галимҗанның соңгы сүзләрен кабул итәргә теләмәделәр. Аларның ризасызлыгын Заһит аңлатты:

— Ничек алай булсын?! Киев студентлары гамәлдә, син әйткәнчә, җебегән тавык, куркак куян булып чыкканнар икән, син түгел, алар үзләре оялырга тиешләр!

Башкалар да:

— Әлбәттә, шулай!

— Синең монда ни гаебең бар?

— Син бит кулыңнан килгәнчә аларны оештырырга, сәяси көрәшкә чакырырга, иҗтимагый-сәяси аңнарын арттырырга тырышкансың! — дигән сүзләр белән Заһитның фикерен куәтләделәр.

Ләкин Галимҗан Ибраһимов сабыр гына башын чайкады:

— Ятып калганчы атып кал, тисә — тиенгә, тимәсә — тирәккә дип, мондый мәсьүлиятле эштә балаларча ашыгучанлык күрсәтеп хәрәкәт кылмаска кирәк иде. Менә бу үзе гафу ителмәслек җавапсызлык түгелме? Аннары ул ханзадәләргә нигезсез өмет баглап, үземә юл күрсәтерлек, чын мәгънәсендә революцион идеяле танышларымнан ераклаштым. Дөресрәге, алар үзләре миннән ераклаштылар, чөнки мондый ышанычсыз, сыналмаган кешеләр белән сәяси эшләрен тәвәккәллек астына куярга теләмәделәр. Менә шул дуслардан аерылышуыма бик үкенәм!

— Син бигрәк таләпчән инде, Галимҗан! Хәрәкәт син теләгәнчә барып чыкмаса да, сәяси көрәш идеясен яшьләр баштан ук теләп кабул иткәннәр бит. Иҗтимагый, сәяси мәсьәләләрдә белемнәре, ачык фикерләре булмавы да табигый. Бик аз эшләп кала бит түгәрәк. Тәҗрибәсезлектәнме яки башка нинди дә булса сәбәптәнме, охранка кулына тиз эләгә. Бәлки, ул түгәрәк озаграк яшәгән булса, яшьләрнең иҗтимагый-сәяси аңнары арткан булыр иде. Монда сиңа оялырлык та, үкенерлек тә һичбер нәрсә юк. Киресенчә...

Галимҗан Ибраһимов, Алпаровка фикерен йомгакларга бирмичә, кулын селтәде:

— Халыкта, буласы баштан ук билгеле, дигән сүз бар. Болар баштан ук билгеле булдылар. Мондыйларны күпме өйрәтмә, күпме димләмә, барыбер файдасыз булачак, чөнки ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми икән!

Шәһит кинәт кызып:

— Яшьләрне сәяси көрәшкә димләү файдасыз димәкче буласыңмы

әллә? Яхут сәяси көрәшче булыр өчен анадан көрәшче булып туарга кирәк дип әйтмәкче буласыңмы?! — дип кычкырды.

— Мин бит тормышыбыздагы тигезсезлекләрнең, җәберләүләрнең төп сәбәпләрен дөньядагы барча яшьләргә аңлату файдасыз дип әйтмәдем. Киресенчә, бик кирәк, хәтта зарур! Сүз фәкать ханзадәләр турында иде. Мәсьәлә шунда: нинди яшьләргә ничек, нинди юл белән аңлатырга?..

Галимҗан соңгы фикерен киңрәк, тулырак итеп аңлатырга теләгән иде, Шәһит дусты аның сүзен тагын бүлде:

— Аны күп уйланып торасы юк! Үзебезгә журнал яки газета чыгарырга кирәк! Менә шунда үзеңнең ноктаи назарыңны теләгәнеңчә иркенләп аңлатырга мөмкин!

— Журнал яки газета чыгару фикеренә кушылам. Мин үзем дә бу турыда бик уйланам. Ләкин монда үзеңнең ноктаи назарыңны иркенләп язу мөмкинлегенә шикләнәм,— диде Галимҗан.

Заһит кинәт гаҗәпсенеп:

— Газета үз кулыңда булгач, нигә шикләнергә? — дип сорады.

— Безнең татар матбугатында мәсләгендә нык торган, үзенең максатларын, омтылышларын халык арасында мөмкин кадәр киң таратырга тырышкан, үзенә ят булган фикерләргә урын бирмәгән бердәнбер «Урал» исемле газета бар иде. Ләкин, үзең дә беләсең, патша хөкүмәте аңа күп яшәргә ирек бирмәде, тиз генә туктатты... Хәзерге шараиттә тормышыбыздагы безне изгән, җәберләгән фактларның сәбәпләрен вакытлы матбугат аркылы фәкать оста киная белән генә аңлата алачакбыз. Әгәр менә шундый осталыкка ирешә алсак, халык күңелендә патша хөкүмәтенең золымнарына каршы көрәш теләге уята алачакбыз!

Дусларны газета чыгару хыялы шулкадәр мавыктырган иде ки, алар әңгәмәнең яшьләр хәрәкәте турындагы мәсьәләләрдән читләшә төшкәнен дә сизмәделәр.

Заһит, гадәтенчә, тагын җентекли башлады:

— Газетаны да, журналны да болай гына чыгарып булмый, аңа дөнья кадәр акча кирәк. Басмаханәгә түлә, кәгазь сатып ал, язышучыларга гонорар бир, клишелар ясат, почтага харәҗәтлән... Бу кадәр акчаны каян алмакчы буласыз? Әллә хәзинә таптыгызмы?!

— Син, Заһит, бигрәк төпченергә яратасың,— диде Шәһит ачуланып.— Газета чыгара башлар өчен әллә ни хәзинә кирәк түгел. Башта, үзара акча җыярга да, бер я ике санын чыгарырга һәм матбугатта күтәрелгән берәр мәсьәлә буенча укучыларны кызыктырырлык дискуссия башлап җибәрергә кирәк, шуннан инде язышучылар да, укучылар да җитәрлек табылыр!

— Анысы шулай... Ләкин, дөрес булса, газета-журнал чыгаруны байлыгы булган, могтәбәр дип танылган кешеләргә генә рөхсәт итәләр икән, дип ишеткәнем бар.

Гыйбад Алпаровның бу сүзләрендә хакыйкать бар иде, шуның өчен уйланып калдылар. Алпаров, иңбашларын җыерып, аптыравын белдерде:

— Столыпин үтерелгәннән соң бәлки ул кадәр катылык күрсәтми торганнардыр инде.

Шәһиткә шул җитте, караңгылана төшкән чырае ачылды.

— Чыннан да, шулай булуы бик ихтимал. Губернатор исеменә гариза язып, журнал чыгарырга рөхсәт сорап карарга кирәк. Моңа ни дип әйтәсез? — дип, иптәшләренә карады. Каршы килүче булмады. Тик Галимҗан, озын керфекләре арасыннан еракка карап, уйчан тавыш белән:

— Газета, әлбәттә, кирәк. Тик шунысы бар — бүгенге көндә безнең үзебезнең сәяси программабыз томан эчендә, бик ачык түгел. Гомуми төшенчәләр турында сафсата сатудан конкрет мәсьәләләргә күчү кирәк. Хәзерге көндә халкыбызны изгән, кол иткән, Сәгыйть Рәмиевнең сүзләре белән әйткәндә, халкыбызның бәхетен тартып алган

аллаларны ватарбыз, көл итәрбез! Ә соңыннан, ул аллаларны җиңеп таптагач, нишләрбез? Халыкка нинди бәхетләр, нинди шатлыклар бирү кулыбыздан килер?

— Чыннан да, бу турыда һичбер төрле конкрет фикеребез юк бит! — дип, Алпаров башын чайкады.

— Халыкка бәхет-сәгадәт вәгъдә иткән дөрес фикерне каян табарга, каян алырга?!

Заһитның бу соравына Галимҗан җавап бирде:

— Минемчә, башкалар тарафыннан күптән кәшеф ителгән нәрсәләрне безгә яңабаштан кәшеф итеп утырырга кирәкмәстер. Русиядә сәяси партияләр күп, һәркайсының үз программасы, үз юлы, үз кагъбәсе бар. Безгә бигрәк тә социал-революционерлар һәм социал-демократлар партияләренең программалары белән бик җитди рәвештә танышырга кирәк. Үз юлыбызны шулай билгеләгәч кенә яшьләр арасында сәяси эш алып барырга, сәяси белем таратырга хаклы булачакбыз.

Сәяси партияләрнең программалары белән танышу юллары, яшьләр арасында иҗтимагый, сәяси белем тарату формалары турында иптәшләр бик озак сөйләштеләр, хыялландылар. Бу әңгәмә нәтиҗәсендә журнал яки газета чыгару фикере дә ныгыды, хәтта буласы журналга «Аваз» дип исем дә куйдылар. Беренче санны чыгару өчен танышлары арасында акча җыюны үз өсләренә алып, журнал чыгаруга губернатордан рөхсәт сорауны Шәһиткә тапшырдылар.

* * *

Галимҗан Ибраһимов «Татар сарыфы» исемле китабы турында Шәһиттән сорашырга икенче көнне генә мөмкинлек тапты.

Кичтән газета чыгару хыялы белән бик соң ятканлыктан, көндезгә унга чаклы йоклаганнар. Галимҗан уянганда, кояш байтак күтәрелгән, яхшы ук кыздыра башлаган иде инде. Уянгач ук ул, һәрвакыттагы кебек, узасы көннең планын төзи башлады. «Иң беренче нәүбәттә «Татар сарыфы»ның басылуы ни хәлдә икәнен белешергә, мөмкин булса, гонорарын алырга. Аннары «Йолдыз» редакциясенә кереп, Казан, Оренбург газета-журналларының соңгы саннарын карап чыгарга. Шул ук урамдагы «Аң» журналының идарәханәсенә барып, андагы яңалыкларны белергә. Балалар өчен «Ак юл» исемле журнал чыга башлаган икән. Журналның үзе белән дә, редакторы белән танышырга. Авылга кайту якларын да караштырырга кирәк булачак»,— дип уйлады ул. Бүгенгә эш бик күп булачак, вакытны әрәм итмим дип, урыныннан сикереп торган чакта, ялгыш, тәмләп йоклап яткан Шәһитне дә уятты. Аңысы яткан урынында киерелеп алды:

— Син тордыңмы инде? Кая ашыгасың, йокла тагын әзрәк.

— Эшлисе эшләр, күрәсе кешеләр күп. «Татар сарыфын» баса башладылармы икән? Шуны да белешергә кирәк. Ике көннән бирле синнән шуны сорамакчы булам: һаман туры килми. Әхмәтгәрәй белән гонорар турында ничек килештегез? Бик алданмадыгызмы икән?

Шәһитнең күзләре шар кебек булып түгәрәкләнеп ачылды:

— Нинди гонорар? Хәсәни әфәнде белән нәрсә турында килешергә кирәк иде? — дип гаҗәпләнде.

Инде Галимҗан аптырашка калды.

— Әллә сез минем зинданнан язган хатымны алмадыгызмы? Төрмәдән, Нуркин белән икегезгә атап, русча бер хат язган идем. «Татар сарыфы»ның гонорары турында Хәсәни белән килешегез дә, баса башласыннар дип үтенгән идем...

— Без синнән һичбер төрле хат алганыбыз юк,— дип, Шәһит җилкәләрен җыерды.

Кинәт, шикле бер нәрсә исенә төшкән төсле, озак итеп иптәшенә төбәлеп карады. Сорарга да, сорамаска да белми икеләнеп тора иде, күрәсең.

— Ә син минем төрмәгә адреслап язган хатымны алдыңмы?
— Юк, алмадым... Хатны татарча язган идеңме?
— Әлбәттә, татарча!
— Алай булса, аңлашылды. Киевтәге охранкада татарча белгән кеше булмаска тиеш. Сезнең хатны кемгә булса да тәрҗемә итәргә биргәннәрдер дә соңыннан миңа тапшырырга онытканнардыр. Син анда ни турында язган идең?
Шәһит элеккедән дә ныграк гаҗәпләнде, чырае бөтенләй үзгәрде, агарынды. Дустына туры карый алмыйча, башын иеп, читкә борылды.
— Әллә син бирәр ярамаган фикер язган идеңме? Ни өчен шулай үзгәрдең?
— Юк. Ярамаган фикер язмаган идем. Фәкать синең кайгыңны уртаклашуымны белдергән идем...
— Нинди кайгымны? Зинданга эләгүемнеме?
— Юк... Әткәңнең вафат булуы сәбәпле, кайгыңны уртаклашуымны белдереп язган идем...
Галимҗанның башына күсәк белән суккан кебек булды. Ул берничә минут сүз дә әйтә алмыйча катып калды. Ниһаять:
— Бу авыр хәбәрне ни өчен бүгенгә кадәр әйтми тордың? Вокзалда ук әйткән булсаң, мин Казанда тукталмыйча, туры Солтанморатка китү юлын караган булыр идем! — диде.
Шәһит үзенең гаепсез икәнен күрсәтергә тырышты:
— Гыйрфан абзыйның вафаты турында мин бит сиңа Киев төрмәсендә утырган чагында ук яздым. Ул хатның сиңа барып җитмәвен каян белим? Аннары, бу турыда сиңа Шакирҗан абзый да язгандыр дип уйладым.
— Кичер, дус! Бу кара хәбәр искәрмәстән килеп орды, шуның өчен кызып китеп сине урынсыз рәнҗеттем... Бичара әнкәй! Бер яктан, гомер иткән юлдашының вафаты, икенче яктан, әткәйнең җеназасына кайта алмавым! Ни генә уйламагандыр ул, нинди генә хәсрәт чикмәгәндер! — дип, Галимҗан башын түбән иде. Бераздан күтәрелеп иптәшенә карады:
— Әгәр төрмәгә ябылуым турындагы хәбәр әткәй вафатына кадәр авылга барып җиткән булса, аңа бик авыр булгандыр, бәлки авыруын шул да көчәйткәндер әле,— дип күрсенде.
Дустының соңгы сүзләре, бигрәк тә аның шулай көрсенеп куюы Шәһиткә бик авыр тәэсир итте. Галимҗанны тынычландырырга тырышып:
— Ул хәбәр авылга барып җиткән булса, Шакирҗан абзый сиңа язган булыр иде,— диде.
— Бәлки язгандыр да, ләкин синең хатың кебек охранканың тирән сазлыгына батып, миңа җитешмәгәндер. Юк! Казандагы эшләрне тизрәк бетерергә дә Солтанморатка китәргә кирәк! — дип, Галимҗан ашыгып киенә башлады.

* * *

Авыл мужигы газета алдырмый, әлбәттә, чөнки аның газета, китап сатып алырга артык акчасы юк. Икенчедән, укырлык хатсаваты да җитми. Барлык хәбәрне ул базардан ишетеп кайта. Үзенең хуҗалык эшләре белән Уфа, Оренбург базарларына барган арада авылдашларына, авылына кагылган яки башка нинди дә булса кызыклы бер вакыйга турында хәбәр ишетсә, шуны төкми-чәчми алып кайтып, якыннарына, таныш-белешләренә сөйли. Шулай итеп, «озын колак» буенча килгән хәбәр телдән-телгә йөри-йөри арттырылып, күпертелеп, авыл эчендә бик тиз тарала.

Шакирҗан, энесе Галимҗанның Киев зинданына ябылуы турындагы хәбәрне, авыл учителе Мирсәет Сәгыйтевтән алып торган «Вакыт» газетасыннан укып белде. Бу кара хәбәр халык телендә тагын да каралып энисенә читтән килеп ишетелмәсен, аның йөрәген бик каты җәрәхәтләмәсен дип курыкты ул. Шуның өчен бу турыда энисенә үзе әйтергә булды һәм аны ялгышлык белән булган, тиз арада аңлашылырга тиеш мәсьәлә кебек итеп күрсәтергә тырышты.

Шулай да, кара тутлы озынча битен тирән шадралар ерткалаган урядникның, каты-каты атлап, ишегалдындагы бакча ишегеннән кереп килгәнен күргәч, Хәсәнә остабикә аздан гына һушыннан язмады.

— Тагын ни булды икән?! Ходаем, үзең сакла, үзең якла! — дип, аяклары калтырап, чак егылмыйча, сәрви агачы күләгәсенә салынган сәкенең читенә таянырга мәҗбүр булды.

Ләкин улының Киевтән кайтасын белгәч һәм кайткандыр инде дип, бу аждаһаның аны барлап килүен аңлагач, җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй җиңеләеп китте.

— Кайчан кайта? Бүгенме? Туры өйгә кайтамы? — дип, куанычыннан хәтта урядникның беләгенә барып тотынды.

— Аныклап әйтә алмыйм. Бүген булмаса, бәлки, иртәгә кайтыр, ә иртәгә кайтмаса, берсекөнгә кайтып житәр. Тик кайткач ук волостька хәбәр итегез. Ул кая барса да, кем белән очрашып сөйләшсә дә, без аны күзәтеп торырга тиеш. Безгә боерык шундый! — диде урядник.

Хәсәнә остабикәнең йөзе яктырып китте.

— Алай булгач, улым кая барса да, үз иркендә, тик сез аның кайда икәнен генә белеп торырга тиеш икәнсез! Бу сөенечле хәбәрегез өчен мин дә сезне сөендерим! Аз гына сабыр итегез! — дип, ашыгып, өйгә кереп китте һәм озакламый чыгып, ике егерме тиенлек көмешне урядникның кулына тоттырды. Анысы да бик мәмнүн булып, авызын ерып елмайды һәм:

— Бувайте здоровеньки! — дип, чыгып китте.

Улы Галимҗанның авылга кайтачагын ишеткәч, Хәсәнә остабикә бер минут вакытны да бушка үткәрергә теләмәде. Иртәгә сумсалар, бәлешләр, бөккәннәр пешерергә әзер торсын дип, җиз иләктән он или башлады. Шакирҗан белән Габделхәким игенчәчемнәрне карарга дип чыгып киткәннәр иде. Алар кайтып житү белән Хәсәнә остабикә Шакирҗанны Рәян картка җибәрде:

— Бар, әйт, иртәгә көтү киткәнче иртә үк килсен. Галимҗан авылга кайта икән. Былтыргы сарык тәкәсенең берсен чалырга кирәк. Бу эшкә Рәян карттан да изге кеше табылмас. Әтиегезне дә яд итәрбез, Галимҗанны да каршыларбыз! — дип баш яулыгының очы белән ихтыярсыз аккан күз яшьләрен сөртте.

— Ә син, Габделхәким,— диде ул, төпчегенә борылып,— Хәтимә җиңгигә бар, вакыты булса, иртәгә иртә үк килсен. Абыең кайтачагын әйт. Эш күп булыр. Берүзем генә житешә алмам.

...Шундый тырышлык белән әзерләнеп көткән ана улының капкадан кереп килүен күрми калды. Бу вакытта ул сөйгән бәрәннең үпкә бавырын тазартырга дип, су буена төшкән Хәтимә җиңгигә булышырга дип киткән иде.

— Әнкәй, абый кайтты! — дип кычкырып йөгереп килгән Габделхәкимнең тавышын ишетү белән, гадәттә, бик сабыр холыклы Хәсәнә остабикә, бөтен дөньясын онытып, улы артыннан йөгерә-йөгерә, өйгә кайтты.

Галимҗан ал бакчадагы сәке читендә утырып тора иде. Әнисенең капкадан килеп керүен күреп, урыныннан сикереп торды һәм каршы атлады. Улының кочагында калган Хәсәнә остабикә аның күкрәгенә башын куеп, әйтәсе сүзләрен әйтә алмыйча, сулкылдап еларга тотынды. Галимҗанның да күңеле нечкәреп, күзлә-

ренә яшь килде. Әнисен кочагыннан чыгармыйча, аркасыннан кагып, калтыраган тавыш белән:

— Елама, әнкәй, елама! Әткәйнең җеназасына килә алмадым, кичер мине! Әткәйнең вафаты турында хәбәр вакытында килеп җитмәде шул! Бу кара хәбәрне ишетүемә бары тик ике-өч көн генә! — дип, әнкәсен юатырга тырышты.

Ул, кыр эшләрен бетергәнгә кадәр, Солтанморатта калырга булды...

* * *

Казанга кайтып, «Апанаевское подворье» дигән мосафирханәнең номерында урнашканнан соң, Галимҗан Ибраһимов, Әхмәтгәрәй Хәсәни белән очрашыр өчен, «Аң» редакциясенә китте.

— Хуш, килдегез, Галимҗан әфәнде! Мин сезне авылда күп булса бер-ике атна торырсыз дип уйлаган идем, ә Сез өч айга якын торып килдегез. Сагындырдыгыз, сагындырдыгыз,— дип, Хәсәни аны ачык йөз белән каршы алды.

Исәнлек-саулык, һавалар торышы, ашлыкларның уңышы турында сорашулардан соң, Галимҗан Ибраһимов, ниһаять, сабырсызлык белән көткән хәбәрне ишетергә теләп:

— «Татар сарыфы», басылып, дөньяга чыктымы икән, Әхмәтгәрәй әфәнде? — дип сорады.

— Борчылмагыз, Галимҗан әфәнде. Басылып чыгу гына түгел, сатылып та бетте дип әйтергә мөмкин! Мөгаллимнәр, шәкертләр, гомумән, халкыбызның мәдәни катлавы көтеп алган мондый китап ятып каламыни! Хәзер инде бу китап буенча Сезнең белән исәп-хисапны тәмам өзәргә мөмкин! — дип, зур уңыш казанган кыяфәт белән елмаеп, ике учын бер-беренә уГалап куйды.

«Бу китаптан әфәндем яхшы ук файда алганга охшый»,— дип уйлап, Галимҗан да көлемсерәде. Әлбәттә, Әхмәтгәрәй әфәнденең гонорар турындагы сүзләре әдипкә дә яхшы тәэсир иттеләр, чөнки ул кулында булган бөтен акчасын диярлек авылда әнисенә биреп калдырган иде.

Галимҗан Ибраһимовның елмаюын күргәч, Хәсәни сүзне үзенә кирәк юлга борды:

— Мин сезне, Галимҗан әфәнде, сабырсызлык белән көттем. Хәтерегездә булса, авылга китәр алдыннан үзегезгә бер тәкъдимем барлыгын аңлаткан идем,— дип башлады да, җавапмы, сораумы көткәндәй булып, тукталып торды. Ләкин Галимҗан Ибраһимов бер сүз дә әйтмичә, эндәшми утыра бирде. Кунагының йөзендә һичбер төрле үзгәреш күрмәгәч, Әхмәтгәрәй сүзен дәвам итәргә мәҗбүр булды:

— Газета-журналларда басылган тәнкыйтькә, әдәбиятыбызны, телебезне өйрәнүгә багышланган мәкаләләрегез, китапларыгыз безнең матбугатта беренче урынны тоталар. Матур әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен, бөтен кануннарын сезнең кебек белгән кеше бу көндә татар галәмендә юк дип уйлыйм. Инде сезнең берсеннән-берсе мәгънәле, матур хикәяләр һәм татар романы язуыгыз да каләмегезнең көчен күрсәтә.

Хәсәни тагын тукталып торды. Галимҗан исә, болай бик төчеләнеп мактавы бушка түгелдер, тел төбендә ни барын әйтеп бетерсен әле дип, кашларын җыерып, эндәшми утыруында булды.

— Гомумән алганда, «Аң»ның мөндәриҗәсе турында уңай фикердә булуыгызны әйткән идегез. Әгәр журналны тагын да яхшырак итеп чыгарыйм дисәк, редакциядә эшне Сез алып барырга тиеш!

Галимҗан Ибраһимов бу тәкъдим турында фикер белдерергә ашыкмыйча:

— Сез үзегез дә журналдагы вазифаларыгызны яхшы башкарасыз бит! — дип кенә куйды. Галимҗанның мактавыннан күңеле булган Әхмәтгәрәй елмайды:

— Шулай дип уйлавыгыз күңелгә, әлбәттә, бик ятышлы. Ләкин минем журналдан башка да нәшриятта эшләрем күп. Аннары, матбугат, әдәбият мәсьәләләрендә мин үземне Сезнең белән бер рәткә куя алмыйм. Әгәр Сез «Аң»да редакторлык вазифасын өстегезгә алсагыз, журналның татар дөньясында чын мәгънәсендә тотнаклы әдәби, иҗтимагый, фәнни, фәлсәфи журнал булачагына мин ышанам!

Галимҗан Ибраһимов башын чайкады.

— Мин журналга редактор була алмыйм. Дөресрәге, бу эшне миңа рөхсәт итмәячәкләр, чөнки мин хәзер полициянең ачыктан-ачык күзәтүе астында яшим. Бәлки, яшерен күзәтү дә бардыр. Аны инде үзләре беләләр...

Хәсәни бераз уйланганнан соң билгеле бер карарга килеп:

— Ярар, алай булса, редактор дип әйтмик, сәркатип диярбез, ә чынында исә редактор булырсыз! Бу турыда тиешле урыннарда сөйләшеп, ризалыкларын алырмын дип ышанам,— диде.

Асылда Галимҗан журналда эшләүгә каршы түгел иде. Киресенчә, аңарда берәр газета яки журнал редакциясендә фикердәш кешеләрне туплау, шул редакцияне үзләренең органы итү теләге белән яши иде. Бу эш өчен көндәлек газета яхшырак булыр иде дә, ләкин журналның да үзенә күрә уңай яклары бар дип уйлап, Галимҗан риза булды.

* * *

Менә 1913 ел да үтеп китте, ә күңелдә туган образларны кәгазьдә гәүдәләндерергә һаман вакыт табылмый.

Иртә белән редакциягә килгән авторлар белән очрашулар, сөйләшүләр, матбага белән бәйләнешле эшләрне башкару, кичен кулъязмалар уку, журналга басарлыкларын редакцияләү...

Җитмәсә тагын «Татар шагыйрьләре» дигән китабы басылып чыгу белән кайбер әфәнделәр: «Галимҗан Ибраһимовның татар әдәбият дөньясында үзе генә тәхет биләп утырасы килә. Шуның өчен, Тукай үзе үлсә дә, шөһрәте көннән-көн арта-көчәя барганыннан куркып, бу китабында аны кимсетергә, ул шагыйрьме-түгелме дигән булып, дәрәҗәсен төшерергә тырыша», — дип тавыш күтәрергә маташалар. Бу да аның кәефен боза иде. «Мин бит быел басылып чыккан бу китапта гына түгел, 1910—1911 нче елларда ук «Йолдыз» газетасының берничә санында басылган мәкаләләремдә дә шул фикерне язган идем. Бу әсәрдә исә мәсьәләне киңрәк, тирәнрәк итеп кенә тикшердем. Я, ни өчен ул елларны шау күтәрмәделәр икән? Аннары без Тукайның үзе белән капма-каршы утырып, уфылдап кайнаган самавырдан чәй эчә-эчә, әдәбият, шигърият кануннары турында, шулай ук аның үзенең иҗаты турында да сәгатьләр буенча, бик кызуланып бәхәсләшкәнебез бар. Ни өчен шундый гади мәсьәләләрне ваклатып, пычратып, гайбәткә әверелдерәләр икән?!» — дип уйлап, Галимҗанның күңеле рәнҗи иде.

«Әгәр дә күңелдә туган һәм, уйлана торгач, хыялында билгеле бер сюжет калыбына кертелеп өлгергән зур күләмле, тирән мәгънәле әсәр язам дисәң, башка эшләреңне ташлап, бүгенге көндә үзеңне чолгап алган мәшәкатьләр, әрнүле, рәнҗүле тойгылардан читкә китәргә, бөтен иҗат көчеңне шул күңелеңдә кадерләп саклаган әсәреңә генә бирергә кирәк! — дигән фикергә килгәч, Галимҗан «Аң»дагы эшен бик кирәкле һәм үзе өчен бик кызыклы дип уйласа да, журналдан китәргә, журналдан гына түгел, вакытлыча Казаннан ук китәргә кирәк дигән карарга килде.

Чал башыннан үткән күп вакыйгаларны сагышлап, моңланып, ярсып, дулкынланып хикәя кылган мәшһүр Кара диңгез турында Галимҗанның рус әдәбиятыннан күп мәртәбәләр укыганы бар иде. Диңгезнең үзен генә түгел, зифа кипарисларны, яшел атлас яфракларын җәеп утырган магнолияләрне, тузганактай җиңел алсу чәчәкле мимо-

залар белән күңелне кызыктырган шәһәрләрне Галимҗанның күптән күрәсе килә иде. Күптәнге шул теләгенә ирешер өчен ул Кара диңгез буендагы шәһәрләрнең берсенә китәргә уйлады.

Китәргә теләвенең тагын бер сәбәбе бар иде. Юл уңаеннан Киевта тукталып, Зураб, Агаш, Лизалар белән очрашырга, алар белән сөйләшеп утырырга тели иде ул. Бәлки, алар аркылы андагы революцион партияләрнең программалары белән дә танышырга, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр турында китаплар, брошюралар алырга мөмкин булыр дип өметләнә иде. Киевкә тукталу өчен рәсми сәбәп тә бар, тентү вакытында жандармнар кулына төшкән китапларын, кулъязмаларын кайтарып алмаган иде әле ул.

Башта Әхмәтгәрәй әфәнде Галимҗанның «Аң»нан китүенә каршы төште. Бернинди үгет тә тәэсир итмәгәч:

— Соңгы вакытта журналда Сез, Галимҗан әфәнде, «Милләтчелекне ничек аңлыйсыз?» һәм «Яңа елдан ни көтәсез?» дигән маузугта ике анкета тараткан идегез. Шул анкеталарыгызга әле яңа гына җаваплар килә башлады. Бу эшне ахырынача очлап чыгарырга кирәк түгелме? Бу — бер. Икенчедән, эш хакыгыз дип уйласагыз, үзара киңәшеп, анысын да арттырырга мөмкин булыр иде,— дип тә карады.

— Мин Казаннан бөтенләй китәргә уйламыйм, китабымны язып бетергәч үк кайтачакмын. Аңа кадәр анкеталарга җаваплар да килеп бетәр. Һәм, укучыларның фикерләрен йомгаклап, редакция исеменнән журналда мәкалә белән чыгарга мөмкин булыр. Бәлки, әле дискуссия ачарга да туры килер. Бусы инде җавапларның нинди булуына карап эшләнер. Ә акча мәсьәләсенә килсәк, ара-тирә мәкалә, я кечкенә хикәя язып җибәрермен, гонорарын тоткарламый юлласагыз, миңа шул җитеп торыр,— дип җавап кайтарды Галимҗан.

— Бу турыда ике сүз булу ихтималы юк! Фәкать шуны да игътибарга алырга кирәк, Кавказда, Кара диңгез буенда яшәү өчен генә түгел, анда барып җитәргә дә күп акча кирәк. Шул турыда да уйладыгызмы? — дип сорады Хәсәни әфәнде.

Галимҗан Ибраһимовны мәсьәләнең бу ягы кызыксындырмый иде. Җавапны бик тыныч бирде:

— Үзегезгә мәгълүм: мин байбәтчәләр кебек типтереп, акчаны күп исраф итеп яшәүчеләрдән түгел. Хәзерге көндә «Татар шагыйрьләре» өчен дә, «Татар сарыфы» өчен дә алган гонорарларыма әле кул тидермәдем. Аннары, журналда эшләгәнем өчен хезмәт хакымны да, «Аң»да һәм «Йолдыз»да басылган мәкаләләрем өчен дә гонорарларымны алмадым әле. Барысын бергә җыйсам, ярты ел гомер итәргә җитәр.

Әхмәтгәрәй әфәнденең Галимҗан Ибраһимовны журналдан җибәрәсе килмәве аңлашыла иде, чөнки ул эшли башлагач, «Аң»да иҗтимагый, сәяси, фәлсәфи мәсьәләләргә, сәнгатькә багышланган мәкаләләр, әдәби күзәтүләр еш-еш күренгәләде. Әдәбиятта, матбугатта танылган әдипләр, алдынгы фикерле яшьләр журнал тирәсендә оеша башлады. «Аң»ның тиражы да ай саен арта барды.

Дөрес, мондый яңалыкларның кайберләре Әхмәтгәрәй әфәнденең күңеленә ошап ук җитми иде. Мөселман динен реформалаштырып, бөтен «Әһле мөслимин»не берләштерү, Төркестанда җир биләргә хокук алып, шуның нигезендә татар сәүдәсен киңәйтү, байлыгын арттыру, җәмгыяте хәйрияләр аша ярдәм оештырып, киң татар гаммәсенең[1] аң-белемен күтәрү, тормышын яхшырту кебек буш хыялларга, Печән базарын, Болак буйларын кузгаткан интригаларга, Харитонов типографиясенең Коръәнне баскан чакта аятьләрне буташтыруы сәбәпле туган шау-шуларга Галимҗан Ибраһимовның журналда урын бирмәве Әхмәтгәрәй әфәнденең күңелен борчый, редакциядә төрле аңлашылмаулар тудыра һәм Галимҗанга журналны үзе теләгәнчә нигездән үзгәртеп корырга ирек бирми иде.

---

[1] Гаммә — масса

Соңгы вакытта яшь әдипнең күңелен Казаннан биздергән тагын бер сәбәп бар иде. 3 февраль көнне артист Габдулла Кариев яшәгән «Амур» мосафирханәсенең тугызынчы бүлмәсендә яшьләрнең җыелышы булырга тиеш иде. Галимҗан Сәйфетдинов һәм Кариев белән алдан килешү буенча, Галимҗан Ибраһимов анда «Татар яшьләренең вазифалары» дигән темага доклад ясарга булды. Бу докладында ул, татар интеллигенциясенең, бигрәк тә киң татар массасының бишенче ел революциясенә мөнәсәбәтен ачыкларга һәм алдагы революцион көрәшләрдә дөрес юл сайлар өчен иҗтимагый, сәяси, икътисади мәсьәләләрне яхшы өйрәнү кирәклеген исбат итәргә уйлады. Аның фикеренчә, бу җыелыш алдынгы карашлы яшьләрдән революцион оешма төзү юлында беренче адым булырга тиеш иде. Ләкин җыелышка уннан артык кеше чакырылган булса да, Галимҗан Сәйфетдинов, Гафур Коләхметов, Ибраһим Кулиев һәм Шәһит Әхмәдиевләрдән башкалары килмәде. Яшьлек кызулыгы белән Галимҗан Ибраһимов: «Бу Казан яшьләре һаман шулай искечә эшсез, имансыз, фасыйк икәннәр! Болар белән эш башлау, эш кылу имкане булмаячак!» — дип уйлады һәм аның Казаннан китү фикере тагын да көчәйде.

Әдипне Кавказга китү теләгеннән кайтарып булмаячагын аңлаган Әхмәтгәрәй әфәнде:

— Ярар, алай булса, язган мәкаләләрегезне, хикәяләрегезне «Йолдыз»га җибәреп маташмагыз, туры «Аң»га, минем адреска салыгыз. «Йолдыз» кебек саранланып, гонорарыгызны кысып, киметеп утырмам, кичектерми шунда ук җибәрермен! — дип ышандырды.

Чыннан да, Әхмәт Гәрәй әфәнде Галимҗанга тиешле булган айлык хезмәт хакын да, гонорарын да тоткарламыйча, саранланмыйча бирде. Ниһаять, 1914 елның 13 февралендә Галимҗан тиз йөрешле поездга утырып Көньякка таба юл тотты.

## Көньяк

Казанда һәркөн диярлек кар ява, тротуар читләренә таудай көртләр өелә иде. Көньякка киткән саен, табигать җылына, кояш рәхимлерәк була бара, кырлардагы кар юрганының шиңеп юкаруын поезд тәрәзәсеннән дә чамалап була. Киевкә килеп җиткәндә, җиңелчә салкын җилле һава үзенең сафлыгы белән Галимҗанга яз башын хәтерләтеп, күңелендә яз көне генә була торган җилкенү уятты.

Киев туфрагына аяк басу белән, аның беренче омтылышы — иске дусларын эзләп табу, алар белән очрашу, сөйләшү, хәбәрләшү булды. Шуның өчен иң элек университетка китте. Хокук факультетының расписаниесенә карагач, Николайны табу аңа читен булмады.

Якташы Галимҗанны күрү белән, ашыгып, лекциядән соң бушаган аудиториягә алып керде. Урынга утыртып тормыйча гына:

— Син каян килеп чыктың? Узган ел Солтанморатка кайтам дигән идең бит! — диде.

Николай нәрсәдәндер шикләнгән, Галимҗанны күрүгә аптыраган сыман иде. Галимҗан, риясызланмый, аннан ачыктан-ачык сорады:

— Сиңа ни булды? Мин килүгә гаҗәпләнгән кебек күренәсең...

— Дөресен әйткәндә, сине күргәч, чыннан да аптырап калдым,— диде Николай.— Узган ел, сез моннан киткәч, охранка күп кешеләрне кулга алды. Шуның өчен хәзер бик сак булырга туры килә. Син бит Киев жандармериясенә билгеле кеше. Болай иркенләп йөрергә ярамый.

— Аңлашылды. Син миңа шуны гына әйт, Зурабны кайда күрергә мөмкин?

— Ул төрмәдә...

— Ә Агаш?

— Ул да.

«Әлбәттә, революцион көрәшкә җаны-тәне белән бирелгән Лиза да зинданга эләккәндер»,— дип уйлап, бу кыз турында сораштырырга Галимҗан бераз җөрьәт итми торды. Ниһаять, Николайга күтәрелеп карамыйча гына:

— Ә Лиза белән очрашырга мөмкин булмасмы? — дип сорады.

— Аны да күрә алмассың,— дип җавап кайтарды Николай.

— Әллә ул да зиндандамы?

— Юк,— диде егет нәфрәтләнгән кебек авызын кыйшайтып,— ул безнең арадан китте.

— Ягъни?

— Нindидер поляк офицерына гашыйк булып, бөтен дөньясын онытты, шуның белән этисенең утарына кайтып китте. Анда зур туй ясаганнан соң, мадам Елизавета үзенең офицеры белән ширбәтле аен үткәрер өчен Италиягә сәяхәткә киткәннәр дип сөйлиләр.

Николайның шулай мыскыллап әйткән хәбәре Ибраһимовның йөрәгенә хәнҗәр белән кадаган кебек булды. Күңелендә иң садә хисләр уяткан Лизаның шулай булырына Галимҗанның һич ышанасы килмәде. Лизаның революцион көрәшкә тугрылыгына ул бер минут та шикләнми һәм аның белән бергә бөек идеаллар өчен фидакарьләрчә көрәшүне үзенә бәхет-сәгадәт саный иде. Үзенең рухи илһамчысы, рухи юлдашы дип санаган кызның нindидер фасыйк, патша ялчысы, патша сакчысы булган офицер өчен иң гали, иң мөкатдәс эшен ташлап китүе турындагы хәбәр аны аяктан егылыр дәрәҗәгә китерде. Ул берничә минут сүз әйтә алмыйча катып калды. Ниһаять, исен туплап, кулын селекте дә ишеккә таба юнәлде. Ишек тоткасына тотынгач кына Николайга әйләнеп карады һәм бераз карлыккан тавыш белән:

— Хуш, сау бул, мин киттем! — диде.

Николай гаҗәпләнеп, иңбашларын җыерып, аның артыннан карап калды.

* * *

Сәяси белем, киңәш бирерлек иске танышларын Киевтә таба алмавы, бу көрәштә үрнәк булырлык юлдашы дип күңел түрендә саклаган кешесенең шундый мөртәт булып чыгуы Галимҗанның ихтыярын какшата язды. Ләкин Украин халкының бөек шагыйре, талантлы рәссамы, тирән фикер иясе Шевченконың тууына йөз ел тулу көннәренең шаһите булу әдипнең җәрәхәтле йөрәгенә дәва бирде. Самодержавие бу көнне билгеләп үтәргә рөхсәт итмәсә дә, Киев халкының күпчелеге каһарман әдипнең онытылмас рухы белән яши иде. Бу хәл Галимҗан Ибраһимовка да күңелсез уйларын җиңеп, башын күтәрергә ярдәм итте.

Шевченконың әсәрләре белән Галимҗан Ибраһимов күптән таныш иде, шуның өстенә хезмәт ияләренең, алдынгы интеллигенциянең шагыйрьне ни дәрәҗәдә яратуын, йөрәкләренә якын итүләрен күреп, аеруча сөенде. Шевченконың патша хөкүмәте кысрыклавына да карамыйча, шигырь һәм рәсемнәрендә үз халкының аһ-зарын җырлавы татар әдибен сокландырды. Бу каһарман шагыйрьнең әсәрләре безнең халкыбызның да кайгысын сөйли, безнең дә язмышыбызны чагылдыра, шуңа күрә ул безнең халкыбызга да якын дип уйлап, татар халкын бөек кобзарь белән таныштыруны үзенә бурыч санады һәм, зур мәкалә язып, «Йолдыз» газетасына җибәрде.

Юлчының юлда булуы яхшы диләр. Ләкин Галимҗан тиз генә китә алмады. 1913 елдагы тентү вакытында жандармерия кулына төшкән әйберләрен кайтарып алу мәшәкатьләре ике-өч көнгә сузылды... Кызганычка каршы, кулъязмаларны, бигрәк тә бәхетсез «Казакъ кызы» романының житмештән артык битен, китапларны кайтармадылар. Галимҗанның гаҗәпләнеп:

— Китапларым, кулъязмаларым ни өчен кайтарылмый? Аларда хө-

кумәткә каршы әйтелгән бер сүз дә юк бит. Аларны кайчан алырга мөмкин булыр? — дип сорады.

Аңа каршы подполковник Лахутин:

— Аларны соңыннан алырсыз. Каян, кайчан алырга мөмкин булачагы турында хәбәр итәрбез,— диде.— Сез моннан кая китәргә уйлыйсыз? — дип тә сорады.

Жандармерия идарәсен адаштыру нияте белән Галимҗан:

— Мин моннан туры Казанга кайтмакчы булам. Гомумән, Казанда яшәргә уйлыйм. Киевкә сездәге әйберләремне алыр өчен генә килдем,— дип җавап кайтарды.

Ләкин подполковник Галимҗанга ышанмады. «Бу «интеллигент» вак-төяк нәрсәләр өчен генә шундый ерак юлга чыкмагандыр. Аның башка ниятләре, үзе кебек шикле кешеләр белән очрашу, элемтәгә керү ихтималлары бар. Аның Киевкә килүе турында Казан идарәсенең махсус хәбәр итүе бушка түгел, әлбәттә!» — дип уйлады. Узган елгы вакыйгаларда Галимҗанны танып калган шымчыларның берсен аның артыннан күзәтергә җибәрде. Шымчы юлчының Одессага китәчәген килеп әйтте.

Бу хәбәрне алу белән, Киев жандармерия идарәсе Казанга: «Интеллигентный» кушаматы белән сезгә билгеле булган Галимҗан Ибраһимов 11 мартта, күзәтүчесез, Одессага китте. Аның артыннан тышкы күзәтү оештырылсын өчен, Одесса губернасының жандармерия идарәсенә хәбәр ителде»,— дип, белдерү җибәрде. Шуннан башлап «Интеллигентный»ның һәрбер адымы Казан жандармерия идарәсенә дә, Киев жандармерия идарәсенә дә мәгълүм булып торды. Хәлбуки, Галимҗан Ибраһимов Сухумга барып җиткәнче, юл мәшәкатьләре, билет мәсьәләләре белән бәйләнеше булмаган бер кеше белән дә очрашмады, сөйләшмәде. Ул бары тик Севастопольдәге мәшһүр панораманы, Одессаның Диңгез буе бульварын һәм монументаль баскычын, шуның кебек башка кызыклы урыннарны гына иркенләп карап йөрде.

Кыя таулар итәгеннән башлап Кара диңгез кырыена җиткәнче тәбәнәкләнә барган калкулыклар өстендә утырган һәм яшеллек дәрьясына чумган Сухумның җылы, хуш исле һавасы яшь әдипне иркәләп кочагына алган сыман булды. Тужуркасын һәм Кәрим Тинчуриннан алып та, һаман кайтарып бирелмәгән плащны сул беләгенә асып, уң кулына портпледын тотып, Галимҗан күлмәкчән генә пароходтан төште.

«Цесаревич Георгий» исемле пароходны каршы алырга җибәрелгән шымчы күзәтелергә тиешле кешесен менә шул плащ аркасында бик тиз танып алды һәм диңгез буендагы Михайловская набережная дигән урамнан «Венеция» мосафирханәсенә чаклы аның артыннан калмыйча барды...

## Сухумда

Кутаис губернасының жандармерия идарәсе, Сухумга килеп төшкән 17 марттан башлап Казанга кайтып киткән көненә кадәр «Интеллигентный»дан күзен алмады. Галимҗан исә аны-моны белмәде, беренче көнне генә мөсафирханәдә кунды да, маклер ярдәме белән булса да, арзанрак квартир эзләргә булды. Каштан, сәрви агачлары, мимозалар үсеп утырган берничә урамны әйләнеп чыккач, диңгезгә якын бер тыкрыкта үзенә җайлы бүлмә табып урнашты. Сухумның мәшһүр Ботан бакчасын күрергә күптән хыяллана иде, беркадәр эшләрен бетергәч, шунда китте.

Шәһәр уртасындагы бу бакчада нинди генә агачлар да нинди генә үсемлекләр юк иде. Ерак Африкадан, Италиядән китерелеп һәм Сухум туфрагында бик әйбәт тамыр җәйгән пальмалар, банан, апельсин, мандарин агачлары; Кытайдан, Япониядән китерелгән эрбет агачлары, Һиндстаннан хуш исле сандал агачлары, бакчаның кечкенә күле өстендә

түгәрәк подноска охшап җәелеп яткан ялпак яфраклар арасындагы ак, алсу виктория чәчәкләре... Табигатьнең искиткеч матурлыгы, байлыгы Галимҗанны үзенә гашыйк итте, ә Кара диңгез дулкыннарының яр буендагы чуерташларны сыйпый-сыйпый, серле тавыш белән бертуктаусыз пышылдап утырулары әдипнең иҗат фантазиясен тагын да көчәйтеп, күптәннән бирле күңелендә асраган әсәрен язарга мәҗбүр итте.

Ботан бакчасын карап кайтканның икенче көнендә, күк йөзен кара болытлар каплап, дәһшәтле давыл купты. Ул ярсып, үкереп, диңгез дулкыннарын тау-тау күтәреп яр буена атып ташлады. Бу күренеш Галимҗан Ибраһимовка Бишенче ел революциясе көннәрендәге көрәш дулкыннарының, менә шулай ярсып, самодержавие көчләренә каршы ыргуларын хәтерләтте һәм романны давыл күренешеннән башлап китү үзеннән-үзе килеп чыкты.

Романның беренче юлларын язу белән, Галимҗан Ибраһимов бөтен дөньясын онытты. Аның күз алдында — фәкать язылып яткан әсәре, аны тудырган вакыйгалар, күренешләр, кешеләр...

Егерме ике көн бертуктаусыз күзәткәннән соң, Кутаис губернасындагы жандармерия башлыгы үзенең Казандагы коллегасына яшь әдипнең көннәре һич үзгәрешсез, һаман бер төрле үтүен язарга мәҗбүр булды: «Ул беркем белән дә очрашмый, һәркөнне уникедән бергә кадәр почтада була, шунда «до востребования»гә килгән хатларын, газеталарын алып укый да өенә кайтып китә. Кайчакта кич белән пристаньга яки бульварга чыгып, һавада йөреп кайта. Ул әдәби эш белән шөгыльләнә булса кирәк. «Венеция» гостиницасында да «журналист» дип язылган иде. Аңа килгән хатларны ачып укыр өчен кирәкле чараларны күрәбез»,— дип, бик тыйнак кына хәбәр бирде.

Яңа әсәрен язган вакытта күңелендә туган идеал образларны яисә ачу, үкенү, нәфрәт уяткан тискәре шәхесләрне үзләренә хас сыйфатлары белән, чынбарлыкка туры китереп, тагын да баетыбрак, тагын да җанландырыбрак күрсәтү теләге шулкадәр көчле иде ки, ул ихтыярсыз, тирәягындагы иптәшләре, таныш-белешләре арасыннан китабындагы типларны, вакыйгаларны раслый, гомумиләштерә торган сыйфатларны, күренешләрне эзләде. Нәтиҗәдә, ирексездән аның күз алдына Хөсәен Ямашев килеп басты. Аның какшамас, фидакарь революцион көрәшче сыйфатлары Зариф Булатовта бик ачык чагылдылар. Урта гасырдагы гарәп әдәбияты классигы шагыйрь Хәрири иҗат иткән үткен телле, һичкемгә баш бирмәс, төрле маҗаралардан җиңел генә котыла белгән Серуженин исемен йөрткән персонаж исә чая холыклы, берничә тапкыр жандармерия кулына эләгеп, зинданга ябылган булса да, аннан качып чыга белгән Гыйлемдар Баембәтовны хәтерләтә иде. «Ашказар» көенең халык күңеленнән чыккан чын моңын өйрәнер өчен Башкортстанга китеп барган шагыйрәнә күңелле Сәхип белән тормыштагы дусты Хөсни Кәрим арасында да уртак сыйфатлар табып була. Инде, революцион көрәшне бары тик кызыклы маҗаралардан торган уен дип тапкан һәм үз-үзенә сокланып, мин нинди нык йөрәкле, батыр кыз дип хыялланырга яраткан, ә беренче каршылыкларга очрау белән үзенең кемлеген күрсәткән мирза кызы Рауза образында Киевтәге танышы Гөлсем Әхтәмованың һәм Галимҗанның йөрәген җәрәхәтләгән Лизаның сыйфатлары ачык сизелә иде.

Галимҗан Ибриһимов Казан егетләреннән өметен өзеп, боларны оештырып, сәяси көрәшкә әзерли башлау мөмкин түгел дигән фикер белән Сухумга чыгып киткән булса да, романындагы фидакарь көрәшчеләрнең тәэсире белән аның күңелендә яңа өметләр уяна башлады. Либерал байлар айга бер яки ике атнага бер чыгара торган журналлар аркылы гына үзеңнең иҗтимагый, сәяси идеалларыңны халыкка тарату мөмкин булмаслыгын ул хәзер аңлаган иде. Моны «Аң» журналында дүрт ай эшләве аңа ачык күрсәтте. Бу эш өчен иҗтимагый-сәяси программасын халыкка даими җиткереп барган көндәлек газета кирәк.

Галимҗан Ибраһимовның үзенә дә, аның иптәшләренә дә газета чыгарырга охранка, әлбәттә, рөхсәт бирмәячәк. Киев зинданыннан котылып, Казанга кайтканнан соң Кабан күле буендагы дачада иптәшләре белән сөйләшеп утырган чакта газета турында хыялланулары исенә төште. Илебезнең хәзерге хәле, мөселман халкының рухи һәм икътисади ихтыяҗлары, татар мөгаллимнәренең матди, мәгънәви, рухи һәм хокукый хәлләре, мәктәп, мәдрәсәләрдә уку-укыту эшләренең куелышы кебек, барлыгы унтугыз бүлектән торган мәсьәләләрне күрсәтеп, «Аваз» исемле газетамы, журналмы чыгарырга рөхсәт сорап, Шәһит Әхмәдиев исеменнән гариза биргәннәр иде. Ул вакытта Казан губернаторы яшьләрнең соравын кискен рәвештә кире какты. Ләкин кул кушырып утыра торган чак түгел, бер дә булмаса Казанда чыга торган газеталарның берсенә якынаерга һәм аның тирәсендә фикердәшләрне оештыра башларга кирәк, дип уйлады Галимҗан.

Май урталарында Хәлим Искәндәревтән[1] килгән хат Галимҗан Ибраһимовны бу турыда тагын да ныграк уйланырга мәҗбүр итте. Эшләргә кирәк дип уйлаган эшен кичектерергә яратмаган кеше буларак, бу юлы да иптәшенә хатны тиз язды. «Без бит синең белән узган ел да, «Йолдыз»ны үз органыбыз итәргә кирәк дип сөйләшкән идек. Баттал эшли башлаганнан бирле «Йолдыз»да эшләр уңышлырак бара. Ләкин ул үз тирәсенә тиешле кешеләрне туплый алмый. Вәхаленки, без «Йолдыз»га үз фикердәшләребезне мөмкин кадәр күбрәк җыеп, бөтен көчебезне куеп эшләргә тиешбез. Минемчә, һәрбер матбугат эшчесе Казанда яшәргә һәм шул казанда кайнарга бурычлы. Мондагы эш фәкать телеграммаларны русчадан тәрҗемә итү, төссез, коры, казенный мәкаләләр язудан гына гыйбарәт булмаячак. Киресенчә, газетада синең фантазияне канатландырырлык киң дәрәҗәдә мөмкинлек булыр. Безгә, редакторлыкны Һади Максуди кулыннан алып, аны нәшир итеп кенә калдырырга кирәк булыр» ...дип язды ул.

Көннәр буе роман өстендә эшләп арыган, ялгызлыктан интеккән чакларында ул шулай ара-тирә хатлар язып, якын күргән иптәшләре, фикердәшләре белән планнарын уртаклаша иде.

«Хәят дулкыннары» исемле трилогия итеп планлаштырылган әсәренең «Безнең көннәр» дигән беренче бүлеген дүрт ай эчендә тәмамлагач та Галимҗан Сухум белән саубуллашты һәм пароходка утырып, Одессага китте. Аннан поезд белән Казанга юл тотты. Ниһаять, 23 июльдә Казан туфрагына аяк басты...

* * *

...1917 ел. Февраль аеның соңгы көннәре. Төннәрен ара-тирә кар явып, җирне каплаган йомшак ак юрганның өстен яңартып торса да, яз башы якынлашуы сизелә иде. Кояш ягымлырак елмая, көннәр якты, күңелләр нииндидер билгеле булмаган шатлык көткән кебек җилкенеп тора.

Галимҗанның Солтанморатта чагы иде бу. Бүлмәнең түр тәрәзәсе янында күлмәкчән генә утырган Галимҗан ишегалдына чаналы ат килеп кергәнен күрде. Кунакны чыгып каршылар өчен ул киенеп тә өлгермәде, кинәт ишек ачылып, күптән күрешмәгән балалык дусты Габделәхәт Сөләйманов килеп керде.

— Хуш киләсең, Әхәт! Сине нинди җилләр безнең якка ташлады? — дигән сүзләр белән Галимҗан иптәшенә каршы атлады. Алар кул кысышып күрештеләр, Галимҗан Әхәтнең тунын, бүреген салдырып, сандык өстенә ташлады. Аннары кунагының иңбашына кулын куеп, аны бүлмә уртасындагы өстәл янына китереп утыртты.

---

[1] Хәлим Искәндәрев — Троицк шәһәрендәге мәдрәсәдә укытучы.

— Я, сөйлә, сине монда нинди җилләр ташлады? — дип, соравын кабатлады.

— Авылга кайтканыңны ишеттем дә, шәһәрдә яшәгән кеше бик күп яңа хәбәрләр белә торгандыр, дип килдем. Бигрәк тә Питербургтагы хәлләр турында ишетермен дип уйлаган идем. Үзеңне дә сагындым, күрәсем килде,— дигән җавапны ишеткәч, Галимҗан өстәл өстендәге бер өем газеталарны Әхәтнең алдына якынрак этәрде:

— Менә, укы! Монда хәбәрләрдән башка нәрсә юк! — диде ул. Ләкин иптәшенең газеталар караштыра башлавын көтәргә сабыры җитмәде, яңа хәбәрләрне үзе сөйли башлады:

— Син, Габделәхәт туган, газеталарны укырга өлгерерсең әле. Мин сиңа, юлга чыгар алдыннан гына ишеткән өр-яңа, газеталарда әле басылып өлгермәгән хәбәрләремне сөйлим. Солдатлар, эшчеләр демонстрацияләренә атмыйбыз дип, үзләре алар ягына чыгалар икән! Патшалыкның кара көчләре белән революцион көчләр арасында хәзер аяусыз бәрелешләр бара. Дөньяда менә нинди куанычлы, өметле кузгалышлар турында хәбәрләр бар, Габделәхәт туган!

Алар, сөйләшеп утыра торгач, шактый ук мавыгып киттеләр. Шул вакыт бүлмәгә, ишекне өендәге кебек киң ачып, авылның мәзине килеп керде. Галимҗан Ибраһимовның борын канаты бер-ике тапкыр сикереп куйды. Зиннәт мәзиннең шулай вакытсыз килүен яратмау галәмәте иде бу. Ләкин үзе моны сиздермәскә тырышты:

— Рәхим итегез, Зиннәт әфәндем хәзрәтләре, үтегез, табынга якынрак утырыгыз.

Мәзин, ике куллап Галимҗан һәм Габделәхәт белән күрешкәч, өстәл янына килеп утырды. Кулын күтәреп, сакалын селкетеп, пыш-пыш килеп, дога кылды. Шул араны табындагы ризыкларга да күз йөртеп өлгерде. Догасын тәмамлап, битен сыпырып алгач ук сүзгә күчте:

— Остабикәнең машалласы бар. Аның табынына күз салсаң, дөньяда коточкыч сугыш бара дип уйламассың! Хәзерге көндә авыл җирендә генә түгел, Өфе кебек зур шәһәрнең кибетләрендә дә ипи, чәй, шикәр таба алмассың! Сугышка кадәр сәдакага сарык бәтие, бозау кебек терлек бирә торганнар иде. Хәзер кая! Хәтта чебеш тә бирмиләр. Бәясе көннән-көн төшә барган кәгазь акча төртәләр дә вәссәлам!

— Аһ-зарыгызны соңыннан сөйләрсез, башта ризыктан авыз итегез. Әнкәй әле генә өстәлгә кайнар бәккәннәр китереп куйды,— дип, Галимҗан Ибраһимов аның бетмәс-төкәнмәс зарлануын туктатты.

Шуны гына көткән мәзин, ачкүзләнеп, ашыга-ашыга, зур-зур кабып, өстәлдәге ризыкларны сыпыра башлады. Ниһаять, шикәрле чәйне алты чынаяк эчкәннән соң аны түнтәреп, тәмләп кикерде дә Галимҗанга карады. Гади бер нәрсә әйткән кебек, ул:

— Ишеттегезме? Патшаны тәхеттән төшергәннәр бит,— диде.

Өстәл янындагылар ышанырга да, ышанмаска да белмичә, икесе беравыздан:

— Сезгә аны кем әйтте? — дип сорадылар.

— Кем әйтсен? Балаларны урысча укытучы учитель Мирсәет әйтте. Аңарга Питербургтан кемдер телеграмма суккан.

Моны ишеткәч, Галимҗан Ибраһимов мәзинне күзләре белән тишәрдәй итеп карады, утырган урыныннан кузгала алмыйча катып калды. Ниһаять, исен туплады:

— Тамак өчен җаныңны да, динеңне дә фида итәргә әзер икәнсең, фидия козгыны. Кайнар сумсалардан коры кала күрмим дип, шундый хәбәрне әйтми утырасыңмы! — дип, өстәл янынннан китеп, ашыга-ашыга киенә башлады.

— Габделәхәт, әйдә! Киттек! — дип кычкырды ул, мәзингә әйләнеп тә карамастан.

Ишегалдында кунакның тугарылмый калган чанасына утырып, атны Мирсәет Сәгыйтев өенә кудылар.

Телеграмма, чыннан да, бар икән. Галимҗан аны Мирсәет кулын-

нан алып укыгач, иптәшләренең икесен берьюлы кочаклап, зырылдатып әйләндерә башлады. Ләкин ул акылын тиз җыйды.

— Бу көнне дә күрәсебез бар икән, дуслар! Аны күптән тибеп төшерергә кирәк иде! Нигә без монда вакытыбызны бушка үткәрәбез?! Әйдәгез, волостька, Корманайга киттек! — дип, ишекне ачты.

Габделәхәт белән Мирсәет тә аның артыннан чыгып, чанага утырдылар. Яңадан Галимҗаннар йортына кайтып, аларның да атын җиктеләр һәм ике ат белән волостька киттеләр.

Солтанморат белән Корманай арасы җиде чакрым иде. Галимҗан Ибраһимов кулындагы дилбегәне бераүгә дә бирмичә, үзе дә атка кушылып йөгерерлек булып, аягүрә басып барды. Атын Корманайга җиткәнче бертуктаусыз куды.

Пальто чабуларының каршы искән җилдә ике якка ачылып җилфердәве, алга омтылган гәүдәсе аны очып барган лачынга охшата иде.

Егетләр, атларны ак күбеккә төшереп куа-куа, Корманай урамына килеп кергәндә, ярсуларына түзә алмыйча:

— Патшаны кадалдырганнар!

— Патшаны тәхеттән куып төшергәннәр!

— Николайның сыртына типкәннәр! — дип кычкырдылар.

Аларның сәер сүзләрен ишетеп, урамда очраган кешеләрнең кайберләре аптырап, барган юлларыннан туктап, катып калдылар, кайберләре шундый гаҗәеп хәбәрне башкалар белән уртаклашырга теләпме, урам буйлап йөгерә башладылар, ә кайберләре, хәбәр китерүчеләрдән яхшырак сорашырга уйлап, чана артыннан иярделәр.

Волость идарәсенә килеп җитү белән Галимҗан Ибраһимов чанадан сикереп төште дә, атын бәйләп тә тормастан, ишеккә таба атылды.

Чытырдап торган суык саф һавадан кергән кешеләргә тәмәке төтене һәм авыр сасы ис белән тулган бүлмәдәгеләрнең шәүләләре генә күренә иде.

— Кто там? Закройте дверь! — дип кычкырган ямьсез, калын тавыштан Галимҗан урядник Кузьминны танып алды.

Кузьмин да ишекне япмый кергән кешенең үзенә күзәтергә тапшырылган Галимҗан Ибраһимов булуын таныды. Алашаныкы кебек озынча битендәге тирән шадралар белән өзгәләнгән калын кашларын җыерып:

— Ә-ә, Сез икәнсез! Ишек ябарга сыртыгызга кулыгыз җитмиме әллә? — дип кычкырды.

Кузьминның тавышына һич исе китмәгән Галимҗан:

— Николайның тәхеттән төшерелүе турындагы телеграмманы күрсәтегез! — дип таләп итте.

Бу сүзләрне ишеткәч, Кузьминның болай да кызарып торган керфексез күз кабаклары тагын да ныграк кызарды. Күзләре атылып чыгардай булып акайды. Басып торган урынында катып калды. Кырыйдарак утырган волость кредит ширкәтенең рәисе Порчуханов та, колгага охшаган бик озын һәм ябык писарь дә, каравылчы Шәрәф карт та утырган урыннарыннан сикереп тордылар. Аларның йөзләрендә аптырау катыш курку ачык күренә иде. Шул арада атларны бәйләп кергән Габделәхәт белән Мирсәетне күргәч, урядник тагын да шүрләп төште, чөнки ул бу кешеләрнең Галимҗан Ибраһимов белән дус икәнен белә иде. Куркуын сиздермәскә тырышкан урядник, Галимҗаннан читкәрәк китеп, бүлмә буйлап ары-бире йөри башлады.

— Ни өчен бу хәбәрне халыктан яшерәсез? Кая ул телеграмма? Күрсәтегез!

Кузьмин артка чигенеп, билендәге кылычының сабына тотынды.

— Һичбер төрле телеграмма да, хәбәр дә килгәне юк! Провокация таратасыз! Моның өчен нинди җәза алачагыгызны беләсезме? — дип акырды.

Галимҗан, Мирсәеткә килгән телеграмманы кесәсеннән чыгарып, Кузьминның алдына ук килеп басты:

— Менә ул телеграмма! Безгә килгәч, сезгә дә килергә тиеш!

Урядник, Галимҗан Ибраһимовның кулындагы кәгазьгә күз кырые белән генә карап алды да:

— Бу — рәсми кәгазь түгел! — дип, аркасы белән стенага барып терәлде.

Галимҗанның ачуы чиктән тыш кабарды.

— Шулаймыни? Рәсми булмаса, без аны хәзер рәсмиләштерәбез!

— Бу провокация бушка үтмәс! Әллә зинданны сагындыгызмы? — дигән сүзләр белән куркытып маташкан урядникны яшьләр волость каталажкасына яптылар.

Патша хакимиятенең билгесе булырдай нәрсә бар икән монда дигән кебек, Галимҗан тирә-ягына каранды. Аның күзенә бүлмәнең бер почмагында торган кечкенә өстәл өстендәге «Свод законов» китабы эләкте. Ибраһимов башта аны ерткалап ташларга уйлаган иде, ләкин кулы бармады. Китапны каравылчы Шәрәф агайның кулына тоттырды:

— Бар! Моны архивка илтеп куй! — диде, үзе иптәшләренә борылып: — Әйдәгез, киттек! Уфага барырга кирәк. Монда басып торудан файда юк! — дип, ишеккә таба юнәлде.

Урамга чыгулары белән, егетләрне гөж килгән халык төркеме каршы алды. Кешеләр, кулларын бутап нидер кычкыралар, кочаклашалар, кайберләре, кайсы тарафка кушылырга белмичә, аптырап, тирә-якларына каранালар.

Шатлыклы хәбәрне китергән егетләрнең идарәдән чыгуларын күреп, барысы да аларга таба борылды.

«Патшаның тәхеттән төшерелгәнен бу егетләр каян белгәннәр, кемнән ишеткәннәр? Патшаны кемнәр тәхеттән куып төшергән? Николай урынына башка патша булачакмы, яки тормыш бөтәнчә, патшасыз корылачакмы? Сугыш тукталырмы? Фронтларда арыслан кебек егетләребез, якаларына ябышкан әҗәлдән котылып, өйләренә кайтып килерләрме икән?» — Җыелган кешеләрнең менә шуларны беләсе килә иде. Ләкин егетләр үзләре дә бу сорауларга ачык кына җавап бирә алмыйлар иде әле. Шулай да бер сүз дә әйтмичә китүне вөҗданнары кабул итмәде. Мирсәет тә, Габделәхәт тә киракле сүзне Галимҗан әйтер дип көтәләр иде. Ул исә кесәсеннән әлеге телеграмманы чыгарып:


— Менә, бу хәбәр безгә Питербургтан килде,— диде.— Монда: «Николай патша тәхетеннән төшерелде. Власть халык кулына күчте»,— дип язылган. Әгәр патша тәхетеннән куылмаган булса, мондый телеграмманы телеграф, әлбәттә, кабул итмәс иде. Урядник Кузьмин, волостька мондый хәбәр килмәде дигән була. Бәлки шулайдыр, килмәгәндер. Ләкин бу хәбәр Уфага рәсми рәвештә килеп җиткән булырга тиеш һәм иртәгә, һичшиксез, бөтен газеталар бу вакыйганы тәфсилләп язып чыгарлар! Шуның өчен мин иртәгә үк Уфага китәргә булдым. Рәсми хәбәрләр басылган газеталарны почта аркылы җибәрермен, ә сез монда Кузьминны кулдан ычкындырмагыз. Уфадан рәсми хәбәр килгәнче, вакытлыча үз арагыздан ышанычлы берәр кешене волостька сайлап куйсагыз, яхшы булыр дип уйлыйм...

Шул араны, өстенә таушалып беткән шинель кигән һәм култык таякларына таянган бер солдат, халык төркемен ерып, алга чыгып басты. Солдатның гадәттән тыш дулкынланган йөзен күреп, Галимҗан аңа таба кулын сузды:

— Патша хакимияте тарафыннан иң җәберләнгән кеше арагызда менә бу солдат түгелме? Әгәр вакытлыча шушы кешене волостька сайлап куйсагыз, ялгышмассыз! Инде безгә Солтанморатка китәргә вакыт. Сау булыгыз, агайлар! — дип, Галимҗан чанасына барып утырды.

Икенче көнне таң аткан чакта, ул инде юлда иде.

*Бу санда тәкъдим ителә торган яңа шигырьләрен Татарстанның халык шагыйре Сибгат ага Хәким тиздән булачак 75 еллыгына дип үзе сайлап китергән иде... Аксакал шагыйрь көтмәгәндә арабыздан китте. Ә иҗаты, шул исәптән күп санлы укучыларына ирешәчәк соңгы шигырьләре — туган ягы, авылы кешеләре турында уйланулар циклы да инде үлемсезлеккә юл ала...*



# Сибгат Хәким

## Арча халкын беләм...

Эшең төшеп, әйтик, элегрәк
Барып чыксаң шунда Арчага,
«Ничек»кә бер салкын җавап иде:
Ничек булсын, һаман бер чама.
Арча хәзер «бер чама»дан чыкты,
Артта калды инде «бер чама».
Хәрәкәте, рухы, ритмы белән
Бөек эшләр өчен бу заман.
Арча халкын беләм, күптән беләм,
Арчага ят эштә «урталык».
Тукай үрнәгендә бөеклеккә
Карап бара кебек бу халык.

*6 сентябрь, 1985.*

## «Айгыр уты»

Сары айгыр үз иркендә тоеп,
Шатлыгыннан гүя пошкырды.
Тик урнында хуҗа басып калды,
Кабатлады: каһәр, ычкынды...
Янгын — авыл абзарыннан кинәт
Атылып чыккан сары айгыр күк.
Ә шәүләсе — бала чак йөзендә
Ятып калган сары кайгы күк.
Ялы сары, тояклары сары,
Сикерә урам, инеш-су аша,
Тирә-якка көлтә-ялкын чәчә,
Күкрәгән бер киереп суласа.
Тотар идең, башта йөгәне юк,
Тояклардан оча очкыны.
Әнкәй, каушап, кирәклесен түгел,
Сөйри иде иске-москыны.
Җәй җиттеме, дер калтырап яши,
Курка халык «Айгыр уты»ннан.
Авылдан тик бары бер йорт кала —
Читтә, боегып, аерым утырган.
Миңа кайчак, була калса, сугыш
Сикерер шул «Айгыр уты» күк,
Континенттан континентка сикерер,
Каплар сагыш айны төтен күк.
Диңгезләр һәм океаннар аша
Чыгар сикереп, дөнья аһ-зардан
Кибәр, көяр... Башланды бит үзе
Бер кечкенә генә абзардан.
Бу дәүләтләр сары айгыр япкан
Абзарлар күк, кайсы лапастан
Чыгар хәвеф? Утның уйнавыннан
Рәхәт таба кайсы саташкан?

«Айгыр уты» купса, каушавыннан
Йөри иде әнкәй мүкәләп.
Балалары үскән йорт-нигезе
Аның өчен үзе бер дәүләт.

*1985.*

## Көзге ачы җилләрдә

Көз. Әллә нинди авыр көз,
Күп йөзләрне саргайткан.
Гражданнар сугышыннан
Исән кайткан солдатлар
Капка төбенә җыелды,
Түбәсе ышыгына.
Шундый көз, ятадыр укып
Өзлексез кеше дуга.
Кулларны иңнәргә куеп,
Әйләнеп бер бөтенгә,
Бернинди гармунсыз-нисез,
Тирбәлеп бер ритмга,
Фронттагыча бертөсле
Яңгыр шыбырдавына,
Тыкырыкта ялгыз агачның
Җилдә шыгырдавына

Җырлады алар кушылып,
Пычракка бас, суга бас.
Төн буе тирбәлде алар,
Тирбәлгән күк шул агач.
Оедым, онтылдым, тагын
Күзне ачып җибәрдем,
Моңына, сызгыруына
«Күзге ачы җилләр»нең
Беркем дә йокламый кебек,
Юеш, яшьле ястыклар,
Үксе тыкрыкта бар толлар,
Тәсбих тарткан карчыклар.
Иртән җил, яңгыр туктаган
Тын, шуңа шомлана баш,
Ята карт кулларын җәеп,
Кайгыдан сынган агач.

*3 февраль, 1985.*

## Миңа җыр бүләк иттеләр

Мин егетләр арасында
Үстем сугылып-йөреп,
Безнең кызларның кашлары
Чишмә-су юлы кебек.
Зурларга яулык бәләкте,
Чигүле — тирәклесе.
Миңа җыр бүләк иттеләр —
Күңелләр тибрәткече.
Авылымда үсеп дан тоткан
Чибәр Хәләлгөлләрнең
Моңнарын таң җилләренә
Кушып илгә җибәрдем.
Кызлар су китерде кичен,
Ташыдылар кисмәкләр,
Егетләр чишмә янынна
Төнгә чаклы китмәсләр.
Кызлар су китерде кичен,
Үзләренә иң әлек.
Туган йорт, туган нигезгә
Алдан йөри игелек.
Кызлар су китерде кичен,
Мөмкин булса кашыкка
Салып китерерләр иде
Тыкрыкта һәр карчыкка.
Тыкрыкта һәр йортта карчык,
Рәхмәте чишмәләргә.
Кызларның рәхмәте бигрәк
Күбрәк буш мичкәләргә.
Егетләр көтте... Чакырды.
Су буенда калган моң.
Суларын бушатты кызлар
Төпләренә талларның.
Кеше күрмәгәндә генә
Хәтта баганаларга
Күпме су койдылар алар,
Рәхмәт багалмаларга.
Шуңа яшел безнең урам,
Килеп кичкәннәренең
Хисе калган, моңы калган
Киме чишмәләренең.
Зурларга яулык бәләкте,
Чигүле — тирәклесе.
Миңа җыр бүләк иттеләр —
Күңелләр тибрәткече.

*1985.*

●

Калинин сазлыкларыннан
Чыга хәзер үткәннәр,
Гармун мехлары шикелле
Хәзер минем үпкәләр.
Суласам, сулышым җитми,
Дәваларга ысул тап:
Пәке тыккан мехлар кебек
Ябылалар пышылдап.

*14 август, 1985. (Аккош күле.)*

## Плакат

Башында чоры күк горур
Папаха, ал тасмалы.
Өстендә шинель һәм мылтык,
Аягы... Чабаталы.
Шул плакат авылда ике.
Барлыгы ике данә,
Түрдә кадерле урында
Саклана идарәдә.
Эләләр берсен плакатның
Базар көн «Пожарный»га.
Миңа шул солдат булмаса
Авылда базар нигә?
Ә берсен эләләр илтеп
Читтәге тегермәнгә.
Җыела халык, улларын
Күрергә тилмергәнгә.
Мылтыгы корулы, уяу,
Билгеле шәп атасы.
Үзе мыексыз, мыеклар
Җибәргән чабатасы...
Өй. Базар... Ике арада
Чабам чабалган чаклы.
Үсте базарда туктаусыз
Чабатаның да хакы.
Базарда сатылмый калган
Соңгы пар чабатамны
Сузам солдатка, сакласын
Илне-җирне — ватанны.
Төн житте, кермәде йокы,
Бар көчемне җыйсам да;
Шул солдат басып тора күк
Бер ялгызы җиһанда.

*1985.*

## «Сарык аяк»

Туган як кирәк шагыйрьгә,
Гомергә сагынырга як.
Син дә бар, бәхетеңне сына,
Марида «Сарык аяк» —
Борынгы йоласыдыр ул
Күги һәм Тарлюкларның.
Мәхәббәт тоттыра кайчак
Аягын сарыкларның.
Бу бер уен гына бары.
Шулай да, дус, алданма.
Сарыкларның яшен, картын
Бер караңгы абзарга
Өерделәр, шунда бергә
Ябылды карт тәкәләр.
Тарлюкларның толымында
Чылтырады тәңкәләр.

Жыелды мари кызлары,
Йөзләр — кояш, йөзләр — ай.
Жыелды өлкән агайлар,
Ә марича изайлар.
Бу бер уен гына бары.
Ике күзем Тарлюкның
Күзендә. Бу «Сарык аяк»
Үзе кебек тәмугның.
Ике генә чакрым, Тарлюк,
Йортыма сиңа моннан.
Их, сөйрәп чыгарсаң иде
Яшьрәген сыйрагыннан.
Әйтергә жиңел, базарда
Йөрү түгел мал карап.
Яшьлеген каян беләсең
Аякларын кармалап.
Тарлюкка күзем төшкәнне
Сизделәрме, татарга
Бездән дә бер «Сарык аяк»
Эләксен дип, абзарга
Мине дә төрттеләр шунда.
Әллә очы тәртәнең?
Юк, бу кәкре мөгезләре
Иде иң карт тәкәнең.
Шундый ачу белән сөздә:
Сиңа бүләк Тарлюктан.
Кайчан да бер очрашуны
Көтә идем мин күптән.
Әйтерсең, алдымда басып
Тора күк салмыш мари,
Күзеннән Тарлюкка булган
Ниндидер сагыш карый.
Теге тәкәнеке кебек
Маңгаенда бөдрәсе.
Тәмугка керүең артык
Кабат монда кергәнче...
Туган як кирәк шагыйрьгә,
Кирәк бер сагынырга як.
Эзләргә булдым үземнең
Авылдан «Сарык аяк».

*27 январь, 1985.*

## Башак чыңы

Арыш өлгергән көннәрдә
Түзмим, житми чыдамым,
Чыгам кырга, тыңлыйм арыш
Башагының чыңлавын.
Кыр тып-тын, бер жан иясе
Авазы, нидасы юк.
Арыш та кояш, зәңгәр күк,
Тик изге илаһилык.
Кемнәрдер чәчкән дә жирдән
Киткән гүя, кешесен
Күрмим, ничәмә буынны
Искә төшерә шушы чың.
Һәр башак — бер гомер,бер чың.
Чыңы белән башакның,
Чыңы адашкан гармунның —
Йөрәгемә газап, моң.
Яшьлек, синең дә бу жирдә
Бар иде бит бар чагың.
Елыйсы килә шул кырда
Кочып арыш башагын.

*Август, 1985.*

## Кояш Тимбикова

# ТЫН БАКЧАДА

ПОВЕСТЬ

*Ленин орденлы Галина Павловна Васильевага багышлыйм.*



Әйдә туйга әзерләнәләр. Алиянең бердәнбер кызы Рушания күрше авыл егете Булатка кияүгә чыга. Күңеленнән риза булса да, сәгате сукты дигәч кенә, Алиягә сәеррәк тоела башлады. Кызының сүзләренә каршы төшеп тә матаашты әле ул:

— Кем инде гомердә бер була торган туйны кыш көне, чатнама суыкта ясый? Кайдан уйлап чыгардыгыз аны, ә?

Кызы актан-карадан берни дә әйтмәгәч, ана диванынннан кузгалып телевизорны сүндерде дә кызына елышыбрак утырды.

— Сабыр итик бераз, кызым! Ике-өч ай вакыт хәзер үтә ул. Яз житсен. Алмагачлар чәчәк аткан вакытка чамалап әзерләник! Борынгыларча, зурлап ясарбыз. Бер көнен алма бакчасында уздырырбыз. Теге, бер рәтендә — ал, икенчесендә ак чәчәкле алмагачлар үсә торган аланда табын корырбыз, кунаклар су буена да төшәрләр. Чишмә буенда учак ягарбыз, казан асарбыз...

Әнисенең тәкъдиме ифрат кызыктыргыч иде. Рушания чәчәкләр патшалыгындагы табын тирәли тезелешеп утырган дус-ишләрен, туган-тумачаларын күз алдына китерде. Яшьләрне котлыйлар — кунакларның иң өстенә чәчәкләр ява! Әкияттәге кебек. Тик Булат белән Рушаниянең туе алай үтмәячәк шул.

— Юк, әни. Хыялланып башыңны авырттырма. Туебыз кыш үзгендә, 31 декабрьдә булачак. Яңа елны каршылаганда безгә кодаларың килә, өлкәннәр мәжлесе шул көнне үтә.

— Ничек син барын да шулай бер үзең хәл итеп куйдың соң әле?

— Үзем генә түгел, Булат белән.— Кызның зур зәңгәр күзләре әнисенең кинәттән моңсуланып калган йөзенә текәлде. Ул капылт кына: — Менә укы инде алайса,— диде. Күлмәк кесәсеннән алып, бер кәгазь кисәге сузды.— Синең сүзгә каршы килмәс идем дә бит...

Ашкынуын, кызының серләре дөньясына керергә омтылышын никадәр генә сиздермәскә тырышса да, бу хәленнән үзе үк уңайсызланса да, Алия сабырсызланып хатка үрелде. Куллары сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп китте.

---

*КОЯШ ТИМБИКОВА — прозаик. ТАССРның атказанган культура работнигы, республика журналистларының Х̂. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты. «Тәңкәле тау», «Ярлар биек», «Кышкы талпыну» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шакмаклы дәфтәрнең куш битенә вак кына хәрефләр белән язылган хатка Булатның кайнар хисләре түгелгән... Әни кеше берничә юлга күз генә йөгертеп алды, аннары, кызарып:

— И-и, кызым,— диде.— Булатның ихласлыгыннан шикләнмим. Икегезне тиң яратам. Мә, кирәкми. Туй көнен әче кышка билгеләвегезгә генә аптырабрак калган идем.

— Син хатның азагын укы, туйга кагылышлы сүзләрне!

Кызы болай ачылып киткәч, Алия бөтенесенә риза инде. Егетенең хатын укытырга тәвәккәлләгән икән, димәк, бары да әйбәт. Анадан нидер яшерергә уйламый. Ул хатның кызы күрсәткән өлешен тоташтан укып чыкты.

«... Риза бул әле, Рушаниям! Ясыйк әле туебызны ап-ак карлы, котырган буранлы көндә! Җылы җәйләр, шау чәчәкле язлар гына матур, дип уйлаучылар шаккатсыннар. Кышкы сафлык, кар бөртекләрендәге аклык алардан киммени?

Артлы яшел чаналарга пар атлар җиктерербез, дугаларга җиз кыңгыраулар тагарбыз, сөлгеләр, шәлъяулыклар бәйләрбез. Атларыбыз кар шәлләрен бөркәнгән, теге без ярата торган назлы наратлар тезелгән урле юлдан да уратырлар. Авыл хәйран калыр: «Кара сана, диярләр, туйны кышын да күңелле ясап була икән!»

Без өйләнешкән төндә Җиргә яңа ел килер, без тормышыбызның яңа юлына аяк басарбыз»...

— Матур икән шул,— Алия хатка текәлгән килеш үзалдына сөйләнде.— Мә, кызым, матур икән.

— Әйттем бит! — Рушания әнисе сөйләгән алмагачлы табынны да истә тота иде әле.— Алмагачлы туйда болай ук булмастыр да әле!

— Бакчага тел тидермик, балам!..

Туйга ай ярымлап калганда, Булатның әти-әнисе белән алар нәселеннән тагын берничә кеше килде. Кыз сорарга, туй уздыру тәртибе турында килешергә. Монысы — гадәткә тугрылык кына инде. Һәр ике як моңарчы ук балаларының яратышып йөрүен белеп яшәде, үзләренчә әзерләнә дә тордылар.

Күрше авылныкылар булса да, Булатның бөтен нәсел-нәсәбе Алиягә таныш, шулай ук егет ягы да Рушанияне яхшы белә. Шуна күрә килешү кичәсе тантана төсен алды. Туйга бәйле сүзләр, бүләкләрне кемнәргә бирү мәсьәләләре бик тиз түгәрәкләнде. Туйның вакыты турында да бәхәсләшеп тормадылар: «Үзләре шундый тамаша корырга уйлаганнар икән — әйдә, аларча булсын»,— диделәр.

Язларның назын, көзләрнең муллыгын көнләштерерлек кар-буранлы, ап-ак туй көтелә!

Авылда йорттан-йортка йөртелә торган, бер-берсенә егерме ике кеше сыешлы ике өстәл бар. Алия аларны бер атна алдан кайтартып куйды. Моңарчы бер дә тотылмаган сөттәй ак ашъяулыклар җәйделәр.

Алиянең туйга ерак шәһәрдән кайткан ике сеңелесе дә баш күтәрми булышып йөриләр. Чынында, гел алар эшли, Алия нәрсәнең кайдалыгын күрсәтеп кенә тора.

* * *

Ишек ачылып китте. Җылы өйне суык томан тутырды. Кем кергәнлеге дә беленми иде.

— Абау, салкынлыгы! Бармакларым әллә өшеде инде? — Туй күлмәгенең соңгы җөен җөйләп бетерергә күрше Әминәләргә кергән Рушания икән.— Сулуга каба. Бөтен тәнем куырылды.

— Әй, кызым! Кыш көне шул этәч тиресе кебек курткадан кем йөри инде? — Алия елмаеп кына ачуланган итте.— Шаярма! Салкын бер тисә, тиз генә ычкындырмый ул.

— Әминә апаларга гел күлмәкчән элдертә идем инде. Бүген — һавасы башка.

— Радиодан ничегрәк әйттеләр соң? — Сүзгә кунаклар кушылды. Ул да түгел, бары да тынып калды. Бәби итәкле, челтәрләр белән бизәлгән ап-ак күлмәк киеп, уртага чыгып баскан Рушаниягә текәлделәр. Кызның солы саламыдай аксыл-сары чәчләре дулкын-дулкын булып аркасына төшкән. Башына ак ефәк чәчәкләрдән ясалган такыя киеп куйгач, кыз очар кошка охшап калды. Чәч дулкыннары өстендә үтә күренмәле озын япма тирбәлә. Баласына яман күз тиюдән шикләнгәндәй, Алия:

— Килешле чыккан, кызым,— дип сүзне кыскартырга ашыкты.— Үзең теккәч, яхшы шул, бөтен ягын чамалыйсың аны.

— Бу юлы бер дә ике кат җөйләргә туры килмәде, әни.

— Изге эш шулай җайлы бара ул,— диештеләр кунаклар.

Хатын-кызларның сүзен бүлеп, ишек шакыдылар. Хәбәр китерүче:

— Телефоннан Булат әйтергә кушты, чыкканнар! — диде.

Булат — Алия председательлек иткән колхозның агрономы. Тиздән ул кыз янына килеп җитәчәк. Кыңгыраулы пар атларда. Иптәш егетләре мотоцикллар куачак икән. Монысы тамашаны куертыр өчен.

Өйнең тынычлыгы бетте. Ишегалдыңа, капка төбенә кешеләр җыела башлады. Күрше кызы Мәйсәрә капка бавы тотарга әзерләнгән, кияү булачак кешегә әйтәчәк такмагын кабатлый...

Кинәт тирә-якны: «Киләләр! Киләләр» — дигән тавышлар тутырды.

Авылны җиз кыңгырау авазы яңгыратты. Иң алдан җиз төймәләр белән бизәлгән дирбияле пар ат чаба. Ямь-яшел артлы чанага кияү белән аның гармунчы, җырчы дуслары төялгән. Арттан кычкырта-кычкырта өч «Жигули», дүрт мотоцикл килә.

— Абау, җаным! — дип «аһ» иттеләр.— Бу «Балыклы»ларны һич белеп бетерә торган түгел. Мондый көнне кем мотоциклга утыра инде?

— Рушания кебек кызны эләктерсәң, син әле кушаяклап та чабар идең.

— Анысы шулай, шулаен...

Яшел чанадан кыска кайры тун, чәшке бүрек кигән Булат сикереп төште, атылып капкага килде. Мәйсәрә «мең алтын» сорый иде:

... Капка бавы — бер алтын,<br>Безнең апа — мең алтын!

Булат артыгын көтеп тә тормады, кыз баланың кулына ислемай шешәсе тоттырды.

— Керт, зинһар, тизрәк! Егетләрнең колагы өшегәндер.

Башка ишекләр дә тиз ачылды, кортлы майны да ялт-йолт кына авыз иттеләр — шартын үтәмичә генә ярамый. Адәм чыдамаслык салкынлык Алиянекеләрне дә өйгә куып кертте. Бүрек колакчыннарын, затсызлыктан саналмасын өчен генә күтәреп бәйләгән мотоциклчы егетләрнең кайберләре, чыннан да колагын өшеткән. Алар хушбуй сорап алдылар да, кече якка кереп, битләрен ышкырга тотындылар.

Кунаклар табын тирәли урнашкач Алия:

— Пилмәнне дә әзерликме инде? — дип, төп кодагые белән киңәшеп алды.— Шулпам әзер. Пилмәнем өйалдында. Салсам, хәзер күпереп чыгар.

Кодагые кырт кисте:

— Юк, юк! Хәзергә яшьләр чәй генә эчеп алырлар. Язылышып кайтсыннар, аннары иркенләп утырырлар! — Шулай да ул шиген белдерде.— Чоландагы пилмәннәреңне кертеп куй! — диде.— Тышта бик салкын. Пыяла кебек булып беткәннәрдер. Шулпаңны боз итәрләр.

Ир-атларның сүзе дә көннең салкын торуына барып тоташты.

— Кышның суыгы хәерле,— ди бирсә.— Җебеп, быксып утырудан яманы юк.

— Сүзең хак.— Җепшек кышның җәе дә начар.
— Дөрес. Әле соңгы елларда рәтле кышның булганы юк.
— Бусы Булат өйләнгәнгәдер инде...

Көлүчесе көлде, житди сүзне сузарга теләгәне аерылып сөйләшә башлады. Өйдәге вакыйгалар үз көенә дәвам итте. Бер-беренә никах балдаклары кидертешкәч, Рушаниягә бирергә дип, Булат Казаннан канәфер чәчәкләре кайтарткан иде. Мамык шәлгә төреп, аларны да авыл Советына алып бардылар. Аннары кып-кызыл чәчәкләрне табын түренә утырттылар.

Бары да алар теләгәнчә барды. Кичке мәҗлескә дә нәкъ вакытында җыелдылар. Туйны мәктәп директоры Рәхимә Вәлиева ачып җибәрде. Үзләренең Аклан мәктәбендә укып, югары белемле кешеләр булып өлгергән Булат белән Рушаниягә бәхетләр теләде.

Мәҗлеснең иң кызган чагында Алия кече якта телефон шалтыравын ишетеп алды.

— Әйе,— дип, трубкага эндәште.

— Председатель! — Колхозның зоотехнигын тавышыннан танып алды Алия.— Каюмовна кирәк! Алия апа!

— Ни булды?

— Котельныйның бер казаны киреләнде, ферманы җылыта торганы. Инженер юк...

— Беләм. Бездә, туйда утыра ул. Хәзер!

— Радио илле градустан да артык суык көтелә, диде.

Алия туй турында уйламый да иде инде. Инженер Гариф — түр башында. Уң як стена буенда слесарь утыра. Ничек кузгатырга аларны?

Яңа ел алдыннан Алия, һәр бәйрәм вакытындагыча, колхозның иң җаваплы урыннарына житәкчелек вәкилләреннән күзәтүчеләр билгеләде. Су бирү, җылыту үзәге, электр челтәре, радио-телефон элемтәләре — барысы да бүленгән иде. Үзе ул идарәнең өч катлы бинасына күз-колак булырга тиеш.

Ишеккә якын гына утырган гармунчы баянын сыздырып җибәрде. Алия зур бәладән котылды. Хәзер кунаклар җыр агышына буйсыначаклар. Бераз күздән югалып торсаң да, үзең белән берничәсен алып китсәң дә сизелмәячәк.

* * *

Идарә каршындагы биек багана башында зур лампочка көн яктысы чәчеп утыра. Алия идарә йортының бөтенлеген барлауны шуннан ук башлады. «Ут яна, яктылык бар»,— дип уйлап, тынычланып куйды. Гадәттәгечә, ишек ачык иде. Председатель бусагадан атлауга, уң яктагы кечкенә бүлмәдән дежур хатын чыкты.

— Бу кадәр дә тынгысыз булырсың икән! — дип, Алияне ачуланырга тотынды.— Инде бердәнбер балаңның туе көнендә дә йөрмәсәң...— Ул кинәттән туктап калды.— Бит алмаң ап-ак, Алия жаным, өшеткәнсең!

Алия тәрәзә пыяласына барып капланды. Салкынны салкынның үзе белән генә кайтарып буласын ишеткәне бар аның. Тәрәзәләр эчке яктан бозланып каткан — гомер күренгән хәл түгел.

Алия тынычлана төшкәч, дежур хатын сабыр гына:

— Әллә ничә мәртәбә шалтыратты берәү,— дип сөйләргә тотынды.— Сине сорый, авыл хәлен сорый. «Тәртипме?» — ди. Мин әйтәм, аптыратмагыз, дим. Барысы да тәртиптә. Председатель — туйда, аңа комачаулый күрмәгез!

Алия, «Тәртипме?» дигән сүзеннән, шалтыратучының кемлеген аңлап алды: Казаннан колхозга шефлык итүче завод директоры Исмәгыйль Ишмиевич булырга тиеш.

Алар сүзне очлап та бетермәде, телефон шалтырады. Трубканы Алия алды. Элемтәнең аргы очындагы кеше, исәнлек-саулык та белешмәстән:

— Ну, ничек анда сезнең, тәртипме? — дип сорады. Алиягә рәхәт булып китте. Күңеленең бер почмагына шом савыла башлаган иде дә, бөтен борчуларын онытып, көлеп җибәрде ул.

— Ни диярга дә белмим әле, Исмәгыйль Ишмиевич. Исәнмесез? Алия бу.

— Нәрсә булды? — Трубкадагы тавыш җитди иде.— Ничек туенда түгел? Күңелем сизенгән иде аны. Әйт, нинди ярдәм җибәрим?

— Хәзергә берни дә кирәкми, ул-бу юк дисәм дә ярый. Котельныйның бер казаны кирели иде дә, инженер белән слесарь шунда китте.

— Газ ничек?

— Аңа ни булсын?

— Кысылуы ихтимал. Котельныең да шуңа киреләнгәндер әле. Сезнең күрше совхоздагы дуңгызчылык комплексында — авария. Электр чыбыклары өзелгән, су торбалары шартлаган. Яшь хайваннар бозлы су эчендә калган.

— Сәбәбе?

— Тышта илле алты градус суыклык икәнен беләсеңме соң син?

— Термометрга карарга кыймаган идем шул.— Алиянең бугазына төер килеп тыгылды.— Уйларга да куркам.

— Бетерешергә ярамый. Мин заводта булам. Кирәксәм, хәбәр ит. Монда да эшләр шәптән түгел, бөтенебез — аяк өсте, кайсы яктан китереп сугасын белеп булмый. Каушама, ярдәм итәрбез. Теге дуңгыз комплексына да ике машина кайнар су җибәрдек, электриклар китте. Ара ерак түгел бит.

— Минекеләргә кайнар су гына ярдәм итмәс шул.— Алия елап җибәрмәс өчен сүзен кыскартты: — Булмый алай.

— Ни сөйлисең? Синдә бит дуңгыз балалары юк.

— Миндә — алмагачлар. Мең гектар, гектарына — сигез йөзәр төп.— Алиянең тавышыннан саркылган шом Ишмиевкә дә күчте.

— Бәрәкәт! Мин бит әле аларны бөтенләй истән чыгарганмын. Алар ничә градуска чыдый соң?

— Бер кышны кырыкка түзгәннәре өчен тезләнеп рәхмәт укыган идем. Иллене үк күтәрә алмаслар шул...

Идарәдән чыккач аңа туп-туры алга китәргә кирәк иде. Ул исә, белепме-белмичәме, уңга каерылды. Гадәттә, Акланны олы юл ягыннан өзлексез узып торучы машиналар тавышы, төннәрен алар фарасыннан бөркелгән ут яктысы җанландырып тора иде. Гасыр эчендә дә сирәк кабатланучан суык юлдагы һәртөрле хәрәкәтне туктаткан. Өн дә юк. Төннең аязлыгы да сәер. Күктәге йолдызлар шомлы томанга төренгән, ай да боек. Ул гүя: «Кичерегез, кешеләр! Мин сезгә берничек тә ярдәм итә алмыйм, үзем дә туңам»,— дип, көчсезлегеннән җәфалана сыман.

Җир кешеләренең төнге тормышларын бизәүче күк җисемнәре шәфкатьсез элпә артында калган. Арага шыксыз зәмһәрир кергән дә, дөньяны тораташ итеп катырырга тырыша шикелле. Җил-фәлән дә юк. Этләр өргәне дә, абзар-куралар ягыннан малларның күшәгәне яки пошкыргалап куюы да ишетелми. Авыл өстенә салкын кабер тынлыгы ябырылган.

Ниһаять, Алия дә тирә-юньне бөтереп алган шомлы афәткә игътибар итте. «Шыгырдарлык кары да юк бит аның,— дип офтанды.— Кар мулрак явып өлгергән булса, бу кадәр гайрәтләнә алмас та иде».

Тыкрыктан аз гына борылуга алмагачлар дөньясының олы капкасына төртеләсең. Озын тигез рәтне башлап җибәргән беренче алмагачны күргә председательне курку алды. Ник монда килеп чыгуына аптырады. Аяусыз суыклык патшалыгында япа-ялгызы ни генә эшли ала соң ул? Тизрәк кире борылырга кирәк! Шулай да ул тагын алга атлады. Гаскәр башлыгыдай мәгърур утыручы беренче алмагачка якынайды. Ярым караңгы тирәлектә аның хәл-әхвәлен ачыкларга мөмкинлек юк, әлбәттә. Алиянең исә бу чарасызлык белән килешәсе килми. Барын да хәзер үк

аңларга тырышудан аңа агач кәүсәсе кумерләнеп көеп чыккандай тоелды. Ботакларга кагылырга кыймады ул. Тагын аз гына текәлеп торсаң, агач бөтенләй уалып төшәр кебек тоела. Алия башын аска иде, җилкәләрен җыерып, учлары белән колакларын томалады, чөнки аңа бакча кинәт ыңгыраша башлар шикелле иде.

Председатель кирегә борылды, ашыга-кабалана өенә чапты. Аны капка төбендә үк көтеп торалар икән.

— Әни, нишләвең инде бу? — Мамык шәлгә, олы тунга төренгән, киез итекләр кигән Рушаниянең тавышына үпкәләү төсмерләре чыккан.— Туйны ташлап йөрмәсәң, идарәңә ни була дип уйлыйсың?

Кызның сүзен Булат куәтләп алып китте:

— Чыннан да, Алия Каюмовна, әй лә, әни...— Булат үзенең кияү кеше икәнлегенә ияләнеп җитмәгән иде әле.— Мин дежур белән килешеп куйдым бит. Андый-мондый күңелсезлек чыкса да, безнең мәҗлескә кагылмаска тиешләр иде. Ярар, әйдә, әйдә, керик!

— Күңелсезлек кенәме соң бу? — Алия кайгысын яшерә алмады.— Алмагачларыбыз харап була. Бакча җан бирә...

Алар өйалдына кергәннәр иде инде. Ихтыярсыздан әйтеп ташлаган сүзләренең кызы белән кияве кара кайгыга салуыннан коты очты Алиянең. Алдан ук аларны тынычландырырдай сүзләр эзләде. Тик, ни хикмәт, яшьләр өзелеп төшәргә ашыкмадылар. Рушания:

— И, әни! — дип куйды. Янәсе, нинди әни соң син? Туй көнне дә бакча турында уйлыйсың?

Булат ачыктан-ачык ярып салды:

— Син ул алмагачларыңны онытып тор, әни! Менә ул синең иң кадерле алмагачың! — Кияү Рушанияне үзенә кысты.— Миңа нинди шәп багалма үстергәнсең! Монысын мин бернинди суык бабайга да бирмим! Ә бакча? Нәрсә инде ул кадәр борчылырга?! Сиңа бирәсен биргән инде ул: дәрәҗә, орден, исем, байлык! Бер-ике елдан пенсиянең иң зурысын каерып алачаксың. Шуңарчы җил-яңгыр тидертмәскә мин дә бар әле. Казанда минем бер якын дус эшли, безнең системада — Мәмишев. Бакчаны басуга әйләндерә дә бирә! Әллә нинди әмәлләр белә ул!

Алиянең бу сүзләргә гаҗәпләнерлек көче юк иде инде. Бары тик аптырады гына ул: яңа гына кияү булып өлгергән бу кешенең әлеге сүзләреннән йөрәк ничек шартламый түзә? Җир нигә убылмый? Күк ничек аларның өстенә ябырылмый?..

* * *

... Больницада көндезге йокы вакыты иде. Бригадир Хәмдүнәнең, җәяүләп, район үзәгенә барулары, билеты булмаганга, автобуска көчкә эләгүе, таңнан бирле авызына бер валчык ризык, бер йотым чәй капмаган килеш монда килеп егылуы берәүне дә шаккатырмады. Ишек төбендәге ак халатлы өч хатын өчесе берьюлы сөйләшепме сөйләшәләр. Уртадагысы урындыкка утырган, икесе ике якка баскан. Утырганының итәгендә бер кочак әйберләр: үтә күренмәле капчыкта бала башы кадәр йомгак, кулларында бер җиңе бәйләнеп бетмәгән кофта. Хәмдүнә аның энәләренә хәйран калып карады. Үзләре кыска гына, очларына кавырсын бау кертеп, зур әйберләр бәйләү өчен җайлаганнар. Башка чакта Хәмдүнә бу хатынның ни бәйләвен, ничә күздән башлавын, нинди үрнәк сайлавын, тагын әллә ниләрен сораштырып бетерер иде. Бу юлы аны берсе дә кызыктырмады, күз генә салып алды да:

— Миңа нервныйлар бүлеге кирәк, кай якка үтәргә? — дип сорады.

— Йокы сәгате.— Бәйләүче хатын аңа күтәрелеп тә карамады. Бармаклары автоматик рәвештә җеп үрә, үзе ләчтит сата.— Мин ул Разумовскийны аңламыйм,— ди.— Шул картны өеннән чакыртып китереп, яңадан дәвалый башлады. Имеш, яңа төрле дару кайтарткан. Ә карт минем җелеккә төшә: ник тәрәзә төбенә тузан кунган, имеш, ник минем идән чүпрәге коры, нигә җылы су юк?..

Аның сүзен тегеләре күтәреп алып китте: врачларны, яңа салынган авыруларны теттеләр генә! Хәмдүнә башта сүзләренең очы чыкмасмы дип, көтеп карады, аннары боларга мәҗбүр булды:

— Көпә-көндез нинди йокы инде ул сездә?

Ак халатлылар, әле син китмәденмени, дигәндәй, өчесе берьюлы аңа карадылар. Сүзне тагын урындыктагысы башлады:

— Анысын синнән сорамыйлар инде. Икедән дүрткә кадәр йокы вакыты.

— Бар, бар, үз юлыңны кара, идән таптаучылар синнән башка да җитеп ашкан.

— Һич аңлатып булмый бу халыкка! — дип өченчесе, Хәмдүнәгә карамыйча гына, хезмәтләренең авырлыгын тасвирлый башлады: — Бер әйтәсең, тыңламый, ике әйтәсең — китми...

— Шул кадәрле авыр эштә нишләп өчәүләшеп сөйләшеп утырасыз соң әле сез? — Хәмдүнәнең артыгына түзәр тәкате калмаган иде инде.— Ишек төбенә килгән кешене кире бору өчен берәү җитмәгәнме? Әнә авылга кайтып бер генә көн бакча казыйсыгыз бар иде, күрер идегез халыкның нинди икәнен! — Ул, сүз уңаеннан, өстендәге калын плащын сыдырып төшерде. Чәчәкле-чуклы шәльяулыгын суырып алды. Куе яшел кофтасында ордены, медальләре, «Атказанган колхозчы» значогы, ВДНХның бронза медале ялтырап китте.— Кайда баш врачыгыз? Мин сезнең йокы сәгатьләрегезне белмим, әмма ләкин Алиянең көндез түгел, кара төндә дә керфек какмый ятуына иманым камил. Колхоз хәтле колхоз таралып бара анда, сез монда ләчтит сатып, бәйләм бәйләп утырасыз... Һе, «йокы вакыты», имеш! Тапканнар йоклар чак!

Өч хатынның икәве юк булды, өченчесе аягүрә басты.

— Баш врачны кирәксенсәң, бигрәк әйбәт, ишетмәгәнеңне ишеттерер, бар, кер, әнә уң кул якта, икенче ишек, Варлам Никитич Разумовский. Неврологическида да булгач, кертми дә кертми инде, андыйларны төймә каптырып, укол кадап йоклаталар.

— Җаны миңгә өзгәләнгән кешене барыбер йоклата алмыйсыз.— Хәмдүнә өстен-башын төзәткәләде.— Хәер, башкаларын белмим, безнең Алия Каюмовнаны бер даруыгыз да йомшарта торган түгел — шуны гына әйтәм.

Ул шул ук сүзләрне баш врач янына кергәч тә кабатлады:

— Ник икәнен беләсездер инде. Сөйләгәндер. Безнең колхоз юырттырып барган юрганың сөрлегеп егылуы кебек булды бит.

Үзе сөйләмәсә дә, докторлар Алия Каюмовнаның больницага ник эләгүен беләләр иде белүен. Авыру председательнең үзеннән бу хакта сорашмадылар. Ачылып китеп, үзенең сөйли башлавын көттеләр. Ул исә бакча хәлләрен телгә дә алмады, үзенең бәласеннән генә зарланды:

— Йоклый алмыйм, ашыйсым килми, башым буп-буш...

Янына берәүне дә кертергә теләмәде. Кызы Рушания белән Булат кияве килгән иде, сәгатьтән артык утырганнардыр — сөйләштерә алмадылар. Алар киткәч, Алия, мендәргә капланып елады.

Хәмдүнәнең турыдан-туры баш врачка эләгүе ике як өчен дә яхшы булды. Бу хатынның егерме ел буена Алия колхозында бригадир булып эшләвен, аның иң якын сердәше икәнен белгәч, Разумовский кабинетка дәвалаучы врачны да чакыртты. Кирәкле бөтен мәгълүматны алдылар.

Ахырдан Хәмдүнәнең үтенечен кире кагарга да яхшысынмадылар. «Тыныч кына үтеп карагыз,— диделәр.— Аның палатасы икенче катта, ишеге ачык, чөнки бик эссе. Йокламый торган булса, үзе чыгар, башкаларга комачауламагыз!»

Алия үзе дә, йоклап киткән бүлмәдәшенә комачауламас өчен, коридорга чыккан иде. Коридорның икенче башыннан «тарс-тарс» атлап килүче хатынның Хәмдүнә икәнлеген танырга, ул читлеккә эләккән коштай, ары каранып, бире талпынып алды. Сөйләшергә аның һичнинди теләге юк. Хәмдүнә белән очрашкач, сөйләшми котылу мөмкин түгел. Сүзнең

дә иң куркынычы, алмагачлар турындагысы башланачак. Нишләргә, кая качарга? Берәр палатага кереп поссан?.. Мөмкин түгел, бу Хәмдүнә бульдозер кебек, бөтен бүлмәләренне тигезләп чыгып китәр, эзләгәнен тапмый калмас.

Алия, чарасызлыгын аңлап, карашларын зур тәрәзәгә борды да, коридор уртасында туктап калды. Ни гаҗәп: Хәмдүнәнең дә юлында очраган һәр нәрсәне таптап узардай күренгән адымнары салмакланды, хәрәкәте көчсезләнде.

Алия каршына килеп баскач, ул бөтенләй каушады. Авыру дусты үзе сүз башларга мәҗбүр булды:

— Ник килдең инде? — Икесе дә бик озак эндәшми тордылар. Аларга бу ара ел кебек тоелды.— Мин бит бу сәгатьләрдә берәүне дә кабул итмим.

Ярый әле гомерендә дә теленә алмаган шул сүзне ычкындырды председатель. Югыйсә, Алияне таңресе урынына күреп йөргән Хәмдүнә ничек кыюланып китәр иде.

— Алаймыни? — диде ул башта. Монысы фикерен җыеп бетерү, бер тын алу гына иде. Аннары тезеп китте.— Әле кайчаннан бирле кешеләрне аерым сәгатьләрдә генә кабул итә башладың? Больницага кердем дигәч тә...

Алиянең башында зиһенен томалап торган ниндидер сөрем ачылып киткәндәй булды. Аңа әллә кайчан шул рәвешле усал иттереп, авылча сөйләшүче кирәк икән бит!

— Ни, э-э, әле монда берәүне дә кертмиләр, йокы сәгате.

— Ник йокламыйсың соң? Нигә кипәп сарып йөрисең, башкаларны борчып?

Алия, кинәт кенә кузгалып килеп, Хәмдүнәнең күкрәгенә капланды.

— Ачуланма, ичмасам! — Аның яшь аша әйтелгән сүзләре Хәмдүнәне дә елата язды.— Болай да җанымны кая куярга белмим. Кызган! — Алиянең моңарчы берәүгә дә болай ачылганы юк иде. Танышлардан качуы да кызгануларын күрергә теләмәүдән ләбаса.— Мин дә адәм баласы бит...

— Ә-ә, алаймы? Кызгандырып читтә генә, шифаханәдә ятмакчы буласыңмы? Безне, авылыңны кем кызгана соң? Ташладың да киттең. Аягың исән, кулларың бар, башың-күзең үз урынында, сырхаулап ятасың. Больницага качып котылырлык булса, колхоз белән кереп ятар идек аны.

— Ниләр бар соң анда?— Бу Алиянең больницага эләккәннән бирле кешечә уйлап, борчылып әйткән беренче соравы иде...

* * *

Хәмдүнә белән бер класста, бер партада утырып җиде ел укыдылар алар. Сиғезенчегә дә бергә керделәр. Анысы күрше авылда иде. Икесе дә әтисез. Сугыштан кайтмадылар. Алиянең ике сеңелесе, Фоат исемле абыйсы бар. Беркөнне Хәмдүнә Алия аягында өр-яңа чабата күреп:

— И-и, Фоат абый ничек матур үргән! — дип сокланды.

Ул белә иде инде: Алиянең абыйсы күздән бирле, чабата үрергә өйрәнәм, дип, югары оч керәшен картына, «Кестәнтин» бабайларга йөри. Өйдәгеләр, ул кайтып керүгә сорарга тотыналар:

— Булдымы инде? Өйрәнеп бетердеңме? Үзең үргән чабатаң кайда?

— Алай җиңел генә була торган эш түгел ул.— Абыйлары башта шул сүзләр белән котыла килде.

Соңга таба, әниләре: «Булмас бу, улым, йөрмә вакыт уздырып»,— дип, егетнең өйдән чыгып китүенә каршы төшә башлагач, җавап үзгәрә төште:

— Бөтен җирен үрә беләм хәзер, башлап китүе белән табан әйләндерүен генә чамалап җиткерә алмыйм әле.

Кыш үтте, язгы сулар китте, чабатаның иң кирәк чагы. Алияң өр-яңа чабата киеп, мәктәп коридорында горур атлап йөри. Шыгыр-шыгыр.

— Бигрәк матур! — диде Хәмдүнә.— Озак әйрәнсә өйрәнде, пөхтә чыккан.

— Тәмле сүзләреңне әрәм итмә! — Алия көлеп җибәрде.— Фоат абый үрмәде. Ул кичә Кестәнтин абыйның кече кызы Маняны ябыштырып алып кайтты. Кыш буе шуңа йөргән икән. Чабатаны әтинең күн тышлы бүрегенә алыштырып алдык, ике пар бирделәр...

Кызларның сүзе өзелде. Сугыштан кайтмаган әтиләренең өйдә калган кием-салымнарын балаларга җайлаштыру, бер яктан, аларны мең бәладән коткарса да, икенчеләй уйлаганда, соңгы истәлеккә хыянәт иткән кебегрәк сизелә. Хәмдүнә белән Алиянең сүзе дә шуңа өзелде.

Үзенә атап алынган чабатаны исә Алия бик саклап киде. Үз авылларыннан чыгуга сала да яланаяклап элдертә. Урта мәктәпле авылга кергәч тә, мәктәп урамына борылгач кына, коелы бер йорт янына туктап, аякларын улакта юып, яңадан киенә.

Очны-очка ничек кенә ялгарга тырышсалар да, сигезенче классны тәмамлый алмады алар. Язгы имтиханнарны тапшырыр өчен, әлеге мәктәп балаларына тагын да ерактагырак авылдагы башка бер урта мәктәпкә барырга куштылар. Имтихан комиссиясен оештырырлык югары белемле укытучылар юк икән. Акланнан утыз чакрым, инде «мыеклана» башлаган чабата киеп анда ничек барып җитәргә? Хәер, хикмәт киемсалымда гына түгел. Һич уйламаганда Алия бик каты авырып урынга егылды. Авыл фельдшеры: «Салкын тигән,— диде.— Район үзәгеннән врач чакырыгыз. Мин генә әллә ни эшли алмыйм...»

Бу мәшәкать артыннан йөрерлек кеше юк. Фоат абыйлары Маняга өйләнгәч, кара-каршы йорт салырлык акча җыеп кайтам, дип, Донбасс ягына чыгып китте. Таңнан алып кара төнгәчә колхоз эшеннән кайтып кермәгән ана, врач артыннан, җәһәннәм чокырындагы район үзәгенә ничек бара алсын? Өйләрендә фельдшер барында: «Әһе, әһе, алай икән»,— дип, аның һәр сүзен җөпләп торса да, үзенә бөтенләй башка нәтиҗә чыгарды. Икенче көнне, хәтәр кайнар итеп мунча якты, кызын пешергәнче чапты, аннары мунчадан болайрак кызу мич башына, кайры түн өстенә менгезеп салды. Юкә чәчәкле, мәтрүшкәле чәй дә эчерткәч, кызның хәле рәтләнү ягына борыла төште. Тик имтиханнар чоры шактый авышкан, тугызынчыга күчүчеләр билгеләнеп беткән иде инде. Алия авырганга күрә, Хәмдүнә дә мәктәпкә йөрүдән туктады.

Авылда язгы кыр эшләре түгәрәкләнгәч, хатын-кыз өчен иркенрәк бер ара була. Сабан туе да юктан гына шул вакытта үткәрелмидер инде. Мәктәпне ташлаган Алия белән Хәмдүнәнең алдагы язмышын шушы чор хәл итте.

Сабан туе мәйданыннан кайтып баралары иде. Аларны тарантас җигелгән атлы куып җитте. Кызлар аның якындагы урман хуҗасы гаярь егет Вәсим икәнлеген әллә каян таныдылар. Бу якларда ул бердәнбер.

— Әйдәгез, кызлар, утырыгыз! — Өстенә солдат шинеленнән тегелгән пиджак сымаграк нәрсә кигән Вәсимнең авызы-күзе елмая иде.— Сезне утыртам, дип, иптәшләрне калдырып киттем, әйдәгез инде!

— Бигрәк зур эш кылгансың! — Алия уртәшергә теләгәндәй җавап кайтарды.— Моннан гына җәяү дә кайтып җитәбез без. Мәйданда чакта килеп күренәсең бар иде аны!

— Ягез инде, кыстатмагыз!

Кызлар, чыпчыклардай чыркылдаша-чыркылдаша, тарантаска меңделәр. Шуны гына көтеп торган Вәсим, дилбегәне кулына урап тотты да, атны бөтенләй кире якка борып, Алия белән Хәмдүнәне очыртып алып китте. Ат карурман ягына юыртты. Кызлар беләләр: анда урманчы егетнең зур өе бар. Ул күбесенчә шунда яши.

— Син безне кай җәһәннәмгә алып киттең? — Хәмдүнә барыбер сорамый түзмәде. Алиягә дә пышылдады.— Бу безгә урман пәриенең өен күрсәтә.

— Әйдә, барып күрик булмаса!

Йөзьяшәр наратлар, чытырманлыклар арасындагы зур йорт юан-юан бүрәнәләрдән салынган икән. Кызлар аңа карап авызларын ачып торган арада егет олы капканы ачып җибәрде. Юаш өреп йөнтәс эт чыкты. Кызлар аны-моны уйлаштыргалаганчы, егет атны Иделдәй киң ишегалдына кертте.

Монда бөтенләй башка дөнья иде. Өйгә кушып ук салынган абзарлар, утынлыклар-фәләннәр, биек коймa — барысы бергә йортка сәер бер кальга төсмере биргән. Җиләк-җимеш, яшелчә утыртылган җыйнак кына бакчада чыгырлы кое да бар. Өй эчендә тагын да сәеррәк. Авыл өендәге кебек тәрәзә пәрдәсе, кашага, түшәк-ястыклар белән күпертеп җыелган урын-җир — берсе дә юк. Түр башында — шоп-шома, сап-сары такта өстәл, аның ике ягында шундый ук шәп-шәрә такта сәкеләр. Бер киштәгә китаплар тезелгән. Өстәл каршындагы киң, кыска киштәдә — бер бөтен икмәк. Ишек төбендә тәбәнәк кенә мич кебек нәрсә бар. Плитәсендә чәйнек белән калай кружка тора.

— Аба-ау! — диде Хәмдүнә кәрә-керешли үк. — Кара нинди сәер өй!

— Әнекәйгенәм! Менә монда рәхәттер ичмасам! — Алия дә тыела алмады. — Бу Вәсим авылга ник сирәк кайта дисәм...

— Минем кебек ятим кешегә гөр килеп яшәгән авылны күрү кыен ул, кызлар. Мине кызганалардыр сыман. Минем бичара булып күренәсем килми. Урманда без барыбыз да тигез. Табигатькә мин кирәк, миңа — ул.

— Бу өйне ничек шулай серле итә алдың? Әкияттәге кебек.

— Себер тайгасында күреп кайткан идем. Армиядә чакта. Андагы аучылар илле-алтмыш чакрым саен шундый йорт ясыйлар. Мич ягарга, тамак ялгарга әйбер калдыралар. Теләсә кем, теләсә кайчан, шунда кереп тамак ялгап чыга ала. Ул үзе дә азактан килүчеләр турында кайгыртырга тиеш. — Ашарлык, җылынырлык әйберләр юнәтеп калдыра. Тайганың беренче законы бу.

Урманда булгангадыр — өй эче салкынча иде. Сабан туена җиңелчә генә киенеп чыккан кызлар бөрешеп утырмасыннар өчен, Вәсим ут үрләтте. Плитә өстендәге чәйнек кайнап чыкты. Егет урман нигъмәтләре салып, хуш исле чәй пешерде.

— Урман чәе менә шундый була ул! — ди-ди, Алия белән Хәмдүнәне кыстарга тотынды. — Әйдә, суынганчы, эчегез, аннары шифасы кими аның.

Рәхәт иде монда. Кызлар үзләренең кайда икәнлекләрен дә оныттылар кебек: авыл халкы, әниләре ни уйлар? — бу хакта да башларына китермәделәр. Хәзер алар өчен Вәсим уйларга тиеш иде кебек.

— Сез беләсезме, кызлар? — Егет сүзен бөтенләй икенче яктан башлады. — Мин бит урманда бик кечкенә кеше. Монда зур хуҗалык эшли. Кисәләр, утырталар, үләндер, гөмбәдер, орлыктыр җыялар. Үзенең инженерлары, техниклары, эшчеләре бар. — Егет тукталыбрак торды. — Бар, дию, бик дөрес тә түгелдер, булырга тиеш. Кеше җитми монда. Килегез сез безгә эшкә!

Кызлар бер-берсенә карашып алдылар. Ризалыклары йөзләренә үк бәреп чыккан иде. Вәсимгә исә Алиянең ризалыгын сизүдән дә зуррак шатлыкның кирәге дә юк. Ул, сәке читеннән сикереп торып, чәйнеккә үрелде.

— И-и, кызлар, чәйне кайнарлатыйк әле! — дигән булды. — Төне буе урман әкиятләрен сөйләп чыгармын әле мин сезгә! Яме?

Алиянең яшькелт-зәңгәр күзләренә мөлдерәп нур тулды. Ул карашын Вәсимнән аерып ала алмый интегә иде. Хәмдүнә Вәсимнең «төне буе» дигәненнән өнсез калса да, дусты Алиянең хәлен аңлап, эндәшмәде. Дустының бәхете, бәлки, нәкъ шушы төнгә бәйледер?!

Һич көтмәгәндә, Алия үзе урыныннан кузгалды:

— Әйдә, Хәмдүнә, караңгы төшкәләгәнче, кайтып китик! — диде.

Вәсим дә артыгын кыстамады. Ат белән озатырга теләвен генә әйткән иде. Алия, ике кат сөйләшергә урын калдырмаслык иттереп, аныңсыннан да баш тартты.

— Урманны чыкканчы үзең генә озатып куй! — диде.— Аннары элдертәбез...

* * *

Больница коридорында берле-икеле сүз әйтеп, күпме торганнардыр — икесе ике якка карап, боегып калганнар иде, аларга бик йомшак тавышлы карчык эндәште:

— Сез дә йоклый алмыйсызмы, кызлар?

Алия белән Хәмдүнә, сискәнеп китеп, аңа борылдылар. Авызы-күзе көлеп торган, ифрат та җыйнак кыяфәтле, матур бер карчык иде бу. Кыска бөдрә чәчләре кап-карага буялган, күз-керфекләренә сөрмә тартылган, иреннәренә иннек тә тидергән. Өстенә карап торуы рәхәт. Больницага эләккәннәр арасында мондыйлар сирәк булучан.

— Кызлар, әйдәгез, мин сезгә җырлап күрсәтәм, яңа җыр чыгардым! — Карчыкның бу сүзләре Алияне дә елмаерга мәҗбүр итте.— Аскы катның бер башында медперсоналның «Кызыл почмагы» бар. Рояльләре шундый һәйбәт! У-у-у! — Карчык кулларын кушырып иңк астына куйды, күзләрен йомып, башын чайкап торды.— Андый шәп рояльне безнең консерваториядә дә күргәннәре юк! Әйдәгез! Шыпырт кына!

Аның чакыруына буйсынмый мөмкин түгел иде. Алия белән Хәмдүнә, бу нинди хикмәт дигәндәй, аптырашып, як-ягына түнә-түнә атлап киткән сөйкемле карчыкка иярделәр. Озын коридордан узганда карчык: «Миндә — рак,— диде.— Врачлар миннән яшерәләр, мин — белгәнемне — алардан. Йөрсеннәр әле мине җүләргә санап! Сөенсеннәр. Кешенең сөенгәнен күрүдән дә ләззәтлерәк хис юк».

Сөйкемле карчык рәхәтләнеп кеткелдәде. Битендәге мең дә бер җыерчыкка нур тулды, күзләре яктылык сирпеде, табигыйгә охшатып ясалган ап-ак тешләре җемелдәде.

Атамасы ук котны ала торган чир турында аның шулай шаярып сөйләве Хәмдүнәне шаккатырды. Алия дә салмак кына атлап барган жиреннән тукталды. Икесе берьюлы:

— Булмас ла, ялгышканнардыр әле!? — дип кычкырып җибәрделәр.

— Врачлар берни белмиләр алар,— Хәмдүнә, берәүнең өметен яктыртыр өчен, башкаларны хурлап ташларга да күп сорамый.— Сез дә шаяртып кына әйттегез бугай. Чир хакында көлеп сөйлиләрмени?

Алия дә һаман бер сүзне кабатлады:

— Булмас, булмас! Кит аннан!

— Нигә булмасын? — Карчык житдиләнде.— Минем бу дөньяда күрмәгән бер генә нәрсәм дә калмады: ачлы-туклы укыдым, җәяүләп гастрольләргә йөри торган идек, фронт юллары, госпитальләрдә үлеп яткан солдатларга җырлаулар. Ирем дә сугыштан кайтмады. Дуслар хыянәте, көнчеләр үчләшүе. Рак кына мине читләтеп үтмәс инде.— Ул тагын көлде.

Хәмдүнә аңа, чынмы соң бу дигәндәй текәлебрәк караган иде, карчыкның күзләрендәге нурның ялтыравыннан тетрәнеп китте. Шатлык балкуы түгел, бинаһая тирәннән саркып чыккан сагышлы яшь пәрдәсенең җемелдәве икән бит. Соңгы яшедер, бәлки. Бөтен җанны сыгып җыелган соңгы дымыдыр кешенең.

Борынгы рояль урнашкан бүлмә җәһәннәм чокырында икән. Салкынча, караңгы, күңелсез. «Кызыл почмак» өчен бигрәк шәп урын тапканнар!» — дип уйлады Хәмдүнә. Шулай да аның гарьләнүе озакка бармады — дөньяны әлеге сөйкемле карчык яңгыраткан моң тутырды. Бүлмәнең шыксызлыгы да хәтердән чыкты. Алар гүя ифрат киң аланда, яшьлек елларында эшләп йөргән урман куенында, берсеннән-берсе уздырырга тырышып сайраучы кошлар дөньясында, табигать кочагында

Өнсез калып тыңладылар. Бераздан бүлмәне Алиянең сулкылдап елау авазлары томалады. Хәмдүнә, нишләргә белмичә, рояль ягына карады. Музыкант карчык та аңа борылган иде. Бармаклары — клавишалар өстендә, алары үзәк өзгеч моң сыгалар, күзләре Хәмдүнәгә ишарәли, ияген дә кага карчык: «Син сизмәмешкә салыш, аңа шул кирәк. Күз яшен коя белгән җанда өмет бар». Ул да түгел, карчык шактый карлыккан тавыш белән, гарәп мәкаменә охшаш көй, җаена, салмак кына җырлап җибәрде:

...Гомер урләренә алып менде
Шаулы еллар баскычы.
Йөрәгемнән шул елларның
Алып ташлыйм кайсысын?

Уйнавыннан туктады. Хәмдүнә белән, ияк кагып кына саубуллашты да юк булды. Алия һаман елый иде әле. Шуның аркасында бүлмәнең караңгылыгы тагын да куерган кебек. Шулай да әле генә яңгыраган көйләр тәэсирендә, Хәмдүнә ныклы бер карарга килде.

— Әйдә, елап-сыктап утырма! Син авылга кирәк. Авырсаң, шунда ятарсың, үзем карармын! Гәүдәң генә булсын! «Алия — больницада, аннан шәһәрдә кала икән»,— дигән сүз генә ишетелмәсен! — Алия кузгалмый утыргач, Хәмдүнә соңгысын әйтте.— Мин моннан синсез китмим!

— Алай тузынмасаң да кайтам, синнән калмыйм.— Алия елмаерга тырышты. Аннары кисәктән музыкант карчык турында сөйләп китте: — Без шул үзебез турында кайгырып картаябыз. Бу карчык башка. Сизденме?

— Сәеррәк шул. Исәрләргә охшашрак димме?!

— Их, Хәмдүнә, синең белән миңа исәр сыман күренә, чынлап уйласаң, зур талант бит ул. Безгә кечкенә күренгән нәрсәдән дә ул әллә нинди мәгънәләр чыгара. Син аның бармакларына игътибар иттеңме?

— Күрдем дә котларым очты — шыр сөяк, өрәк кулы кебек.

— Менә шул инде синең, авыру карчыкның бармагы — шыр сөяк. Уйлабрак торган идем, башкача килеп чыкты. Клавишалар өстенә җәеп җибәрә ул әлеге кәкере-бөкере, нечкә бармакларын, көен башлый, йөзе балкып янарга тотына, сүнеп барган күзләрендә очкыннар уйный. Аның бармаклары нык тамырлар кебек, шул орчык кадәре генә карчыкны олы дөнья, Җир белән тоташтыралар шикелле. Тоташтыралар да җанына шифа өрәләр. Шулай булмаса, якасына ябышкан зәхмәтле чир турында көлеп сөйли алыр идеме?

— И-и, карале, чыннан да, Алия, менә хәзер дә күз алдымда тора, ул бармаклар — нәкъ тамыр! Тармаклы нык тамырлар.

— Безнең алмагачларныкы кебекме?

— Ярар инде, председатель. Гел-гел бер балык башы чәйнәмик! Әйдә, сал бу килбәтсез халатны, үз киемнәреңне алыйк!..

Больницада, ачылып китеп, шактый сөйләшеп ташласа да, Алия юл буе эндәшмәде. Автобус эче җайлы, җылы иде. Йомшак утыргычка чумдылар да, чит кешеләр кебек, бер авыз сүз алышмыйча, бардылар да бардылар. Алия, эндәшмә, уйланасым бар әле, дигән кебек, күзләрен йомды, Хәмдүнәсе башта, бу әллә нинди кирәкмәгән нәрсәләр турында хафаланып, тагын авыраеп китмәсә ярар иде, дип, шиккә калып торды. Сүз башларга, яман уйлардан арындырырга теләде, тик тел әйләндерергә кыюлыгы җитмәде.

Алия исә, гаҗәпкә каршы, ямьсез уйлардан еракта, үткәндә кичергән ләззәтле истәлекләргә чумган иде. Колагында һаман больницада ишеткән җыр яңгырый сыман: «...Йөрәгемнән шул елларның алып ташлыйм кайсысын?»...

... Ул елны алар Хәмдүнә белән икәү урман хуҗалыгында эшли башладылар. Кайсының тәэсире көчлерәк булгандыр — Вәсимнең күңелне

канатландыручан серлелегеме, урманның җанга рәхәт бирүчән табигате-ме? Инде берничә елдан бирле шул биләмәләрнең хуҗасы булган Вәсим:

— Килегез, кызлар, безгә эшкә! — дигәч, алар икесе дә ризалаштылар. Ул чакта колхозларда яшьләргә даими эшләр юк иде. Урманчыларга ярдәм кирәк чагында колхоздан кеше җибәреп тору гадәткә кергән. Хәмдүнә белән Алиянең теләген карт председатель шатланып хуплады.

— Яхшы итәсез, кызлар! — диде.— Минем дә йөз ак булыр. Райкомда да, райбашкармада да күкрәк киереп йөрермен. «Алма кебек ике кызымны бирдем, артыгын сорамагыз!» — диярмен.

Шул китүдән Алия Вәсим житәкчелегендә шактый эшләде, гомерлеккә калырга да риза иде. Аһ, кыз бала үз язмышын үзе генә хәл итә алсачы!

Алия белән Хәмдүнә урман хуҗалыгының тәэминат бүлегендә, урман кисүчеләр ашханәсендә эшләделәр. Бер кашык ботка өчен үзәкләр өзелә торган еллар иде. Бай хуҗалык, бик кирәкле хуҗалык, дип кенә аларга манный ярмасы бирәләр. Шуңа өстәп, тоз да су. Башка берни дә юк. Кызлар, тозлы суда җебегән күгелҗем боламыкка татлырак тәм кертү өчен, әллә нинди әмәлләр эзлиләр иде.

Суны урманның төрле чишмәләреннән дә алып кайтып азаплаhandлар. Аңа төрле үлән яфраклары, тамырлар салып кайнатып та маташтыралар. Болардан гына боткага әллә ни туклыклылык та, ләззәт тә өстәлми. Кайчак аларга колхоз фермасыннан берәр бидон аертылган сөт, өйдән берәр йомарлам май, үзләре эшли торган бүлектән бераз шикәр алырга җай чыга. Башка көнне ул бер-ике кашык күгелҗем сыекчаны әзмәвердәй ир-атлар каршына китереп куярга ояла торган Алия, ботканың тәмлелегенә ышанганда, үзен яу батырыдай хис итә. Сөткә пешкән бераз май белән тәмләтелгән саргылт ботканың хуш исе әле дә борынны кытыклый шикелле.

Урман кисүчеләр шул тирәдәге авыллардан фатир алалар иде. Хәмдүнә белән Алия дә шулай. Боткалары тәмле пешкән көннәрнең берсендә Вәсим кызларны кайтып йөрмәскә, аның өендә генә куна калырга чакырды. Алия үзе башлап ризалык белдерергә җөрьәт итә алмас та иде, мөгаен. Хәмдүнә җавап бирде:

— Әй, Вәсим, нинди илаһи зат соң син? — дип башлады.— Аяк атларлык та хәл калмады.— Ул Алиягә күз кысты.— Әле син әйтмәсәң дә, сорарга ниятләп тора идем. Бер почмагың табылыр шунда.

— Әйдәгез, алайса! — Вәсимгә шул гына кирәк.— Утырыгыз арбага.

Ул көз яңгырлы килде. Тәгәрмәч эзенә мөлдерәмә су тулган. Ат чыптыр-чыптыр бара. Читтән карап торсаң, бу арбадагы кешеләрдән дә арыган, йончыган җаннарны таба алмассың кебек. Әмма болар читтән карап торучыга гына шулай. Арбадагыларның күңелендә чалт аяз көн, йөзләрендә нур уйный. Вәсим тиздән, җып-җылы өендә кечкенә чәй табыны тезеп куеп, каршына ике кызны утыртып сыйлаячагын күз алдына китереп, балкып утыра. Хәмдүнә, болай йөрүе өчен кешеләрдән начар сүз ишетәчәген сизенеп борчылса да, дусты өчен бик зур яхшылык эшләвен тоеп шатлана. Алия әлегә куанырга да, кайгырырга да белми. Вәсим өенә ник баруын да аңламый. Соңгы вакытта Вәсимне гел күрәсе килә башлады. Исәнләшеп кенә узса да, башы күккә тия, шул бер очрашу барлык кыенлыкларны оныттыра. Арытмый да, эш көненең узганы да сизелми...

Алар әти-әнисе йортыннан Вәсимгә мирас булып калган олы җиз самавыр янында утырдылар да утырдылар. Вакыт турында уйлаучы булмады: төн икәнен дә хәтердән чыгардылар шикелле. Өстәл түрендәге уңлы лампа филтәсе күмерләнә башлагач кына, Хәмдүнә:

— Абау, җаннарым, бер лампа керосинның башына житкәнбез бит,— дип, урыныннан кузгалды.— Безгә диган урынны кайсы сәкегә җәяргә, Вәсим?

Хәмдүнә өйдәге вак-төяк эшләрне караштырганда, Вәсим Алияне төнге урманга алып чыкты.

— Учак ягабызмы?

— Ярыймы икән соң? Әй күңелле булыр иде ул! Күпме эшләп йөреп, шунда бер учак та ягып караганыбыз юк.

Алар Хәмдүнәнең бүленеп калуын онытгылар. Вәсим өй янында гына учак үрләтеп җибәрде. Башта Алия дә аңа коры-сары китергәләде. Аннары җылылык, яктылык яныннан еракка китәсе килми башлады. Вәсим көйләп куйган түмгәккә утырды да озын таяк белән учакны төзәткәләп кенә торасы итте. Учак зур түгел иде, тау кадәресенең кирәге дә юк. Ике кешегә җитәрлек кенә кайнар учак. Бераздан Вәсим дә, Алия янына утырып, тынып калды. Сөйләшмәделәр. Учактагы чыбыклар чыртлавыннан башка һичнинди тавыш юк кебек. Бераздан биек наратлар ягыннан кошлар аваз салгаларга тотынды. Сайраулары да, үзара аңлашулары да түгел иде бу. Йокы аралаш, аны-моны белештермичә, гөлдердәшеп куялар.

— Вакытлы-вакытсыз яктылык ясап, кошларның йокысын бүлдек бугай, Вәсим? — Алия тын утырудан үзе дә туя башлаган иде.— Әллә сүндерикме?

— Янсын әле! Әйтәләр бит: безнең йөрәкләр янганчы, утын янсын, диләр.

— Йөрәгең янамыни? — Алия кайчан да булса бер әйтелергә тиешле сүзне, бу егет белән аңлашырга кирәклеген сизенә. Һәм кинәт кенә гомергә бер ишетелердәй ул сүзне нәкъ менә шушы төндә, серле урман куенында, әлеге изге учак шаһитлыгында әйтүләрен тели башлады.— Ничек була соң ул йөрәк януы?

Вәсим кызның теләкләрен аңлап өлгермәде. Кеше табигате шулай яратылган: бер-берен аңлаша алмый интегәләр. Егет — кызны, кыз егетне бер-ике сүздән үк аңлап куйса, мәхәббәт кебек ләззәтле хис үзенең серләрен гасырлар буе саклый алыр идемени соң? Вәсим дә кызның чытлыкланып биргән соравына төшенмәде, йөрәген ачып сала алмады. Ятимлегеннән гарьләнә-гарьләнә гашыйк булуын, инде хәзер саташыр дәрәҗәгә җитүен белдермәде. Бу кичерешләре — иң зур байлыгы, иң кадерле сере иде аның. Шикләнә калды егет: әйтеп салырсың, кыз, ялт иттереп кире кагар да куяр, дөнья бөтен мәгънәсен югалтыр. Шуңа күрә йөрәк януының ничеклеген сораган Алиягә башын ваемсызлыкка салып җавап кайтарды:

— Мин бит кеше сүзен генә әйтәм,— диде.— Үзем мин йөрәкнең кайдалыгын да белмим: әллә тибә, әллә юк.

Берәү булса, егетнең мондый сүзләренә үпкәләр иде. Сикереп торыр да, йокы басты, дип, кереп үк китәр иде. Алиянең исә үз хәле хәл, үпкә-сапка уены уйнаулардан узган. Егетнең ачылып китәргә тәвәккәлли генә алмавын да тоеп-сизеп утырды ул. Ялкын яктысында Вәсим кулларының сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп торуы да күренә, озын керфекләр белән каймаланган соры күзләре, гүя моңлылыгын яшерер өчен, бераз кысыла төшкәннәр, серне чыгармасыннар, дигәндәй, күперенке иреннәрен дә тешләгән егет. Куе коңгырт чәч каплаган колаклары, кыз ягыннан тагын нинди аваз килер, дигән кебек тырпаеп, сакта тора.

Алиягә ышаныч иңде. Йөрәгенең кайдалыгын да белмәгәч, кара төндә Алия өчен ник учак ягып маташа соң әле ул? Урман эшендә Алия белән Хәмдүнә генә түгел, тагын җиде-сигез хатын-кыз бар. Вәсим башкаларны үз өенә чакырмый бит, боларны гына аерып алды. Инде өенә алып килгәч, төнге урманны күрсәтергә теләгәч, Хәмдүнәне дә шома гына аерып калдырды.

— Бәрәкәт, безнең Хәмдүнә ник һаман чыкмый соң? — Алия дустын да чакырырга теләде.— Алып килим әле!

— Кирәкми. Йокласын! — Вәсимнең тавышы танырлык та түгел. Ягымлы ялвару, үтенү.— Икәү генә утырыйк әле!

Егет үз мөнәсәбәтләренә кагылышлы башка сүз әйтә алмады. Алия-

гә артыгының кирәге дә юк иде инде. Сүз башларга шунысы да бик житә.

— Ярый чакырдың әле, Вәсим.

— Ник алай дисең?

— Сагынган идем. Бик.

Егет ялгыш ишетмәдемме, дигән сыман, башын күтәреп, күзләрен мөлдерәтеп, Алиягә карады. Моңарчы очрашкалаганда Вәсимгә туры карарга кыймый йөргән кыз да бу юлы аңа борылды. Күзләре ут яна.

— Ни дидең, Алия, кабатла, зинһар!

— Нигә, әллә кабатламас, дисеңме? Сагынам мин сине, Вәсим, гел сагынам. Янымда басып торсаң да, китеп барыр чагыңны уйлап, кабат килүеңне көтә башлыйм.

Вәсим, карашын кыздан аермыйча, тынсыз калып тыңлый. Алия дә туктарга теләми. Электән килгән гадәт кануннары, әйтерсең лә, бу төн өчен түгел. Югыйсә кыз бала телгә алырдай сүзләрме соң алар?

— Үзең дә беләсең бит инде, Вәсим: яратам бит мин сине.

— Ни дидең? Кабатла!

— Яратам. Беләсең бит инде.

— Кайдан сиздең?

— Күзләрең соң, күзләрең берни дә яшерә белмиләр бит!

— Яшерергә теләмим дә бит әле.

Карашларын бер-берсеннән ала алмыйча алар тагын да якыная төштеләр. Битләре биткә тиде. Учак дөрли иде. Жылы, якты. Салкын, юеш көз үзенең көзлеген онытты кебек.

Шушы төнге сөйләшүдән соң Вәсим белән Алиянең дуслыгы авылдашлар өчен дә сер булудан туктады. Авыл туй көтте. Ил өстеннән сугыш афәте узды дип кенә, ата-баба гадәтләрен гадәтләмичә, туйсызнисез гаилә кормаслар бит инде.

Ни гажәп: бүселеп чыккан муллыгына караганда, тормышның кыенлыгы кешеләрне ныграк дуслаштыра. Алия белән Вәсимнең туе матур узсын өчен бөтен авыл бер булып тырышты. Авылда алма бакчасын саклап калган бердәнбер кеше бар иде — Биктимер агай. Алиягә иң әүвәл шуңардан бер әржә кып-кызыл алма килде.

— Коштабакларга тутыр да, өстәл түренә меңгезеп куй, бәбкәм.— Биктимер әржәсен кул арбасына куеп, үзе китерде.— Ризык ризыкны тарта, шуңа калганнары да жыелыр...

Вәсим бөртекләп жыйган акчаларына, туй истәлеге булсын, дип, Алия өендәгеләргә бүләкләр алды. Урмандагы өен рәтләде. Бүлмәнең эчен дә үзгәртте. Буйдак чактагы сәкеләрнең берсен сүтеп атты, икенчесенә, сырлап-бизәкләп, култыксалар ясады — гажәеп матур агач карават килеп чыкты...

* * *

Автобус кинәттән тукталганга, пассажирлар урыннарыннан дәррәү куптылар. Алия күзләрен ачты.

— Кайтып та життекме әллә?

Хәмдүнә Алиянең тиз үк мондый дөньяви хәлләргә игътибар итәчәгенә ышанып житмәгән иде әле, сискәнеп куйды:

— Чыннан да кайтып житкәнбез икән шул! — Ул Алияне өенә кадәр озатып куймакчы иде. Ни дисәң дә — больницадан чыккан кеше бит.

— Безгә барасың килсә, мә, минем сумканы да алып кайт.— Алия кире якка борылды.— Мин Биктимер бабай янына кереп чыгам әле.

Карт мич башында утыра иде.

— Һе! Әллә мин әйтәм, күземә күренә инде? Син түгелме соң, Алия кызым? — Ул көчсез тавышы белән кеткелдәргә тырышып, сүзе саен «һе» дип, сулуын бүлеп, мич буендагы эскәмиягә төшеп басты.— Халык сине чирләгән дип, ихластан хафаланып сөйләгән була. Менә ышан сүзгә!

— Булды, Биктимер бабай, анысы да булды.— Алиянең бу хакта озын-озак сөйләшәсе килми иде.— Мин әле синең белән башкасы турында сөйләшергә килдем, үзең дә чамалыйсыңдыр.

— Утыр янымa, әйдә! Аяк өсте сөйләшмә. Ни чыкты тагын?

Алия бу йортка шактый еш килә. Күп очракта картның хәлен белергә кучтәнәч-фәлән яки колхоз рәхмәтен тапшырырга керә. Бу юлы хатынның тавышы ук башка. Биктимер карт, сирәк-сирәк керфекле күзләрен челт-челт йомып, сакал-мыексыз шома ияген сыпыргалап, идән ярыгына текәлде. Алиянең ник килүенә төшенмәкче иде. Председатель берсендә терлек азыгы кытлыгыннан котылырга киңәш сорап килде.

Коры җәй иде ул. Янгыр яумавы — бер хәл, Кама суы кипте. Терлек азыгы үсә торган үлән басуларына су сиптерүче җайланмалар өнсез калды. Су бетте. Алия дә, агроном да башта үлән өчен әллә ни хафаланмадылар. Яна көн туды исә, иген кырларына чыгып, арыш-бодайларның хәлен белергә ашыктылар. Тирә-күрше хуҗалыкларның басулары турында шомлы хәбәрләр ишетелеп торды: «Арышларын силоска чапканнар»... «Бодайлары көйгән»... Алиянең колхозына да бу афәт килер микәнни?

— Нишләрбез? — Ул агрономнан сорый.— Ничек коткарып була?

— Безнең җир яхшы эшкәртелде, чыдарга тиешләр.

Чыннан да, бөтен шарты җиренә житкерелеп эшкәртелгән, ашламасы-фәләне мул бирелгән иген басулары сирәк килә торган шушы корылыкка да түзделәр. Әммa терлекләр җәй көнендә ук ачка интегә башлады.

— Нишлим, бабай? — дип, Алия Биктимер карт янына килде.— Маллар кырылып бетсә, нишләрмен? Хәзер үк сөт кимеде, артым юк. Нишлик, бабай? Элекке чакта, корылык килсә, нишли идегез?

— Элекке чамалар хәзергесенә ярамый, кызым. Ул заманда мондый байлыкләр юк иде. Җәй коры килсә, кеше үз башын саклап калырга азапланды. Ишегалдындагы бөтен мал-туарын чалып сала да читкә, игеннәргә зыян тимәгән якка ашыгалар. Кыш салкын килсә, иданнәрен ягып бетерәләр. Җир иданле өйдә яшиләр иде.

Бераздан ул тамагын кырып куйды. Тавышы үзгәрде.

— Хәзер, шөкер, өметсезлек юк кешедә. Кайгысы ук башка төрле: нишлик, имеш — сыерның сөте бер поттан кимеде? — Карт кеткелдәп куйды.— «Пот» диләр. Менә сиңа замана, ә! Кайчаннан бирле әле сыеклыкны потлап үлчи башладылар?

— Әй, бабай, хикмәт ничек аталуындамыни? — Алиянең үзәген өзеп, яңа бер югалту искә төште.— Җәе рәтле килсә, быел һәр сыердан биш мең килограмм сөт аласы идек бит!

— Табылмаган мал тау хәтле, дигән борынгылар. Ул кадәр өзгәләнмә.— Карт кырысланып китте.— Малларыңның башын саклап каласың килсә, бер уй бар миндә...

Алар, салмак кына атлап, Кама ярына килделәр.

— Күрәсеңме? — Биктимер карт әле һаман житди, үз тавышына сөенергә дә, көенергә дә белми иде.— Елга эчендә күпме атаулар! Бары да ямь-яшел!

— Карале! Ничек беребезнең дә башына килмәгән?!

— Бу дөньяда бернәрсә дә юктан бар булмый. Әүвәле бу урыннарда иксез-чиксез болыннар иде бит. Буа буып, су агышын боргалый башлагач, алар аста калды. Көннәр корыга киткәч, күз суларымны түгеп, шул болыннар ягына карыйм да карыйм. Башта атаулар калыкты, аннары яшелләнделәр, хәзер әнә дулкынланып ук утыра!..

Ничәдер атналар үткәч, житәкче оешмалар корылык аркасында саеккан зур сулардагы утраулардан печән чабу турында күрсәтмә дә бирделәр. Аңа кадәр Алия колхозы якын-тирәдәге утрауларны «ялап» чыккан иде инде. «Бу җирләр — колхозныкы түгел, бәлки, ярамыйдыр»,— дип шикләнеп, шыпырт кына эшләделәр. Урлашкандай. Әле кибеп тә өлгермәгән печәнне төннәрен көймәләргә төяп ташыдылар. Шул өмә көннәре Алияне халыкка тәмам үз иттерде. Ул үзе дә чалгы күтәреп

чыкты. Соңгы чүмәлә авыл ягына озатылганчы, Алия утрауларда булды...

Ул еллардан соң Биктимер бабай өшәнгән, тәмам мич башы картына әйләнгән инде. Колхоз башлыгына ни генә әйтә алыр икән ул?

— Әйдә, балам, тартынма, күңелеңдәген әйтеп кара! — Председательнең ник килгәнен аз гына да чамалый алмаганга үзен битәрли иде ул.— Минем кулдан ни генә килер икән инде хәзер?

— Уйлап караганың бармы синең, Биктимер бабай? Алмагачлар нишләде икән безнең, ә! — Алиягә иң авыры — шушы сүзләрне әйтеп салу.— Син бит кырык бернең суык кышында да бакчаңны саклап кала алгансың?

Карт авыр сулап куйды. Бу кешенең өметен өзмәслек сүзне каян табарга? — Ә-ә, син алмагачлар хакында икән әле. Кырыгынчы еллардагы суык иллегә җитмәгән иде шул.

— Өмет юк икән алайса, Биктимер абзый.

Карт, өстеннән тау төшкәндәй, җиңеләеп калды. Хәзер инде председательгә барысы хакында да ачыктан-ачык әйтергә мөмкин.

— Син, бала, терелерләр дип ышанма. Авыр булыр, түз, тиз арада яшь үрентеләр утыртырга кара!

— Өшегәннәрне нишләтергә соң?

— Төбе-тамыры белән жыештырырга кирәк. Төпләүне озакка сузма, оттырырсың.

* * *

Ул елны яз иртә башланды. Март керүгә жылытты, кар китте, аннары тагын суытты, җир эремәде. Аклан кешеләренең күңелсезлектән, билгесезлектән интеккән җаннарына шул гына җитмәгән иде. Кисәктән жылытып җибәрсә, рәхәтрәк булыр кебек. Әйтерсең, күңелнең тоташтан сулкылдап торуы язның көйсезлегенә генә бәйле.

Алия белә: язның сузылуыннан зыян юк, кар суы котырынып агып бетми, җиргә сеңә бара. Иген кырларына, көтүлекләргә яхшы булачак. Тик Акланга болар гына җитми. Аклан, өнсез калып, алмагачларның януын көтә.

Председатель кеше күзенә күренүдән курыккандай, бакча тарафына караңгылы-яктылы чакта үк чыгып китә. Күзәтүен иң яраткан рәттән — Якты Инеш алмагачларыннан башлый. Монысын, зур җитәкчелек белән киңәшеп-ниеп тормыйча, колхозчыларның үз кирәгенә генә дип, шушы ташландык урынга утырткан иде. Беренче башлап Вәсим йөрде, Биктимер абзый өйрәтеп торды. Ал чәчәк ата торган эниләр. Алар чәчәк күрсәткән елны Вәсимне... агач басты.

Алия алмагачларның яңа төрләрен утыртырга, бакчаны киңәйтергә тотынды. Әйтерсең лә авылны алма бакчасы итсәң, Вәсимне терелтеп була! Юк, иксез-чиксез бакчаның чәчәккә күмелүен Вәсим күрә алмады. Көннәр буе урын-җир өстендә ятарга калган иде инде ул.

Берсендә Алия эштән кайтып керде. Өс киемнәрен ишек төбендә үк калдырды. Вәсимнең ятагына үтте.

— Менә мин дә кайтып җиттем, картым! — диде. Бу аның һәркөнне әйтә торган сүзләре.— Бу арада эш юк. Аннан-моннан күз салган гына итәм дә синең янга сызам.

— Алай итмә! — Вәсим сыңар кулын хатынына таба сузды.— Кил әле, утыр янымга. Син үзеңнең нинди зур хуҗалык башында икәнеңне онытма!

— Ярар инде! Гел шул председательлекне китереп кыстырасың. Үзең киңәш биргәнгә генә ризалашкан идем бит мин. Синең яныңа да кайтырга ярамый башкаса, иплән кенә баш тартырмын әле менә. Хатыннар чыдарлык эшмени соң бу?

— Алай киреләнергә булгач, институтларда укып, хыялланып йөрүләрең кая китә? «Диплом ала алсам, авылны гөлбакча итәм!» — ди торган идең...

Икесе дә, үткәндә кичергәннәрнең ләззәтенә бирелеп һәм бүгенге хәлнең чарасызлыгын чамалап, сүзсез калдылар. Урман йортында әкияттәге гашыйклар кебек яшәгән көннәре, Рушания кызларының туу шатлыгы. Бала аякка басып, әбисе янында калырлык булгач, Васим:

— Безгә бу җиде класс белән генә калырга ярамый,— дип, икесенә дә укырга кирәклекне тәкрарларга тотынды.

Икәүләшеп әзерләнделәр. Урта мәктәпкә имтихан тоттылар. Аттестатлы булдылар. Әйтүе генә ансат. Васим белән Алия исә, аттестат алу өчен, мең үлеп, мең терелделәр. Физикадан сынау бирүен Алия гомер буена онытмаячак.

Физик Хатыйп Җаббаров — тирә-юньгә даны таралган, талантлы педагог иде. Башта Васимнән сорады. Ир кеше — ир кеше инде, кем әйтмешли, тумышыннан физик. Китаптан укып өлгермәгәнен чамалап та белә. Кагыйдәсен онытканы булса, ясап та күрсәтә. Ахырда, укытучы аңа:

— Яхшы! — диде.— Барыгыз, хәерле юл!

— Мөмкин булса, мин Алия Субаеваны да көтеп торыр идем.

— Мөмкин түгел. Миңа ассистентлар кирәкми.

Васим класстан чыгып киткәч, укытучы бер-ике сорауга җавап тыңлап карады да Алиягә:

— Белмисең бит,— диде.

— Белмим шул, Хатыйп абый. Дәресләрне бер кат укып чыгарга да вакыт тимәде. Соңгы бүлекләрен дә Васим белән бергә кабатласам, буладыр иде инде, мин кызыбыз янына кайтып йөрдем, авырып алды ул. Васим үзе генә өйрәнде...

— Аттестат нәрсәгә соң сиңа? «Ирем ала, мин генә ник калышыйм?» — дисеңме.

— Юк ла! Авыл хуҗалыгы институтына бармакчы идем. Васим — урман техникумына. Минем әнә шул үзебезнең тап-такыр, шәп-шәрә авылны урман кебек бакчалы итәсем килгән иде. Укымасаң, кем сиңа ул эшне бирә?!

Карт укытучы бер Алиягә, бер өстәлгә таратып салынган билетларга карап-карап алгалады. Аның чал чәчле башы калтыранып куя, борын төбендә генә калдырылган ап-ак мыегы дерелди. Үзе һаман берни дә эндәшми утыра. Ниһаять, ул урыныннан кузгалды, өстәлдәге әйберләрне иске, зур портфеленә тутырырга тотынды. Аттестат алу өметен тәмам өзгән Алия кымшанырга да кыймыйча утыра бирде.

— Әйдә, болай итик без! — Укытучы, портфелен кулына алып, Алия утырган парта янына килеп басты.— Моннан китик. Керик минем өйгә. Эш өстәлемне мин бүгенгә сиңа биреп торам. Көне буе китаптан мин кушкан темаларны укыйсың. Тәрәлеп калсаң, шунда ук сорыйсың. Аңлата барырмын. Сиңа уңай тамга куярга бердәнбер чара шул. Иртәгә сәгать унга мин авылдан китәм. Синең эшне төгәлләмичә юлга чыксам, яхшы булмас.

Буйдак картның өй дигән бүлмәсе мәктәп бинасында ук иде. Ишеге генә башка якта. Бүлмә пөхтә, педагогларда гына булырга мөмкин җиһазлар: стенада — дөнья картасы, Ленин портреты. Түрдә — язу өстәле. Һәр тарафта китаплар. Йокы урыны икенче якта, күрәсең.

— Менә сиңа урын, Субаева! — диде укытучы. Ул китапның кайбер битләренә кәгазь тасмалар салып чыкты.— Менә китап, билгеләнгән темалар...

Алия шунда гына әлеге карт укытучының таләбе язмышындагы иң җитди сынау икәненә төшенеп житте. Аңа хәзер бу башваткычны ташлап, чыгып китәргә дә мөмкин, дүрт ягың кыйбла. Тик хыялың-фәләнең дә шуның белән бергә очып китәчәк.

— Рәхмәт, абый! — Алия укытучының аңа соң мәртәбә нинди зур мөмкинлек тудырганлыгын аңлап алды. Тагын: — Рәхмәт! — дип кабатлады.

— Монда рәхмәт әйтерлек нәрсә юк, минем үзем өчен кызыклы

факт. Ачыклыйсым килә: башың эшлиме синең, әллә язу артыннан гына йөрисеңме? Менә шул!

— Эшли, абый, эшли! — Алия, сүзенең ышанычсыз яңгыравын чамалап, өстәргә ашыкты.— Эшләтермен, абый, тырышырмын!..

Җиде төн урталары булгандыр — Алия, укытучысы кагылып куюдан сискәнеп китте.

— Син, Субаева, менә мондый такмакны кемнәр чыгарганлыгын беләсенме:

«Суга үпкә батару, казык белән басару,
Үпкә суда батмый икән, баскан саен калкару...»

Алия, төндә күргән төшеннән арынгандай, бер мәл эндәшми-нитми торды. Ишеткән такмагын кабат күңеленнән үткәрде, көлеп җибәрде:

— Белә-әм! — диде.— Күршебездәге керәшен карчыгы Грәпи әби сөйли торган иде. Бу такмакны борынгы заман егетләре җырлаган. Имеш, бер байның сарыгын чалганнар, эчен-башын бәкегә салмакчы булганнар. Үпкәне һич батыра алмый интекканнәр. Аулак мәҗлес буласы өйгә килгәннәр. Анда теге байның улы да утыра ди. Шуңа сиздермәс өчен, хәлләрен такмаклап күрсәткәннәр.

Алия — укытучы мәзәктән көләр дип уйлаган иде, тик физик карт кисәктән җитдиләнде.

— Соң! — дип, кызга кырт кисеп, сорау бирде.— Уйла инде хәзер: ни өчен үпкә суга батмый?

— Җиңел булганга.

— Юк, син Субаева, шул хәлне әле генә укыган физика законнарына нигезләп аңлат миңа! Әйт әле, нинди закон ул?

Алия салкын дәрьяга чумган кебек булды. Аннан сикереп чыкты да ут эченә ташланды. Кашлары җыерылып килде, яшькелт күзләре очкынланды, бармакларын күе чәчләренә батырды. Ул укытучысыннан да җитдирәк кыяфәткә керер:

— Архимед законы,— диде.— Сыеклыктагы әйбер үзе кысып чыгарган сыеклык авырлыгы кадәр көч белән астан өскә таба этелә. Үпкәнең күләме зур, сыеклык күп кысыла, димәк зур көч этә аны...

* * *

Якты Инеш итәгендәге әниләрне алар иң зур теләкләре тормышка ашкан шул елны утыртып калдырганнар иде. Вәсим урман техникумына керү имтиханнарын яхшы биреп, студент билеты алгач, кайтышлый яшь үсентеләр турында сөйләшкән. Алиясенең институтта читтән торып укырга кабул ителүен ишеткәч, җирне әзерләп үк куйдылар. Бер тиен чыгымсыз, авыл яшьләренең өмәсен оештырып, алма бакчасы ясадылар.

Кадерле истәлекләр рәхәтенә бирелгән Алия, иренең чәчләрен сыйпаштырып, тәмам онытылып, шактый утырды. Вәсим йокыга талган кебек иде. Йокласын. Хатыны өйдә юкта әллә ниләр уйлыйдыр, борчыладыр, кәтәдер. Хәзер әнә тыныч аңа.

Алиянең якты уйлары кинәт киселде. Вәсим сыңар кулы белән аның беләгеннән кысып тотты. Үзен-үзе белештермичә бөтен гәүдәсе белән калкынып куйды. Гадәттән тыш зур итеп ачылган күзләре Алиягә текәлде.

— Ни булды, Вәсим? Нәрсә? Ник дәшмисең, Вәсим?

— И-их!

Вәсим башкача җавап кайтара алмады. Гәүдәсенең бөтен авырлыгы белән ятагына авып төште. Бөдрәләре тәртипсез хәлдә ак мендәр өстенә таралды, күзләре мәңгегә йомылды.

— Вә-си-и-им! — Җанын ярып чыккан ул ачы тавыш Алиягә әле булса тынгылык бирми. Һаман яңгырый, Вәсимне югалту авырлыгын гел искәртеп тора.

* * *

Алия хәзер дә күзәтүләрен беренче итеп утыртылган әнисләрдән башлый. «Ни хәлләрегез бар? Кайрыларыгыз тере кебек, бөреләрегез дә бүртә шикелле, чәчәк ата алырсызмы?..» Ул үз тавышына үзе сәерсенә: «Тиле кеше кебек үзалдыма сөйләшәм».

Март башыннан ук бер көнен калдырмый бакчаны күзәтеп йөргән председатель бакчаның язмышын хәл итү өчен җибәрелгән махсус комиссия эшли башлагач, алмагачлар арасына чыгудан баш тартты.

— Минем эшем муеннан! — дигән булды.— Кичке биштә идарәдә очрашырбыз. Шул вакыт житәдер бит?

— Өлгерергә тырышырбыз.— Җавапны Мәскәүдән чакыртылган галим кайтарды. Рус егете иде ул, җете зәңгәр күзле, сыек сары чәчле, озын, ябык.— Күп анализлар алдан ук ясалган. Машина белән йөрибез бит, өлгерербез.

Киттеләр. Алар бакчаны иңләп-буйлап айкаганда, «муеннан эшле» саналган председатель кыл да кыймылдата алмады. Йөрәге ярсып типте, башын мең төрле сорау тутырды: «Ничә гектарын сызарлар?», «Кайсы сортлар чыдамлырак икән?», «Өстәмә чыгым күп булырмы?»

Комиссиянең гомуми карарын Мәскәү галиме тәфсилләп бирергә булды. Комиссия эше өчен ул иң җаваплы кеше икән. Алия аны таныган сыман да иде, исенә төшерә алмады, кемлеген башкалардан сорарга туры килде. «Өлкә комитетының беренче секретаре үзе ВАСХНИЛдан чакыртып алган. Академик ул»,— диделәр.

«Менә бәхетле җан! — дип сокланды Алия.— Мин, монда бер бакча язмышын хәл итә алмыйча, больницага барып егылдым. Бу кеше бөтен ил бакчаларына хуҗа булып йөри. Сәләтне бирсә, бирә дә инде бу табигать! Менә бәхетле җан!»

— Бүген дөньяда миннән дә бәхетсезрәк кеше юк...— Алия үз уендагы фикернең киресен ишетеп, аптырый калды. Галим аска карап сөйли бирде.— Мин, иптәшләр, бик кайгылы хәбәр әйтергә тиеш-мәҗбүрмен...

Председатель калганын ачык хәтерләми. Нәтиҗәне генә белә: бакча тоташы белән беттегә исәпләнә. Хәмдүнә, бухгалтер, партком секретаре сораулар бирделәр. Җанны җылытырлык җавап ишетелмәде. Академик:

— Юк! — дип, кырт кисте.— Мондый зур хуҗалыкны, булырмы, юкмы дигән икеләнүләр белән юмалап, баланста калдырырга мөмкин түгел. Үземнең вазифага кермәсә дә, колхозның киләчәге турында шуны гына әйтим: колхозда терлекчелек зур отыш бирә икән. Хәзер бөтен көчне шул тармакка юнәлтергә кирәк! Ялгышмасам, сез һәр сыердан бишәр мең кило сөт аласыз. Бу — зур байлык.

— Безгә байлык кына җитми! — Хәмдүнә, бичара, бөтен ачуын шул кешедән алырга тели иде кебек.— Безнең халык, әнә шул алмагачларның корыган яфрагы урынына акча элеп куйсаң да, әйләнеп карамас. Аңа язлар саен ак чәчәккә күмелгән бакча кирәк! Шунсыз күңелләрен күтәрә алмыйсың.

Егет туктады. Аның күзләре зәңгәр яктылыгын җуйган кебек иде. Киң маңгаен җыерчыклар сырлаган, тавышы яңгырамый. Ул Алия ягына карарга да кыймый. Я аска текәлеп, я әллә кая югарыга карап сөйли:

— Хәлегезне аңлыйм. Тик кабат әйтми булдыра алмыйм: бакча дәүләт балансыннан сызылырга тиеш. Чөнки якын арада гына бу мәйданнан, гомумән, файдаланырга мөмкин түгел. Корыган агачларны төпләмичә, аңа бернәрсә чәчеп тә булмый. Мәйданны чистартып, рәткә кертү өчен сигез-ун ел кирәк, минемчә.

— Әнисләр нишләгән? — Алиянең тавышы танырлык түгел иде.

— Без аларны тикшереп тә тормадык. Бердән, әниснең суыкка чыдамлыгында аерма юк, икенчедән, аның урыны да су буенда, ул җирне эшкәртергә бирәү дә алынмаячак. Утыртканда ничек утыртмагансыздыр, машина керерлек тә түгел. Кем утырткандыр?

— Авыл комсомоллары.— Алия үзалдына сөйләнгәндәге кебек кенә әйтте.— Көрәк белән казыган идек, ат белән тирес ташыдык...

Алия артыгын әйтә алмады, сүзе, Васимгә тоташыр да, елатыр, дип шикләнде. Сүз үткәндәгеләр түгел, киләчәк хакында барырга тиеш.

Алия утырышны түгәрәкләде. Соңыннан:

— Комиссия өчен кечкә аш әзер,— диде.

Председатель кабинетында икәү генә калгач, Хәмдүнә:

— Ни кыланышың бу синең?— дип, Алияне тиргәргә тотынды.— Аларның ни гаепләре бар? Кеше Мәскәүдән тикле килгән. Әйдә, үзең сыйла кунакларны!

Дөнья дуслардан мәхрүм итмәсен икән. Ярый шунда Хәмдүнә киңәш бирде, ашханәгә Алияне дә ияртеп алып китте әле! Әңгәмәнең шактый файдалысы анда дәвам итте. Алар тамак ялгаган арада, авылны караңгылык баскан иде. Казанга илтүче автобуслар күптән туктаган. Алия үзе янында басып торучы академикка:

— Кайгырмагыз! — диде.— Кунак йорты иркен безнең. Көзен алма җыярга килүчеләргә җитәрлек иттереп салдырган идек.

— Сез безне, әлбәттә, Казанга озатып куярга тиеш идегез инде, Алия ханым,— диде трест вәкиле.

— Була. Шоферны чакыртыйк алайса.

— Миңа авылда куну хәерлерәк.— Мәскәү кешесенең төнгә каршы юлга чыгасы килми иде.— Иртән алтыларда кузгалсак, турыдан-туры эшкә тотынырга мөмкинлек була.— Ул Алиягә борылды.— Миңа сезнең өйдә урын табылмасмы?

Алия бу үтенечкә һич гаҗәпләнмәде. Аны күрүгә күптән таныш бер талпыныш сискәндереп өлгергән иде инде. Мәскәү галименең һәр сүзне җайлый баруы, ярдәмгә әзер торуы да җанны тынычландырырга ярады. Өйдә алмагачларга кагылышлы берәр фикер әйтәсе дә бардыр, бәлки.

Рушания белән Булат, песи балалары кебек бер-берсенә елышып, диванда китап укып утыралар иде.

— Кызым, таныш! Булат әйткәндер инде, Мәскәүдән үк килгән. Аннары самавыр куярбыз,— әтиең дә исән кебек булып китәр,— җиз самавырны!

Алия кунакны үз кабинетына алып керде.

— Ничә бүлмәле сезнең бу зиннәтле сараегыз? Менә сиңа авыл! — Кабинеттагы йомшак креслога чумгач, академик соклануын әйтеп салды.— Шәп көйләгәнсез, ә?

— Колхоз йорты бу. Кызым кияүгә чыккач күчендек. Ул укыта, кияү белән мин — колхозныкылар.

— Ирегез үлгән икән, ә?

Күңелдәгене туп-туры әйтеп салулары яхшырак икән. Кайчак сизеп торасың: аяныч хәлеңне белеп, артыңда «аһ-уһ» киләләр, күзләрендә кызгану ярылып ята, авыз ачып сүз катмыйлар. Бу әнә маңгайга бәреп сорады. Чыдасаң, чыда, авыр булса, ела да җибәр.

— Ун ел инде. Әнисләр беренче тапкыр чәчәк аткан ел иде.— Алия хәтта елмая-елмая сөйләргә тотынды.— Мин мең капчыкка заявка биреп кайттым. Васимгә әйткән идем, көлә. Җүләрем, алманы капчыкка җыймыйлар, әрҗәләр кирәк булачак ди. Мин сугышка кадәр әтинең базардан ярты капчык алма алып кайтуын гына беләм, бу кадәр зур уңышны ничек җыюларын башыма да китерми идем.

— Консерв заводын кайчан салдыгыз?

— Беренче уңышлар бик яхшы чыккач, җилкенеп тотынган идек. Озаккарак сузылды. Васим аны күрә алмады инде.

— Әйбәт завод, җиһазлары заманча көйләнгән.

— Краснодарга барып өйрәндек. Мин дә бардым. Васим җибәрде, күреп кайт ди. Белгечләреңә киңәш бирергә яхшы була ул. Хәзер шул сүзнең бик дөрес булганын гел тоеп йөрим. Васим дөрес әйткән.

— Нигә гел «Васим» дә «Васим» инде ул?

— Минем өчен алмагачлар да, Вәсим дә — бербөтен. Минем гомер икегә бүленгән: «Вәсим барында» һәм «Вәсимнән соң».

Алия комач булды. Гадәттә, ирләр белән сөйләшкәндә, ул рәсмилекне сакларга тырыша. Бу юлы барып чыкмады. Шул хәлен сизеп: «Уф!» — дип кенә куйды.

Алар газета-журналлар өелгән өч аяклы кечкенә өстәл янындагы креслоларга утырганнар иде. Алиянең тез буыннары, куллары ихтыярсыздан дерелдәп-дерелдәп китә. Кинәттән дөньясын рәхәтлек тутыруын тоеп, ул гаҗәпләнә. Шул ук вакытта аңа кыен да, оят та кебек. Карашлары академикның ап-ак, шоп-шома, озын бармаклы көчле кулларына төшкәч, җилдә каралган үз куллары белән чагыштыру Алияне чынбарлыкка кайтарды.

— Теләсәң, теләмәсәң дә, Вәсим абыеңны бик еш искә төшерергә туры килә. Хуҗалык зур. Вәсим биргән киңәшләрнең гел кирәге чыгып тора.— Ул, мөлдерәтеп, галимгә карады.— Сез аның нинди кеше икәнен белмисез.

— Беләм шул.— Мәскәү кешесе, сүзенең Алияне шатландырачагын сизеп, бераз көттереп алды.— Ул чыгарылыш имтиханнары тоткан елны, мин урман техникумы биләмәләрендә кыргый алмаларны өйрәндем. Кызыксынып китеп, имтиханнарга да кергәләдем. Вәсим Субаев дигән студент урмандагы кыргый җимешләр турында сөйләргә тотынды. Шулкадәр белеп, мавыгып тасвирлады ул, минем андагы алмаларны барып күрәсем килде. Урманчының өенә киттек.

— Шакмаклы костюм кигән идегез! — Алиянең хәтере ачылды.— Мин дә бар идем бит инде ул чакта.

— Сез агроном идегез. Бу юлы мине танымадыгыз гына.

«Күреп өлгермәс борын җанны айкап алдың!» — Алия үз уенан үзе кызарып чыкты. Нәкъ шул вакыт Рушаниянең:

— Әни! — дигәне яңгырады.— Табын әзер. Әйдәгез, самавыр чәе эчик!

Табын янындагы әңгәмәне Булат алып барды. Аның укымышлы кунактан сорап каласылары күп икән.

— Мәскәүдә яшәп, авыл белән бәйләнмәсәгез, эш беткән идеме инде сезгә? — дип башлап сорады ул.— Хаер, нәтиҗәсе академиклыкка килеп чыккач, нәрсәгә бәйләнүнең әһәмияте калмый.

— Яшьрәк икән киявегез, Алия Каюмовна.— Мәскәү кешесенең Булат белән сөйләшәсе килмәве сизелеп тора.— Ярый, өйрәнер әле. Картаерга күп кирәкми.

— Ә менә минем һөнәр белән Мәскәүдә эш табып буламы?

Булатның бу сүзләре һавада эленеп калды. Алия аның тозсызлыгын яшьлек баласеннән генә күргән Мәскәү галименә тагын мөлдерәтеп карады. Юк, аңа озак карап тору мөмкин түгел иде. Хатын, юк йомышын бар итеп, кече якка керде. Кузгалып китүгә, гәүдәсендә академикның зәңгәр нурлы күз карашын тоеп, тагын аптырады. Аннары ул үзенә чыннан да кирәкле эш тапты: кунакка урын-җир рәтләде. Булатка дип бүленгән аерым бүлмә бар иде, шундагы диванны таратып салды. Репродукторда:

...Тимим күңелемә:
Өзгәләнсен, янсын!
Кеше кайчак үзен
Кичерә дә алсын! —

дип җырлыйлар. Алиягә киңәш бирәләр, диярсең.

* * *

Иртән идарәсенә барып күренүе булды, ишек төбендәге секретарь кыз: «Абау! Күз тимәсен, Алия Каюмовна, бигрәк тә чибәр инде сез! — дип, председательнең котын алды. Алия аны-моны сөйләшмәстән:

— Комиссия киттеме? — дип сорады.— Хәмдүнә килсә, миңа кер-сен әле!

Бүген үзенең аеруча матур икәнлеген бу кыздан башка да белә иде Алия. Матур икәнеңне тоюның никадәр рәхәт икәнен дә аңлый ул. Мондый уй кыюландыра, кеше арасында үз сүзеңне әйтергә көч индерә, кирәксә, яман эштән йолып кала, шәфкатьле булырга өйрәтә: «Матур икәнсең, һәр ягың күркәмлек күрсәтсен, кешеләр соклансын!»

Төне буе керфек какмый үзалдына елмаеп ятса да, Алия һич арымаган иде. Өстенә дә сирәк очракларда гына кия торган яшел костюмын сайлап алды. Зөбәрҗәт кашлы алкасына килешә ул. Күзләренә дә.

— Рөхсәттер бит? — Хәмдүнә иде бу.— Керергә кушкансың икән. Нәрсә, бригадирлыктан алыргамы? Кая куярсың икән инде: кыргамы, фермагамы?

— Ашыкма, исәнләшик әле башта! — Алия торып басты.

— Менәтерәк! Бигрәк чибәрләнгәнсең! Бик дөрес тә иткәнсең, болай киенүеңне әйтәм әле! Иртәгә үзем дә шулай киенәм! Эзләп таба алсам, теге эре бизәкле йон күлмәкне киям. Дустан дошман күп: алмагачлары бетте дип, безнең кайгырганга сөенеп йөрмәсеннәр! Әйеме, сердәш?

— Тукта, сабыр ит. Мин сиңа теге галим киңәшен әйтәм: алмагачларны бик тиз төпли башларга кирәк. Хәзер үк. Җәй буе эшләрбез. Шефлардан да сорарбыз, Исмәгыйль Ишмиевич ярдәм итми калмас.

— И-и, карале! Ничек үзебез шуңа тотынырга кирәклеген чамаламаганбыз, ә?

— Миңа бу фикерне Биктимер бабай да әйткән иде. Больницадан кайткан көнне. Бакчаның гамәлдән сызылып торуы да яхшы икән, без аны аңлап җиткермәгәнбез. Бу хәл иркенләп эшләргә җай бирә.

Хәмдүнә чыгу ягына борылгач, Алия, тагын урыныннан торып, аңа каршы басты:

— Кара, Хәмдүнә, минем кебек хатынны аулак җиргә чакырсалар, ни дигән сүз була ул? — дип сорады.

«Академик чакырдымы?» — дип сорамады Хәмдүнә. Монысын үзе чамалады. Көлмәде дә, хәтта башка чактагы кебек ашык-пошык сөйләргә дә тотынмады. Шактый ара уйланып торды.

— Мин болай дим: мине ник чакыруларында гамем юк, күрәсем килсә, әйтер сүзем, ишетер киңәшем булса, барыр идем. Күңелең ни теләсә, шуны әләм итеп алга барасың. Чакырган кешедә синең эшең юк, аны белеп тә булмый. Үз күңелең сафлыкта икән, кешедән шикләнмә!..

Академик Алияне Казан кунакханәсенә чакырып китте. Бу тәкъдимне ни дип аңларга да белмәде Алия. Хәмдүнә, әнә, ачты да салды. Хәзер аңа оят, ничек үзе шул гади хакыйкатьне белмәгән ул? Егеттән шикләнеп, әллә ниләр уйлап, аптырап бетте. Югыйсә, барысы да бик гади — аралар якын чакта, тагын бер күреп, сөйләшеп калырга иде! Нигә үз-үзеңне тышауларга? Алия үз күңеленең сафлыгына ышана лабаса!

* * *

Кеше үз-үзен ахырынача белеп бетерә алмый икән. Шоферы Миша гадәттә туктала торган йортка кереп калгач, Алия чәчен төзәттерергә, купшыланырга кирәк тапты. Гомер буе үзе генә тарап йөрткән чәчләре аңа артык гади булып тоелды. Кала парикмахерлары эшсез утыра иде. Төрлесе-төрле яктан Алиягә сорау яудырырга тотындылар:

— Тигезләп кисәргәме?

— Химик бөдрәләтү кирәкмиме? Карага буйыйкмы?

— Юк, кисмичә генә, буяу да тидермичә, матур иттереп җыештырыгыз әле зинһар өчен!

Чәчен купшы иттереп күпертеп кую аңа затлылык, абруйлылык

төсмере кертте. Хатын эчтән генә: «Әй, йөргәнмен икән гомер буе үз бәямне үзем белмичә!»,— дип көлеп алды.

Урамга чыгып, бераз баруга, ана дөнья тарайгандай тоелды. Атлавы ук җайсыз иде. Аның чәченә парикмахер уннарча кыстыргычлар тертеп чыккан, хәзер шулар аны баса, сытарга тырыша кебек. Җитмәсә, шул кыен хәлне урамдагы бөтен кеше белә, барысының да күзләре Алиядә генә шикелле.

Академик урнашкан кунак йортына керү белән, ул көзгеле бүлмәне эзләп тапты, башындагы ясалма күпертмәләрне сыдырып төшерде, ничек җитте шулай тарады да, шома чәчләрен уртадан аерып, колак яфракларын күмдереп куйды.

Галим бүлмәсе, колхозның гомуми җыелышы диярсең, аяк басарлык та түгел иде. Күңеле киң икән. Алия килеп кергәч, ул аз гына да тартынып-нитеп тормастан:

— Менә яхшы! — диде.— Әйдә, узыгыз, утырыгыз! Дөресен әйткәндә, мин Сезнең килерегезгә ышанмадым. Татар хатыннары тарсынучан булалар.

— Миңа гадәтләрне онытkалап торырга да туры килгәли. Бакча академигын тагын кайчан күрә алам әле?

Бүлмәдәгеләр барысы да галимнең үзе кебек үк гадиләр, инсафлылар. Алар Алиягә дә, күптәнге танышларын күргәндәй, гади мөнәсәбәттә булдылар. Араларында ике кыз да бар. Алиянең нәкъ шуларга карап утыруын күргәч, егет таныштыруын алардан башлады:

— Авыл хуҗалыгы институты кызлары,— диде.— Без хат алышабыз. Кызларның алмагачлар фәне буенча кызыклы күзәтүләре бар.

Алия турында кызларга аны-моны әйтүнең кирәге чыкмады. Алар:

— Без Алия Каюмовнаны беләбез,— диделәр.— Ел саен ул колхозга алма җыярга йөрибез без. Алмагачларның сортлары — искиткеч!

Алия бер мәлгә онытылып торды. Кызлар белән сөйләшкәндә, галим тагын да чибәрләнә кебек. Әллә кайда калган яшьлектәге көнчелек сыман наян хис уянгандай булды. Бу халәтенә гаҗәпләнеп, председатель узалдына елмайды. Бераздан ул гомуми сүзләргә кушылып китте.

...Колхоз машинасының арткы урыннарына кереп поскач, Алия сумкасыннан уч төбе кадәр генә ап-ак каты кәгазь кисәген алды. Академик, кирәге чыкканда, хат язуны үтенеп, визиткасын биргән иде. Шуңа карады да председатель кунакханәдәге сөйләшүләрне күңелennән кабат кичерде. «Инде төшендегезме: бакчаны гамәлдән чыгарып тору сезгә ун ел буе әлеге мәйданда иҗат итү мөмкинлеге тудыра». «Төшенмәсәм, ни була?» «Калганы, сөйкемле ханым, сезнең нинди хуҗа икәнлегегезгә бәйле». «Көтегез алайса, мин дә сезнең фәнгә җим эзләүчеләр исемлегенә языламl» «Көтәм, хатларыңны көтәм, яме?!».

Алиянең бөтен өмете татарны гомер-гомердән коткарып килүче өмәләрдә иде. Тик бу юлы өмәне киңрәк итәргә кирәк. Колхоз, мәктәп балалары, шәһәрдәге шефлар. Исмәгыйль Ишмиевич заводына, бөтен шартын туры китереп, хат яздылар. Хәбәрнең барып җитүен чамалап, ул директорга шалтыратты.

Алия шикләнә иде. Зур завод директоры дәрәҗәсенә ирешкән Исмәгыйль, Вәсимнең якын дусты, Алия уйлап чыгарган «башбаштаклыкка» кул куярмы? Шикләнүе рас килде, тавышы ук башка иде Ишмиевичның, калай шалтыраган кебек.

— Мин синең ул хатыңны ертып аттым. Берәүгә дә күрсәтә алмыйм, оят. Ничек син коммунист башың белән шул юлга бастың? Бер яктан җир сызып ташланган, икенче яктан, шуңа күпме көч түгүне сорыйсың.

— Җирнең тик ятуы отышлыракмы? Киңрәк алдырып уйлыйк әле!

— Син ул эшләреңне кысасына керт, сметасын төзе, рөхсәтен ал!

— Борын төбендә язгы чәчү торганда, мин шул эш артыннан йөримме?

— Алай катлаулы булса, йөрмә, тик утыр, бакчаңның печәнен җый!

— Без печәнгә калмаган, Ишмиевич! Су сибеп үстерәбез без печәнне, гектарыннан йөзәр центнер азык бирәмлеге алабыз. Печән түгел, алма кирәк безгә! Ярар, ярдәм сорамады дип уйла, тыныч яшә!

Ахыр килеп, Алияне яңа алдашуга күндерде Исмәгыйль директор.

— Өмәңә ни кирәксә, шуны җибәрәм, тик хатыңны башкача яз! Әйтик, су сибүле көтүлекләрне карап чыгасы бар, торбаларын ялгарга кирәк диген. Шимбәгә кешеләр көт, җибәрербез.

Корыган алмагачларның кәүсәсен кайда урнаштыру үзе бер бәла булды. Аларны утын итеп ягу турында Алиянең ишетәсе дә килмәде. Шулкадәрле затлы агачка ут төртү өчен кеше җаны түгел, вәхши җанвар кирәк. Ул, урман хуҗалыгына барып, белешеп кайтты. Элекке елларда алмагач кәүсәсеннән эш кораллары ясаганнар, сын сурәте чокучы рәссамнар да бу агачны кирәксенгәннәр. Председатель шул шөгыльдәге оешмаларга шалтыратырга тотынды.

— Сезнең эшкә яраклы агач бар, шимбә көнне килсәгез, алып китәргә була.

Алия үзенең бу сәер хәбәре белән әллә кемнәрне шатландырачагына ышанган иде, тик, ни гаҗәп: телефон чыбыгының аргы башындагыларның берсендә генә дә, ичмасам, кызыксыну чаткысы кабынмады. Берсе:

— Сметада андый акча юк,— диде.

— Безгә акча кирәкми,— Алиянең тантаналы тавышы сүрелә төшкән иде инде.— Күпме кирәксә, шулкадәр алып кына китегез!

— Бушлай кергән товарны фондка ничек кертик соң без?

— Ай аллам, анысын үзегез карарсыз инде, мин белмим.

— Юк инде, иптәш, кем, Субаева, Сез, зинһар өчен, безне җинаять юлына бастырмагыз! Сез — колхоз, ә без — дәүләт оешмасы!

— Колхоз кемнеке соң, сезнеңчә? Кирәкме сезгә алма агачы материалы, юкмы?

Берсеннән-берсе ахмаграк җаваплар ишетеп, хәйран калса да, Алия алмагач кәүсәләренә икенче тормыш бирергә тырышуыннан туктарга теләмәде. Урман хуҗалыгындагы элекке дусларына кабат мөрәҗәгать итте. Урманчыларның махсус цехында бу агачтан балта осталары өчен эш кораллары ясарга алындылар.

Язгы чәчүгә кадәр өч мәртәбә җыелган өмәдән соң, алма бакчасының шактый өлеше төпләрдән арындырылгач, Алия Мәскәүдәге дустына хат салды. Председательгә аннан башка да күп язу-сызулар белән эш итәргә туры килә. Тик бу хатны язар алдыннан Алия гаҗәеп бер дулкынлану сизде. Нәрсә инде бу? Сумкасында йөртә торган кеч-кенә көзгесенә карады: маңгаенда дүрт сыр, бите ияк астына салына башлаган, күзләре күзлек сорый. Шулай да җанны тартып торучы кешең булу рәхәт икән. Рәхәт кенә дә түгел, кирәк икән ул андый кеше. Әле шушы академик өйрәтеп калдырмаса, үзенең дөньяда барлыгы белән күңелләрне җилкендермәсә, бакчаны терелтү артыннан бу кадәр үк кайнарланып йөри алыр идеме икән ул?!

Хатына да күңеле кушканнарны язды Алия: «...Дөньяда сезнең кебек кешенең булуы әйбәт икән. Сез хәзер минем өчен — өмет яктысы. Мин аны шушы бөеклегендә, саф килеш саклаячакмын...»

Хаты төп эше, бакча турында иде аның, әлеге сүзләр арага гына кысылып-кысылып керделәр. Кабат укып карады, оят кебек иде. Шулай да язганын ертып ташларга теләмәде.

* * *

Алиянең күңеле күтәрелгәннән-күтәрелә барган көннәрнең берсендә Рушания мәктәптән кара коелып кайтты. Булат өйдә юк. Алия дә район үзәгенә китәр алдыннан өстен-башын төзәтергә генә кергән иде.

— Авырыйсыңмы әллә, кызым?
— Юк алай...

Кыз, әнисенә бик нык үпкәләгән чакта гына, шулай теләр-теләмәс сөйләшә. Гадәттәгечә булса, Рушания хәзер, табын тезеп, чәй эчәргә тиеш. Ник һаман өстәл тирәсенә килми? Йокы бүлмәсенә кереп дә батты.

— Кызым, минем китәсем бар, ник чыкмыйсың? Сөйләшмисең дә?

— Китәсеңне ишеттем инде.— Кыз әнисенең каршына чыгып басты.— Китәсең икән шул.

— Кая китәм? Кемнән, нәрсә ишеттең?

Кыз, сорауларның ихласлыгын тоеп, бераз ачыла төште.

— Мәскәү академиягына кияүгә чыгасың дип сөйлиләр. Имеш, ул беренче килүендә дә синең арттан гына йөргән, син дә аның янына Казанга баргансың, парикмахерскига кергәнсең...— Ул, әнисен нинди утка салуын аңлап алды.— Беләм инде, чәчеңне үзгәртеп йөргәнең юк-югын.

— Ник булмасын? — Алия, комач кызарып, башын аска иде.— Кияүгә чыгар өчен түгел, гомер эчендә бер, үземне башкалар кебек үк хатын итеп тоеп алып, парикмахерга кергән идем шул.

— Алай булгач, дөрес сүз сөйлиләрдер инде?

— Гайбәтчеләр гомер-гомергә, бер чеметем дөрес сүздән әләктереп алып, дөньяны болгата башлыйлар, кызым.

Алиянең елыйсы килә башлады. «Менә сиңа хисләрнең саф бөеклеге». Район үзәгенә баргач та, кергән һәр бүлмәсендә, гел эчпошыргыч хәбәрләр генә ишетеп йөрде. Бераве аңа алмагачлардан чистартылган җиргә чөгендер утырттырачаклар икән дип, үзәгенә үтте.

Моннан да ахмаграк тәкъдимнең булуы мөмкин түгел иде. Алия аны җитди итеп тыңлап та тормады. Тик кергән һәр җирдә очраган һәр адәм шул ук сүзне кабатлый башлагач, аның тәкате корыды, райкомга, беренче секретарь Уткузовка аңлатып чыгарга кирәк тапты.

Уткузов — өлкән кеше. Алияне яхшы белә. Вәсим белән Алия урман өендә яшиләр иде. Читтән торып уку мәшәкатьләрне арттырды. Бала карарга да вакыт тими, ул — авылда. Вәсим һәркөнне өем-өем китап тәяп кайта, кичләрен контроль эш язалар, имтиханнарга әзерләнәләр.

Бер кичне аларга урман хуҗалыгы белән танышырга чыккан житәкчеләр керде. Хуш исле чәй пешерде Алия, үзе кайнаткан вареньеларын чыгарды. Урман туфрагында үскән ярмалы бәрәңге, тозланган яшелчә, гөмбә куйдылар. Ул елны күп иттереп күркә үстергәннәр иде. Кайнар бәрәңге янына күркәнең салкын итен өеп китерделәр. Кунаклар сөйләшми-нитми генә сыйландылар, чәй ризыкларыннан соң Алия бер кәнди кыздырылган чикләвек тә куярга онытмады. Низам Фатихович Уткузов кына нигъмәтләрдән үзенчә нәтиҗә чыгарган икән.

— Ху-уш,— дип сузды ул.— Сез шәп көйләгәнсез. Ашау — байдан. Саф һава. Урманда бушлай үсә торган нигъмәт мул!

— Нигә? — Вәсим тыныч иде.— Аларны һәркем җыярга хаклы.

— Хикмәт анда түгел. Сез менә шул рәхәт тормышка күнеп китәчәксез хәзер. Тәпәннәрегез тулгач, базар юлына чыгарга гына кала.

Вәсим белән Алия икесе берьюлы көлеп җибәрделәр.

— Нигә? Урманда яшәүнең шул файдасын да күрмәгәч...— дип, Алия дә шаяртып алды.— Вәсим ташып торыр, мин сатып бирермен. Безнең авылның бер әби безне чикләвеккә алып бара иде дә: «Ягез, балалар, сез бөген торыгыз, мин җыеп торыйм!» — дип әйтәдер иде.

Беренче секретарь көлмәде.

— Мин аңлыйм: Вәсимнең урыны — урман, ул — урман өчен туган җан, Алия хакында уйларга кирәк! Авылларда укымышлы кешеләр бармак белән генә санарлык. Югары белемгә ирешкәч тә урманчыларга аш пешерерсеңме?

Шушы сөйләшүдән соң Алия белән Вәсимнең тормышы авылга

күчте. Урман өенә яшь техник урнашты. Алия Акланның агрономы булды. Озак та үтмәде, яшь коммунист Алия Субаеваны председательлеккә тәкъдим иттеләр...

— Ишеттем, ишеттем! — Уткузов Алияне үз итеп каршылады. — Алмагачларыңны чөгендергә алмаштырырга ризалашмагансың. Дөрес. Ике нәрсәне бутарга ярамый.

— Кай арада ишетеп өлгердегез, Низам Фатихович?

— Монда ишеттерәләр. Иренмәсәң, тыңлап кына утыр: синең академикка киявгә җыенуың турында да, хатлар яудырып торуың хакында да минутында җиткерәләр. — Секретарь Алиянең бу сүзгә мөнәсәбәтен ачыкларга теләгәндәй сүзен суза төште. — Шула-а-ай.

Иреннәре калтырана башлагач, Алия урыныннан торып, тәрәзә ягына узды, секретарьга аркасы белән борылды. Күз яшен күрсәтмәскә иде! Мондый чакта акланып маташудан да авыррак хәл юк. Әңгәмәдәшенне ышандыруы да кыенлаша. Шуңа күрә Алия, акланмый-нитми генә, җавап табарга тырышты.

— Тол хатыннарга гайбәт тиз ябыша ул, аңа ышануы да җиңел, — председатель һич кирәкмәгән бу сүзне башка якка борырга теләде. — Мин әле бүген генә бу хакта кызым белән аңлаштым, сезгә дә бөтенесен кабатлап утырырга кирәкмәстер. Сезгә йомышның зуррагы бар, Фатихович. Планда каралганнан тыш ашламалар кирәк безгә, алмагачларга.

— Ничә гектарга?

— Төгәл әйтүе кыен. Әнисләребез исән калды. Корыган бакчаның яртысы чистартылды инде. Әле тагын ваклап-ваклап эшлибез. Шефлар бик булышты. Кулымнан килсә, Исмәгыйль Ишмиевич эшчеләренә орденнар тагар идем!

— Күзгә таба әллә тагын бер күтәрелеп алыргамы, Алия? — Секретарьның бөкрәя башлаган гәүдәсе тураая төшкән кебек тоелды. — Гыйльми комиссия ун еллык дип хисаплаган эшне син бер тотынуда бәреп алсаң, ә?!

— Яхшы кешеләргә туры килдек без. Урман хуҗалыгы корыган каусәләр өчен шактый акча да күчергән әле. Өмә көннәрендә бушлай сыйлаган идек, казна такыраймасмы дип, шүрләбрәк тә йөрдек. Хәзер хәлебез җиңеләйде. Бу елда ук бетмәсә дә, икенче язга эш түгәрәкләнә.

— Күзге өмәне тагын да киңрәк итәргә булыр дип уйлыйм, бөтен районны тартырбыз. Шундый чакта да берләшмәгәч, бер район булып яшәвебездән ни мәгънә кала?

* * *

Акланлылар, корыган бакча мәшәкатен күздә тотып, уракка иртә төште. Тымызык яңгырларга кадәр аларның ашлыгы бөртекләп җыеп куелган иде инде. Аннары, яше-карты, тракторы-машинасы бакчага ябырылды. Берәүләре яздан чистартылган мәйданга яшь үсентеләр утырту өчен әзерлек күрде, башкалар калган урындагы корыган агачларны төпли, чистарта иде.

Урманчылар алмагач каусәләрен чистартканда, ботак-чатак өемнәре хасил була. Аларны су буена, ачык аланнарга ташыдылар. Аерым кешеләргә чыбык-чабыкны яндырырга куштылар. Учаклар үрләттеләр. Башта бакчадагы һәр хәрәкәтне күзәтеп кенә йөргән Алия, ялкын яктылыгын күргәч, Хәмдүнәдән аерым эш сорап алды.

— Мин дә учак ягыйм әле, Хәмдүнә!

— Ягарсың, тик белеп тотын, монда да норма бар! — Хәмдүнә председательнең аерым эшкә бәйле булуын теләми иде.

— Аңласана хәлләремне! Күңелем шул утка тартыла!

Мин сине һич аңламыйм дияргә бригадирның теле бармады.

— Ярар, — диде. — Әнә, карамалы чишмә янындагы өемнәрне сиңа тапшырам, анда бик күп түгел. — Башкача өйрәтеп тормады. Алияга

ярдәм кирәк булачагын гына уйлап алды.— Мин дә янында барырмын әле.

Чыбык-чабык өемнәрен әллә ни зур итмәгәннәр. «Вәсимнең икебез өчен генә яккан учагы кебек»,— дип күңеленнән чагыштырды Алия. Бер учактан икенчесенә күчеп, ут үрләтте, үзе яшьлегендә кичергән бәхетле мизгелләргә әйләнеп кайткандай очында. Шаян ялкын телләренең биешүен күзәтүдән аның башында бер сорау уянды: гомереннең кайсы мизгеле бәхетле синең? Ут юри шаяра, юри сорый кебек. Үзе сорый, үзе бик яхшы хәтерли, Алиядән дә яхшырак белә шикелле. Чөнки Алиягә бәхетнең ни икәнлеген, нинди леген ут аңлатты, нәкъ шушындый учак, беренче булып, аның күңелендә бәхеткә ышаныч уятты. Ул кечкенә учак бик ерак та калган сыман иде инде, беркая да китмәгән, бәхетле мизгел кул сузымында гына икән. Әнә бит: Вәсим учакка чыбык-чабык ташый, ялкыннар биешә, карт чыршылар шыгырдап-шыгырдап куя, кошлар тынычсызланалар. Ут бирде бәхетне Алиягә, зәмһәрир суыклык тартып алды...

— Хәмдүнә-ә-ә! — Алия, саташа башлавыннан куркып, кычкырып җибәрде.

— Монда мин, монда! — Хәмдүнәнең килеп җиткән чагы икән.— Кай арада шулкадәр учак үрләттең? Ник барын бергә ягасың? Берәм-берәм генә яндыр, куркыныч бит.

— Юк. Бик рәхәт әле! Янсын. Безгә генә янарга димәгән.

* * *

Икенче яз өчен эшне азрак калдырырга күпме тырышсалар да, алмагачларның шактые кара көеп утыра иде әле. Алия икенче язны да мең мәшәкать өстенә бакча кайгысы белән каршылады.

Бер кешене кырыкка бүләргә йөргән чакта бүген-иртәгә чәчүгә төшәргә дигәндә, председательне Казанга, бакча трестына чакыртып, телефон шалтырады.

— Иртәгә генә ярамасмы? — дип өзгәләнде Алия.— Бүген машина-тракторларның әзерлеген барламакчы идем.

— Хәзер үк юлга чыгыгыз! Трестның терлек азыгы хәзерләү бүлегенә керегез!

Бу бүлектә колхозның бер генә йомышы да юк иде. Эше бүленгән кешенең ачуы чыгучан, ачулы кеше кызып китүчән. Алия дә әлеге бүлеккә ачуы кабарып, дуылдап барып керде.

— Исәнмесез! — диде дә, җавап-сәламләү дә көтеп тормастан, тел очындагы соравын бирде.— Киңәшмә-фәләнме соң?

Җыйнак бүлмәнең түрендә искиткеч чибәр япь-яшь ир утыра. Дегет кебек кара чәч, сызып ясагандай тигез каш, уймак кадәре генә авыз, кып-кызыл иреннәр. Чия төсле бәрхет костюм кигән, алсу күлмәк, коңгырт галстук.

Алия егетнең, торып, аңа каршы килүен көтте, буй-сынын күрергә теләде. «Бу кадәр чибәрлек ир-атка кирәкмәс тә иде инде»,— дип уйлады. Егет исә буй-сынын күрсәтергә, Алия каршына килеп басарга уйлап та карамады. Ул хәтта башын да күтәрмәде. Маңгае астыннан гына карангалап, муенын уңга-сулга боргалап, бик мөһим фикерләргә чумгандай утыруында булды. Алия: «Басмасаң да билгеле, буең да шәп синең», дигән нәтиҗәгә килде. Әнә бит, урындык аркасы аның билендә үк тукталып калган. «И-и, дөнья, кемнәрнең үзәген өзәргә яраттың бу җанны?»

Егет, Алиягә сәлам биреп тормастан, турыдан-туры:

— Я, ничек, эшләргә ниятең бармы синең Аклан колхозында, әлләә?..— дип, кинаяле сүзгә күчте.— Югыйсә, ул алмаларың кыйммәткә төшә.

Сүзнең алма бакчасы турында барачагы Алиягә көч бирде.

— Акчадан да кыйммәт булмаслар,— диде.— Акчабыз бар әле без-

нең. Алмалардан калганы гына да ике ел буена бурычка-фәләнгә батмыйча яшәрлек. Фермаларыбыз табыш китереп тора. Акланнарның йөзе ак. Мин тәпи йөреп киткәннән бирле шул авылда эшлим, энем. Сез мине кем беләндер бутадыгыз ахры?!

— Мин синең энең түгел, трестның бүлек мөдире Мәмишев.

— Хуш! Алайса, минем белән дә «сез» дип сөйләшүегезне сорыйм, иптәш Мәмишев. Исемем — Алия, әтием — Каюм, фамилиям — Субаева. Акланлылар председатель итеп сайладылар, хөкүмәт РСФСРның атказанган агрономы исеменә лаек тапты, орден бирде.

Мәмишевның иреннәре елмайды. Әллә ни иде бу: карашында — мыскыллау, үзе елмаеп азаплана.

— Менә болай: әгәр тыныч кына эшлисегез*килсә, моңарчы яшереп яткырган дүрт йөз гектар җирегезгә азык чөгендере утыртасыз. Безгә быелгы яз өчен генә булса да, шулкадәр мәйданга чөгендер чәчү кирәк. Кая барып бәрелергә белми йөргәндә, миңа бу фикерне Булат әйтте. Киявегез бугай әле. Мин каян алыйм ул җирне? Ә өстән кушалар. «Булмый» дия алмыйм бит инде?!

Алия агарынып чыкты. Аның бу кыяфәтен ризасызлыкка юрап, Мәмишев тагын кырыслана төште:

— Инде элекке авторитетыгызга аркаланып, киреләнәсез икән, бигайбә, ханым! Башка эш эзләгез! Табарсызмы — белмим. Чөнки мин ризалашмыйча киткәннәрне җиз иләктән үткәзәм, әйтик, КРУ иләгеннән. Ә? Сездә КРУлык эш муеннан! Элекке ирегезнең дусларына черек агач сатып, акча ясагансыз. Казандагы дусларыгызны бушлай сыйлап җибәргәнсез. Ә?!

Мәмишев торып басты. Алияне аның буе кызыксындырмый иде инде. «Башы кечкенә шул,— дип уйлады ул.— Балкашык кадәр чырайда күз кебеге дә, борыны да, авызы да, колагы да бар. Акыл өчен урын азрак калган». Алиянең әбисе еш кына: «Көлле тавилен ахмак», дигән гарәпчә мәкальне кабатлый иде. Һәр озын ахмак, мәгънәсендә. Туры килсә дә килер икән!

— Я ни дисез?

— Бездә чөгендернең үз мәйданы бар. Хәтта колхозчыларга да яртышар тонна бүлеп бирәбез. Бакчаның төпләнгән өлеше буш түгел, без аңа көздән яшь үсентеләр утырттык бит инде. Чиста җирен көз өчен әзерлисе бар, ашлап куярга кирәк. Бусы — бер, икенчесе — КРУ мәсьәләсе. Аны, һичшиксез, китерергә кирәк. Кырасын кырырлар, арулап калырбыз. Өченчедән, минем «элекке ирем» юк. Минем ирем — Вәсим Субаев. Бер ул, минем өчен һаман да бар ул. Башка ул кешенең исеме белән тел тибрәтмәвегезне таләп итәм! Хушыгыз!..

* * *

Хәмдүнә, түр диванда йоклап яткан Алияне күргәч, юк сәбәпне бар итеп, ишек төбенә кире чыкты. Рушаниядән сорады:

— Нәрсә бу, балам? Төсе качкан күренә. Теге чакта больницадагы кебек.

— Кичә Казаннан кайтканнан бирле шулай ята. Бакча өчен тарткалашкан. Үзе сөйләмәде, Булат кына әйтте. Казанда аның танышы бар, шуның аша белеп тора ул.

— Ул Булат та бер тиенлек койрык таккач, ун тиенлек эткә әйләнде.— Хәмдүнә, җилләнеп түр якка атылды.— Карале, Алия, кичә без Сак-Сок хәлендә калганбыз бит!

Алия күзләрен ачты. Сөйләшәсе килми иде. Хәмдүнә сизмәмешкә салышты.

— Ашыга-кабалана йөрүем шуңа: кичә обкомнан мине эзләткәннәр. Әүвәл үзем туры килмәдем, аннары тоттым да шалтыраттым.

Алия торып утырды. Бу Хәмдүнә үлгән җиреннән сикертеп торгызыр!

— Кем кирәк? — диләр. Мин әйтәм, авыл хуҗалыгы секретарен бирегез! Үзем тоташтыруларына бик ышанып та житмәгән идем. Аклан колхозы дигәч, бирделәр, Алиякәем. Тавышы шулкадәр матур!

— Нәрсә хакында сөйләштегез соң? — Алиянең кызыксынуы йөзенә үк бәреп чыкты.— Миңа аларның матур булуларыннан ике тиенлек тә яхшылык юк.

— Алай димә! Үзең үк кешенең бөтен нәрсәсе гүзәл булырга тиеш, Чехов шулай кушкан дип әйтәсең бит! Матурлык эчтән бөркелеп чыга ул. Күңеле ямьсез кешенең тышкы кыяфәте, бер тозсыз сүз әйтүгә, сүнә дә китә.

— Анысы шулай.— Алия кабат Мәмишевне күз алдына китерде.— Соң? Обкомда да чөгендер утыртуны даулыйлармы?

— Авызыңнан җил алсын! Юктыр. Тавышлары җайлы, шулай да ник эзләгәннәрен әйтмәделәр, чакырдылар гына. Сине язгы чәчү артыннан йөридер дип, минем белән генә хәл итмәкчеләр иде дә, юк, дидем, бакча эше булса, ул үзе барыр, дидем. Ул — аңа шатлык кына дидем.

— Шатландырмыйлар шул әле. Барган бер җирендә, яңь-яшь нәрсәләр, ата каз кебек муен катырып, тиргәп чыгара башласалар, егыл да ул.

— Әйдә, тиз генә җыен әле! Миннән әллә ни чыкмас, урысчам да такы-токы. Әшне бозып кына куярмын.

— Мишаны чакырырга кирәк инде алайса! Кайда икән ул?

— Идарәдә утыра. Сиңа ни булганын да әйтми, телсез калган.

— Председательне йөртүче шундый булырга тиеш. Әйдә!

* * *

Алия партиянең өлкә комитетында, кирәкле кешене туры китерә алмыйча, бик озак ишектән-ишеккә йөрде. Инструкторлар чәчү хәлен генә сорыйлар:

— Кайчанрак чәчә башларсыз икән?

— Җиңү көненә түгәрәкли алырсызмы?

— Карап-карарбыз инде,— ди Алия. Ул бөртекләләр өчен әллә ни уфтанмый.— Бездә бөртекләләр күп түгел бит. Күбесен көздән чәчтек. Уҗым яхшы күренә.

Бүлек мөдире үзенә бер төркем кеше ияртеп килде. Тагын көтәргә кирәк булып чыкты. Күңел түрендәге өмет Алиягә барына да түзәргә куша. Мөдир Акланны яхшы белә. Бакчаны тикшертүдә дә үзе катнашты. Мәскәү белгечен чакыртырга кирәклеген дә бюрода ул кузгаткан диделәр.

Председатель колхозның үтенечен әллә язып үк керим микән дип уйланып, читкәрәк борылган иде, шулчак авыл хуҗалыгы бүлегенең ишеге ачылып, анда кешеләр күренде. Мөдир озата чыга. Ул кабинетка керергә торучыларны күздән кичерде. Карашлары Алиягә тукталып калды.

— Исәнмесез, Алия Каюмовна! — диде.— Сезне чакырып китерделәрме? Телефонограмма бар иде. Әйдәгез әле!

«Мәмишев хәбәренең куертылган нөсхәседер инде»,— дип куырылып калды Алия.

— Менә, танышыгыз әле! Кичә Мәскәүдән алынды бу телефонограмма.

Көткәненең киресенә тап булгач, бакча иясенең күңеле тәмам йомшарды. Тез буыннары калтырана, куллары дерелди. Авызын ачты, сүзе чыкмады.

— Я, ни дип җавап бирик инде? Алар яңа төрле алма үсентесе тәкъдим итәләр. Чәчүләрдән котылгач ук, Мәскәүгә җавап бирик! Ничәнче елга сорарбыз?

— Бакча көзгә әзер булачак.

— Ничә гектар турында сүз бара?

— Тулаем. Без былтыр ук яртылашын төпләдек бит инде.

— Галимнәр, ун ел кирәк дигәннәр иде.— Бүлек мөдиренең йөзе яктырып китте.— Мин сезнең нииндидер бер могҗиза ясавыгызга ышанган идем, шулай да бу кадәресен үк көтмәдем. Болай булгач, Мәскәүләрне дә шаккатырабыз икән әле! Җавапны тиз үк языйк, шулаймы?

— Шулай шул. Бирә алган кадәр бирсен алар, безгә алмагачлар бик кирәк.

* * *

Бер утка, бер суга кереп, аһ-ваһ килеп йөргән көннәрдә Булат кияү кунарга кайтмады. Бу хәлнең сәбәбен бик белергә теләсә дә, бүген-иртәгә бәби табарга торган Рушаниясенең кәефен саклау өчен, Алия сорарга җөрьәт итмәде. Тик кызының сабырлыгы беткән икән. Ул әнисенең йокы бүлмәсенә килеп керде, башка суккандай иттереп сорады:

— Син кайчанга кадәр безгә аяк чаласың әле, әни? — Бизәкле ситсыдан тегелгән йокы күлмәге аның йомрыланган гәүдәсенә шулкадәр килешә иде, ана баласының кыяфәтенә сокланып карап торды. Аның тупас сүзләренең мәгънәсенә төшенмәгәндәй иде.— Булат өйгә кайтмас булды бит инде.

Тиктомалдан ябыштырылган гаепне тыңлау авыр, тик кызының хәлен чамалап, аңа борчылырга ярамаганны аңлап алып, Алия сабыр итте.

— Тыныч кына аңлат әле! — диде.— Ник кайтмады Булат?

— Синең хакта. Ник шул җиреңә чөгендер чәчмисең? Булат барын да килешкән иде. Мәмишев безне Казанга алдырмакчы иде...

Алия хәйран калды: «Әнә кайларга ук үтеп кергәннәр! Куенында елан асрау шулдыр инде ул».

Председательнең тавышы кисәктән үзгәрде. Ул үзен өендә, авырлы кыз баласы каршында икәнен дә онытты кебек:

— Кызымны шәһәрдә яшәтсеннәр өчен генә мең гектарлы алма бакчасына җеназа укысам, мине табигать үзе каһәрләр, кызым!

Төне тагын йокысыз үтте председательнең. Тәрәзәдән язгы таңның яктылыгы сирпелүгә, ул ятагыннан күтәрелде. Аңа мөмкин кадәр тизрәк Булатны күрергә кирәк.

Идарәдә гадәткә кергән тәртип бар: колхозның һәр белгече, үз эш урынына аяк басканчы, иң элек бирегә килә, көне буе ни эшләячәге, кайда булачагы турында килешә. Алия һәркөнне ишектән беренче үзе керә, белгечләрен каршы алырга әзер тора.

Бу таңда Булат аның үзен каршы алды. Алия гаҗәпләнмәде: җанында иман әсәре булган ир-ат шулай итәргә тиеш кебек. Тик хәзер аның белән ничегрәк сөйләшергә икән? Кызының хәсрәтләнүен аңлатыргамы? Ана кешенең моңа хакы бар. Ирнең соңаруы яки бөтенләй кайтмый калуы хатыннарны нинди хафага салуын Алиядән дә тирәнрәк тоючы дөньяда юктыр, мөгаен.

Вәсим дә гел юлда була торган иде бит. Урманы авылдан шактый еракта. Караңгылы-яктылы чыгып китә, өйдәгеләр йокларга яткач кына кайтып керә. Хәер, Алиянең үз эше дә, шөкер, кайбер ирләрең дә күтәреп ала алмаслык. Вәсимне күрәсем килә әле дип, ташлап йөгерә торган түгел. Гомернең бер баскычында сайланыш алдында калдылар алар: я авырлыкларга түзәргә дә гомум эшкә җигелергә, я, яшәп калыйк әле дип, гаилә рәхәтенә чумарга мөмкин иде. Алияләр, Вәсимнәр буыны аның икенче ягы турында уйларга да теләмәделәр. Оят иде. Гомерләрен кешеләр өчен, авыл өчен, колхоз өчен бирелгән итеп тойдылар. Тик...

Бер кичне Вәсим, Алиянең аны көтәрдәй бөтен сабырлыгы беткәч тә, өйгә кайтмады. Хатын, киенеп, Хәмдүнәләргә керде.

— Нишлим? Карурманның кай тарафыннан гына эзләп табыйм аны?

— Милициягә шалтыратып карыйк! — диде Хәмдүнә.

— Вәсимнең анда бер йомышы да юк. Больницадан сорарга иде!

Врачлар белән Хәмдүнә сөйләште. Аннан ишетелгән беренче сүз ук аны чыгырыннан чыгарды:

— Иплэп кенә аңлатып булмыймыни? — дип, врачка бәйләнеп маташты.

Алия, барын да аңлап алып, урамга атылды, больницага...

Белә, ирне көтеп ала алмауның авырлыгын бик яхшы белә Алия. Шулай да кияүгә бу хакта сөйләү кирәкмәс. Үгетли дип, ялгыш аңлавы бар.

— Исәнмесез, Алия Каюмовна! — Булат моңарчы «әни» дип эндәшә иде.

— Исәнме, Булат! — Алия арадагы үзгәрешләрне сиздертмәскә тырышты.

— Сезнең янга керим әле!

— Керерсең. Өс-башымны гына салыйм инде.

Алиягә дә бераз әзерлек кирәк ләбаса! Ул плащын салды, чәчен төзәткәләде, өстәл янына утырды, бүлмәсен күздән кичерде. Тәрәзә төпләрендә яраннар чәчәк атып утыра. Киштәләрдәге үрмә гөлләр стеналарны каплап киткән. Ишек төбендәге зур савытка утыртылган ясмин дә хуш исле чәчәкләргә күмелгән.

— Әйдә, кер Булат! — диде Алия.— Уз, утыр.

— Алия Каюмовна,үзегез дә сизеп торасыздыр...— Кияү кеше озын өстәл янында гел үзе утыра торган караңгы якка чүмәште. Карашларын өстәл астына төбәп, ят тавыш белән сөйли башлады.— Без бергә эшли алмыйбыз.

— Колхоз эшендәге мәшәкатьләрне гаилә белән болгатмаска кирәк...

— Мин ике төрле була алмыйм! — Булат кызып китте.— Өйдә тәүфыйкълы песи кебек йөр имеш, ә идарәдә шул кешегә этлек эшлә...

Алия ялгышлардан азат түгел, тик ул, кешеләр язмышына бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә, хисләрен тезгенләргә күптән өйрәнде. Агрономның сүзләрен ишетми генә үткәрергә кирәк. Иөрәккә кагылдырмыйча. Председатель күзләрен йомды. Колакларны да томаларга иде дә, ярамый...

— Кызыгызны яратуыгыз да тозсыз сезнең. Ана кеше бердәнбер баласының калада яшәвенә кулыннан килгәнчә ярдәм итәр иде. Башкалар әнә кооперативка кирәрлек акча бирәләр, машина бүләк итәләр. Ара ерак түгел, кайтып-китеп йөргән булыр идек. Миңа алары кирәкми, рәтле бер эшкә урнашырга җай тапкан идем, аяк чаласыз.

«Мин бит әле бу хакта беренче ишетәм»,— дип акланмакчы булды Алия. Теле әйләнмәде. Үз өендә яшәгән кешене моңарчы танымый торуына гаҗәпләнде. Булат исә әллә ниләр сөйләде, Мәмишевне мактады, аның кулындагы зур мөмкинлекләрне санады. Алия ни бар сабырлыгын җигеп, эндәшмәскә, сүз көрәштермәскә тырышып утырды. Азактан:

— Балама мин җанымны бирергә әзер,— диде.— Анысы әлегә бераүгә дә кирәкми. Колхоз мәнфәгатенә зарар салып, сине калага урнаштыру кулымнан килми. Бер гаилә өчен мең гектарлы бакчаны корбан итмим!

— Сездән яхшылык көткән мин җүләр.

— Син — сәләтле агроном. Таш шәһәрдә нишләрсең?

— Анда хәзер һәр заводка агроном, зоотехник кирәк.

— Без начар эшләгәнгә күрә заводлар дуңгыз үрчетә башлады.— Алия кызып баруын чамалады.— Ярар, бәхәсләшмик! — Аның кияве каршына барып ялварасы килә иде. Берүзе кала бит. Әллә соң алмагачларга да кул селтәргәме? Сип тә чык чөгендер орлыгын — котыл бөтен бәлаләрдән! Баланә тотынып кит тә бар зур калага! Ул торып басты. Яман теләгеннән арынырга тырышкандай, башын чайкап куйды.— Эштән китүеңне нәкъ закон кушканча, гариза язып сора, рәсмиләштерербез.

* * *

Өендәге шәрә ялгызлыкка һич ияләнеп житә алмый иде Алия. Зур өйнең кайсы бүлмәсенә керсә дә, икенче яктан Рушания тавышы килә кебек. Булатка ачуы чыгуы бер хәл, гел гадәллеккә генә өйрәтеп үстергән кызының, авыл мәктәбен ташлап, бөтенләй эшсез калып, шәһәргә китүен һичничек аңлый торган түгел. Болар Алиянең зиһененә сыймый.

Рушаниянең баласы тугач, барып та кайтты, тик, күңеле һаман өзгәләнә. Шундый көннәрнең бер иртәсендә аңа Мәскәүдән хат килеп төште. Председательгә багышланган бер күч хәбәрләр арасыннан аерылып тора иде ул. Күреп тә алды, авыр уйлары юкка да чыкты.

Хат башыннан-ахырынача бакчаны яңача утыртуга өндәү иде. Рәт араларына су сиптергеч җайланмалар куярга, анысын күчеп-нитеп йөри торган итмәскә, даимине көйләргә!

Бу киңәш нидән башларга белми аптыраган эшләргә төпле бер юнәлеш бирергә ярдәм итте. Булат урынына алынган яшь агроном баштанаяк шул яңалыкка чумды. Алар һәр иртәне, Алия бүлмәсендә икәү калып, даими су сиптергечләр турында гәпләшәләр. Агрономы чыгып киткән иде, Хәмдүнә килеп керде. Председатель аңа да әлеге су сиптергеч турында, академик фикеренең нинди мәшәкатьләргә тоташуы хакында сөйләде.

— Аңа, ерактан торып, акыл өйрәтүе рәхәт лә! — Хәмдүнә Алия турында гайбәт таратырга сәбәп калдыручы бу элемтәне әллә ни хуплamый иде. — Стационар сиптергечләр, имеш. Ул беләме соң әле: Мәмишев бит үз теләгеннән һич кенә дә кире кайтырга уйламый икән.

Кызганычка каршы, Хәмдүнәнең район үзәгеннән ишетеп кайткан күңелсез хәбәре тагын калкып чыкты. Алия мәсьәләне колхоз идарәсе утырышына куйды, партоешма комитетында кузгатты. Бу киңәшмәләр дә шома гына үтмәде. Алия фикерен яклаучылар булса да: «Трестка каршы килеп тору ярамас!», «Райком ни кушса, шуны эшлик!» — диючеләр дә шактый иде. Идарә утырышында Алия, бу мәсьәләнең бөтен четерекле якларын ачып күрсәтү өчен, баш экономистка сүз бирде.

— Җирне чөгендергә яраклы технология белән эшкәртеп, орлыклар алып чәчү, сирәкләү, җыю чыгымнары алмагачлар калдырган акчаны суырып бетерәчәк. Тагын шунысы бар: безнең колхоз терлекләренә ул кадәр чөгендер кирәкми, кемгәдер сатарга туры килә, ташырга, төяргә, бушатырга...

Экономист конкрет чараларны санап кына күрсәтте, бу эшкә үз мөнәсәбәтен сиздермәде ул. Шуңа күрә кырчылык бригадиры: «Нишләргә соң безгә?» — дип сорады. Бөтен кешене борчыган сорауны бер экономистка гына бирү сәеррәк яңгыраса да, тегесе аптырап калмады:

— Минемчә, иптәшләр, колхозның өр-яңа бу борылышы турында без бөтен авыл белән киңәшергә тиешбез. Гомуми җыелыш ясыйк! Без вакытвакыт үзебезнең колхоз икәнлегебезне дә онытып җибәргәлибез...

Аклан халкы җыелышка бердәм катнаша. Алия башка колхоз председательләренең: «Отчет-сайлау җыелышына да китерә алмыйбыз», — дип зарлануына ышанырга да, ышанмаска да белми. Акланлыларны җыелыш булу хәбәре шатландыра да кебек әле. Ишетеп кенә алсыннар. Матур иттереп киенешеп, ирле-хатынлылар — парлашып, ялгызлары, күршесе белән берләшеп, төркем-төркем клубка агыла башлыйлар. Алия аларның клуб залында кайсының кайда утырачагын ук белеп тора. Түбән очның Гайфи агай беренче рәтнең кыл уртасына килеп утырачак. Тракторчы ирләр тәрәзәсез стена буена сырышалар. Хатын-кызлар түргә үтә, аларның аллы-гөлле киемнәре тамаша залын гөл түтәлләренә әйләндерә кебек.

Председатель фикер алышуларның ничек барасын да белә. Алдагы Гайфи бабай кызык. Нинди мәсьәлә кузгалса да, фикере уңай булса да, тәнкыйть итсә дә, сүзенең ахырында рәхмәтләр тезеп китә. Клубтагылар-

га да, президиумга да, Казандагы, хәтта Мәскәүдәге житәкчеләргә дә рәхмәт яудыра. Берсендә зур гына житәкченең фамилиясен ялгыш әйтеп, үзенә кушамат алды. Чәчү әйләнешеннән солы, вика кебек нәрсәләрне төшереп, кукурузга гына йөз тоткан чаклар иде. Үзе солыны яклап сөйләде агай, үзе әлеге фикер иясенә рәхмәт яудырды. Халык егылды көлеп. Берничә көннән ялгыш әйтелгән фамилияне нотык иясенең үзенә чәпәп куйдылар. Карт көненә Крушков Гайфи булып керде ул.

Гайфи бабай бик карт инде хәзер. Жыелышларга килә, әйтәсе сүзен дә әйтә әйтүен, тик бу юлы Алиягә эш кешеләре, әйткәнен эшләп тә күрсәтүчеләр кирәк.

Иртәгә жыелыш. Салкынча урын-жиргә яткан килеш председатель авылдашларының кайсыннан нинди фикер әйтеләчәген юрап ята. Башы тулы сорау, жавапны башкалар бирергә тиеш.

Караңгы өйнең зур тәрәзәләрен машина фарасыннан төшкән яктылык сыйпап узды. «Кайсы болай соңлап йөрер?» Машина аның капкасы төбендә тукталды. Өйдә кыңгырау чылтырарга тотынды. Рушания!

Моңа кадәр һәр тарафыннан жан өшеткеч шом ажгырып торган өйгә рәхәтлек тулды. Залның түр кәнәфиенә оныгын таратып салды Алия — бүлмәгә нур бөркелде. Сабыйның тыпырчынып елавы да — гүя асыл кошлар сайравы, саф чишмәләр чылтыравы!

— Ничек болай кайтасы иттең, кызым? Атна уртасында?

— Булат жибәрде. Сиңа аңлатырга.

— Нәрсәне?

— Шул бакчагыз инде, шул чөгендер. Мәмишевнең бөтен эше шуңа терәлгән. Коткарырга кирәк. Син барысы өчен дә үзең генә жавап бирмә, әни, Булат әйтә, башкалар ни кушса, шул булыр, гел Мәмишевкә каршы төшеп кенә утырмасын, ди.

Аш-су ягында кашык-савытлар жимерелеп төште, алар тавышына бала сискәнеп уянды.

— Мәмишев безгә квартира да, яхшы эш тә вәгъдә итә, әни, язмышыбыз аның кулында.

— Ялгышасыз, балам. Күрәләтә ялгыш юлга кермәгез. Хатаның үзең белми эшләгәне дә житәрлек була әле аның: әллә нигә бер ялгышып куя-куя да гомер азагына тау кадәр өелә. Хәзердән үк язмышын Мәмишев кебекләр кулына тапшырса, Булатың тора-бара нишләр?

— Мин дә бик ышанып житмим лә! Булат бит. Башка сүз кушар кешесе юк.

— Нигә гел кеше эзли соң ул Булат? Үзе эшләгәнгә таянсын! Житмәсә, Мәмишевкә ышанган. Ихлас күңелле түгел ул адәм.

— Менә син бик ихлас та бит, әни, ярдәм итмәдең.

— Эштән качканнарга ничек ярдәм итеп була? Белмим. Булат монда алмагачлар иленең патшасы иде. Иң кирәк чакта илен ташлап китте. Ул бит яшь-яшь. Бакчаны тергезү аны авыл кешеләре алдында каһарман итәчәк иде. Ул әнә Казанга качты.

— И-и, әни!

— Әйткән сүзем шул, кызым: Мәмишевтән алданганыгызны белгәч, исегезгә Аклан төшсә, икеләнеп тормагыз, кайтыгыз. Ишегем ачык. Сезнең хакка авылдан да сорармын, эшсез калмассыз. Мәмишев, ай-һай, сезнең өчен кыл да кыймылдатмаячак. Булат аңа үз эшен юлларга гына кирәк. Монда ник килгән тагын?

— Жыелышыгыз була икән бит.

— Аңа кем хәбәр итеп өлгергән икән инде?

Сорауларның калган-башкаларын кызына әйтеп тормады Алия. Авыл халкы аны моңарчы аңлый иде бит әле! Хәзер дә аңлар...

* * *

— Кадерле авылдашларым! — Алия халык алдындагы сүзен һәрвакыт шулай башлый.— Менә тагын зур киңәшкә жыелдык. Президиум-

да сез сайлаган идарә членнары утыра. Шулар янына партиянең райком вәкилен, бакчачылык трестыннан килгән Мәмишев иптәшне дә чакырырга рөхсәт итегез!

Алия җыелышта каралырга тиешле мәсьәләне дә аңлатып бирде. Залдагылар башта сорау яудырдылар:

— Бездәге чөгендер үзебезнең малларга җитеп ашкан ич?!

— Консерв заводына да чөгендер ташыргамы? Дуңгыз ризыгыннан — варенье!

Кайбер сорауларга үзләре үк җавап кайтара:

— Заводка Молдавиядән алма ташырга була бит, кайгырма!

— Иләкнекен чиләккә бушатып ятасылар бар икән, ә?!

Председатель залга бераз ирек биреп торды. Ихлас сүзләр нәкъ шунда яңгырый кебек.

— Сез нәрсә, һәрчак шундый хаоска юл куясызмы?

Алия, борылып карамаса да, сорауны Мәмишев биргәнлеген белә иде. Тик монда, үз колхозчылары янында аның җаны тыныч, каушамады.

— Бәлки Сез берәр сүз әйтерсез! Рәхим итегез!

Мәмишев чыгышын бик ерактан алдырып китте. Халык та аны: «Шулай, шулай, туганкай, дөрес сукалыйсың!» — дигән сымаграк тыныч кына тыңлап утырды.

Тик иң кирәклесенә җиткәч, Мәмишев сөрлегеп куйды. Кешеләр аңардан акыллы бер киңәш көтә иде. Ул моны аңламады:

— Алдыгызга килеп баскан зур җаваплылыктан сезнең председатель шома гына котылырга чамалый,— дип ычкындырды һәм нык ялгышты.

Аклан кешеләре Алияне Мәмишевкә караганда мең мәртәбә яхшырак белә. Аны хурлау — акланлыларның үзен мыскыл итү белән бер. Шунда оттырды да инде Мәмишев. Шулай да, атылып чыгып, аңа каршы төшүче булмады. Әйтеп ташларсың да, һәр сүзеннән дәгъва, шом бөркеп торучы бу зат сүзеңне яман якка борыр, башың бәладән чыкмас дип фикер иттеләр бугай.

Инде үзара сөйләшүчеләр дә юк. Алия тегеләй дә, болай да өндәп карый, кымшанучы табылмый. Сәер хәл туды. Идарә членнары да аптырый калдылар. Мәмишев, төче елмаеп:

— Бигрәк оста оештыручы икәнсез! — диде.

— Авылдашларым! — Алия, Мәмишевнең янаулы сүзләреннән котылу өчен, кабат торып басты.— Үзегез беләсез, болай барыбыз бергә очрашып сөйләшүләр еш булмый. Эшләрнең иң күп чагы. Инде, вакытны кызганмыйча, тәгаенләп җыелганбыз икән, гомер булмаганча, болай битараф утырмыйк инде!

Сүз сораучы юк. Үзара пышылдашу китте. Бу хәл Мәмишевне җилкендереп җибәрде. Үзенә берәүнең дә комачауламаячагын сизеп, ул тагын трибунага очып кунды.

— Сез әле ул азык чөгендере уңышының бөтен мөмкинлекләрен белмисез. Череп баюдан шикләнәсезме? Отышы ягыннан аны алма белән чагыштырып та булмый. Безнең трест бу язда сезнең районда өстәмә рәвештә дүрт йөз гектар утыртырга тиеш аны. Бары сездә генә шул кадәр буш җир бар. Башка чакта мондый бәхәс чыкмас та, сезгә аны тәкъдим итеп тормаслар да иде. Алма, алма! дип тарткалашырга килешми, аның турында бабайлар — алманың ни туклыгы дип җырлаганнар түгелме соң әле?

Чәчәкле алъяпкыч балкыган зал уртасыннан Хәмдүнә күтәрелде.

— Белер-белмәс көенчә, җырларыбызга кагылмагыз! — усал тавыш барысын да сискәндерде.— Бакчаны харап итәргә тырышуың да җиткән!

Хәмдүнәнең ни әйтергә теләгәне ачыкланып та җитмәде, Крушков Гайфи торды. Үзе сөйләнде, үзе ашыкмыйча гына сәхнәгә күтәрелде, трибунага якынлашты. Мәмишевне ым белән генә читкә этәрде:

— Дөрес бит, әй, кем, Хәмдүнә! Э-э... һе, алай икән, ә алманың туклыгы юк икән. Тик шунысы мәгълүм: һәр якның үз мактанычы була.

Әлмәтлеләр, анау, нефтеләре белән шатлана, чистайлылар — сәгать ясый, безнең сәгатьне космоска да алып менәләр дип әтәчләнеп йөриләр. Кайсы берәүләр машина чыгара. Чөгендер үстереп баючылар да күп. Сарыкларын бетереп, чучкачылыкка күчүчеләр, алай иттереп тә отучылар юк түгел. Алма — безнең куаныч. Инде безгә арттырып чөгендер чәчү,— Гайфи Мәмишевка борылды,— сизеп торам, энем-җаным, сиңа бик кирәктер. Тик безне алмадан аерма, безнең як һәр язда ап-ак чәчәккә күмелмәсә, тормышның яме калмый безгә. Әйе, рәхмәт, җаным!..

Картның сүзләрен колхозның төп таянычы булган механизаторлар хуплар дип көтте Алия.

— Карагыз әле, иптәшләр, механизаторлар! Эш бит барыбер сезнең җилкәгә төшәчәк, ник эндәшмисез?

— Белгәннәр күп сөйләшми ул! Эш сәгате суксын, күрерсез!

— Бу нинди янау тагын? — Мәмишев сикереп торды.— Кем әйтте моны?

— Син, агайне, безнең егетләргә алай ямьсезләнеп эндәшмә, ярыймы? — Хәмдүнә иде бу.— Без колхоз уставын яхшы беләбез.

Алия мәсьәләне тавышка куйды. Кул күтәрүче булмады.

— Безнең бакча турында бер карар бар бит инде. Өмәләр ясадык, ял сәгатьләрендә эшләдек,— дип кычкырды берәү.

— Сайларга өйрәтим әле мин сезне! — Мәмишев шаяртуга күчте.— Кем бакчаны тергезергә, муеннан бурычка батарга риза, кулларын күтәрә!

Кул күтәрмәделәр. Тагын тавыш купты.

— Карап карарбыз әле, җир безнеке!

— Җир дәүләтнеке! Аны әрәм-шәрәм итәргә юл куймабыз! — Мәмишев усалланды.

— Ә-ә, алайса син аны кесәңә салып алып кит, энем!

Мондый хәвефле җыелышны Алиянең беренче тапкыр күрүе иде. Таралыштылар. Алиягә бу хурлыкның җәзасын күтәргә генә калды, кайчан, кайда, кем чакырып алыр да кыска-кыска сораулар бирә башлар? Әллә берәр комиссия килеп төшәрме?

* * *

Көтелмәгән кунаклар китеп, озак та үтмәде, председатель үз кабинетына Хәмдүнәне чакырып алды. Аларның ни хакында сөйләшүен берәү дә белмәде. Кабинеттан чыгып китү белән үк, Хәмдүнә атна буе авылда күренмәде. Кызыксынган кешеләр, бик төпченеп карасалар да, бакча бригадирының кайдалыгын белә алмадылар.

Хәмдүнә исә бу көннәрдә, тәвәккәллегеп учына йомарлап, Мәскәү урамнары буйлап йөри иде. Төп йомышын үтәрдәй академикның эш урынын эзләгәндә, ул шактый вакытын исраф итте, урамнарны, биналарны бутап бетерде. Таныш фамилия элеп куелган ишекне тапканда, эш көне тәмамланган иде инде. Хәмдүнә икенче көнне, таң беленүгә, урамга чыгып йөгерде. Шулкадәр иртә иде әле, академик кабинетының гына түгел, хәтта ул йортның да ишеге ачылмаган. Вакытның артык иртәлеген Хәмдүнә шунда гына аңлап алды. Чәй эчәсе килә иде. Якындагы ашханәгә керде. Кеше әллә ни күп түгел. Биек-биек өстәлләр янында басып кына ашыйлар. «Ризыкның бәрәкәтен качыралар»,— дип, бу хәлне өнәп җиткермәде Хәмдүнә. Шулай да тамак ялгарга булды.

— Миңа чәй! — диде.

— Анысын титаннан агызып үзегез алырсыз, ашарга ни бирим?

— Өчпочмак.

— Ашарга ни бирим дим?

— Треугольник.

— Сосискамы, йомырка тәбәсеме?

— Берсе дә кирәкми, бер-ике телем ипи генә бир.— Хәмдүнә үз

алдына сөйләнде.— Уңмаган нәмәрсә, өчпочмагын өлгертә алмаган, күрәсең. Йомырканы авылда да күргән бар. Сосисканы, шул яшемә житеп авызга алганым юк, шөкер. (Ул әле өчпочмакны Татарстанда гына пешергәннәрен белми иде).

Авылга әйләнеп кайтканчы, Хәмдүнә Мәскәү тормышыннан шактый хәбәрдар булды. Хәтта өчпочмакны анда пешерә белмәүләрен дә аңлады. Дөрес, монысын Алиягә сөйләп торырга кирәк тапмады. Председатель өчен бер кочак кулланма күтәреп кайтты ул. Академик кушты.

— Минем ярдәмем сезгә шул: үз хокукларыгызны үзегезгә аңлатып бирергә мәҗбүрмен.— Брошюралар тапшырганда, галим шулай диде.— Менә болар — дәүләтнең бакчачылыкны яклап чыгарган карарлары, өйрәнегез! Сезнең белмәүдән усал файдаланулары ихтимал. Алия Каюмовнага да аңлатыгыз, җебеп төшмәсен!

— Җебеп түгел, урыныннан очып төшүе бар аның.

— Анысы нинди сүз инде тагын? — Ул кулларын җәеп җибәрде.— Сүз мең гектарлы уникаль бакчаны саклап калу турында бара, ике нәрсәне бутарга ярамый. Андый чакта карьера турында уйлау...— Ул башын селкеп, кулларын бутап алды.— Белмим, белмим. Минем уйлавымча, Алия ханым андый ук йомшак җанга охшамаган.

Хәмдүнә Алиягә академикның һәр сүзен төкми-чәчми тапшырды. Сөйләгәндә аныңча кыланып-кыланып та күрсәтте. Председатель аны әле елмаеп, әле җитдиләнеп тыңлады, аннары кашларын җыерды:

— Үз хокукларыбызны белмибез, юридик наданлык көчле,— диде. Мәскәүдән кайткан кулланмаларны өстәлгә куйды.— Өйрәник без боларны!

* * *

Борчак та, бодай да чәчелеп беткән иде инде. Алия бөтен механизаторларны идарәгә чакыртты. Кушылган вакытка нибары берәү килде.

— Кайда башкалар?

— Белмим. Минем дә вакыт тар. Ни йомыш, әйт тә, Алия, китим әле! Ә?

— Их! — Алиянең өзгәләнүе йөзенә чыкты.— Зур йомыш бар иде бит!

— Гел безнең өскә генә салынырга димәгән, Алия Каюмовна. Без бодай белән карабодайны үз өстебезгә алдык. Килешүгә кул куелган, күмәкләп эшлибез, нәтиҗәсенә карап, хезмәт хакы алабыз — билгеле бит инде, үзегез аңлаттыгыз. Вак-төяк эшкә тарткаламаска килешенде.

Алия, әйтергәме-юкмы, дигәндәй, аңа сынап карангалады. Тегесе башын аска игән, күзләрен яшерә.

— Бик кирәк иде! — дип уфылдады Алия. Башларын учларына кысты да, тәвәккәлләп әйтеп салды.— Бераз бушаган арада бакчага чыгарга дигән идем.

— Ә-ә?!

— Нигә куркасыз? Сезгә бер нәрсәсе дә юк аның. Өстәмә хак та түләргә була. Тик ашыгырга кирәк иде, һәр минут кыйммәт!

Тракторчы егет көләргә тотынды, бүлмә яктырып китте кебек.

— Соң, Алия-кордаш, бүген ул якка колак салмадыңмыни соң? Иртә таңнан шунда эшлибез бит инде. Егетләр мине дә ярты сәгатькә генә җибәрделәр. Төплибез. Көзгә кадәр кими торсын!

— Җыелышта шуңа су капкандай утырдыгызмыни сез? — Алия кабынып китте.— Алайса мин шефлар белән дә, урманчылар белән дә сөйләшим.

— Карабодайга төшкәнче бер атна эшләп була. Тик теге Мәмишев — куркыныч нәрсә, ни дип җавап бирерсез, әй, «бирербез» димәкче идем лә.

— Ә-ә, сез инде минем бөтен вазифаларыма кермәгез, яшьтәш, җавап бирүне миңа калдырыгыз!

Аларның шат авазлары, кабинетка гына сыймыйча, коридорны да тутырды...

* * *

Алия бакчаның күпереп чәчәк аткан вакытын, аннары алма өлгергән чакны ярата. Әле яфрагы да ачылып житмәгән сабакларда ап-ак яки алсу чәчәкләр күренә башласа, аңа яшьлеге әйләнеп кайткан кебек тоела.

Алма пешкән көннәрдә, бакчада ыгы-зыгы куба. Шулай да кояш чыгып килгән чакка өлгерсәң, хәйран каласың. Тып-тын. Чык суына коенган алсу алмалардан бөтен тирәлеккә хуш ис таралган. Алия сабыр гына атлый. Күңелен рәхәт уйлар тутырган. Яңадан тергезелгән алмагач дәрьясының бер дулкынын мәскәүлеләр сорый. Шәфкатьле академик үтенечкә үзе кул куйган. «Алмаларның Идел буендагы табигатен өйрәнүне сезнең бакчада алып бару мөмкин булмасмы?» — дигән. Нигә булмасын?! Алия бакчаның һәр тарафын әүвәл үзе карап, барлап чыгарга теләде, аннары өзеп җавап бирер. Алмалары белән киңәшкән кебек йөри.

Соңгы көннәрдә таң алдыннан бакчага ашыгуы шуннан. Авылдан ул атка утырып чыга. Машина тавышы белән таңның ямен җибәрәсе килми.

Алмагачлар гына тупылдап утыра торган аллеяның аргы башыннан Алиягә каршы атлаучы ир заты күренде. Председатель аны кылкынуыннан ук таныды — Булат кияү. Йоклый калган иде, кай арада килеп җиткән? Машина кугандыр. Каршыга төшү өчен шул якка барып туктагандыр.

Бер-берсенә хәерле иртә теләштеләр.

— Эчне пошырып торган бер сорау бар, кияү.— Сүзне Алия башлады.— Кайтканыгызга ничә көннәр үтте, ачыктан-ачык кына сөйләмисең: ник инде өр-яңадан кубарылып, авылга күченәсе иттең? Мәмишевнең эштән кыскартылуы сиңа кагылмый бит. Әрле-бирле йөренергә калсаң, болай да кып-кыска гомер, юлга чәчелеп бетмәсме?

— Гариза җибәргәндә, хат язган идем бит, әни.

— Күзгә-күз карашып сөйләшүгә ни җитә?

— Хикмәт Мәмишевтә генә түгел. Эш кушарга башкасы да табылыр иде. Безгә кайда да эш бит инде.— Артык тирәнгә китмичә генә котылып булмасмы дигәндәй, Булат туктап торды. Алия аңа текәлеп караган: барын да аңлатмыйча тын да алырлык түгел.— Эшнең күңел тартканы күп түгел икән шул, әни. Шушы дүрт-биш ел эчендә нинди генә оешмаларга, кайсы гына җитәкчеләргә йомыш төшмәде. Берсендә фатир көтеп эшләдем, икенчесенең акчасы күбрәк күренде. Тик бер генә көнемдә дә күңелнең эштән ризалашып, рәхәтләнеп калганын хәтерләмим. Рушания дә авыл мәктәбендәге балаларны сагынды. Бу язда кайткач, бакчаның яңадан тоташ ак чәчәккә күмелгәнен күрдем. Шул барын да хәл итте. Гаризаны шуннан соң яздым. Теге чакта корыган бакчаның каралыгы котымны алган иде.

— Авырлык килгән саен шәһәргә качып котылып кына булса икән!

— Аны үз башына төшкәннәр генә аңлыйдыр, әни.

— Ярар, бетте. Әйдә, мин сиңа ике елдан соң ук чәчәк аткан яңа төр алмагачларны күрсәтәм! Мәскәү бүләкләре!

Алга атладылар. Бөтен дөньясында шул сак адымнар тавышы гына шикелле. Юк, өлгергән алмалар да председатель адымнарына көч бирә: әле бер якта, әле икенче тарафта, әле каршыда ук «туп» та «туп» алмалар төшә. Алия колхозының өр-яңадан тулып пешкән алмалары ява: туп, туп, туп...

## Эльмира Шәрифуллина

# СӨЮ КАРШЫНДА

### Изге җыру

Йөрәк парәм, диеп җыр башладым,
Бишегенә килеп кагылгач.
Гөлләр тама икән телләреңнән,
Сабыеңа шулай табынгач ла,
Сабыеңа шулай табынгач.

Газизләрдән газиз кемнәр газиз,
Үз баласы газиз анага.
Күкрәгенә сабый сарылганның
Йөрәккәе сыймый далага шул,
Йөрәккәе сыймый далага.

Ак биләүгә төргән нарасый җан —
Сабыйлыгы белән сылу ул.
Дөньяларны иңләп таралган җыр —
Бишек җыры, изге җыру ул, һай,
Бишек җыры — изге җыру ул!

### Насыйп булсын

Насыйп булсын очрашулар тагын безгә,—
Уздык күңел түрегезгә:
Күңелегезнең түре иркен, якты икән,—
Чын яз икән күңелегездә.

Насыйп булсын бу язларны бергә күрү,
Бәйрәмнәрдә бергә йөрү.
Сөенешеп, бергәләшеп уйнау-көлү,
Күңелләрне җырга төрү.

Насыйп булсын җырлы, нурлы табыннарга
Тагын шулай җыйналырга;
Яхшылыктан, изгелектән, җырдан-моңнан
Җирдә мәңге сыйланырга!

---

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА — *шагыйрә, «Яңгыр җиле» исемле шигырь һәм «Мизгел» исемендәге проза китаплары авторы. Казанда яши, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли.*

## Ә табигать...

Саласпилста җиде баласы белән тоткынлыкта газаплап үтерелгән Ана монологы.

Җиде балам — минем җиде ярам,
Җиде балам — җиде йолдызым.
Җиде болак төпләрендә янып
Ялтыраплар яткан кондызым.

Ташка әйләнсәм — таш күңелем сызлар,—
Йөрәгемдә бала ярасы...
Юк, табигать андый явыз түгел,
Табигатьнең без үз баласы.

Күкрәгемне көнгә ачып куям,—
Гыйбрәт итим йөрәк ярамны.
Их, табигать, кочагыңа нигә
Алмадың соң хет бер баламны?

Давылыңа салып, дуылдатып,
Очыртыплар китсәң ни булган?
Бәлки исәндер дип көтәр идем
Гарасатлар үткән шул юлдан.

Я ыргытсаң төпсез упкыныңа
Иң-иң биек кыя ташыннан —
Бөркет күзе шәйләр иде, бәлкем,
Һәм баш тартыр иде «аш»ыннан.

Юк!..
Табигать алай явыз түгел,—
Табигатьнең без үз баласы...
Җиде балам — минем җиде ярам,
Һәр баламда фашист тамгасы...

## Мизгел

Мизгелләр яши күңелдә,
Мизгелләр бирми тынгы.
Изге хатирәләр белән
Мөлдерәп күңел тулды.

Офыкларда зәңгәр киңлек,
Җил-давылларда тизлек...
Аяк асларында кайгы,
Түзмәдек түгел, түздек.

Аклы күлмәгемне киям,
Синең соңгы бүләгең.
Ак төсләр калсын өченме,
Шулай кыйммәт түләдең?

Талымсыз түгел күңелләр,
Без сайлап сөйгән идек.
Яр булсын да пар булсын дип,
Теләктә йөргән идек.

Бу дөньяда язмышлар бар,
Синең белән бәйләнгән.
Бу дөньяда мизгелләр бар,
Бер хыялга әйләнгән.

Хыялларның биләмәсе
Иркен дә соң, зур да соң...
Күз генә салып сөегез
Киселгән төп туйрасын.

Күз генә салып сөегез,
Күңелләр сизгер бит ул.
Яшәрткән дә, яшәткән дә
Мәхәббәт — мизгел бит ул!

## Ярый әле...

Тузганаклар туздырганбыз,
Җил чыгарып, үзебез.
Сүз чыгарып туздырдылар,
Утырып калды күзебез...

Туздырдылар тиештә дә,
Тиеш түгел чакта да.
Җырлаттылар, елаттылар
Хакка да, нахакка да.

Өреп-өреп очырсалар?
Дөнья шулай корылган.
Ярый әле китмәдек без
Тузганаклар юлыннан...

## Күңел күзе

«Әнкәй» дигән сүзне ишетер өчен,
Сөяр өчен безнең балаларны,
Юл газабын сизми киләсең гел
Якын итеп ерак араларны.

Авырлыклар килсә, кыен килсә —
Бер бисмилла, гүя, «әнкәй» сүзе.
Шатлыкларны күрсен. Газапларны
Күрми торсын иде әнкәй күзе.

Болай да бит хәсрәтләрне безнең...
Күчтәнәчләр итеп син аласың,
Аерылганда моңсу таңнар булып,
Нурлы көннәр булып югаласың...

Сине уйлау — олы юаныч ул,
Әнисезләр ничек түзәләрдер.
Безнең сезгә сыенганны күреп,
Бәгырьләрен кат-кат теләләрдер.

Кичә килгән идең,
Бүген киттең...
Кулларыңны суздың түзем генә.
Йөрәгеңдә сыкрау, әрнүләрне
Күрде бары күңел күзем генә!

## Сөю каршында...

Фоторәсем каршысына килеп,
Елый, җырлый берәү боегып.
Сандыгында саргайган хат саклый,
Кайнар яше күзләреннән акмый,
Күңеленнән тора коелып...

Ни үле, ни тере хәбәре юк,
Ай-яй усал соң бу язмыш та...
Нәзер әйтте, адарынды күпме,
Көннәр түгел, айлар, еллар үтте,
Хәбәр булмады тик ялгыш та.

Яр көтүдән кыен гамәл юктыр,
Төшләр күрсә — юлга юрады.
Өметләрен акламаган төшләр,
Нәзер белән яуланмаган эшләр
Телем-телем җанын турады.

Хәтерендә, күз алдында әле
Челлә чакны урак уруы.
Сагынулары көчле бар ягыннан,
Эссе ала хәлне бер ягыннан,
Сулышларга каба кызуы.

Тел тибрәтер дым юк авызында,
Күләгәдә булмый хәл алып.
Түзим диеп телен тешләде ул,
Шундый чакта ялсыз эшләде ул,
Түбәсенә салкын су салып.

Иле өчен иде,
Ире өчен! —
Кавышуны теләп түзүләр.
Ун ел үтте,
Утыз, кырык менә...
Көтсен әле бер тын, бер төн генә
Насыйп булыр, бәлки, күрүләр...

Ак чәченә ак яулыгын каплап,
Тезләнә ул рәсем каршына.
Япь-яшь егет аның газиз ире,
Мәхәббәткә тими картлык чире,
Кырык ел — ни сөю каршында?!

## Җырчы килә

Җырчы килә дөнья буйлап,
Җанда чаң кага-кага.
Аланнар эзләп бара ул
Йолдызлар яга-яга.

Җырчы килә дөнья буйлап,
Тынлыкка колак сала.
Керә урманнар иркенә.
Гөлләрдән илһам ала.

Өр-яңадан туа дөнья,
Өр-яңа көн башлана.
Алиһәләр табынырлык
Илаһи хис бар анда.

Җырчы килә дөнья буйлап,
Бар җиһан хәйран кала.
Моң кала көнгә сибелеп...
Мең рәхмәт, гамьле бала!

## Таптым гына...

Җир тетрәтер көч бар кебек синең җанда,
Күк күкрәтер көч бар кебек синең җанда.
Кояш булып балкыр идем синең таңда —
Булсаң янда, минем янда, һәрбер таңда.

Булсаң янда, минем янда, һәрбер таңда,
Сиңа табынып башлар идем иртәләрне.
Гомерем буе эзләп-эзләп таптым гына,
Ал юлымнан газапларны, киртәләрне.

Таптым гына, күзләреңә бактым гына,
Инде килеп шатланыйм да көлим дисәм...
Миһербансыз язмыш белән килешә-килешә
Бәгыремне үзем турыйм, үзем кисәм.

Көттем сине, көтте җаным, вөҗүд көтте,
Читлегеннән чыгар булып йөрәк типте.
Чишәсе сер тагын калды йомгагында,
Санаулы көн «ә» дигәнче үтте-китте.

Барлыгыңны, бу дөньяда яшәвеңне
Ник белгерттең икән миңа, ник белгерттең?
Чарасызлап, бәйгедәге йөрәгеңнән
Ник сөйдерттең икән мине, ник сөйдерттең?

Җир тетрәтер көч бар кебек синең җанда,
Күк күкрәтер көч бар кебек синең җанда.
«Аягыңа уралам да җибәрмим»,— дип,
Томан йөри, салкын томан — синең таңда...

.................

# Солтан Шәмси

# КАЛА-ТАУ ӨНЕ

ПОВЕСТЬ

I



Һай, матур да соң бу тургай сайраулары!

Азат, кулларына таянган җиреннән, башын артка ташлый да күккә карый, күзләрен кыса төшеп, тирбәлә-очына тәкатьсез сайраган тургайны күзәтә. Болын ягыннан тыгыз җил исә, колакларда сызгыра, һавадагы кош та шушы җилдә тирбәлеп сайрый да сайрый... Археолог егет кошның сөенә-сөенә канат кагуын карап тора. Бу минутта ул да тургай кебек бәхетле — чалт аяз көн, болыннан күтәрелгән саф җил, кош сайравы, ялгызың тау башында утыру — барысы да аңа рәхәтлек, өмет, ышаныч бирә...

Бүген экспедиция ял итә. Кала-тауда Азат үзе генә калды. Казу эшләрендә катнашучы мәктәп балалары үзәннең аргы ягындагы авылда. Ә студентлар, мунча кереп, киемнәрен алыштырып килергә дип, электричка белән Казанга кайтып киттеләр. Алар иртәгә килеп җитәчәк.

Азат бу атнаны гаиләсе янына кайтып йөрмәскә булды. Лагерьда ялгызы гына калып, тынычта фикерләрен барлыйсы, кайбер нәрсәләрне уйлап бетерәсе, язу-сызу эшләрен тәртипкә саласы килде. Аннан соң бит монда күз-колак булып торучы да кирәк. Кыскасы, бу ялны ул монда үзе генә калды.

Казан суының урта агымында урнашкан бу Кала-тауда ул инде бернichә ел казу эшләре алып бара. Шушы вакыт эчендә күпме әйбер табылды, нихәтле ачышлар ясалды: борынгы шәһәр, шушы төбәктә кайнаган тормыш елдан-ел ачыла-ачыклана бара иде. Бу исә Азатка тарихны торган саен тирәнрәк аңларга, болгарлар тормышын тулырак күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Ничәмә гасыр җир астында яткан әйберләр, казый торгач, якты дөньяга чыга, халыкның үткәнен, элекке заманнарда ничек яшәвен ачыкларга ярдәм итә.

Менә бу сезонда да байтак әйбер табылды.

Күп тә үтмәде, тургай Кала-тау читеннән башланып киткән арыш кырына төшеп кунды да тынып калды. Инде колакка җил сызгыруы белән еракта сайраган кошлар тавышы гына ишетелгәләп куя.

Башка вакытта монда көне буе эш кайный, һәркем үз вазифасын үти, әмма, шуңа да карамастан, малайлар уен-көлкене, шаяруны да онытып бетермиләр. Азат үзе дә аларга кушылып үртәшә, шулай иткәндә эш шәбрәк бара. Авылдан менеп йөрүче малайлар да, студентлар үзләре дә беренче елларын гына эшләми. Казуның рәтен беләләр. Аларны артык өйрәтеп торасы юк. Шулай да Азатка барысына да эш бүлеп бирү, бал-

---

СОЛТАН ШӘМСИ *(1946) — прозаик һәм тәрҗемәче. «Көмеш чылбыр» исемле китап авторы. Казанда яши.*

чык арасында табылдыклар күрелми калмасын өчен, игътибарны арттыру кирәклеген ара-тирә малайларның исләренә төшерү кирәк була. Моннан тыш та аның эше житәрлек: казу тәртибен кәгазьгә теркәп бару, табылдыкларның урынын сызымда билгеләү... Алардан арынган арада ул да кулына көрәк ала, малайларга булыша.

Бүген исә Кала-тауда тынлык. Жил сызгыра да тургайлар сайрый...

Казу мәйданының бер почмагын көз көне язылачак отчет өчен фотога төшереп аласы бар иде. Азат үткер итеп кайралган махсус көрәк белән балчык стеналарны кырып чыгарга, аяк астын чистартырга булды. Бу осталык һәм тәжрибә сорый торган гаять четерекле эш. Азат аны гел үзе башкарырга тырыша, сирәк очракта гына студентларның берәрсенә тапшыра. Кырып чистартканнан соң, казу мәйданы, малайлар әйтмешли, гөлт итә, көлеп тора. Балчык стеналарда катламнар ачыла, аларның анык чикләре күренә. Күз алдына үткән заманнар, чал тарихның җуелмас баскычлары килеп баса. Бу баскычлар, археологлар телендә, культуралы катламнар дип атала. Культуралы, чөнки алар кешеләр яшәгәндә хасил булган...

Эшләрен бетергәч, Азат билен турайтты да, көрәк сабына таянып, бераз ял итеп алмакчы булды. Шулай басып торганда, авыл күпереннән болын ягына чыгып килүче җиңел машинаны күреп алды. Күзең төшмәслек тә түгел — машина җете кызыл, күзгә бәрелеп тора иде. Менә ул җиңелчә генә тузан туздырып, бире таба килә башлады. Гадәттә, бу юл буйлап Кала-таудан бер чакрымда торган борынгы кабер өстендә гыйбадәт кылырга дип, карт-коры гына үткәли. Әмма машина Кала-тау турысында болынга борылды да чабылмаган үлән өстеннән йөгерә башлады. Азат исә машина артыннан сузылып калган карасу-яшел эзне күреп һәм ачу белән көрәген атып бәреп, тау кырыена ук килеп басты.

Ә машина тәгәрәвен белә. Тау итәгенә житкәч кенә тукталып калды ул. Аннан уртача буйлы, юантыграк гәүдәле, ялык-йолык килеп торган күн пинжәкле, кара күзлек кигән бер адәм чыгып басты. Башын күтәреп, тау башына карагач, кул болгады. Азат исә аны танымады, шуңа күрә җавап та бирмәде. Ләкин аның атап экспедициягә килүе көн кебек ачык иде. «Кем булыр икән?» — дип, баш ватты Азат. Мондый танышлар юк кебек. Бу кунак аны кызыксындырып өлгергән иде инде.

Теге кеше ул арада шапылдатып машина ишеген япты, бикләде, тартып-тикшереп карады. багажникка килеп, аннан ниндидер сумка алды.

Кунаклар Азатка ара-тирә килгәлиләр иде. Галим-голәмә, тарих-археология белән кызыксынучы әдәбият әһелләре, дуслары-танышлары. Кунарга да калалар. Андый чакта алар төне буе җаннарын борчыган нәрсәләр турында сөйләшеп чыгалар, хыялланалар. Азат үзенең эше, тарих, халыкның үткәне турында сөйли. Тегеләр исә аны культура яңалыклары, зыялылар арасындагы төрле хәлләр белән таныштыралар. Әмма мондый кунаклар электричка белән йөри, Азат янына да тирә-юньнең матурлыгына хозурланып, соклана-соклана, ашыкмыйча килә. Археолог аларны ерактан ук танып ала, сөенеп кул болгап, тау башында көтеп тора.

Ә бу кеше бер дә андыйга охшамаган. Башта ул өстенә ишелергә торган биек тауга карап торды. Әйтергә кирәк, тау гаять биек булу өстенә шактый текә дә — түбәсенә менеп житкәнче, кара тиргә батарсың. Турыдан гына күтәрелү турында уйлыйсы да юк, рульдә утырып йомшаган бу аяклар белән — бигрәк тә...

Машина хуҗасы, тау итәгендә басып торган килеш, шулайрак фикер йөртте. Шул ук вакытта Азатның җавап бирмәвенә дә игътибар итте — танымады ахры дип, үзалдына көлемсерәп куйды. Шулай бераз уйлаптамалап торды да, кыйгачлатып, әйләнеч юлдан менәргә булды. Моны күреп, Азат та — таралып яткан утыннарны җыештырырга керешә, кәгазь кисәкләрен учакка тыкты — билгесез кешене каршыларга әзерләнде.

Ул арада күн пинжәкле теге кеше, тауның яртысын үткәч, сумкасын балтырына сөяп куеп, еш-еш сулап, ял итә, башын төрле якка

боргалап, тирә-юньне күзәтә иде. Күзлеген дә салган. Менә ул Азатка таба борылып, якты итеп елмаеп җибәрде, тагын кулын изәде. Шул вакыт Азат та аны танып алды.

— Нәгыйм?! — дип кычкырды.

Юлаучы кайчандыр аның белән бер класста укыган авылдашы иде.

— Ай-һай биеккә кунаклагансың,— диде ул, өскә күтәрелгәч.— Яныңа һич менеп җитәрлек түгел.

Кочаклашып ук исәнләштеләр. Аннан соң Нәгыйм кулъяулык белән түгәрәк йөзен, кыска муенын сөрткәләде, маңгайдан коела башлаган чәчләрен сыйпап, пинжәк чабуларын селкеткәләп, җилләнеп алды. Беренче карашка ул аз хәрәкәтләнүче, һавада сирәк булучы юаная башлаган кабинет әһелен хәтерләтә иде. Күз кабакларының кызарып торуы да аның нервылы, киеренке тормыш алып баруына ишарәли иде шикелле.

Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Азат шаяртып алды:

— Менә күрдеңме инде бабаларыңның зирәклеген? Алар шәһәр-нытмаларны кайда салырга кирәклеген белгән!

— Нәрсә, әллә монда ныгытма булганмы?

— Әйе, бу бит борынгы шәһәр урыны.

Нинди дә булса корылмалар күрергә теләп булса кирәк, Нәгыйм Кала-тау өстенә күз салды, тик төрле төстәге өч палатка, ниндидер балчык өемнәре, үсеп утырган кечерәк кенә тал, тәбәнәк өстәл, ташлары корымланган учак, бүкәнгә чабылган балта һәм турап куелган утыннардан башка бернәрсә дә күрмәде.

— Килеп чыгуыма каршы түгелсеңдер бит? — дип, сынап Азатка карап алды.

— Юк, киресенчә.

— Ярый алай булгач.— Нәгыйм өстәл өстенә күн сумкасын китереп утыртты, нигә килүен аңлатырга кереште.— Туйдырды, малай, заводта ябылып яту да... Бу җәй минем өчен җәй булмады. Цехта реконструкция бара, эш муеннан. Хет кырыкка ярыл. Ике ай инде адәм рәтле ял иткән юк. Ял көннәрне дә заводта үткәрәм...

Хәлең аңлашыла дигәндәй, Азат башын какты.

— Бүген менә качып киттем әле,— дип дәвам итте Нәгыйм.— Барып кайтыйм әле, мәйтәм, Азат чакырган иде бит. Ичмаса бер сөйләшеп утырырбыз, һавада булырмын...

— Бик шәп иткәнсең. Ну, минем монда чегән тормышы инде, үзең күрәсең.— Азат учакка, палаткаларга таба ымлады.— Гаеп итмәссең.

— Нинди гаеп... Нәрсә син.— Нәгыйм кулын күкрәгенә куеп алды.

Үткән кышны, ял көннәренең берсендә, көтмәгәндә чаңгы юлында очрашкан иде алар. Бер-берсен танып алып, туктап сөйләшеп тордылар. Ул чакны сүз эш, семья хәлләре, балаларны сорашудан, «авылга кайтасыңмы-юкмы»дан узмады. Таяк очы белән чаңгы буявын тырнап, аерылышканда, телефоннарын да алыштылар, икесе дә: «Без бит синең белән авылдашлар, ешрак очрашырга, йөрешергә кирәк»,— дип гөжелдәгәннән соң, Азат якташын җәй көне экспедициягә килеп чыгарга чакырды. Әмма моңа карап кына үзгәреш, якынаю булмады. Дөрес, пөхтәлеккә гадәтләнгәнлектән, өйгә кайту белән, һәркайсы телефон номерын куен дәфтәренә күчереп куйды, ләкин эш шуннан узмады. Киеренке шәһәр тормышы мондый очрашуларга вакыт калдырмый иде. Һәркемнең үз тормышы, үз мәшәкате, үз мохиты, дуслары-танышлары бар. Җайга салынган, эзгә төшкән ул тормышка берсенең дә артык үзгәреш кертәсе килмәде. Аннан соң аларны бер-берсенә тарта торган уртаклык та юк иде бит. Шулай булгач, очрашудан ни мәгънә?..

Әгәр дә көннәрдән бер көнне Нәгыйм, бакчачылык турындагы бер китапны эзләп, кибеткә килеп кермәсә һәм тышлыгына Азат фамилиясе язылган хезмәткә тап булмаса, тагын очрашырлар иде микән? Әмма тормыш үзенең көтелмәгән хәлләре белән кызык та. Кечкенә генә бер вакыйга кайвакытта кеше күңелендә хисләр давылы кубара, йокымсырап яткан җанын кузгатып җибәрә, кискен борылышка сәбәпче була.

Бу очракта да шундыйрак хәл килеп чыкты. Әлеге китапка юлыгу Нәгыйм өчен, беренчедән, шаккатырлык яңалык булса, икенчедән, моңарчы йокымсырап яткан уйларын, хисләрен дә уятып җибәрде. Ул нык гаҗәпкә калып: «Азат китабы?... Азатныкымы?!» — дип башын чайкады, күпмедер вакыт аңына килә, бу хәлне башына сыйдыра алмый басып торды.

Чыннан да, моңарчы кем иде соң аның күз алдында Азат? Университетның гуманитар факультетын тәмамлап, үз белгечлеге буенча фәндә эшләүче бәндәләрнең берсе. Ә бу инде, Нәгыйм уенча, шул Лобачевский сыны торган бакча артындагы сары бинага кереп бикләнү, көн яктысы күрмичә, аның моңсу бүлмәләрендә китап актарып, кәгазь кыштырдатып утыру дигән сүз. Тормыштан аерылган, китаптан башканы белмәгән ул мәхлуклар ни майтара алсын соң дип, еш кына үзен алардан өстен куеп фикер йөртергә ярата иде Нәгыйм.

Өйгә алып кайтып укый башлагач, китап аны тагын бер кат гаҗәпләнергә мәҗбүр итте. Иң элек хезмәт аңа саф татар телендә булуы, җанлы һәм образлы итеп, күңел җылысын җәлләмичә язылуы белән ошады. Дөрес, Нәгыймнең инде ун елдан артык татарча китап укыганы юк иде. Башта авыррак булды. Шулай да авылда чакта кереп калган тел, тиздән, кайдандыр эчтән калкып чыгып, аңа ярдәмгә килде. Шул чакны үзендә ниндидер буалар ерылып китүен сизде Нәгыйм.

Киң катлам укучыларга багышланган бу хезмәтен Азат чыннан да бик яратып, хәтта ашкынып язды. Фәннән ерак торган кешеләрне тарих-археология белән таныштыруны гына түгел, туган якның катлаулы үткәнен җанландыруны, аның мөһим дәверләрен яктыртуны да максат итеп куйды. Әлбәттә, китап хәтле китап язганда, аңарга байтак еллар күңелендә йөргән, экспедицияләр вакытында тупланган фикерләре, уйланулары, күзәтүләре, хисләре дә керде һәм, дусларның әйтүенчә, беренче карашка читкә тайпылу булып күренгән бу урыннар, киресенчә, хезмәтне бизи, аңа җан кертә һәм җылылык өсти, аның ышандыру көчен арттыралар гына иде. Ахыр чиктә, Азатның бу китабы унбиш-егерме еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясау кебегрәк килеп чыкты. Кайнар хис, ихлас күңел белән, фәнне һәм хакыйкатьне яратып язылган иде ул.

Нәгыймгә болар барысы да чит-ят нәрсәләр иде. Шуңа да карамастан, ул хезмәтнең рухын сизеп алды. «Мин Азатны бөтенләй белмим икән ләбаса?!» — дип, уңайсызлану хисе дә кичергәләде. Шулай итеп аның алдында өр-яңа дөнья ачылды, күп сораулар борынлады. Ул гомерендә беренче тапкыр тарих, халык язмышы, буыннар бәйләнеше кебек зур нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр булды. Гүя кемдер баз капкачын ачып куйды да, лампа тотып, аска төште һәм күп еллар бастырылып яткан хисләрен уятып җибәрде. Шул вакыт Нәгыймдә, Азатны күреп, бер сөйләшеп утыру, археологның эшләгән җирен үз күзләре белән күрү, табылдыкларны тотып карау теләге туды.

Әмма бу хакта ул Азатка әйтмәскә булды.

— Нәгыйм, минем тәгаллисе кечкенә генә эшем бар иде,— диде Азат.— Биш минутлык кына. Ә син әлегә тирә-як белән таныша тор.

Хуҗа китеп баргач, Нәгыйм, яхшысынмыйча, өстәл өстендәге кукыраеп утырган сумкасын җиргә алып куйды. Аннан тагын бер кат Калатау өстен күздән кичерде. Ләкин бу юлы да анда күз тукталырлык нәрсә тапмады.

Ул арада палаткаларның берсеннән фотоаппарат тоткан Азат килеп чыкты. Ул кап төймәләрен ычкындыргалап, Нәгыйм янына килде дә аны каралып яткан балчык өемнәренә таба алып китте. Казу мәйданына.

Азат күпьеллык тәҗрибә буенча белә иде: археология белән таныш түгел кешегә казу мәйданы берни сөйләми. Чокыр да чакыр, балчык та таш өемнәре генә. Аерма тик шунда — бу чокыр алай ук гади түгел: пөхтә итеп казылган, стеналары да, аяк асты да чистартылган, балчыгы үзгәрәк күренгән урыннар махсус билгеләнгән, кайбер җирдә казан кебек батып кергән уентылар бар, янсә берничә чокыр бер-берсе белән

кисешеп, катлаулы сын ясап бетерә. Кайбер җирдә ниндидер балчык баганалар да утырып кала... Белгеч өчен монда һәрбер нәрсәнең үз мәгънәсе булса, Нәгыймгә боларның барысы да сәер генә иде.

— Менә шушында казынам инде мин,— дип, Азат чокырга сикереп төште. Казу мәйданын беренче тапкыр күргән кунак исә, тирәнлеге бер метр чамасы булган бу киң чокырга чыннан да аптырап карап, иңнәрен генә сикертеп куйды.

Азат, чистартылган почмакка метр таягы сузып салып, аппаратын чертләтә башлады. Бер яктан төшерде, икенче яктан, сиздерми генә Нәгыймгә дә объективын төбәп алды. Шулай итеп тиз арада эшен дә төгәлләде.

— Менә шул гына иде. Хәзер инде нишләсәк тә була,— диде ул, аппаратын капка яшергәч, чокырдан җиңел генә сикереп тә чыкты.

— Син, зинһар, мәшәкатьләнмә. Эшең булса, эшлә, бүленмә,— диде Нәгыйм, үзен гаепле сизгәндәй.

— Юк, юк, ул турыда авыз да ачасы булма. Бүген бәйрәм итәбез,— диде Азат.— Без хәзер синең белән Кала-тауны әйләнеп чыгарбыз. Барысы белән дә танышырбыз. Шуннан соң сүз дә ничектер эзгә тизрәк төшәр.

— Килүчегә дә файдалы...

— Файдасы тисен дим шул. Рас кеше, кызыксынып, бабалары яшәгән борынгы шәһәр урынына килеп чыккан икән, аның турында мәгълүматлар да алып китсен...

— Әллә кемнәрне таныштыру туйдырмыймы соң?

— Ул турыда уйлаган юк. Минемчә һәр кеше үз халкының үткәнен белергә тиеш. Шунсыз ул чын мәгънәсендә гражданин да, патриот та була алмый.

Менә нинди икән Нәгыймнең авылдашы. Үз эшенә бирелгән галим. Тик артык житди түгелме соң? Хәер, ул бит китабында да нәкъ шундый... Мәктәптә чакта Нәгыйм аны мыштымрак бер малай дип кенә белә иде. Ә хәзер, кара, ничек ут чәчә. Азатның каты буйсынмас чәчләре әле һаман куе, кабарып тора икән. Инде көмеш тә кунган. Гел ачык һавада, кояшта йөрүдән йөзе каралган, янган, елмайганда күренеп киткән ак тешләре, сеңердән генә торган какча гәүдәсе аны чегәнгә охшатып калдырган. Кызык!

Нәгыймнең үзенә карап торуын күреп, Азат:

— Әйдә,— диде һәм аны Кала-тауны әйләндереп алган балчык өеменә — валга таба алып китте.

## II

Заманнар узу белән шактый утыра, тәбәнәкләнә төшкән бу өем кайчандыр каланы кыр ягыннан ныгыту өчен хезмәт иткән. Хәзер аның сырты тигезләнгән, җигүле ат үтәрлек. Шулай да ул әле өч метрлап булыр.

Менә алар өем өстенә менеп бастылар. Моннан караганда, үлән белән капланган Кала-тау өсте тигез болынны хәтерләтә иде. Бер читтәрәк казу мәйданы, кара балчык өемнәре күренә. Астан күтәрелгән җил, арыш кырына узышлый, үләннәрне тарап, төрле бизәкләр ясап уза. Йөзләрен рәхәт җилгә куеп, алар беравык тын гына басып тордылар. Күзләрен еракларга сузылып киткән таулар, калкулыклар, болыннар, зәңгәрсу томан эченә кереп югалган үзәннәр иркәләде.

— Рәхәт икән монда,— дип куйды Нәгыйм, Азатка таба борылып.

— Көннәр аяз торганда,— дип көлемсерәде Азат.— Безнең эшне белмәгән кеше археологны менә шулай җәй буе ял итә, табигать кочагында хозурланып ята дип уйлый торгандыр. Аның романтикасын гына күрәдер...

— Нәрсә, әллә романтикасы юкмы?

— Бар, нишләп булмасын, ләкин ул эчтәрәк, күзгә күренми... Менә шушы балчык өеме кирмәнне иң хәтәр яктан, кыр ягыннан килүче дош-

маннан саклаган.— Азат кулы белән дулкыннар йөгерешкән арыш кырына күрсәтте.— Гомумән, бабаларыбыз мондый ныгытмаларны корырга бик маһир булган. Аларны дошман кулы житмәслек урыннарга,— биек тау башларына, яр өсләренә — кыскасы, менүе кыен булган жирләргә салганнар. Бу Кала-тау болгарларның гадәти нытытмасы санала.

Нәгыйм өем алдында сузылган тирән чокырга — урга күз салгалап, археологны тыңлады. Биш метр чамасы тирәнлектәге чокырның шушы көнгә хәтле күмелми саклануы гаҗәп иде.

— Ай-һай тирән,— дип башын чайкап куйды ул.

— Элек тагын да тирәнрәк булган. Өем өстенә имән бүрәнәләрдән биек стена да бастырып куйсаң, бу корылма гомумән кеше үтеп керә алмаслык ныгытмага әйләнә...

Кунак чокыр төбенә карап торган килеш, шуннан өскә үрмәләүче борынгы сугышчыны күз алдына китерергә тырышты.

Балчык өеме, күз күреме жирне дуга кебек борылып үтеп, теге башы белән тирән ерымга барып тоташа иде. Ерым исә кайдадыр кырда ук башлана, Кала-тауга килеп житкәндә кызыл ярлы тирән чокырга әверелә. Шулай итеп, ул да кирмәнне кеше менә алмаслык текә яр белән ныгыта, һаман тирәнәя барып, болынга төшә. Язгы кар сулары да шушы ерымнан агалар, болынны сугаралар. Җәйләрен үлән монда котырып, бил тиңентен булып үсә.

Нәгыйм, ерым ярына килеп житкәч, аның тирәнлегенә шаккатып, байтак басып торды. Житмәсә, төбендә кайдандыр актарылып чыгарылган өстәл киңлеге ташлар да аунап ята иде.

— Әнә, яр кырыеннан үткән юлны күрәсеңме? — дип сорады Азат.— Әнә, киртләчләнеп, яр кырыеннан уза...

— Ә-ә... әйе.— Археолог төртеп күрсәтмәгән булса, Нәгыйм моңа һич тә игътибар итмәгән булыр иде. Жир убылу сәбәпле, юл урыны-урыны белән өзелгән, аны тәжрибәле күз генә тоташтыра, ялгый ала иде.

Кала-тауга менә шушы әйләнгеч юлдан менеп йөргәннәр, бөтен кирәк-яракны шуннан ташыганнар. Хәтта суны да астан алып менгәннәр шикелле.

— Нәрсә, әллә монда су булмаганмы?

— Әйе. Шул хакта хәтта бер риваять тә сакланган. Аны заманында Каюм Насыйри да, рус галимнәре дә халыктан язып алган булганнар. Анда болай диелә: Иске калада ханнар күпмедер вакыт торганнан соң, бер хатын елгадан су алып менгәндә сукрана икән. «Һай, гакылсыз патшалар, мондый жиргә кеше кала саламы? Бакчы, моннан су алып бу кадәр биек тауга менүе ни газаптыр»,— ди икән. Аның сүзен берәү ишетеп ала да ханга барып әйтә: «Бер хатын сине вә кала салган ханнарны яманлап, сукранып судан менәдер»,— ди. Ул вакытта монда Гомәр хан хөкем сөргән. «Яле, ул хатынны монда тотып китерегез әле, ни сәбәптән ханнарны яманлый икән, тикшерергә кирәк»,— дигән һәм үзенең вәзирләрен аны эзләргә жибәргән. Алар тиз арада әлеге хатынны табып та китергәннәр. Хан: «Әй, алла бәндәсе, син безне ни өчен болай яманлап, бездән сукранасың?» — дип сораган. Хатын: «Мин яманламадым, мәгәр дөресен әйттем,— дигән.— Мондый урынга гакыллы кеше кала салмас дип әйттем»,— дигән. «Каланы нинди жиргә салырга кирәк соң?» — дип сораган хан. Хатын: «Каланы алтын чабак эләккән жиргә салырлар»,— дигән. Шуннан соң хан: «Бар, эзләгез, алтын чабак кайда эләксә, шунда кала салырмын»,— дип боерган. Берничә адәм, кармак сала-сала, елга буйлап китеп барганнар. Алтын чабак эзләп килә торгач, хәзерге Сөембикә манарасы турысына килеп житкәннәр. Шунда бер алтын чабак тотканнар. Аннары, фәлән жирдә алтын чабак тоттык дип, тиз генә ханга хәбәрне житкергәннәр. Шуннан хан әмер биргән, осталар жыйдырып, Яңа каланы, ягъни хәзер синең белән мин яшәгән Казан каласын төзетә башлаган...

Азат сөйләп бетерергә өлгермәде, Нәгыйм башын чайкап кеткелдәп куйды.

— Әкият!.. Ни уйлап чыгармас халык!

— Әкият?.. Түгел шул, бөтен хикмәт тә риваятьнең чын җирлеге булуда. Шуңа күрә ул халык күңелендә яшәгән дә.

— Ә моны раслырлык берәр нәрсәң... бармы?

— Рәхим ит. Сакланып калган бәетләрнең иң борынгыларыннан саналган «Казан бәете»ндә дә нәкъ шул хакта әйтелә:

Ул бөлекнең соңында, Казан суы буенда
Ике угылы килүбән, Казан шәһәрен салдия,

— диелә. Монда, «ул бөлекнең соңында» дигән сүзләр монгол яулары вакытында Болгарның җимерелүен аңлатса, «ике угылы килүбән», дигәне Болган ханы Габдулланың уллары — Алтынбәк белән Галимбәкнең монголлардан качып котылуы, Казан суы буенда кала салдыруларын хәбәр итә.

— Анда бит Казан диелә, Иске кала түгел! — дип каршы төште Нәгыйм.

— Дөрес әйтелгән. Яңасына күчеп утырмыйча, ул ничек «иске» була алсын?

Нәгыйм, гап-гади нәрсәне аңламавына уңайсызланып, теше сызлагандай, йөзен чытып куйды, әмма мизгел эчендә бу йөз чытуы көлемсерәү белән алышынды.

— Белмим, белмим. Андый нәрсәләргә таянып кына ерак китеп була микән? Бу мине ышандырмый.

— Нәрсә ышандырмый? Казанга күчүме?

— Юк, анысы шулайдыр. Тик су булмау аркасында күчүләре ышандырып бетерми. Ничек инде крепостьны сусыз җиргә салсыннар, ди? Камалышта калсалар, ул чакта нәрсә?

— Әлбәттә, якын тирәдә аларның берәр чишмә кебек нәрсәләре булгандыр. Әнә бит, әле дә су агып ята,— дип, Азат ерым төбеннән җемелдәп аккан суга ымлады. Ләкин барыбер тау башында су күп булмаганга охшый. Ә күчүнең төп сәбәбе шәһәрнең Казан елгасы тамагыннан ерак торуындадыр, күрәсең. Татар тарихчысы Гайнетдин Әхмәров та шул фикерне яклый: сәүдә әһленә көймәләр белән килеп йөрү җиңел булсын өчен, Казанга күчкәннәр, ди.

Нәгыйм кабат башын чайкап куйды, ничектер санга санамагандай елмайды.

— И-и, слуши... син дә инде... Легендалар кайгысымыни хәзер кешедә?

— Алайса мин мөгез чыгарырга тырышам?

— Шулайрак.

— Ярар. Анысы турында соңрак сөйләшербез. Тик мин сөйләгән риваять үткән гасырда ук язып алынган. Авыл картлары аларны әле дә булса сөйләп йөри!

Нәгыйм аңа ышанмыйча карады.

— Әйе, әйе,— диде Азат.— Күрше авылларда йөргәндә үз колагым белән ишеттем, язып та алгаладым.

— Чынмы?

— Ышанмасаң, өйгә кил, вариантларын күрсәтермен. Аны һәркем үзенчәрәк хәтерли.

Нәгыйм уйланып торды да бераздан тагы шул мәсьәләгә әйләнеп кайтты.

— Син менә легендаларның реаль җирлеге бар дисең. Димәк, без һәр легендага ышанырга тиеш?

— Юк. Мин бит алай кистереп әйтмәдем. Әмма, утсыз төтен чыкмый дигәндәй, риваять нигезендә, һичшиксез, нинди дә булса реаль вакыйга ята. Әлбәттә, күп вакытта ул үзгәртелгән, күпертелгән була. Ә кайчакта бөтенләй танымаслык хәлгә керә. Шулай да хыял җимешен реаль вакыйгалардан аера белгәндә, легенда да мәгълүмат бирерга мөмкин. Фәндә моның шактый уңышлы мисаллары бар.

— Нәрсәне күздә тотасың?

— Алыйк үткән гасырда яшәгән немец археологы Генрих Шлиманны. Ул борынгы грек легендаларында телгә алынган Троя шәһәрен эзләп таба, җир астыннан гаҗәеп әйберләр казып чыгара. Ә бит аңа хәтле Трояны легендалардагы шәһәр дип кенә уйлаганнар. Безнең көннәрдә дә моның мисаллары бар.— Сүз озакка сузыласын чамалап, Азат үләнгә утырырга ишарә ясады. Утырышкач, дәвам итте: — Тур Хейердал, Тим Северин кебек галимнәр турында ишеткәнең бардыр бәлки. Алар төрле тәҗрибәләр үткәреп, борынгы легендаларның, кешелек хәтерендә сакланган, имеш-мимешләр дип йөртелгән хәбәрләрнең дөреслеген раслыйлар. Норвегия галиме Тур Хейердал, мәсәлән, борынгы халыкларның бер континенттан икенче континентка күчүе, ягъни миграция юллары белән кызыксына, ә ирланд Тим Северин экспериментал филология белән шөгыльләнә. Менә күптән түгел ул, бернинди приборлардан файдаланмыйча, борынгы аргонавтлар юлын үтте — Урта диңгездән Грузиянең Колхида төбәгенә килеп чыкты.

— Булса соң, бу бит әле миф йөз процентка исбатланды дигән сүз түгел.

— Анысы шулай. Йөз процентка түгел. Әмма аның булу мөмкинлеген тәҗрибә ярдәмендә раслау үзе дә зур эш.

— Тукта, тукта... Син моның белән нәрсә әйтмәкче буласың? — дип төпченде Нәгыйм. Үзе дә сизмәстән эңгәмә белән мавыга башлады ул.

— Риваять һәр очракта да коры хыял җимеше генә булмый, дим. Шул исәптән Иске каладан Казанга күчү дә...

Нәгыйм дәшмәде, маңгаенда тирән сызыклар хасил булды.

— Гаҗәп...— диде, ниһаять.

— Нәрсәсе гаҗәп? Халык борын-борыннан үз тормышындагы вакыйгаларны буыннан-буынга сөйләп килгән. Шулай аның аңы формалашкан.

— Юк, мин ул турыда әйтмим. Мине менә нәрсә гаҗәпләндерә: җир шарына көлгә әйләнү куркынычы яный, дөнья кыл өстендә тора, шул вакытта кемнәрдер борынгы легендаларны, мифларны өйрәнеп йөри. Кемгә кирәк бу? Ни әһәмияте бар моның егерменче гасыр ахырында? — дип ярсып ук китте Нәгыйм. Гомерен техникага багышлаган, аңа табынып яшәгән, хәзер барысын ул хәл итә, аннан да зур, көчле, мөһим нәрсә юк дип иманып гомер иткән бу кеше үзенең башка дөньяга килеп керүен сизде. Монда башка категорияләр белән һәм башкача фикер йөртәләр иде. Шушындыйрак тойгы Азатның китабын укыганда да үзен сиздереп алган иде. Менә кабат шул ук хәл... Нәгыйм кулга тотып булмый торган нәрсәләр белән шөгыльләнүче бу халыктан гомер буе эчтән көлеп, үзен алардан өстен куеп яшәде. Һәм шушы өстенлекнең уйламаганкөтмәгәндә югала башлавын тою аны ни өчендер өркетә иде.

Азат исә кунакның халәтен сизмәде, фикерен очлап куйгандай итеп әйтте:

— Шундый куркыныч янап торганда да төшенкелеккә бирелмәве, үз-үзен аңларга, үткәнен күбрәк белергә тырышуы кешенең ныклыгы турында сөйләмимени?

Азатның җитди тоны, үз-үзенә ышанып сөйләве кунакның ачуын китерә башлаган иде инде. Ә соңгы сүзләре утка май салгандай килеп чыкты.

— Ныклык... ныклык,— дип үчекләп алды аны Нәгыйм, янак сөякләрен уйнатып.— Мин сине реалисттыр дип уйлый идем...

Тынлык урнашты. Азат теш арасына кыстырылган үлән сабагын чәйнәгәч, авызына ачы тәм таралуын сизде. Кунак, тезләрен кочаклаган килеш, каршы ярга төбәлеп утыра иде. Шул вакыт Азатның исенә мәктәп еллары килеп төште. Нәгыймнәр хәлле гаиләдән санала иде. Аның атасы гел бригадир булып йөрде, барысы да аның кулында иде. Аты, утыны, печәне... Халык, бил бөгеп, аның каршына бара. Малай да,

таяныр көч сизеп, үз-үзенә ышанып, яшьтән үк тормышның рәтен чутын белеп үсте. Мәктәп елларында алар әллә ни дус була алмадылар. Азатның әтисе фронттан яраланып кайтты. Ишегалдыннан чыгарлык түгел иде. Шуңа күрә тормышны күбрәк әнисе белән малайның үзенә тартырга туры килде. Институтка да Азат Нәгыймнән соңрак, армиядән әйләнеп кайткач кына керде. Моның үз сәбәбе бар иде. Нәгыйм белән Азат мәктәпне тәмамлаганда авылда бер сәер тәртип гамәлгә кертелде. Хәзер инде аны бер мәзәк итеп кенә искә аласың, ә ул чакта... ул чакта байтак күз яшьләре түгелде, күңелләр төште. Әлеге тәртип буенча авыл мәктәбен тәмамлаган яшьләргә паспорт ике елдан соң гына бирелә иде. Ә паспортсыз кая барасың, сине бер генә институт та кабул итмәячәк, заводка да керә алмыйсың. Шул сәбәпле укыйсылары килгән байтак яшьләр авылда утырып калды. Дөрес, ике елдан соң алар да кулларына документ алдылар, кайбер үҗәтрәкләре барыбер теләкләренә иреште, студент булды. Ләкин күп вакыт шушы ике ел мәсьәләне авыл файдасына хәл итеп тә куя иде. Кемдер кияүгә чыга, өйләнә, мәктәптә алган белем дә саега төшә, яисә кеше башкачарак фикер йөртә башлый — кыскасы, авылда төпләнеп кала.

Шуның аркасында Азат мәктәпне тәмамлаган елны ук институтка барып керә алмады. Дөресен әйткәндә, бу файдага гына булды. Армиядә ул үзенең киләчәге турында ныклап уйланды, үзе өчен барысын да ачыклап кайтты. Ә менә Нәгыйм, бригадир малае буларак, теге карарны ничектер әйләнеп үтә алды, мәктәпне тәмамлау белән үк Казанга — ул заманнарда бик абруйлы саналган инженерлыкка укырга китеп барды.

Тагын тургай тавышы ишетелде. Ул кайдадыр еракта, өемнең теге ягында сайрый иде шикелле. Бу юлы аның сайравы тоныграк ишетелә. Шулай да Азат аны бирелеп тыңлады. Юк, бервакытта да тыныч кына тыңлый алмый ул бу кошның сайравын. Менә шушы минутта да тургай җыры аның җанына кырлар иркенлеге, күкләр зәңгәрлеге сыман килеп керде, күңеленә утыра башлаган юшкынны юып төшерде.

Бәлки, Нәгыйм дә тургай җырын тыңлап утырадыр?..

Бераздан аларның күзләре очрашты, бер-берсеннән гафу үтенгәндәй, сүрән генә елмаешып куйдылар. Аннан урыннарыннан тордылар да Кала-тауның иң биек, иң матур ноктасына — болын ягына киттеләр.

Моннан караганда, аста җәйрәп яткан болынның таулар кочагына ук кереп торуы бигрәк тә күзгә ташлана иде. Таулар кулларын җәйгән, болын исә, иркәләнеп, аларның күкрәгенә килеп сыенган, йокымсырап ята. Үзән аръягында, җиргә сибелешкән шакмакларны хәтерләтеп, авыл өйләре тезелешкән, арырак тимер юл уза, аннан да арырак саргылт кырлар башланып китә. Офык читенә җитәрәк алар карасу-зәңгәр урманга барып тоташа, ә икенче тарафта бу басулар зәңгәрсу томан эченә кереп югала, күк белән кушыла.

Шушы матурлык, иркенлек Азатның йөрәгенә кереп урнашты, аерылмас юлдашына әверелде. Бернičә сезон дәвамында шушы күренешне һәркөн күреп, аңа күнегеп бетсә дә, кабат үзенең дулкынлануын сизде Азат, хискә бирелеп, сокланып басып торды.

Аның яшерен горурлыгына әверелгән бу тау, елга, тугайлар, тезелешеп киткән калкулыклар һәм кырлар манзарасы Азатның тормышында зур урын алып тора иде. Бигрәк тә Кала-тау!..

Бу ничек шулай килеп чыккандыр, анысын Азат үзе дә әйтеп аңлатып бетерә алмас иде. Әмма Кала-тау аның өчен үзеннән-үзе тере җан иясенә әйләнде. Археолог аның белән тере зат белән сөйләшкәндәй сөйләшә, кайвакытта күңелен бушата, шатлыгын-кайгысын уртаклаша, хәтта үтенә, киңәш сорый иде.

Әйе, хәтта киңәш сорый...

Андый чакта Кала-тау сыртын күперткән килеш дәшми генә тыңлап тора. Ул бик карт инде, күпне күргән, күпне ишеткән. Үз гомерендә сөй-

ләшеп арган. Хәзер ул тынлый гына бела. Тик Кала-тау аны хуплыймы, юкмы — моны күңеле белән сизә Азат. Аңарга ниятләрен, планнарын сөйли дә, тынып калып, тыңлап тора. Кала-тау аңарга жил сызгыруы, тал яфракларының кыштырдавы, иелә-сыгыла чайкалган үләннәр пышылдавы, бытбылдык яисә тургай тавышы белән җавап бирә.

— И мәһабәт Кала-тау! — дип эндәшә аңа Азат.— Син инде бу дөньяда күп яшәгәнсең, бик күп хәлләрнең шаһиты булгансың. Хәтереңдә — чал тарих, халкымның үткәне. Болгар бабаларымның бу якларга килеп урнашуы да, монда тормыш корып, түбәнә кирмән салып, аны биек өемнәр, тирән урлар, чокырлар, диварлар һәм манаралар белән ныгытып, табигатьнең гүзәл почмагында бөтенләйгә утырып калулары да — барысы, барысы синең күз алдыңнан үткән...

И мөхтәрәм Кала-тау! Карт булсаң да — зиһенең үткен, барысы да хәтереңдә. Синең тәнеңдә тарих үзенең җуелмас эзләрен калдырган, эчеңдә аның серләрен, кыйпылчыкларын саклыйсың. Боларны безнең бабаларыбыз рухын дәвам итүчеләрнең табуы, күрүе, белүе кирәк. Без бабаларыбыз мирасын югалтмаска тиеш. Шул мирасны саклаган, аңа таянган халык кына яши һәм яшәячәк...

И мәрхәмәтле Кала-тау! Ач син безгә серләреңне!.. Зинһар, яшермә!.. Алар безнең бүгенгебез өчен кирәк!..

Һәм көннәрдән бер көнне коеп яңгыр яуганда, Кала-тау телгә килде, Азатка ишарә ясады,— яшен уты аның күкрәгенә төртеп күрсәтте.

Азат палатка тәрәзәсеннән табигатьнең ярсып-ярсып бушануын күзәтеп утыра иде. Кала-тау түбәсенә яшен китереп суккач, археолог тетрәнеп китте, бу тикмәгә түгел, дип уйлады. Азат аңлап алды: ул нәрсәгәдер ымлый, күрсәтә иде шикелле. Егет шундук койган яңгыр астына йөгереп чыкты, җиңелчә төтенләп торган урынны таш белән билгеләп, кире палаткага ашыкты.

Иртәгесен шул урында шурф казый башладылар, күп тә үтмәде, аннан хәзинә — чүлмәккә тутырылган борынгы акчалар килеп чыкты.

Бу Кала-тауның аны үз итүе иде. Аның ышанычын Азат шулай казанды...

Бәгыре киселгән, кара кайгы килгән чакта да Азат Кала-тау каршысына килде, аннан киңәш сорады.

Хәбәрне төн уртасында Айратның курсташы Рөстәм китерде. Алар болай да, улларының тиешле сәгатьтә кайтмавына борчылып, ут йотып утыралар иде. Менә ишектә кыңгырау чылтырады, әниләре ачарга ашыкты. Тик ишектә Айрат урынына Рөстәм басып торганын күрделәр. Егетнең күзләре кызарган, иреннәре калтырый иде.

Егет бусагадан атлап керүгә, әниләре, нидер сизенеп:

— Айрат кайда? Нәрсә булды? — дип куркынып сорады.

Рөстәм күзләрен яшерде, башын аска иде, бүреген сыдырып төшерде. Һәм стенага капланып үксергә тотынды.

Азат аны, калтыранган иңнәреннән тотып, стенадан куптарды, үзенә таба борды, ахыр чиккә җитеп тартылган нервыларын көчкә тыеп:

— Нәрсә булды? — дип егетнең күзләренә төбәлде.

— Ул... аны... яраладылар...— дип кенә әйтә алды студент, дөресен әйтергә көче җитмәде.— Бер бандит... Караңгы ишегалдында...— һәм тагын күзләрен яшерде.

Моны ишетүгә, әниләре чайкалып китте, стенага тотынып, идәнгә шуыша башлады.

Улларын җирләгәннән соң ике-өч көн үтүгә, Азат дәшми-тынмый гына чаңгыларын хәзерләде, Кала-тауга барырга җыенды. Кабер тынлыгы кергән өйдән, хатынының сүнеп калган күз карашыннан ярты гына көнгә булса да котылып торасы килде аның. Хатыны Айрат үлемендә аның да гаебе бар дип саный, сагышлы, рәнҗүле күзләре Азатта еш туктала иде.

— Син... син рөхсәт иттең дружинага йөрергә. Җитмәсә, һаман саен аркасыннан сөеп, хуплап тордың. Шәһәребезне әшәке бәндәләрдән арындырырга булыша янәсе...

Әниләре шундый сүзләр тәкрарлый-тәкрарлый елады да елады. Болай да жаны таш булып каткан Азатның түземе төкәнде, хатынын юатырдай сүзләр дә инде табылмый иде. Аның эчендә нәрсәдер кысылганнан-кысыла бара, сулышы тарая, гүя гәүдәсен нык баулар белән урап алганнар да, турая алмый азаплана сыман...

Электричкадан төшеп, авыл аша үтүен дә, ак даладай жәелеп яткан болынга житүен дә хәтерләми ул. Шулай бераз баргач кына айнып киткәндәй булды Азат. Күңеленә тышкы дөнья үтеп керде. Пакь карларны, елга буендагы бәс сарган таллыкларны күрде, соңгы вакытта шундый матур көннәр торганлыгы исенә төште. Атна буе ул моңа игътибар итмәгән, күзләре күрсә дә, күңеле еракта, жаны бикле булган. Улын югалту ачысы барысын да кысрыклап чыгарган.

Бераздан ул Кала-тау өстенә күтәрелде. Аның иң биек ноктасына басып, кояш нурларында жемелдәгән зәңгәрсу карларны, аларның жир яраларын күмеп, бөтенесен тигезләп, сөзәкләнеп калган үрләргә күтәрелүен, аннан, әллә кайларга сузылган офыкка китеп югалуларын карап, байтак басып торды. Әмма бүген жаны сыкрый, бу матурлыкны күңеле кабул итми иде.

— И олуг Кала-тау! — дип, тауга мөрәжәгать итте Азат.— Моңа хәтле тормышта минем ике куанычым бар иде: берсе — газиз улым Айрат, икенчесе — син! Мин улымны үз юлымнан китүче, эшемнең дәвамчысы итеп әзерли идем. Ул инде хезмәтемне аңлап, аны яратып та өлгергән иде. Миңа ярдәме дә тия башлаган иде...— Шушы сүзләрдән соң Азатның күкрәге кысылды, күзләренә яшь килде.—Хәзер ул юк, гомере киселде... Улым безнең арадан китте...— Азат тагын беравык тынып торды.— Хәзер минем тормышымда син генә калдың, Кала-тау, син генә... Нишләргә соң миңа хәзер, киңәш бир, Кала-тау! Дәвам итәргәме миңа бу эшне, юкмы? Ачарсыңмы миңа серләреңне? Монда сарыф ителгән көч, вакыт берәр нәтижә бирерме? Әйт миңа шуны, жавап бир, Кала-тау! Үтенәм синнән!..

Шушы сүзләрне әйтте дә Азат, суларга да куркып, тынып калды. Ул жавап көтте...

Кинәт Кала-тауның эченнән нindидер өн ишетелгәндәй тоелды һәм ул аваз көтмәгәндә өермәгә әверелде, үзән буйлап узды, таллыкларның бәсен кагып төшереп, кайтаваз булып сулдагы калкулыкка килеп бәрелде.

— Ижтиһат ит!.. Ижтиһат ит!.. Тукталма!..

Экспедициягә килгән һәр кешене Азат шушы ноктага китереп бастыра да, «Хозурлан, хәтереңдә калдыр, бәлки, синең күңелеңдә дә шушы изге жиргә карата мәхәббәт чаткылары уяныр», дигәндәй, аны читтән генә күзәтеп тора. Ул Нәгыймне дә монда шундый ният белән алып килде...

Ә кунак биленә таянган да, аякларын селкеткәләп, сүзсез генә басып тора, гүя музей залына элеп куелган мәшһүр картинага бәя бирә.

— Кара, монда күренеш чыннан да шәп икән. Фотосы ничек чыга, ясап караганың бармы?

— Юк,— диде Азат, бу күренешләрне күп тапкыр рәсемгә төшергән булса да.

— Фотоаппаратны алырга оныткамын. Истәлеккә ярыйсы икән...

Нәгыймнең табигать ямен генә соклануы күңелен төшерсә дә, кунагын үзенчә аңларга тырышты Азат. Чыннан да, ни өчен әле Нәгыйм башка нәрсәләргә мөкиббән китәргә тиеш? Аның бит монда беренче тапкыр килүе, күп нәрсәне белми, бүтән һөнәр иясе буларак, аңлап та житкермидер... Шуңа күрә бөтенесен бик гадәти нәрсә итеп кабул итә. Бу таулар аның өчен бары тик таулар, болын да бары тик болын, елга да... Ә Азат исә бу жирләрне бөтенләй башкача күрә: аның хәтерендә бу төбәк турында еллар буе тупланган мәгълүмат, төрле вакыйгалар, жанлы тарих яши, һәм шушы нәрсә болай да гүзәл төбәкне тагын да жанландыра, аңа рух һәм яңа мәгънә өсти.

Аерма шунда: бу күренешләрне Азат акыл белән генә түгел, хис аша да кабул итә.

...— Күреп торасың, урын хәрби күзлектән караганда да, бик уңайлы сайланган,— дип, сөйләвен дәвам итте Азат.— Тирә-юнь ап-ачык, дошманның килүе әллә кайлардан күренеп тора. Кыскасы, кирмән кыр ягыннан биек балчык өемнәре, уңнан тирән чокыр, болын ягыннан текә яр белән ныгытылган. Коймалы, манаралы ныгытманы басып алу уен эш түгел...

Азат шушы биек ноктага баскан килеш кунакка борынгы шәһәрнең тарихыннан мәгълүматлар бирергә тотынды. Башта ул үзләре басып торган тау башында элекке заманнарда шәһәрнең үзәге урнашуын, монда хан үзе, аның якыннары, руханилар, аксөякләр, дәүләт эшләрен алып баручылар һәм шәһәрне саклаучы гаскәр торуын сөйләде. Казып чыгарылган һөнәрче алачыгы күрсәткәнчә, монда кайбер осталар да яши, чөнки вак-төяк йомыш белән дә аска төшү, елга аръягындагы бистәгә йөрү уңайсыз булгандыр. Ә ул бистәдә хезмәт халкы урнашкан була. Анда алтын-көмешчеләр, бакырчылар, чүлмәк осталары яшәгән, алачыклардан металл чыңы яңгырап торган, балта тавышлары ишетелгән, балыкчылар елгада зур-зур балыклар тотканнар. Ә елганың ул заманнарда мул сулы, тирән булуы шик уятмый — казыган вакытта еш кына эре-эре балык умырткалары килеп чыккалый икән. Кыскасы, моннан җиде-сигез йөз ел элек бу урында мәш килеп болгар бабаларыбыз яшәп яткан. Моны материаль культура калдыклары, төрле табылдыклар раслый, һөнәрчеләр бистәсен казыганда әле берәр өй яки остаханә нигезенә, чүлмәк яндыру мичләренә, тимерче алачыгына килеп юлыгасың, эш кораллары, савыт-саба, бизәнү әйберләре, тәңкәише бик күп тормыш кирәк-ярагы табыла тора. Һәм бу нәрсәнең иң кыйммәтле ягы шунда — аларда болгар осталарының эш алымнары, традицияләре ярылып ята. Ә бу инде халыкның мәгълүм сәбәпләр аркасында Болгар дәүләтенең үзәк районнарыннан монда күчеп килүе, бөтенләйгә урнашып калуы турында сөйли...

Боларны тыңлаганда Нәгыймне каршылыклы хисләр биләп алды. Дөресрәге, Азат аны тагын бер кат гаҗәпләнергә мәҗбүр итте. Бер караганда, алар менә шәп-шәрә тау башында басып тора. Каралып яткан казу мәйданы белән балчык өемнәреннән гайре монда берни юк. Ә ничек яратып, бирелеп сөйли Азат! Теле телгә йокмый, димәк, барысы да аның күз алдында басып тора. Икенчедән, чынмы соң болар? Уйлап чыгарылмаганмы, күпертелмәгәнме? Гашыйк кеше үзенең мәгъшукасын идеаллаштырган кебек, Азат та үзе казыган Кала-тауны зурайтып, ролен үстереп, идеаллаштырып күрсәтергә тырышмыймы? Нәгыйм үзе, салкын акыл белән эш итүче буларак, мондый очынуга, бирелгәнлеккә, җирдән аерылган романтизм, дип, шикләнеп карый. Ул барысын да бизмәнгә салып, хисләрен йөгәнләп яшәргә өйрәнгән. Бәлки, шуңадыр, күңел түрендә канәгатьләндерелмәгән бер ихтыяҗ яшәвен сизә ул — аның да, алны-артны уйламыйча, Азат шикелле хискә бирелеп, онытылып бер яшәп аласы килә. Археологның хикәятен тыңлаганда, бу теләк аңарда кабат уянды, күтәрелә, үзен ныграк сиздерә башлады кебек.

Их, аның кул астында да менә шундый үз эшенә бирелгән кешеләр күбрәк булсын иде! Эшләп күрсәтер иде ул! Таяныр кешеләрең булганда эш тә күп тапкыр җиңелрәк бара бит...

...— Иске кала турында әйтеп үткән идем инде,— дип сөйләвен белде Азат.— Су юлында урнашкан бу кала тора-бара төбәкнең үзәгенә әверелә, халкы арта. Бабаларыбыз аны Яңа Болгар дип атыйлар.

— Монда кайчан ясалуы төгәл билгеле берәр нәрсә табылганы бармы? — дип сорады Нәгыйм.

— Бар, нигә булмасын.

— Нәрсә?

— «Болгар әл-Җәдид» дип язылган акчалар. Галимнәрнең әйтүенә

караганда, аларның кайберләре монда сугылган. Без студент чакларда, монда борынгы бер кабер ташы да табылган иде. Анда да төгәл дата бар иде.

Азатның күз алдына әлеге таш табылган бәхетле ел килеп басты. Өченче курста укый иде. Ул чакта инде аңа археология җене кагылып өлгергән, экспедицияләрдә катнашып, казып та караганы бар иде. Әмма Азат ул җәйне башка якта эшләде, ташның ничек табылуын күрмәде. Көз җитеп, укулар башлангач, гадәт буенча, археология түгәрәгенә йөрүче студентларга үткән сезонның нәтиҗәләрен сөйләделәр, игътибарга лаеклы табылдыклар белән таныштырдылар.

— Беләсезме, бу таш безнең өчен нинди кадерле бүләк! — дип, яраткан профессорлары аларның алдына кабер ташының фотографиясен китереп салды да, дулкынланып, арлы-бирле йөренде.— Бу бит болгарларның төньяк районнарга бик иртә үтеп керүен раслый торган менә дигән дәлил. Әгәр моңарчы без бу фикерне чүлмәк ватыклары һәм башка матди культура калдыклары белән раслап килсәк, хәзер инде безнең кулда ташка уелган дата бар. Ә бу кире каккысыз дәлил! Димәк, безнең карашыбыз тулысынча раслана. Бу юлы инде бөтенләйгә!..

Шушы сүзләрдән соң аудитория ду килеп кул чапкан иде.

...— Бу — Болгар дәүләте җирләрендә табылган кабер ташларының иң борынгысы,— диде Азат, хатирәләреннән аерылып.

— Кызык...— диде Нәгыйм, озак басып торудан каткан буыннарын язгалап,— шәп-шәрә җирне казып та мәгълүмат алып була икән...

— Кайда һәм ничек казырга икәнен белсәң, әлбәттә,— диде Азат, аннары сәгатенә карап, көлемсерәп өстәде: — Җитәр, кунакны гел сүз белән сыйламыйлар. Әйдә, бераз капкалап алабыз.

## III

Чыннан да, өйлә вакыты җиткән иде. Кояш инде иң югары ноктасына күтәрелгән, күләгәләр кыскарган, кыздыра. Җил дә тынган, һава ничектер куерып, тыгызланып калган кебек. Тирә-юньдәге тынлык ниндидер дәһшәт вәгъдә итә сыман. Үлән арасында чыркылдаган чикерткә тавышына кадәр ишетелеп тора. Бу бөркү тынлыкны авыл кырыеннан узган поездлар тавышы гына ара-тирә сискәндереп куя.

Азат күккә карап торды да: «Ява гына күрмәсен, юкса тагын ярты көн казу мәйданын чистартып үтәчәк»,— дип уйлап алды. Аннары сөйләнә-сөйләнә, учакны кайгыртырга кереште. Бу эш Нәгыймгә дә тансык иде булса кирәк, урындык алып, ул да якынрак килеп утырды. Бер-ике минуттан учак дөрләп китте, һавага төтен сузылды. Хуҗа кеше корымга буялган кастрюлен, шундый ук кара чәйнеген ут өстенә куйды. Учакка утын өстәде. Аннан соң гына брезент белән капланган фанер әрҗәдән савыт-саба, пычак, ипи-тоз, суган ише әйберләрне берәм-берәм чыгарып, өстәлгә тезәргә кереште.

Сүз ничектер өзек-төтегрәк барды. Бер нәрсәдән икенчесенә сикерде, авылны, уртак танышларын искә алдылар, кемнәрнең кайда, нинди эштә, кем булып эшләвен барлап чыктылар.

Аннары Азат палаткадан транзистор алып чыкты. Азат күреп белә торган диктор заманнар үтү белән сүзләрнең үзгәрүе, ихтыяҗ булмау сәбәпле кайберләренең кулланыштан төшеп калуы, онытылуы турында сөйли иде. Эфирда «Тел күрке — сүз» тапшыруы бара иде. Гадәттә, Азат аны яратып тыңлый, калдырмаска тырыша. Экспедициядә радио зур дөнья белән тоташтыручы бердәнбер әйбергә әверелә, аның кадере арта.

Бераз тыңлагач, Азат:

— Синең игътибар иткәнең бармы? Без бәләкәй чакта «күмәч» сүзе бик еш әйтелә иде,— дип куйды.— Ә хәзер бөтенләй диярлек ишетелми. Батон да батон...

Бөтенләй башка уйларга бирелеп утырган Нәгыйм сүзсез генә аңа карап алды да көлемсерәп куйды.

— Нинди матур сүз иде ул «күмәч»...

Икесенең дә күз алдына балачакның тәмле күмәчләре килеп басты.

— Кара, кызык тапшыру икән,— диде Нәгыйм, дикторны бераз тыңлап торгач.

— Син нәрсә, бөтенләй колак салмый идеңме әллә?

— Юк шул. Телевизор гел эшләп торгач, радионы хәзер тыңлаган да юк. Аннан соң минекеләр бит туган телне аңлап та бетермиләр.

— Киләчәктә алар сине якын итәрме икән соң?

Нәгыйм җавап бирмәде, бер ноктага төбәлеп, уйга калды. Йөзенә караганда, уйлары бик күңеллеләрдән түгел иде ахрысы.

Ул арада су да кайнап чыкты. Азат туралган бәрәңгесен кастрюльгә салды, ит консервасы ачып куйды, суган арчыды. Кояш кыздыруына чыдый алмыйча, Нәгыйм пинжәген урындык аркасына элде, күлмәк төймәләрен ычкындырды, аннан соң сумкасыннан зур козыреклы сәер кепка тартып чыгарып, башына киде. Болай ул бернәрсәгә дә исе китми торган чит ил туристына охшап калды. Ә Азат, авыз эченнән нидер көйли-көйли, һаман учак тирәсендә бөтерелде. Ара-тирә шулпаны кабып карый, телен шартлатып куя, шул ук вакытта кунагын да онытмый, аңа да бер-ике сүз ката иде.

Нәгыймнең күптән инде болай иреккә, табигатькә чыкканы юк. Шуңа ул бөтен ыгы-зыгыдан арынып, тугарылып, хәтта завод мәшәкатьләрен дә онытып, Азатның аш пешерүен күзәтте, төтен бөркеп торган учакка карап рәхәтләнеп утырды. Бераздан археологның шөгыле аңа табигый яшәүнең бер гәүдәләнеше булып тоела башлады. Гасырлар буе шулай барган. Бары без генә көннәр буе һавасыз биналарда утырабыз һәм шуны әле тормыш дип атыйбыз. (Нәгыйм үзе турында уйлап алды.) Дөресен генә әйткәндә, бу минутта ул Азаттан бераз көнләшә иде. Кул һәм акыл хезмәтен берләштерә алган лабаса: җәй көннәрен һавада булса, кышларын бүлмәдә, өстәл янында материалларын тәртипкә китерә. Гармония шулдыр, күрәсең.

Нәгыйм үзенең шушы көнләшүенә гаҗәпсенеп куйды. Үзе дә сизмәстән тагын Азат белән бәхәсләшә башлады. «Мин нигә аннан көнләшим соң әле? Ничек мин аңардан көнләшә алыйм ди? Мин! Җаваплы вазифа башкаручы, көн саен әллә нихәтле четерекле мәсьәләләрне хәл итүче цех башлыгы — ничек инде аннан көнләшим ди?»

Башта бик көчле, бөтенесен күмеп китәрлек булып тоелган бу дәлилләр, уйлый торгач, ничектер кечерәя башлады. Әлбәттә, аның эше Азатныкына караганда ыгы-зыгылырак һәм мәшәкатьлерәк. Ләкин ул аңа Азат кебек бирелгәнме? Азат кебек яратамы соң ул үз эшен? Боргаланмыйча гына әйткәндә, юк, алай ук яратмый аны, менә бит хикмәт нәрсәдә!.. Аңарда Азаттагы җиңеллек, канат юк, тәртә арасына кереп баскан да тарта да тарта, теләсә дә, теләмәсә дә... һәм көндәлек мәшәкатьләрдән өскәрәк күтәрелә алмаган шушы ыгы-зыгы аның бөтен вакытын йота бара...

Тарихи урынга килеп чыгу, Азат сөйләгәннәр, мондагы иркенлек, тынлык Нәгыймне үзеннән-үзе уйга салды. Ул үз тормышын, аның төрле дәверләрен күз алдына китереп, шуларны эчтән кичереп утырды. Әйе, кеше гомере — поезд юлы түгел, анда төрле сикәлтәләр очрап кына тора. Кайвакыт, ятып калмас өчен, кемнәрнедер аркылы атлап та үтәсең, күңелең кушканга каршы да киләсең. Бигрәк тә аның өйләнүе шулайрак килеп чыкты.

Лика — институттан соң Нәгыйм эшли башлаган цех башлыгының бердәнбер кызы иде. Чибәр, зәвыклы, укыган. Әмма тормыш итү өчен бер кимчелеге бар — кулыннан эш килми. Үз-үзенә бик нык ышанган, ихтыяр көче ташып торган яшь инженер Нәгыймнең аңысына бик исе китмәде,— тора башлагач, кулга алырмын дип уйлады. Кызны кулга гына төшерсен.

Аңа өйләнеп алса, Нәгыймнең эшләр пешәчәк. Әти кеше киявен онытмас, үзе пенсиягә китеп барганчы, берәр җылы урынга утыртып калдырырга ничек тә җаен табар.

Бабай белән бер-берсен бик тиз аңладылар. Максатлары туры килде: бабайга юлдан язып барган иркә кызын тизрәк берәр ышанычлы, төпле кеше кулына тапшыру кирәксә, авылдан чыккан сәләтле инженер исә тизрәк шәһәр зыялылары арасына керергә, анда үз кешегә әверелергә ашкынды. Шуңа күрә монда каршылык булмады.

Лика да бу вакытта инде ышанычсыз, капризлы шәһәр егетләреннән тәмам туйган, берәр нык беләккә таянып ял итү, күпмедер вакыт тынычланып калу турында хыяллана иде. Кызны кулга алырмын, үземә кирәгенчә тәрбияләрмен дип, Нәгыйм генә бик тә ялгышкан, үз өстенә күбрәкне алган булып чыкты.

Уйлана торгач, Нәгыйм шуны бик ачык аңлады: ул гомер буе башкалардан өстен булырга омтылган, бөтен көчен шуңа салган, көчәнеп яшәгән икән. Бу көчәнү аны табигый яшәүдән аерган. Нәкъ менә шушы омтылыш, һәрвакыт дулкын өстендә калырга тырышу тота икән аны бу цех дигән авыр һәм җаваплы урында. Ул гел кеше күз алдында, һәр минуты исәптә, һәр сүзе, хәрәкәте уйланган булырга тиеш. Соңгы елларны аның иңен, авыр таш кебек, җаваплылык басканын сизә Нәгыйм. Бу нәрсә аны уйландыра, борчый, куркыта, канәгатьсезлек уята иде.

— Азат, синең белән ничә кеше эшли? — дип сорады Нәгыйм.

— Мине дә санасаң, утыз ике.

— Кемнәр инде алар? Студентлармы?

— Юк, күпчелек — авыл малайлары. Студентлар да бар.

Нәгыймнең йөзендә беленер-беленмәс көлемсерәү чагылып үтте. Үз эше белән мәшгуль булганга, Азат моны күрмәде, ул, чыбык очы белән кастрюль капкачын күтәреп, ашны болгатты, кашыгына бәрәңге кисәге эләктереп алды да, өреп, авызына капты. Шулпаны да татып карады.

— Булган бу, хәзер утырабыз,— диде һәм, кастрюльне тастымал белән тотып, өстәлгә таба китте.

— Мин дә монда бераз кыстырып килгән идем,— дип Нәгыйм дә сумкасын бушатты.

— У-у, болай булгач, без туй табынын да уздырып җибәрәчәкбез.

Кунак алып килгән ризыклар чыннан да затлы, кыр шартларында бигрәк тә тансык иде.

— Нәгыйм! Нәгыйм малай! — диде Азат.— Без синең белән бер авылда үстек, бер мәктәптә укыдык... Икебез дә авылдан чыккан егетләр... Әгәр безне шәһәрдә туып, гомере буе шунда яшәгән яшьтәшләребез белән чагыштырсалар, без тормышка якынрак торган, аны тулырак белгән кешеләр. Чөнки авыл тормышында чыныгып үскәнгә, җиргә якын булганга, шәһәр атын да иярли алдык.

— Дөрес, бик дөрес әйттең,— диде Нәгыйм, кәефе күтәрелеп.— Аның шунысы бар: авыл малаена шәһәрдә аякка басар өчен ике-өч тапкыр күбрәк тир түгәргә туры килә. Мин моны үз җилкәмдә татыган кеше.

— Әйе, берәү дә сиңа квартира әзерләп куймаган, атаңнан калган китапханә дә юк,— дип, Азат та анык|ын җөпләде.

Ләкин бу әле Нәгыйм теләгән сөйләшү түгел иде. Күңелен борчыган сорауларга җавап ишетәсе килеп, сүзне ничек шуңа борырга белмичә, эчтән кытыкланып утырды ул. Ниһаять тәвәккәлләргә булды.

— Азат, монда икенче әллә килеп була, әллә юк. Шуңа күрә минем барысын да аңлатып китәсем килә...

Хуҗа, сәерсенеп, кунагына төбәлде һәм ашаудан туктап:

— Рәхим ит! — диде.

— Беләсеңме, мин бит бая ничә кеше эшлисез дип, синнән юкка гына сорамадым. Син гафу ит, бәлки кәефеңне кыра торган сүзләр дә әйтермен, шуңа күрә, зинһар, күңелеңә авыр алма...

— Борчылма, әйдә, сөйлә! — дип көлемсерәде Азат.
— Мин монда килгәннән бирле ирексездән үземне синең белән чагыштырып йөрим. Инде тауны да йөреп чыктык, өстән үзәнгә дә карап тордык, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләдең дә... Ләкин мин бернәрсәне аңламыйм.
— Кызык, нәрсәне аңламый икән соң минем классташ?
— Син көлмә. Мин серьезно.
— Я, я... шуннан?
— Әйт әле, сиңа күпме түлиләр?
— Ике йөздән аз гына артык.
— Менә күрәсеңме? — Нәгыйм утырган жирендә кыбырсынып алды.
— Ә сиңа? — дип сорады Азат, Нәгыймгә җайлаша барып.
— Ике тапкыр артыграк.
— А! Алайса миңа да синең кебек зур түрә буласы калган.— Сөйләшү торган саен кызыграк төс ала барганга, Азатның шаркылдап көләсе килә башлады. Ә Нәгыйм һаман житди.
— Эш андамыни,— дип куйды ул.— Эш бит масштабларда! Беләсеңме, минем цехта күпме кеше эшли?
— Күпме?
— Өч йөздән артык.
— Шуннан?
— Ничек инде шуннан? Ул коллектив белән эшли белергә кирәк бит.
— Анысы шулайдыр. Ләкин бу минем өчен мөһим түгел.
— Нәрсә мөһим соң синең өчен?
— Эшнең ошавы, канәгатьлек китерүе.
— Ә минемчә, зур коллектив белән житәкчелек итү кешегә күп нәрсә бирә.
— Нәрсә бирә соң?
— Абруй, үз-үзеңә ышану. Болар — бик зур әйберләр. Бөтен кеше шуның өчен тырыша, шушы нәрсәләр булганда, беләсеңме, үзеңне ничек хис итәсең?
— Ничек? — дип, шаяртып сорады Азат.
— Әллә син үзеңнең шундый тар дөньяда яшәвеңне аңламыйсыңмы? Ну, нәрсә күрәсең син бу шәрә тау башында? Монда бит гомер буе казынып ятарга мөмкин. Сукырлык түгелме бу?
— Мин, бәлки, синнән киңрәк дөньяда яшимдер? Бәлки син аны белми генә torгансыңдыр?
— Ай-һай, малай.— Нәгыйм, ышанмавын белдереп, башын чайкады, бер мәл яшәреп яткан тау өстенә карап торды.— Әйе, бүген матур, рәхәт монда. Ләкин бу бит көн дә кабатлана. Туйдырмадымы шушында яту? Нәрсә бирә ул сиңа? Данмы, дәрәҗәме? Ни файдасы, ни мәгънәсе бар бу казынуларның?
Азат беравык сүзсез генә үз алдына карап торды. Аңа авыр иде. Юк, үпкәләмәде ул. Гаҗиз булып утырды. Зур коллектив белән житәкчелек иткән шушы кешегә гап-гади нәрсәләрне аңлатырга туры килә.
— Мин, Нәгыйм дус, сиңа шуны гына әйтә алам,— диде Азат.— Кеше дигән зат борын-борыннан үзенең кем икәнлеген, кайдан килеп чыгуын аңларга тырышкан. Ерак заманнарда аның бабалары кем булган, ничек яшәгән, нәрсә белән шөгыльләнгән — барысын да беләсе килә аның. Һәм, иң мөһиме, нинди культураның дәвамы ул — монысы да кирәк кеше дигән затка... Барысын да аңлыйсы килә аның... Мин менә шул сорауларның кайберләренә җавап табарга тырышам, һәрхәлдә, аны ачыклау өчен монда эшлим. Үз халкымның тарихын күтәрәм, аңа үткәнен кайтарып бирергә телим, үз-үзен аңларга, тарихтагы урынын билгеләргә ярдәм итәм дип уйлыйм. Син моны аңлый алырсыңмы, юкмы,— белмим. Шулай да аңларга тырыш син моны.— Азат тагын бер кат зур козыреклы кәмит кепка кигән кунакка карап алды.
— Конкрет килгәндә, бу Кала-тауның әһәмияте нәрсәдә соң ул

кадәр? Ни өчен син аңа ябышып ятасың? — диде Нәгыйм, тагын да төпчинә төшеп. Бу сөйләшүдән аның өстен чыгасы килә иде.

— Ни өчен ябышып ятаммы? — Азат, сынап, тагын кунагына карап алды: чынлап торып кызыксынамы, әллә болай гына, форма өчен генәме? Юк, чынга охшаган.— Уникенче гасыр Болгар дәүләтенең чәчәк аткан заманы санала. Бу заманда дәүләт һәр яктан да зур үсешкә ирешә. Мәйданы киңәя, әйтеп үткәнемчә, бабаларыбыз дәүләтнең төньягында урнашкан Казан суына хәтле килеп җитә. Монда яңа авыллар үсеп чыга. Шулай тыныч кына яшәп ятканда, Көнчыгыш Европага монголлар ябырыла. Бу яулар Болгар дәүләтенә зур зыян китерсә дә, аңа карап кына болгарлар таралып бетми. Халык бит ул. Инде шәһәрләшеп, Кол Гали кебек шагыйрьләрен булдырган халык! — Азатның кулы һавада дәртле хәрәкәт ясап алды.— Әлбәттә, яулап алынган ил төзелешенә монголлар күп үзгәреш кертә. Башта — бигрәк тә. Шулай да басып алучылар ничә гасыр буе игенчелек белән шөгыльләнгән, утрак тормышта шәһәр культурасы булдырган илнең төп нигезен тарката алмый. Бу шартларда халык үз культурасын, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, дәүләтен саклап калу өчен яңа мөмкинлекләр эзли, шул исәптән монголлар кулы җитмәслек урманлы-сулы аулак төньяк районнарга да күчеп утыра башлый. Иске кала нәкъ менә шушы чорда күтәрелә дә инде. Ул тиздән яңа төбәкнең үзәгенә әверелә... Кыскасы, Иске кала — Болгар белән Казанны тоташтыручы чылбыр ул. Менә ни өчен кадерле ул миңа... Матди культурасы, табылдыклары шул хакта сөйли — күпчелеге болгар материалы...

Көн кинәт сүрелеп китте, офыкның көнбатыш читендә болытлар оеша башлады, кояш инде яртылаш шул болытлар астына кергән иде.

Кунакның уйга чумып, күңелсезләнеп утыруын күреп, Азат урыныннан торды.

— Әллә гармун тартып, бер җырлашып алабызмы? — диде ул.

— Әллә гармуның да бармы?

— Аны калдырган юк инде,— диде Азат һәм, торып, палаткаларга таба китте.

Бу кечерәк гармунны Азат экспедицияләрдә йөртү өчен уңай һәм ачы тавышлы булганга ярата иде. Өйдә аның баяны да бар, анысы моңлы, шәһәр квартирасында уйнарга менә дигән. Ә монысы — чиста, яңгыравык тавышлы хромка — сахраларны яңгырата. Кайвакыт ул шулай, исенә төшеп, Кала-тауның иң биек төшенә килеп утыра да, аста җәйрәп яткан тугайларга, елга аръягындагы авылга карап, берәр көй суза. Тирәюньгә моң тарала, тирбәлә-тирбәлә, үзән өстеннән үтә, авылга ук барып җитә. Бервакыт хәтта, гармун тавышын ишетеп, фермадан кызлар да йөгерешеп чыкты, капка төбенә тезелешкән килеш, куна-төнә Кала-тауда яткан сәер егетнең уйнавын тыңладылар.

— Я, нәрсәдән башлыйбыз? — диде Азат.

— Белмим шул...— Нәгыйм иңбашын җыерды.— Үзең кара инде.

Аз гына уйланып торгач, хуҗа күрекне тартты. Башын кырын салып, күзләрен кыса төшеп, хискә бирелеп уйнады Азат. Шуның ярдәмендә каршысында утырган кунагына, аларны чолгап алган тауларга, тугайларга, үләннәрен җил тараган Кала-тауга хисләрен сөйли, күңелен бушата, гүя риваятьләр, легендалар белән сугарылган бай тарихлы шушы җир белән сөйләшә иде.

> Ай-һай гына дими, көйләр килми,
> Кайгырмыйча гына ир булмый.
> Ничек кенә итеп сөйләсәң дә,
> Чит-ят җирләр туган ил булмый...

Ул, күзләрен йома төшеп, акрын гына җырлый, кушылып китмәсме дип, өмет белән ара-тирә Нәгыймгә дә күз салгалап ала. Ләкин Нәгыйм борынгы җырларны белми, малай чакта колакка кергәннәрен дә

инде онытып бетергән иде. Башта сәеррәк тоелса да, тора-бара бу көйләр аның да күңелен кузгатты, сездермичә генә каядыр тирәнгә, инде әһәмияте беткән, кирәге калмаган дип йөрелгән нәрсәләргә якынайтып җибәрде. Заман шаукымына бирелеп, ул күптән инде андый тирәнлекләргә кереп тормаска өйрәнгән, болай да эш белән каткан башын янә катырмаска күнеккән иде. Әмма, ни хикмәттер, гармуннан агылган көйләр бераздан аны да биләп алды, ул инде бирелеп, ләззәтләнеп тыңлый башлады.

Шулай да бу хис, бу ләззәт аңа балачактагы кебек ансат кына, табигый гына бирелмәде, күңеле нишләптер карыша, нәрсәдәндер бизгән кебек иде. Көйдән ләззәтләнү өчен аңа, ни өчендер, көч куярга, ниндидер капкаларны ачкандай, эчке бер хәрәкәт ясарга туры килде. Бу хәрәкәт адашкан кешенең буран эченнән әле күренеп, әле югалып торган ерак утка таба баруын хәтерләтә иде. Нәгыймгә бу сәер тоелды, ләкин нилектән алай икәнен ул аңлый алмады.

Азат уйнады да уйнады, башын кырын салып, күзен йома төшеп, күңеле белән әллә кайларга китеп уйнады...

— Исеңдә микән, без үсмер чакта шундый бер җыр таралган иде. Болай башлана:

Таң атканда, салкын чишмә буенда
Очраштык без иркәм белән тагын да...

— дип, Нәгыйм җырның сүзләрен исенә төшерде.

— «Вәгъдә».

— «Вәгъдә»? Исеме онытылган, ә сүзләре хәтердә,— диде Нәгыйм үзенекен уйлап.

Азат көй сузды, Нәгыйм, җырны хәтерендә яңарта-яңарта, акрын гына җырлый башлады.

Җыр аңа кайдадыр зәңгәр томаннар эчендә калган яшьлеген, шул яшьлектә калган сөйгән кызын — Нурияне исенә төшерде. Хәзер, еллар үткәч, ул чактагы гашыйклыктан, җүләрлекләрдән көлеп була, әмма онытып кына булмый икән...

Шул вакыт Нәгыймнең күңелендә нәрсәдер чатнап китте һәм челтерәп коелып төште. Еллар буе бикләнеп яткан хисләре ирекә бәреп чыктылар. Егетен укырга озатучы Нуриянең, бөтенләйгә аерылышканны сизенгән хәлдә, юл кырыенда аңа кул болгап калуы аермачык булып, Нәгыймнең күз алдына килеп басты.

...Тамагына төер утырды.

## IV

Кинәт салкынча җил исеп куйды. Икесе дә җил искән якка борылып карадылар, күкне каплап өлгергән күгелҗем-кара болытны күреп, тынсыз калдылар.

Беренче булып Азат исенә килде, сикереп торды да:

— Бик хәтәр килә, тизрәк палаткага керергә кирәк,— дип, ашыга-ашыга өстәлне, савыт-сабаларны җыештырырга кереште.

Нәгыйм дә, сикереп торып, тиз-тиз булышырга тотынды.

...Палаткада кара-каршы куелган ике раскладушка, уртада кечкенә генә өстәл, почмакта ниндидер приборлар, әрҗәләр, мылтык, киемсалым өелгән.

Азат кунагына сөлге тоттырды, икенчесе белән үзе сөртенде. Аннан икесе дә калын фуфайка киделәр, шәм кабыздылар һәм тынычлана төштеләр.

Ә тышта — мәхшәр. Җил палатканы селкетә, очыртып алып китәргә теләгәндәй, төрле якка йолыккалый, ныклыгын сыный. Яңгыр да, җил белән ярышкандай, дөньяны каплап коя, палатканы туктаусыз чәбәкли, ачык калган ярыктан эчкә бәреп керә, идәнгә су җәелә.

Шулай күпмедер вакыт табигатьнең ярсуын тыңлап утырдылар.

Берәр төрле музыка тоту нияте белән, Азат транзисторга үрелде, ләкин эфирдан музыка урынына тоташ чытырдау гына ишетелде. Радиоалгычны сүндерергә туры килде. Аннан соң ул, нәрсәдер исенә төшкәндәй, палатка почмагындагы әрҗәне ачты, актарынырга тотынды, эчтән кечерәк капчык тартып чыгарып, кире урынына килеп утырды.

— Мин бит әле сиңа табылдыкларны күрсәтмәдем,— дип, капчыктан кәгазьгә төрелгән төргәкләрне бушатырга кереште. Арадан берсен сайлап алып, чишеп җибәрде һәм Нәгыймнең учына берничә тәңкә китереп салды.

— Җучи акчалары. Теге борынгы кабер ташы турында сөйләгән идем бит, шул заманда сугылган.

— Җучи? — дип сорады Нәгыйм.

— Әйе, Чыңгызның өлкән улы. Монголлар яулап алганнан соң Болгар дәүләте Җучи улусына керә бит. Шулай да күпмедер вакыт үтүгә, монголлар исеменнән булса да, бабаларыбыз үзләре акча суга башлыйлар...

Мондый нәрсәне беренче тапкыр күргәнгәме, уалып китүләреннән курыккандай, Нәгыйм акчаларны саклык белән карый башлады. Алар турында уку — бер нәрсә, кулга тотып карау бөтенләй башка икән.

— Монда нинди дер язулар да бар,— дип тәңкәләрне шәм яктысына китерде Нәгыйм.— Көмеш ахры.

— Әйе, көмеш.

— Укый аласыңмы?

— Кайберләрен укыйм. Әмма аларның үз белгечләре бар. Гадәттә, аларга биреп укытам. Ышанычлырак була,— диде Азат. Тәңкәләрне төреп, бер якка алып куйгач, Азат икенче төргәкне сүтте. Монысыннан кечкенә генә савыт килеп чыкты.

— Кара савыты,— дип аңлатты археолог.

— Ничек кара савыты? — дип гаҗәпләнде Нәгыйм.

— Гап-гади кара савыты. Каләм манып яза торган.

Нәгыйм, савытны кулына алып, нидер уйланып торды да:

— Кайдан таптың? — дип сорады.

— Астан, авыл урыныннан.

— Нинди нәтиҗә чыгарасың инде шуннан?

— Нәтиҗә бер — кара-савыты укый-яза белә торган халыкта гына була.

Нәгыйм килешүен белгертеп, башын гына селекте.

Тагын бер төргәкне сүттеләр. Анысыннан көмеш беләзек килеп чыкты. Кунак моны да шәм утына якын китерде, дикъкать белән әйләндерә-әйләндерә карады. Аннары беләзекнең очында ниндидер бизәкләр күреп, аларны тырнак очы белән кырып-чистарткандай итте дә әйтеп куйды:

— Монда ниндидер рәсем бар, җәнлек башы димме?

— Арыслан башы. Болгар сәнгатенә бик хас бизәк ул. Шәһри Болгарда табылган хәзинәләр арасында да очрый,— дип аңлатты Азат.

Беләзекне кире биргәнче, авырлыгын үлчәгәндәй, Нәгыйм аны уч төбендә селкетеп торды да:

— Моны бит кемдер беләгендә йөрткән,— дип, соклануын яшермичә, Азатка карады.

Азатның да карашы җылынып китте, үз итеп елмайды.

Шулай һәрбер төргәкне сүтеп, карап, яңадан төреп, алар байтак вакыт сөйләшеп утырдылар. Азат күрсәткән әйберләр арасында кайчы, пычак, җиз йозаклар, шул йозакны ача торган ачкычлар, металлдан коелган көзге, бил каешын, ат дирбиясен бизәү өчен эшләнгән төрле аеллар, ук башлары, чүкеч, кечкенә генә ювелир сандалы, мәрҗән бөртекләре, кадак, үлчәү тәлинкәләре кебек төрле тормыш кирәк-ярагы бар иде. Шушы әйберләр Нәгыйм алдында, гүя кыска вакытка гына нин-

дидер серле пәрдәне ачып җибәрделәр һәм ул ерак бабаларының тормышын үз күзләре белән күргәндәй булды. Шушы әйберләр тарих томаны эчендәге «болгар бабаларыбыз» дигән төшенчәне шактый конкрет итеп аның күз алдына китереп бастырды. Һәм бу аның элеккеге шөбһәләрен, шикләрен юып төшергәндәй итте. «Димәк, Азат сөйләгәннәр барысы да дөрес булып чыга?» — дип уйлады ул. Бу инде үзеннең күп нәрсәләрдән мәхрүм икәненне тану кебек иде. Ә тану җиңел бирелми, әчтә нәрсәдер һаман карыша...

— Болар барысы да тормыш-көнкүреш әйберләре. Ул заманда киң кулланышта йөргән әйберләр. Табылдыкларның күпчелеге авылдагы музейда саклана. Теләсәң, иртәгә анда да барып килергә була,— диде Азат.

Давыл басыла төште, җил инде палатканы баягы кебек тетрәтми, янгыр тигез һәм тыныч ява иде. Палаткада коры, шәм яна, урын йомшак, теләсәң рәхим ит, йокы капчыгына кер дә чум.

Бераздан алар чыннан да бил тиңентен капчыкка кереп яттылар. Болай җылы, уңай иде. Шәмне сүндермәделәр, чөнки йокы килми, инде караңгы төшсә дә, иртә иде әле.

— Шулай да минем эш белән чагыштырганда синеке, малай,— бала-чага уены гына,— диде Нәгыйм, ниндидер уйларына йомгак ясагандай итеп. Ул палатка түшәменә төбәлеп ята иде.

— Кызык? — Азат көлемсерәп куйды.

— Әйе, әйе... Карап-карап торам да, эх, миңа булсын иде, мәйтәм моның ише мәшәкатьләр, дим... Минем өстә бит тоташ бер производство, җаваплы цех, план, күпме кеше... Сине монда берәү дә ашыктырмый, өстән чыбыркылап торучы юк. Бүген эшләмәсәң, иртәгә дә көн бар...

— Алай булгач, тарих бүлегендә укыйсың калган.

— Һе... ул чакта тарих мине кызыксындырмый иде әле. Аннан соң... тормыш бит хәзер безнең ише халык кулында. Сез түгел, без алып барабыз дөньяны.

— Менә монысы әле бәхәсле нәрсә. Мәсьәләгә ничек киләсең бит.— Азатның җавабы сүлпәнрәк яңгырады, чөнки яңабаштан бәхәскә керәсе, сүз куертасы килми иде аның. Бүген болай да күп сөйләшенде, дөресен әйткәндә, аның инде ял итәсе килә иде.

— Монда, минемчә, бәхәсләшерлек нәрсә юк. Барысы да ачык,— дип, кырт кисте Нәгыйм.

— Нәрсә ачык? — теләмәсә дә, Азат сүзне дәвам итәргә мәҗбүр булды.

— Барысы да! Үзең уйлап кара: егерменче гасырны егерменче гасыр иткән бөтен нәрсә без — техника иярләүчеләр тарафыннан эшләнә. Әйе, әйе, без туплаган белем, техника казанышы кешене космоска алып чыкты! — Нәгыйм йөзе белән борылды да терсәгенә таянды. Шәм уты тирбәлеп куйды, палатка стенасы буйлап шәүләләр йөгерешеп алды.

— Галәмгә бит зыян китерү өчен дә менеп була. Андый планнар коручылар турында көн саен ишетеп торабыз. Ә менә кешелеккә зыян китерми торган адәм баласын тәрбияләү, белсәң килсә, безгә — гуманитарийларга йөкләнгән. Безнең татарда шундый мәкаль бар: корал эшләр, ир мактаныр, диләр. Бу очракта сез корал булсагыз, без инде ир, ягъни шул коралны эшкә җигүче, аңа дөрес юнәлеш бирүчеләр булабыз түгелме? — Азат, көлемсерәп, кунагына карап алды.

— Корал димәктән... дип, үзенекен итте Нәгыйм.— Менә соңгы сугышны гына алыйк. Без уйлап тапкан корал булмаса, фашистларны тар-мар итә алыр идекме? — Нәгыйм телен шартлатып куйды.— Юк инде, бәхәсләшмә.— Ул яңадан чалкан әйләнеп ятты.

— Әлбәттә, сугышта коралсыз бернишләп тә булмый. Ләкин шул ук корал дошман ягында да бар иде бит. Башта аларныкы күбрәк тә иде әле. Бөтен Европа куәтен файдаландылар. Барыбер без җиңдек! Чөнки безнең якта сугыш коралы гына түгел, көчле рухи корал да бар иде. Алдынгы караш, дөреслек, Туган илгә чиксез мәхәббәт бар иде безнең якта.

Без җиңдек! — Азат кунак бирәр сүз әйтер дип көтсә дә, каршы җавап булмады, һәм ул фикерен дәвам итте:

Беләсеңме, андый сынаулар вакытында туган җиреңнең үткәнен, аның тарихын белү кешегә бик нык ярдәм итә. Кешене ул эчтән ныгыта, туган җиренең калканы итә. Җәлилгә тоткынлыкта нәрсә ярдәм иткән дип уйлыйсың? Туган иленә, халкына булган мәхәббәт, әлбәттә! Болар аңа көч, рух ныклыгы биргән! Тарихын, халкының үткәнен, культурасын белмәгән кешедә ничек мәхәббәт яралсын да нинди ныклык булсын...

— Ярар, шулай да булсын ди. Ләкин син барыбер гуманитар фәннәрнең, шул исәптән, тарихның да ролен арттырып җибәрәсең шикелле... Ни әйтсәң дә егерменче гасыр ул техника гасыры.

Азат аңа гаҗәпләнеп карады:

— Син нәрсә, әллә мине техникага каршы дип уйлыйсыңмы? Техниканың бөек ролен бирәү дә инкяр итәргә җыенмый. Сүз бит техника белән мавыгып китеп, кешене, аның җанын онытмау турында бара... Ә җанны тәрбияләүдә гуманитар фәннәр төп рольне уйный. Шул исәптән тарих фәне дә...

— Ләкин син бит ерак заманнар белән шөгыльләнәсең. Болгар... монгол... ничек әле анда? — Нәгыйм төгәл сүз таба алмыйча Азатка борылды, бармагын шартлатып алды.

— Урта гасырлар,— дип ярдәмгә килде Азат.

— Әйе, урта гасырлар... Бу бит әле кайчан булган, үткән-беткән... Бүгенге көнгә ни катнашы бар?

— Менә монысы ялгыш караш,— диде Азат һәм, аякларын капчыктан чыгарып, торып ук утырды.— Туган җиреңнең тарихын, культурасын белү, без яшәгән катлаулы, фән-техника революциясе барган заманда, бигрәк тә кирәк. Шунсыз син билгеле бер ил, халык, милләт вәкиле буларак, бик тиз үз йөзеңне, сиңа гына хас сыйфатларны югалтачаксың, кыйбласыз җан иясенә әверeләчәксең. Андый бәндәнең бернәрсә өчен дә җаны авыртмый, исе китми. «Ник барысы да кадалып китми, миңа рәхәт булса, шул җитә»,— дип уйлый ул. Андый бәндә инде туган җире өчен беркайчан да утка кермәячәк...

Нәгыйм каршы бер сүз дә әйтә алмады. Түшәмгә карап кузгалмыйча ята бирде. Уйлары бик күңелледән түгел иде аның. Бу минутта ул үзен тормышта нииндидер зур нәрсәләрдән мәхрүм калгандай хис итте. Әйләнеп карасаң, гомер инде үтеп тә бара икән бит. Ә менә шушы гомер эчендә, тормыш ыгы-зыгысына бирелеп, дәрәҗә, төрле уңайлыклар, шартлар артыннан куа-куа, шулар өчен көрәшә-көрәшә, иң мөһим нәрсәләрне күрми калган, алар турында уйланырга вакыт таба алмаган түгелме соң ул?.. Азатта Нәгыйм әле төшенә генә башлаган нииндидер зур дөреслек, хаклык, тамырлары тирәнгә киткән иман ныклыгы бар сыман тоелды. Шушы нәрсә Нәгыймнең тынычлыгын алды, нииндидер көчәя барган сызлау булып күкрәгенә җәелә иде.

Шул мәлне, инде капчыгына кереп ятып, йокларга әзерләнгән Азат, нииндидер уйларын әйтеп каласы килгәндәй, тагын башын күтәрде.

— Без соңгы вакытта һаман сыйфат та сыйфат дибез, аны күтәрү турында сөйләшәбез. Син менә, производство кешесе буларак, туган җирне ярату хисләре белән җитештерелгән нәрсәнең сыйфаты арасында бәйләнеш барын сизәсеңме? — дип сорады.

Азат башын күтәргән көенчә беравык җавап көтеп торды, ишетмәгәч, нәрсәдер сизенеп:

— Ярар, йокла, иртәгә дә көн бар әле,— дип шәмгә өрде.

Ут сүнгәч, палатка кинәт иркенәеп киткәндәй булды, аларны тышкы дөньядан аерып торган элпә әреп юкка чыкты. Тышта җил тынган иде инде, яңгыр тавышсыз-нисез, сибәләп кенә ява. Аның дымлы сулышыннан изрәп, Кала-тау да, якын тирәдә тезелешеп киткән калкулыклар, болын һәм елга да тирән йокыга талдылар. Табигатьнең бу серле

халәте палаткадагыларга да тәэсир итте, алар да, үз уйларына бирелеп, акрынлап йокыга талды.

Нәгыйм иртәрәк уянды. Иңенә сырма элеп палаткадан чыкты. Шундый тынлык... Яңгырдан соң тирә-юнь тагын да яшәреп, һава сафланып калган.

Бераздан ул Кала-тауның кичә Азат белән сөйләшеп торган иң биек ноктасына килеп житте. Болын һәм елга өстенә сыек кына томан җәелгән, һәм ул кояш нурлары астында күзгә күренеп тарала бара. Табигать уяна, җир җылына, үлән өстендә ялтыраган чык тамчылары кибә, югала. Бу күренешләр Нәгыймдә бүген ниндидер башкачарак хисләр уята иде. «Нәрсә соң бу?» — дип шушы сәер халәт турында уйланып торды Нәгыйм. Хикмәт шунда: ул кайсы якка гына борылмасын, нәрсәгә генә күзе төшмәсен, хәтеренә Азат сөйләгән легендалар, халык күңелендә яшәгән хикәятләр, төрле вакыйгалар килеп төшә иде. Ни әйтсәң дә, кичә Азат аңа байтак әйбер сөйләгән икән шул. Бу хәл Нәгыймдә ниндидер сәер халәт тудыра, гүя ул бер үк вакытта ике заманда яши, үзен шул ике заманны — бүгенге белән үткәнне — тоташтыручы сыман хис итә иде.

Шунысы кызык: Нәгыймне чолгап алган бу халәт, фикер белән хис тәңгәллеге бер-берсенә һич тә комачауламый, киресенчә, ниндидер эчке татулык белән бер-берсен үзара тулыландыралар гына иде. Күз алдында торган бу күренешләргә ниндидер яңа мәгънә, яктылык өстәлә иде шикелле. Нәгыйм өчен өр-яңа, беркайчан да кичерелмәгән халәт иде бу. Гаҗәпләнеп һәм сөенеп, кунак шул хакта уйланды. Менә, көтмәгәндә, арыш кырыннан яңа туган көнне сәламләгән кош тавышы ишетелде.

Һай, матур да соң бу тургай сайраулары!

*Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы*

## Нина Матвеева

# ОХШАШ ХӘЛЛӘР

**хикәя**



Степанчиковлар бер-берсеннән беркайчан да сер яшермиләр. Әнә шуңа күрәдер дә алар үзләрен бик бәхетле саныйлар. Гаилә тормышының камиллегенә хилафлык килгәләп ала икән инде — моңа Телевизор һәм хәсис Телефон әфәнделәр гаепле була, абайламыйча калсаң, шул әшәке жаннар, ямьне жибәрергә генә торалар.

Бер-берсеннән серләре юк та бит, әмма ире яки хатыны, аркасы белән борылып, телефон трубкасына «әйе-юк»лар белән буташтырып, эһе-меһе килә башласа, йон баскан йөрәккә дә шик төшәр шул! Хәләлең кем белән сөйләшүен әйткәч (сер яшермиләр бу өйдә!), күңелдә уянган вәсвәсә басыла-аныйсы басылуын. Ләкин каһәр суккыры телефон, йөрәккә ут салып, тагын шалтырарга тотына бит... Тормыш диген инде син моны.

Степанчиковлар кешеләр белән аралашырга яраталар, аларның дуслары күп, дипломатлар әйтмешли, таныш-белешләре белән жылы һәм үзара аңлашу мөнәсәбәтләрен сакларга оста алар. Ләкин ашарга утыруга һәм жиде төн уртасында, хәтта сызылып таң атканда да шалтырарга иренмәүче телефон дигәнеңнең ат башыдай йозак салсаң да, авызын томалап булмый шул. Кемнеңдер лотореяга машина отуын, кайсыныңдыр дәү нәчәлник булып күтәрелүен, төлке тун алган Мариянең урамда очраган танышларына да сәлам бирмичә кукраеп узуын, мактанчык Елизаветаның иннек яккач һәм сөрмә тарткач, бөтенләй котсызланып калуын кабалана-кабалана хәбәр итәргә генә тора телефон!.. Өендә ике телефоның булса, икесе дә тынгы белмәсләр иде, әй! Күпме шалтыраса да, алмыйча тончыктырасы иде үзен, әмма телефон тәгәрмәчен кирәккә әйләндереп интегүчеләр булуы ихтимал бит.

Телефоннан шалтыратучыларны төркемнәргә аерырга бик мөмкин, әлбәттә. Ул чагында бу төркемнәр түбәндәгеләрдән гыйбарәт булыр иде: телләре кычытудан шалтыратучылар, каныңа тоз, ә күңелеңә ут салырга теләүчеләр, үз кирәге төшүчеләр, фәлән-фәләнгә фәлән-фәләндә булышырга үтенүчеләр, тырнак астыннан кер эзләүчеләр, сине хилаф эшкә күндерергә омтылучылар, синең гаилә бәхетеңнән көнләшүчеләр һәм... һ. б., һ. б.

Степанчиковлар никадәр генә сакланырга тырышсалар да, аларга төрле-төрле мәгълүмат-хәбәрләр өеме-өеме белән ирешә тора. Һәм бу өемнәр акрынлап тауга әверелә бара. Димәк, «әйе-юк» дип жавап кайтарулар тагын да ишәеп кенә китте.

Бервакыт Степанчикова, ире чираттагы сәфәрдән кайткач:

— Син гафу итә күр инде,— диде,— хатыны алдында ир кеше телефон трубкасына «әйе» дә «юк» дип кенә кабатласа, ул һичшиксез сөяркәсе белән сөйләшә булыр. Әйе... юк... шулай... әйбәт...

Моңа Степанчиков шырпы кебек кабынып китте:

— Син нәрсә, аңгыра баш! Вася белән сөйләшәм бит мин! Кунакханәдә танышкан идек. Ул анда бер асылкошка гашыйк булды. Шул чибәркәйне сагынуын миңа сөйләп күңелен бушатуы бит!

— Ярар инде, ярар, кызма. Мин болай гына ич... Ә Вася өйләнгәнме соң ул?

— Беркатлы да инде син! Өч бала атасы ул! Икенче хатыны!

— Кунакханәдәге гыйшык-мыйшыкларсыз ямь тапмыйдыр инде алайса,— дип, ваемсыз гына әйтеп куйды Степанчикова һәм күз кызыктырырлык аякларын селкеткәләп алды. Бу сихри хәрәкәт Степанчиковны әңгәмәдән читкәрәк тайпылдырды. Кемнең аяклары матур булу турында кайчандыр хатыны белән бәхәсләшкән иде алар, менә шул исенә төште:

— Ирләр аягы мускул көче белән җәлеп итеп тора, хатын-кыз аягының матурлыгы күз буарга гына ярый, чынлыкта эт сыйрагыннан ким түгел,— дип җиңешкән иде хатыны.

Тик бу очракта ул нигәдер, эшли торган институтында әйтүләренчә, үзенең «дөньядагы иң матур аякларына» ишарәләмәде, ә сәнгать музеендагы мәрмәр сынның гүзәллеген кимсетте. Бәхәсне чишү өчен, ике дә уйлап тормыйча, музейга киттеләр. Хатын-кыз сынының аякларыннан Степанчикова санап бетергесез кимчелекләр тапты. Югыйсә, Степанчиков фикеренчә, бу аякларның һәркайсы гүзәл иде. Һәм ул, хатыны күрмәгәндә генә, аның берсен хәтта сыпырып та карады. Хатыны, чагыштырып, тәм тапмасын өчен, ирләр сыннары янына барудан кырт кисеп баш тартты. Чөнки ирләр аягын дөнья бетереп мактаганда, хатыны аның — элеккеге кавалеристның камыт аякларын истән чыгарачак иде...

Ул хатынының аякларына кабат күз төшереп алды да Вася мәсьәләсенә әйләнеп кайтты.

— Ну... башланды-китте инде шуннан... Кем белән булмый соң...— диде Степанчиков, кулларын күкрәгенә куеп.— Чәченә чал төшкән ирләрне шайтан котырта ди бит...

Хәләле җавап кайтармады, иреңең ак төшкән чигәсен бармаклары белән сыйпап куйды.

Степанчиковага күбесенчә ирләр шалтырата иде. Ул гадәттә ирләр укый торган институтны тәмамлады һәм пеләш курсташларының, аларның элекке һәм хәзерге хатыннарының, балаларының, дусларының, хезмәттәшләренең, күршеләренең кирәген кайгыртуны хәзергәчә дәвам итә иде. Аларның барысына да исемнәрен кечерәйтеп эндәшә, трубканы куяр алдыннан «үбәм үзеңне» дия иде, ә очрашканда, чыннан да үбә тегеләрне. Мондый иркә кыланулар Степанчиковның кытыгын китерсә дә, хатынының бугазына ябышып, аңлатма сорау дәрәҗәсенә барып җитми иде ул. Төгәлрәк әйтсәк, аларның мөнәсәбәте мәхәббәткә һәм үзара аңлашуга корылган, ягъни назлау, эчкерсезлек, хөрмәт итү, бер-береңә бирелгәнлек гаилә терәген какшамаслык итеп тота иде.

Бервакыт... Салкыннан йөзе сөйкемле алсуланып, бәхетле елмаеп кайтып керде Степанчикова. Үз артыннан ишекне япканчы ук, кулындагы җыйнак һәм бизәкле тартманы иренә сузды.

— Сөеклем, бу — сиңа, синең бүлмәгә куярга. Бәясен сорама, бурычка кермәдем. Ахирәтем алып килгән. Аның ире чит илләргә еш йөри бит.

Тартмадан, яссы итеп ясалган телефон трубкасы килеп чыккач, Степанчиков аңа озаклап карап торды. Трубка дигәнеңнең әллә ничәмә төймәләре һәм бәләкәй көянтәләре, төрле төсләр уйнатып, йорт хуҗасына күз кысалар кебек тоелды.

— Ә... ә моны нәрсәгә куясы? Аппараты кайда соң моның? — дип, тартма төбен капшады ул.

Степанчикова күңеле булып көлеп җибәрде:

— И-и авыл гыйбаты да соң син! Бөтен хикмәт тә шунда шул — аппаратының аерым булмавында! Трубкага барысы да сыйган. Кыскасы, Вангкок...

— Гонконг,— дип төзәтте Степанчиков. Чит телләр мәсьәләсендә аның белеме хәләленекеннән өстенрәк иде.— Тәк, тәк, хикмәтенә төшеник әле без бу хикмәти нәрсәкәйнең... Монысы хәтер төймәсе икән... Ә менә бу төймә кирәк чакта шау-шу ясату өчен икән...

— Анысы нәрсәгә тагын? — дип аптырады хатыны.

— Әйтик, синең кем беләндер сөйләшәсең килми ди. Трубканы куярга да уңайсызланасың. Шул чакта шушы төймәгә басасың да, алло, алло, мин сезне ишетмим, дисең, линия бозылган ахрысы дип өстисең. Гафу итегез, ягъни. Һәм — шалт трубканы!

Степанчикова телефон аппаратының мондый үзенчәлегенә бик тә гаҗәпләнде, хәтта кәефе китте, әмма моны сиздермәскә тырышып:

— Мондый әкәмәтне бары тик Вангкокта гына уйлап таба алалардыр,— диде.

— Гонконгта,— дип, сабыр гына төзәтте Степанчиков һәм рәхмәт йөзеннән

хатынының аркасыннан сөйде; уенчыктай аппарат, сердәш булырга чакырып, тагын күз кыса кебек тоелды аңарга...

Шулай итеп, Степанчиковлар гаиләсенә яңалык үтеп керде. Озак еллар буена хуҗаларына хезмәт итүдән какшап беткән, өч җирдән пластырь ябыштырылган иске аппарат бөтенләйгә аш бүлмәсенә күченде. Гарьлегеннән һәм көнләшүеннән элекке таләпчән зәһәр тавышы карлыгып калды.

— Хәзер минем сөйләшүләрне тыңлый аласың,— дип эчкерсезләнде гаилә башлыгы.

— Син дә минем сөйләшүләрне тыңлый аласың. Синнән яшергән серем юк,— дип киң күңелләнде хәләле.

Алар шатланып көлеп җибәрделәр, шөкер, унбиш еллык гаилә берләшмәсен (моңа уналты яшьлек малайлары да керә) какшатырлык серләре юк. Игезәк телефоннардан әнә шул малай гына җәфа чигәдер хәзер. Улларының шәхси тормышына тыкшынуны әнисе дә, әтисе дә кирәк санамыйлар иде. Җитеп килүче егет бервакыт әйтә куйды:

— Гаҗәп хәл, бер-берегезнең сөйләшкәннәрен тыңлый аласыз, әмма өйдә үзгәреш сизелми, икегез арасында җәнҗал купканы да юк.

— Купмаганга купмый,— диде әтисе.

— Бер-беребезнең яманатын чыгарырлык серләребез булмаганга купмый,— дип, иренең фикерен куәтләде әнисе.— Барлык мәсьәләләрне дә киңәшеп-килешеп хәл итәбез...

— Борынгы җәмгыятьтәге кебек,— дип төрттереп әйтте уллары.

— Борынгычарак,— дип төзәтте әтисе.— Тарихта шундый чор булган. Һәр сер алдашуга китерә, ә алдашу исә ызгыш-талашка илтә.

— Серләре күбәю кешеләрне бер-берсеннән һаман саен читләштерә генә бара,— дип нәтиҗә ясады Степанчикова. Үзе плитә янында термобигудиләр белән кайнашты.

— Ә шулай да мин Нелька белән сөйләшкәндә, колакларыгызны трубкага ябыштырып тыңлавыгыз күңелле хәл түгел инде,— дип, әңгәмәгә нокта куймакчы булды уллары һәм урыныннан кузгалды.— Үзеңне утлы табага баскан кебегрәк хис итәсең. Әдәпсезлек була бу, картлачлар...

Степанчикова, бигудиләрен дә онытып, улына усал итеп карады.

— Әй, егеткәй, бер генә секундка килегез әле монда! Синең Нелька белән сәгатьләр буена сафсата сатуыңа бу дөньяда ике генә кеше түзеп тора ала.— Син дә ул. Әтиең белән болай килештек: әгәр кайсыбызга да булса уртак танышыбыз шалтыратса, без икебез дә трубканы алабыз һәм өчәүләп сөйләшәбез. Шулай уңайлы, вакытка да бәрәкәт, ни хакында сөйләшүебезне берберебезгә кабатлауның хаҗәте юк...

— Ә нәрсә турында сөйләшүне әйтү мәҗбүриме? — дип сорады уллары, әнисе кайчак әтисе белән сөйләшкәндәгечә кырыс итеп.

— Мәҗбүри! — диде әтисе, каршы сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп.

«Хатын хаклы — параллель телефон ике арада киеренкелек чыгарырдай бәләкәй генә нәрсәкәйнең дә юлына шартлатып киртә салды»,— дип уйлады. Һәр серләр кайчан да булса барыбер ялган коруга яки икейөзлелеккә китерәчәге хак шул.

Баштарак Степанчиковка хатынының нәрсә турында сөйләшүен, хатыны белән кемнеңдер әңгәмә куертуын тыңлау кызык булып тоелган иде. Әмма бу аны тиз туйдырды. Ул адәм балаларының сүз боткасындагы закончалыкка игътибар итте. Әйтик, аның хәләле таныш фин кешесе белән балалар, спорт һәм чит илләргә сәяхәт хакында гына сөйләшә иде. Баксаң, Финляндиядә политика, әдәбият һәм кино турында сөйләшү, гомумән, гадәткә кермәгән, төп игътибар үз кирәгенә бирелә икән.

Бездә сөйләшүләр ниндидер кысалар белән чикләнми: теләсә нәрсә турында сөйләшәбез, һәм иң гаҗәбе — еш кына бушка сафсата сатабыз. Фин кешесе турында Степанчиков хатынына:

— Миңа мондый чикләнгәнлек ошый,— диде.— Кешенең эчке дөньясы да, тирә-юнь мохит кебек үк, пычранырга мөмкин. Мәгълүматлар заманы нәкъ менә шуңа күрә хәтәр дә инде. Шуңа күрә начар әсәрләр укымаска һәм талантсыз спектакльләр карамаска, юләрләрнең лыгырдавын тыңламаска һәм вактөяк хакында озаклап сөйләшмәскә кирәк.

— Мин әле телевизордан футбол, фигуралы шуу һәм аэробика кебекләрне бөтенләй күрсәтмәс идем,— дип ялгап китте хәләле.— Син андыйларны яратасың яратуын. Шулай да күңел керләнү мәсьәләсендә еракка кереп китмик әле. Бәлки, кешенең аралашып сөйләшүе мәрхәмәтле булу, бүтәннәрнең хәленә керү итеп саналырга тиештер? Менә әле генә Танька белән сөйләштек, сүз вак-

төякләр тирәсендә генә барды. Ә аның файдасы искиткеч булды. Танькага, әлбәттә. Аның күңеле эреде дә китте, дөньяны җимерердәй ачуын онытты да җибәрде.

Һәм Степанчиковлар, өчәүләшеп, үз күңелләрен кердәндерүгә каршы бер батырлык эшләп ташладылар — төсле телевизорларын саттылар! Күрегезче, кичләр бәрәкәтле озын һәм кичләрен өйдә нәрсә дә булса эшләргә мөмкин икән бит! Кайдадыр Колумбиядә, вулкан атып, шәһәр җимерелүен, Мексикада җир тетрәвен, фәлән шәһәрнең кибетләре үтмәс товар белән дыңгычлап тутырылуын, фәлән балеринага сиксән яшь тулуын, фәлән институтта цемент-йомычка плитәләре ясау ысулын табуларын һәм башкаларны телевизордан карау мәҗбүри дә түгел икән ләбаса! Боларны иртәнге чәй янында газеталардан укып та белеп була икән ич! Аннары шунысы да бар бит әле: дускаебыз телефон әһәмиятле яңалыкларны сайлап-аралап кына ирештереп тора, өстәвенә, аларга ихластан аңлатмасын бирә бара...

Бервакыт... Степанчиковлар телефон трубкасына бер үк вакытта сузылдылар. Бер-берсенә сиздермичә тыңлау өчен түгел, әлбәттә, мондый кызыксыну заманнары күптән үтте инде. Гаилә башлыгы үз бүлмәсендә, ә хәләле аш бүлмәсендә иде, трубкаларны алулары шуңа күрә генә бер үк вакытка туры килде.

Уртак танышлары — үтә дә серле чыгышына ишарәләп тагылган «Фарсы кызы» кушаматлы Соня шалтырата икән. Степанчиков — гадәттәгечә: «Фарсы гүзәленә сәлам!» — дип исәнләшкәннән соң трубканы куймакчы иде. Чөнки Сонябың, башка сүз төркемнәрен санга сукмыйча, исемнәрдән генә торган сөйләмен жене сөйми аның.

— Сәлам! Канистра, өч, зәйтүн мае,— дигән тавыш ишетелде трубкадан.— Кирәкме?

— Кирәкме, зәйтүн мае, өч, канистра,— дип уйлап та тормастан кире баштан кабатлады Степанчиковның хатыны.— Нәрсә, нәрсә? Ә, аңладым — шәп!

Степанчиков телефон трубкасын йотардай итеп ярты минутлар иснәде, гадәти сәламен дә бирмичә трубканы кире куярга гына торганда, үксеп елау тавышы ишетте.

— Сонечка! Ни булды сиңа? Котярамы?

— Котяра,— дип сулкылдады Фарсы кызы.— Дача, кыш, мәхәббәт, салкын.

Степанчиков аның зәйтүн маеннан хәзерге дусты Костяга тиз генә күчүенә гаҗәпләнде. Аларны, әлбәттә, Степанчикова таныштырды; мыекларына карап тыр инде, Котяра дип кушамат та тагып өлгергәннәр, әй!

— Соня, дим, аңлыйм мин сине. Дача өең җәй өчен генә шул синең. Кышын анда салкын. Гашыйклар очрашырга яраклы урын түгел. Әгәр синдә очрашагыз? Көндез дим, төшке аш вакытында дим.

— Син нәрсә?! Әни, Вовка, Тузик...

— Ә аның фатирында? Кылын тартып карамадыңмы?

— Әтисе, әнисе, сеңлесе, мең кыенлык...

— Өйләнешегез соң алайса, адәм имгәкләре!

Трубкадан тагын очкылык тоту аралаш сулкылдау ишетелде:

— Азатлык... Бәй-сез-лек... Кыз-га-ныч...

— Беләсеңме, ахирәт, син арттырып җибәрәсең! — дип ачуланган булды Степанчикова, бу мәлдә иренең икенче телефоннан сөйләшүне тыңлап торуын искәреп.— Мин үземнеке белән серле очрашулар өчен урын эзләмәдем! Яратасыңмы? Җитәклә дә загска алып бар соң үзен! Аңламассың сезне, хайвани дәрәҗәдә уйланасыз...

— Мә-хәб-бәт, ю-ләр! — дип үкседе трубка. Һәм, Степанчиковны шаккатырып, борынгы фарсы теленнән хәзерге аңлаешлы рус теленә күчте. Артык дулкынланганда мондый хәл була инде, хәер.— Котяра теләми бит! Беләм мин сезнең халыкны ди, башта бармакка балдак киертәсез, аннары муенга богау саласыз ди. Ярар, алайса, Котяра, дидем үзем дә, безгә болай да әйбәт, шушылай очрашкаларбыз, нигә үзебезне арканлап куярга икән дидем.— Трубка бераз тынсыз торды, һәм Степанчиков Сонянын трубкага пышылдаганчы якягына каранып алуын күз алдына китерде.— Син минем тактиканы беләсең бит инде... Җәйне аз гына булса да озайта алсам, беркая да китә алмаячак ул, муенчактан ычкынмас...

— Дачада бик салкынмыни соң? — дип, житди итеп сорады Степанчикова.

— Үзең барып кара, ачкычын бирәм,— дип көлеп бүлде аны Соня. Һәм, Степанчиковны күз алдына китерептер: — Синең Баобабың кайда соң әле? — дип өстәде.

Иренең йөзе җимерелүен сизенеп, Степанчикова:

— Сонька, сүзеңне үлчәп сөйлә! — дип ачуланды.— Мин иремне яратам...

— Ярар, ярар, Баобаб түгел, Цахескаен булсын, алайса. Шулай да безгә кайда очрашырга соң?

— Кем белән? Цахес беләнме? — дип, аны-моны уйламыйча сорады Степанчикова.

Степанчиков, бу көтелмәгән сорауларны ишеткәч, трубканы ачу белән ташлады һәм, иске тәмәке савыты читендә бармакларын биетеп, үзалдына әйтеп куйды:

— Юләр дисәң дә юләр инде бу хатын-кыз халкы! Зәйтүн мае, Котяра, дача, мәхәббәт, Тузик, Баобаб — тьфу! Сүз боткасы...

Әйе... Ә,чыннан да, бер-берсен яратучы ике кеше кайда очрашырга тиеш соң әле? Шуклану-узыну өчен түгел, киләчәктә бәхетле гаилә кору максатыннан бер-береңне күбрәк белү өчен... Әйтик, тегесенең дә, монысының да фатирында очрашу мөмкин түгел: балалары бар, картайган әти-әниләре һәм күршеләре, белеп алсалар, киңәшләре белән теңкәңне корытачаклар, өйләрендә килгән-киткәнгә ияләшеп калучы этләре булса тагын... Кайда очрашырга тиеш соң алар? Вакытлыча бүлмә алып торыргамы? Кыйммәт, аннары — табып кара син аны! Дуслардамы? Рәхмәтләр генә яусын! Бервакыт Степанчиков үзенең булачак хәләлен дустының өенә алып барган иде, кәләшсез кала язды! Кунакханәдәме? Булмаганны! Мораль яктан тотнаксыз дигән тамга сугачакларын көт тә тор! Шулай да, кайда очрашырга соң?.. Степанчиков дулкынланып йөренә башлады... Алай... Котяраны кунакханәгә сөйрәп тә алып керә алмассың шул. Тынычлык һәм уңайлык булсын да аңа, өстәл нигъмәт-сыйдан сыгылып торсын...

Телефонның тагын ягымлы челтерәве (ә аш бүлмәсендә ул таларга житкән эттәй өрде) Степанчиковның уйларын бүлде. Ир белән хатын трубкаларны бер үк вакытта диярлек алдылар. Уртак танышлары Костя, ягъни Котяра шалтырата икән.

— Сәлам, картлач! Синең Калошаң трубканы колагына ябештергәнче, ишетеп кал. Укып күрсәтәм.— Степанчиков аш бүлмәсендә хатынының йөзе ничек жимерелүен күз алдына китерде, әмма ачуланмады.— Тыңлыйсыңмы? Тыңла, давай: «Сез бу вакытны һич тә онытмаячаксыз. Дәртле унбиш кыз сезне һәм сезнең тәнегезне тели. Без аерым бүлмәләрдә массаж ясыйбыз. Рәхәтлек бүләк итәбез. Су тутырылган махсус түшәкләр. Безнең кызларыбыз янына килегез һәм аларның берсен аерым бүлмәгә чакырыгыз. Безнең кызларыбыз сер саклый белә. Унбиш гүзәл кыз: «Мин синең белән булырга телим»,— дип кенә тора. Зифа буйлы һәм дәртле кыз сезнең белән өегезгә яки кунакханәгә барырга ашкына. Ул сезнең барлык теләкләрегезне үтәячәк. Аны бүген үк телефоннан чакырыгыз. Бәясе очсыз. Чеклар һәм кредит карточкалары белән дә түләргә мөмкин. Телефон: 656-590».

— Нәрсә бу? Мәскәү телефоны түгел ич...

— И-и, жанкисәгем! Лос-Анжелесның «Голливуд пресс» газетасындагы белдерү бу.

— Каян алдың син аны?

— Жанкисәк! Бу белдерүне безнең «Аргументы и факты» газетасы сиксән бишенче елның кырык икенче санында күчереп баскан, «Сары шайтан морале» дигән мәкаләдә.

— Ә синең монда нинди катнашың бар соң? Минем аңлавымча, мәкалә пропагандистларга череп баручы капитализм турында хезмәт ияләре белән аңгәмәдә файдалану өчен басылган.

Трубкадан ике кешенең — Котяраның һәм Степанчикованың — сүзсез генә озак мыш-мыш сулавы ишетелде.

— Ә бит, картлач, чыннан да,— дип, житди итеп сөйли башлады Костя.— лектор бу белдерүне ирләр алдында укыса, нәфрәтләнүләренең чиге булмаячак: «Менә кабахәтләр! Менә хәсисләр! Бетсен капитализм! Моңа чик куелсын! Әлеге гүзәл унбиш кызны монда жибәрсеннәр! Без үзебезнең сәламәт коллективта аларны тиз тәрбияләрбез...»

— Костя, дим! Костя! — дип бүлдерде Степанчиков дустын.— Син күпертмә әле, яме. Син бит барысын да аңлыйсың, шуңа күрә кәефеңне бозма. Син лутчы миңа менә нәрсә әйт. Мисал өчен, бездә, нык үскән социализм илендә, акыл утырткан бер ир белән бер хатын бер-берсен өзелеп яраталар ди. Аларның балалары бар, картайган әти-әниләре бар, өйләрендә эт асрыйлар, өстәвенә ир кешесенең аерган хатынын, хатын кешесенең аерылган ирен дә исәптән сызып ташлап булмый...

— Кыскарак тот, картлач, вакыт кысан минем. Нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңламыйм.

— Менә шул ике гашыйк кайда очрашырга тиеш? Берсенең дә өйләрендә ярамый, фатирлы буйдак дуслары юк...
— Дачада! — дип шартлатып әйтте Костя.— Хәзер һәркемнең диярлек дачасы бар. Миннән башкаларның диюем...
— Ә кышын? Дачада салкын бит...
— Салкынын салкын инде, син хаклы,— дип тирән сулады Костя.— Үземнең теңкәгә тигән хәл.
— Күрче, шундый ук хәл бит, шуңа охшаган хәл! — дип дулкынланып кычкырып ук җибәрде Степанчиков.— Еллар бара тора, ә аларга кайдадыр очрашырга кирәк ич инде! Лос-Анжелеста яшәмибез ләбаса без...
— Туктале, борчылма алай ук,— дип пышылдауга күчте Костя.— Бер вариант әйтә алам үзеңә...
— Нинди?
— Мунча. Аерым номер. Мунчачыга акча төртәсең дә керәсең дә китәсең. Юыну мәҗбүри түгел. Әңгәмә корып утырырга мөмкин. Телисең икән, чәй аралаш сыра йотымларга була, җаның ни тели, ягъни мәсәлән...
— Ә... әгәр... әгәр белеп алсалар?
— Аерым номерда икегезгә җәннәт икәнен тәрәзәдән башыңны тыгып кычкырсаң, белерләр, әлбәттә...
— Кычкырырга кирәкми анысы,— дип уйга калды Степанчиков, аш бүлмәсендә хатыны икенче телефоннан тыңлап торуын бөтенләй онытып.
— Мунчага йөрергә кирәк, җанкисәк! — дип кычкырып көлде Костя.— Чисталык — сәламәтлек нигезе!
Степанчикова, ире янына кереп, ишек яңагына сөялде.
— Йә, ни диярсең? Син — Баобаб, мин — Калоша... Менә бу нәрсә булмаганда,— ул Степанчиковның язу өстәлендәге телефон трубкасына төртеп күрсәтте,— үзебез турында бик аз белә идек, яшәве җиңел иде... Әйдә, сатыйк та шул мөртәтне, төсле телевизор алыйк...

Берничә ай узгач, Степанчиков мунчага барасы итте. Югыйсә, кимендә соңгы унбиш елда мунча ягына аягын да атлаганы юк иде аның.
— Мунчага? — дип кайтарып сорады Степанчикова. Ул шушы сүзгә бәйләнешле нәрсәнедер хәтерләргә тырышып карады, тик моны исенә төшерә алмады. Үрсәләнүдән аның йөзен кара болыт каплады.
Степанчиков чыгып киткәч кенә, иренең кайчандыр Костя белән телефоннан сөйләшкәндә әйткән сүзләре келт итеп исенә төште һәм ул бу сүзләрне, үзе дә белештермәстән, кычкырып кат-кат кабатлады:
— Шундый ук хәл ләбаса! Бер-берсенә тамчыдай охшаш хәлләр!..

Русчадан **Мәгъсүм ХУҖИН** тәрҗемәсе

Мөхәммәт Мусаев

# АКЧАРЛАК

хикәя



Күктүбәдә күгелҗемләнеп кичке шәфәкъ яна... Кара диңгезнең офыкка барып тоташкан тарафы, кояшның әле яңа гына баеганлыгын белдереп, куе кучкыл кызыл төскә кергән. Шул кызыллык диңгез буенда мәһабәт пәһлеванны хәтерләтеп, калкып торган Кара-Дагның көзгедәй шома кара ташларында чагыла. Ә аннан аз гына арырак кара төймә күренә — диңгез култыгына карап көймә йөзә.

Без, Күктүбәгә ял итәргә килгән бер төркем язучылар, кичке диңгез киңлегенә карап хозурланабыз. Кайчандыр шушы ярларда мәшһүр Пушкин басып торган. Диңгездән искән йомшак җилләр аның бөдрәләрен иркәләгән. Шагыйрь Кара-Дагны Алтын капка белән тиңләгән. Эндәшмибез. Тын гына диңгез өстен күзәтәбез. Йәгерек хыял шул Алтын капканы ачып үз ирке белән чаба. Әй, ул Күктүбәнең кичке шәфәгы!.. Вакыт агышы да монда бөтенләй үзгә. Диңгез өстенә иңеп килгән төнге караңгылык кара пәрдәсе белән куркытырга теләмичә, бөтенесен берьюлы күрсәтеп калырга җыенгандай, сиздермичә генә сине үз кочагына ала, җаныңа сафлык өстәп, бөтен тәнеңә назлы бер рәхәтлек алып килә. Син канатлы кош кебек хыялыңда шушы киңлекне иңләп очасың, канат очың белән галәм читенә кагылып узасың. Моңарчы меңәр еллар буена башка кеше ача алмаган серләрне ачарга хыялланасың...

Мәңгелекнең үзе кебек серле ул диңгез хәяте. Күгелҗем эңгер киңлеген иңләп көймә йөзүен дәвам итә.

Иртәгесен дә мин шуңа игътибар иттем — көймә һаман диңгездә иде. Иртәнге сак тынлыкта ишкәкләрнең су өстенә бәрелеп шапылдавы аермачык булып ишетелә. Көймәче Алтын капкага якынлашып килә. Шуны гына көткән кебек, каяндыр таулар арасыннан бер акчарлак очып чыкты да, Кара-Дагның пычактай үткен очлы кыясына килеп кунды. Кошның карашы көймәдә иде. Аның үз-үзен тотышыннан дулкынлану сизелә иде.

«Күрмәде, ахрысы...»

Кошның шатлыклы дулкынлануы борчылу хисләре белән алышынды.

«Гаҗәп, бик гаҗәп. Нишләп әле ул мине танымады икән? Әллә бөтенләй бүтән кешеме? Юк-юк нәкъ үзе. Кояшта янып ком төсенә кергән аркасы да, кул хәрәкәте дә, кыска итеп алдырган чәче дә — һәммәсе якын, таныш. Ә узган ел ул моннан киткән чагында озаклап кул болгап хушлашкан иде».

Аның күңелен аңлатып булмаслык сагыш хисләре биләп алды. Кайгылы кешеләрнең йөзе ничек моңсу булса, акчарлакның да карашы шундый боек иде. Көймәнең үзеннән ераклаша баруын ул озаклап карап торды һәм ниндидер бер ашкынулы гайрәт белән канат кагып һавага күтәрелде. Тизрәк-тизрәк күптәнге дустын куып җитәсе килде. Узган елдагыча, көймәче аны кармак белән үзе тоткан тәмле-татлы балык белән сыйлар кебек тоелды. Рәхәт иде ул чагында: акчарлак үзенең балаларына да ташый иде әлеге сыйны. Шуны искә төшергәч, аңа ничектер җиңелрәк булып китте, бер мизгелгә ул әле генә дустына хәтере калуын да онытты.

Кош көймәне бик тиз куып җитте дә аны әйләнеп очарга тотынды, бер югарыга күтәрелде, бер түбәнгә атылды. Тик нигәдер дусты аңа һаман игътибар итми иде.

Ә көймәче суга якорь салып, кармак җебен сүтәргә кереште. Ниһаять: «Балык, кап-кап, яр өстендә ялтырап ят»,— дигән таныш сүзләрне кабатлап суалчан кигертелгән кармагын ыргытты. Вак-вак дулкыннар арасында балык канатыдай кызыл калкавыч әле уңга, әле сулга авышып тирбәлергә тотынды. Тирбәлгән калкавычны күреп, балык чиртә, дип уйларга да мөмкин иде. Әмма ул

дулкын хәрәкәтеннән генә шулай тирбәлә иде. Моны акчарлак яхшы белә, балык эләксә, калкавыч төпкә чума. Чиртер, чиртмичә кая китсен ул балык дигәнең. Акчарлак, гадәтенчә, көймә койрыгына очып килеп кунды. Карашы аның фәкать калкавычта иде. Дулкыннар көченә буйсынып, су өстендә көймә чайкала. Юк, көймә генә түгел, көймә белән бергә балыкчы да, акчарлак та...

«Әйдә якынрак кил, дустым минем!» — Акчарлак балыкчыдан, гадәттәгечә, шушы сүзне ишетергә теләде. Ләкин аңардан андый аваз чыкмады.

«Минем монда икәнлекне күрми микәнни?»

Акчарлак бер адым алга атлады, икенче адымын ясады. Балыкчының йөзенә карыйсы килә иде аның. Барып чыкмады.

«Күрәсең, балык тоткач кына борылып шатландырырга уйлыйдыр миңа». — Кош янә дикъкать белән калкавычны күзәтергә тотынды.

Ә балыкчы көймәсенә акчарлакның килеп кунуына гаять шат иде. Моңарчы әле беркайчан да бер генә кошның да аның янына шулай якын килгәне юк иде. Шуңа күрә, кошны куркытырмын, дип аз гына селкенергә дә куркып утырды балыкчы.

Шәһәр мәйданында ул әллә ничә мәртәбә күгәрченнәргә җим сибеп карады. Тик нигәдер ул сипкән җим янына алар килергә ашыкмыйлар иде. Андый чакта ул күгәрченнәр белән мәш килеп уйнаган сабыйлардан, алар янындагы пенсионер әби-бабайлардан көнләшә иде. Һәм, менә кошлар үз итмиләр, дип уйлый иде.

Болай уйлавы белән ул үзенең хаклы түгел икәнлеген дә белә-белүен. Ләкин шул чактагы шиге барыбер күңеленнән җуелмады. Кош-корт, гомумән, хайваннар, кешеләр хакында начар уйламый. Алар иярәшергә яки читләшергә мөмкиннәр, әмма кешеләрнең холкы турында нинди дә булса фикер йөртә белмиләр. Бу җан ияләренә кеше акылы, сөйләшү сәләте бирелмәгән.

Әгәр бүтәнчә булса, көймә койрыгына кунган акчарлак та кошларга гына хас назлылык белән күп нәрсә турында сөйли алыр, «Мин сине, Кешем, яратам»,— дип әйткән булыр иде. Кош үзенең былтыргы дустына шундый ияләшкән иде. Чиксез сагыну хисләре белән көтеп алды ул аны. Акчарлак яңа чыгарган балаларына да аның хакында күп мәртәбәләр сайрады. Нәниләре хәзер көн саен әниләреннән: «Игелекле ул кеше килмәдеме әле?» — дип сорашалар.

Акчарлак шулай татлы хыялга чумып утырган арада, кинәт калкавыч төпкә чумды һәм көймәче кояшта көмештәй ялтырап торган бер балыкны тартып чыгарды. Кош шунда ук балыкны кармактан эләктереп алырга әзерләнде. Былтыр дусты аңа тәмле сыйны әнә шулай кармактан алырга мөмкинлек бирә иде. Әмма бу юлы алай булмады — көймәче балыкны кармактан үзе алды...

«Ни дигән сүз бу?!» Кинәт акчарлакның күңелен хәвефле сагыш биләп алды, аның күз алды караңгыланып китте. Ул янәшәдән генә узып барган катерны да күрмәде. Ә катерны берничә дельфин озатып килә иде. Пассажирлар һәммәсе палубадан шуларны тамаша кылып хозурланалар иде. Диңгез өстенә магнитофон тасмасыннан җыр агыла:

Чал дулкыннар кочагында
Оча-чума акчарлак.
Акчарлактай оча-чума
Яшьлегемә кайткан чак.
Акчарлагым, әйт, үзеңә
Мине тиң итәсеңме?
Әллә инде сөйгәнемә
Сөенче илтәсеңме?

Акчарлак ул җырны ишетмәде. Балыкчының кармагы кабат су өстенә сикерде һәм калкавыч баягыча дулкыннар арасында тирбәлә башлады.

Ә көймәче бөтенләй икенче төрле фикер йөртә иде. Әгәр кармак сабын кисәк кенә күтәрсәм, кошны куркытырмын дип уйлады. Шуңа күрә ул артык хәрәкәтләр ясарга да тырышмады. Бары тик тоемлау хисе белән генә ят кунакны күзәтте. Менә ул, аңа үзе тоткан балыкны бирү өчен, сиздермичә генә борылып көймә койрыгына күз төшерде. Шулчак аның тәне буйлап электр йөгереп узгандай булды. Ул дертләп китте — карашы кошның карашы белән очрашты. Акчарлакның күзендә көтелмәгән халдә генә була торган ниндидер бер хәвефле очкын чаткысы кабынды. Әгәр ул кешеләрдәй сөйләшә белсә: «Юк! Юк!» — дип ачырганып кычкырган булыр иде. Аның каршында бөтенләй бүтән кеше басып тора иде.

Кош күзендәге ул чаткы ничек шулай тиз кабынса, шулай ук бик тиз

сүнде һәм акчарлак... таштай тәгәрәп су өстенә егылып төште. Ул жансыз иде инде.

Балыкчы кинәт исенә килеп, көймә койрыгына атылып барып, суга иелде. Акчарлакны алу өчен учын ачты. Менә бит бәхет — гомере белән саубуллашкан балык кабат диңгез кочагына чумды. Акчарлак гомере аңа гомер китерде.

Яшәешнең төп кануны бу — бирәүнең бәхетсезлеге икенче берәүгә бәхет китерә.

Акчарлакның үлеме балыкчыны тетрәндерде. Ул аны кат-кат әйләндереп карады. Кошның шулай сәер үлеменә сәбәп булыр бернинди дә яра эзе күренмәде.

Көймәченең кулы сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде. «Әллә миннән курыктымы? Ә мин аны куркуга салырлык берни дә кылмадым. Үзен балык белән сыйларга гына теләдем...»

Ирексездән көймәченең бите буйлап ике тамчы яшь тәгәрәде. Ирләр әнә шулай тын гына елыйлар.

Балык каптыруның кызыгы, тәме калмады. Ул көймәсен ярга таба борып, ишкәкләрен кулына алды.

* * *

...Көймәче ветеринар янында чыккач та, ишек янәгына сөялеп озак уйланып торды. Әле генә операция өстәле янында булган сөйләшүне исенә төшерде.

«Синең сөйләвеңнән үк, акчарлак йөрәге ярылудан үлгәндер, дип уйлаган идем. Кошны ярып карагач, үзең дә күрдең, уйлаганым дөрескә чыкты.— Әйе,— диде аңа ветеринар кулларын юа-юа,— бу җан ияләре кешеләргә тиз ияләшә. Күрәсең, сезгә чаклы ул кем беләндер дустанә мөнәсәбәттә булган һәм Сезне шул кешедер дип саташкан...»

Көймәче акчарлак белән очрашкан минутларны янә күз алдыннан кичерде. Менә ул аңа карап тора һәм кинәт диңгезгә егылып төшә. «Күрәсең, ул шундый игелекле кеше булгандыр. Йөрәк тикмәгә генә ярылмый шул ул!»

Көймәче уйланып бик озак басып торды.

* * *

Күктүбәдә күгелҗемләнеп кичке шәфәкъ яна. Алгын капка янында акчарлаклар оча... Ә диңгезнең кызарган офык тарафында төймә чаклы гына күренеп көймә йөзә.

**Чечен теленнән Госман САДӘ тәржемәсе.**

# Ким Васин

# ҖЫР ШУЛАЙ ТУДЫ

**ЛЕГЕНДА**

Кәгазь кисәге белән капланган керосин лампасының яктысы тонык кына булып өстәлгә төшә. Бәләкәй генә бүлмә почмаклары караңгылыкка чумган.

Өстәл янында ябык, авыру кыяфәтле кеше утыра. Ул инде күптән таныш сүзләрне, мөгаен, йөзенче тапкыр укыйдыр:

Мчатся тучи, вьются тучи;
Невидимкою луна
Освещает снег летучий...

Өстәл өстендә бөек рус шагыйренең ачык китабы белән янәшә язып-сызып чуарланган кәгазь битләре ята.

Кеше китапны читкәрәк этәрә дә чиста кәгазь ала.

Ничәмә тапкыр ала инде ул чиста кәгазь кисәген, ничәмә тапкыр, дулкынланып, үзенә кирәкле сүзләрне эзли, әмма барыбер таба алмый.

«Юк, булмый,— дип өзгәләнә ул.— Ә югыйсә бит бөек шагыйрьнең сүзләре рус телендә ничек гүзәл яңгырый... Туган телеңдә, чувашча шулай әйтеп бирә алсаң икән ул!..»

Бу кеше — «ышанычсызлыгы» өчен туган Чувашиясе якларыннан Царевококшайск дигән караңгы бер мари шәһәрчегенә сөрелгән, шушында шәһәр училищесында укытучы Михаил Федорович Федоров. Аның күңелендә, чуваш теле бай, чуваш телендә дә матур әдәбият була ала, моны исбатларга гына кирәк, дигән үҗәт бер фикер яши.

Баштарак Федоров шигырьне тәрҗемә итәргә генә тели. Ул Пушкин сурәтләгән күренешләрне ачык итеп күз алдына китерә. Аннары хәтердә башка картиналар — балачак күренешләре пәйда була... Һәм ул үзенә ошаган әлеге шигырьне болай гына тәрҗемә итеп булмаслыгына төшенә. Йөрәк башка нәрсә — чуваш күңеленә якын булган туган як кышы һәм бураны турында сөйләүне таләп итә.

...Невидимкою луна
Освещает снег летучий...

Бу бит балачактан таныш ай! Әнә ул, алтын тәлинкәгә охшап, кар баскан кырлар, көрткә күмелгән чокырлар өстеннән йөзә, ә авыр соры болытлар аның артыннан йөгерә! Ул болытлар, әбисе әкиятләрдә сөйләгәнчә, кара атларга атланган сәләмә убырлы карчыкларга охшаган.

Кышкы буранлы кичләрдә Мишши еш кына әбисе янына мич башына менеп утыра һәм аның әкиятләрен тыңлый иде.

Аннары малай вакытта ук әле әтисе белән урманга утынга баруы исенә төшә.

Суык битне өтә, борынны чеметә. Ә Миширгә ул бармы да юкмы — аны горурлык хисе җылыта: ни дисәң дә, ул малай-шалай түгел инде, эшче, мужик... Ярдәме әллә ни булмаса да, әтисе дә канәгать үзеннән — менә дигән булышчы үсә!

Күңелгә бигрәкләр якын шул туган як күренешләре! Хәтердә җанлы булып яңаралар, ә менә кәгазьгә ничектер тупас, шыксыз сүзләр булып яталар. Шагыйрьнең хис һәм фикерләре әйтелми кала.

Туган чуваш илендә яшәгәндә үк язып караган иде ул болар турында. Әмма шигырьләре дулкынландырмады да, йөрәккә дә үтеп кермәде. Нидер житми иде аларга.

...Федоров өстәл яныннан тора һәм йөренә башлый.

Фикерләр болытлар өере булып ага. Шигъри сүз бик кыен туа. Өйрәнерлек кеше дә юк, чөнки Федоровка кадәр чуваш телендә һичкем шигырь дә, поэма да язмаган.

Туган якларыннан читтә хәтта чуваш телендә сөйләшер кешесе дә юк.

Кайчакларда Федоров якындагы мари авылларына мари җырларын тыңларга баргалый. Аларның моңы да аңа чуваш моңнарын хәтерләтә...

Федоров тәрәзә янында туктала. Караңгы пыяла артында берни: ай да, болытлар да күренми, көзге төн төпсез упкынны хәтерләтә...

Өй түбәсенә туктаусыз әчпошыргыч яңгыр сибәли.

«Мондый төнне шүрәле-арсюри гына йөрсә инде,— дип уйлый Федоров.— Юлга чыккан кешенең, үзе дә сизмәстән, шүрәле кулына эләгүе бар. Кеше якты көнне ярата шул... Хәер, якты көндә дә кара көчләр хакимлек итә бездә».

Федоров күптән түгел мөдир белән булган бер сөйләшүне исенә төшерде.

Мөдир көндезге аштан соң, авыр сулап, йомшак креслога чумып утыра иде. Алдында, селкенергә дә куркып, ертык бишмәт кигән ябык бер малай басып тора.

Малайны мөдир янына Федоров алып килгән иде.

Михаил Федорович, шәһәр училищесында укытудан тыш, якындагы Ошурга дигән мари авылында мәктәп ачтырырга тырышып йөрде. Мәктәп ачылды. Федоров анда еш була. Бу малай да шул Ошурга мәктәбендә укыды. Үзе ятим, ярлы, ә үзе шундый акыллы, бик тә белемен арттырасы килә.

«Казна хисабына укытырга җибәрергә кирәк»,— дип уйлады Федоров һәм малайны мөдир янына алып килде.

Федоров үзе дә ярлы крестьян гаиләсендә үсеп кеше булды. Көндезләрен укыды, ә кичләрен итекчедә эшләде.

Әмма юкка гына тырышкан икән Михаил Федорович малайга ярдәм итәргә.

— Бөтенесе галим булса, кем минем сюртукны ямар соң? — диде мөдир, юан корсагын сыйпап.— Уку теләсә кем эше түгел ул. Акчасы юк икән, көтүче булсын. Әйе, әйе көтүче булсын!

Федоровның бөтен гәүдәсен ачу биләп алды, әмма ни эшли ала соң ул? Мөдир баш кеше, дәрәҗә иясе, ә ул — гап-гади укытучы, өстәвенә әле күзәтү астында яши.

Берничә минуттан пычрак урам буйлап арба узып китте. Анда ертык бүрек кигән абзый, аның янәшәсендә — башы иелгән малай утыра иде...

Мөдир белән сөйләшкәннән соң Михаил Федорович төне буе йоклый алмады.

Малай турында исенә төшердеме, Федоровның йөрәге атылып чыгардай булып тибә башлый:

«Давыл, шүрәле, әкияти хыяллар түгел, иң мөһиме — кеше, адәм баласының кайгысы һәм өметләре!»

Федоров өстәл янына утыра һәм яза башлый.

Әмма ул язган юллар шүрәле-арсюри хикмәтләре турында түгел, ә мөһимрәк, әһәмиятлерәк нәрсәләр турында иде инде.

...Әнә шулай итеп, мари җирендә, иске Царевококшайскида, элек беркемгә дә билгеле булмаган укытучы илһамы белән чуваш телендә беренче поэма, чуваш әдәбиятының беренче сүзе — «Арсюри» поэмасы туды. Поэма ярлы чуваш Хведер турында иде.

Бер вакыт кичкә таба Хведер, бер кисәк икмәк ала да, атын җигеп, Урхас урманына утынга китә.

Ә һава нык бозыла. Баш өстендә соры болытлар куера, җил күтәрелә. Урман ыңгырашып шаулый. Ачлы-туклы ат көч-хәл белән юырта.

«Их, атым да арык, тормыш та авыр: хатыным чирләде. Микола ходайга шәм куярга, кирәмәт-шайтанга колынны бирергә кирәк ахры»,— дип уйлый Хведер.

Караңгы төшә, ә котырынган җил агачларны сыга, ботакларны сындыра. Җил тавышы Хведер күңеленә дә шомлы уйлар сала.

Алга барырлык бернинди көч юк — тирә-юньдә һич ни күренми. Ә алда нәрсә ул? Пәри торамы юл уртасында, әллә кешеме? Усал арсюримы соң әллә?

Арсюри! ...Әлбәттә, шул... Шул булмый, кем булсын! Кар тузаннары күтәреп, Виснер кыры буйлап бүре кыяфәтендә чаба — Хведерны юлдан яздырырга тырыша.

Ат юлын югалта, тирән кар эченә кереп бата, өстәвенә дуга сына. Ә җил мең төрле тавыш чыгарып үкерә.

«Я хода, коткар үзеңнең колыңны! — дип пышылдый Хведер, саташып.— Кәҗәгә охшаган, озын аяклы арсюри бу!.. Исән-имин генә кайтып җитеп булса икән. Юкса, үлеп калуың да ихтимал. Хатын, балалар кала бит, минсез аларны кайгы һәм ачлык көтә...»

Хведер үзенең хәерче тормышына, арык атына, хәйләкәр һәм явыз арсюрига ләгънәт укый. Бәхетле тормыш турында уйлап, йөрәге сыкрый аның.

Кәгазьгә җыр кебек матур һәм моңлы сүзләр тезелә.

...Поэмасын язып бетергәч һәм язылганнарны кабат укып чыккач, Федоров күңелсезләнеп уйлап куя: «Җырласыннар әйдә, укысыннар... Ә кем укыр? Безнең халык бит караңгы төн кебек томаналыкта яши».

Үзе үлеп озак та үтмәстән, Идел киңлекләренә «Нарспи» поэмасы белән чуваш халкының зур шагыйре Константин Иванов чыгасын да, кояшның тормыш бирүче беренче яңа нурлары белән бергә Мишши Сеспель тавышы яңгыраячагын да, Эльгер, Ухсай, Хузангайлар шигърияте чәчәк атачагын да белми әле ул.

Күп нәрсәне белмәде ул, әмма бер нәрсәгә ышанычы нык иде: туган теле югалмаячак аның, кечкенә чишмә зур елгага әверелер, һәм шул чак халык чуваш телендә беренче шигъри сүзләр әйткән укытучы Федоровны зур хөрмәт белән искә алыр.

Мари теленнән **Миргалим ХАРИСОВ** тәрҗемәсе.

**Мостай Кәрим,**

Башкортстанның халык шагыйре, Ленин премиясе, СССР, РСФСР һәм Башкортстанның Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое.

# ОЛУГ ТУКАЙ ТУРЫНДА

Әйтер сүзләремне мин Тукай телендә әйтмәкче булдым.

Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән,
Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Җитмеш биш ел буе шул ук кәҗә шул ук тәрәзәдән карап тора. Теге заманнан соң дөньяда һәм күңелләрдә күпме үзгәрешләр булды, зәвыклар һәм модалар күпме алмашынды. Гади кәҗәләр урынына итсез-сөтсез гибридлар килде. Алар хуш исләре аңкып торган яшел печән урынына синтетик сагыз чәйниләр. Кендеккә чаклы киселгән күлмәк итәкләрен дә, вак-вак туракланган шигырь юлларын да байтак күрдек. Ә теге беркатлы, ихлас күңелле үлемсез кәҗә һаман сакалын селкетә, Тукайның даһиларча гади шигъри юллары, аксау-туксау белми, һаман җырлап торалар. Укымышлыларыбыз дип йөргән бәгъзеләребез олы яки кече изгелекләр кылган кешегә авыз тутырып рәхмәт әйтүне дә онытып барабыз, ә әшнәлек-танышлык аркасында гөнаһлы, кырын файда күрсәткәннәргә акчалата яки әйберләтә ришвәт бирергә өйрәнеп киттек. Ә илаһи күңелле әлеге надан кәҗә бер учлам үлән өчен кадимнән бирле Галигә рәхмәтләр укый.

Бихисап кешеләргә, бихисап халыкларга бихисап җан азыгы биргән Тукайга рәхмәтләр укырга килдек без бүген монда.

Татар халкының бәхете булып, дөнья әдәбиятының шатлыгы булып, моннан йөз ел әүвәл бу дөньяга Габдулла Тукай килде. Үз милләтенең гасырларга сузылган газапларыннан һәм өметләреннән, моңнарыннан һәм ораннарыннан, тир катыш канлы туфрагыннан һәм изге җаныннан ярался ул.

Язмыш аңа бер генә тотам, бер генә чеметем гомер бирде. Шул арада ул Россиядә үзен дә, сүзен дә үлемсез итте. Алай гына да түгел. Аның исеме һәм даны ил чикләреннән артылып чыкты, Көнбатыштагы караимнардан алып Көнчыгыштагы уйгырларгача барып җитте. Тукайны мин егерменче гасырда төрки телләрендә язган иң бөек шагыйрьләренең берсе дияр идем. Аның янәшәсенә, ихтимал, бары Назыйм Хикмәтне генә куеп буладыр.

Тукай дигән могҗизаның сере нәрсәдә соң? Әлбәттә, талантта. Ләкин бит аны табигать бирә, кеше үзе сайлап ала алмый. Әгәр дә андый сайлау мөмкинлеге булса, иң елгырлар, иң өлгерләр зур-зур талантларны алдан эләктереп бетерерләр иде. Сабырлар, инсафлылар авыз ачып калыр иде. Бәхеткә каршы, зур талант күбрәк әдәплеләр, акыллылар, намусчаннар өлешенә төшә. Тукай дигән могҗизаның төп сере, минемчә, шунда: ул үзенең бөек талантын дөнья культурасының казанышлары белән баета алды, шул талантына тулысынча баш булып, аны халык тормышының, заманының иң төп, иң олы юлы белән алып китте, алсыз-ялсыз хезмәт иттерде, аны үз-үзенә соклану яки кызык өчен генә сүз уйнату кебек вак, буш, мәгънәсез нәрсәләргә исраф кылмады. Әйтер сүзен ул кешеләр башы өстеннән ерак зәңгәр бушлыкларга карап әйтмәде,

11 июньда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап үткәрелгән тантаналы кичәдәге чыгышлардан.

ә замандашларының, кан-кардәшләренең мөлдерәмә хәсрәт һәм өмет тулы күзләренә карап әйтте. Аның таланты ширбәт телле юатучы да, вак җәнҗалчы да булмады. Ул батыр көрәшче булды. Халык өчен, хаклык өчен, кеше азатлыгы өчен көрәште, дөньяның ямен җибәреп, аңа чүп өстәп кенә йөрүчеләргә каршы көрәште. Көрәште. Шуңа күрә, көрәшчеләргә хас, аның дусы да, дошманы да күп булды. Шагыйрьнең гражданлык кыюлыгына, намуска тугрылыгына, әдәбиятның изге вазифасына ничаклы бирелгән булуына да әле хәйран каласың.

Габдулла Тукайның җәмгыятьтә тоткан урыны турында уйланганда уйга шундый чагыштыру килә. Александр Сергеевич Пушкин үз халкында нинди рухи яңару һәм күтәрелеш тудырса, Тукай да үз халкына карата шундый хезмәтне башкарды.

Ә безгә, башкортларга килгәндә инде, без Тукай алдында муеннан бурычлыбыз. Ул безнең халкыбыз мөгаллимнәренең, мәгърифәтчеләренең берсе һәм бик күренеклесе булды, безнең әдәбиятыбызга остазлык итүчеләрнең иң атаклысы һәм иң якыны булды. Үземә кагылып шуны әйтәсем килә. Мин илле елдан артык инде Тукайга сокланып туя алмыйм. Җитмеш өч ел элек дөнья куйган шагыйрьнең кабер туфрагы минем күкрәгемдә әле булса суынмаган, аның хакындагы хәсрәтем әле булса басылмаган. Шул соклану белән шул хәсрәтне, сәгате суккач, үзем белән алып китәрмендер, ахрысы... Әйткәнемчә, Тукай үз-үзеннән генә дәһи булмады, аны тарих тудырды, тормыш үстерде, кешеләр күтәрде. Байтак заманнар без, дөньяда ике төсне генә — ак белән караны гына аера торган кайбер төпсез тәнкыйтьчеләргә ияреп, Тукайны чолгаган яки Тукайга кагылышы булган кешеләргә, уңны-сулны аермый, күбрәк ләгънәт укып килдек. Әйдәгез, бүген, Тукайга йөз яшь тулган көнне, бөек шагыйрьгә сабый чагында икмәк һәм учак җылысы бирүчеләрне, егермесе тулганчы ук аның зур гыйлемле, зирәк акыллы иҗатчы булып өлгерүенә булышлык итүчеләрне, аның беренче китапларына юл ачучыларны, аларны хәрефләп җыючыларны, басучыларны, сатучыларны рәхмәт тойгылары белән искә алыйк. Тукайны аңлаган һәм канатландырган татар зыялыларын, алдынгы фикерле татар сәүдәгәрләрен, татар мөдәррисләрен, шул исәптән Мотыйгулла хәзрәт Төхвәтуллинны, яхшы уй белән хәтергә төшереп үтик.

Габдулла Тукайның бер генә бөртек күз яшен сөрткән кеше дә изгеләр исемлегенә теркәлергә хаклы...

## Николай Доризо,

рус шагыйре, РСФСР Язучылар союзы секретаре.

# ШАГЫЙРЬ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Төрле хәлләрнең бер-берсенә бик уңышлы ялгануы аркасында, мин Казанга турыдан-туры шигъриятнең егерменче Бөтенсоюз Пушкин бәйрәме узган Михайловскоедан килдем. Әле һаман шул тантаналар тәэсирендә яшәгәнлектән, мин бүген Пушкин белән Тукай исемнәренең янәшә яңгыравында тагын да зур бер закончалык күрәм, чөнки рус әдәбияты өчен Пушкин кем булса, татар әдәбияты өчен Тукай да шундый ук зат. Аларның якынлыгы беренче карашка күренгәннән шактый ныграк, тирәнрәк.

Без Пушкинны милләтнең бөек дәһие дип атыйбыз һәм аның беренче чиратта чын рус күренеше булу белән бергә, шигъриятенең дөнья мәдәнияте казанышына әйләнеп, халыкара яңгыраш алуын басым ясап әйтәбез. Шуны ук тулы җаваплылык хисе белән Г. Тукай шигъриятенә карата да расларга мөмкин.

Тукай Пушкинны яхшы белә, ярата, һәм аңардан өйрәнә. Ул бу хакта:

> Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
> Ай кебек, нурны алардан иктибас иткән бу баш,—

дип яза.

Кеше һәм художник буларак житлеккәч, ул бу шагыйрьләрне кат-кат телгә ала, шигырьләренең берсендә үзен ике бөек рус шагыйре белән бер сафка куя. Бу һич тә нииндидер әрсезлек булып тоелмый, ул юлларда чын хакыйкать ярылып ята.

Рус классиклары кебек, Тукай да — үз халкы өчен шагыйрь генә түгел. Ул, хосусан, әдәбият, ләкин киңрәк алганда, бөтен милли мәдәният өчен вакыйгага әйләнеп, сәнгать-

нең барлык тармаклары — татар музыкасы, нәкышы, театры үсешенә куәтле этәргеч бирде. Г. Тукайның тулаем иҗаты үз халкына бөек мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Шагыйрьнең һәр юлыннан диярлек сызлану саркый, чөнки ул мәхәббәтне, нинди генә ачы булса да, хакыйкатьне белдерү чарасы дип аңлый. Тукай туберкулездан һәлак булмый, ул бу кадәр яшьли нәкъ менә хөр, азат күрергә теләп тә, аны шулай күрә алмаган халкы өчен сызланып яна-яна юкка чыга. Ләкин Тукай күпме, шул исәптән, туган халкы аны хөрмәт белән искә ала, аны горурлыгы, вөҗданы итеп атый торган шушы якты көнне дә алдан күреп һәм алдан чамалап, шигырьләрендә тасвирлап, әйтеп калдыра.

Иҗаты милли җирлеккә һәм башлангычларга нык нигезләнү Тукайны кыен тәрҗемә ителә торган шагыйрьгә әйләндерде. Мисалга: Пушкинның «Мороз и солнце, день чудесный...» дигән юлларын башка телләргә тәрҗемә итү, мөгаен, мөмкин түгелдер. Нәни генә төгәлсезлек җибәрдеңме, бер генә сүзне икенчесе белән алыштырдыңмы, пакьлекне, бөтен күкрәк белән суларга теләгән кышкы һаваның рәхәтлеген тою югалачак та бетәчәк. Мондый искиткеч образлы, дулкынландыргыч юллар Тукайда да бар, тик аларны, кызганыч ки, әлегә татар укучысы гына укый ала. Бу хәл тагын бер мәртәбә безнең Пушкин алдында да, Тукай алдында да нинди зур бурычлы икәнлегебезне искәртә. Бу эш нинди генә авыр булмасын, без кадәри хәл ул юлларның даһилыгын иң тулы рәвештә саклап, теләсә кайсы телдә сөйләшүче һәр укучыга җиткерергә тиешбез.

**Сергей Кошечкин,**
рус язучысы, «Правда» газетасы хезмәткәре

# КҮҢЕЛДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

Куйбышев өлкәсенең карлар күмеп киткән Камышлы дигән татар авылында тыныч бер кышкы кичтә мин Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар»ыннан өзекләр тыңлап утырган идем. Әсәр ул чакта әле русчага тәрҗемә ителмәгән иде. Миңа аны дустым — район газетасының редакторы шагыйрь Әнвәр Давыдов сөйләгән иде. Тукайның шигырьләрен һәм прозасын яхшы белгәнлектән, аны тыңлап утыру өлешенә сирәк тия торган хозур вакыйга иде.

Әнвәр әллә ни хиска бирелмичә, тыныч кына сөйли, тик һәр сәхифә күңелемне сыкратканнан-сыкрата бара иде. Язмыш Тукайга нинди мәрхәмәтсез булган! Газап чигүләре санап бетергесез — авылдан-авылга, бер ят бусагадан — икенчесенә...

Габдулланың Кырлай авылында бәләгә таруы хәтеремдә аеруча уелып калган.

Монда аны бер игенче абзый асрамага ала. Көз. Салкыннар җитә, ләкин малай әле ялананяк йөри. Ул көндез бакчада эшли, аягы туңа башласа, аларны туфракка күмеп куя. Бер мәлне бәрәңге казучы апасы ялгыш Габдулланың аягына очлы көрәге белән китереп чаба. Малай кычкырып җибәрә һәм читкә тайпылып елый башлый. Аннары тирән җәрәхәтенә балчык сибә дә тагын бәрәңге чүпләргә керешә. Аяклары яңа туңа башласа, ул инде аларны моннан соң туфракка күмәргә бөтенләй җөрьәт итми...

Бер уйлаганда, Габдулланың Кырлайда уздырган балачагы бары тик күңелсез, сагышлы хатирәләрдән генә торырга тиеш иде сыман. Ләкин алай түгел. Аның туган ягына багышланган шигырьләрендә башка хисләр, башка истәлекләр дә яши.

> Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
> Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине, —
> Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;
> Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби...
> Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
> Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының...
> Һәм кәтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың,
> Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.

Тукайның «Туган җиремә» шигыреннән бу. Шагыйрьне Сергей Есенин югары бәяли. Югарыдагы юллар гәүдәләндергән тойгыларны Есенин туган илне шагыйранә күзаллау дип атый. Рус һәм татар шагыйренең куәт, матурлык чыганагы нәкъ менә ватанны тою белүдә. Тукай татар кызының чибәрлегенә сокланганда яки ярлыларның язмышына ачынганда да, ялкауларны һәм ялганчыларны мыскыл иткәндә яки тәкәббер аксөякләрне

фашлаганда да, хөрриятнең якынлашуына өметләнгәндә һәм ятимә кызларга хәерле тормыш юлы теләгәндә дә аның күз алдында һәрвакыт туган илы образы тора. Шагыйрь туган җиренең бәхетле киләчәге хакына яши, үзе турында уйламастан, үзен кызганмастан, шуның өчен көрәшә.

«Исемдә калганнар»ында бала чагында аякларын җиргә күмеп җылытуын тасвирлаганнан соң, Тукай:

«Моны ни өчен яздың?» — диярләр.

Ни өчен язйым? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга, тоттым да яздым», — ди.

Габдулла Тукай үзенең барлык шигырьләрен үзе туган, яшәгән, сызланган җире, туган халкы өчен чыдап булмаслык дәрәҗәдә җаны әрнегән өчен язган.

Әгәр аның йөрәгенә күз салу мөмкин булса, без анда төрле-төрле хәлләрнең рәхимсез кагылуыннан пәйда булган җәрәхәтләрнең берәү генә түгеллеген күрер идек.

Язмышы ничек кенә бөгәргә тырышса да, ул аның белән горурланып яши.

«Йолдызым якты, һаман нурлы»,— дип язды Тукай «Күңел йолдызы» шигырендә. Халык аның үзен инде күптән күңеленә йолдыз итеп кабул итте, яшь, газиз, йөрәк пәрәседәй якын улын ул һаман, кадерләп, кайнар күкрәгендә асрый.

**Абдулла Арипов,**
үзбәк шагыйре, Үзбәкстан ССРның Хәмзә исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

# ТУКАЙ ХАКЫНДА СҮЗ

Тукай татар халкының гына түгел, бәлки барлык төрки халыкларның, шул җөмләдән үзбәкләрнең дә сөекле шагыйре. Тукайның теле дә, рухы да безгә гаять тә якын. Сүз бу турыда гына түгел. Тукай иҗатында бөек шагыйрьләргә хас булган барлык сыйфатлар ачык күренеп тора. Бөек шагыйрьләр милли, территориаль чикләрне белмиләр. Табигый, чын шагыйрь иҗатында дөньяны күзаллау миллиләшкән була. Тукай шигъриятендә без Шәрык классик әдәбиятының иң гүзәл традицияләре янәшәсендә рус, Европа әдәбиятының бәрәкәтле тәэсирен күрәбез. Тукай Пушкин, Лермонтов, Толстой кебек олуг язучыларга даими мөрәҗәгать итеп торды. Үзбәк зыялылары гасырыбызның башлангыч елларында Тукай иҗаты аркылы рус әдипләрен таный белде дисәк, ялгышмаган булырбыз. Шул рәвешле Тукай, башка татар мәгърифәтчеләре белән берлектә, демократик фикерләрнең Шәрыкта, хосусан, Үзбәкстанда таралуында бер күпер булды. Тукай янып-көеп камчылаган социаль кимчелекләр Үзбәкстанга, үзбәкләр хаятына да хас иде. Дини фанатизм, милләтчелек, тарлык, үз мәнфәгатең өчен генә кайгырту, икейөзлелек кебек дәвер кимчелекләре дә Тукайны борчый иде. Шуңа да ул «дөньяны пакьли алмадым» дип хәсрәт чикте.

Ул елларда татар халкы алдында торган проблемалар үзбәкләр өчен дә уртак иде. Шул сәбәптән, үзбәк халкы Тукай шигырьләрен бик тиз үзенеке итеп кабул итте. Тукай мәктәпләрдә укытыла башлады. Әмма Тукай — барлык дәверләр өчен дә авазлаш шагыйрь. Тукайдан теләгән шигырегезне алып укыгыз, ул нәкъ бүген язылганча тәэсир итәр. Ә дөнья... һаман әле «пакьләнеп» бетмәгән. Тукай санаган кимчелекләрнең формасы гына үзгәргән. Мәсәлән, бүгенге мещаннар, обывательләр түбәтәй урынына эшләпә киеп, тәсбих урынына сигарета гына тота бит... Без бу бүгенге кимчелекләргә, сорыкортларга каршы көрәшмәктәбез: Тукай исә үзенең иҗаты белән бу өлкәдә дә безгә өлге булып тора.

Баш имә, зур син, бу әдна җанлылар дөньясына;
Падишаһ син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа.

Тукайның бу юллары һәр заман шагыйрьләрен гражданлык батырлыгына өнди. Шундый шагыйре булган халык бәхетле һәм үлемсез.

Ә безнең үзбәк әдипләре Габдулла Тукайга даими мөрәҗәгать итеп тора, галимнәребез исә аның иҗатын өйрәнә. Тукай әсәрләре үзбәк телендә кат-кат басылып чыкты.

Мин үзем дә шигырьдә бу данлы адашымның бер укучысымын. Хәзер сезгә мин Тукайга багышлап язган шигыремне тәкъдим итәм.

Мин димәм асла сине: «мескен Тукай...»
Дәртле идең, нурлы син, көчле, Тукай!
Чөнки син азат заманны эстәдең,
Максатың хөрлек иде, хөрлек, Тукай!
Үзбәк, татар, казакъ, я башкорт булып,
Күренерсең миңа гел төрле, Тукай!
Син караңгы төннәрдә беттең янып,
Гүргә кертте асылда... кимлек, Тукай.
Хак сүзенә милләтең күзен тексә,
Күпме затлар кылды сукырлык, Тукай.
Русия Ленин булып килгәч кенә
Китте илдән кимсетү, хурлык, Тукай.
...Һич гаҗәп булмас сине яд әйләсәм,
Икебез дә җирдә — җыр, орлык, Тукай!

## Николай Бабуглы,

гагауз шагыйре

### Шагыйрь

*Габдулла Тукайга*

Гомерең кыска кыскасын,
Җырың үлемсез —
Йолдыз булып күк йөзендә
Балкый синең сүз.

Уеңны син кошлар итеп
Очыргансыңдыр;
Ерактан йөрәккә кунган
Ул — синең моңдыр.

Үзеңә язгы бәйрәмнән
Ямь эзләмичә,
Әйткән сүзең шифа булып
Җаннарга күчә.

Тәкъдирдә язган дип кенә
Имәдең башың,
Егылдың изге юлында,
Газиз кардәшем...

Хәтердә син гел тересең —
Һич бетмәс көчең;
Мәңгелек саф чишмә сыман
Син безнең өчен.

Гагаузчадан **ӘХМӘТ РӘШИТОВ** тәрҗемәсе

## Равил Фәйзуллин

# ХУШ, ИТАЛИЯ! ИСӘНМЕ, ВАТАН!

Без бу илгә «Лунарионуова» әдәби ассоциациясе чакыруы буенча бардык. Ассоциация дигәннәре — Сицилиядә чыга торган «Лунарионуова» әдәби журналы тирәсендә тупланган бер җәмгыять. Аның белән күренекле итальян язучысы, журналның баш редакторы Марио Грассо житәкчелек итә. Италиядә иҗтимагый, мәдәни, әдәби оешмалар һәм төркемнәр шактый. Шулар арасында «Лунарионуова» ассоциациясе үзенең масштабы һәм прогрессив юнәлеше белән үзгә бер урын тота. Соңгы елларда беркадәр җанлана төшкән совет-итальян әдәби бәйләнешләре нигездә шушы оешма катнашында бара. Соңгы дүрт елда «Лунарионуова» чакыруы буенча егермегә якын совет язучысы Сицилиядә булып кайткан. Быел язын СССР Язучылар союзы белән әлеге ассоциация арасында бергәләшеп эшләү турында килешү төзелде. Димәк, алга таба элемтәләр тагын да ныгый төшәчәк.

Шулай итеп, Марио Грассо безне үз иленә дәште. Без дигәнем — совет язучылары делегациясе — шагыйрә Юнна Мориц, публицист һәм тәрҗемәче Афанасий Веселицкий һәм мин. Юлдашларым — миңа караганда дөньяны күбрәк айкаган кешеләр. Ю. Морицның Италиягә икенче тапкыр баруы, ә А. Веселицкий, шушы ил буенча белгеч һәм тәрҗемәче буларак, сәфәргә ешрак чыга — елына берничә урап кайта икән ул бу якларны. Минем исә Италиягә беренче чыгуым. Шулай да, зыян юк, күңел түгәрәк: яңа җир-илләр белән беренче күрешүнең кабатланмас үз кызыгы, тәэсирләре була.

## Сицилия, Этна, Сиракуза...

Әгәр миннән: «Сайла — Италиянең бөтен атаклы шәһәрләрен йөреп чыгасыңмы, әллә Сицилия утравын күреп китәсеңме?» — дип сорасалар, бер дә икеләнмичә, соңгысына ризалашыр идем. Ни өчен алай? Нигәдер күңел шулай; гели. Ихтимал, бу теләкнең төпле нигезе дә бардыр. Сицилия — дөньядагы иң данлыклы утрауларның берсе. Картадан карагыз: Италия — «итекнең» башында яткан өчпочмаклы таш сыман булып тора ул. Әмма гади таш түгел. Урта диңгезнең нәкъ уртасында яткан гәүһәр таш!

Сицилия соңгы дәвердә Италиянең артта калган ярлы аграр ягы исәпләнә. Әмма артталык дип нәрсәне аңлыйсың бит! Дөрес, кайбер экономик күрсәткечләр түбән биредә, Милан, Туриннардагы кебек, индустрия юк, байлык та кимрәк. Аның каравы, монда табигыйлек күбрәк. Гореф-гадәтләр ныграк, тел, борынгы җыр-көйләр сафрак булып сакланган. Монда тавыш, төтен аз. Күк зәңгәррәк, әфлисуннар күәшлырак. Сицилия — мафия ватаны. Мафия турында матбугатта еш язалар, шул нисбәттән бирелгән хәбәрләрдә Сицилия аталмыйча калмый диярлек. Сицилия — янартаулар, зилзиләләр иле. Этна вулканы яки бүтән берәр янартау ата башлау белән, дөньяның төрле почмакларында янәдән Сицилияне телгә алалар, чөнки бу утрау — вулканнар буенча иң атаклы җир. Һәм, ниһаять, Сицилия — борынгы антик сәнгатьнең күркәм бер төбәге. Олы юлдан читкәрәк чыгып, аяк астына карасаң, моннан мең еллар элек кеше кулы белән шомартылган, кайчандыр берәр бинаның бизәге булган мәрмәр-таш кисәген күрүең бар. Шуның янында ук куагыннан өзелеп төшкән лимон яки зәйтүн җимеше дә ята булыр...

Сицилия илдәге егерме өлкәнең берсе булып саналса да, Италия конституциясе буенча, аерым автоном хокукларга һәм вәкаләткә ия. Аның үз парламенты һәм региональ хөкүмәте бар. Димәк, монда мөстәкыйльлек күбрәк дигән сүз. Төп Апеннин атавыннан читтә булу, тарихи традицияләр (Урта гасырларда Италия көньягының байтак өлеше Сицилия исемен йөрткән), климатик шартлар (моннан Африкага — Тунис ярларына да ерак түгел, ара 200 чакрым чамасы булыр) — һәммәсе Сицилияне халыклар күз алдында үзгә бер халдә, үзгә бер урында тота.

Кыскасы, без Сицилиядә! Әйтәсе дә юк, җылы һәм йомшак җилле яклар бу. Без Рим — Катания самолеты белән утрауга декабрьнең дүртесендә килеп төштек. 20 градус җылы. Кешеләр күлмәкчән, юка кофтадан. Без, кар көртеннән чыгып, аллы-гөлле бакчага кергән кебек булдык. Булдык кына түгел, чыны шул: бакчалар, аллеялар, клумбалар шау чәчәктә. Безне аэропортта ассоциациянең актив члены — Антонио Грассо һәм бик чибәр яшь шагыйрә Лорелла Фраскана каршылады. Менә ике «мерседес» машинасы безне Урта диңгез ярлары буйлап җилдертә. «Диңгездә су коеналармы хәзер?» дип сорыйм Лорелладан. Ул, бер кулын рульдән алып, гаҗәпсенебрәк миңа карады: «Коену сезоны күптән бетте инде! Кыш житте, тиздән рождество бәйрәме...» Соңрак белдем, суның җылылыгы 20 градус чамасы... Ә без андый суны май кебек җылы дибез инде. Менә бит, җиренә, иленә карап, кыш төшенчәсен кем ничек аңлый!

Кеше кем генә булмасын, яңа җирдә, бигрәк тә чит ил җирендә, үзен үзгә, киеренкерәк халәттә тота. Андый чакта күзләр үткенрәк, колаклар сизгеррәк, «күңел локаторы» да гадәттәгедән күбрәк сеңдерүчән. Әлбәттә, һәр сәяхәт-сәфәрнең максаты, башкарасы бурычы була. Шактый ук чыгымлы булган (әйтик, бер җанның самолет белән барып-кайтуы гына да мең ике йөз сум чамасына төшә) безнең сәяхәтебезнең дә үз миссиясе бар иде. Бу хакта алдарак әйтеп узармын. Кеше шулай яратылган инде: аның җаны һәрвакыт нәрсәдер яңаны ачарга, нindидер яңаны белергә омтыла. Бу табигый омтылыш кешенең бер бәхетедер инде, күрәсең. Яңа җирне, аның кешеләрен күреп, белеп, аңлагач кына, син үз алдыңа куйган бурычыңны үти аласыңдыр. Сицилиягә килеп, мәшһүр Этна вулкан тавын күрми китсәң, үзе бер гөнаһ булыр иде шикелле. Әлбәттә, беркем дә сине ирексезләп, янартау итәгенә җибәрергә тормый. Әгәр телисең икән, рәхим ит, гид белән машина синең хозурыңда.

Этна — Сицилиянең үзенә күрә бер символы. Аның силуэты бирегә һәркайда: төсле открыткаларда, юл күрсәткечләрдә, реклама щитларында... «Лунарионуова» тарафыннан эшләнеп, безгә бирелгән чакыру билетларында һәм программа тышлыгында да Этнаның таныш сурәте төшерелгән иде. Хәер, бирегә әлеге янартау кәгазьләргә төшерүгә артык мохтаҗ түгел, башыңны күтәреп кенә кара: әнә ул үзе, «трубкасын тартып», төтенли дә төтенли... Без Этна турында балачактан ук дәреслекләрдән укып беләбез. Ул, бәлки, Везувийдан кала, иң билгеле вулкандыр. Дөрес, җир йөзендә Этнага караганда күпкә дәһшәтлерәк вулканнар да юк түгел. Андыйлар безнең Камчаткада да бар. Африкада да. Әмма Этна күпкә популяррак. Ни өчен? Чөнки тегеләре читтә, цивилизация төбәкләреннән еракта, ә Этна, Везувий, Стромболилар һәрчак кеше күзендә, фән, мәгърифәт, сәнгать гөрләгән җирдә. Аларның һәр сулышы белгеч-галимнәрнең игътибар үзәгендә. Өстәвенә, Этна Италиядә генә түгел, бөтен Европада биек саналучы вулкан. Дөньякүләм абруйлы вулканчы Һарун Таҗиев (ул Бельгиядә яши) әйтүенчә, Этна вулканнар холкын өйрәнү өчен иң кулай янартауларның берсе.

Менә мин дә, тигез ялан-болыннар, таллыклар, каенлыклар, инеш-үзәннәр баласы, әнә шул Этна дигән янартау итәгендә басып торам. Диңгез өслегеннән 2 мең метр биеклектә. Вулкан-«сызлавык»ның үзәгенә — кратерга кадәр әле тагын чакрымнан артык менәсе бар. Ләкин моннан ары барырга рөхсәт юк. Безнең Миргазыян Юныс мондый вулканнарның авызына якынрак барган. Үзенең бер китабында ул шушы хакта матур итеп язып та чыкты. Күрәсең, диңгезчеләр кыюрак халык, өстәвенә, хокуклары да үзләре белән булса кирәк. Ә без менә шушы ноктада тукталып калдык. Зимагурларча җилбәгәйләнеп, Такташ әйткәнчә, «галстугы белән билең бу да... әйдә, киттек, әнем»,— дип кенә чабулап булмый: рәсми тәртипләрне сакламый чара юк. Ярый, без Һарун Таҗиев түгел, вулкан-тау белән болай аңлашуыбыз да бик җиткән. Төп кратерның үзәгеннән тирә-юньгә таралган төтен күзләргә керә. Учак төтене кебек, ләкин исе, тәме, әчелеге бүтән. Әнә әле моннан берничә ай элек кенә ташып аккан лава ерганагы. Әйтерсең лә сумала агызганнар

Гомумән, без басып торган тирәлек кара пенопласт кантарларыннан тора кебек. Нindидер бер илаһи Гулливер кара туфраклы җирне аннан-моннан сөреп ташлаган шикелле. Юл кырыеннан ун метрлап эчтәрәк вулкан ату фаҗигасын кичергән йорт калдыклары. Шул нигезне карыйм. Стенадагы обойлар сакланган, электр үткәргеч тасмалар тырпаеп тора, кара янган ташлар арасында чынаяк китекләре, нindидер кәгазь-документ кисәкләре... Ияләре кая бу йортның? Афәттән котыла алганнармы? Әллә?.. Шунысы кызык: янәшәдә генә булачак йортның (масштабына караганда вилла булырга охшый) нигезен салып кайнашалар. Зур гына кишәрлек бүлеп алып, тимер рәшәткәләр корганнар. Йөк машиналары каяндыр балчык-туфрак ташый... Кемдер бу йортны үзе өчен, үзеннән бигрәк, балалары, оныклары өчен сала бит инде! Ә берничә айдан яки берничә сәгатьтән янә җир тетрәмәс дип кем әйтә ала? Дөрес, халык сынавынча, лава — кайнар инеш бер йөрелгән эзгә кабат төшми икән. Менә, яшәүгә, омтылышка, көч һәм акча салынган эшне аклауга төп аргумент! Ә утлы чишмәнең холкын тәгаен генә аңлап булмый! Соңрак белдек: Сицилиядән китеп, берничә көн генә үтүгә, без йөргән төшләрдән янә лава ташкыны шаулап үткән. Газеталар без торган шәһәрдә кайбер кунакханәләрнең җимерелүе турында да язып чыктылар...

Мәшһүр Сиракуза шәһәрен барып күрү дә ярады. Хикмәт шунда: безнең халыкка Сицилиянең бу тирәләре ябык диярлек. Әле моннан 10-15 еллар элек киң вәкаләтләргә ия рәсми журналистларга да Сицилиягә фәлән сәгатьлек пропусклар белән генә керү мөмкин булган... Сиракуза — бик борынгы шәһәр. Аның өч мең елга якын тарихы бар. Заманында шәһәр — крепость саналган, бөтен Урта диңгез буенда дан тоткан. Безгә фәлән мең еллык тарихлы шәһәрләр турында сөйләү кыен, андый саннар һәм ерак тарих белән эш итәргә әллә ни күнекмәгәнбез. Гасыр башындагы хәлләр дә безгә ерак тарих шикелле тоела. Ераграк тарихыбыздан истәлек һәйкәлләре калмаган диярлек. Хәер, әле чагыштырмача яшь кабер-станнарыбызны да тиешле хәлдә тотарга ирешә алганыбыз юк. Моннан егерме биш гасыр элек салынган грек театры ташларына утырып уйланган уйлар бу. Төзегәннәр бит. Ике аяклы, ике куллы кешеләр төзегән. Теминит дигән сөзәк таш тавын чокып төзегәннәр театрны, мәңгегә дип төзегәннәр. Цивилизацияле кеше ул, күрәсең, мәңгелек белән уртак тел табарга омтылган кеше буладыр. Юкса, таралырга торган кирпеч белән аннан-моннан бина-мазар корыштырып, ничек мәңгелеккә дәгъва итәргә мөмкин? Айлы төннәрдә, диңгез каршында, шушы борынгы ташларга утырып, Эсхил, Софокл, Еврипидның бөек трагедияләрен тамаша итү үзе бер вакыйгадыр инде ул...

Амфитеатр рәтләре буйлап йөрибез. Җылы ташлар арасыннан кәлтәеланнар шуып үтә. Әйтерсең, бу ташлар өстеннән гасырлар да шулай ялт итеп үтеп киткән! Кайбер таш утыргычларга исемнәр уелган, алар — борынгы түрәләрнең, гаскәр башлыкларының, патрицийларның махсус урыннары. Егерме биш гасыр буе искән җил дә, яуган яңгыр да аларның исемнәрен һаман юып бетерә алмый әле. Дөнья кызык: гүзәл театр корылмалары белән янәшәдә диярлек төрмә бинасы. Төрмәләр күргән бар (шөкер, экскурсиядә, музей хәленә китерелгәннәрен), ә бу үзгә төрмә. Биеклеге 8 метрлы бу бинаны чүмәлә формасына китереп өйгәннәр. Бернинди тишек-тәрәзә шикелле нәрсә юк, тик конус-гөмбәз очында гына бала кулы сыярлык тишек бар. Кояш яктысы эчкә, прожектор шикелле, шул уемнан төшә. Ә ул тишекнең калдырылуы да яктылык төшәр өчен түгел, ә түбәндә, җир идәнле зиндан төбендә яткан тоткыннарның сүзләрен ишетеп торыр өчен! Чүмәлә-төрмәнең акустикасы шундый шәп: тыңлаучыга сигез метр түбәндә сөйләшкән кешеләрнең сүзләре колакка пышылдаган шикелле ишетелә икән. Шуңа күрә аның бинасын «Дионис колагы» дип атаганнар да. Шунысы да бар: бу төрмә дөньядагы беренче сәяси төрмә исәпләнә. Өйгә кайткач, әлеге төрмәне төзеткән Дионисий турында материаллар караштыргаладым. Зур совет энциклопедиясендә аның турында белешмә-мәгълүмат болай башланып китә: «Дионисий — тиран...» Исемнән соң беренче атамасы — тиран... Мондый хәлне моңарчы очратканым булмагангамы, кызык һәм сәер булып китте. Ә бит ул үзе гаскәр башлыгы, ил башлыгы булган. Ул исән вакытта Сиракуза зур культура учагына әверелгән. Алай гына да түгел, үзе трагедияләр, шигырьләр, җырлар язган! Ә тарих хәтерендә барыбер тиран булып калган...

Караңгы зинданнан чыккач, яктылыктан күз бер мәлгә әлҗе-мөлҗе килеп ала да, якты дөнья шундый ямьле булып күренә! Янәшәдәге зәңгәр диңгез,

күктә ак болытлар, тирә-ягында җимешле куаклар, чәчәк аткан гөлләр. Дөнья ул, караңгылыктан бигрәк, яктылыктан, нурдан, изгелектән тора дигән шикелле, экскурсия ахырында безгә Сиракузаның чишмәле урыннарын да күрсәттеләр. Әле ниндиен генә! Моннан 2200 еллар элек бөек Архимед сызымнары буенча корылган торбалардан бүген дә су челтерәп агып ята, игелекләлек бүген дә кешеләргә хезмәт итә. Әйе, кемдер төрмә сала, кемдер чишмәгә улак куя. Архимед законнарын бала чакта өйрәнеп оныттык инде. Шулай да мәктәп елларында «Занимательная математика» дигән китаптан укыган бер куплет шигырь һаман истә.

Грозный Рим трубил победу
над стенами Сиракуз.
Но трудами Архимеда
многим больше я горжусь.

Мондагы кешеләр дә, ихтимал, бөек математик һәм физик якташының бар хезмәтләрен белеп тә бетермиләрдер. Ә ул корган торбалардан яшәү суы ага да ага. Үзенең бөеклеген эчкән су аша ничә гасыр буе һаман белдереп тора Архимед. Сиракуза дию гә, Архимед исеме хәтергә килә хәзер. Әлеге шәһәргә барган көн турында юл дәфтәремә мондый сүзләр язылган: «10 декабрь, 1985 ел. Сиракуза. Барып кайтырга өч сәгать вакыт үтте. 3 сәгать буена машинаның алгы утыргычында юлдашларыма сүз катмыйча гына, оеп, үз уйларыма чумып бардым. Декабрь, ә җәй. Кояш кыздыра. Бөркү. Юл читләренә кәрҗин-кәрҗин лимон, мандарин, әфлисун чыгарып куйганнар. Теләгән кеше акчасын калдырып, алып китә. Җимешләре өлгергән лимон кырлары ифрат матур. Диңгез яры буйлап барабыз. Зәңгәр дулкыннар өстендә альбатрослар оча. Ара-тирә ялгызак ак йортлар кала. Бакча эчендәге түтәлләрдә хатын-кызлар ниндидер кәлшәләр утырта. Өзек-өзек җыр авазлары ишетелеп китә. Мондагы пейзаж М. Сарьян полотноларындагы шикелле. Кырым, Кавказны хәтерләткән күренешләр дә бар. Җәннәт дигәндә, шушы җирләрне искә алырга ярыйдыр инде. Ә кайдадыр якында гына — бәлки әнә теге калкулык артындадыр? — ракеталар яшеренгән, кайдадыр ерак түгел, күгелҗемләнеп торган дулкыннар астында су асты көймәләре посып тора...» Аңлашылмый: шушы гүзәл дөньяга нәрсәгә алар? Чыннан да, Сицилиянең үзендә һәм аның тирәсендәге утрауларда хәрби базалар шактый күп. Шактый гына түгел, бик күп. Чит ил матбугаты хәбәрләренә караганда, Италия территориясендә Атлантик блок карамагындагы 129 объект исәпләнә. Зәңгәр диңгезгә, яшел калкулыкларга караганда, әнә шундый авыр уйлар да килә...

Инде Сицилия турында сүз баргач, мафия турында да, үзем аңлаганча, бер-ике җөмлә язып үтмәү дөрес булмас. Мафия төшенчәсе хәзер шулкадәр киң таралыш алды ки, аны белмәгән кеше юктыр. Өстәвенә, «мафия» сүзенең мәгънәсе дә киңәйде. Оста оештырылган кумәк җинаять турында да хәзер мафия дип кенә җибәрәләр. Шагыйребез Гамил Афзал хәтта «Мафия патшалыгы» исемле шигырь дә бастырып чыгарды. Кайбер юллары истә калган: «Череп яткан илләр чүплегендә кара гөмбә үсә — мафия. Кара фрак кигән мафиягә сенаторлар килеп баш ия. Закон — кәгазь, хөкем — комедия, патша булып тора мафия. Юаш халык кирәк мафиягә, мафиягә дәүләт баш ия...» Интуиция белән генә язылып, шигырь бераз беркатлы яңгыраса да, асылда, төп фикер-мәгънә белән килешми булмый. Мафия, чыннан да, хәзерге вакытта кайбер илләрдә җинаять формасы гына түгел, ә бәлки социаль мөнәсәбәтләрне дә белдерүче системага әйләнеп бара. Әйткәнемчә — мафиянең ватаны — борынгы Сицилия. Безнең гасырда мафия эшчәнлегенең алымнары бүтән илләргә дә киң таралды. Илленче елларда Америкада тамыр җәйгән «Коза ностра» исемендәге көчле мафия оешмасының эшләгән җинаятьләре бөтен дөньяга мәгълүм. Мафия үзенең канлы җинаятен дөньяның кайсы почмагында гына эшләмәсен, җепнең очы барыбер күп очракта Сицилиягә килеп тоташа. Халыкара масонлык оешмасын да, гангстерлыкны да мафиядән аерып карап булмый. Шулай да Сицилиянең үзендә «мафия» дип авыз ачып сөйләргә яратмыйлар. Сораштырганда да бу хакта теләр-теләмәс кенә җавап бирәләр. Гадәттә, ул җаваптан әллә ни аңлап та булмый. Кешенең авыруы турында үз алдында сөйләп тору уңайсыз булган шикелле, әллә мафия чынлап та аларның «авырткан җирләре»ме, әллә традицион куркумы, әллә аны бу якның табигый бер күренеше дип санауларымы?! — Кистереп әйтү кыен.

Мафия сүзенең этимологиясен дә төгәл әйтеп бирә алмыйлар. Бер версия буенча мафия — «онората сочьета», ягъни «абруйлы кешеләр җәмгыяте». Икенче берәүләр бу сүзнең мәгънәсен итальянчадагы «ана» сүзе белән бәйлиләр. Янәсе, бер ана балалары кебек якын, теләктәш кешеләр. Оешманың структурасы да гыйбрәтле: унлап кеше оешкан группа — «коска», бернichә коска — «гаилә», ә «гаилә»нең башлыгы — «капо»... Кайбер тикшерүчеләр мафияне тарихның билгеле бер этабында Сицилия өчен зарур күренеш булганлыгын да расларга тырышалар. Янәсе, ерак заманнарда мафиячелек Сицилиянең мөстәкыйльлеге өчен кирәк булган, аларны «благородный разбойниклар» сыйфатында күрергә теләүчеләр дә юк түгел. Имеш, мафиянең башлангыч кодексында этик нормалар бозылмаган: үз җиреңне ятлардан саклау, кумәк эш йөртү, сүздә тору, сатлык җанга мәрхәмәтсез булу, сер саклау һ. б. Әмма мафия — тарих барышында нинди генә метаморфозалар кичермәсен,— бүгенге көндә ул Италия җәмгыятенең яман шеш кебек бер әшәке авыруы... Без Сицилиядә булган көннәрдә мафиячеләрне күпләп кулга алу, Палермода аларны махсус эшләнгән төрмәләргә җыю башланган иде. Һәм, ниһаять, быелгысы елның февраль аенда Палермода моңарчы тарихта күрелмәгән процесс башланды. 474 кешенең эше судта карала. Мафиячеләрнең кылган җинаятьләре коточкыч! Мафия турында сугыштан соң, бигрәк тә соңгы егерме ел эчендә бик күп язылды, китаплар, фильмнар чыкты. Соңгы чорда Италия дәүләте, гомумән, илнең прогрессив җәмәгатьчелеге мафиягә каршы чын-чынлап ныклы көрәш җәелдерде. (Бу хәрәкәттә Италия коммунистлар партиясенең роле аеруча зур.) Палермода бара торган процесс бу җинаятьчелекнең тамырына балта чабу булачак дип ышанасы килә. Ләкин яман көч тиз генә бирешергә теләми. Процессны белән бетәр, күрербез.

## Танышулар. Әдәби кичәләр

«Лунарионуова» ассоциациясе оештырган халыкара очрашуларның «Италиядә культура көннәре»нең бу тугызынчысы иде. Әүвәлгеләре ничек һәм нинди даирә белән үткәндер, әйтә алмыйм, әмма соңгы бишесендә совет язучылары (нигездә шагыйрьләр) актив катнашкан. Оештыручы җитәкчеләрнең әйтүе буенча, Культура көннәре елдан-ел киңрәк колач ала бара. Шундый бәйрәмнәрнең тугызынчысында, совет язучыларыннан тыш, Америка Кушма Штатлары, Англия, Франция, Конго, Югославиядән килгән әдипләр дә катнашты. Унике көнгә исәпләп төзелгән программа бай һәм төрле, эчтәлеге белән байтак әһәмиятле проблемаларны эченә алган иде. Докладмы, дискуссион чыгышмы, газеталарда чыккан мәкалә яки интервьюмы,— фикер әйтү формасы нинди генә булмасын,— төп мәгънә һәрбер намуслы иҗат кешесен борчый торган проблемаларга барып тоташа иде. Иҗатчы һәм җәмгыять. Әдәбият һәм политика. Телевидение һәм поэзия. Халык иҗаты һәм модернизм. Әдәбият һәм киләчәк. Тәрҗемә принциплары... Әлбәттә, төрле континентларда яшәгән һәм төрле идеология белән сугарылган каләм ияләренең бу мәсьәләләргә карашы тәңгәл килеп бетә алмый. Шулай да, төрле карашларны белеп тору үзенчә гыйбрәтле.

Без программада күрсәтелгән чараларның байтагында, үзебез өчен файдалы һәм кирәк дип тапканнарының барысында да катнаштык. Шунысын да ассызыклап әйтеп узарга кирәк: ассоциация җитәкчеләре совет делегациясен игътибар үзәгендә тоттылар, безгә карата аеруча ихтирамлылык күрсәттеләр. Төрле шәһәрләрдә безнең делегация белән аерым очрашулар, аерым кабул итүләр дә булды. Мөгамәлә шундук сизелә: трибунадан сүз биргәндә дә, күрешкәндә дә, утырган урыныңнан да... Урамнарда «Совет язучылары делегациясен сәламлибез» дигән язуларны күрү, әлбәттә, бик күңелле булды. Ни дисәң дә, без бит әле чыкылдап торган капиталистик илдә йөрибез. Хикмәт без-шәрәфләр килүдә түгел.— бүтән илтәшләр килгән булса да, каршылау шулай ук яхшы булыр иде,— эш бүтәндә: Сицилиядә безгә кадәр булып киткән совет делегацияләре биредә зур уңыш казанып, җирле халык белән уртак тел табып, үзләрен яраттырып китә алганнар. Безгә кадәр ярты ел чамасы элек биредә Р. Гамзатов булып киткән. Аңа кадәр мәскәүле шагыйрьләр Юрий Воронов (ул хәзер КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге мөдире), Александр Межиров, Людмила Щипахина, латыш Имант Зиедонис, украинлы Виталий Коротич, грузин Жансуг Чарквиани булган.

Безгә эстафетаны дәвам итәргә, ирешелгән биеклектән төшмәскә, булдыра алсак, Совет-Италия әдәби мөнәсәбәтләрен тагын да ныгытырга кирәк иде. Һәл кадәре без шуны эшләргә тырыштык та.

Кызганычка каршы, Италиядә, мөгаен, бөтен Көнбатыш Европада дип әйтергә кирәктер, күпмилләтле совет әдәбиятын без теләгән кадәр белмиләр әле. Төгәлрәк әйткәндә, кайбер милли әдәбиятлар турында бөтенләй белмиләр. Бу хакта Ассоциация президенты Марио Грассо (Ул СССР язучыларының VIII съездында да катнашты) күптән түгел «Литературная газета»га биргән интервьюсында болай дип әйтте: «1981 ел ахырында совет язучылары белән миңа Монделлодагы очрашуда катнашырга туры килгән иде. Анда совет язучылары журналистларның күп санлы сорауларына чын йөрәктән, күңелдәгеләрен әйтеп, ихлас җаваплар бирделәр. Бу очрашудан соң мин дөрес информация алышуның, Советлар Союзы белән халыкара аңлашуда Совет-Италия язучылары хезмәттәшлегенең зарурлыгын һәм кирәклеген аңладым». Чыннан да бу очракта, Марио Грассоның политик зирәклегенә сокланмый мөмкин түгел. Ул җитмештән артык телдә иҗат итеп торган совет әдәбияты турында объектив фикер йөртергә омтыла. СССР Язучылар союзы идарәсе, шушы табигый ихтыяҗны исәпкә алып, күпмилләтле совет әдәбиятының бүгенге хәлен реаль гәүдәләндерә алырлык вәкилләрен Апеннин атавына җибәрә дә инде. Ихтимал, бу очрашуларда гел Мәскәү язучылары гына катнашса, сөйләшү кимәле никадәр генә югары булмасын, бәлки, сөйләшү һәм тәэсирләр нәтиҗәсе бертөслерәк булыр иде. Ә инде төрле телләрдә һәм традицияләре буенча төрле рухта һәм төрле милли үзенчәлекләр белән иҗат итүче әдипләр белән аралашу — объектив чынбарлыкны белү өчен зарур шарттыр.

Сицилиядә ун көнләп вакыт эчендә без җирле итальян язучылары һәм чит илләрдән килгән кунаклар белән шактый яхшы ук танышып өлгердек. Европа халыклары сөйләшә торган төп телләрне тиешенчә белмәү ныклап аралашырга комачауласа да, тәрҗемәчеләр ярдәме белән без берберебезне кызыксындырган мәгълүматлар алыша алдык. Турыдан-туры аралаша алмау, тәрҗемәче авызына карап торырга мәҗбүр булу аркасында, үзеңне уңайсыз халәттә, кимчелекле кеше кебегрәк хис итәсең. Кайбер очракта катлы-катлы тәрҗемә итүләр китә. Әйтик, әңгәмәдәшең французча әйтә, берәү аны итальянчага күчерә, икенче берәү русчага әйләндерә. Куян шулпасының шулпасы килеп чыга. Сөйләшүнең тәме, нюанслары югала. Ә язучы өчен фикернең бормалы юлларын белүнең, сөйләм нечкәлекләрен тоюның никадәр мөһим икәнен әйтеп торасы да юк. Моны, болай тәфсилләп, ни өчен әйтәм: кызганычка каршы, без, татар язучылары, чит телләрне юньләп белмибез. Телләр белмәү — безнең бер кимчелегебез. Әгәр зур максатлар куеп, әдәбиятыбызны зур дөньяларга алып чыгарга телибез икән, без «муму» булып утырып, битараф тәрҗемәчеләр генә безнең эшләрне башкарып чыга алмас...

Шагыйрь үзенең шигырьләрен укыганда күбрәк ачыла, шул чакта аның күңел тибрәнешләрен күбрәк тоясың. Без, Культура көннәрендә катнашучылар, бер кунакханәдә торып, беркадәр аралашып яшәсәк тә, чын мәгънәсендәге аңлашулар әдәби кичәләр вакытында булды шикелле. Менә базык гәүдәле, ак чәчле инглиз шагыйре Джон Силкин. Ул монда үз хисабына хатыны белән килгән. Англиядә киң билгеле шагыйрь һәм үзе чыгара торган поэзия журналының хуҗасы, редакторы. Шигырьләрен салмак кына, тавышны артык уйнатмыйча гына, җайлап укый. Гуманистик шигырьләр. Бөтен сүзләрен аңлап бетереп булмаса да, шигырьнең рухын, эчке экспрессив көчен тоеп утырасың. Менә Америкадан, Нью-Йорктан килгән озын һәм нәфис Мария Бритон. Негр шагыйрәсе. «Бар нәрсәгә орына алсаң икән!» дигән шигырен укуы әле дә күз алдымда. Тыңлаучыларны тетрәндерерлек итеп укый. Адәм баласы булып туып та, хокукының чикләнгәнлеген тоюның авырлыгын җан ачысы белән әйтә иде ул үзенең шигырендә. Француз шагыйре Віргелио де Лемос белән мине кыска шигырьләр якынайтты. Ул да җыйнак формалар белән мавыга икән. Кичәләрдә француз дустыбыз үзенең әле яңа гына язган кыска шигырьләрен укыды. Арада Юнна белән миңа багышлангannары да булды. Виргелио де Лемосның Парижда үз журналы бар. Кем белә, бәлки, әлеге шигырьләр басылып та чыккандыр инде...

Залда утырганда шундый уй да килеп китә: аллә ничә мең чакрымнардан, төрле континентлардан җыелган кешеләрне нәрсә берләштерә монда? Ни өчен әле алар бер-беренә, тыңлаучыларга үз телләрендә шигырьләрен укыйлар? Нәрсә телиләр алар, нәрсә исбатламакчы булалар? Әйе, диңгез-

океаннар кичеп, таулар-үзәнлекләр үтеп, бирегә килгән кешеләрнең конкрет-рак максатлары да бар. Әйтик, үз халкының, үз иленең әдәбиятын пропагандалау, әдәби журналлар, бу очракта «Лунарионуова» белән үз журналлары арасында эшлекле элемтә урнаштыру. Болардан тыш, минемчә, аларны тагын бер уртак теләк берләштерә: шушындый халыкара очрашуда шагыйрьләр бүгенге поэзиянең көчен сынап карыйлар, аның бүгенге заманга, кешеләргә кирәк дәрәҗәсен ачыкларга омтылалар. Ә заманасы шигырь өчен өзелеп төшәргә тормый. Каты замана, артык аек, артык акыллы замана. Яманлыкның яхшылык муенына менеп атланырга шартлары килеп торган замана. Европа илләрендә халыкның поэзиягә бик исе китмәве, шигырь китапларының аз тиражда чыгарылуы яхшы мәгълүм. Безнең ил шигырь сөючеләрнең күплеге, шигырь китаплары тиражларының зурлыгы белән бөтен дөньяда дан тотса да, соңгы биш-алты ел эчендә халыкларыбызның шигырьгә беркадәр суынуы сизелә башлады... Ә шулай да, без, төрле ил шагыйрьләре, Сицилия җирендә, иркенәеп, шигырь укып йөрибез әле. Күңелдә ышаныч бар: шигырь бетә торган сәнгать түгел ул. Кешелек яшәгәндә, җирдә сөю һәм өмет яшәгәндә, бишекләр тибрәнгәндә, кошлар сайрап күтәрелерлек зәңгәр күк булганда, поэзия бетә аламы соң? Шигырь пулянның очып бару юлын үзгәртә алмый, ә үлем китерә торган кнопкага басуны тыеп калдырырга булышырга мөмкин...

Без чыгыш ясаган заллар гадәттә тулы булды. Ихтимал, җыелган кешеләрнең бер өлеше, шигырь тыңлап ләззәтләнүдән бигрәк, ничегрәк икән болар дип, безне карарга да килгәннәрдер. Анысы да гаеп эш түгел. Ә чыгышларны болай бик җылы кабул иттеләр. Безне аеруча кызыксынып тыңладылар. Бу — табигый да. Итальяннар инглизләрне яки французларны күп күргән, ә безнең халык — биредә бик сирәк кунак. Кайберләренең хәтта рус телен беренче ишетүе. Юнна Мориц үзенең шигырьләрен бик оста укый. Алтмышынчы еллар башында күтәрелеп чыккан бу шагыйрәнең шигърияттә үзенең абруйлы урыны бар. Аны илебезнең төрле почмакларында алкышлап каршы алалар. Сицилиядә дә ул үзен Анна Ахматоваларга хас горур һәм затлы тотып, әсәрләрен артистларча югары осталык белән башкарды. Арттырып әйтү түгел: минем чыгышка игътибар аеруча зур булды. Татар кешесе чыгыш ясый. Бу факт үзе генә дә җирле халык өчен көтелмәгән яңалык иде. Татарлар турында ишеткәннәре бар, күрәсең, бу сүз аларда әллә нинди ассоциацияләр тудыра булса кирәк. Безнең тарихны чамалы белсәләр дә, дөресрәге, абсолют күпчелек бөтенләй белмәсә дә, «татар» сүзен ниндидер куркыныч дәһшәт-көч белән бәйләп караулары тәгаен иде. Алар безне «татар» урынына «тартар» диләр. (Бу сүз соңрак үзебезгә дә ошап китте, юлдашларым шаяртып, мине «тартар» дип йөри башладылар.) Кызыксыну шундый зур булгач, өстәвенә, делегациянең рәсми җитәкчесе дә саналгач, мин һәр чыгышымны бик җаваплы дип санадым. Сыналган тәҗрибә: үзеңне артык белдекле санап, артык катлаулы сөйләүгә караганда, гади һәм чын күңелдән сөйләү яхшырак. Нинди генә җирдә булмасын, гади халыкка, хезмәт кешесенә шулай кирәк, шулай үтемле. Кыска гына итеп, башта үзебезнең халык, республикабыз, ил тормышында тоткан урыныбыз, әдәбиятыбыз турында сөйләдем. Халык игътибар белән тыңлады, чөнки алар өчен бу яңа информация иде. Аннан соң русча, татарча шигырьләр яңгырады. Халык җырлары сүзләрен, Тукай әсәрләрен («Туган тел»не бөтен чыгышларда да сөйләдем шикелле) һәм үземнең берничә шигырьне укыдым. Һәммә җирдә бик бирелеп тыңладылар. Башта бер үк шигырьне русча, аннан татарча укый идем дә, тәрҗемәче аны итальянча (шигырьләр алдан ук тәрҗемә итеп куелган) кабатлый иде. Соңрак остарып киттек, вакытны да экономияләдек: татарчадан турыдан-туры итальянчага күчә башладык.

Бу очрашуларда татар поэзиясе дигән төшенчә дә италия, француз, рус, инглиз шигърияте белән беррәттән саналып йөрде. Һәм җирле матбугат битләрендә шулай аерым бер халык поэзиясе булып теркәлеп калды. Без җыенысы унлап әдәби очрашуда чыгыш ясадык. Аның бер ишләренә Культура көннәрендә катнашучы барлык делегация вәкилләре чакырылды, ә кайберләрендә без — совет шагыйрьләре генә катнаштык.

Ачибонаккорсида исә безгә ике тапкыр чыгыш ясарга туры килде. Беренчесендә шәһәр җитәкчеләре — мэр һәм муниципалитет членнары фәкать безнең белән генә очраштылар. Залга шулай ук шәһәрнең абруйлы кешеләре дә җыелган иде. Очрашу бик рәсми башланды. Өстәлдә СССР һәм Италия флагчыклары. Тәхет кебек урындыкта пиджак өстеннән күкрәк аша иңгә

кыйгачлап киң тасма салган мэр үзе утыра. Аның янына безне утырттылар. Урындыкларыбыз артында әзмәвердәй карабинерлар. Басып сөйләгәндә, сулыш алганнары баш чүмеченә сизелеп тора. Баштa рәсми тәбрикләүләр булды. Мэрның тәбрик сүзенә җавап рәвешендә мин дә нотык сөйләп алдым. Муниципалитет китапханәсенә «Казан», «О, Волга» дигән альбомнар, шулай ук Муса Җәлилнең рус, инглиз телләрендә чыккан сувенир китабын бүләк итеп калдырдым. Очрашу рәсми төстә башланса да, тора-бара теге яки бу мәсьәлә турында сораулар да бирә башладылар, шигырьләр укуны сорадылар. Ахырга таба муниципалитетның актлар залы поэтик салонга әйләнеп китте. Атмосфера җылынды. Очрашуны оештыручылар да бик канәгать калдылар булса кирәк. Ихтимал, бераз арттырып әйтүләре дә булгандыр, хуҗалар безгә: «Көтелмәгән уңыш казандыгыз!» — диделәр. Ничек кенә булса да, моны ишетү күңелле иде. Очрашу ахырында мэр безгә муниципалитетның истәлек бүләген — исемнәребез уелган көмеш медальләр тапшырды.

Рәсми өлеш тәмамлангач, безне бүтән бинада шәһәркүләм кичке мәҗлескә чакырдылар. Монда күбрәк яшьләр иде. Җырладылар, биеделәр, күңел ачтылар. Безнең делегация хөрмәтенә оештырылган үзенә күрә бер бал-маскарад иде ул. Күрәсең, программа буенча алдан шулай каралган булгандыр. Без муниципалитет бинасында тагын бер кат булдык әле. Бу юлы бүтән илләрдән килгән делегацияләр белән берлектә. Шәһәр үзе зур булмаса да, олыдан кубып, Культура көннәре уңае белән халыкара әдәби премия билгеләгән. Бу визит шушы бүләкне тапшыру уңае белән оештырылган иде. Безнең өчен бу кич аеруча истәлекле булды. Әлеге премиягә безнең юлдашыбыз — тәрҗемәче һәм публицист Афанасий Веселицкий лаек табылды. Ул аңа тәрҗемә эшләре һәм халыкара әдәби бәйләнешләрне ныгытуга керткән хезмәтләре өчен бирелде. Күңелле нәрсә, чит ил туфрагында үз әдәбиятың өчен горурлык хисе уята торган күркәм факт. Чит ил делегацияләре каршында безнең дәрәҗәне тагын да күтәреп җибәрде бу бүләкләү.

Очрашуларның тагын берсе хәтергә сеңеп калган. Монысы рәсми очрашу түгел иде. Безне бер итальян гаиләсе кунакка, дөресрәге, көндезге ашка чакырды. Түбән катлау кешесе түгел хуҗа, киресенчә, югарырак даирәдән. Соңгы елларга кадәр Ачиреале шәһәрендә карабинерлар идарәсе начальнигы булып хезмәт иткән. Хәрби чины югары. Безнеңчәгә күчергәндә, шәһәр милиция идарәсе башлыгы була инде. Маттео Калабретта әше буенча,— шик юк,— поэзиядән ерак кеше. Шулай да без чакыруны кабул иттек. А. Веселицкий аны яхшы белә. Мәскәүдә һәм Сицилиядә берничә тапкыр очрашкан булганнар. Чакыруның төп сәбәпчесе, әлбәттә, Веселицкий, аңа ияртеп, безне дә дәштеләр. Ул безне гаиләсе белән, Этна тавы итәгенә урнашкан кышкы вилласында кабул итте. Очрашу, билгеле, бик матур булды. Хуҗалар чын мәгънәсендә кунакчыллык күрсәттеләр. Өч сәгатькә сузылган аңгәмәдә байтак нәрсәләр ачыкланды. Сагаебрак кына килгән идек, киткәндә, дустанә тойгылар белән аерылыштык. Аңарчы ул безгә үзе төшергән документаль фильм күрсәтте. Карыйбыз: таныш күренешләр, таныш мәйданнар. Бәй, Мәскәү ич, Кызыл Мәйдан, «Россия» кунакханәсе! Таныш урамнар, хәтта кадрда таныш йөзләр дә күзгә ташлана. Маттео аны Мәскәүгә килгәч төшергән икән. Веселицкийның әйтүе буенча, бу фильм Калабреттаның сәяси карашында шактый ук зур роль уйнаган икән. Зур чиновник, безнең ил хакында буржуаз матбугат, радио-телевидение материаллары аша белә, утырган карашы бар. Караш шул — буржуаз пропаганда тәрбияләгәнчә. Мөмкинлек табып, безнең илгә үзе барып карамакчы була бу. Киноаппарат ала. Үзе икеләнә: төшерергә рөхсәт итмәсләр, «ирексез ил»гә бара бит, шулай да... Мәскәүгә килеп, кешеләр белән аралашкач, теләгән җиренә иркенләп барып йөргәч, башкаланың кызыклы һәм истәлекле урыннарын рәхәтләнеп кинога төшергәч, безнең ил турында фикерләре үзгәрә дә куя. Буржуаз дөнья кубызына яраклы кадрлар төшерергә чамалап килгән кешенең киноаппаратыннан башкала турында шактый ук объектив, безнең илгә ихтирам тудыра торган документаль фильм килеп чыккан. Әлбәттә, аның аңындагы үзгәрешләр алай тиз, кино төшергәндә генә булмагандыр, безнең ил халкы турында дөрес информацияле әдәбият укыгандыр, иң мөһиме, кешеләр күңелен укыгандыр. Ни генә булмасын, хәзер ул Сицилиядә совет кешеләренә симпатия белән карый торган кешегә әйләнгән. Авырлык белән булса да, төшергән фильмын Сицилия телевидениесеннән дә күрсәтүгә ирешкән.

Минем өчен тагын бер сюрприз булды бу йортта. Анысы да фильм белән бәйле. Һәвәскәр фильмның чираттагысы Мадридтагы «Пласа де торос» аренасындагы коррида — тореодорларның үгез белән сугышуы турында иде.

Җентекләбрәк карыйм, үз-үземә ышанмыйм: мин күргән коррида бит бу! Кайчан төшердегез дим.— Моннан өч ел элек, майның өчесендә, ди. Әйе, нәкъ шул көнне мин дә шушы ук аренада тамашачы булып утырган идем. Дөнья гаҗәп кызык, гаҗәеп очраклылыклар бар җиһанда. Кем уйлар: Мадридта күргән тамаша, экранда гына булса да, икенче бер чит илдә синең күз алдында кабатлансын әле! Чиксез зур да син дөнья, шулай ук кысан да син! Адәм балалары әллә нинди мөнәсәбәтләр белән бер-берсенә бәйләнеп беткән. Без кайчак аны шәйләмибез, ул хакта уйланмыйбыз. Язмыш кайчак сине шундый очраклылыкларның шаһит итә дә, тетрәнеп китәсең...

Ачиреаледәге (Катаниядән 15 чакрымнар ераклыктагы курорт шәһәре; без, нигездә, шул шәһәр кунакханәсендә яшәдек) тагын бер кичә хәтердә калган. Бусы бераз моңсурак кичә булды. Без Сицилия шагыйре Салвадор Агатиның китабы чыгу уңае белән оештырылган әдәби очрашуга бардык. Төп итальянча түгел, диалект телдә яза торган шагыйрь. Китабын «Лунарионуова» чыгарган. 42 битле кечкенә генә китап. Күп булса 300 ләп шигъри юл... Залга нибары 40 лап кеше җыелган. Бер әдәбият белгече китапның яхшы яклары, үзенчәлекләре турында сөйли. Аны икенче берәү алыштыра. Шигырь язучы кеше булса кирәк, ул да мактап сөйли. Сөйләгәннәренең бөтен нечкәлекләрен әйтеп бирергә тәрҗемәче өлгерә алмый. Аннан шагыйрьнең үзенә сүз бирделәр. Әлбәттә, ул залдагыларга рәхмәт әйтте, кичә ахырында үзенең китабын килгән кешеләргә өләшеп чыкты. Бик аз данә белән үз хисабына бастырган булса кирәк. Мәҗлес үзе бер караганда ярыйсы гына: авторны котларга кешеләр килгән, ул канәгать... Ә минем күңелдә барыбер авыр тойгы калды. Зур борынгы зал. Ә анда, адашып кергән кошчык шикелле, поэзия бәргәләнә... Бу бит Данте, Петрарка иле. «Бездә дә поэзиягә шушындый караш булыр микән?» — дип сорыйм Юннадан. «Юк! — дип кырт кисеп әйтте ул.— Мин һәрчак шыгрым тулы аудиторияләрдә чыгыш ясыйм». «Аерым чыгармалар булса да, бездә дә яшьләрнең поэзиягә битараф өлеше күбәя бару тенденциясе бар»,— дип сүзгә кушылды Веселицкий. Мин дә, теләмәсәм дә, аның белән килешергә мәҗбүр. Әйбергә табыну, прагматизм, бүгенге көн белән генә яшәү байтак кешеләрне поэзиядән читләштерде. Күрәсең, яшь буынны рухи тәрбияләүдә кимчелекләребез дә бардыр. Күңелдә шундый өмет: тормышыбызны сәламәтләндерүгә юнәлтелгән бүгенге шифалы чаралар кешеләрнең күңелләрен дә чистарта төшәр. Ә кеше күңеле матурлыксыз, поэзиясез ничек байый алсын ди инде!

## Башкалалар була таш кала...

Сицилиягә барышлый Римнең аэропортына гына сугылып үткән идек. Әшне бетергәч, кайтканда тукталырбыз, дидек. Һәм менә шул көн килеп җитте. Без янәдән Леонардо да Винчи исемендәге атаклы аэропортта. Нихәл, Рим! Безнең синдә ыгы-зыгылы рәсми эшләребез юк, синең белән танышырга, урам-мәйданнарыңны, музей-һәйкәлләреңне, синдә яшәүче кешеләрне күрергә, бәрәкәтләр эзләп китәргә дип тукталдык.

Римлеләр быел үз шәһәрләренең 2739 еллыгын билгеләп үттеләр. Әлеге борынгы шәһәр Тибр елгасы буендагы җиде калкулык өстенә салынган. Үзәкнең дә үзәге булып Палатин һәм Капитолий дигәннәре санала. Шәһәрнең салынуы турында мондый легенда бар. Имеш, борын заманда Энейлар нәселеннән булган Нумитор патшаны үз туганы Амулий үтерә һәм тәхеткә менә. Нумиторның кызы Рея Сильвия игезәк бала тапкач, Амулий, аларның тамырын корытырга теләп, Сильвияне үтертә, игезәк балаларны Тибр суында батырырга боера. Кәрзин белән суга ташланган балаларны дулкын ярга чыгарып ташлый. Ачлыктан, суыклыктан ачыргаланып кычкырган балалар тавышын ишетеп, ана бүре аларны үзенә сыендыра, имезә... Менә шушы ике туган, үсеп җиткәч, шәһәр сала башлыйлар. Дөнья талашсыз, үтерешсез яши алмый торгандыр инде, күрәсең, шәһәр диварларын салганда, туганнар арасында гауга чыга, һәм Ромул исемле туганы Ремны үтерә дә корылган шәһәргә үз исемен бирә һәм аның беренче идарәчесе була. Итальянлылар үз башкалаларын Рим димиләр, ә Рома дип йөртәләр. Байтак европалылар да шулай атый. Ә менә бездә Рим исеме кереп киткән. Әллә шәһәрне салышкан икенче туганын да онытмауга ишарәме бу? Хәер, бу минем үземчә фараз итүем генә. Легенданы, бәлки, һәммә кеше белми дә торгандыр, ә менә шул легенданы гәүдәләндергән бронза фигураны — ике сабый баланы

имезеп торган ана бүре сынын белмәүче юктыр. Бу сурәт мәктәп дәреслекләрендә дә бар, Римгә багышланган бүтән китапларда да. Капитолий музеенда без ул сынның үзен дә күреп чыктык.

Әйткәнемчә, Ю. Мориц белән А. Веселицкий Римдә моңарчы да булган кешеләр. Аларның үз танышлары, үз интереслары, үз юллары, дигәндәй, миңа Римне үзем теләгәнчә, үземчә ачып йөрергә туры килде. Совет илчелеге аша миңа тәрҗемәче беркеттеләр. Кулда Рим картасы, янда тәрҗемәче, шәһәр синең каршыңда: йөр, кара, өйрән, гыйбрәт ал... Тәрҗемәче Даниэла Либэрти дигән 22-23 яшьләрдәге бер чандыр гына кыз булып чыкты. Италия Коммунистлар партиясе члены, Совет-Италия дуслыгы җәмгыяте әгъзасы. Русча яхшы белә, Мәскәүдә рус теле буенча курсларда да булган. Югары белемле. Шулай да даими эше юк икән. Әлеге җәмгыять аша ара-тирә безнең илдән килгән делегацияләргә яки турист группаларына гид сыйфатында хезмәт күрсәтә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп үтик: Римдә эшсезлек — гадәти күренеш. Сәбәбе дә бар — шәһәрнең халкы күп (3 млн. чамасы), промышленность предприятиеләре аз, җитештерүче көчләр белән җитештерү средстволары тәңгәл килми. Рим асылда — чиновниклар һәм руханилар, кара киемлеләр һәм ак якалылар шәһәре. Рәсмилек һәм вакарьлек шәһәрнең йөзенә чыккан. Шушы күк гөмбәзе астында инде меңәрләгән еллар торган таш биналарның, сын итеп юнылган мәрмәр ташларның салкын һәм битараф карашы римлеләрнең дә холкына йоккан кебек. Кемнәрнең хәерче булып, кемнәрнең бай булып яшәүләре бу борынгы калага нәрсә? Бакый гомере эчендә андый контрастларны аз күргәнме ул? Аңа төрле партия талашлары, урам тулы демонстрацияләрең яки почмакларда бомба шартлауларың ни? Үз гомерендә күпме яуларны, җимерүләрне кичермәгән ул! Җир өстендәге Рим ул әле ярты Рим генә диләр. Әлеге хикмәти тәгъбирдә чыннан да дөреслек бар. Кай җирне казыма, шуннан борынгы корылма яки һәйкәлләр хәрабәсе килеп чыга. Шуңа күрә, шәһәр муниципалитеты метро челтәрен киңәйтүдән дә сагая. (Дөрес, Римнең үзәгендә метро бар, әмма ул бик кыска.) Римне Европаның мәркәз шәһәре дип тә йөртәләр. Үзара килешенгән кебек, болай дию бирәүдә дә шик уятмый. Бәлки Париж гына беркадәр көнләшеп куядыр. Әмма тарихының зурлыгы ягыннан, антик культураның төп үзәкләреннән берсе буларак, Париж Римгә җитә алмый. Католик дөньяның мәркәзе буларак та, беренчелекне ул үзенә нык беркеткән. Аңа тикмәгә генә Мәңгелек шәһәр титулы бирелмәгән шул.

Ике-өч көн эчендә дә байтак нәрсә күреп була икән! Әлбәттә, диңгез дулкыны күбеген күзләгән шикелле, өстән-өстән генә күрү инде ул. Мондагы сәнгать байлыгын ныклап өйрәнер-аңлар өчен ике-өч гомерең дә җитмәс. (Кайбер белгечләр әйтә: Италиядәге сәнгать хәзинәсенең кыйммәте,— әле акчага күчереп исәпләп,— бүгенге Американың бөтен байлыгыннан күпкә өстенрәк!) Вакыт бабай артыңнан камчылап торуга карамастан, күргәннәр дә, шөкер, байтак булды. Колизей, Венеция мәйданы, Форум, Изге Петр соборы, Ватикан музее, Аппиа юлы, Пантеон, Капитолий, Боргезе музейлары һәм кешеләр, кешеләр, кешеләр... Цивилизациянең гүзәл үрнәкләре булган бу истәлекле урыннар турында, ул гына да түгел, шушы урыннардагы һәр бина, һәр һәйкәл хакында төрле телләрдә, төрле халыклар тарафыннан әллә никадәр хезмәтләр, китаплар язылган. Күп беләмлеккә салышып, мәгърифәтле җиһанга мәгълүм нәрсәләрне кабатлыйсы килми. Хәттә, теләгәндә дә, бик үк булдыра да алмас идем. Әйтик, Ватикан музеенда гына да нинди шедеврлар юк! Микеланджелоның «Сикстин капелласы», Рафаэльнең атаклы фрескалары, Праксительнең Афродита статуясы. Шунда ук «Аполлон Бельведерский», «Лаокоон»... Болар турында белеп сөйләр өчен гомер буе туплаган махсус сәнгать белеме кирәк. Ә күз? Күзгә гел акыл белән боерып булмый: туйганчы карый ул, кирәк чакта нурлана, үзенчә сөенә, раслый, икърар итә, үзенчә бәя бирә...

Италиялеләрнең бер гадәте бар: алар өйләдән, төшке аштан соң ял итәләр. Учреждениеләр, конторалар эштән туктый, кибетләр ябыла, урам чатларында каштан яки артишок кыздырып сатып торучы фәкыйрьләргә кадәр каядыр югалып тора. Көннең билгеләнгән сәгатендә бер кавым ял итәргә гадәтләнгәннәр. Урамнар, мәйданнар бушап кала. Рим кебек зур шәһәрләр бөтенләй үк бушанып бетә алмый, әлбәттә. Чит-ят яклардан турист булып килгән халык авыз ачып йөри бирә. Русның «нет худа без добра» дигәне шикелле, әйдә, италиялеләр ятып торсын, безнең кебек кешегә үзенчә шәп вакыт бу. Ыгы-зыгы кимегәч, шәһәрне күбрәк күрәсең. Урамнарның төзелешенә, биналарга, алардагы бизәк-орнаментларга, һәйкәлләрнең, сын-

нарның нечкәләп эшләнгән детальләренә игътибарлырак буласың. Һәм тагын бер инанасың: Рим — зур бер музей. Кече яшьтән үк шушы сәнгать әсәрләрен күреп үсеп, ничек начар рәссам яки сынчы булырга мөмкин? Җавап бер генә: талантың һәм хезмәтең белән шушы гигант музейны баетсаң гына, син бу сәнгать дөньясында яши аласың. Бөтен дөньяның рәссамнары тикмәгә генә Римдә мәктәп узарга ашкынмыйлардыр. Россия хөкүмәте дә элекке заманнардан ук инде үзенең талантлы осталарын Римгә, озак сроклы командировкаларга җибәреп торган. Атаклы рәссам А. Иванов үзенең «Иисус пәйгамбәрнең халыкка пәйда булуы» дигән әсәрен егерме еллап Римдә торып ясаган. Ленинград яки бүтән зур шәһәрләрдәге байтак борынгы күркәм биналарны торгызырга да италияле осталар булышкан бит.

Милан — Италиянең йөрәге саналса, Рим илнең мие дип йөртелә. Рим — административ үзәк. Дәүләт учреждениеләренең күбесе Римдә урнашкан. Сәясәтләре белән бер-берсеннән нык аерылып торган төрле партияләрнең дә үзара көрәш мәйданы Рим булыр. Партияләр димәктән, Италиядә алар байтак. Төп партияләр — христиан-демократлар, социалистлар, республикачылар, социал-демократлар, либераллар партияләре... Бүгенге хөкүмәт башында торучы Бенедетто Кракси үзе Социалистлар партиясеннән. Хөкүмәт төрле партия вәкилләреннән укмаштырылганга күрә, тиешле бердәмлек юк, сәясәт рулен төрлесе төрле якка бормакчы була. Болай кискенрәк әйтергә нигез бар: Италия республика булып 40 ел яшәү дәверендә кырыктан артык хөкүмәт кризисы кичерде. Әйтик, үткән елгы кризис АКШ самолетларының Италия территориясендә законсыз төстә хуҗа булып йөрүләре белән бәйле булды. (Америка истребительләре Мисыр самолетын Сицилиядә төшерергә мәҗбүр иттеләр.) Бүгенге хөкүмәткә оппозициядә торган коммунистлар партиясе турында аерым сөйләү кирәктер. Чөнки ИКП — Көнбатыш Европада иң көчле коммунистлар партиясе. Быел ИКПның апрель аенда узган XVII съезды мәгълүматларына караганда, партиянең 1,6 млн члены бар. Италиянең өчтән бер сайлаучысы аларга тавыш бирә. ИКП — тиешле шартлар булганда, ил белән идарә итәргә сәләтле партия. Грамши, Тольятти исемнәренә бәйле бу партия белән безнең ил коммунистлары һәрвакыт санлашып килде. ИКПның хәзерге генераль секретаре — Алессандро Натта. Тәрҗемәче миңа ИКП секретариаты урнашкан бинаны да күрсәтеп узды. Венеция мәйданыннан ерак түгел урнашкан биш катлы йорт. Италиянең чын патриотлары, алдынгы карашлы кешеләре хезмәт итә анда.

Италия язучыларының милли синдикаты да Римдә урнашкан. Аның генераль секретаре Альдо де Яко үткән ел язучыларның Ленинградта оештырылган халыкара очрашуына да килгән иде. Чыгышы хәтердә калган. Шул ук очрашуда Италиянең зур шагыйре Элио Филиппо Акрокка белән дә танышып калган идек. Әмма алар белән Римдә очрашып булмады, ул көннәрне алар башкалада түгел иделәр. Милли синдикатның исеме зур булып яңгыраса да, ул безнең илдәге Язучылар союзы кебек ныклы оешма түгел. Штатында да бары берничә кеше. Билгеле бер юнәлештә эш алып барса да, синдикатны илдәге әдәби процесс белән идарә итә дип әйтеп булмый. Язучылар, асылда, һәрберсе үзбаш мөстәкыйльлектә яши, хәрәкәт итә, кыскасы, кем ничек булдыра ала, шулай тормышта һәм иҗатта үзенә юл яра. Язучылар, гадәттә, теге яки бу матбугат органында хезмәт итә, яисә үзе матбагачылык белән шөгыльләнә. Мәсәлән, иң атаклы язучыларның берсе Альберто Моравия гомере буе газетага язышты. Мөгаен, ул безнең илдә иң билгеле итальян язучысыдыр. Италиянең бүгенге көндә исән булган зур язучыларыннан тагын Леонардо Шаша исемен әйтергә кирәктер. Аның соңгы романнарыннан берсе «Моро эше» дип атала. Әлеге әсәр 1978 елда террористлар тарафыннан үтерелгән күренекле дәүләт эшлеклесе Альдо Моро фаҗигасына багышлана. Гомумән, Италиядә турыдан-туры иҗат эше белән шөгыльләнә торган профессиональ язучылар юк диярлек.

Рим — контрастлар шәһәре. Кемдер, миллион доллар торырлык алкалар тагып, мәрмәр залларда кәеф-сафа кора, кемдер, кулын сузып урам чатында сораныл тора, кемдер, социаль гаделлек даулап, полиция белән маңгайга-маңгай килә, кемнәрдер шул ук вакытта банк талый, собор залларында, әхлак кануннарын сакларга өндәп, гыйбадәт кыла, шуның янәшәсендә генә урнашкан секс-театрда тамаша карый. Рим, гомумән, бик чуар. Килгән халык та күп. Эмигрантлар да җитәрлек. Гарәп халкы да байтак. Әйтик, ГФРда төрек эшчеләре күп булган кебек, биредә ливиялеләр шактый. Яһүдләр дә аз түгел икән. Чөнки Рим, Вена кебек үк, эмиграция хәрәкәтенең бер тукталышы, юл сайлау урыны. Римне язмышлар чаты, дип тә

әйтеп буладыр. Үз вакытында безнең илдән китеп, хезмәттә һәм җәмгыятьтә кеше булларак үз урынын таба алмыйча каңгырып йөрүче яһүдләр дә монда җитәрлек. Алар күбрәк вокзал, базар, порт, парк тирәләрендә таптаналар. Үз халык вәкилләрен эш белән тәэмин итә алмаган башкала чакырылмый килгән мөһаҗирләргә яшәү шартларын ничек тудырып бетерсен. Кызганыч язмышлы кешеләр. Ничек кенә сау-таза булма, нинди генә һөнәр белмә, алар монда барыбер икенче сорт кешеләр санала. Эшсезлек коточкыч нәрсә! Үзенең көчен һәм акылын кулланып чара тапмаган андый кеше акча түләнә торган теләсә нинди тәкъдимгә риза була. Мондый төр категория кешеләрен политик авантюристлар һәм мафия корольләре үзләренең җинаять операцияләрендә шактый оста файдаланалар.

Тәрҗемәчем Даниэла миңа совет туристлары теләп йөри торган истәлекле урыннарны күрсәтте. Шундыйларның берсе — Н. В. Гоголь яшәгән йорт. Римнең иң күркәм һәм поэтик почмагы саналган Испания мәйданыннан ерак түгел Виа Систина урамында урнашкан. Тәртип саны — 126. Гоголь яшәгәндә, ул урамның исеме Виа Феличе, ягъни Бәхетле урам дип йөртелгән. Бөек язучы да монда үзенең бәхетле елларын кичергән дип уйларга кирәк. Биредә ул «Үле җаннар»ның беренче томын язган. Йорт стенасына истәлек тактасы беркетелгән. Бу мәрмәр плитә Римдә яшәүче рус колонисе тарафыннан 1901 елда куелган. Язучы башкала турында үзе мондый сүзләр язып калдырган: «Римгә әкренләп иялэнәсең, ә инде бер гашыйк булгач, гомергә онытмыйсың». Рус әдәбиятының икенче бер бөек әдибе А. М. Горький да Италия җирендә байтак еллар гомер кичерде, тарихта калырлык әсәрләр иҗат итте. Гасыр башында якташыбыз Ф. И. Шаляпин да бу якларда, Идел улы буларак, үзенең көчле авазын ишеттерде. Л. Н. Толстой токымының байтак вәкилләре бүгенге көндә дә Римдә яшиләр әле. «Барлык юллар да Римгә илтә» дигән тәгъбирдәге шикелле, соңгы гасырларда Россиянең байтак атаклы кешеләре Италия башкаласында булганнар, истәлек-юлъязмалар калдырганнар. Казан университеты галимнәренең дә Италия университетлары белән бәйләнештә торулары билгеле. «Волжский вестник»ның 1888 елгы 56 санында бу хакта хәбәрләр дә бар. Үткән ел Мәскәүдә, политик әдәбият нәшриятында «СССР — Италия» дигән документлар һәм дипломатик актлар тупланган китап чыкты. 1917—1984 елларны эченә алган әлеге зур җыентыкта безнең ил белән Италия арасында төрле чорда төрле төсмерләр алган политик, экономик һәм культура бәйләнешләре турында бәйнә-бәйнә язылган.

Италия башкаласы турында күп сөйләргә мөмкин. Язмамның бу өлешен бөек Гете әйтеп калдырган сүзләр белән тәмамлыйсы килә: «Италияне һәм Римне күреп белгән кеше беркайчан да үзен бөтенләй үк бәхетсез дип атый алмыйдыр».

## Самолетта уйланулар

Болай әйтү бераз шартлырак, әлбәттә. Самолетта гына түгел, күбрәк җирдә уйланып йөрисең. Шулай да, җирдән аерылгач, болытлар арасында уйга чумып баруның үз тәме, үз мәгънәсе бар. Менә безнең дә Италиягә сәяхәт тәмам. Самолет очыш биеклегенә күтәрелеп килә. Рим пинийлары аста калды. Таможня хезмәткәре тамгасы салынган кызыл тышлы совет паспорты кесәдә. Көндәлек блокнотым тез өстендә... Апеннин ярымутравыннан ераклашкан саен бу җирнең безнең яклар белән бәйләнеше турында күбрәк уйланыла, нинди дер мөнәсәбәтләр, вакыйгалар, фактлар белән араларны якынайтасы килә. Бәйләнешләр, асылда, бер яклырак. Борын-борыннан шулай килгән. Без әлекке Рим империясен мәктәпнең беренче елларында ук өйрәнә башлыйбыз. Урта диңгез тирәләренең тарихы шундый, цивилизациясе шундый... Көнбатыш Европаның фәнен, сәнгатен, әдәбиятын, гомумән, культурасын күзалласаң, ирексездән, һәммәбезгә мәгълүм исемнәр хәтергә килә: Леонардо да Винчи, Галилео Галилей, Джордано Бруно, Рафаэль, Микеланджело, Тициан, Паганини... Тагын әллә никадәр исем санарга мөмкин. Дөресен генә әйткәндә, безнең күбебез Урта диңгез төбәгендәге цивилизацияне бар бөтенлеге белән ныклап белмибез әле. Моның тарихи сәбәпләре дә бар. Борын заманнардан бирле Идел-Урал халыклары, бигрәк тә болгар-татарлар, иң әүвәл Шәрык цивилизациясе белән җимләнгәннәр. Мәгърифәткә тартылган яшьләр, гадәттә, Бохара, Димәшкъ, Каһирә кебек үзәкләргә барып гыйлем алганнар. Миңа калса, Көнбатыш Европа белән безнең мөнәсәбәтләрне Рус дәүләтенә кушылганнан соңгы дәвергә бәйләп аңлату хакыйкатькә якын

булыр. Дөрес, аңарчы да итальян сәяхәтчеләре дөньяны бик күп айкаганнар. Әйтик, Марко Поло, инде XIII гасыр ахырында ук Кытай һәм Үзәк Азия, Кавказ якларында булып, гаять кыйммәтле мәгълүматлар калдырган. Каспий, Дон, Идел тирәләренә килеп чыгучылар да булган. XV гасырда яшәгән Венеция сәүдәгәре Йосафат Барбаро һәм шул ук Венеция республикасы илчесе Амброджо Контаринииарның юлъязмалары шул хакта сөйли. Төрки халыклар өчен тарихи кыйммәткә ия «Кодекс куманикус»та (XIV йөз башы ядкаре) италиялеләр тарафыннан төзелгән. Аның төп нөсхәсе хәзерге вакытта Ватикан китапханәсендә саклана. Шул ук музейда төрки-татар хикәяләре тупланган итальян телендәге китап та бар. Китапчы галим Ә. Кәримуллин тикшерүләренә караганда, беренче татар басма китабы чыгуда да италиялеләрнең роле зур булган.

Антик цивилизация төбәгенә борын заманнарда безнең халык вәкилләре дә тартылганнардыр һәм барып чыкканнардыр дип уйлыйсы килә. Без аларны белмибез генәдер. Рәсми дипломатик каналлар буенча булмаса, рус флоты составында диңгезче яки Суворов походлары вакытында солдат сыйфатында бу тирәләрдәге хәрби яки сәүдә операцияләрендә катнашканнардыр. XIX гасыр ахырында ук эре капитал һәм интеллигенция вәкилләреннән кайберәүләрнең Апеннин ярымутравында булулары билгеле. Әйтик, журналист һәм язучы Ф. Кәрими Европа буйлап сәяхәте вакытында Италиягә дә кагылган. Революциягә кадәрге татар вакытлы матбугатында Италия сәнгате һәм бу илнең бөек шәхесләре турында байтак материаллар чыккан. 1908 елны Сицилиянең төньягында көчле җир тетрәүдән бик күп кешеләр һәлак булганнан соң татарлар арасында махсус бәетләр таралган. (Бу хакта М. Мәһдиев газетада язып та чыккан иде). Совет чорында безнең нәшриятта һәм вакытлы матбугат битләрендә Италия әдәбияты һәм сәнгате вәкилләренең байтак әсәрләре дөнья күргән. Шулай да, соңгы дәвердә (40—50 елны күздә тотып әйтәм) бездә иң күп басылган итальян язучылары — Джованни Джерманетто һәм Джованни Родари. Һәр икесе дә үз заманында Казанда булып киткән. Беренчесе Бөек Ватан сугышы чорында бераз вакыт бездә яшәп тә алды. Дж. Джерманетто — шактый ук мәгълүм язучы. (Иң билгеле әсәре «Цирюльник язмалары») һәм Италия Коммунистлар партиясенең күренекле вәкиле. Үткән ел әдәби җәмәгатьчелек аның 100 еллыгын билгеләп үтте (1959 елны үлде). Казанда яшәгән чорда ул татар әдәбияты белән нык кызыксынган. Тукайга багышлап шигырь бастырып чыгаруы әнә шул хакта сөйли. Әлеге шигырьнең кайбер юлларын искә төшереп узыйк:

Юк, үлмәдең, гакыллы ир, мәшһүр Тукай!
Тавышың яши кабатланып һәр буында.
Халкың кебек бөек, матур җырларыңдай
Даһилыгың яңгырап барыр гасырларга.

Моннан 15 еллар элек мәшһүр балалар язучысы Дж. Родари Казанга махсус килеп киткән иде. Бездә аның «Чипполино маҗаралары» (1957) һәм «Зәңгәр ук сәяхәте» (1960) әсәрләре аерым басмалар булып чыкты. Республикабыз язучылары белән очрашуында ул үзенең татар телендә чыккан әсәрләрен күреп, болай дигән иде: «Минем бу китабым үземнән бәхетлерәк, чөнки ул татар балалары белән татарча сөйләшә белә!» Хәзер инде Родари исән түгел, әмма ул безнең күңелләрдә сөйкемле, якты кеше булып калды. Шагыйребез Зөлфәт үзенең күләмле бер шигъри әсәрен аның якты истәлегенә багышлап язды. Италияле Джерманетто Тукайны хөрмәтләп шигырь язса, икенче бер итальян Рениеро Ланфредини, герой шагыйребез Муса Җәлил белән бер камерада утырып, аның соңгы көннәре шаһите булды. Нәтиҗәдә без шагыйрьнең гомер җыры азагы турында күбрәк мәгълүмат белә алдык. Фаҗигалар белән тулы бу заманда халыкара бәйләнешнең әнә шундый гыйбрәтле миссаллары, әнә шундый формалары да бар шул. Безнең театрларыбыз репертуары һәм концерт программалары турында сүз чыкса, италияле авторларның әсәрләре турында аеруча күп сөйләргә мөмкин. Әйтик, «Севилия чәч алучысы» (Дж. Россини), «Риголетто», «Трубадур», «Травиата» (Дж. Верди)... Болар безнең опера һәм балет театрының репертуарын бизәүче әсәрләр түгелме? Бу җәһәттән, Татар дәүләт академия театрында К. Гольдони, Э. Де Филиппо һәм башка драматургларның әсәрләре буенча куелган спектакльләр гөрләп барды...

Табигый бер сорау туа: ә татар әдәбияты, сәнгате турында Италиядә беләләрме соң? Бу хакта кистереп уңай җавап бирү кыен. Төрле елларда безнең хакта аз-маз хәбәрләр басылган. Әйтик, 1925 елда бездә беренче милли опера куелу уңае белән Римдә «Көнчыгыш Европа» (L Europa orientale) дигән журналда бер мәкалә басылып чыккан. 1957 елны «Совет чынбарлыгы» (Realto Sovetica) журналында Мәскәүдә үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы турында материал басылган. 1963 елда «Европа әдәбияты» (L Europa letteraria) журналында Муса Җәлил турында мәкалә һәм аның шигырьләре урнаштырылган. Мәкаләнең авторы һәм шигырьләрнең тәрҗемәчесе — Марианно Джузеппе. Соңрак чорга килгәндә, 1978 елны Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Италиянең төньяк шәһәрләрендә гастрольдә булып кайтты. Артистларның бу сәяхәте татар милли сәнгатен Европа үзәгендә күрсәтүдә, гомумән, италия-татар мөнәсәбәтләре тарихында үзе бер якты сәхифә. Итальян-татар бәйләнешләре турында белгәннәрем шулар. Ихтимал, мин белеп бетермәгән тагын бүтән фактлар да бардыр. Булса, бик шәп. Шулай да безнең бай тарихлы әдәбиятны, шактый үзәнчәлекле сәнгатьне чит илләрдә, Европада, шулай ук Италиядә дә киңрәк күрсәтү, пропагандалау буенча эшләр бик күп, бик күп әле. Бу юнәлештә тугандаш халыкларның уңай тәҗрибәсен өйрәнү дә артык булмас. Мисалга ерак барасы түгел: әйтик, күрше чуваш дусларыбыз үзләренең поэтик анталогияләрен француз, венгр, итальян телләрендә чыгаруга ирешкәннәр икән, бу очракта үрнәк алу яхшы гына булыр. Бу мәсьәләдә турыдан-туры безнең «йомшак җиребез» — тәрҗемәче кадрлар тәрбияләү һәм чит тел белүче тәрҗемәчеләр белән бәйләнешне ныгыту кирәклегенә кайтып кала.

Бүгенге заман — халыкара аралашу заманы. Кыйтгалар белән кыйтгалар, дәүләтләр белән дәүләтләр, халыклар белән халыклар аралаша. Дәүләт эшлеклеләре белән дипломатлар бер-берләренә йөреша, фән һәм техника кешеләре үзара информация-мәгълүмат алыша, әдәбият һәм сәнгать, гомумән, культура әһелләре дә бу җәһәттән бер-берен ныграк аңларга, уртак тел табарга, рухи казанышлар алмашырга омтыла. Яшәү рәвешләре һәм сәяси юнәлешләре нинди генә булуга карамастан, замана аралашуны һәм аңлашуны таләп итә. Ахыр чиктә, җир йөзендәге тынычлык, иминлек, сугышны булдырмау халыкларның үзара аңлашуына, сүз беркетеп килешүенә, дуслаша алуына бәйле бит. Тынычлык өчен гомум хәрәкәттә, кайбер өлкәннәргә сабак күрсәтеп, нәни балалар да актив көрәшә хәзер. Мәскәү укучысы Катя Лычеваның АКШка барып, дуслык, иминлекне ныгытырга өндәп йөрүен бөтен дөнья сөенеп күзәтте. Икенче бер бала — Катяның яшьтәше — 10 яшьлек Ника Турбина да Италия буйлап сәяхәттә йөрде. Үткән ел аңа гуманистик рухлы шигырьләре өчен Италиянең зур бүләге — «Алтын арслан» премиясе бирелде.

...Самолет Мәскәү өстенә якынлаша. Уфалы Ибраһим Абдуллин романы исеме белән әйтсәк, «Хуш, Рим! Исәнме, Туган ил! Без чит җирләрдә йөреп, гыйбрәт алып, Синең якты киләчәгең өчен хезмәт итәргә яңа дәрт, яңа омтылышлар белән кайтып киләбез.

Ачиреале — Рим — Казан.

*1985 ел ахыры,*
*1986 ел башы.*

Казан утлары АЭС әдәби пост

## Николай Морозов

# БӘРЕЛЕШЛӘР АША

Кама Аланына барган саен, күңелдә бу төзелешне беренче кат күргән көннәр хатирәсе яңара. Тәүге кичерешләр онытылмый — беренче мәхәббәт кебек. Татарстан җирендә күтәрелә башлаган яңа шәһәрчек һәм куәтле электр энергиясе бирәчәк станция корылышының һәр үзгәлеге хәтергә нык сеңеп калган.

Безнең АЭС — КамАЗ, «Нижнекамскнефтехим», КамТЗ кебек гигантлар арасында аерым бер яктылык белән балкып торыр, мөгаен. Безнең илдә бүгенге көндә электр энергиясе бирүче станцияләрнең уңдүрте атомнан көч ала. Тагын утызлап станция салынып ята. Татарстан АЭСы аларның иң көчлеләре рәтенә басачак.

Кама Аланындагы корылманың нинди куәткә ия булачагын аңлату өчен, аны Түбән Кама ГЭСы белән чагыштырып карыйк. ГЭС турбиналарына күз салсаң, мәһабәтлеге сине хәйран итә. АЭС реакторлары, чынында, уңдүрт катлы ташпулат биеклегендә булсалар да, аларның күп өлеше җир астында калганлыктан, аз гына калкып торалар. Әмма АЭС энергияне биш мәртәбә артыграк бирә.

Татарстан АЭСы бу төр станцияләрнең эш алымына да яңалык алып килә. Әлегә кадәр салынган станцияләрнең берсе генә дә электр энергиясен чамалап бүләргә көйләнмәгән. Аңлатыбрак әйтсәң, болай: алар күпме энергия эшләп өлгертсәләр, шуның барын берьюлы электр челтәренә бирә бaралар. Көндез дә, төнлә дә — бертөрлексез. Ә, мәгълүм булганча, төннәрен электр энергиясенә ихтыяҗ шактый кими. Татарстан АЭСын проектлаучылар бу хәлне истә тотканнар. Кама Аланындагы энергия чыганагы акыллы хуҗа кебек эшләячәк: төнлә кулланыштан арткан энергия, янга калдырылып, җыелып барылачак һәм көндез, станция көченә өстәмә булып, төп чыганакка кушылачак.

Атом энергетикасы — безнең өчен ифрат серле нәрсә. Шуңа күрә мин дә, Кама Аланына барган саен, булачак станциянең директоры Лев Николаевич Журавлев белән сөйләшүне көтеп алам.

— Татарстан атом электр станциясе гаять отышлы станция булачак! — дип сөйләп китә ул.

Кызганычка каршы, аңардан ишетеп белгәннәремнең барын да язып бетерү мөмкин түгел. Шулай да кайбер мәгълүматлар белән уртаклашуны кирәк саныйм. Лев Николаевич инде утыз ел буе атом-төш гыйлеменең үзәгендә кайный. Ул Коладагы АЭСта да эшләгән, чит илләрдәге бу төр станцияләрне дә күргән. Үзенең хикәяләвен шактый гадиләштереп, башка сыймастай тоелган катлаулы процесслар турында да бик аңлатып сөйли ул. Үз һөнәрен яратучыларга хас дәрт белән бик теләп тәфсилли. Фәннәр кандидатының көчле теоретик икәнлеге дә әллә каян сизелеп тора. Гүя аның өчен бу фәндә бары да ап-ачык. Хәер, ышаныр-ышанмас хәлдә бу эштә ни дә булса майтару мөмкин дә түгел

Директор белән әңгәмәләрдән мин менә нәрсәләрне ачыкладым. Татарстан АЭСы атом станцияләренең башка төркеменә карый. Аны чимал белән тәэмин итү тимер юлчыларга мәшәкать тудырмаячак. Әгәр монда күмер яга калсаң, Кама Аланына һәркөнне тулы алты состав килергә тиеш булыр иде.

— Монысы яхшы-ы,— дип суздым мин.— Тик бу реакторларның һәммәсендә Хиросиманы харап иткән бомба куәте ята бит?!

— Шикләнүең табигый.— Журавлев елмайды.— Атом-төш энергетикасының серләрен белмәгән кешеләрдән бераү дә бу сорауны читләтеп узмый.

— Дөресен әйтим: Кама Аланын күргәч, йөрәгем кысылды, шундый хозур урынга атом станциясе салучыларга ачуым кабарды. Бигрәк матур яклар, Швейцария Альпындагы кебек урман белән капланган калкулыклар, көмеш сулы елга, кечкенә генә авыллар, борма-борма юллар...

— Тукта, хисләрне калдырып торып, кайбер саннарга күчик әле! — Директор кинәттән, кулын күтәреп, сүземне бүлде. Папкасыннан кәгазь кисәге алды.— Безнең илдә һәр кеше, башка илләрдәге кебек үк, күпмедер миллибэр нурланыш ала. Бу — тормыштагы бөтен нәрсәне истә тотып алына торган нурланыш, ягъни монда табигатьтәге радиацион нурланыш та, рентген кабинетларында эләгә торган нурлар да — барысы да исәпкә алына. Шушы микъдарның нибары йөздән дүрт миллибэры гына атом электр станцияләре эшчәнлеге аркасында тарала. Хәтта станциянең үз хезмәткәрләре, реакторга бик якын торып эшләгәннәре дә нурланышны кеше сәламәтлегенә куркыныч янарлык күләмнән 5—10 мәртәбә азрак кабул итәләр. Инде ышандыгызмы?

— Ярый инде...

— Юк, әле булмаган икән. Тагын бераз аңлатыйм. Беләсезме, гап-гади җылылык электр станцияләре атмосферага, атом электр станцияләренә караганда, йөзләрчә мәртәбә күбрәк радиация тараталар. Кеше рентген кабинетында, атом электр станциясе тәэсире белән чагыштырганда, меңнәрчә мәртәбә артыграк радиация ала. Бу, әлбәттә, рентген кабинетына керергә ярамый дигән сүз түгел. Ул кабинетларда уннарча еллар буена эшләүче врачлар бар. Мин бу сүзләрне АЭСлар эшчәнлегенең кешегә һич тә зарары юклыгын раслар өчен кабатлыйм.

— Бу станцияләрдә куркынычсызлыктан саклану чаралары нинди:рәк соң? — Мин тәмам тынычлану өчен тагын сорап калырга булдым.— Артык йомшак яки бик кырыс түгелме?

— Билгеле булганча, СССР сәламәтлек саклау министрлыгында радиациядән саклану буенча махсус комиссия эшли. Шул комиссия моннан биш еллар чамасы элек АЭСлар салу проектларына һәм алардан файдалану ысулларына яңа, тагын да кырысрак таләп-кагыйдәләр булдырды. Безнең әлеге АЭС шул яңа кагыйдәләргә дә буйсындырылып салына. Чернобыльдәге күңелсезлекләрдән соң исә бу таләпләр тагын да җитдиләнде. Кама Аланындагы төзелеш аларның барысына да җавап бирерлек иттереп алып барыла. Станция табигатькә дә, кешеләргә дә һичнинди дә куркыныч тудырмаячак. Бу юнәлештәге чыгымнарга дәүләт саранлык күрсәтми. Станция эшчәнлеген сынап карау өчен генә дә аерым, бик кыйммәтле объект салына. Тагын шуны да өстәргә кирәк саныйм: АЭСлар төзүгә китә торган чыгымнарның яртысы диярлек саклану чараларына тотыла, алар станция эшчәнлегендәге куркынычсызлыкны өч-дүрт мәртәбә тәэмин итәрлек дәрәҗәдә ясала...

Татарстан АЭСы турында аның директоры Л. Журавлевтан алынган мәгълүмат әңгәмәбезнең җанга ятышлы өлеше булды. Табигый ки, киләчәк турында күңел канатландыргыч сүзләр тыңлау һәрчак рәхәт. Биек ташпулатлардан корылган, әкияттәгедәй серле яңа шәһәрнең, кеше акылы ирешмәстәй көчкә ия станциянең пенопласт шакмаклардан ясалган макетына карап, бераз елмая төшеп, якты киләчәк турында хыялланып утыру ничек рәхәт булмасын инде?! Хәзерге Кама Аланындагы саздагы урамнарда батып утыручы машиналар өчен кайгырып торганчы, киләчәктә салыначак табадай шома асфальт юллар, дөньякүләм мактанырлык куәткә ия станцияне күзаллау, әлбәттә, күңеллерәк! Тик чынбарлыгыбыз киләчәктә булачак ләззәтле минутлар турында хыяллануны түгел, мәсьәләләрнең эшлекле төстә тәгәл хәл ителүен көтә.

Чынында исә бездәге бу төзелешкә беренче көненнән үк күңелсезлек арты күңелсезлек килеп кенә торды. «Камгэсэнергострой»ның төзүчеләр арасында «батя» кушаматы алган шәфкатьле начальнигы Евгений Никанорович Батенчук әйтмешли, станция «алдын артка әйләндереп» салына башлады. Ул, минем аптырап калуымны сизгәч, иплә6рәк аңлатты.

— Менә үзегез уйлап карагыз,— диде.— АЭСка кирәкле җир эшләрен без сиксән беренче елда башладык.— Батенчук бераз уйлап алды, аннары, рәттән тезеп китте.— Күз бәйләш уйнаган кебек, тоттык та тәвәккәлләдек. Портлар да салдык, вакытлы причал әмәлләдек, юл суздык. Хәзер ис китә: ничек батырчылык иткәнбез дим?! Теләсә нинди гаеп тагып, безне җавапка тарттырырга мөмкин иде. Ник дисәгез, станция салынырга тиешле мәйдан

бары тик 1982 елны гына бүлеп бирелде бит! Менә хикмәт нәрсәдә! Проект төрле канцелярияләрнең биек ташпулатларыннан җиргә бик озак төшә. Проектчылар документлаштыруның төрле бүлекләре буенча бер елдан өч елга кадәр соңга калалар...

КПССның XXVII съезды материалларыннан мәгълүм булганча, Татарстан АЭСы 1989 елны энергия бирә башларга тиеш. Вакыт тар. Хәзер төзүчеләрдән өчләтә тизлек сорала. Шунсыз планның үтәлүе мөмкин түгел. Никме? Чөнки реактор бүлеге урнашырга тиешле җирдә механизаторлар — скреперчылар, бульдозерчылар артык озак кайнашты. Төзүчеләр телендә әйтсәң, «нуль циклы»ның эше бетми торды. Узган елның декабрь урталарында орденлы бригадир Өмет Наурбиев егетләре бу урыннан беренче батман туфракны умырып алганнар иде. Ел узды. Реакторлар бүлегенең нигезенә куелырга тиешле плитәләрне түшәргә мөмкин. Димәк, 1986 ел шуның белән — вәссәлам! Атом электр станцияләрен салу тарихына карасаң, бер закончалыкны ачарга була: әлеге нигез түшәлгәннән алып энергия бирә башлаганчы төзелешкә берничә ел кирәк.

Шунлыктан Кама Аланындагы хәлләр турында, бик тырышсам да, гел күтәренке рухта гына сөйли алмыйм. Әйтергә генә ансат — мең алтынга сатып ала алмаслык ике еллап вакыт исраф ителгән!

Хәзер Е. Батенчукның аһ-ваһ килүләрен тыңлап, барын да проект төзүчеләрнең ваемсызлыгына сылтап, тынычланып утырыргамы инде? Мөмкин, әлбәттә. Проектлаучыларның гаебе зур. «Атомтеплоэлектропроект» институтының Рига бүлеге хезмәткәрләре ТатАЭС төзелешенә бу ел башына бирергә тиешле документациянең ун миллион сумлык хезмәткә кирәклесен тапшырып өлгертмәделәр. Биргән кадәресе дә төзүчеләрне канәгатьләндерерлек түгел. Проект килә, тик ул чираттагы эшкә кирәкле кәгазь булып чыкмый. Проект шундый нәрсә: аңардагы кечкенә генә төгәлсезлек тә төзелештәгеләрне ике-өч ай буе эшсез утырырга мәҗбүр итә. Аңлашылып җитмәгән деталь турында Ригага сорау китә. Тегеләр ризалашмый, телефон аша бәхәс куера, аннары берәүгә командировкага барырга туры килә. Төзелеш шуларның барын да көтеп утырырга мәҗбүр.

Ригалыларга әйтер усал сүзләр күп. Күңел җылысын кушыбрак иҗат итсәләр, бу чуалчык хәлләрне булдырмаска да мөмкин бит. Төзелеп ята торган АЭС дирекциясенең эшчән тәкъдиме дә бар: проектлаучыларның бик уңган, тулы хокуклы бер төркемен Кама Аланына китереп утыртырга! Аңлашылмаучылык чыктымы — бер-ике сәгать эчендә төзәтеп өлгертерлек булсын. Юк. Проектлаучыларга заман таләп иткән тизләнеш теләге барып җитмәгән әле. Ә менә заказчы белән төзүчеләр арасында эшлекле мөнәсәбәт туып килә. Соңгы вакытта гына оештырылган СССР атом энергетикасы министрлыгы бу төзелешкә нык таяныч булыр дип ышаныйк.

Әйткәнебезчә, мондагы заказчы — төзелә торган атом электр станциясенең дирекциясе, генеральный подрядчы исә «Камгэсэнергострой» берләшмәсе. Җитәкчеләре, алдан телгә алынганча, Лев Николаевич Журавлев белән Евгений Никанорович Батенчук. Бәхеткә, бу очракта заказчы да, эшне башкаручы да бер үк министрлыкка — СССРның энергетика министрлыгына карыйлар. Тик, кызганычка каршы, алар арасындагы мөнәсәбәтләр соңгы айларга кадәр әллә ни җылы түгел иде. Мин, моның сәбәбен аңларга теләп, бик озак күзәтеп йөрдем, төрлечә фикер итеп карадым. Һәм мондый нәтиҗәгә килдем: Татарстан АЭСын төзү мәйданында һәрьяктан бер-берсенә капма-каршы ысулларга таянучан җитәкчеләр очрашкан. Хәзер мин шул фикеремне расларга тырышып карыйм.

Сүзне, олылыгын, индустриябезне үстерүгә керткән күп хезмәтләрен хөрмәтләп, Социалистик Хезмәт Герое Евгений Батенчукны тасвирлаудан башлыйк. Кама буендагы шәһәрләрдә безнең «батя»ны белмәгән төзүче бар микән?! Аңа багышланган язмалар, китаплар гына да күпме! Аның турында фильмнар да төшерелде. Андагы көч-куәт, инженерлык осталыгы, оештыру сәләте булмаса, ай-һай, КамАЗыбыз шундый тар вакыт арасында салынып өлгерер иде микән?! Хәзер искә төшерүе дә куркыныч кебек: проект институты документацияләргә яңалыклар кертергә тотынды. Әмма алар кәгазь өемнәренә батып утырган арада, Батенчук мәсьәләне үзенчә хәл кылды. Бораулап кертелә торган субайлар булдырды да завод корпусын шуларга менгереп куйды. Зур тәвәккәллек иде бу. Мең төрле шикне, шикләнүчеләрне һәм сак эш итүчеләрне җиңәргә, ышандырырга кирәк иде. Ни булса ул, КамАЗ нәкъ менә Батенчук «аякларында» атлап китте.

Евгений Никаноровичның тәвәккәллеге АЭС төзелешендә дә сизелеп өлгерде инде. 30 квадрат километрлы сусаклагыч өчен, наратлыкны кисеп, мәйдан булдырылды. Проектлаучылар шушы киңлектәге меңнәрчә төпләрне тамыры-ние белән казып чыгарырга тәкъдим иттеләр. Шунсыз эшкә тотынырга ярамый иде. Батенчук исә биниһая күп вакытны, коточкыч көчне ала торган әлеге шөгыльне кирәкмәс мәшәкатькә саный. Ул төпләргә тимәскә, ә туфрак суырткычлар ярдәмендә, булачак диңгезнең төбен күтәртергә боера. Бу алым ун миллион сумны янга калдыра. Евгений Никаноровичның икенче фикеренә таянып, чокыр казылырга тиешле мәйданга техниканы тизрәк кертү өчен, хәтта бер елганың агышын да кирегә боралар.

Эштә турыдан-туры ярдәм итү өчен, ул бөтен җирдә үзе булырга, барын да үз күзләре белән күрергә тырыша. Мәсьәләне урынында хәл итү ягында ул. Мин аның прораблар будкасында килеш, вакытлыча үткәрелгән телефоннар аша Мәскәү белән сөйләшеп азапланганын, андагы кешеләрне ышандырганын, нидер таләп иткәнен күргәнем бар.

Берсендә:

— Барын да үзегез хәл итеп йөргәч, урынбасарларыгыз ни эшли соң сезнең? — дип сорадым.— Мөстәкыйльлекләренә хилафлык килмиме? Барын да сез булдырып биргәч, аларның теләге сүнеп куюы да ихтимал.

— Катнашуым эшне тизләтә, җиңеләйтә икән, мин кемнеңдер кыймылдавын көтеп утыра алмыйм! — Батенчук елмайды.— Янып-көеп йөрүче кешегә үз вазифасы гына һәрчак аз тоела...

Ярар, күпмеңле төзүчеләр коллективының мәшәкатьләре үзәгендә кайнаучы, ару-талуны белмәс Евгений Никанорович турында әйтелгәннәрнең шул кадәресе җитеп торыр. Инде булачак АЭСның директоры Лев Николаевич Журавлев эшчәнлегенә күз салыйк. Баштан ук әйтеп куям: ул — югары класслы белгеч, атом-төш физикасын һәм теоретик, һәм практик яктан су кебек эчә. Утыз елдан артык шул фән белән мәшгуль. Ленинградта укыган, Кола атом электр станциясендә эшләгән, атом-төш институтында укыткан, чит илләрдәге физикларга консультацияләр биргән. Кыскасы, әле оешып кына килә торган, хәзергә әллә ни зур булмаган коллективның җитәкчесе үз эшен шәп белә. Бик төгәл. Башкалардан да шуны таләп итә. Шапшаклыкны, вәгъдәсезлекне, буш сүзне кичерми. Кайчак, артык дәрәҗәдә тәкәллефләнеп китүен күреп, аны вакчыл дип тә уйларга мөмкин. Хәтеремдә: кайсыдыр бина салына торган урыннан бергәләп үткән идек. Әле нигезен генә түшиләр. Нәрсә икәнен дә белерлек түгел.

— Кара инде, ә?! — Журавлев ихлас күңелдән борчылырга тотынды.— Шунда бер такта кадаклап, ни эшләгәннәрен язып кую авыр микәнни соң боларга? Тәрбиясезлек бит бу! Һаман да культуралы иттереп эшләргә өйрәтә алмыйбыз.

Ул төзүчеләр хезмәтен оештырудагы төгәлсезлекләрне дә, проектлаучыларның урамнарны тарайтырга тырышуларын да ошатмый. Культура яки көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын, өйләрне салуда кысылып-пысылып маташуларны һич өнәми.

Башкарылган эштән канәгать булып бетмәү, гел кимчелекләр күреп йөрү — җитәкчегә кирәкле сыйфатмы? Әлбәттә. Тик әлеге ике җитәкченең канәгатьсезлеге чынбарлыкта төрлечә чагыла. Батенчук, күргәнебезчә, җиң сызганып, шул кимчелекне бетерү чарасын табарга тырыша башлый. Журавлев исә, эшкә аяк чалучыны белеп алса, кабинетына кереп утыра да... күңелендәген кәгазьгә төшерә башлый. Кулымда — аның дәгъвачыл язмалары. Алар министрга, КПССның Татарстан өлкә комитетына, КПССның шәһәр һәм район комитетларына, проект институтына — барын да санап чыгу мөмкин түгел. Хатларның эчтәлеге бер үк: «Төзелеш аксый. Коткарыгыз!»

Бата башлаган корабта да шулай — иң әүвәл чаң кагалар. Тик анда читтән ярдәм килгәнне көтеп утыру гадәте юк. Чаңны кага торалар, үзләре күңелсезлекне бетерү чарасына керешәләр. Лев Николаевич 1983 елдан бирле бик хаклы рәвештә: «Генеральный подрядчыбыз «Камгэсэнергострой» бөтен планнарны өзә,— дип аһ ора.— Төзүчеләр мондый темплар белән эшләсә, станция 1989 елда түгел, хәтта бишьеллык ахырына да сафка баса алмаячак».

Ихтыярсыздан: «Лев Николаевич, сезнең үзегездә дә гаеп юкмы соң?» — дип сорыйсы килә. Башта бу сорауга һәрчак кире җавап биреп тордылар. Янәсе, заказчы оешма, ягъни АЭС дирекциясе, төзелешне һич тә тоткарламый. Шулай да бервакыт тикшереп карарга булганнар. Тикшерүче комиссия

мондый нәтиҗәгә килгән: «АЭС төзелешенең тоткарлануына проект-смета документларының вакытында бирелмәве сәбәп булып тора. Заказчы проектларны һәрвакыт соңга калдырып тапшыра. Тоткарлаулар бер елга, хәтта аннан да озагракка сузыла»...

Күрдегезме: Кама Аланы төзелешенең акрын баруында заказчының да гаебе юк түгел икән. Димәк, эшнең алга таба тизрәк атлавы хакында бергәләп кайгыртырга кирәк булган. Кызганычка каршы, без, кадерле вакыт җилгә очып киткәч кенә, чын дөреслекне аңлап алганбыз. Бу — мәсьәләгә искечә карау нәтиҗәсе. Яңа төр төзелешкә беренче көннән үк бөтенләй башкача мөнәсәбәт кирәк булган.

Әмма «Камгэсэнергострой» кешеләренең беренче адымнарын күздән кичерсәң, нәкъ әнә шушы үткәндәге ысуллар искә төшә. Төзүчеләр, Кама Аланына беренче аяк басканда эшкә ифрат дәрәҗәдә дәртләнеп тотындылар. Евгений Никанорович халык алдында хәтта: «Беренче реакторны 1987 елда сафка бастырачакбыз!» — дип тә ычкындыра. Моңарчы зур-зур эшләрне башкарып чыккан шундый абруйлы кешегә ышанмаска урын да юк иде. Алар кулы белән салынган КамАЗ гөрләттереп эшли, мәһабәт шәһәрләр күз алдында, Түбән Кама ГЭСы балкып утыра. Атом станциясен дә күз ачып йомганчы салып куюларына нигә шикләнергә?!

Әмма шау-гөр килеп башланган беренче адымнар салмакланып калды. «Камгэсэнергострой» җитәкчеләренең яңа төзелешкә булган дәрте дә сүлпәнәйде. Берләшмә ел буе башкара торган 350 миллион сумлык хезмәтнең нибары 46 миллионлыгы гына АЭС төзелешенә кертелде. Кама Аланына бүленгән материаль-техник байлык та бик чамалы. Әйтик, үткән елда бу мөһим төзелешкә бирелергә тиешле алты мең тонна металл-прокатның бары яртысы гына Кама Аланына килеп ирешт. Калганын башка төзелешләргә таратып бетергәннәр. Шундый ук мөнәсәбәт төзелеш материалларын гына түгел, җир казучы һәм башка төр машиналар бүлүдә дә сизелә. Эш хәтта шуңа барып җиткән ки, һәркем АЭСка җибәрелгән мөмкинлекләрдән үзенә зуррак файда умырып калырга тырыша башлаган. Мәсәлән, Кама Аланындагы 12 нче йортның идәненә Брежнев шәһәре йортлары өчен яраксыз саналган линолеум җәйгәннәр.

Төзелешне тизләтү буенча кичекмәс чаралар күрәсе урында төзелеш җитәкчеләре бер-бер артлы вәгъдәләр яудырдылар, купшы сүзләр артына постылар. Җанга рәхәт вәгъдәләр көндәлек аңгәмәләрдә дә, атна саен була торган утырышларда да, айга бер үтүчән җыелышларда да, квартал азагындагы киңәшмәләрдә дә яңгырап кына торды. Беркетмәләрне алып карасаң, беренче реактор куелырга тиешле чокырның нигезе үткән елның июнендә үк түшәлгән булырга тиеш иде инде.

Заказчы белән төзүче арасындагы низагларны тикшерүгә кайтып калган ул бичара беркетмәләр эшкә этәргеч буламы соң? Алардагы йомгаклау сүзләренең күбесе: «...эшне канәгатьләнмәслек дип билгеләргә!», «...игътибарны юнәлтергә!», «...искә алырга!» кебек гомуми күрсәтмәләрдән гыйбарәт.

Һәм, гаҗәпкә каршы, төзелешнең шул тын агымына изләнеп тә җитәләр. Әпен-төпен эшләп узган дүрт ел (!) эчендә АЭС директоры Л. Журавлевның министр тарафыннан нибары бер тапкыр шелтә алуы, ә Е. Батенчукның гомумән берничә усал сүз дә ишетмәве шуны раслый. Аңа карата җиңелчә генә әйтелгән «кисәтергә!», «күрсәтергә!», «җитди рәвештә таләп итәргә!» әйләнмәләре еракта яңгыраган күк күкрәве авазларын гына хәтерләтә.

Евгений Никаноровичны тыңлап торсаң, аңардагы ышанычлы йомгаклау сүзләренә, кабаланмый гына аңлату ысулларына гаҗәпләнми мөмкин түгел. Ул хәтта коточкыч четерекле хәлен аңлатканда да чыгышын шул хәтле оста очлый белә ки, алкышлап кул чаба башлавыңны сизми дә каласың. Вәгъдәләргә ул ифрат юмарт.

Эшкә килгәндә исә хәл алкышлардан ерак тора. «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең хөртиләнә башлавы 1982 елга ук тоташкан. Төзелеш программасын үтәмәү ул чакта ук 100 миллион сумлык булды. Салынмый калган ун мең квартира дигән сүз бу! Җитәкчеләр яңа ысуллар, төзелешне индустрияләштерү турында фәлсәфә куерта тордылар, эш артка тәгәри барды. Унберенче бишьеллыкта, унынчысы белән чагыштырганда, төзелешнең механизмнар һәм энергия белән тәэмин ителүе 20 процентка кимегән. Хезмәт җитештерүчәнлеге элекке дәрәҗәсендә калган. Бу күрсәткеч буенча «Камгэсэнергострой» министрлыктагы башка коллективлар арасында иң артта бара.

Кама Аланындагы бер генә төзүчедән дә юньле сүз ишетә алмыйсың: бар да тәэминатчыларны каһәрли. Кирәкле материалны көтеп утыра-утыра, аларның кадерле вакытлары әрәмгә уза. Үткән ел шул сәбәп аркасында эш сәгатьләренең өч проценты исраф ителгән.

Татарстан АЭСын салучылар яңа бишьеллыкка әнә шундый ифрат күңелсез күрсәткечләр белән килеп керделәр. Әгәр КПССның XXVII съездында хезмәт коллективларындагы шушындый ысулларга чик кую турында кискен әйтелмәсә, Татарстан АЭСындагы хәлләр һаман шулай барыр иде, мөгаен. Бәхеткә каршы, съезд кимчелекләргә күз йоммаска, четерекле социаль һәм хуҗалык мәсьәләләрен кабыргасы белән куярга чакырды. Илдә ярыш, борылыш чоры башланды. Һәркемнән акны — ак, караны кара дип әйтү таләп ителә хәзер.

Кама Аланындагы төзелештә дә съезд карарларында күрсәтелгән кискен борылыш рухы сизелә башлады. Бу юнәлештә, минемчә, КПССның Татарстан өлкә комитетында XXVII съезддан соң ук уздырылган бюро утырышы беренче рольне уйнады. Утырышка Татарстан АЭСы төзелешенең бөтен җаваплы кешеләре чакырылган иде. «Атомтеплоэлектропроект» институтының Рига бүлеге директоры В. Халявский да килде.

Шактый озакка сузылган утырышта моңарчы гел мактау-хуплау сүзләре генә ишетергә өйрәнеп, тәнкыйтьтән читтә кала килүче җитәкчеләрдән дә эшлекле җаваплар таләп иттеләр. Хәтта республика төзүчеләренә һәрчак үрнәк төсендә йөртелгән «Камгэсэнергостройның» да маяк булудан тукталганлыгы фаш ителде. Маякның яктырмый башлавына да берничә ел үткән икән ләбаса! Мөхтәрәм Евгений Никаноровичны да бу юлы күпшы сүзләр күтәрып кала торган түгел иде. Барысыннан да бары тик эш, төп-төгәл үтәлә торган эш таләп ителде.

Батенчук агай тәмам пошаманга төште.

— Әгәр материаллар вакытында килсә...

— Юк инде, хөрмәтлебез! — диделәр аңа.— АЭС турында сөйләгәндә, «әгәр-мәгәр»ләрдән башка гына аңлашыйк! КамАЗны корганда, сез үзегез дә һичнинди шартлар куеп тормый идегез. Кирәк чакта җиде төн уртасында кешеләрне күтәрдегез, үзегез дә тәүлек әйләнәсе төзелештә ята идегез. Һәркем — «Кирәк икән, димәк, кирәк!» дигән хакыйкатькә буйсындырылган иде. Тәүлегенә миллион сумлык эш башкарган чаклар булды.

Хәзер Евгений Никаноровичта көрәш рухы сүнгән, ул сүлпәнләнебрәк калган шикелле. Хәер, еллар буе мактау сүзләре генә ишетеп торгач, сүлпәнләнерсең дә. Әйткәләп торсыннар иде аны: «Карале, начар эшлисең бит син!» — дип, күзеңә бәреп әйтсеннәр иде. Юк шул, хак сүзне ишетмәде ул. Хатасын төзәтү җиңелрәк булыр иде. Хәзер менә...

Озын өстәл янына җыелып утырган кешеләр, әйтерсең лә җиде ят затлар, шактый кыен хәлдә калдылар. Батенчукка хас сыйфатлар — еллар буе юшкын булып утырган мин-минлек чире, җиңел генә җиңү мөмкинлегенә ышану, биргән вәгъдә алдында җаваплылык тоймау — бары да берәмберәм калкып чыкты, фаш булды, тәнкыйть ителде. «Батя»ны бу хәлендә күрү сәер иде: башы иелгән, җиңелчә калтыранган бармаклары әйбәт иттереп язылган чыгыш битләрен кыштырдата. Монда алдан әзерләнгән чыгышның һич кирәге чыкмады, чөнки Батенчукка җитди сораулар бирелде, дөп-дөрес җавап таләп ителде.

— Инде эшне нидән башларсыз?

— Без планлаштырган яңа чаралар, якынча, өч йөз эш көнен янга калдырырга мөмкинлек бирәчәк.— Батенчукның тавышын танырлык түгел. Ул калтыранган кулларына нинди дер схема сызылган кәгазьләр алды.— Инженерлар уенча...

— Дәүләт планы өзелсә, бу кәгазь генә ярдәм итмәячәк! — диделәр аңа.— Моңарчы да күрсәткәләдегез сез андый схемаларны.

— АЭС өчен бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам!

Җитәкченең бу сүзләре тирәннән уйлап әйтелгәнгә охшый иде. Евгений Никанорович аңгәмәнең җитдилегенә, ялтыравык вәгъдәләр белән генә эллә кая китеп булмасына инанган иде инде.

«Атомтеплоэлектропроект» институтының Рига бүлеге директоры В. Халявский исә утырыш агымын тоеп өлгермәгән иде ахырысы — кыен хәлдә калды. Ул институтның бик шәп план буенча эшләвен тасвирларга тотынды.

— Алай булгач, ни өчен Татарстан АЭСына кирәкле документларны һәрвакыт соңарып бирәсез? — дип сорадылар.

— Димәк, шулай кирәк! — Халявский тәкәбберләнеп маташты.

Утырыштагыларның ачуы йөзләренә чыкты. Председательлек итүченең дә тавышы кырысланды:

— Кичерәсез! — диде ул.— Безгә алай кирәкми шул! Без институт эшендә кискен борылыш ясалуны таләп итәбез! Төзүчеләр сезнең эштәге акрынлыкка түгел, ә сез төзелешнең кызу темпына җайлашырга тиешсез! Шушы кискен борылышны аңлый аласызмы?

Ерактан килгән кунакны ничек «пешерү»нең калган ваклыкларына тукталмасак та ярар. Әмма сөйләшүнең нәтиҗәсе хәзер үк сизелә. Институт вәкилләре Кама Аланына йөрүне ешайттылар. Проектчылар белән төзүчеләр күзгә-күз очраша башладылар. Төзелешкә беренче чиратта ни кирәгеен үз күзләре белән күргәч, эштә тоткарлык кими төште. Элек курьерлар аша гына йөртелгән кәгазьләр агымы да азайды. Проектлаучыларның махсус төркеме хәзер төзелешнең үзендә торып эшли: андый-мондый төзәтү кирәк булса, ерактан рөхсәт килгәнне көтеп, вакыт әрәм итүләр бетте.

Заманыбыз һәр урында нәкъ менә шундый эшлекле борылышлар көтә.

КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросының әле телгә алынган утырышы алдыннан гына миңа Л. Журавлевтан хат килде. «...Татарстан АЭСының эшләре харап. Шулай да аны коткарырга мөмкин әле. Тик моңа гомуми тырышлык һәм гадәттән тыш чаралар күрү кирәк»,— дип язган иде ул.

Бу сизгер күңелле, барына да аек акыл һәм тәнкыйть күзе белән караучан җитәкченең дәгъва төсендә язылган соңгы хаты булды. Бюро утырышы аның да моңа кадәрге алымнарын үзгәртебрәк җибәрде шикелле. Ул әлеге утырышта аңа тиеш тә булмаган өстәмә җаваплылык алды. Аңардагы фикер борылышы утырыш агымында булды кебек. Уйлап кына карагыз: бюро карарының проектында Кама Аланы белән Зәй арасында 1987 елның беренче яртысында яңа юл тармагы салынырга тиеш дип теркәлгән иде. Бу арада җир асты коммуникацияләре күп. Алтмышлап урында торбалар, кабельләр челтәрен кисеп үтәргә туры килә. АЭС дирекциясе әнә шул коммуникацияләрнең хуҗалары белән уртак тел табарга тиеш. Авыр эш бу. Ризалыгы алынырга дигән оешмалар Кама Аланыннан еракта: кайсы Казанга, кайберләре Мәскәүгә үк урнашкан. Ризалаштыруы да җиңел түгел, сүзне бик оста алып бара белергә кирәк. Журавлевның шелтәсе дә нәкъ шуңа охшаш эштәге уңышсызлык өчен иде. Бу юлы исә Лев Николаевич, бюро карары расланыр алдыннан гына, урыныннан торып басты:

— Зәй белән ике арадагы яңа юлны өлгертү вакытын үзгәртергә кирәк саныйм,— диде ул.— Ул безгә быел ук кирәк! Үзем алынам.

Сүзенең ышанычлылыгын раслар өчен, нинди мөмкинлекләргә таяначагын да әйтте. Карар проектына төзәтү керттеләр.

Лев Николаевич утырыштан соң да җитәкчелек алымына яңалык кертүгә йөз тотканлыгын кат-кат күрсәтте. Үзе башлап йөрергә, һәр сүзне эштә расларга тотынды ул. Хәзер ул проектларның вакытында тапшырылуы белән генә дә канәгатьләнеп калмый. Проект бүгенге көндә түгел, киләчәккә карап төзелергә тиеш дип таләп итә. Кама Аланындагы өйләрнең бер-берсеннән читтәрәк салынуына, ишегалларының иркенлегенә басым ясый. Шәһәрдәге җирнең тоташкан асфальт белән каплануына да каршы чыкты ул. Өйләр янында гөл түтәлләре, җиләк-җимеш агачлары үсәргә тиеш дип аваз салды. АЭСны төзүчеләргә һәм электр станциясендә эшләүчеләргә һаваның кислородка баерак булуы кирәк. Журавлев бу фикерен республиканың санитария хезмәтләре оешмасына да җиткерде һәм яклау тапты. Хәзер Кама Аланы кешеләренең һәрберсенә, элекке проекттагыча, 4 квадрат метр түгел, 7 квадрат метр яшел мәйдан туры килә. Балалар бакчаларына, мәктәпләргә дә өстәмә мәйданнар булдырылды. Күпкатлы йортларның иң өстәге балконнарына түбә ясауны проектлауга тәкъдим кертте. Кыскасы, Л. Журавлев яңа шәһәрдәге рәхәт тормышны киләчәктән көтеп торганчы, бүгеннән үк булдыра башларга чакырды һәм һәр эштә шул максатны алга сөрә.

Яңа йортлардагы тормыш та Лев Николаевич тәкъдиме буенча үзгәртеп көйләнә. Торакларга күз-колак булуны гаиләләргә тапшыру алымына гына тукталыйк. Әйтик, өйдәге бер гаилә бөтен йорт өчен җаваплылыкны үз өстенә ала: электр, су, чисталык, төзеклек — бөтенесе өчен алар кайгырта. Хатыны, мәсәлән, баскычларның чисталыгын караса, ире өй эчендәге торбаларныңфәләннәрнең, тәрәзә-ишекләрнең, электр челтәренең төзеклеген тәэмин итә, урам себерә. Бу эшкә алынган кеше, әлбәттә, һәр яктан оста булырга тиеш: краннарны да төзәтә белә, чатнаган пыяланы да алмаштыра, ишекләрнең

биген дә чамалый. Өйдә яшәүчеләр, үтенечләрен язып, билгеле бер әрҗәгә хат кисәге генә салалар. Гадәттәгечә, йортлар идарәсенең сантехникларына, электрикларына айлар буе инәлеп, вакыт әрәм итмиләр.

Мин Кама Аланының тугыз катлы ике йортында булдым. Берсен — Гыйззәтуллиннар, икенчесен Чебурахтиннар гаиләсе карый. Әлеге яңалык кертелгәнгә елдан артык вакыт үткән. Димәк, нинди дер нәтиҗә ясарга да мөмкин. Нәтиҗә — искиткеч. Бөтен кеше рәхмәт укый. Йортлар идарәсенә караган өйләрдән аһ-зар ява. Йортларның чисталыгын, төзеклеген чагыштырсаң да — җир белән күк арасы кадәр аерма.

Дөрес, мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әйтик, йортлар идарәсенең җыештыручылары айга сиксән сум чамасы ала, гаиләсе белән йорт караучыларның һәрберсенә икешәр мәртәбә артыграк түләнә. Финансистлар белән шактый көрәшергә туры килә. Лев Николаевичның тәкъдиме исә барыбер игътибарга лаек. Эш сөймәгән арзанлы слесарьлар тотканчы, өйләрне кадерләп саклаучы хезмәткәргә артык акча түләү барыбер отышлырак.

Лев Николаевичка хас омтылыш хәзер яңа шәһәрнең башка кешеләренә дә «йога» бара. Казан химия-технология институтын тәмамлап, егерме елдан артык илнең атом электр станцияләрендә эшләгән Әрхәметдин Бәдертдинов — шундыйларның берсе. Кукмарада туып үскән. Татарстанда да атом энергетикасына нигез сала башлауларын ишетеп, туган якка төпләнеп калу өчен, Кама Аланына кайткан. Станция өчен белгечләр әзерли. Үзе баш инженер урынбасары вазифасына җигелмәкче.

— Ул килеп керсә, өстәл сәгатемне каплап ук куям.— Журавлев аның турында сөйләгәндә, елмаеп кына утыра.— Белеп торам: башына берәр кызыклы фикер кермәсә, минем яныма килми дә ул.

Бәдертдинов кебек энтузиастларның янып-көеп йөрүе нәтиҗәсендә Кама Аланы үзенә генә хас матурлыкка ия шәһәргә әйләнеп бара. Беренче карашка гаҗәеп сәер йорт янында тукталып:

— Музеймы әллә? — дип сорадым.

— Мунча ул безнең! — Журавлев көлеп куйды.— Бөтен җирдә бертөрлелек туйдырган иде. Менә шундый мунча салырга булдык.

Шәһәр өчен уңайлыклар уйлап, инде халык арасында исеме дә таралып өлгергәннәрдән балалар врачы Сергей Викторович Попковны да атарга мөмкин. Балалар консультациясе бинасын бизәүне, аңарда йөзү бассейны булдыруны да Попков башлап йөргән.

— Сабыйларны йөзәргә өйрәтеп азаплауның нигә хаҗәте бар? — дим.

— Сәламәтлекне саклау өчен.— Попков кинәттән җитдиләнде.— Сабый чактан ук йөзә белүче балалар, бассейн күрмәгәннәргә караганда, ике-өч тапкыр сирәк авырый...

Инде КПССның Татарстан өлкә комитетындагы утырыштан соң «Камгэсэнергострой» кешеләренең хезмәтендәге үзгәрешләргә дә күз салыйк. Дөрес, монда да ныклы эзгә төштеләр дип ук әйтеп булмый булуын. Әле анда, әле монда эздән чыккалаучылар очрап тора. Әмма КамАЗны салгандагы кебек көрәшчән һәм җиңүчән рух ныгый бара. Хәзер төзүчеләрне: «Кирәк икән, димәк, кирәк!» дигән омтылыш биләп алган.

Татарстан АЭСы төзелешендәге борылыш та, тизләнеш тә сыйфат өчен көрәш белән тыгыз бәйле. Бу эштәге кечкенә генә ваемсызлык та ил өстенә кара кайгы китерүе ихтимал. Чернобыль вакыйгасы мәңге кабатланмасын өчен «Камгэсэнергострой» кешеләре бөтен көчләрен куялар. Әпен-төпен эшләүләр, ашыгу-кабаланулар монда җинаятьтән саналырга тиеш. Брак җибәрүчеләр хәзер премиядән колак кагып кына котыла алмыйлар. Эш прокуратурага ук барып җитә. Кайберәүләр мәсьәләнең болай ук җитдиләнеп китүенә риза да түгелләр:

— Нәрсә булган ул кадәр!? — диләр. Әле бит һәлакәт юк, ник шул хәтле аһ орырга?

Чыннан да брак — һәлакәт үк түгел. Тагын бераз чыгым тотып, төзәтеп тә куйсаң, эзе дә калмый. Әмма бүгенге эштәге кечкенә генә саксызлык та киләчәктә зур күңелсезлеккә китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә, социалистик гуманизм төшенчәсен ялгыш аңлап, төзелештә ваемсызлыкка юл куючыларга җәзаның иң катысы бирелергә тиеш. Кама Аланында моны тирәннән аңлый башладылар.

«Башладылар» сүзен төгәл аңлау кирәк. КПССның XXVII съездыннан соң «борылыш», «үзгәреш», «тизләнеш» кебек сүзләр яңа бер мәгънә алдылар. Без яңача яшәү, хезмәткә дә яңача карау өчен көрәш ачтык. Озакка

сузылачак, бик кирәкле көрәш бу. Тик бу юлда әлеге төшенчәләрнең купшы модага әйләнеп китүеннән сакланырга кирәк. Кешеләрнең аңындагы, фикер йөртүендәге борылышка ирешү тиз генә була алмый. Ашыгу-кабалану яңа ялгышларга, формализмга китерүе ихтимал. Яңа белән иске, буш сүз белән ышанычлы вәгъдә арасында көрәш бара.

Алда әйткәнемчә, Кама Аланындагы эшләр һәр төзелешкә хас кимчелекләрне кичерде: заказчы белән төзүче арасындагы низаглар, язып өркетүче җитәкче белән вәгъдәсез кешенең каршылыклары, олы мәсьәләләргә җиңел карау — бары да булды. Әле дә яман хәлләр бетте дип ышанып әйтергә ярамас. Әмма юнәлеш яхшы якка таба юл яра.

...Соңгы тапкыр очрашканда Лев Николаевич Журавлев бер хат укытты. Аны бик зур оешмага язганнар. Имзасыз хат. Билгесез кеше: «...Журавлев булачак АЭСка кадрларны дөрес җыймый,— дип зарлана.— Мәсәлән, төп һөнәре биолог булган А. Русанова химия цехына начальник итеп билгеләнәчәк. Нәрсә, атом станциясендә балык үрчетмәкче булалар микән әллә?..»

Әй, ачуы кабарган Журавлевның!

— Русанованың атом энергетикасын үстерүгә караган фәнни хезмәтләре бар. Шуны да белмәгән бит бу адәм актыгы! — ди.— Керсен иде үз яныма, аңлатып биргән булыр идем.

— Хат иясен белсәң, тотып алып ачуланыр идеңме, Лев Николаевич?

— Дөрес сүз язса, ул кадәр авыр булмас иде. Яла ягу бит бу.

— Димәк, эштәге хәлләрне коллективтагы кешеләргә хәбәр иткәләп торырга кирәк. Яшертен-пошыртын эшләүләргә юл калдырмагыз.

— Анысы да бар шул.

Лев Николаевич бераз тынычлана төшкән иде инде, кинәт кычкырып җибәрде:

— Белдем! Анонимканы кем язганны белдем!

— Инде бәйләнеп интектерәчәксезме?

— Әллә рәхмәт әйтимме?

— Анысын карарсыз, минем сезне аңлап бетерәсем килә иде, шуңа гына сорыйм.

— Беләсезме, бу — беренче анонимка. Элегрәк мондый нәрсә була алмый да иде, чөнки мин таләпчән түгел идем. Хәзер кырыслана барам. Кайберәүләргә ошамый. Әле күптән түгел гомуми эшкә аяк чалганы өчен берәүне эштән чыгарырга туры килде — хатны шул язган...

Калганын сорап тормадым. Киңәшнең аңа кирәге юк. Журавлев яңача эшләүгә шактый кыю тотынган. Үзгәрешнең җитәкчелектән башланырга тиешлеген дә, нинди булырга кирәклеген дә аңлаган иде ул. Татарстан АЭСы төзелешендә хәзер бөтен ил күләмендә баш калкыткан яңалык, үзгәреш, мәсьәләләрне башкача хәл итү юл яра. Җиңел түгел. Бәрелешләр аша. Каршылыклар төзелеш мәйданында гына түгел, һәр кешенең үзендә дә җитәрлек. Димәк, яңага борылыш һәр кешедә дә көрәш аша бара. Атом электр станциясе үз вакытында балкып кабына икән, бу зур төзелешнең җиңүе белән бергә кешеләр күңелендәге күркәм сыйфатларның да тантанасы булачак.

**О. С. Мөхетдинов,**
КПССның Азнакай райкомы беренче секретаре

# ЧАТЫР-ТАУГА ЧАЛ КУНМЫЙ

Бу якларның матурлыгын тояр өчен безгә арышлар серкә очырганда, бодайлар башак кысканда, карабодай чәчәк атканда килегез. Килегез дә Ык буйларында, Мәллә суы үзәннәрендә, Чатыр тавы итәкләрендә йөрегез. Туачак иртәгезне, бер генә тапкыр булса да, девон хәзинәләренә юл ячучы буровойларда каршылагыз, нефть коеларының сиртмәләренә күз салыгыз. Югары көчәнешле электр чыбыкларының таң җилләре белән салмак кына серләшкәнен тыңлап торыгыз...

Азнакайлылар керосинны сукыр лампага да үлчәп кенә тоткан чакларда шушындый якты таңнар турында хыяллана алдылармы икән? Ансыз булмагандыр, әлбәттә. Кеше күңеле һәрчак яхшыны өмет итә. Ләкин барыбер мондый могҗизаны күз алларына китерә алмаганнардыр. Район бит үзе нефть дәрьясы өстендә утырган.

Колхозлашу елларында биредә 80 нән артык авыл исәпләнгән. Аларның да байтагы — 8—15 йортлы вак хуторлар, Столыпин реформасы җимешләре. Хәзерге авылларыбызга «авыл» атамасы бик үк туры килеп тә бетми кебек. Кайбер авылларда яшәүчеләрнең шактый өлеше — нефтьчеләр. Һөнәрләре төрле булса да, кешеләр үзара ярдәмләшеп, хәтта ярышып эшлиләр. Промышленность предприятиеләре авылларны шефка алган, ә колхоз-совхозлар аларга шулай ук кулдан килгән теләсә нинди ярдәмне күрсәтергә әзер. Кыскасы, шәһәр белән авыл монда янәшә, алар — ут күршеләр хәзер.

Революциягә кадәр бу якларда татарлардан эре җир биләүче һәм сәүдәгәр, патша Думасы члены Мингаза, көтү-көтү елкы һәм башка терлек асраган, тире эшкәртү, май ясау корылмалары һәм Мәкәрҗә ярминкәсендә сәүдә үзәкләре тоткан Җамали кебек алпавытлар да яшәгән. Кәкре Елга, Әлкәй һәм башка авыллардагы ярлы-ябагай түккән тир, күз яшьләре шулар кесәсенә алтын булып агылган. Хәзер авыл халкының материаль хәле Мингаза һәм Җамали кебек байларныкыннан һич тә кайтыш түгел. Рухи байлык, культура, аң-белем хәзинәсе турында әйткән дә юк — алары бу байларның төшенә дә кермәгән. Без хәзер материаль байлыклар турында да ныклап сөйләшә алабыз. Авылларга карагыз: һәркайда кимендә ике-өч бүлмәле, матурлап-бизәп салынган йортлар, буяп-сырлап ясалган капкалар, калай яки шифер белән ябылган терлек каралтылары. Байтагының хуҗалыгында гаражлар, димәк, автомашинасы яки мотоциклы бар. Һәр йортта телевизор, радио, суыткыч, электр, газ. Суы да өйгә кертелгән. Әле шушы кешеләрнең тырышлыгы белән барлыкка китерелгән колхоз-совхоз байлыгы күпме! Бусына инде Җамалиларның гына түгел, бәлки үзләре Петербургта яшәп, бу якларда 15 әр мең дисәтинә җир биләгән Елачич, Гиллен кебек помещикларның да буйлары җитәрлек түгел.

Социалистик революция башлангач, Җамали абзый, «ахыр заман җитте, мондагыларны җир йотар», дип, илдән чыгып качкан. Җир исә безне йотарга һич тә җыенмый. Киресенчә, бөтен байлыкларын бик юмарт рәвештә үзенең чын хуҗаларына кайтарып бирә тора. Аңа кадер-хөрмәт күрсәтергә, аның белән сакчыл һәм белеп эш итәргә генә иренмә. Ә «заман» мәсьәләсенә килгәндә, ул чынлап та алпавытлар өчен «ахыр» булды — яңа заман, яңа эра башланды.

* * *

Чатыр тавы — безнең як табигатенең йөзек кашы. Диңгез өсте тигезлегеннән 334 метрга күтәрелгән дә, әйтерсең лә, бөтен тирә-юньне үз күзәтчелегенә алган.

Аннан караганда күренә торган асфальт юл уйларны тарих тирәнлегенә, моннан 3500 еллар элек булган заманнарга илтә. Археологик табылдыклар, шул исәптән, Азнакайның үзендә 1979 елның җәендә бәрәңге базы казыганда килеп чыккан каберлек һәм андагы чүлмәк китекләре, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы галимнәре фикеренчә, бронза эрасының бура (кабер эчен буралап ясау) культурасы чорына туры килә. Димәк, бик борынгыдан ук инде кешеләр биредә үзләренә яшәү һәм сыену урыны тапканнар.

Бу төбәктәге авылларга башлыча XIII һәм XVIII гасырлар арасында нигез салынган.

Ягыбызның үткәне Россия хезмәт ияләренең азатлык өчен көрәш тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән. Районыбызда Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар хәрәкәтенә кагылышлы истәлекле урыннар — байтак. Карамалы авылындагы Җәмәлҗән (Емельян) куаклыгы — шуларның берсе. Биредә патша гаскәрләре белән восстаниечеләр арасында канлы бәрелешләр булган. Чатыр тавындагы, бакыр чыгару өчен казылган, элекке чокырларда әле безнең көннәрдә дә шул вакыйгаларның шаһиты булган уклар, кылыч һәм сөңге сыныклары табыла. Аю тавы да халык тарафыннан Чатыр тавы (Пугачев сугышчылары монда, чатырлар корып, берничә тәүлек торган) итеп үзгәртелә, ә шушында агып яткан чишмә «изгеләр чишмәсе»нә әйләнеп китә.

Безнең районга кергән Павловка, Микулино, Владимировка, Чемодурово кебек рус авылларының күбесе патша самодержавиесе тарафыннан җирне, урман-суларны эре помещикларга бүлеп бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Ләкин бу төбәкнең тарихын килмешәк боярлар түгел, ә халык үзе, аның чын уллары иҗат иткән. Чемодуроводагы земский мәктәп укытучысы, 1905—1907 еллардагы революцион вакыйгаларда кайнаган В. П. Городецкий, Әлкәй волость суды члены, татарлар арасында «иң дөрес кеше» дип аты чыккан Д. П. Павлов кебекләрнең исемнәре әле хәзер дә зур хөрмәт белән искә алына. Совет власте өчен ак чехларга, Колчак бандаларына, сәнәкче кулакларга каршы көрәшләрдә гомерләрен аямаган беренче большевиклар — укытучылар К. Т. Рахманько, Мотыйгулла Нәбиуллин, Стәрле авылы егете, өяз комсомол комитеты председателе Габдрахман Хикмәтов һәм башка батырларның якты истәлеге алдында баш иябез.

* * *

Районның мәйданы 2183 квадрат километр. Ә урман-суларга бай булуыбыз да күпләрне көнләштерерлек. Ык елгасы үзе генә дә секундына 75 кубометрлап су алып килә. Мәллә, Стәрле, Зәй елгалары да туган ягыбызга ямь өсти, челтерәп аккан йөзләрчә чишмәләр — юлчылар юанычы. Урманнарыбызның матурлыгына исең китәр. Алар мәйданның 15 процентын тәшкил итә. Биредәге күп санлы ял базалары, пионер лагерьлары, нефтьчеләрнең «Акчишмә» санаторий-профилакторие, Актүбә урман-санаторий мәктәбе хезмәт ияләренең һәм аларның балаларының иң яраткан урыннары, сәламәтлек чыганагы булып тора.

Табигатебезгә тел-теш тидерерлек түгел: Тукай әйтмешли, җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява. Аның гүзәллеге элек рус язучысы С. Т. Аксаков иҗатында чагылыш тапкан булса, хәзер без бу хакта өлкән әдипләребез Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким әсәрләрендә укый алабыз. Районда шларыбыз Гариф Галиев һәм Әнәс Кари язмаларында да туган ягыбызга дан җырлана. Бездә озак еллар буе яшәгән һәм эшләгән Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар», «Саф җилләр» романнары һәм башка кайбер әсәрләре районыбыз тормышыннан алып язылган. Хәзер инде роман-повестьлары дистәгә җиткән Мөсәгыйть Хәбибуллинның да әдәбияттагы тәүге уңышлары безнең төбәккә бәйле. Татарстан Язучылар союзы членнары Марсель Галиев, Флера Гыйззәтуллина, Нур Әхмәдиев, «Чаян» журналының баш редакторы Рәшит Зәкиев бездәге авылларның игелекле туфрагында аунап үскәннәр, ягыбызның шифалы һавасы аларны иҗатка рухландырган.

Азнакай төбәге элек-электән белемле кешеләргә, сәнгать осталарына бай, музыкага-җырга гашыйк як. Галимнәрдән Сәгадәт Ибраһимов һәм Альберт Яхин, Галимҗан Фазлыев, Фоат Вәлиев, Әҗвәт Абдуллин, татар теле һәм әдәбияты буенча күп кенә дәреслекләр төзегән педагог Вәли Хаҗиев кебек якташларыбызның исемнәре еракларга билгеле. Бездә үсеп чыккан фән эшлеклеләрен СССР Фәннәр Академиясенең Себер филиалында, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институтында да очратырга була.

Күренекле артистлар Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Луиза Солтанова — безнең авыллар җирлегендә шытып чыккан талантлар.

Һәр төбәк үзенең хезмәт сөючән, иртәгәсе турында кайгырта белүче иҗтиһатлы кешеләре белән матур. Үз эшен көндәлек ихтыяҗга әйләндереп, аннан ямь һәм ләззәт табып яшәүчеләр бик күп бездә. Социалистик Хезмәт Геройларыбыз гына

да сигезәү: нефтьчеләр Михаил Гринь, Гәрәй Баһманов, Әсгать Гарипов, Мөгаллим Гыймазов, врач Газифә Хәсәншина, элекке колхоз председателе Вәгыйз Хаҗиәхмәтов, башта тракторчы, хәзер колхозда партком секретаре Алмас Булатов, комбайнчы Фәхразый Кәримов. Атаклы бораулау мастеры Матвей Гринь, карабодай үстерү остасы Фоат Шакиров һәм колхоз бригадиры Фаяз Таҗиев Дәүләт премиясе лауреатлары булдылар.

Бөек Ватан сугышы фронтларында күрсәткән тиңсез батырлыклары өчен райондашларыбыздан Әкрәм Вәлиев, Иван Никитин һәм Петр Манаковка Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Якташыбыз, генерал-майор Фатих Булатовның «Генерал язмалары» исемле китабы буенча, Татарстаннан читтә яшәүчеләр дә яхшы беләләр. Ул командалык иткән дивизиянең сугышчан юлы әсәрдә документларга нигезләп бик ачык тасвирлана.

Сугыш турында сүз чыккач, илебез азатлыгын саклаганда һәлак булган биш мең арысландай ир-егетебез хакында да әйтми китү мөмкин түгел. Алар безнең күңелләрдә һаман яши, исемнәре мәрмәр такталарда мәңгеләштерелгән, авыл һәм мәктәп музейларындагы тарих сәхифәләренә кертелгән.

Сугыш китергән бәла-казаның тәэсире районда әле 70 елларга кадәр нык сизелде. Уйлап карагыз: сугышка кадәр бездә иң югары иген уңышы — гектарына 14,53 центнер — 1937 елда алына, ә яңадан бу дәрәҗәгә 1966 елда гына ирешелә, ягъни тәмам чыгырыннан чыккан җирләрне рәткә кертү өчен утыз еллап вакыт кирәк була.

Халкыбызның сугыш чорындагы һәм ул китергән бәла-казаларны бетергәндәге фидакарьлегенә, ныклыгына һәм түземлелегенә сокланмый булдыра алмыйсың. Илгә-җиргә чиксез мәхәббәт, дошманга карата тирән нәфрәт, якты киләчәгебезгә ныклы ышаныч шундый тиңсез авырлыкларны да җиңеп чыгарга көч биргән аңа.

* * *

Районыбызда нефть индустриясе, аңа бәйле тармаклар һәм авыл хуҗалыгы эшләре бергә үреп алып барыла. Бездә меңләгән кешеләрне туплаган берничә эре коллектив — нефть-газ чыгару, бораулау эшләре һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау идарәләре бар. Районга автомобиль юллары идарәсе, нефть кудыру станциясе, һәрберсе 200—300 техника берәмлегеннән торучы биш транспорт һәм берничә төзү оешмасы хезмәт күрсәтә.

Татарстан биргән бөтен нефтьнең 16 проценттан артыграгы безнең промыселларга туры килә. Үткән бишьеллыкта кара алтын табучыларыбыз планнан тыш 250 мең тонна сыек ягулык, 7,5 миллион кубометр газ озаттылар, бораулаучылар заданиегә өстәмә рәвештә 80 мең метр тау токымнары тишеп үттеләр һәм 51 нефть скважинасы корып тапшырдылар. Төзелеш эшләрендә 200 миллион сумнан күбрәк капитал салым үзләштерелде. Районыбыз нефтьчеләренең Көнбатыш Себердәге җир асты байлыкларын үзләштерүгә керткән өлеше дә аз түгел, ул быел тагын да артачак.

Авыл эшчәннәре унберенче бишьеллыкны күркәм нәтиҗәләр белән төгәлләделәр. Азык-төлек программасын тормышка ашыру юлында игенчеләребез фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәттеләр.

Кайбер культураларны игү тәҗрибәсе игътибарга лаек. Районда интенсив технология нигезендә үстерелгән 5965 гектар арыштан 1985 елда уртача 30 ар центнер уңыш чыкты. Ә «Актүбә» совхозында ул — 44, «Тырыш» колхозында 46 центнерга җитте. 9300 гектардагы сабан бодаеның чыгышы 31,2 шәр центнер булды.

Терлекчеләребезнең дә матур эшләре бар. «Тырыш» колхозы уңганнары, мәсәлән, 1984-85 еллардагы кышлату чоры нәтиҗәләре буенча КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Сөт савуда өчмеңчеләр хәрәкәте киң җәелдерелә. Вахитов исемендәге совхозның Загорье, «Азнакай» совхозының Уразай, «Авангард» колхозының Тымытык, «Коммунизмга» колхозының Камышлы фермаларында бу чик тулысынча яуланды инде.

Р. Харисова, Е. Скрынник, И. Шакирҗанова, Ф. Хөснетдинова кебек уңганнарыбыз сыерлардан 4000 килограммга кадәр сөт сава башладылар.

«Эконом», Тельман исемендәге колхозларда һәр төп ана дуңгыздан 28—26 шар баш үрчем алып үстерәләр.

Озак еллар сарык асраучылыкта эшләүче Н. Сираҗиев, Ф. Абдуллин, М. Шәйхуллов, Ә. Әхмәтханов иптәшләрнең даны республикага билгеле: алар елның елында һәр 100 башка 115—117 бәрән үстерәләр, һәр сарыктан 4,2—4,3 килограммлап йон кыркыйлар.

Алдынгылар үрнәге — безнең зур ышаныч. Аларга таяну нәтиҗәсендә район сөт, ит һәм йон сату планнарын уңышлы үтәп килә.

Халык хуҗалыгының кайсы гына тармагына кагылсаң да, эшнең барышы кадрлар-

га кайтып кала. Бу иң элек җитәкчеләргә һәм баш белгечләргә карый. Аларның халык белән эшли белүенә, оештыру сәләтенә күп нәрсә бәйләнгән. Бездә, бәхеткә каршы, Н. Якупов, М. Харрасов, Т. Фатихов, И. Гыйләҗев кебек колхоз председательләре, С. Әхмәдишин, Х. Шәмсимөхәммәтов кебек агрономнар, республикабызның «Урак-85» чемпионы Р. Хәсәншин кебек комбайнчылар, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы, Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры М. Хәйруллин кебек тракторчылар, ТАССРның атказанган зоотехнигы М. Гатауллин кебек белгечләр, орденлы ферма мөдире Ф. Җамалиев кебек өлгерләр бар.

— Сездә халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, культура хезмәте күрсәтү ничегрәк тора?— дип тә сорарлар инде игътибарлы укучылар. Рәхәтләнеп җавап бирәм: начар түгел. Азнакай һәм Актүбә эшчеләр поселокларында, 9 совхозда һәм 16 колхозда 24 урта, 13 сигезьеллык, 10 башлангыч мәктәп булып, аларда югары квалификацияле 641 укытучы һәм 162 тәрбияче эшли. 6 педагогка атказанган укытучы исеме бирелгән, йөздән артыгы — СССР һәм РСФСРның мәгариф отличниклары, берсе — Крупская исемендәге премиягә лаек булды. Мәктәп реформасын тормышка ашыра барып, соңгы биш елда мәктәп тәмамлаучылардан 3533 укучы төрле һөнәр алып чыкты. Алар арасында шоферлар, тракторчылар, машина белән сыер саву операторлары, төзүчеләр, сатучылар, тегүчеләр һәм башка һөнәр осталары бар. Район халкына тагын ике профтехучилище һәм Лениногорск нефть техникумы филиалы хезмәт күрсәтә.

124 врач һәм 660 урта медицина работнигы халык сәламәтлеге сагында тора. 4 поликлиника, 6 больница, 3 санаторий-профилакторий, авыллардагы һәм предприятиеләрдәге медпунктлар — барысы да хезмәт ияләре карамагында.

Культура хезмәте күрсәтү, физкультура-спорт өлкәсендә дә уңышларыбыз юк түгел, билгеле. РСФСРның атказанган культура работнигы Касыйм Еникеев җитәкчелегендәге халык театрының даны еракларга таралган, хор һәм бию коллективлары, үзешчән ансамбльләр чыгышлары да күп тапкырлар Дипломнар белән билгеләп үтелде. Музыка һәм спорт мәктәпләре уңышлы эшли, китапханәләрнең китап фонды елданел арта. Ләкин халыкның культурага булган ихтыяҗы һаман үсә бара. Шунлыктан без хезмәт ияләренең ялын оештыруның яңа формаларын эзләүне өзлексез дәвам иттерәбез.

Хәл итәсе мәсьәләләр күп әле. КПССның XXVII съездыннан соң алар тагы да ачыклана төште. Без, беренче чиратта, якындагы елларда сыек ягулык чыгаруның бүгенге дәрәҗәсен киметмәскә тырышабыз. Алдагы 10—15 ел дәвамында, бөртеклеләр уңышын гектардан 30 центнерга кадәр күтәреп, тулай җыемны 200 мең тоннага җиткерүне һәм дәүләткә ашлык сатуны 100 мең тоннага кадәр арттыруны бурыч итеп куйдык.

**Илтани Илялова,**
сәнгать фәннәре кандидаты

# ХАЛЫК ХЕЗМӘТЧЕСЕ БУЛУ

Халкыбызның яңа культура учагы буларак барлыкка килгән татар театры туган көненнән үк үзен алдынгы карашларны үткәрүче иҗтимагый трибуна, массаларны идея-эстетик яктан тәрбияләүдә гаять үтемле корал итеп танытты. 1906 ел, 22 декабрь... Милли профессиональ театрны татар халкының рухи тормышындагы тарихи ихтыяҗ тудырды. Беренче рус революциясе елларындагы гомуми күтәрелеш театрның барлыкка килүен тагын да тизләтте. Соңрак кара реакция «бөредән шартлап чыккан» театр юлына теләсә нинди мәкерле киртәләр корырга талпынып карады, әмма, К. Тинчурин сүзләре белән әйткәндә, тумыштан ук революцион булып туган театр хәрәкәтен бернинди көч тә туктата алмады. Театрны буу максаты барып чыкмагач, аның демократик асылын юарга омтылдылар, «кулга иярләштереп», аны халыктан аерырга маташтылар. Татар театры менә шулай туган көненнән үк демократик үсеше өчен киеренке көрәш башлап җибәрде. Театрны эзәрлекләделәр. Спектакльләр күрсәтергә рөхсәт ителмәде. Цензура революцион идеяләргә ишарәсе булган пьесаларны катгый рәвештә тыйды. Актерлар төрле һөҗүмнәргә дучар ителде. Шулай булса да, театр яшәде. Шушындый авыр шартларда да ул заман ихтыяҗы таләп иткән идеяләрне үткәрү, халыкны революцион көрәшкә рухландыру өчен үзендә бетмәс-төкәнмәс көч тапты.

«Театр очкыннары. Яңа кояшның беренче нурлары»... Революционер-ленинчы М. Вахитов «Мусульманская газета»да басылып чыккан (1914, 12—13 сан) бер мәкаләсен әнә шулай исемли. Театрга каршы чыккан реакцион көчләргә карата катгый сүзен белдереп, ул татар сәхнә сәнгатенең «беренче пионерлары» булган фидакарьләрнең игелекле хезмәтен югары бәяли: «...Кариев, Болгарская, Байкина — җиңеп килгән яңа тормышның беренче, сәламләү нурлары, киләчәк буыннар куансын өчен армый-талмый эшләүче сукачылары һәм чәчүчеләре».

Беренче театр труппасын («Сәйяр») җитәкләгән Г. Кариев, гомерләре буе сәхнәдән аерылмаган беренче артистлар С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарская, В. Мортазин-Иманский, А. Кулалаев, К. Шамил, шулай ук соңрак оештырылган «Нур», «Ширкәт» һәм Әстерхан труппалары актерлары Ш. Шамильский, Г. Казанский, З. Богданова, З. Солтанов, С. һәм Җ. Байкиннар, яңа реалистик драматургиягә нигез салган Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Ш. Камал, күренекле әдипләр Г. Тукай, Г. Ибраһимов, революционер-ленинчылар Х. Ямашев, М. Вахитов — татар театрын, милли демократик сәхнә сәнгатен үстерүгә менә кемнәр юл ачты. Татар театрының демократизмын формалаштыруга, сәхнәнең матурлык һәм яхшылык идеалларын раслаучы көрәш мәйданы булуын аңлауга зур өлеш керткән Тукаебыз үзенең карашларын «Театр» исемле шигырендә аеруча ачык итеп белдерә:

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр — яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Театр колдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең, күләрсең —
Күләрлек булса, булмаса — еларсың.

Күрерсең тормышың нинди: җит шме?
Җитеш булмаса, кая җире җитешми?..

Шагыйрь дөнья культурасыннан аерылган хәлдә иҗат итүне күз алдына да китерә алмаган. Театрның күпкырлы, интернациональ афишасын төзүдә, мөгаен, Г. Тукайның да йогынтысы булгандыр. Әлеге беренче афишаларда, белгәнебезчә, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Фәйзиләр белән берррәттән, Гоголь, Островский, Шиллер, Гейне, Мольер кебек дөньякүләм билгеле классикларның исемнәре дә торган.

Халыкның милли үзаңын уяту, аның гомум культура дәрәҗәсен үстерү кебек катлаулы һәм мактаулы миссияне үтәү өчен яшь театрга сәхнә сәнгатенең иң нәтиҗәле төп алымы — тормыш дөреслеген ышандырырлык итеп чагылдыручы реалистик алымга таянырга кирәк иде. Нәкъ менә шушы юлга басып, заманның мөһим мәсьәләләрен күтәреп, театр халык өчен кирәк сәнгатькә әверелде.

Труппа шуны яхшы аңлап эш итте: чын мәгънәсендә культура учагына әверелү өчен, иң беренче чиратта, театрга халык интересларын гәүдәләндерүче реалистик драматургия кирәк. Менә шуңа күрә, труппа милли репертуар булдыруга зур көч куйды. Һәм нәтиҗәдә революциягә кадәрге татар театры үзенең идея-эстетик юнәлешен шактый ук ачык чагылдырган бай афиша барлыкка китерде.

Беренче татар артистлары халыкка якын театр тудыруның икенче бер мөһим шартын актер уенының ышандыручанлыгында, тормышчан образлар иҗат итүдә күрделәр. Халыкчан театр оештыру эшендә алар милли реалистик әдәбиятка прогрессив рус театрының сыналган сәхнә методологиясе ярдәмендә таянырга омтылдылар. Рус сәхнәсе реализмының шифалы көче бигрәк тә шунда сизелә: ул, үзенә табынуны таләп итмәгән хәлдә, теләсә нинди милли театрга бөтен тулылыгында ачылырга, тормышны дөрес чагылдырырга, язучы белән театрны халык дөньясына якынайтырга булыша. Татар театрының «чишмә башы»н ачучылар моны аеруча яхшы аңлап эш иттеләр.

Чынбарлыкны реалистик төстә гәүдәләндерү, шулай итеп, татар сәхнә сәнгатенең нигезенә әверелә. Актерлар беренче елларда ук тормышны дөрес һәм тәгәл чагылдыруга ирештеләр. Һәм алар үзләре дә халыкның ничек яшәгәнен нечкәләп белүләре, һәрбер образның асылына төшенүләре ягыннан аерылып торганнар. Милли сәхнә реализмына нигез салучы Г. Кариевтан, шулай ук «Сәйяр» һәм «Нур» труппаларының беренче артистларыннан башланган эстафета әнә шулай уңышлы төстә дәвам иттерелгән. Халыкка хезмәт итү... Беренче профессиональ театр эшлеклеләре әлеге бөек максат хакына чын мәгънәсендә янып яшәгәннәр, кыска гына вакыт эчендә милли актерлык сәнгатен тудыруга ирешкәннәр. Менә шулай Кариев мәктәбе, «Сәйяр» мәктәбе туган. Әлеге тәгъбирләр, дистәләп ел үтүгә үк, театр җәмәгатьчелеге теленә кергән. Революциягә кадәр үк барлыкка килгән бу күркәм традицияләр татар театр сәнгатенең моннан соңгы үсешендә төп юнәлешне билгеләде.

Революциягә кадәрге татар театрының шактый ачык төсмерләнүче иҗат юнәлеше аны Бөек Октябрьдән соң турыдан-туры Совет властеның ышанычлы таянычы булуга китерде. Бернинди икеләнүләр булмады. Берәүләр утлы сугыш кырына китеп барды, икенчеләр сәнгать постында көрәшүләрен дәвам иттерделәр. Гражданнар сугышыннан соң алар совет милли сәхнәсенең, аның флагманы — академия театрының әйдәүчеләренә һәм горурлыгына әверелделәр. Революциягә кадәр үк танылырга өлгергән күренекле актерлар К. Тинчурин, З. Солтанов, Н. Таҗдарова, Ш. Шамильский, Н. Арапова, К. Шамил, Г. Болгарская, Ф. Ильская һәм алардан соң килгән буын вәкилләре яңа җәмгыять төзүдә театрга йөкләтелгән җаваплы миссияне, аерым алганда, сәхнә сәнгатенең төп ике компонентын — репертуар һәм идея-эстетик мәсләк мәсьәләсен һәрвакыт игътибар үзәгендә тоттылар.

Гражданнар сугышы чорында һәм егерменче еллар башында Ш. Госманов, Г. Ибраһимов тарафыннан иҗат ителгән революцион пьесалар, агитация-плакат, героик-романтик театр репертуары үрнәкләре буларак, аннан соң да күпмедер вакыт яшәүләрен дәвам иттерделәр. Аларны тагын да актуальрәк әсәрләр алмаштырды. Яшь совет театрының югары идеяле заманча репертуарын булдыру өчен сыйфат дәрәҗәсе җәһәтеннән яңа бер сикереш ясарга кирәк иде. Һәм ул ясалды да: К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Н. Исәнбәт, Г. Кутуй кебек танылган әдипләр, беренче совет пьесаларының иң яхшы үрнәкләренә таянып, тормыштагы көнүзәк мәсьәләләргә багышланган комедияләр һәм мелодрамалар иҗат иттеләр. Әлеге авторларның күп кенә әсәрләре, вакыт сынавын уңышлы үтеп, татар драматургиясенең алтын фондына керделәр.

Һәрбер чорның үз проблемалары була. Утызынчы елларда, мәсәлән, бөтен игъ-

тибар илне индустрияләштерү, колхозлар оештыру, кулаклар белән кискен көрәш һ. б. шундый зур бурычларга юнәлтелде. Заман белән бер адымда атлаучы язучыларыбыз шул проблемаларны хәл итү барышында яңа кеше тәрбияләнүен төрле яклап күрсәтергә омтылдылар. Утызынчы елларның икенче яртысында заман агышын халку рәвештә гәүдәләндергән җитди әсәрләр күренә башлый. Шушы чорда язылган «Шәмсекамәр» (М. Әблиев), «Чаткылар», «Ташкыннар» (Т. Гыйззәт) кебек әсәрләр хәзер татар драматургиясенең бәяләп бетергесез казанышлары булып санала. Халкыбызның яшәү дәрте белән янып йөрүче акыллы һәм җор кешеләрен күрсәткән «Кыю кызлар» (Т. Гыйззәт), «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт) кебек комедияләр дә төрле буын тамашачылары тарафыннан һәрвакыт яратып карала торган спектакльләргә әверелә.

Утызынчы елларда театр көнүзәк проблемалы әсәрләргә ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен рус совет драматургиясе хәзинәсеннән дә нәтиҗәле файдалана, атап әйткәндә, В. Киршон, В. Иванов, А. Афиногенов, В. Шкваркин, А. Арбузов кебек танылган авторларның революция, социализм төзү һ. б. җитди темаларга багышланган пьесаларын уңышлы сәхнәләштерә. Табигый ки, фашизмга каршы көрәш чорында сугыш тематикасы беренче планга чыкты.

Илленче һәм алтмышынчы елларда драматургиягә яңа көчләр килү сәхнә сәнгатебезне яңа баскычка күтәрергә мөмкинлек бирде. Татар әдәбиятының реалистик традицияләренә тугрылык, заманча фикерләү осталыгы, чорыбыз елъязмачысы булырга омтылу Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев, А. Гыйләҗев, И. Юзеев кебек каләм ияләрен театрда яңа бер күтәрелеш тудырырлык әсәрләр иҗат итүгә китерде. Татар драматургиясенең илкүләм абруе арту аның күпмилләтле совет культурасы традицияләре җирлегендә үсүеннән киләдер. Драматургларыбыз гомум кешелек проблемаларына һаман саен тирәнрәк үтеп керәләр. Соңгы вакытта тарихи һәм тарихи-революцион темаларга игътибар артты. Театр җәмәгатьчелеге, мәсәлән, Н. Фәттахның «Кол Гали», Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр», Д. Вәлиевнең «1887 яки таңребез бер — хөррият» исемле әсәрләре буенча куелган спектакльләрне яратып кабул итте.

Татар драматурглары, производство темасына мөрәҗәгать итеп, бүгенге казанышларыбыз иҗатчысы булган актив герой образларын тудырдылар. Шундый замандашыбызны без Д. Вәлиевнең «Тормыш бүләк итәм», «Диалоглар» дилогиясендә, Т. Миңнуллинның «Монда тудык, монда үстек» драмасында күрәбез. Прозаик Г. Ахуновның «Хәзинә», «Ардуан батыр», «Чикләвек төше» исемле роман һәм повестьлары нигезендә эшләнгән спектакльләр дә заманны әйдәүче актив геройлар галереясын баетуга хезмәт итәләр. Эшчеләр сыйныфы турындагы пьесаларда геройның әхлакый үсешенә ныграк игътибар бирелә. Югарыда санап үтелгән әсәрләрдә без моның күркәм үрнәкләрен күрәбез.

Бүгенге заман татар драматургиясенең новаторлыгы, бөтен совет сәхнә сәнгатендәге кебек үк, конфликтны сюжет нигезенә түгел, ә алынган проблеманы ачу җирлегенә коруда күренә. Конфликт теге яки бу күренешнең философик асылын ачуга нигезләнә. Уңай һәм тискәре персонажлар арасындагы конфликтка түгел, ә геройның рухи дөньясындагы эчке каршылыкларга ныграк басым ясала. Милли сәхнә әдәбиятының әлеге сыйфаты «өченче тип» әсәрләр — мораль-этик пьесаларда да шактый калку чагыла. Мондый төр әсәрләрдә, гадәттә, әхлак мәсьәләләре төрле яклап яктыртыла, халык хәтерен түкми-чәчми саклау, туган туфракка мәхәббәт кебек темалар да колачлана. Әйтик, И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан», А. Гыйләҗевның «Югалган бер көн», «Ефәк баулы былбыл кош», Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Монда тудык, монда үстек» пьесаларында шундый фикер үткәрелә: Кеше хәтерсез-үткәннәрсез, туган туфрак белән аерылгысыз итеп бәйләүче тамырларсыз яши алмый. Югарыда санап үтелгән пьесаларның берсе тикмәгә генә «Нигез ташлары» дип аталмагандыр. Нигез ташлары... Кешенең дә әнә шундый рухи нигезе була. Әсәрдә нигез төшенчәсе тирән мәгънәле символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Шунысы үзенчәлекле: татар драматургиясендә әлеге проблемалар нигезендә халык язмышы үзәгендә яшәгән мөхтәрәм картлар — ил картлары йөзендә гәүдәләндерелә.

Татар театрында обывательлекне фаш итүнең ерак тамырлары бар. Әлеге традицияләр милли драматургиябезнең атасы Г. Камалдан ук башлана. Хәтерлисездер, әдипнең сатира хөкеменә куелган «адәмчекләр»е арасында күлмәк өчен газиз улын сатып җибәрергә әзер торучылар да очрый. Бүгенге драматургларыбыз, классиклар тәҗрибәсен тирәнтен өйрәнеп, җәмгыятебез өчен ят булган бу күренешне заманча ачарга омтылалар. Мещанлык һәм рухи чикләнгәнлекне ачып бирү өчен алар драма жанрына мөрәҗәгать итәләр. Менә шуңа күрә, спектакль көлдерә дә, иң мөһиме, уйландыра да. Шулай итеп, мещанлыкның асылы, антигуманистик «теория»се фаш ителә. Драматург Д. Вәлиевнең «Әгәр үзеңә хыянәт итсәң» әсәрендәге Салихны гына

искә төшерегез. Үзенең «умырткасызлыгын» фаҗигале төстә тануы белән ул күңелдә кызгану хисе уята. Табигать тарафыннан талант бирелсә дә, аның гомере кызыксыз һәм нәтиҗәсез үтә. Шундый ук проблеманы күтәрүче «Дуслар җыелган җирдә» пьесасы (Т. Миңнуллин) үзенчәлекле притча, диспут рәвешендә язылган. Безгә нәрсә булды? Шәхесләр булып өлгерә алдыкмы? Тынычлану һәм туклык безне обывательлек сазлыгына батырмыймы? Спектакль геройларын әнә шундый сораулар борчый. Аларны әнә шундый авыр уйлар эзәрлекли...

Рухи сайлык мотивына Р. Хәмид башкачарак якын килә. Үзенең пьесаларындагы Наил белән Илсурны ул бер-берсен тулыландыручы геройлар итеп гәүдәләндерә. Берсе — агроном, икенчесе — инженер. Әмма аларның кылган гамәлләре ничектер кеше ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелмәгән шикелле. Коры эш өчен эшләү... Кешеләргә шатлык китерү ләззәтен алар инде тоймый башлаганнар. Җансыз роботка әйләнеп баралар. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр салкынлыгы Р. Мингалимнең «Өченче бүлмәдә эт яши» драмасында да шактый кискен төстә күтәрелә. Тормыш ваклыклары әсирлегенә бирелү, хис-тойгылар салкынлыгы, әнә шулай, балалар яшисе бүлмәдә эт тотуга китерә.

Соңгы елларда татар драматургиясендә яшәү мәгънәсе турындагы философик мәсьәләләрне күтәргән интеллектуаль пьесалар иҗат итү активлаша төште. Шундый әсәрләр рәтенә, мәсәлән, Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр» пьесаларын кертергә мөмкин. Әлеге әсәрләрнең берсе — трагикомедия, икенчесе публицистик трагедия жанрында язылган. Пьесаларда алга куелган катлаулы мәсьәләне чишү юллары шактый ачык төсмерләнә. Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең фаҗигале язмышын өйрәнгәндә, «Театр» журналында әйтеп үтелгәнчә, драматургны гадәттән тыш авыр ситуациядә дә сынмаган көчле рух серләре кызыксындыра. Әлеге драматургның каһарманлык нигезләре, кеше рухының үлемнән өстен калуы турындагы уйланулары И. Юзеевның символик сурәтләү алымы белән язылган «Соңгы төн» трагедиясенә аваздаш яңгырый. Шагыйрь язмышы — халык язмышы... Әлеге әсәрдә дә хакыйкатькә әверелгән әнә шундый фикер уткәрелә.

Җитмешенче елларда иҗат ителгән милли пьесалар кешегә дан җырлаулары белән генә түгел, ә шәхеснең һаман саен тирәнрәк рухи катламнарын ачулары белән әһәмиятле. Аларда аерым кешеләрнең образы күпгасырлык үткәннәр, халык дөньясы белән бәйләнештә ачыла.

Сәхнә сәнгате методологиясенә килгәндә, татар театры, әйткәнебезчә, беренче адымнарыннан ук реалистик юнәлештә баруын дәвам иттерә. Егерменче еллардагы стилистик эзләнүләр тормышны дөрес чагылдыру принцибын тагын да тирәнәйтте, һәм әлеге принцип театрның яшәү рәвешенә әверелде. Сәхнәләштерү сәнгатенең яңа формаларын эзләү театрның магистраль юлын киңәйтүгә китерде. Утызынчы елларда театрга аяк баскан режиссерлардан Г. Исмәгыйлев, Ш. Сарымсаков милли сәхнә корифейлары традицияләрен уңышлы төстә үстерделәр. Татар театры эшчәнлеген бүгенге заман «стандартлары»на якынайтуда, аның илкүләм абруен күтәрүдә М. Сәлимҗанов, П. Исәнбәт кебек режиссерлар зур өлеш керттеләр. Эзләнүләр дәвам иттерелә.

Безнең карашыбызча, театр үсешендәге яңа этап хәрәкәт логикасын, геройларның фикер сөрешен тирәнәйтү, жанр һәм автор стиле үзенчәлекләрен калкурак ачу белән билгеләнә. Актерлык сәнгате үсешен бербөтен ансамбль тудырудан башка күзаллап булмый. Хәзерге театр коллективы милли сәхнә традицияләрен яңача үстерергә омтыла. Көнкүреш сурәтләнешендәге ышандыручанлык заманча образлылык белән баетыла, театрдагы романтик тенденцияләр шигърилеккә якынайтыла. Коллектив һәрбер спектакльнең жанрын төгәл билгеләргә омтыла. Репертуарда психологик драма белән беррәттән, трагедия, фарс, мелодрама, водевиль, героик-романтик драмаларга да зур урын бирелә. Ачык театраль формадагы татар спектакльләре мавыктыргыч тамаша төсендә үтә. Шунысы игътибарга лаек: спектакльләрнең күпчелеге эзләнүләр барышындагы аерым этап, тагын да тәэсирлерәк сурәтләү чараларына ирешүдә билгеле бер баскыч буларак кабул ителә. Әлбәттә, милли сәхнә сәнгатенең үткәндәге казанышларына таянмыйча, спектакльләр куелышындагы яңалыкка ирешеп булмый. Менә шуңа күрәдер, күп кенә пьесалар татар тамашачысы өчен якын булган традицион психологик драма рәвешендә сәхнәләштерелә.

Традицион актерлык сәнгате характерларның эчке логикасын бирүдә яңа сурәтләү чаралары белән баетылды. Тиешле урында тотанаклык күрсәтү, хис-кичерешләрне тезгенләү, икенче бер очракта, киресенчә, ташып чыгу сәхнәбездә тагын да табигыйрәк күрсәтелә башлады. Кайчандыр штамп тарафыннан кысрыкланган кызыклы уен алымнары сәхнәгә яңадан кайтарылды. Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов үзенең эшкә килү елларын түбәндәгечә искә төшерә: «Актерларны бүгенге категорияләр югарылыгында фикер йөртергә, аларны сөйләмдәге гадәти төшенчәләр, алымнар һәм шомарып беткән интонацияләрдән качарга

мәҗбүр итәргә кирәк иде. Бездән үзара мөнәсәбәтләрнең заман таләп иткән чынлыгына ирешү, бүгенге хакыйкатькә киеренкелек төсмере өстәлүен тою соралды. Артистларның эчке чикләнгәнлеген бетерү, персонаж характерын импровизацион төстә ачарга ирешү, образга сәхнә иҗатчысының үз карашын булдыру... Безнең алда әнә шундый бурычлар торды».

Бу җәһәттән шуны әйтергә кирәк: М. Сәлимҗанов спектакльләрнең тулаем образлылыгына ирешә. Пьесаларның куелышыннан аңлашылганча, заманча ритмнар актер уенына гына түгел, сценографиягә дә һәм хәтта сәхнә күренешләре алмашынганда да кирәк. Бүгенге театрда бер генә мизгел дә «заяга» узмаска тиеш. Боларның барысы да театрга халык тормышы белән яшәргә мөмкинлек бирә. Режиссер үзенең иҗади эзләнүләрендә щепкинчыларга — Мәскәүдә белем алып кайткан Ф. Әхтәмова, Н. Дунаев, Г. Исәнгулова, Н. Ихсанова, Р. Таҗетдинов, М. Хәйруллина, Ф. Хәмитова, Ә. Шакиров, Р. Шәрәфиев кебек яшьләргә, шулай ук бай сәхнә тәҗрибәсенә ия булган Ф. Халитов, Г. Шамуков, Ш. Биктимеров, Г. Надрюков кебек өлкәннәргә ышанычлы төстә таянды. Аерым артист ирешкән һәрбер казаныш бөтен ансамбльнең уртак казанышына әверелә барды. Мондый күренеш күркәм тенденциягә әйләнде.

Татар театры сиксән еллык гомерендә мактаулы зур юл үтте. Бүгенге биеклеккә күтәрелү җиңел булмады. Әмма «яктылыкка, нурга» коендыручы культура учагы буларак туган театр үзенең төп үсеш юлыннан беркайчан да тайпылмады, туган халкына хезмәт итүне барысыннан да өстен максат итеп куйды һәм, шулай итеп халкыбызның олы мәхәббәтен казанды.

## Кәрим Тинчурин

# МУЛЛАНУР ИПТӘШ ВАХИТОВ ҺӘМ ТАТАР ТЕАТРЫ

*Кәрим Тинчурин — классик драматург, оста хикәяче буларак укучыларга киң билгеле. Соңгы елларда аның театр тарихына караган мәкаләләр язуы да билгеле булды. «Кызыл Армия» газетасының 1919 ел 11 сентябрь санында дөнья күргән «Мулланур иптәш Вахитов һәм татар театры» исемле мәкалә — шуларның берсе. Бу мәкалә халкыбызның бөек улы, Ленинның көрәштәше М. Вахитовның татар совет театрын оештырудагы ролен ачыклау ягыннан зур әһәмияткә ия. Мәкалә әдипнең әлегә кадәр дөнья күргән җыентыкларына кермәгән.*

Хәсән **ГОБӘЙДУЛЛИН,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

Иптәш Мулланур Вахитов белән минем беренче танышуым 1917 елның апрелендә «Татар социалистлары комитеты» төзелгән вакытта булды. Ләкин мин Вахитов иптәшне аңарчы ук сәнаигы нәфисә мөхибе бер истинник[1] итеп таныйдыр идем. Аның татар театры хакында пайтәхет[2] газеталарында язылган мәкаләләре, ул вакыттагы татар театрын ни кадәр сөйгәнлеген һәм татар сәнаигы нәфисәсен аякка бастыру өчен күрсәткән инкыйлаби[3] юллары, аның шул вакытта ук сәбатлы[4] инкыйлабчы һәм завык сәлим[5] ияce булган чын истинник икәнлеген күрсәтә иде. Вахитов иптәшнең 1905 еллардагы сәяси[6], иҗтимагый хезмәтләре белән танышлыгым булмаганга, аның татар театры хакында пайтәхет газеталарында язылган мәкаләләренә карап кына мин аның сәбатлы бер инкыйлабчы һәм чын күңеле белән татар сәнаигы нәфисәсен сөюче зыялы бер кеше икәнлеген аңлап, аңа күңелемне утырткан идем. Россиядә инкыйлаб коявы тугач Вахитов иптәш белән якыннан танышырга туры килгәнгә, аның татар сәнаигы нәфисәсе хакындагы карашын да якыннан белергә туры килде. Вахитов иптәш сәбатлы көрәшче булганы өстенә, ул шул кадәр ул маһир оештыручы да иде.

---

[1] Сәнаигы нәфисә мөхибе бер истинник — матур сәнгатьне чын мәгънәсендә яратучы.
[2] Пайтәхет — башкала.
[3] Инкыйлаби — революцион.
[4] Сәбатлы — какшамас, ныклы.
[5] Завык сәлим — чын, саф завык.
[6] Сәяси — политик.

Шуның аркасында ул кыска бер вакыт эчендә әтрафына хаксызлыктан изелгән бөтен халыкларны җыя алды. Шул җөмләдән татарның тәгассыбе[7] татарның тупаслык аркасында изелгән, патша идарәсенең тырнагы эченда хур-мәсхәрә ителгән татар артистларын да ул үз канаты астына алды. Театрга күңел куйган яшь татар һәвәскәрләрен оештырып, «Мөселман социалистлар клубында», беренче буларак татар сәхнәсе тәшкил итте. Сәнаигы нәфисә хакында мөтәхассыйслардан[8] лекцияләр укытты. Бу эшләрнең һичберсе руслар арасында вөҗүткә килмәгәннәр[9] иде әле.

Инкыйлабчы Вахитов, инкыйлабчы сәнаигы хадимнәрен[10] оештырып, татарның зәгыйфь сәнаигы нәфисәсенә моннан өч ел мөкаддәм[11] нигез салды. Ягъни татар ярлы халкы өчен сәнаигы нәфисә ишекләрен ачу белән бергә ул шул ук зәгыйфь татар сәнаигы нәфисәсен нык нигезгә утыртырга чын күңеле белән тырышты.

Вахитов иптәш белән очрашкан вакытларда, ул ике сүзнең берендә татар театрын яхшырту, аны алга җибәрү, татар театры өчен махсус бина тәшкил итү, дәүләттән ярдәм алып, театр китапларын күбәйтү шикелле сүзләр сөйләп, безгә, артистларга, рух кертеп мәгънәви көч бирәдер иде. Сәнаигы нәфисә хакында булачак мөһим лекцияләр хакында артистларга алдан хәбәр әйтеп, безне шул лекцияләргә чакырадыр иде.

Вахитов иптәшнең Казан татар театры хакында төзегән планнарының күбесе, аның Казаннан китүе белән вөҗүткә чыкмыйча калдылар. Ләкин ул Питер, Мәскәүнең сәяси казанында кайнаса да, өстенә йөкләнгән вазифалары ни кадәр күп һәм авыр булсалар да, ул шул вакытларда да татар театрын, татар сәнаигы нәфисәсен, татар артистларын исеннән чыгармады. Үткән ел Вахитов иптәш, чехлар Казанга керү алдыннан Казанга кайтып, артистларны махсус күреп, татар сәнаигы нәфисәсе хакында алда торган планнарын сөйләгән иде. Хәтта шул максат белән Васильево дачасында хосусый бер киңәш мәҗлесе сыман нәрсә ясалып та үткән иде.

Вахитов иптәшнең шул вакытта сөйләгән сүзләренә караганда, ул «Сәйяр труппа» артистларын Мәскәүгә алып барып, кинематограф ленталарына татарның үз нәрсәләрен уйнап, шуннан соң Мәскәүдә артистлар мәркәзе[12] ясап, артистларның мәгыйшәтләрен[13] дәүләт хисабыннан тәэмин иттереп һәм, театр өчен лазем булган[14] бөтен әсбабларны хөкүмәт хисабына ясатып, Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Самара, Петропавел һәм Себер шәһәрләрендә татар театрлары ясатып, шул театрларга артистлар һәм музыкантлар җитештерү өчен драма студияләре, музыка мәктәпләре ачарга планы барлыгын сөйләгән иде. Ул вакытта Казан артистлары тәгътыйльдә[15] булганга, Кариев та Мәскәүдә булганга, бу киңәш мәсьәләсе көзгә кичектерелү муафыйк табылган иде[16]. Ләкин бу көз Вахитов иптәш өчен һәм татар театры өчен шомлы көз булды.

Татар театрына, татарның һәрбер якты якларына аяк чалып килүче татар буржуазиясе, татар муллалары изге җан Вахитов иптәшнең җанын килмешәк чехословакларга, карагруһ русларга саттылар. Вахитов иптәш вәхшиләр тарафыннан үтерелде[17]. Шуның белән аның татар театры хакында корылган планнары да вакытында вөҗүткә чыга алмый калды. Дөрес тә, Вахитовның калган инкыйлабчы иптәшләре, Вахитов омтылган шул ук бер йолдызга омтылганга, барыбер аның планнарын вөҗүдкә чыгардылар. Ләкин мәрхүм Вахитов сәламәт булган булса, хәзер инде безнең үзебезнең пролетариатыбыз өчен берничә шәһәрдә үз театрыбыз булып, берничә дистә артистларыбыз да арткан булыр иде.

Кабереңдә тыныч ят, арыслан йөрәкле инкыйлабчы җегет, татар театры, татар сәнаигы нәфисәсе үзенең беренче чәчәген синең кабереңөстенә илтәр. Сәнаигы нәфисә нуры белән нурланган татар пролетариаты беренче догасын синең рухыңа баглыйдыр.

---

[7] Тәгассыб — фанатизм.

[8] Мөтәхассыйс — белгеч, специалист.

[9] Вөҗүткә килү — тормышка ашу, башкарылу.

[10] Хадим — хезмәткәр.

[11] Мөкаддәм — элек.

[12] Мәркәз — үзәк.

[13] Мәгыйшәт — яшәеш, тормыш, тереклек.

[14] Лазем булган — тиеш булган.

[15] Тәгътыйль — каникул.

[16] Муафыйк табылган иде — тиешле табылган иде.

[17] Монда сүз М. Вахитовның Казанда 1918 елның 19 августында контрреволюционерлар тарафыннан атып үтерелүе турында бара.

# ТОРМЫШ ТАЛӘБЕ

ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ ЙОМГАКЛАРЫ

1986 ел буе журнал битләрендә әдәби тәрҗемә проблемалары хакында сөйләшү барды. Ул әдәби җәмәгатьчелектә дә, укучылар арасында да яңгыраш тапты. «Тәрҗемә турында сөйләшәбез» дигән баш белән илебезнең төрле төбәкләреннән редакциягә күп санлы хатлар килде. Дискуссиядә катнашып журналыбыз битендә мәкалә, реплика яисә хат белән чыгыш ясаган һәр кеше бу сөйләшүнең кирәкле булуын, күтәрелгән мәсьәләләрнең үтә актуаль икәнлеген язды.

Әйе, тәрҗемә проблемаларына җитди игътибар бирүне бүгенге тормыш үзе таләп итә. Хәзерге чорда — илебездәге милли культураларның һәммә яктан тизләтелгән үсеш кичергән һәм бер-берсе белән аралашулары, кызыксынулары көчәйгән заманда — халыклар арасында рухи күперләр сала торган әдәби тәрҗемә эше һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга тиеш.

КПССның XXVII съездында кабул ителгән социаль-экономик үсешне тизләтү программасы таләпләреннән чыгып караганда да бүгенге тормышта әдәби тәрҗемә гаять мөһим роль уйный. Милли әдәбиятлар тудырган иң уңышлы әсәрләргә ил күләмендә киң мәйдан бирү, аларны барлык совет укучыларына ирештерү һәм шул юл белән андый әсәрләрне коммунистик тәрбия максатында тагын да эффектлырак файдалану — көннең зарурияте.

Дискуссия журналның быелгы 2 нче санында Р. Сафаров һәм Л. Лероновтан килгән ике хат нигезендә башланып китте. Шул ук санда анкета урнаштырылып, анда мәсьәләне төрле яктан яктырткан сораулар да куелды. Сөйләшү барышында уртага салынган мәсьәләләр шактый ачыкланды, күп кенә сорауларга җаваплар табылды.

Сөйләшүдә катнашучылар дөрес билгеләп үткәнчә, соңгы елларда әдәби тәрҗемә өлкәсендә ирешелгән уңышларны беркем дә инкарь итә алмый. Илебездәге күп төрле телләрдә иҗат ителүче совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре үз вакытында татар теленә тәрҗемә кылынып, басылып чыгу факты укучыларда бигрәк тә канәгатьләнү тудыра. Мисал өчен, Ч. Айтматов, В. Распутин, Ю. Бондарев, В. Астафьев кебек осталарның әсәрләре татарча дөнья күрү күп санлы укучыларның күңел ихтыяҗын гына үтәп калмады, ә бәлки күпмедер дәрәҗәдә әдәбиятыбыз өчен дә этәргеч булды, язучыларыбыз иҗатына да тәэсир ясады.

Татар әдәбиятын башка телләргә тәрҗемә итүдә дә сизелерлек уңышлар бар. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы С. Иванов тәрҗемәсендә русча дөнья күрү, Г. Тукайның һәм М. Җәлилнең юбилейлары уңаеннан басылган яңа тәрҗемәләр, шулай ук герой-шагыйрьнең Киевтәге «Днипро» нәшриятында чыккан китабы һ. б. лар — тәрҗемә өлкәсендә соңгы елларда ирешелгән уңышларның кайберләре. Шулай ук замандаш прозаикларыбыз һәм шагыйрьләребезнең әсәрләре дә төрле телләргә тәрҗемә ителде. Аерым әсәрләр үзәк журналларда басылып чыкты.

Мондый мисаллар безнең әдәбиятның гомум совет культурасы үсешенә лаеклы өлеш кертүен күрсәтә, башка милли әдәбиятлар белән бергә, алар янәшәсендә чәчәк атуын раслый.

Әмма, дискуссиядә чыгыш ясаган күпчелек авторлар урынлы язып үткәнчә, безгә әдәби тәрҗемә өлкәсендәге уңышларыбыз белән канәгатьләнергә иртә әле.

Алда торган бурычларның иң зурысы — татар әдәбиятының төрле чорларда яшәгән классиклары, күренекле әдипләре иҗатын тәрҗемә итү. Бу

тугандаш милләтләр алдында үз халкыбызның борынгыдан килгән рухи көчен, аның дәверләр буена тупланып җыйналып килгән көчле байлыгын күрсәтү дигән сүз. Бу — әнә шул кыйммәтле хәзинәне совет кешеләренең уртак рухи байлыгы итү дигән сүз.

Әдәби тәрҗемә турындагы дискуссиядә катнашучылар әлеге зур проблеманы хәл итү буенча мөһим тәкъдимнәр дә керттеләр. Мәсәлән, Татарстан китап нәшриятында классикларны рус телендә бастырып чыгару буенча махсус редакция оештырырга кирәк дигән фикер игътибарга лаек. Хәл ителүе җиңел булмаган бу тәкъдим тормышка ашырылган очракта, тәрҗемә эшендә система тагын да көчәер иде, тәрҗемәче көчләрне бергә туплау өчен һәм яңа кадрлар әзерләү өчен ышанычлы нигез табылыр иде.

Тагын бер мөһим мәсьәлә дип, тәрҗемә өчен әсәрләр сайлап алу билгеләнде. Башка телләрдән татарчага әйләндергәндә бу эш шактый планлы рәвештә, система белән башкарыла.

Ә менә үзебезнең әдәбият әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә иткәндә, план буенча һәм оешкан төстә эшләү сизелми. Нәтиҗәдә әһәмиятле генә әсәрләрнең тәрҗемәчеләр игьтибарыннан читтә калу очраклары була һәм шуның аркасында башка милләт укучыларында безнең әдәбиятыбыз хакында тулы булмаган фикер туу өчен мөмкинлек ачыла.

Дискуссия барышында бу юнәлештә дә эшлекле тәкъдимнәр әйтелде. Республика әдипләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү өчен Татарстан Язучылар союзы каршында аерым бер совет я комиссия төзелсә, эшне яхшыртуда аның файдасы күп булыр иде. Тәрҗемә итәргә әсәрләр сайлаганда, беренче чиратта идея-эстетик кыйммәте югары булган китаплар алыныр иде. Димәк, уртак максатка да якынрак киленер иде.

Башка телләргә тәрҗемә итүче талантлы һәм тәҗрибәле кадрлар булдыру. Сөйләшүдә катнашучылар күтәргән тагын бер үткен проблема әнә шул. Күпләр әле хәзергә бу мәсьәләнең дә канәгатьләнерлек хәл ителмәгәнлеген күрсәттеләр, байтак кына мисаллар китерелде. Иң төп бәла — язучыларыбыз әсәрләренең күпчелек очракта уртача сәләтле һәм очраклы кешеләр тарафыннан тәрҗемә ителүе, шул сәбәптән түбән сыйфатлы булып чыгуы.

Хәзер бездә русчага тәрҗемә ителергә теләгән автор тәрҗемәчене нигездә үзе эзли, үзе таба. Билгеле, бусы да начар түгел. Бу, асылда, шулай булырга тиеш тә. Әмма яхшы сыйфатлы әсәр язып та, тәрҗемәче эзләп йөрмәгән автор белән нишләргә? Безнең байтак кына яхшы әсәрләребез әнә шул сәбәпле бер читтә торып кала түгелме? Совет яки комиссия төзелсә, ул әлеге авторга ярдәм итәр иде.

Дискуссиядә чыгыш ясаган күпләр үзебездә талантлы тәрҗемәчеләр тәрбияләп үстерү мәсьәләсенә тукталдылар, проблеманың төрле аспектларын кузгаттылар. Элеккерәк елларда Татарстан Язучылар союзы каршында эшләгән семинарлар, яшь тәрҗемәчеләрнең иҗатларын тикшерү утырышлары искә алынды. Яшьләрнең аеруча сәләтлеләрен М. Горький исемендәге әдәбият институтында укытып кайтару идеясе бертавыштан хупланды. Шулай ук булган кадрларыбызга игътибар бирү һәм аларны даими эш белән тәэмин итү дә көн тәртибенә куелды.

Тәрҗемә эшенә гомуми игътибарны көчәйтү кирәклеге дә хаклы рәвештә искә алынды. Мисал өчен, аерым әсәрләрне тәрҗемә итү буенча ачык конкурслар уздыру һәм иң яхшы хезмәтләрне билгеләп үтү, шулай ук ел дәвамында республикада яисә ил күләмендә тәрҗемәләнгән татар язучыларының уңышлы әсәрләренә бүләкләр булдыру — эшне һичшиксез җанландырып җибәрәчәк.

Әдәби тәнкыйть тарафыннан тәрҗемә эшенә җитәрлек игътибар булмау да урынлы әйтелде. Бу тармакның проблемалары ачылмый. Басылып чыккан аерым хезмәтләр дә ныклап рецензияләнми кала.

Гомумән, тәрҗемә эшен җанландыруга бәйле байтак кына мораль һәм материаль кызыксындыру мәсьәләләрен хәл итәсе бар. Шулай ук тәрҗемә секцияләренең эшен дә заман таләп иткәнчә үзгәртеп корырга кирәк. Мисал өчен, секция утырышларында тәрҗемә ителгән яңа әсәрләр тикшерелсә, бу тармак алдында торган иң үткен мәсьәләләр турында бергәләп киңәшүсөйләшүләр уздырылса һәм шуның ише башка практик чаралар күрелсә — уртак эшкә файда булыр иде.

Әдәбиятыбызның иң уңышлы әсәрләрен рус теленә үз вакытында тәрҗемә итүгә дә дискуссиядә катнашучылар зур әһәмият бирделәр. Аерым әсәрләрнең соңга калып тәрҗемә ителүе аркасында союз күләмендә тиешле

яңгыраш алып җиткермәве күрсәтеп үтелде. Игътибарга лаек әсәрләр тәрҗемәдән соң тәнкыйть тарафыннан да анализланса, киң пропагандаланса, эш өчен яхшы булачагы әйтелде.

Тәрҗемә эшенең профессиональ «серләре» турында сөйләшү барышында аеруча еш язылды. Сүз алган байтак тәрҗемәчеләр үзләренең ничек бирелеп хезмәт итүләрен сөйләделәр, иҗат «кухняларын» ачтылар. Мисал өчен Мәҗит Рафиковның 3 санда басылган мәкаләсе бик күп яшь тәрҗемәчеләргә файдалы булырлык һәм эшкә намуслы мөнәсәбәт үрнәге була ала. «Әгәр дә оригиналь әсәрне күңелемә, рухыма чын-чыннан якын күреп, яратып тотынсам, мин аны инде икенче телнең үзем белгән бөтен чараларын эшкә җигеп, үземнең бөтен тырышлыгым, үҗәтлегем белән рус укучысына җиткерәм. Тулы килеш, кайнар килеш, дәртле, куәтле килеш. Нәкъ үзем яратып күңелгә кабул итеп алган килеш. Хыянәтсез, хилафсыз»,— дигән сүзләр вакытсыз арабыздан киткән останың яшьләргә васыяте сыман яңгырый.

Әйе, һәр эштәге шикелле биредә дә талант һәм тырышлык, эшкә намуслы мөнәсәбәт уңыш алып килә, укучылар яратып кабул итәрдәй тәрҗемә әсәрләре тудыра.

Әмма дискуссия барышында бик дөрес күрсәтеп үтелгәнчә, тәрҗемә эшендә әле тагын башка «серләр» дә байтак. Шулардан берсе — әсәрне оригиналданмы яисә подстрочник ашамы тәрҗемә итү. Сөйләшүдә сүз алучыларның күбесе оригиналдан турыдан-туры тәрҗемә итүнең һичшиксез яхшырак икәнен раслады, мисал итеп күп санлы әсәрләр китерелде. Хәзерге шартларда ике телне дә яхшы белгән әдипләр отряды булу моңа реаль нигез дип күрсәтелде.

Ләкин шул ук вакытта, юлга-юл тәрҗемәне дә практикадан сызып ташларга мөмкин түгел. Чөнки бу ысул белән әсәрләребезнең 90 проценты тәрҗемә ителә.

Шул уңайдан дискуссиядә катнашучылар юлга-юл тәрҗемә әзерләү эшенең аеруча зур җаваплылык соравын һәм аңа һәрчак намус белән карау кирәклеген басым ясап күрсәттеләр. Классикларыбыз әсәрләрен тәрҗемә өчен әзерләгәндә, бу момент еш кына хәлиткеч факторга әверелә. Бер дә сер түгел: ашык-пошык һәм өстән генә әзерләнгән подстрочниклар аркасында кайбер классикларыбызны бүтән милләтләрнең тиешенчә аңлап, бәяләп җиткермәү очраклары күренгәли.

Тәрҗемә процессындагы иң мөһим моментлар хакында да байтак сүз барды. Күпчелек авторлар мондый фикерне якладылар: төп хикмәт текстның образлы һәм хисси-ассоциатив эчтәлегендә. Оригиналның милли колоритлы эчтәлеген икенче телнең образлы иҗат чаралары аша биреп җиткерә алуда. Әнә шундый адекват чаралар комплексын табып бетерә алуда. Әлбәттә, бу очракта тәрҗемәченең таланты да, осталыгы да һәм сизгерлек белән чама хисен югалтмавы да аеруча нык сорала.

Шул уңайдан тәрҗемәгә бирелмәүче шигъри әсәрләр булу яки булмау турында да сүз чыкты. Күпчелек авторлар бик хаклы рәвештә андый әсәрләрнең булмавын, ә бәлки тәрҗемәгә авыр бирелә торган шигырьләр генә булуын әйттеләр. Бер үк вакытта тәрҗемә процессында, гомумән, күпмедер югалтуның котылгысыз булуы да ачыкланды. Әмма аны булдырмаска омтылу бөтен тәрҗемәчеләр өчен идеал, зур максат булып кала.

Дискуссиядә катнашучылар хәзерге тәрҗемә практикасындагы кайбер күңелсез тенденцияләргә дә тукталдылар. Мисал өчен, оригиналдагы төссез һәм уңышсыз әсәрләргә кайчак тәрҗемәчеләр тарафыннан җан кертелү, ә шундый ук эшкәртелүгә дучар булган кайбер классик әсәрләребезнең шактый тоныкланып калуы борчылу хисе белән искәртеп үтелде. Димәк, бу уңайдан да тәрҗемә вакытында саклык һәм төгәллек кирәк булу аңлашыла. Практик эшчәнлегебездә шуңа омтылу сорала.

Тәрҗемә эшенә алынган кешенең таланты һәм осталыгы өстәвенә, аның зур хәзерлекле булырга тиешлеге, халыкның тарихын һәм культурасын яхшы белергә тиешлеге сөйләшүдә шулай ук ассызыклап узылды. Әнә шул сыйфат җитмәгән очракта килеп туган күңелсез күренешләр искә алынды. Киләчәктә болар кабатланмаска тиеш.

Илебездәге милли әдәбиятларны баету һәм үзара якынайту чарасы буларак киләчәктә тәрҗемә эшен яхшырту буенча мөмкинлекләр турында да дискуссиядә катнашучылар җитди уйландылар. Башка әдәбиятлар үрнәгендә тәрҗемә процессын тагын да камилләштерү җәһәтеннән кызыклы тәкъдимнәр әйтелде. Мисал өчен, шагыйрь Нури Арсланов, дискуссиядә катнашып, болай дип язды: «Литвалылар үзләренең Соломея Нерисларын тәрҗемә

итүдә бик күркәм эш эшләгәннәр: утызлап танылган рус шагыйрен җыеп, киңәш уздырганнар. Шул утыз арасыннан егермеләп шагыйрь Соломеяны русчага әйләндергәннәр... Безгә дә шуңа охшашрак бер егетлек күрсәтергә ярамыймыни?! Әле бит алда Кол Галиләрне, Сәйфи Сараиларны русча чыгарасы бар. Без һаман уртакул тәрҗемәчеләр белән чикләнәбез».

Шулай ук тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин тарафыннан әйтелгән фикер дә игътибарга лаек: «Грузия, Латвия, Украина, Белоруссия оешмаларында илебез халыклары телен өйрәнүне оештыралар, аерым әдәбиятлар белән аралашырдай махсус белгеч кадрларны хәзерлиләр. Безгә дә бу хакта уйлана башларга вакыт. Чыннан да, заман таләпләреннән артта калмау өчен, безгә бу өлкәдә дә заманча киң колач белән һәм перспектив фикерләп эш итәргә кирәк.

Бу уңайдан дискуссиядә чыгыш ясаучылар тагын бер мөһим моментка аерым тукталып уздылар. Сүз бүгенге тормышта тәрҗемәнең әһәмиятен аңлап җиткермәү очраклары турында бара.

Хәтта аны бөтенләй кирәксенмәүчеләр дә очрый. Мондый караштагы торучылар үзләренең позициясен әдәбият-сәнгать әсәренең гаять нечкә хасиятле һәм бик үк милли үзенчәлекләргә ия рухи күренеш булуы белән аңлаталар. Кайбер уңышсыз тәрҗемәләр вакытында яхшы оригиналның идея-эстетик дәрәҗәсе төшү очракларын мисал итеп, гомумән дә тәрҗемә эшенең әһәмиятен шик астына алалар.

Әмма уңышсыз мисаллардан гына чыгып фикер йөртү чынбарлыкны дөрес чагылдырмый. Тәрҗемә өлкәсендәге матур күренешләр игътибардан читтә калмаска тиеш. Бүген ил һәм дөнья күләмендә дан казанган байтак әдипләрнең иҗаты киң катлау укучыга нәкъ менә тәрҗемә аша барып җитте бит! Әйтик, үзебезнең М. Җәлил иҗатының да дөнья күләм орбитага тәрҗемә аша чыгуы — барыбызга да билгеле факт.

Журнал битләрендә тәрҗемә турында барган бу сөйләшү ачык күрсәткәнчә, хәзер инде әлеге мәсьәләгә әһәмият бирми яшәү мөмкин түгел.

Шулай итеп, әдәбиятыбыз өчен мөһим булган тагын бер мәсьәлә турындагы дискуссия тәмамланды. Алдарак әйтеп үткәнебезчә, анда әдәби җәмәгатьчелек тә, укучылар да киң катнаштылар. Нәтиҗәдә, алынган проблема шактый тирән һәм масштаблы яктыртылды, алда торган бурычлар тагын да ныграк ачыкланды.

Әмма дискуссиядә тәнкыйтьчеләрнең, тәрҗемә буенча белгечләрнең һәм татарчадан русчага тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләрнең көтелгәннән азрак катнашуын да әйтеп китәргә кирәк. Культурабыз һәм әдәбиятыбыз үсешенең әһәмиятле мәсьәләсен тикшергән вакытта аларның актив катнашуы сорала. Тәрҗемә теориясе һәм заман таләпләреннән чыгып карап, бүгенге тәрҗемә практикасын тирәнрәк анализлаган саллы мәкаләләр дә аз булды. Киләчәктә уздырылачак сөйләшүләр тәҗрибәле белгечләр катнашында узса, эшне яхшырту өчен тагын да файдалырак булачак, әлбәттә. Шулай ук редакция укучыларыбызның да киләчәк дискуссияләрдә тагын да активрак катнашуын көтеп кала.

Әдәбиятыбызның-сәнгатебезнең, культурабызның көннән-көн үсүе һәм чәчәк атуы безне куандыра. Әмма бүгенге тормышта халыклар культурасы бер ялгызы гына, аерым гына үсми. Ул башка культуралар белән аралаша-аралаша үсә. Әнә шул матур процесс бүген милли культураларга үсәргә яңа көч бирә. Журнал битендә барган әдәби тәрҗемә турындагы сөйләшү тагын да бер кат шуны раслады.

Шулай ук дискуссия безнең әдәбиятыбызның гомуми хәзинәгә саласы әле бик күп җәүһәрләре барлыгын күрсәтте. Аларны башка тугандаш халыклар белән уртак сөенеч итү буенча алда зур эшләр тора. Хәзер бу мәсьәләдә нык уйланган һәм системалы эш сорала.

Тәрҗемә өлкәсендә яңа үрләр яулау — тормыш таләбе, заман таләбе!

**РЕДАКЦИЯ**

# ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ҖИМЕШЛӘРЕ

Казан — илебезнең көнчыгышындагы халыкларда, бигрәк тә төрки халыкларда милли матбугат булдыруда һәм үстерүдә зур роль уйнаган шәһәр. Ә менә аннан көнчыгышка сузылган дуслык күперен башлап кемнәр салган? Халыклар һәм культуралар дуслыгының чишмә башында кемнәр торган? Хәзерге вакытта төрле республика галимнәренең күз уңында торган мөһим проблемаларның берсе әнә шул. Соңгы вакытта илебезнең төрле шәһәрләрендә бер-бер артлы дөнья күргән китаплар шул турыда сөйли. Бу уңайдан күренекле китап белгече Әбрар Кәримуллинның «Басма сүз тарихыннан» исеме белән Казан дәүләт университеты нәшриятында басылып чыккан яңа хезмәте дә укучыда зур кызыксыну уята[1].

Галим күп еллардан бирле милли китап, татар басма сүзе проблемалары белән шөгыльләнә. Аның 70—80 елларда дөнья күргән берничә монографик хезмәте илебездәге китап белгечләре һәм китап сөючеләр арасында киң билгеле. Ә. Кәримуллинның бу хезмәтләре татар басма сүзе тарихын бер бөтен иттереп күз алдына китереп бастыра. Патша цензурасы куйган киртәләр татар китабының үсешен шактый тоткарлый. Ә. Кәримуллин дөрес күрсәтеп үткәнчә, милли басмалар аша революцион идеяләр таралуы царизмны аеруча борчуга сала иде. Галимнең хезмәтләре бик күп татар басмаларының мәгърифәт идеяләрен генә таратучы түгел, ә бәлки революцион характерда да булуын күрсәтә.

Билгеле булганча, казан татарлары — Россиядәге төрки халыклар арасында китап басу эшенә беренчеләрдән керешкән халык. Моннан 200 дән артык ел элек үк, ягъни 1780 елларда ук, казан татарларында беренче китап басу машиналары күренә башлый. 1800 елда Казанда беренче типография ачыла. Бу татар мәгърифәтчесе Габделгазиз Бурашев оештырган «Азиат» типографиясе була. Ә. Кәримуллин күрсәтүенчә, 1801 елдан 1855 елга кадәр Казанда 576 исемдә китап басылып чыга. Ягъни Россия провинцияләрендә дөнья күргән һәр өч китапның берсе татар китабы була. Казан басмаханәләрендә дөнья күргән китапларның шактый өлешен әдәби әсәрләр, дәреслекләр, иҗтимагый-политик эчтәлекле китаплар алып тора. Әнә шуңа күрә Казан бик күп халыкларның игътибарын үзенә җәлеп иткән дә инде. Көнчыгыш халыклары телендәге китаплар XIX йөзнең икенче яртысында аеруча күп басыла. Россиянең ерак төбәкләрен китап басу осталары белән тәэмин итүдә дә Казан мәгълүм роль уйнаган. 1900 елгы мәгълүматларга караганда, Казанда китап басу эше белән барысы 241 оста, 147 эшче һәм 136 өйрәнчек шөгыльләнгән. «Казан типографияләре, — дип яза Ә. Кәримуллин, — полиграфия техникасы казанышларын куллануда һәм алар белән тәэмин итү ягыннан алганда, башкала типографияләреннән калышмаганнар».

Ә. Кәримуллинның бу хезмәтендә үзбәк басмаларының беренче адымнары яктыртыла. Урта Азиянең мәдәният-мәгърифәт тарихында казан татарларының роле бәян ителә. Мәгълүм булганча, үзбәк китап культурасы тарихында зур роль уйнаган Казан шәһәрен Гафур Гоһәм дә тирән ихтирам хисләре белән искә алган, нәкъ менә татар эшлекләре «үзбәкләргә милли шрифт алып килде» дип басым ясап әйткән иде.

Ә. Кәримуллин хезмәтендә үзбәк басма китабының елга башында торган шәхесләр турында сөйләнелә. Казан университеты типографиясендә каравылчы булып торган Бикчәнтәйнең улы Шаһингәрәй Бикколов әнә шундыйларның берсе була. Ә. Кәримуллин бу гаҗәеп останың биографиясен ачыклый, данлы хезмәт юлын яктырта.

Ата-анасы үлгәч, Ш. Бикколов типографиягә эшкә урнаша. Монда ул унбер ел буена гарәп хәрефләре белән китап баса. Аңа шулай ук рус һәм Көнбатыш Европа телләрендә китап басу серләренә төшенергә туры килә. 1869 елда Ш. Бикколов Петербургка чакырыла һәм Россия Фәннәр академиясе типографиясендә хәреф җыючы булып эшли.

1881 елдан башлап Ш. Бикколов Ташкентта эшли башлый. Аның кулыннан төрле характердагы йөзләрчә китап үтә, бик күп яшьләр китап басу һөнәрен үзләштерә.

---

[1] Каримуллин А. Г. Из истории печатного слова. Казань, 1984.

Үзенә кадәр эшләгән тикшерүчеләрнең хезмәтләренә һәм архивларда эзләнүләренә таянып, Ә. Кәримуллин үзбәк милли матбугатының барлыкка килүе һәм үсеше тарихының кызыклы һәм гыйбрәтле сәхифәләрен ачып сала. Бу игелекле эшне башлап җибәрүчеләр: М. Кәримов, Ш. Бикколов, Г. Яушев, Б. Биктимеров h. б., шулай ук беренче календарьлар, беренче тапкыр үзбәк телендә дөнья күргән «Төркстан вилаяте газеты»ның нәшер ителүе h. б. хакында бик җанлы һәм мавыктыргыч итеп яза ул. Ә. Кәримуллин раславынча, Казаннан килгән оста Ш. Бикколов революциягә кадәр Ташкентта чыккан барлык үзбәк китапларының да диярлек редакторы булган.

Анализлана торган хезмәттә үзбәк китабы тарихының тагын бер сәхифәсе — үзбәк китабы цензурасы да тәфсилле тикшерелгән. Күп төрле чыганаклардан җыелган бай фактик материалларга таянып автор милли китап язмышында патша цензурасының тоткан урыны турында да кызыклы һәм гыйбрәтле итеп сөйли алган. Төркстанда нәшер ителүче теләсә нинди китапны басарга рөхсәт Петербург тарафыннан бирелү милли матбугатны үстерүдә өстәмә кыенлыклар тудырган. Моның нәтиҗәсе буларак: «1884—1893 елларда Ташкентта да һәм гомумән Төркстанда да бер милли китап та дөнья күрмәгән»,— дип билгеләп үтә Ә. Кәримуллин.

Урында көнчыгыш китаплары цензурасы оештырылганга кадәр, ягъни 1905 елга кадәр, бу өлкәдә хәл үзгәрешсез кала биргән. Беренче буржуаз-демократик революциядән соң Төркстанда яңа хосусый типографияләр, литографияләр ачыла. Аларның кайберләре җирле халык вәкилләре кулында була. Ш. Бикколов һәм аның иптәшләре тырышлыгы нәтиҗәсендә үзбәк милли китабының беренче осталары Абдрахман һәм Сираҗетдин Ходжаевлар да китап басу серләрен өйрәнәләр.

Ташкентта Ш. Бикколов эшләгән беренче совет басмаханәсенең барлыкка килүен һәм үсүен тасвирлаган сәхифәләр дә зур кызыксыну уята. Әйе, совет власТеның беренче елларында ук Ш. Бикколовның юбилее юкка гына киң күләмдә билгеләп үтелмәгән. 60 елдан артык китап басу станогында эшләгән бу оста дисталәрчә яшьләрне үз һөнәренә өйрәткән. Юбилей көннәрендә «Төркстан хәбәрләре» газетасы Ш. Бикколовның фидакарь эшчәнлегенә югары бәя биреп, ул «Төркстан крае өчен алыштыргысыз хәреф җыючы булды» дип билгеләп үтә.

Ә. Кәримуллинның хезмәте нигездә Шаһингәрәй Бикколовның тормышын һәм эшчәнлеген генә яктыртa. Ә андый фидакарьләр ул чакта йөзәрләгән була. Алар халыклар дуслыгының, мәдәни бәйләнешләрнең елга башында тордылар. Шуңа күрә милли китап каһарманнарының эшчәнлеген өйрәнми торып, безнең көннәрдә социалистик культураның чәчәк атуын бөтен тирәнлеге белән аңлау мөмкин түгел. Халыклар арасындагы туганнарча хезмәттәшлек сәхифәләрен яктыртучы бу хезмәтнең төп кыйммәте дә әнә шунда.

**Николай МОРАДЫМОВ,**
филология фәннәре кандидаты.
*Ош шәһәре,*
*Кыргызстан ССР*

# ЗИННӘТЛЕ СҮЗЛӘР ХӘЗИНӘСЕ

Бу кызгылт тышлы калын китап затлы шкатулканы хәтерләтә. Тылсымлы-зиннәтле сүзләр белән тулы томның [1] тышлыгына күк гөмбәзен терәп торырдай символик мәһабәт агач ясалган. Көнчыгыш халыкларының күп гасырлы, күп телләргә тәрҗемә ителгән поэзиясе, чыннан да, тамырлары мең еллар тирәнлегенә киткән, җилдә шаулаучы мәңге яшел ябалдашы кояшка үрелеп, киләчәккә омтылган әзмәвер агач рәвешендә күзаллана.

Китапта Көнчыгыш поэзиясенең төрле чорларга караган классик үрнәкләре тупланган. Борынгы һинд гимннары «Махабарата», «Рамаяна», Санкрит антологик лирикасы... Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Гомәр Хәйям рабогыйлары, Рудаки, Сәгъди, Хафиз, Җәми, Низами, Физулиның лирик миниатюралары, газәлләре, мәснәвиләре... Хәразминең «Мәхәббәтнамә»сеннән өзекләр, Алишер Нәваи, Бабур, Мөкими, Рабиндранат Тагор һәм башка бик күп шагыйрьләрнең шигырьләре... Хәзерге заман Бангладеш, Пакистан, Индонезия, Төркия, һиндстан поэзиясе үрнәкләре — менә җыентыкка тупланган рухи хәзинәләрнең кайберләре.

---

[1] Көнчыгыш шагыйрьләре Сергей Северцев тәрҗемәсендә. М., «Наука» нәшрияты. 1984. 608 б.

Хронологик колач белән (безнең эрага кадәр өченче-икенче меңьеллыклардан бүгенге көнгә кадәр) бик күп исемнәр бирелгән булса да, китап сирәк була торган бөтенлек һәм бердәмлек тәэсире калдыра. Бу бердәмлек кинәт кенә тумый, чөнки китапта тасвирлау стандарты буларак кабул кылырлык шартлы «шәрык колориты» юк. Хикмәт шунда: С. Северцев әсәрләргә авторча якын килеп, үз «ачкычы»н таба алган һәм, шул рәвешле, аларның үзенчәлекләрен һәм индивидуаль йөзләрен тулырак ачуга ирешкән. Стильләр, жанрлар, образлар никадәр төрле булмасын, аларны бер нәрсә — тәрҗемәченең иҗади индивидуальлеге берләштерә. Оста актер кебек С. Северцев, үзе булып калган хәлдә, образга керә белә. Тәрҗемәли торган шагыйрьнең эчке дөньясына тирәнрәк кергән саен, үзе өчен яңа, вакыт-вакыт читрәк стихиягә тулырак бирелгән саен, тәрҗемәдә аның үз йөзе ачыграк күренә. Тәрҗемәнең катлаулы диалектикасы шундый.

Шагыйрь һәм тәрҗемәче Сергей Северцев исеме укучыларга яхшы таныш. Ул — Н. Тихонов, Б. Пастернак, А. Тарковский традицияләрен дәвам иткән совет тәрҗемә мәктәбенең урта буын вәкилләреннән. Аның остазлары арасында Л. Пеньковский һәм В. Державин да бар. С. Северцев тәрҗемәләренә югары сүз культурасы, Көнчыгышның рухи мирасын тирәнтен белү, сайлап алынган әсәрнең асылына төшәргә чын-чынлап тырышу, аның җанын аңларга омтылу хас. Аның бөтен иҗади практикасы С. Северцевның тәрҗемәне үле «калькалау» яки җимешсез бизәк итеп аңламавын раслый. Тәрҗемәче төп нөсхәнең бүтән тел укучысы өчен яшерен матурлыкларын ачуны, оригиналны яңача укуны максат итеп эшли.

Тәрҗемәче буларак, С. Северцевның тагын бер мөһим сыйфаты бар: иҗади даимилек. Менә инде кырык елга якын ул совет һәм чит ил Көнчыгышы халыклары поэзиясен, шул җөмләдән татар шигъриятен дә тәрҗемә итә. Ул Муса Җәлилнең фронт лирикасыннан кайбер шигырьләрне һәм «Моабит дәфтәрләре»н, бүтән шагыйрьләребез әсәрләрен уңышлы тәрҗемәләде.

«Мәңгелек агач» җыентыгына Габдулла Тукайдан тәрҗемә ителгән бер цикл шигырьләр кергән. Татар шагыйрен хаклы төстә Көнчыгышның дөньякүләм шөһрәтле әдипләре сафына куя торган әлеге тәрҗемәләр Тукай иҗатының бүтән шәрык классиклары белән эчке тирән тугандашлыгын ачарга ярдәм итәләр. Тукай әсәрләре бу асылташлар арасында югалып һәм тоныкланып калмый, киресенчә, тагын да матуррак балкый, байтак уртак, әмма үзенчә кабатланмас нәкышләре белән күзне назлый.

Әлеге тугандашлыкның тирән нигезен татар поэзиясенең башка шәрык культуралары белән борынгыдан килгән тарихи бәйләнешы билгеле. Философик нигезләр, күп кенә иҗади һәм эстетик принциплар, шигърият үзенчәлекләре уртаклыгы. Әйтик, Тукай «газәл» техникасын нечкәләп белгән, рәдиф рифма белән осталарча эш иткән, шәрык, башлыча, гарәп шигырь төзелеше нормаларын үз күргән. Шуңа игътибар итәсең: Көнчыгыштагы бүтән шагыйрьләрнең әсәрләре белән бер сафка куелган җыйнак кына циклында аның үзенә генә хас иҗади үзенчәлеге тагын да ачыграк күренә. Иҗатының җитлеккән чорында Тукай шәрыкча бизәкләүдән, экзотик чуарлыктан, купшы сүзләрдән качкан. Аның язуы төгәллек һәм гадилек белән аерылып тора. Тукай шәрык шигъриятенең уртак үзәненнән атлап кына калмады, бер үк вакытта ул, яңа формаларга һәм жанрларга мөрәҗәгать итеп, шәрык шигъриятенә Көнбатыш поэзиясе, барыннан да элек, реалистик рус поэзиясе казанышларын кертүгә юл ачты. Революциягә кадәр Көнчыгышның күп кенә шагыйрьләре Пушкин, Лермонтов, Кольцов иҗатларына нәкъ менә Тукай шигырьләре аша килделәр.

Гаҗәеп бай бу җыентыкка революциягә кадәрге бүтән татар шагыйрьләренең иҗатлары кермәве кызганыч. Әйтик, нечкә лирик һәм шигырь техникасы остасы Дәрдмәнд поэзиясе китапның кабатланмас ямьле сәхифәләреннән берсен тәшкил итә алыр иде. Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Сәгыйть Рәмиев, Шәехзадә Бабич шигырьләре дә рус укучыларының революциягә кадәрге Көнчыгыш хәзинәләре турында күзаллауларын шактый киңәйтер иде. Бу мәсьәләдә мин тәрҗемәчене гаепләргә җыенмыйм. Төп бәла шунда: без үзебез шигърият казанышларын бик начар пропагандалыйбыз, рус укучыларына аны барлык матурлыгы һәм күләме белән тәкъдим итә белмибез.

Менә бер генә мисал. Җыентыкта борынгы үзбәк шагыйре Дурбәкнең «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасыннан өзек китерелгән. Бу өзек тулаем әсәр хакында шактый тулы күзаллау бирә. Ә бит болгар-татар шагыйре Кол Галинең шул ук киң таралган сюжетка язган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы ике йөз елга диярлек алданрак иҗат ителгән! Кайбер белгечләр Дурбәк поэмасында Кол Гали йогынтысы сизелә, «Кыйссаи Йосыф» Дурбәк әсәре өчен беренче чыганаклардан булгандыр дип саныйлар...

Кызгылт тышлы котыйчыкны хәтерләткән бу китап — «Мәңгелек агач» җыентыгы — күпмилләтле совет әдәбияты тормышында күренекле вакыйга, культураларыбыз арасындагы үзара бәйләнешларның ныгый баруын раслаучы күркәм дәлил.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# ТУГАНЛЫК ТАМЫРЛАРЫ

Илебез халыкларының гасырларга сузылган дуслык бәйләнешләре, тарихи хезмәттәшлеге һәрвакыт игътибар үзәгендә кала. Халыклар арасындагы шундый бәйләнешләрне барлау безнең фәндә һәм әдәбиятта да күптән башлана. Революциягә кадәр үк инде бу юнәлештә шактый тәҗрибә һәм мәгълүмат тупланган. Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинев хезмәтләрен генә искә төшерик. Бу эш безнең чорда кабат җанлану дәверен кичерә һәм яңа казанышларга ирешә. Әле күптән түгел генә филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллинның бу темага караган «Из истории печатного слова» (Казань, 1984) китабын укыган идек. Инде менә үзбәк галиме Шерали Турдыевның «Әдәби хезмәттәшлек җимешләре» (Ташкент, 1984) китабы кулыбызга керде.

Хезмәт үзбәк-татар культура бәйләнешләрен өйрәнүгә багышланган. Анда 1890 еллардан алып Бөек Ватан сугышына кадәрге чорда ике халык арасындагы мәдәни хезмәттәшлек, әдәби бәйләнешләр һәм аның әһәмияте игътибар үзәгенә куелган. Җәмәгатьчелек игътибарыннан һәм тикшеренүләрдән берникадәр читтәрәк калып килә торган фактларны барлау, өйрәнү әдәбиятыбыз тарихын, аның үзенчәлекләрен тагын да тирәнрәк яктыртырга мөмкинлек тудыра. Ш. Турдыев туплаган материаллар татар революцион демократлары — Тукай һәм аның сафташлары эшчәнлеген тагын да тогәлрәк күз алдына китерергә ярдәм итә. Г. Тукайның тууына йөз ел тулган елда бу темага кагылышлы яңа материалларны мәйданга куюы зур хуплауга лаек. Без дә төп игътибарны шул мәсьәләгә юнәлтергә булдык.

Ш. Турдыев китабында Тукай чоры татар революцион демократиясенең чишмә башы, җирлеге, колачы, үсеш баскычлары турында уйланулар зур урын алып тора, бу революцион-демократик хәрәкәтнең, бөтенроссия мөселман халыкларын иңләгән социаль хәрәкәт булганлыгы раслана. Россиядә буржуаз-демократик революция якынаюы илнең колониаль өлкәләре халыкларын да сискәндереп уята. Көнчыгыш урта гасырчылык тереге саналган төбәкләрдә дә феодаль-клерикаль идеологиягә каршы көрәшкә омтылучы кешеләр мәйданга чыга башлыйлар. Мондый хәрәкәт татар халкы арасында, билгеле тарихи сәбәпләр тәэсирендә, чагыштырмача, җитлеккән рәвештә күренә. Шуңа күрә алдынгы татар укымышлылары Казахстан, Урта Азия кебек өлкәләрдәге яңалыкны яклаучы көчләргә ярдәм, юл-юнәлеш күрсәтүче ролен дә өсләренә алганнар. Үзбәк халкы, үзенең Саттархан кебек укымышлылары эшчәнлегендә, рус телен өйрәнү аша традицион культураны яңарту юнәлешен билгели. Бу юнәлешне ачыклауда, үзләштерүдә Саттарханга (1890 елларда) татарлардан артиллерия офицеры («Тупчы түрә») Мөхәммәтйосыф Еникеев зур ярдәм күрсәтә (25 б.). Бер төркем татар яшьләре 1904 елда Еникеевлар өендә драмтүгәрәк оештыралар. Алар бу түгәрәккә үзләренең үзбәк дусларын да җәлеп итеп, күмәк көч белән төрек шагыйре Нәмыйк Кәмалның «Мәхәббәт баласе» дигән пьесасын уйныйлар (27—28 б.).

1905—1907 ел революциясе дулкынында татар революцион-демократлары бу яңару хәрәкәтен яңа баскычка күтәрделәр. Бу хәрәкәтнең илкүләм-милләтара характер алуы һәм казанышлары Г. Тукай иҗатында аеруча калку чагыла. Г. Тукай шигырьләре кардәш халыкларның уртак авазы, уртак эстетик казанышы буларак та мәйдан тота. Ш. Турдыев китабында, мәсәлән, үзбәк халкы арасында аның нәкъ шулай кабул ителгәнен расларлык фактлар китерелә. Г. Тукайның Казанга кайтуына бер ел үтәр-үтмәс үк инде аның әсәрләре «Төркстан вилаяте газеты»ның 1908 ел, 24 август санында үзбәк укучыларына тәкъдим ителә (35 б.). Газетаның 1908 ел, 20 октябрь санында да редакция «Яшен» турында белешмә һәм «Яшен»нән материаллар урнаштыра (36 б.). Ш. Турдыев бу игътибарның сәбәбен дөрес билгели: «Чөнки... шигырьләр фәкать реакцион татар руханиларын, ...байбәтчәләренең әшәкелекләрен генә түгел, бу тискәре типларның Төркстандагы ишләрен дә фаш кыла иде»,— ди ул (36 б.). Идея-эстетик аныклыгы, эзлеклелеге, сәнгатьчә төгәллеге нәтиҗәсендә Г. Тукай сатирасы башлангыч адымнарында ук, ерак өлкәләрдәге кардәш халыклар игътибарын казанган: ерак юлны якын итеп, «Төркстан вилаяте газеты» битләренә барып кереп алган. Аерым очрак, аерым кеше казанышы гына түгел, киң җирлеккә нигезләнгән көчле социаль хәрәкәт авазы һәм коралы булганга ул шул игътибарны казана алган.

Идеология өлкәсендә феодаль, клерикаль көчләргә һөҗүм Тукайлар чорында барган саен ныгып, тирәнәеп, күпьяклырак булып киткәнен күрәбез. Яңа, дөньяви мәктәп өчен көрәш, Идел буенда тамырланып, Урта Азия киңлекләрендә дә җәелә: Урта Азия шәһәрләрендә яшәүче татар укымышлылары «үзләренең балалары өчен» «ерак читтә дә» яңа тип («җәдит») мәктәпләр оештыралар: җирле халыктан булган дус-ишләренең балаларын да мондый мәктәпләргә теләп кабул итәләр. Җирле укымышлылар бу мәктәпләр тәҗрибәсе белән кызыксыналар,— аларның метод һәм программалары белән танышып, аны җирле шартларга яраштырып үзгәртеп, үзләре дә куллана баш-

…ывилар (41 б.). Матбугат, театр өлкәсендә дә шундый ук җанлану, яңару процессы барганын күрәбез. «Сәйяр» труппасының әледән-әле Урта Азия шәһәрләренә килеп чыгуы җирле һәвәскәр драмтүгәрәкләр эшен җанландыра, Хәмзә кебек драматурглар җитлегүенә көчле тәэсир ясый. К. Мотыйгыйның 1914 елда концертлар белән чыгышы җирле газетада: «...Безнең — җыелышларга, сәхнәләргә чыккан җыр, музыка сәнгатебез юк. Җыр юклыктан түгел, үрнәк күрсәтүче, юл күрсәтүче юклыктан... Милли театрыбызны юлга салган кебек, милли музыка сәнгатебезне дә гайрәтле яшьләребез юлга салып җибәрерләр дип өметләнәбез...» — дигән кебек проблема буенча җитди сөйләшүләр башларга сылтау була (32 б.). Мондый фактлар — культура яңарту, гади бер мәдәни-агарту хәрәкәте генә түгел, феодаль, клерикаль көчләр кулыннан тарих мәйданын тартып алу өчен кискен, хәлиткеч көрәшнең үзенчәлекле чагылышы иде. Бу хәрәкәткә һәр адымда, һәр юнәлештә иң кискен һәм күпьяклы каршылыкларны җиңеп мәйдан тотарга туры килә. Царизм, жандармериядән алып туң гореф-гадәтләргә кадәр булган консерватив көчләр бу хәрәкәткә бердәм каршылык күрсәтәләр. «Сәйяр» труппасы Төркстан гастрольләренә кузгалган көндә үк алар эшчәнлегенә комачау тудыру—кырыс күзәтү астына алу турында Казан жандармерия идарәсеннән Төркстан өлкә охранка бүлегенә ашыгыч, яшерен телеграмма оча (47—48 б.). Төркстанда мәгариф, мәдәният өлкәсендә үзгәрешләр кертергә тырышкан өчен генә Мирмухсин Шермөхәммәдевне, кяфер дип, руханилар үлем җәзасына хөкем итәләр дә, ул бу эзәрлекләүдән Уфадагы татар мәдрәсәсе «Галия»гә китеп котыла. Татар матбугаты, аеруча «Шура» журналы Төркстан реакцион руханиларының бу нахак һөҗүмнәренә каршы каты ризасызлык белдереп чыга (52 б.). Әйе, бу киеренке көрәштә реакциянең шәфкатьсез һөҗүменә яңалык көчләре үзләренең ныгый, чыныга барган бердәмлекләрен генә каршы куя алганнар.

А. И. Герценнең рус революцион демократлары турында әйткән «килер давылларның яшь штурманнары» дигән сүзләрен безнең Тукайлар эшчәнлегенә карата да кулланып булыр иде. Алар, дөрестән дә, хәрәкәтне давылларга илтеп җиткерә алдылар, зур давыллар аша, Г. Ибраһимов кебек, штурманнар булып үтә алдылар. Ш. Турдыев китабында бу давыллы этапка мөнәсәбәтле материаллар да бар. Октябрь җиңгән көннән, социализмга җирлек хәзерләү рәвешендә, мәктәп, матбугат, театр, әдәбият һ. б. өлкәләрдә революцион демократлар программасын тәгәл гамәлгә кертү башлана. Урта Азиядә бу мөһим эшләрне башкаруда татар укымышлылары да актив катнашалар. «1918 ел башларында Н. Сакаев Төркстан армиясендә «Шәрык» труппасын оештыра. 1920 ел башларында аны, режиссер итеп, Ташкентка чакыралар» (61 б.). 1919—20 елларда Камал I, С. Сәйдәшев Сәмәрканд һәм Кәттә Курган шәһәрләрендә театр эшен юлга салалар (62—63 б.). «Иштиракиюн» («Социализм») газетасының 1919 ел, 19 октябрь санында С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә «Интернационал» («Бәйнәлмилəл») тексты үзбәк телендә дөнья күрә. Яңа культура эшләрен оештыру-җанландыруда, әйтерсең лә, Г. Тукай үзе дә катнашадыр кебек. 1920 ел апрелендә Үзбәкстанда Тукай көннәре уткәрелә. Шул уңай белән «Иштиракиюн» газетасының 1920 ел, 15 апрель санында «Көнчыгыш шагыйре Габдулла иптәш Тукай» дигән мәкалә урнаштырыла (68 б.); уку китапларына, җыентыкларга шагыйрьнең әсәрләре кертелә. Әмма бу чорның уртак идеаллары инде шигырьдә генә түгел, конкрет фактларга нигезләнгән публицистик прозада тулырак, тәэсирлерәк гәүдәләнеш таба. Моны Г. Ибраһимов иҗаты мисалында күрә алабыз. Үзәк Мөселман Комиссариатындагы эшчәнлеге Г. Ибраһимовның кардәш халыклар белән элемтәләрен яңа баскычка күтәрә. Аның әдәбият фәнендә марксизм методын үзләштерүгә һәм социалистик яңарыш дошманнары ак эмигрант идеологларын фаш итүгә багышланган хезмәтләре, үз вакытында Г. Тукай шигырьләре кебек, шунда ук, башка республика җәмәгатьчелегенең дә игътибарын казана. Мәсәлән, аның «Кара маяклар» әсәре 1926 елда, әүвәл, «Кызыл Үзбәкстан» газетасы битләрендә басылып килә; соңра, «Кара җитәкчеләр» дигән исем белән үзбәк телендә аерым китап итеп чыгарыла (69 б.). 1927 елда Үзбәкстан җәмәгатьчелеге Г. Ибраһимовның юбилеен киң билгеләп үтә.

Әйе, Ш. Турдыев зур һәм кирәкле эш башкарган. Дөрес, кереш һәм өч бүлектән торган бу хезмәтнең һәр бүлеге бер тигезлектә эшләнгән дип булмый. Революциядән соңгы бәйләнешләрне күзәтүгә багышланган икенче, өченче бүлекләр тирәнрәк, зуррак гомумиләштерүләргә мохтаҗ. Бу хезмәт аерым төгәлсезлек, чатаклыкларны башлап җибәрүче булып калмасын иде дигән теләктән чыгып: «Меңнәр яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын драма әсәрләре исемлегенә кертү (26 б.), «Яшен» журналының исеме һәр урында «Яшел» дип басылу, М. Фәйзине — Р. Фәйзи дип, аның «Яшьләр алдатмыйлар» пьесасының исемен «Яшьләр алданмыйлар» дип күрсәтү (64 б.), «Нәҗиб Ломовой» дигәндә «Ломовой»ны — «ломать» — «бозмак» сүзеннән дип аңлату (94 б.) кебек кайбер төгәлсезлекләрне күрсәтмичә үтә алмыйбыз.

Кыскасы, автор кызыклы һәм әһәмиятле китап чыгарган. Аны күпьеллык эзләнүләрен шулай уңышлы йомгаклавы белән котлыйбыз.

**Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ҖАНЫГЫЗГА СУКМАК САЛЫЙМ...

Харрас Әюповның 1985 елда басылган «Каен балкышы» исемле шигырьләр китабын быел яз башында гына кулыма алдым. Яңа китапларны, яңа дус тапкан кебек, һәрчак дулкынланып укыйсың:

Байлык-фәлән теләмәде безгә,
Кичерсәк тә гәрчә кыен чак —
Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Берәребез юлга җыенсак.

Байлыгымның олылыгын тоеп
Ышанып керәм якты көнемә;
Дәверләрне ачар ачкычым бар —
Рәхмәт яусын туган телемә!

Туган тел барыннан да битәр әти-әни, сөйгән ярлар, дус-ишләр теле, тирән серләр, кайнар мәхәббәтләр теле. Х. Әюпов күбрәк шулар турында уйландыра. Тиз үзгәрешле, ашкынулы, фәнни-техник сюрпризлар белән тулы тормышыбызга бу шагыйрь сугыш артының югалтулар сагышын кичергән авылында, тын, идиллик табигать кочагында үскән самими малай күзләре белән карый. Кояш баешларында һәлак булган әтиләр, абыйлар кайгысыннан, тол хатыннарның моң-зарларыннан мул сут алып, күңелендә нык тамырланган сагыш, юк-юк та, төрле рәвешләр, мотивлар алып, аңарда үзен һаман да сиздереп килә:

Без дә — Җирнең бер җәйләре генә,
Бер генә кат яфрак ярабыз.
Шатлык булып киләбез дә җиргә,
Сагыш булып китеп барабыз...

Х. Әюповның лирик герое,— минем күзаллавымча, бәдәнендә көч-куәт, йөрәгендә яшәү яме кайнап торырга тиешле яшь ир. Үлем-китем тирәсендәге уйлар аңа болай ябышмаска тиеш иде. Әмма ул «исеп узган бер җил генә кеше»... шикелле төшенке уйларга чумып, бик еш көрсенә:

...Бушандым,
Ярый, яшәүнең
Ышану-йоласы бар.
И, әле бар бит безнең дә
Күбәләк буласылар!..

һәр тойгының, фундаментка утыртылган өй шикелле, социаль, психологик нигезләре була. Тәнкыйть Харрастагы бу сәеррәк мотивларга ничек карый, аларны ничегрәк бәяли икән? Яшь тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәев үз китабында («Кешем, асылың кем?» 1984) Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Г. Рәхим, Зөлфәт, М. Әгъләмов кебек шагыйрьләр белән бергә, безне кызыксындырган автор иҗатына багышлап та аерым мәкалә урнаштырган. Тәнкыйтьче Х. Әюповның «Ышаныч», «Кояшлы яңгыр», «Каен балкышы» җыентыкларындагы иҗатын күздә тотып, «йөзе ачыкланган, җитлеккән шагыйрь булуын раслый да, күзаллавын түбәндәгечә конкретлаштыра: «Х. Әюповның иҗаты абыйларыннан калган иске күлмәкне киеп үсүче малай кебегрәк. Ә малай үсә, торабара аңа бу күлмәк кысан була башлый. Югарырак үрелгәндә, җиңнәреннән терсәкләре күренеп киткәли...» һәм тәнкыйтьче аның «шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен югарырак күтәрергә комачаулый торган» кимчелекләрне барларга керешә: кабатлаулар, сүз ярлылыгы, форма ярлылыгы, бер үк шигъри үлчәмнәр... Мәкаләдән мин үземне кызыксындырган сәвальгә тәки җавап таба алмадым: тәнкыйтьче шагыйрь иҗатына социаль аспекттан торып бер караш салмыйча китте. Ә бит ул мәкалә башында үзен тәнкыйть вәкиле итеп танытып, шагыйрьгә үзе күрмәгән барлык якларын күрсәтергә алынган иде.

Сизенүемчә, соңгы еллар татар шигырь тәнкыйтендә поэтика мәсьәләләре белән кызыксыну тенденциясе шактый көчле. Хәзер моңа сөенүчеләр күп. Әмма мин шагыйрь Зөлфәтнең «Татарстан яшьләре» газетасында (1984 ел, 19 май саны) урын алган бер фикерен онытмыйм: «Бездә поэзия тәнкыйте юк дәрәҗәсендә. Рецензияләрдә, мәкаләләрдә сүз күбрәк шигырь төзелеше, рифмалаштыру, ритм кебек әйберләр тирәсендә әйләнә. Әсәр кайсы ягы белән социаль тормышка барып ялгана, гомум-поэзия фонында ул нинди яңгыраш ала — менә нәрсәләр борчырга тиеш чын тәнкыйтьчене».

Шагыйрь сүзләреннән чыгып, мин еракка-ракка китеп уйлыйм. 20—30 еллар татар совет әдәби тәнкыйтендә шактый нык тамыр җибәреп, аннан соң да, үзен ямьсез яктан сиздереп килгән вульгар социологизмга кар-

шы кәрәшә-кәрәшә, чама тойгысын җуеп, икенче бер якка чалулана башлау галәмәте түгелме бу?

Танкыйть үзенең фәнни эрудициясен, сәнгатьчә зәвыгын, теоретик гөман итуләрен дәлилли, раслый торгач, үзенең башка бурычын — әдәбият белән тормыш бәйләнешен тикшерүне, социологик анализны тәмам оныта, җуя башлады шикелле. Ә дөньяга караш, идеология һәм идея белән азыклану кебек катлаулы проблемалар, әйтерсең, үткән классик әдипләр өчен генә яши. Танкыйть заман шагыйрьләренә нисбәттә бу мөһим күренешләрне читләтеп үтә. Нәтиҗәдә шагыйрь иҗатындагы социаль-психологик факторлар, моментлар билгеләнми, үсеш, үзгәреш конкрет барланмый һәм шагыйрь үзе дә объектив, тулы бәя ала алмый кала. Хәер, зур гомумиләштерүләр ясарга ашыкмыйча, Ф. Зөлкарнәев китабына килик әле.

Танкыйтьче Х. Әюповның иҗат кредосы «Мирас», «Шелтә», «Гомер», «Әйтегезче», «Төнге күктә кемдер шырпы сыза» кебек шигырьләр билгели дип гөман итә. Минемчә, лирик герой биографиясенең аерым моментларын ачкан бу әсәрләр һич тә Харрасның төп индивидуальлеген характерламый. Дөресен әйтим, бу шагыйрьнең китапларын кулыма алсам, тагын шул ук Зөлфәтнең матбугаттагы бер чыгышын хәтерләп куям. Безнең яшь шагыйрьләрнең бер төркеме «башны кискәгә салып язган булып кылан»са, икенчеләре елак дигән иде ул. Менә шул «елак»лар арасына Зөлфәт, тәгаен, Әюповны да кертәдер дип шикләнәм. Чынлап та, елау Харрастагы зур бер поэтик халәтне тәшкил итә. Аның шигырьләрендә, мәсәлән, чулпы чыңнарыннан асыл ярлар гына түгел, чорлар елый, метафорик гасырлар эте елап өзгәләнә, хуҗасын эзләп, ат елый... Күзен сөртергә кулмәк булмаганга, борынгы әдәби персонаж Ягкуб елый, ялгызлыктан гаҗиз калып, заман карты елый... Аңардагы каеннар да күз яшьләре түгә, кара моңга батып, төн дә елый, сандугачлар да сайрамыйлар, бары тик елыйлар гына... Ә лирик геройның үзен әйткән дә юк! Елау, моң, бәгырь әрнү хәтта халәт чикләреннән дә ташып чыгып, Харрас иҗатындагы пространстволы фонга да әйләнеп куя:

Тоташ гел моң гынадыр инде
Җир белән күкләр арасы.

Бу кадәр сентиментальлектә лирик геройның фикерләвенчә, хәтта күзәнәкләренә үтеп кергән «гомер узу», «җирдән китү» кебек фаталь хакыйкать гаепле. Харрас, минем карашымча, шул хакыйкатькә чамадан тыш зур игътибар бирә һәм аңа дөнья серләренә әле генә төшенә башлаган малай күзләре белән карап кабарта:

Гасырлардан барлыйм — кешеләр юк!
Бу югалту җирдә кемгә хаҗәт?
Кешелекне йота бара вакыт,
Беркем гаҗәпләнми —
Шунсы гаҗәп...

Шул ук вакытта, нарасый бала акылы сыман, яшәеш законнары каршында үз гаҗизлеген тоймавы белән күңелгә керә ул:

Китә алмамдыр җирдән,
Юкса дөнья
Кемгә калыр, нигә юлыгыр?
Яз-көзләрен барлап чыгыйм диеп,
Йөрү генә минем бу гомер...

Гомер төшенчәсен үзенчә, мәңгелек масштабындагы мизгел, нокта гына санап һәм яшәүгә гашыйк җан буларак, шагыйрь гомер үтүен аерым бер нечкәрү, тойгылану белән кичерә. Шагыйрь вакытны каһәрли. Беренче очрашуларда Харрас поэзиясендәге Дон Кихотлыкны җитди рәвештә кабул итәсе килми, аны хәтта мистикада, эгоизмда гаеплисең. Чөнки үлем ничаклы зур фаҗига, гаҗизлеккә салган хәл булмасын, кеше рухы белән аңардан өстен тора. Әнә бит яшьләй үлемгә дучар булуын белгән Г. Тукай материалист оптимизмы белән әйткән: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы»... М. Җәлил баш очында палач балтасы эленеп торган коточкыч халәттә дә үлемнең үзен җиңәрлек рухи көч тапты. Фронтта һәлак булган Ф. Кәрим: «Үзем үлсәм, балаларым кала минем гомерем булып, Ватаным»,— дип, шәхси үлем-китеменә дә чын гражданлык карашы белдерде...

Әмма Харрасның поэтик фикерләвенә ныграк төшенгән тәкъдирдә, чагыштыруларның, бигрәк тә каршы куюларның урынсыз булуына төшенәсең. Аның лирик герое да шәхси җанына хөр, ирекле мөнәсәбәттә. Хәтта кеше булуына да «табигатьнең үзүзен тойган заты» (Ф. Энгельс) дигәндәй якын килә ул:

Мәңгелек буйлап Җиһанга
Таралган безнең дәвам.
Әле ут булып янам мин,
Әле су булып агам.

Һәм шул өзлексез процесста яңа, бәхетле әверелеш:

Инде менә мин дә кеше җирдә
Иртә тудым микән, соң микән?..

. Харрасның лирик герое кеше булуның катлаулы миссия икәненә ачык төшенә һәм Җиһан, мәңгелек, яшәеш каршында кешелекне яшәтү өчен үзен чиксез җаваплы итеп тоя. Шагыйрьнең фикерләвендә Кеше, Гомер, Яшәү кебек төшенчәләр артык гомумиләшкән, хәтта абстрактлашкан. Анда яшәү өчен хәвефләнү тойгысы да еш кына абстракт гәүдәләнә. Мәсәлән, аның бер шигырендә яшел бәбкәләрне тилгәннәрдән яшел чирәмнәр саклый. Тик вакыт чирәмне уңдыра, корыта, бәбкәләргә куркыныч туа:

Ә бәбкәләр һаман яшел,
Күкләр һаман шулай биек —

Алданалар мескенкәйләр
Тилгәннәр күрми диеп.

Нинди тәскә сыенырга,
Кайсы тәштә чүгәләсе? —
Безне кемдер сагалый кук -
Җир өстендә күләгәсе.

Мин шагыйрьнең сагышын аңлыйм. Хәвеф, сагыш — Харрас поэзиясенең төп нервысы. Ф. Зөлкарнәев исә Х. Әюповның мәхәббәт турында язганда, вакытны онытып торалмау хасиятенә гаҗәпләнә. Янәсе, мәхәббәт, тылсым-сихер булып, гомер-гомергә шагыйрьләрне дөньядан, вакыттан ваз кичтергән... Харрасның сәҗдә торткан темасы башка шул. Аны «Иске нигез» шигыре бик ачык күрсәтә:

Әй урыны.
Монда вакыт
Бер таба да акмый бугай!

Тынгы бирми буш нигезләр...
Бер көн берәү минем кебек,
Бушап калган Җир шарына
Башын иеп килер кебек...

Харрасның яшәү концепциясе буыннар турында фикерләү белән органик бәйләнә. Ул үзенең лирик героен да «нәсел тәрәзәсе» итеп саный. Шуның аша дөньяга әллә ничә буын карап тора, герой алар белән яши:

Әткәмә һәм ерак бабайларга
Мин быелгы җәйнең гөлләрен,
Урманнарын, суын күрсәтермен,
Улларымның ничек көлгәнен.

Харрасның лирик герое халык рухы белән бергә, берлектә. Заманга да ул күбрәк сыналган кануннар, әхлак үлчәмнәре белән килә, бәя бирә. Үткәннәр киләчәк белән бәйләнгәндә генә Җирдә яшәү тантанасы буласына шагыйрь ышана... Әйтелгәннәрдән чыгып, мин Х. Әюповны фәлсәфи шагыйрь дияргә җөрьәт итәр идем. Әмма бу турыда Ф. Зөлкарнәев катгый әйтә: «Х. Әюпов — асылда хис-тойгы шагыйре, аны беркем дә фәлсәфи шагыйрь димәс...»

Тагын бәхәсләшә барып, бу фикердәге бер каршылыкка ишарә итәргә кирәк. Әйтерсең, хис-тойгы шагыйре булу — фәлсәфилеккә каршы килә һәм киресенчә. Ф. Зөлкарнәевның фикерләвендә җитмешенче еллардагы бер төркем яшьләрнең поэзияне тойгы шигыре, акыл шигыре дип бүлгәләү, каршы кую ялгышы бар.

Фәлсәфи лириканың җитди вәкилләре кебек, Харрас та вакыйга, хәрәкәт тасвирына тартылмый, ә образ-уй, образ-кичереш, образ-идея сурәтләүгә басым ясый. Сүздәге уй тыгызлана, образлылыкка шагыйрь халыктагы гыйбарәләрне, фольклор мотивларын, ассоциативлыкны кыю куллану аркасында ирешә, һәм шулай ук, Харрасның үзенчәлекле иҗат манерасы — абстрактлыкта, бушлыкта образ ясый алу осталыгы зур роль уйный.

Төнге күктә кемдер шырпы сыза —
Офыккача сузыла эзләре,
Тик кабынмый никтер шырпылары...
Кайсыгызның нәрсә эзләве?

Х. Әюпов, һичшиксез, фәлсәфи лирика жанрында көчле. Ә менә лириканың башка тармакларында, әйтик, мәхәббәт, гражданлык лирикаларында, политик лирикада шагыйрь үзен тапмаган әле. һәрбер сәнгать әсәре кебек шигырьнең оешуы өчен дә драматизм моменты кирәк. Шагыйрь моны күбрәк кичереп таба. Харрасның лирик герое авылда, табигать кочагында үскән кеше икәнлегенә ишарә ясалган иде. Миграция дулкыны аны, үз, табигый яшәешеннән аерып, шәһәргә китерә. Хәзер ул туган төбәген, яшьлеген, ярын сагына. Шул җирлектә «Туган якка үрелеп карар идем, болытларга башым тигәнче» яки «Араларда язмыш киртәләре, очрашулар харам... тыелган!» кебек драматик мотивлар үсеп чыга. Ләкин болар — уйланма, әдәби традицияләр тәэсире белән генә туган нәрсәләр. Иң мөһиме: мәхәббәткә, үз гражданлык тормышына нисбәттә Х. Әюповта зур шагыйрьләрдә була торган оригинал концепция юк.

Кыскасы, шагыйрьнең бүлгәләнүе һәм таркалуы чиле-пешле шигырьләр язылуга китерә икән, бу турыда җитди уйланырга кирәк аңа.

Ә соң сентиментальлек белән ни эшләргә? Урынлы-урынсыз күңел нечкәртүләрдән, гаҗизлектән ничек котылырга? Х. Әюповның «Олимпия уты» дигән шигырендә ике төрле ут образы тасвирлана. Берсе — сугыш уты, көйдерүче ут; икенчесе — дуслык уты. «Утка каршы ут кабыза Дөнья» — дип, шагыйрь планетадагы сугыш чукмарларына, явыз, шакшы көчләргә каршы куәтләнгән изге көрәшне хуплый. Шагыйрьнең иҗатында да көрәш утының, тормыш ялкынының көчлерәк дөрләве кирәк. Кеше җанына бары тик көрәш рухы һәм пафосы гына ышаныч, дәрт, омтылышлар бирә. Хәер, Харрас үзе дә шуңа омтыла сыман. Аның соңгы китабы лирик геройның эзләнү һәм көрәшкә дәртләнү авазы белән ябыла:

Хилаф-хаксыз эшләр кыла алмаслык
Итәм әле беркөн мин сезне;
Җаныгызга сукмак кына салыйм,
Эзләп кенә табыйм шул сүзне!..

Сәгыйдулла **ХАФИЗОВ.**

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1986 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## ПРОЗА

Батулла. **Алып батыр мажаралары.** Повесть-әкият. №№ 6, 7.
Баянов Ә. **Мәңгелек бәхәс.** Повесть. №№ 10, 11.
Бәширов Г. **И язмыш, язмыш.** Повесть. № 3.
Вәлиев Рөстәм. **Дөнья гаме.** Романнан өзек. № 4.
Галиев М. **Сатурн һәм умач.** Хикәя. № 6.
Гыйләҗев А., Литвин А. **Августның алтысына кадәр.** Роман-хроника. №№ 9, 10.
Касыймов Э. **Җир балкышы.** Роман. №№ 1, 2.
Кутуй Р. **Чатнаган көзге.** Хикәя. № 11.
Мөхәммәдиев Р. **Ачык тәрәзә.** Хикәя. № 5.
Мөхәммәдова Г. **Сикәлтәле туры юл.** Документаль повесть. №№ 11, 12.
Низамиев Р. **Матурлыкның яшәр урыны.** Повесть. № 4.
Нуруллин И. **Фатих Әмирхан.** Документаль повесть. № 1.
Тимбикова К. **Тын бакчада.** Повесть. № 12.
Фәизов Р. **Яңа күршеләр.** Хикәя. № 9.
Хафизова Р. **Әти кайткан көн.** Хикәя. № 2.
Хисмәтуллин Р. **Аягүрә.** Хикәя. № 3.
Хужин М. **Төп нигез.** Хикәя. № 8.
Хәбибуллин М. **Йөрәккә тамган яшь тамчылар.** Хикәя. № 9.
Хәсәнов М. **Язгы ажаган.** Роман. №№ 5, 6, 7, 8.
Шәкүров С. **Сәхнәнең кыл уртасында.** Повесть. № 3.
Шәмси С. **Кала-тау өне.** Повесть. № 12.
Яруллин Ф. **Кыйгак, кыйгак каз кычкыра.** Повесть. № 8.
Әхмәтов С. **«Май аенда...»** Фантастик хикәя. № 2.

## ПОЭЗИЯ

### 1986 ЕЛ — ТЫНЫЧЛЫК ЕЛЫ

Шабаев М. **Дөнья тыныч.** Шигырь. № 1.

* * *

Арсланов Н. **Уйлануылар.** Шигырьләр. № 1. **Робагыйлар.** № 10.
Афзал Г. **Тагын бер ел...** Шигырьләр. № 5.
Беляев И. **Җиңүле яшьлек.** Шигырьләр. № 5.
Вәлиуллин Р. **Шигырьләр.** № 11.
Ганиева И. **Тамчылар.** Шигырьләр. № 3.
Гатауллин Р. **Безнең муза.** Шигырьләр. № 3.
Гыйззәтуллина Ф. **Киңәшүләр кирәк.** Шигырьләр. № 7.
Гәрәева С. **Урал җиле.** Шигырьләр. № 8.
Зарипов Н. **Киттек.** Шигырьләр. № 11.
Зәйдуллин Р. **Күпер.** Поэма. № 5.
Игәнәй Я. **Тарихның нәни ярчыгы.** Шигырьләр. № 7.
Измайлова Н. **Бер диңгез мәхәббәт.** Шигырьләр. № 1.
Камалов Х. **Яңа шигырьләр.** № 5.
Каюмов М. **Канатлар.** Шигырьләр. № 8.
Латыйп Г. **Зәңгәр ялкын.** Шигырьләр. № 11.
Мадъяров Н. **Кырлар тулып.** Шигырьләр. № 11.
Мансуров З. **Ярымшарлар.** Шигырьләр. № 10.
Мингалим Р. **Җыр канаты.** Шигырьләр. № 6.
Миңнуллин Р. **Марафон.** Шигырьләр. № 6.
Моратов Г. **Теләк.** Шигырьләр. № 7.
Муллагалиев С. **Бер яктылык.** Шигырьләр. № 11.
Мәхмүдов Ә. **Атакага бара шигырьләр.** Шигырьләр. № 9.
Мөэминова Э. **Үз даһиең санап.** Шигырь. № 4.
Рәшитов Ә. **Автопортретка штрихлар.** Поэма. № 3.
Сафин Ф. **Мәхәббәтнең бәхет кичендә.** Шигырьләр. № 11.
Сибгатуллин К. **Җырлый-җырлый.** Шигырьләр. № 1.
Фәйзуллин Р. **Язуларга теркәлмәгән сүзләр.** Шигырьләр. № 7.
Халиков Х. **Минем бабай.** Шигырьләр. № 9.
Харис Р. **Тузга язганнардан.** Шигырьләр. № 8.
Хисмәтуллин Р. **Сабан туена!** Шигырьләр. № 9.
Хәким С. **Айгыр уты.** Шигырьләр. № 12.
Шакирҗанова Л. **Ике хәбәр арасы.** Шигырьләр. № 3.

Шәйхи М. **Иделләрем, илләрем.** Шигырьләр. **№ 10.**
Шәрифуллина Э. **Сөю каршында.** Шигырьләр. **№ 12.**
Әхмәтҗанов Рәшит. **Күпер уртасы.** Шигырьләр. **№ 8.**
Әхмәтҗанов Роберт. **Тукайның соңгы рәсеме.** Шигырьләр. **№ 9.**
Әхсәнов И. **Яктырдың чорга, замандаш.** Шигырьләр. **№ 10.**
Әюпов Х. **Яшен вакытында язылган шигырь.** Шигырьләр. **№ 6.**

## ДРАМАТУРГИЯ

Хәмид Р. **Майның унбишләрендә.** Драма. **№ 11.**
Юзеев И. **Сөйгәнемнең туган көне.** Трагикомедия. **№ 7.**

## ОСТАХАНӘ

Гайфуллина А. **Уйларны ирекә чыгарам.** Шигырьләр. **№ 9.**
Баянов Э. **Яңа исем — яңа сүз.** А. Гайфуллина шигырьләре турында. **№ 9.**
Садыйков З. **Тавык боты.** Сатирик хикәя. **№ 7.**
Бәширов Г. **Җаваплылык сизеп.** З. Садыйков хикәясе турында. **№ 7.**

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Корбанов Р. **Сандугачлы таллар.** Шигырьләр. **№ 1.**
Хәйруллин Д. **Сорау...** Шигырьләр. **№ 1.**

## АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

Ишморатова Р. **Кичке җидедән соң.** Пьеса. **№ 6.**
Нури З. **Куркыныч кунак.** Шигырьләр. **№ 7.**
Саттаров М. **Әлкәш Ибрай бәете. № 10.**
Хафизов С. **«Яшел елан»га каршы. № 3.**
Хәсәнов А. **Кагылмый?** Хикәя. **№ 1.**

## ФОЛЬКЛОР

**Себер татарлары экиятләре. № 8.**

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Агивер Х. **Баллы мыек.** Хикәя. **№ 5.**
Афанасьев П. **Тизлек.** Шигырь. **№ 5.**
Васин К. **Җыр шулай туды.** Легенда. **№ 12.**
Галкин А. **Иделдә.** Шигырь. **№ 5.**
Давыдов-Анатри В. **Нигә елый каен?** Шигырь. **№ 5.**
Енеш В. **Ирләр булыйк.** Хикәя. **№ 5.**
Исламов Ф. **Тарихи бергәлек. № 5.**
Максимов Н. **Имтихан.** Хикәя. **№ 5.**
Матвеева Н. **Охшаш хәлләр.** Хикәя. **№ 12.**
Мусаев М. **Акчарлак.** Хикәя. **№ 12.**
Ухсай Я. **Мине татарга саныйлар.** Шигырь. **№ 5.**
Семендер Ю. **Пинерби.** Шигырь. **№ 5.**
Сәрби Р. **Ялвару.** Шигырь. **№ 5.**
Юхма М. **Ай юлы.** Шигырьләр. **№ 5.**

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

### КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Ермаков В., Зарипов М. **Үрдән-үргә. № 1.**
Сәгытдинов Э. **Җир баласының бәхете. № 2.**

### КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Бәдретдинов Х. **Җиде мең төрле борчак. № 5.**
Зарипов М. **Мәңге яшел агач җимеше. № 8.**
**Иңнәрендә ил гаме. № 11.**
Кожевников Ю. В. **Вузның иртәгәге көне. № 10.**
Мөхәммәтшин Г. **Балтачлылар үрнәгендә. № 3.**
Уманская Л. **Җиңүчегә — чәчәк бәйләме. № 8.**
Хәсәнов А. **Бал дисәң. № 7.**
Шәрипов В. **Яңа гасыр тракторы. № 11.**
Әйди Т. **Һөнәрле Әләзән. № 9.**

### МӘКТӘП РЕФОРМАСЫ: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Мөэминова Э. **Дәвам. № 9.**

### ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Бакиров Н. **Туфрак туганнары без** (Әлки). **№ 5.**
Баһрамов Н. **Әгерҗегә килегез. № 6.**
Галиев Р. **Нефтьчеләр үзәге** (Әлмәт). **№ 3.**
Гыйләҗев М. **КамАЗ куенында** (Тукай районы). **№ 4.**
Зарипов Р. **Нурминкәнең көмеш суы** (Кукмара). **№ 1.**
Захаров Б. **Җаваплылык арта** (Бөгелмә). **№ 9.**
Зәйнуллин И. **Буа районы. № 2.**
Кәримов З. **Аксубайлыларның йөзе ак** (Аксубай). **№ 10.**
Мөхетдинов О. **Чатыр-тауга чал кунмый** (Азнакай). **№ 12.**
Сибгатуллин Ф. **Үргә күтәрелгәндә** (Мамадыш). **№ 8.**

Тәхәветдинов Ш. **Үсү юлыннан** (Лениногорск). **№ 7.**
Әхмәтов М. **Үсеш, ярыш еллары** (Балтач). **№ 11.**

## ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Бибишев М. **Кешеләр хакына. № 6.**
Морозов Н. **Бәрелешләр аша. № 12.**
Низамов И. **Нигез салганда. № 9.**
Әмирханов М. **Низаг. № 1.**
Әмирханов М. **Беренче председатель. № 10.**

## БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Бәйрәмова Ф. **Көрәш. № 6.**
Вәлиев Д. **Саер кешеләр. № 7.**
Гәрәева С. **Тормышка гашыйк. № 3.**

* * *

Гәрәй Р. **Туган җир куенында. № 5.**
Елизарова М. **Бөгелмә егете. № 3.**
Фәйзуллин Р. **Хуш, Италия! Исәнме, Ватан! № 12**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. **Тәнкыйтьчеләр. № 11.**
**Киләчәк бүген башлана.** Г. Төхватов белән М. Вәлиев әңгәмәсе. **№ 6.**
Мансуров З. **Йөрәк бәйрәме. № 2.**
Мостафин Р. **Язучы һәм телевидение. № 6.**
Рәхим Г. **Туган ил хисе. № 9.**
Сверигин Р. **Замандашлар бәхетен кайгыртып. № 7.**
Юныс М. **Исәннәрнең кадерен бел. № 8.**
**Яңалык — тормышта һәм әдәбиятта.** Яшь тәнкыйтьчеләр әңгәмәсе. **№ 10.**

## ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

Дементьев В. **Хәсән Туфан чәчәкләре. № 11.**
Налепин А. **Яшәү белән үлем арасында. № 9.**

## ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Сафаров Р., Леронов Л. — **№ 2.**
Рафиков М., Кукушкин Р. — **№ 3.**
Арсланов Н., Юсупов Р. — **№ 5.**
Хәмидуллин Л., Баянов Ә. — **№ 6.**
Исхак Ә., Гатауллин Р. — **№ 7.**
Садриев Ф., Мөхәммәтшин Г. — **№ 8.**
Яруллин Ф., Вәлиева В., Миңнеханов И. — **№ 9.**
Ахунов Г., Каюмова Ф. — **№ 10.**
Мәһдиев М., Сафарова Г., Нәбиуллина Н., Хәмзин К. — **№ 11.**
**Тормыш таләбе.** Әдәби тәрҗемә турында сөйләшү йомгаклары. **№ 12.**

## БИБЛИОГРАФИЯ

Абилов Ш. **Бөек шагыйрьнең үлемсез әсәре. № 2.**
Бажанова В. **Театрлар дуслыгы. № 11.**
Бакиров М. **Әдәбиятыбыз тарихына яңа адым. № 7.**
Гайнетдинов М. **Туганлык тамырлары. № 12.**
Камалов Б. **Биеклек. № 1.**
Морадымов Н. **Хезмәттәшлек җимешләре. № 12.**
Мостафин Р. **Зиннәтле сүзләр хәзинәсе. № 12.**
Мәхмүтов Х. **Эпосны өйрәнүдә яңа адым. № 10.**
Мөхәммәдиев Р. **Шагыйрьлекнең ике канаты. № 8.**
Саттарова Л. **Сынлы сәнгать елъязмасы. № 3.**
Фәйзуллаева М. **Еллар һәм җырлар. № 3.**

## РЕЦЕНЗИЯЛӘР КОНКУРСЫНА

Галимуллин Ф. **Тормышны ярату. № 10.**
Кукушкин Р. **Шигъри күперләр остасы. № 6.**
Зөлкарнәев Ф. **«Көмеш чылбыр» боҗралары. № 9.**
Сәхапов Ә. **Кемнәр алар — «һәм башкалар»? № 8.**
Фәсиев Ф. **Кульъязма мирасыбыз сәхифәләре. № 5.**
Хатипов Ф. **Яшәеш гаме. № 5.**
Хафизов С. **Җаныгызга сукмак салыйм. № 12.**

## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

**Гомәр Бәшировның «И язмыш, язмыш» повесте турында фикерләр. № 10.**
Диндаров И. **Мәхәббәт һәм шигърият. № 3.**

## СӘНГАТЬ

Бәхтиярова Ч. **Музыка сарае.** Казан дәүләт консерваториясенең 40 еллыгына. **№ 1.**
Латыйпов К. **Көндезге яктылык. № 11.**
Салихова З. **Халыкчанлык тамырлары. № 7.**
Хөснетдинов Р. **Моң чишмәсе № 3.**
Шәрифуллина Э. **Бергә гомергә. № 8.**
Әйди Т. **Дәверләрне буйлап — киләчәккә. № 3.**
Әһлиуллина Ф. **Җанлы учак.** Р. Таҗетдинов турында документаль хикәя. **№ 10.**

## ЯЗУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Арсланов Н. **Якын дуслар идек.** № 11.

## ТАРИХЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Алишев С. **Батырша батырлыгы.** № 2.
Ионенко И. **Штаб офицеры язмалары.** № 9.
Юсупов М. **Беренче рус революциясендә татар хатын-кызлары.** № 3.

### ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Мусин Ф. **Күркәм бәйрәмебез.** № 1.
Шамов А. **Үтәлми калган теләк.** № 3.

### КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я., Госманов М., Таһиров И. **Һади Атласи турында.** № 11.
Арсланов Л. **Кемнәр алар «Әстерхан каракалпаклары»?** № 10.
Боголюбов М. **Профессор Таһирҗанов.** № 2.
Зәйнуллин Ж. **Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе һәм «Кәлилә вә Димнә» турында.** № 11.
Ибраһимова Ф. **Мәгърифәт йорты.** № 8.
Кочкина А. **Идел буе болгарларында рун язуы.** № 11.
Курбатов Х. **Археолог А. Кочкинаның «Идел буе болгарларында рун язуы» исемле мәкаләсенә карата.** № 11.
Михайлова С. **Халык мәгарифен әйдәүче.** № 6.
Фәрхетдинова Х. **Моңлы гомер.** № 11.
Червонная С. **Җәүһәрләргә тузан кунмасын.** № 8.

### БЕР ГИПОТЕЗА

Фәттах Н. **Фест дисбесенең сере.** № 5.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Арипов А. **Тукай хакында сүз.** № 12.
Бабуглы Н. **Шагыйрь.** Шигырь. № 12.
Бохараев Р. **Тукай тирәсендә.** Драматик повестьтан өзек. № 4.
Ваһабзадә Б. **Сабир һәм Тукай.** № 4.
Вәлиев Рөстәм. **Дөнья гаме.** Романнан өзек. № 4.
Гайнанова Л. **Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы.** № 4.
Гатауллин Р. **Тукай сагындыра.** Шигырь. № 4.
Доризо Н. **Шагыйрь генә түгел.** № 12.
Зәбиров Х. **Казанда Тукай урыннары.** № 4.
Исхаков Б. **Тукай һәм казах әдәбияты.** № 10.
Каһһари Т. **Габдулла Тукай һәм уйгур әдәбияты.** № 7.
Кочетков В. **Шигъри причалда.** Шигырь. № 4.
Кошечкин С. **Күңелдәге йолдыз.** № 12.
Кәрим М. **Олуг Тукай турында.** № 12.
Мостафин К. **Белсә иде, белсә иде!** Шигырь. № 4.
Мәһдиев М. **Шагыйрьнең бишеге.** № 6.
Мөхәммәдева Г. **Тукай Әстерхан зыялылары арасында.** № 7.
Нәфиков Р. **Тукайның дусты, партия солдаты.** № 2.
Нәҗми Н. **Шигърият йолдызы.** № 4.
Огнецвет Э. **Рухи кардәшлек.** № 4.
Плисецкая М. **Гүзәл һәйкәл.** № 4.
Рәсүлева З. **Тукай шәҗәрәсе.** № 4.
Сеитов С. **Тукай турында уйланулар.** Шигырь. № 4.
Таһир Г., Надиров Н. **Бәрәкәтле хәрәкәт.** № 4.
Төхфәтуллин Р. **Кырлайга сәяхәт һәм самавыр йөзлегенә язылган шигырь.** Истәлек-хикәя. № 3.
Фатыйхов Ә. **«Туган илем Кожамакты карьясендер».** № 7.
Хаҗиәхмәтов Т., Мәһдиев М. **Кушлавыч.** № 1. **Өчиле.** № 2. **Сасна.** № 3. **Кырлай.** № 4.
Хәким С. **Тукай дәфтәреннән.** № 4.
Хәсәнов Мансур. **Тукайның бөеклеге.** № 4.
Хөснуллин К., Әхмәтов Р. **«Җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле».** № 4.
Шаһиева Р. **Тукай һәм сынлы сәнгать.** № 3.
Шәңгәрәев Ф. **Кымызга бару юлында.** № 10.
Якупов Р. **Тукай-Кырлай, 1986 ел.** Фотохикәя. № 10.
Әгъзәмов Ф., Гыйльметдинов Р. **Әдипнең матбугатка карашлары.** № 2.
Әгъләмов М. **Тукайдан хатлар.** Поэма. № 2.
Әхәтов Г. **Сүз эчендә энҗе бар...** № 4.
Әюпов Х. **Бер иңдәге.** Шигырь. № 4.

### Ф. ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Вәлиев Н. **Әдип көлә.** № 1.
Гобәйдуллин Х. **«Әльислах»чы Гарифҗан Мостафин.** № 1.
Гомәрев Х. **Фатих Әмирхан — Әстерханда.** № 1.
Дәүләтшин Г. **Ф. Әмирханның кульязма мирасы.** № 1.
Мәһдиев М. **Яңа Бистә Прометее.** № 1.
Нуруллин И. **Фатих Әмирхан.** Документаль повесть. № 1.
Расих А. **Фатих Әмирхан хаты.** № 6.
Әмирханова З. **Абыем турында.** № 1.
Әхмәтҗанов М. **Ф. Әмирхан архивыннан.** № 1

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Апакаев П. **Лачыннар канат ныгыта.** № 2.
Дементьев В. **«...Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә!»** № 2.
Еники Ә. **Муса Җәлил хатлары.** № 2.
Зәйдуллин Р. **Җәлил кояшы.** Шигырь. № 2.
Моратов Г. **Җәлил һәйкәле янында уйлану.** Шигырь. № 2.
Мостафин Р. **Муса Җәлил турында.** № 2.
Рафиков М. **Ике сын.** Шигырь. № 2.
Хамматов Ш. **Нигез ташларын салганда.** № 2.
Хәсәнов М. **Идел һәм Муса.** Истәлек. № 2.
Шәмсетдинов Н. **Тынлык — набат.** Шигырь. № 2.

## ТАТАР ТЕАТРЫНА 80 ЕЛ

Гыйззәт Б. **Нигез ташларын салганда.** № 11.
Илялова И. **Халык хезмәтчесе булу.** № 12.
Тинчурин К. **Мулланур иптәш Вахитов һәм татар театры.** № 12.

• • •

Абилов Ш. **Язучы мирасында ниләр бар?** Г. Минскийның туувына 80 ел. № 9.
Бәширов Г. **Аның тылсымлы көче.** С. Садыйкованың тууына 80 ел. № 11.
Газизов Р. **Кариев турында белгәннәрем.** Г. Кариевның тууына 100 ел. № 5.
Гафиятов А. **Печән өсте.** К. Булатовага — 50 яшь. № 3.
Кайбицкая Г. **Бөек иҗатчы рухы.** 80 яше тулу уңаеннан. № 5.
Кукушкин Р. **Матурлык сагында.** Г. Шәрәфигә 60 яшь. № 9.
Маликов Ә. **Сәҗидәгә хатлар.** С. Сөләймәнованың тууына 60 ел. № 10.
Низамиев Р. **Иҗаттагы егет чак.** Р. Кутуйга 50 яшь. № 11.
Сәйдәшева З. **Халык дөньясын сөеп.** А. Ключаревның тууына 80 ел. № 3.
Хаков В. **Күңел кылларын тирбәтүче.** 60 яше тулу уңаеннан. № 9.
Хәйруллин Ш. **Атаклы якташым.** Г. Кариевның тууына 100 ел. № 5.
Хәйруллин Ә., Хәбибуллин Ф. **Татар театрының рухы.** Г. Кариевның тууына 100 ел. № 5.
Хәким С. **Халык хәзинәләрен ачучы.** Ф. Урманчеевка 50 яшь. № 5.
Шабаев М. **Ул — август йолдызларыннан.** Ф. Г. Лорканың һәлак булуына 50 ел. № 8.
Шакир С. **Демьян Фәтхи.** 80 еллыгына. № 11.
Эйди Т. **Өметне аклаган каләм.** А. Расихка 70 яшь. № 9.
Әхмәтов Р. **Шәмдәлләрдә якты утлар...** Г. Чокрыйның тууына 160 ел. № 11.

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Гомәрова Р. **Өйгә тынычлык теләү.** № 3.
Горшунов Ю. **Театрга нигез салучылар.** № 5.
Горшунов Ю. **Август, икмәк...** № 8.
Горшунов Ю. **Җир хуҗалары.** № 11.
Ключаревская Е. **Сабан туе — хезмәт туе.** № 6.
Коробцова Л. **Җәлилнең лирик портреты.** № 2.
Коробцова Л. **Чәйгә чакыру.** № 12.
Коробцова Л. **Чәчәк вакыты.** № 7.
Седых Т. **Көз мәле.** № 10.
Цой В. **Шигъри пейзаж остасы.** № 1.
Цой В. **Мәңгелек яз юлдашы.** № 4.
Цой В. **Нигез.** № 9.

• • •

**Бер сорауга — бер җавап.** №№ 4, 5, 10.

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары.** № 3.

**Кызыклы хәлләр.** № 8.

**Культура тормышы көндәлеге.** №№ 1—12.

## ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

15 октябрьдә Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында башкала җәмәгатьчелеге вәкилләре татар халкының бөек улы, күпмилләтле Ватаныбыз һәм дөнья әдәбиятының күренекле шагыйре, халыклар дуслыгы җырчысы Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичәгә җыелды.

Президиумда — КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге мөдире Ю. П. Воронов, РСФСР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары Ф. Ә. Табеев, КПСС Үзәк Комитетының Пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары Н. Б. Биккенин, КПСС Үзәк Комитетының Пропаганда һәм агитация бүлеге секторы мөдире Г. А. Зюганов, РСФСР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары Т. Г. Иванова, КПСС Үзәк Комитетының Оештыру-партия эше бүлеге инструкторы В. П. Пичугин, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге инструкторы Н. Н. Митрофанов, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев, РСФСР Культура министры урынбасары А. И. Шкурко, СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләре секретарьлары, башка иҗат союзлары һәм оешмалары җитәкчеләре, язучылар, КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, ТАССР культура министры М. М. Таишев.

Кичәне кереш сүз белән Г. Тукайның тууына 100 ел тулу бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча Бөтенсоюз юбилей комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе председателе, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Г. М. Марков ачты.

Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗат юлы турында Татарстан АССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов сөйләде.

Социалистик Хезмәт Герое, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков, Казахстан ССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре О. О. Сөләйманов, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин Г. Тукайның үлемсез иҗаты турында сөйләделәр.

Кичәнең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

## ТАТАРСТАН РӘССАМНАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫ

9 октябрьдә Казанда Татарстан рәссамнарының V съезды булды.

Татарстан Художниклар союзы идарәсенең отчет чорындагы эшчәнлеге турындагы доклад белән Татарстан Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев чыкты.

Доклад буенча фикер алышуда рәсем сәнгате секциясе җитәкчесе А. Н. Мәҗитов, «КамАЗ» иҗат группасы җитәкчесе В. Я. Акимов, РСФСРның атказанган художнигы И. К. Зарипов, ТАССР Художниклар союзының партия оешмасы секретаре Е. Г. Голубцов, Чувашия АССР Художниклар союзы идарәсе председателе урынбасары С. И. Мадуров, РСФСРның халык художнигы Б. И. Урманче, скульптура секциясе җитәкчесе В. И. Маликов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин, СССРның халык художнигы, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты Х. А. Якупов, ТАССР Госстрое председателе Р. С. Насыйров, РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре Н. Ф. Новиков, ТАССР Художниклар союзы каршындагы яшьләр берләшмәсе җитәкчесе Ф. Х. Якупов һ. б. катнаштылар.

Татарстан рәссамнары съездында КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты, РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре, «Зур Идел» зона күргәзмәсен оештыру комитеты председателе В. Ф. Жемерикин, иҗат союзлары һәм оешмалары җитәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, күрше республика һәм өлкәләрдән килгән кунаклар катнашты.

ТАССР Художниклар союзының яңа идарәсенең беренче утырышы булды. Иҗат союзы идарәсе председателе итеп РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты В. М. Маликов сайланды. Татарстан Художниклар союзы идарәсе председателе урынбасарлары итеп РСФСРның атказанган художнигы И. К. Зарипов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты В. Н. Скобеев һәм А. А. Абзгильдин сайланды. Ревизия комиссиясе председателе итеп ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. К. Федоров сайланды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

13 октябрьдә балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда

нәниләр өчен берничә китап язган яшь язучы Фарсель Зыятдинов иҗаты тикшерелде. Аның иҗаты турында шагыйрь Р. Мингалимов сөйләде.

23 октябрьдә поэзия секциясенең чираттагы утырышында шагыйрь Эдуард Мостафин иҗаты турында фикер алышу булды.

Э. Мостафин иҗаты турында аксакал шагыйрь Н. Арсланов доклад сөйләде. Фикер алышуда шагыйрьләр Р. Гатауллин, Ә. Рәшитов, Б. Сөләйманов, М. Әгъләмов, М. Галиев, Зөлфәт, Н. Акмалов һәм тәнкыйтьче Мансур Вәлиев чыгыш ясап, шагыйрь иҗатының җитлеккән һәм талантлы иҗат булуын билгеләп үттеләр, кайбер кимчелекләренә тукталдылар. Э. Мостафин СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим ителде.

## ЖУРНАЛ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

23 сентябрьдә Әлмәттә Нефтьчеләрнең культура һәм техника сараенда «Казан утлары» журналы укучылары белән иҗади очрашу үткәрелде.

Очрашуны КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Ф. Х. Мөхәммәтов ачып җибәрде.

Әдипләрдән Г. Афзал, Ш. Бикчурин, М. Хәсәнов, Ә. Гаффар, К. Булатова «Казан утлары» турындагы фикерләре белән уртаклаштылар, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Журналның баш редакторы урынбасары Р. Мөхәммәдиев һәм проза бүлеге редакторы Р. Низамиев «Казан утлары»ның якындагы планнары хакында сөйләделәр, укучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирделәр.

Әдәби бәйрәмгә әверелгән бу кичә Әлмәт үзешчәннәре концерты белән тәмамланды.

24 сентябрьдә Азнакай районы культура йортында язучы Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде.

«Казан утлары» журналының быелгы саннарында басылып чыккан бу роман укучыларда зур кызыксыну уяткан. Медсестра Җ. Мөхәммәтова, пенсионерлар Н. Яруллина һәм Б. Габидинова, китапханә хезмәткәрләре Л. Таҗиева, Г. Харисова һ. б. күп кенә иптәшләр әсәрне яратып укулары, андагы геройларның тормышчан булуы, теленең халыкчан булуы турында сөйләделәр.

Роман авторы М. Хәсәнов, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары язучы Р. Мөхәммәдиев һәм проза бүлеге редакторы Р. Низамиев укучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирделәр, әдәбият һәм тормышның актуаль проблемаларын кузгаттылар.

2 октябрьдә Брежнев шәһәренең «Энергетик» культура сараенда «Казан утлары» журналына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

Брежневта яшәп иҗат итүче К. Сибгатуллин, Я. Игәнәй, прозаик Г. Кашапов, Алабуга дәүләт педагогия институты профессоры Г. Әхәтов һ. б. «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

Кичәдә Казаннан килгән язучылар — «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Салих Маннапов, редколлегия члены М. Маликова, проза бүлеге редакторы Т. Әйди катнашты һәм чыгыш ясады.

Соңыннан Брежнев шәһәре үзешчәннәре көче белән концерт күрсәтелде.

## ҖӘЙГЕ ГАСТРОЛЬЛӘР

Июль аенда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры илебез башкаласы Мәскәүдә үзенең гастрольләрен уздырды.

Гастрольләр Мәскәүнең оперетта театрында һәм Кремльнең Съездлар сараенда зур уңыш белән барды.

Милли репертуар составында Н. Җиһановның яңа редакциядәге «Җәлил» операсы, Б. Мулюковның халык музыкаль драмасы «Кара йөзләр», Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе һәм Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты бар иде.

Август аенда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Кыргызстан һәм Казахстанда җәйге гастрольләре булып узды. Айның беренче яртысында театр коллективы Кыргызстанның Фрунзе, Ош шәһәрләре һәм тирә-яктагы якын районнарда яшәүчеләргә үзенең спектакльләрен күрсәтте, иҗади очрашулар уздырды.

Казахстанның башкаласы Алма-Ата шәһәрендә күрсәтелгән спектакльләр күп меңләгән тамашачылар өчен зур сәнгать бәйрәменә әйләнде.

Театр репертуарында К. Тинчуринның «Казан сөлгесе», Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз», «Әниләр һәм бәбиләр» һәм башка спектакльләр бар иде.

## ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯДӘ

15—21 сентябрьдә Ташкент шәһәрендә Даими халыкара алтаистик конференциянең XXIX сессиясе булып узды. Анда Советлар Союзыннан һәм дөньяның башка күп кенә илләреннән Алтай семьялыгына кергән торган халыкларның телен, тарихын, этнографиясен, культурасын, әдәбиятын, фольклорын өйрәнүче галимнәр җыелган иде. Алтай семьялыгына керүче халыкларның берсе булган татар халкының теле, тарихы, әдәбияты һәм фольклорына караган мәсьәләләр дә байтак докладларда үзәк урынны алды.

Татарстан гыйльми делегациясендә профессорлардан М. З. Зәкиев, Д. Г. Тумашева, Ф. Э. Ганиев, Р. А. Юналиева кебек тел галимнәре, әдәбиятчы Н. Ш. Хисамов, фольклорчы Ф. И. Урманчиев, сәнгать белгече Г. Ф. Вәлиева-Сөләйманова бар иде.

# ЧӘЙГӘ ЧАКЫРУ

Нәкыш ысулы белән эшләнгән натюрмортлар рәссамнарыбызның иҗат хәзинәсендә шактый очрый. Әмма турыдан-туры шушы жанрга гомерләрен багышлаган осталар бармак белән генә санарлык. Халык традицияләренең шигъри асылын кабатланмас рәвештә ачып бирүче натюрмортларны барлаганда, Р. Килдебәков, И. Зарипов, С. Неустроев, В. Зуев кебек рәссамнарның әсәрләре күз алдына килә. Сурәтләнешләре ягыннан аерылып торучы әлеге натюрмортларда бер уртаклык сизелә: халык поэтикасына тамыр җибәргән декоративлык. Шушы ук сыйфатны без В. Поповның «Чәйгә чакыру» дип исемләнгән әсәрендә дә ачык күрәбез.

Индустриаль темалар өстендә актив эшләүче рәссамның натюрмортларында «монументаль фикерләү» алымының чагылуы бик табигый. Автор монда да үзе булып кала. Полотнода сурәтләнгән предметлар ничектер зураеп киткән шикелле тоела. Самавыр, чокыр-чынаяк, ваза... Һәрберебезгә таныш булган гадәти әйберләр. Әмма алар көндәлек сүзләр белән аңлатып бирә алмаслык тантаналы аһәң тудыралар. Әлеге тойгы халыкта ризык өстәлен олылаудан киләдер.

Гөбәдия, өчпочмак, чәкчәк, кош теле... Татар хатыннарының аш-су хәзерләү осталыгын чагылдыручы әлеге «персонажлар» күз явын алырлык төсләр белән балкучы картинага тәгәлләнгәнлек бирeп торалар. Форма, фактура, төсләр бирелеше ягыннан рәссам шактый камил дәрәҗәдәге бөтенлеккә ирешкән. Табында артык әйбер булмаган кебек, полотнода да кирәксез детальләр күренми. Кыскасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Владимир Попов «Чәйгә чакыру» исемле натюрмортында халыкның кунакчыллыгын, ризыкны һәрвакыт олылавын һәм шулай ук бүгенге тормышыбызның көннән-көн матурлануын чын сәнгать югарылыгында гомумиләштерүгә ирешкән.

**Людмила КОРОБЦОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында драматург Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» исемле пьесасы буенча куелган спектакльдән күренеш. Габдулла Тукай ролендә — артист Илдус Әхмәтҗанов.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе Цена 90 тиен. коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)